# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

# БЕЗНЕҢ КӨННӘР

*Роман*

## I

Төн караңгы, дөнья тын, ләкин диңгез шаулый, диңгез түбәндә кемгәдер ачулы шикаять белән үкеренә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек ташлы текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагы бер-ике атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр... Ләкин сезгә куркыныч юк, дулкын никадәр дәһшәтле булса да, ул сезнең биек тау итәгендәге ятагыңызга килеп җитә алмаячак. Сезгә тыныч булырга: тәрәзәңезне ачып, диңгез тавышын тыңларга да, соңра рәхәт-рәхәт йокыңызны дәвам иттерергә мөмкин.

Олуг Русия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыны да мәмләкәтнең караңгы почмакларында яшәгән безнең халкыбызга башта шулай тоелды.

Кайдадыр хөкүмәт белән халык сугыша... Кайдадыр урамнарда баррикадалар ясала, киң мәйданнар адәм үлекләре белән тула… Кан дәрьялар булып ага... Ләкин ул әллә кайда, еракта... Монда аның куәтле шаулавы ишетелеп, йөрәккә бераз шом сала. Тик шулкадәр. Әмма дулкын үзе килеп җитә алмаячак. Халык тыныч булырга, тарих белән килгән иске яшәвен рәхәтчә бардырырга мөмкин ..... Һәм шулай, мондагы хәят үзенең иске эзеннән акрын гына акмакта да.

Тик менә көннән-көн каралана барган төрле хәбәрләр генә, ничектер, җанны бераз борчыйлар, хыялда куркынычлы сурәтләр тудырып, йөрәккә бераз әндишә[1] салалар.

Ул дулкын башта бер дә искитәрлек нәрсә түгел иде. Ниндидер студентлар, укып-укып, эшкә аша алмаганнар да инде ачудан фетнә чыгаралар. Бу бик гади, бик табигый иде. Ләкин хәбәрләр моның белән тукталмады. Һәрбер көн халык хыялындагы куркыныч сурәтне зурайта бара, барган саен, хәбәрләрнең куркынычы арта. Менә-менә кояш батышыннан күтәрелгән куркыныч кара болыт тиз арада бөтен күк йөзен каплап алачак та, коточкыч күкрәүләр, яшьнәүләр башланачак...

Элек, азган студентлар, диләр иде. Бара торгач, мәйданга яңа бер халык килеп чыкты. Ни диләр үзләрен – социалистмы, кемме, диләр. Бер кулларында бомба, җәһәннәм машинасы, икенче кулларында кызыл флаг улдыгы хәлдә, болар дөньяга яңа дәһшәтләр тудыра башладылар.

---

[1] *Әндишә* – шик, курку, шом.

Менә пайтәхетнең эшчеләре кузгала, дөньяга “эш ташлау” дигән яңа бер сүз туа. “Хөррият! Хөррият!” диләр, шуның юлында заводлар ябыла, фабрикалар бөлә, тимер юллар туктый... Кемнәр – барачак, кемнәр кайтачак юлында яртылыкта кала... Ул арада дулкын авылларга да барып җитә. Кичә үзенең бояры алдында егылып сәҗдә итмәктә булган крәстияннәр бүген алпавытның йирен талый, утарын яндыра, урманын кисә, белмим, тагын ниләр кыла... “Хөррият! Хөррият!” диләр, бу сүз телләрдә тәсбих урынында йөри. Шуның белән бергә үк бүген полицмейстерга, иртәгә губернаторга, соңра министрга ташланган бомба тавышларыннан шәһәрләр дәһшәт белән тула. Талаулар гади эшкә әйләнә. Бүген почтадан йөз меңне басалар. Иртәгә банк хәзинәсеннән ярым миллион талана... Икенче яктан зинданнар яңа тоткыннар белән тула, мәйданнарда үзенең шомлы кыяфәте белән күккә сузылган дар агачлары һәм иблис йөзле, кызыл якалы җәлладлар үзләренең корбаннарын көтәләр... Мәмләкәт күге караңгы болыт белән каплана, менә тиз арада күк күкрәячәк, яшен яшьнәячәк тә хәят, белмим, нинди куркыныч сәгатькә киләчәк...

Ул көннәр вакыйгаларның яшен тизлеге белән кузгала торган заманы иде. Кайдадыр, еракта, күтәрелгән шундый куркыныч дулкынның шаулавын ишетеп, бу шәһәрнең аңардан әмин[1] булуы, үзенең шул дәһшәтле йирдә яшәмәве өчен, Тәңрегә шөкрана кылмакта булган халкыбыз да, ниһаять, яшеннең якынаеп килгәнен сизенә башлады.

Тыныч яшәргә өйрәнгән җаннар кинәт сискәнеп китә:

– Йа Ходай!.. Әллә безгә дә килеп җитәме?!

Җитә, җитә, канлы дулкын бу шәһәрне дә баса, үзе еракта булып, куркыныч сурәте белән хыялда торган революция аждаһасы боларны да йотарга якынлаша...

Шәһәрдә ниндидер ят адәмнәр күргәннәр. Һәр көн иртә белән каланың төрле урамнарында зәңгәр кара белән язылган кәгазьләр табалар.

Анда: “Күп йокладык, инде уяныргa вакыт!!!” – дип язылган, ди.

Нинди йокы!

Нинди йокы!

Халык бу хакта уйларга өлгерә алмый, шәһәрдә “эшчеләр берлеге” дигән яңа бер сүз туа: имеш, каланың бөтен эшчеләре берләшәчәкләр дә губернатор каршысына барачаклар, нидер сораячаклар, бирелмәсә, имеш, эш ташлаячаклар...

Бу хәбәр башта көлке күренде:

– Менә мәҗнүннәр!.. Менә җүләрләр!!! Барсыннар, ташламагае,

[1] *Әмин* – тыныч.

кадалып китсеннәр, дөньяда эшчедән күп нәрсә юк: берсе ташласа, унысы килер, байга барыбер. Ә болар бала-чагалары белән ачтан үләрләр...

Ләкин ул заман вакыйгалар язгы ташкын кызуы белән агалар иде. Халык шул югарыгы уе белән җуанып бетә алмый, шәһәрдәге завод-фабрикаларның берәм-берәм туктавы сөйләнә башлый, шуның артыннан ук "водопровод" туктаячак, кич электриклар сүнәчәк, бөтен күмәч эшчеләре эш ташлаячак: шәһәр бер вакытта судан, икмәктән, яктыдан мәхрүм калачак, дигән бер ихтимал телләргә алынып, халыкны бөтенләй каушатып төшерә... Инде ышанмау да кыен. "Алар" моңарчы идән астыннан эшлиләр, якты дөньяга тик шул зәңгәр язулы кәгазьләре генә чыга иде. Менә өченче көн инде "үзләре" дә күренделәр.

Халык бераз аптырап калды:

– Бу ни гаҗәп!.. Араларында һичбер коточкыч әйбер күренми... Бар да безнең кебек ике аяклы, ике күзле нәрсәләр... Тик бик күпләр дә бик усаллар... Киң урамнарны иңеннән буена тутырып, юлыннан язган зур елга кебек агылып йөриләр. Алларында кызыл байрак бара. Бара торгач, бер җиргә туктыйлар да араларыннан берсен югары күтәрәләр. Ул, кулындагы кызыл байрагын селкә-селкә, кызып, нидер сөйли; бөтен мәйдан дөнья күтәреп шаулый, аңар "ура" кычкыралар... Шундый бөтен шәһәрне күтәрәчәк кебек тоелган тавыш белән беркөн губернатор каршысына бардылар. Талаш, кычкырыш, шау-шу китте. Гаскәр белән атыш башланды. Ниләр булганын Ходай белсен, яралыларның исәбе-саны юк, үлгәннәр кырыктан артык, дип сөйләделәр... Якындагы өйләрнең ак диварлары мылтык җәдрәләре белән шадраланды, урамнар кызыл канга буялды.

Менә шул көн кич адәм ышанмаслык хәбәр таралды:

– Шәһәрне алалар, имеш...

– Кем ала?

– Кемнән ала?

– Ни өчен ала?

Болар бар да җавапсыз кала, тик һәммә кеше, куркыныч яшен алдындагы минутка охшаш бер халәт хис итеп, мөселман агай-эне:

– Ходаем, тагы нинди афәтләр бар икән?.. – диярәк, Тәңрегә мөрәҗәгать итә...

Гомуми куркыныч эчендә күңелне җуатырга тиеш булган бер хәл бар исә, ул да шул фетнәчеләр эчендә әһле исламның күренмәве иде. Бу хакта сөйләшәләр дә:

– Кяфер үзара сугыша... – дип, бераз тынычланып куялар.

"Кяфер үзара сугыша..." дигән сүз бераз тынычландырса да, һәр турыда саклануны ярата торган табигатьләр бу көннәрдә бөтенләй гафил тора

алмыйлар. Һәркайда бер куркыныч хәбәр йөри. Гүя “тегеләр” күп халык торган йортларга керәләр, имеш тә, кылычларын ачып, безгә кушыласыңмы, юкмы, кушылмасаң, хәзер башыңны чабып өзәм, дип кычкыралар, аз гына карышсаң, шунда ук үзеңне бетерәләр, имеш, диләр. Бу хәбәр, башка һәркемнән бигрәк, кадим мәдрәсәләрне зур хафага салды. Һәрбер шәкертнең, хәлфәнең башына: “Мәдрәсәгә кереп көчли башласалар, ни кылырмыз...” дигән курку төште.

Сак кешеләр саклану юлына да керә башлыйлар. Якынрак авылдан килгән бер башкорт шәкерте:

– Әти авырый икән... Мине чакыртып язган... – дип, авылына сыза. Берничә казачий шәкерте[1+]:

– Керсәләр, каршы торырга ярар... – дип, авылыннан үзенең күгәргән сөңгесен китертә. Бер мишәр исә:

– Сакланганны Ходай саклар... – дип, үзенең шикәр вата торган зур калын тимерен өстәл өстенә билгеле йиргә алып куя... Хәлфәләр дә тик ятмыйлар. Мәдрәсәнең капкасы ныгый, аны караңгы төшүгә ябып бикләтә башлыйлар. Ишекләргә яңа тупсалар, яңа бикләр куела...

Һәркем шулай кулыннан килгәнчә саклана.

Шәһәрнең иң могтәбәр хәзрәте Вафа ахун һәр җомга саен бу хакта сүз ача:

– Җәмәгать, ислам вә Коръән намыннан[1] хитаб кылып[2] диямен ки, җир йөзе фетнәләр белән тулды. Урамнар фетнәчеләр белән тулды... Шул фетнәчеләр арасына кушылып, әһле исламны сатучы булмасын! Фетнәчеләр, багый вә гыйсъян әһелләре[3] арасында бер мөселманның күренүе – бөтен мөселманга йөз каралыгы булачак, ислам вә Коръән әмере белән әйтәмен ки, шул гыйсъянчылар, шул кяферләр арасында бер мөселман карасы булмасын... Бу – бөтен мөселманның йөзенә кара ягачак...

Тирән бер ихлас һәм күз яшьле тавыш белән сөйләнгән бу вәгазь халыкка шундый нык тәэсир итә иде ки, күпләр җомга намазыннан күз яшьләрен сөртә-сөртә чыгалар... Шуның берлә бергә тынычлыклары да арта, инде әминлеккә ирештек дигәнгә якын бер халәт хис кылалар...

Ләкин бу тынычлык күпкә бара алмады.

Шул көн кич тагы урам буйлап йөргән халыкның башлыклары арасында, кызыл флагның нәкъ янында, яһүди байда приказчик булып торучы Габдрахманны күргәннәр, имеш, дип сөйләделәр. Ләкин шуның артыннан ук тагы икенче бер хәбәр дә таралды: чын булса, ул Габдрахманны

[1] *Намыннан* – исеменнән.
[2] *Хитаб кылып* – мөрәҗәгать итеп.
[3] *Багый вә гыйсъян әһелләре* – изүче һәм баш күтәрүчеләр.

ике егет тар тыкрыкка чакырып алганнар да:

– Ник мөселманнарга йөз каралыгы ясыйсың?.. – дип, канга батырганчы кыйнаганнар. Кыйнаучы егетләр үзләре:

– Бирдек кирәген егеткә… Малаең, абзыкайларым, моннан соң якын бармам, дип җылый-җылый тәүбә итте, – дип мактанып йөриләр. Габдрахман үзе дә яңагына яулык бәйләп чыккан, диләр...

Ләкин бу хәбәрнең тынычландыруы да озакка бармый.

Берничә көннән соң тагы яңа вакыйгалар:

– Имеш, шәһәрнең иң могтәбәр байларыннан Кадыйр байның унике приказчигы баш күтәргәннәр... Һәммә кеше боларны “кызылланганнар”, имеш, дип сөйли... Һәм шул арада ук шәһәрнең иң атаклы гыйлем йортларыннан мәдрәсәи исламия шәкертләре арасында остазларына каршы көрәш башланган... Гүя ике йөз шәкерт, кул куеп, мөдәррисләренә гариза биргәннәр, ниндидер ислахлар[1] сорыйлар, кайсы мөгаллимнәрнеңдер мәдрәсәдән чыгарылуын эстиләр[2]. Имеш, бер атна мөддәт3, шул арада дәрескә кермәячәкләр, сораганнары бирелмәсә, мәдрәсәдән чыгып китәчәкләр...

Һәр икесе бер-береннән аңлаешсызрак булган бу ике хәбәр башта шул “Кадыйр бай” приказчиклары белә[4] мәдрәсәи исламия шәкертләре хакында булса да, бик тиз арада алар һәр икесе үсәләр:

– Юк, фетнәнең башы Кадыйр бай приказчиклары белән мәдрәсәи исламия шәкертләре булса да, алар ялгыз түгел, имеш... Тиз арада алардан башкаларга да йоккан. Гүя приказчиклар үзара “Ярдәм” исеме белән яшерен бер җәмгыять ясап, шунда акча җыялар, гүя шул җәмгыятькә хәзер Кадыйр байныкыннан башка Ибраһим бай, Сәлах хаҗи, Зәңгәр Вәли, Чатан Садри, тагы әллә кемнәрнең приказчиклары да кушылган. Алар барлыгы берләшәчәкләр дә:

– Эш вакыты сигез сәгать булсын... Хезмәт[*] хакы арттырылсын... Приказчиклар белән адәм кебек мөгамәлә кылынсын! – дип сораячаклар, сораганнары бирелмәсә, урыннарын ташлаячаклар, имеш...

Шәкерт фетнәсе дә шул дәрәҗәдә тиз җәелеп, хәзер алар шәһәрнең зур мәдрәсәләреннән дүртесен кулларына алганнар, гүя “Исляхате мәдарис” исеме белән бер җәмгыять[2+] ясап, шунда төрле мәдрәсә шәкертләрен әгъза иткәннәр, тиздән барлыгы бер булып, эшкә тотыначаклар, беренче эшләре:

---

[1] *Ислахлар* – үзгәртү, реформалар.
[2] *Эстиләр* – телиләр.
[3] *Мөддәт* – вакыт.
[4] *Дөресе:* белән.
[*] Г. Ибраһимовта: *хедмәт.*

– Мәдрәсәләргә яңа тәртип кертелсен... Русча мөкәммәл[1] укылсын... Фөнүне җәдидә[2], рәдде нәсара[3], тәфсир, хәдис һәм әдәбияте гарәбия[4] кебек дәресләр кереп, схоластика бөтенләй ташлансын… – дип гариза бирәчәкләр, мөдәррисләр моны кабул кылмаса, шул дүрт-биш мәдрәсә шәкерте барлыгы бергә уку ташлаячаклар, мәдрәсәдән чыгачаклар…

– Кяфер үзара сугыша... – дип, бер якта әмин яшәп калуны өмид иткән халыкка бу адәм ышанмаслык хәбәрләрнең һәр икесе әллә нинди чобалчык вә аңлаешсыз бер тәэсир бирәләр... Халыктан бигрәк, байлар белән мөдәррисләр бу хәбәрдән ачу катыш аптыраулы бер халәткә киләләр. Һәр бай үзенең куәтенә ышана, шуңар күрә ул башта мондый хәбәрләргә каршы мәсхәрәле тавыш белән көлә генә:

– “Чыксыннар!.. Чыгып, кая баралар? Тамагы ачыккач, яңадан килеп ялыныр да, мин аны типкәләп җибәрермен... Менә җыен маңка малайлар!.. Адәм көлкесе бит, имеш, сигез сәгать эш вакыты... Имеш, бер ярым хак арттырылсын – тот капчыгыңны!.. Әле унбиш сәгать эшләп тә, әллә кая китә алган юк!..” Ул башта шулай каршылый. Ләкин приказчиклары арасына баргач, нидер яңа рух сизенеп, эченнән бик аз гына шикләнә башлый. Моңарчы һәр сүзеңә баш иеп торган Фәхри хәзер, ничектер, башкачарак кылана... Бүтәннәре дә элекке кебек түгелләр... Аз гына сүз әйтергә, аз гына артык эш кушарга ярамый – мин синең колың түгел дигәндәй, йөз күрсәтә башлыйлар. Бай боларны сизенә, тышыннан белдерми, ләкин эчтән бераз шүрли, тагы шул минутта ук үзенең йомшаклыгына ачуланып:

– Бирермен... мин ул этләргә... Тамаклары туйгандыр... Эт симерсә, иясен талый... – дип, ачудан кыза, ди, бик аз гына тавыш булса, өстләренә аяк тибеп кычкырырга карарлап куя... Тагы шунда ук шөбһә килә:

– Куарсың кууын да... Адәм хурлыгы бит... Приказчиклары баш тарткан, имеш, дип сөйли башларлар...

Мөдәррисләр дә тыныч түгел. Һәр хәзрәт үзенең иге-чиге булмаган авторитетына ышана:

– Дөнья буталса да, минекеләр мотыйг[5] калыр, ди...

Ләкин мәдрәсәгә барып, ул-бу турысында сүз чыкса, аның эченә дә моңарчы таныш булмаган бер шөбһә, бер шик керә. Хәзер шәкерт, ничектер, әүвәлге түгел... Киемендә, йөреш-торышта булган үзгәреш тагы бер хәл... Инде заманасы шул, диләр... Менә бит, ул остазы белән карулашуны шәплек

---

[1] *Мөкәммәл* – камил, тулы.
[2] *Фөнүне җәдидә* – яңа фәннәр.
[3] *Рәдде нәсара* – христиан динен кире кагу.
[4] *Әдәбияте гарәбия* – гарәп әдәбияты.
[5] *Мотыйг* – сүз тыңлаучы, буйсынучы.

саный... “Синең фикерең алайдыр, ә мин менә болай уйлыйм...” дияр мәртәбәдә башсызлык күрсәтә. Бер төрлесе дәрескә дә суынды. Башта яшерәләр иде, инде хәзер “схоластика белән ми черетү!” дигән сүзне минем алдымда әйтүдән дә тартынмыйлар... Казый:

– Әллә кайларга китеп югалалар, әллә нинди вак-төяк әкиятләр укыйлар, ди... Бар да шул юк-бардан чыккан ахмаклык... Тукта, аларны бер йөгәнләргә кирәк... Маңкалары кипмәгән, остаз белән каршылашырга икән ... Танысыннар минем кем икәнемне...

Бу тынычсызлыклар бай белән мәдрәсәдә генә калмый...

Һәр гаиләнең беркөе генә, моң гына аккан иске һәйбәт, тыныч хәяте эченә моңарчы таныш булмаган яңа бер әндишә керә... Бу көннәр, башка һәркемнән бигрәк, аналарга авыр, хәсрәтле, куркынычлы сәгатьләр алып килделәр... Бала җанлы Камиләнең угылы – приказчик. Кайда да булса байлар белән приказчиклар арасында сүзгә килү булганлыгы ишетелә кала калса, аның йөрәге бөтен тынычлыгын югалта, йокысы кача, ул газиз угылының шундый хәлгә төшеп әрәм булмавы хакында Тәңрегә ялвара башлый:

– Ходаем, үзең сакла... Ходаем, үзең сакла... Үзең бәхетеннән, тәүфигыннан аерма...

Кәримәнең, тиздән һәйбәт урынга мулла сайланып, ил башлыгы булырын өмид итеп торган бердәнбер угылы мәдрәсәдә укый. Менә кайдадыр, шәкертләр белән хәлфәләр арасында тавыш күтәрелгән, дигән хәбәр чыга... Кәримә, бу хәбәрне ишетү белән, үз угылы да шулар эчендә түгелме икән дип, бөтен тынычлыгын җуя. Булмаса, баласы тәүфигында йөрсә иде дип, нәзерләр әйтә, углыннан хат килгәнче, озын төннәрен газапта, догада үткәрә... Хәбәр килә, аның угылы тегеләргә кушылмаган. Ана йөрәге шатлыгыннан бәйрәм итә. Ләкин бу шатлык озакка бармый, тынычсыз йөрәк һәрбер хәбәрдән үзенә кайгы көтә:

– Алда ниләр күрсәтәсең бар, Раббым... Илаһым, тәүфикъ бир! Һидаять бир[1]!

Аталар да тыныч түгел. Ләкин ул кайгырып җыламый, намаз артларында Тәңрегә ялвармый. Аның ир табигате икенче төрле җавап бирәчәк: угылы хакында андый-мондый хәбәр чыкса, ачудан йөзе кара көя, тешләре каты кысыла, ул ата хакын танымаган кадерсез малае тугрысында:

– Тукта... Тукта... Танытырмын мин аңа кем икәнен... – дип, эченнән угылын ни эшләтергә карар биреп куя.

Ул баласының үзенә, остазына, хуҗасына карышканын күрсә, тотачак

---

[1] *Һидаять бир* – туры юлга керт.

та, тәүфикка китергәнче ярачак, аның белән дә акылга утырмый икән – куып чыгарудан да кире тормаячак...

– Мин кем?.. Ата хакы кайда?..

Мәдрәсәгә биргәннәр икән – укысын. Байга биргәннәр икән – хезмәт итсен. Яхшы укысын, яхшы хезмәт итсен, фатиха алыр, адәм рәтенә керер.

---

Ләкин бу заман – яшь табигатьләрнең саф күңелләре алдында нурлы гарешнең[1] ачылган көннәре иде. Аналар аглыйлар, караңгы төннәрдә газиз угылларының юк-барга катышмавы хакында Тәңрегә ялваралар. Аталар, угылы тарафыннан ригая кылынмаган[2] аталык хакы өчен, ачудан кара көя, аны тәүфикка китергәнче ярырга әзер тора. Мөдәррисләр, байлар баш имәгән шәкертләре, приказчиклары хакында: “Тукта, мин аларга танытыйм әле, кем икәнлекләрен”, – дип, тәһдидкә[3] үзенең тарих белән тасдыйк кылынган[4] хокукын гамәлгә куярга карар бирә. Ләкин бу чаралар һәммәсе гаҗиз. Алда үзенең могҗиз нуры белән гареш ачылган, һичбер куәт яшь йөрәкләрне аңа таба барудан, аңа ирешү юлында ашкынудан тыя алмаячак.

Бу ашкынудан нинди нәтиҗә туар, нурлы гарешкә очырып мендерәчәк канатлар бармы? Алар боны уйлый алмыйлар. Хәят дулкынлана, тарих белән ясалып килгән иске тормыш төбе-тамыры белән кузгала. Алда, ерак күктә, матур киләчәк – нурлы гареш ялтырый. Яшь күңелләр үзләрен моңар барудан тыя алмыйлар.

## II

Дулкынның куәтле көннәреннән бере иде.

Руслар арасында “беглец” дип, татарларда бер йирдә “качкын”, икенчеләрдә “сәрүҗи” дип аталып йөргән Хәбиб Мансуров караңгы төндә шәһәр бакчасының кечкенә капкасыннан чыкты да, капкыннан качкан ерткыч кебек, як-ягына ялт-йолт каранып, шәһәрнең төн ягына таба сызды. Аның башында сынган киң читле салам эшләпә. Өстендә култык астындагы тишекләреннән көзге яңгырлы, ачы суык җил уйнап торган юка пальто, аягында кыска кунычлы итек кисәге, уң кулында ниндидер бер төргәк, сул кулында тимер таяк иде.

Ул, бераз баргач, Николаевскийга төште дә, аякларын тагы кызулата башлады. Аңа сәгать өчкә поездга өлгерергә кирәк. Хәзер ике булып киләдер.

---

[1] *Гарешнең – бу урында*: күкнең иң югарыгы катлавының.
[2] *Ригая кылынмаган* – хөрмәтләнмәгән, игътибар ителмәгән.
[3] *Тәһдидкә* – куркытып кисәтүгә, янауга.
[4] *Тасдыйк кылынган* – расланган.

Димәк бер генә сәгать вакыт бар. Шул арада Урмановка да кереп чыгасы... Ашыкмаса, кичегергә мөмкин... Үчеккән кебек яңгыры да арта бара, җиле дә өстәге төймәләре җүнләп каптырылмый торган пальто ашасыннан күкрәккә туры суга...

Николаевский белән ике чат үткәч, Пушкинскийга керде дә уңга, тар, караңгы тыкрыкка борылды. Монда фонарьлар юк, үтә караңгы... Аяк асты тубыктан бата, кайбер йирдә кыска кунычлы итек бөтенләй чума иде. Шулай да ул бу йирләрне тыкрык белән үтәргә мәҗбүр күрде... Шул берничә урам тирәсендәге полицейскийлар аны таныйлар... Якты урам белән барсаң, шуннан ук тотып алулары мөмкин... Ул шулай уйлап өлгерә алдмады, аяклары үзлегеннән кире чигенделәр... Чү... Тукта... Алда бер карачкыл тора... Полицейский, бугай... Фу... хәерче, багана икән... Чү, тагы кем... Каһәр булсын, тагы багана...

Ул, курыкканга куш күренә дип, үзеннән-үзе көлде дә, суык яңгырга күшеккән ябык тәнен бер җебенәчә юешләнгән нәзек пальтосы эченә бөрештерә төшеп, йөгерә-атлый Екатеринскийга чыкты:

– Ни булса, шул булыр... Барлык полицейский танып өлгермәгәндер әле...

Ул Урмановның яңа квартирында булганы юк иде. Яңлыш кителмәсен дип, өйрәтү буенча уйлый башлады:

– Успенский белән шәһәрнең читенә, яланга чыкканчы барасы. Анда почмактан икенче капка белән зур каенлы йортка керәсе... Йорт уртасында тәбәнәк киң өй. Шуның йир астындагы катлавына шакылдатасы... Менә Успенский урам... Әнә шәһәрнең чите дә ерак калмый... Ул тагы кызулый төште.

– Хәбиб Мансуров – утыз еллар учитель булып, хәзерендә пенсия белән яши торган Гомәр картның бердәнбер угылы иде. Ул, быел школаны бетереп, учитель булып чыгачак иде. Ләкин дөньялар болайга китте.

Бу ел дүртенче сыйныфка чыгу белән беренче эш – аны иптәшләре арасына прокламация тарату, кызыл фикердә булу белән гаепләделәр[3+]. Шуның өчен аны директор чакырып алды да кабахәтләп сүкте, бер юлга гафу кылыначагын, ләкин тагы сизелсә, әхлагы төшереләчәген, ниһаять, хокукын югалтып, школадан куылачагын белдерде. Шул көн кич директорга һөҗүм була. Бұның кем эше икәнен белмиләр, шулай да күпләр, моны ишетүгә, Хәбиб Мансуровтыр, дип уйлыйлар. Аның зирәк, эшчән, ләкин башбирмәс табигате белән күптән үк ни кылырга белми йөргән кайбер мөгаллимнәр, аннан да бигрәк назыйр[1] ачыктан-ачык моны сөйли башлыйлар... Ул, әлбәттә,

---

[1] *Назыйр* – мөдир.

хибескә[1] алыначак иде, ләкин... Өйләдән соң сәгать өчтә чыгып китүеннән кайтмады, эзләп тә таба алмадылар, шул китүдән аның эзләре суынды.

Хәбиб Мансуров яңадан школага аяк басу, үзен күрсәтү түгел, исемен, кыяфәтен дә алыштырып, шул көннән дулкын эченә кереп китте.

Менә ничә айлар инде ул кайда туры килсә шунда куна, ни тапса шуны ашый, вакыты белән ачыгырга да туры килә иде. Ул башта руслар арасында эшләргә уйлап караган иде. Аны тиздән ташлап, авылга, крәстияннәр арасына китте. Соңра, авылны да ташлап, монда килде. Менә икенче ай инде ул монда эшли. Башта эшчеләр арасына, завод, фабрик тирәләренә керергә уйлаган иде, русның үзендә дә эшләүче юк түгел, мөселман эшчеләре, ничектер, аны канәгатьләндермәделәр. Ниһаять, ул эшчеләр арасындагы кечкенә ике түгәрәкне дәвам иттерү белән бергә, татар яшьләре, укучылар, приказчиклар арасына керде. Эшләр яхшы бара, палиция дә танымый иде... Моннан берничә көннәр элек шәһәр театрында мөселманнарның зур җәмгыяте булды. Мәсьәлә Думага сайлау һәм ул вакыт кайсы партия белән кушылу хакында иде. Халык шуны куәтләп сөйләгән берничә хатиб[2] артыннан:

– Мәшрутиять гавамиячеләр[4+] белән... – диде. Президиум сәхнәдә, һәр хатиб шунда чыгып сөйләргә тиеш иде. Ахырдан урта буйлы, кара-сары шадра йөзле, күз карашлары михнәт һәм җәфа катыш ялкын белән ялтырап торган бер егет сүз алды. Моның өстендә яңа тройка[3], ялтыр ак яка, аягында ялтыр сары штиблетлар, башында котелок[4] иде. Ул бераз купшы адымнар белән сәхнәгә җиңелле генә күтәрелде дә, йомшак, ягымлы бер тавыш белән:

– Әфәнделәр, Думадан һәрбер сыйныф, һәрбер халык үзенә файда көтә, һәр кеше бу Дума үзенең көн итүенә бер җиңгеллек бирер дип ышана. Байлар сәүдә малына түләүләрнең азаюын, эшчеләр хезмәт хакы арттырылуын көтә. Авыл халкы йир өмид итә. Поляк, яһүд, татар кебек чит милләтләр үзенең дини, милли ихтыяҗлары үтәлүен, һәркем бөтен Русия халкына киңлек, тигезлек, хөррият булуын тели... Ләкин, әфәнделәр, бу хәзерге рәвеш белән сайланып барган вәкилләрдән гыйбарәт, хәзерге тар хокуклы Дума бу теләкләрнең, бу өмидләрнең һичберен бирмәячәк, бирә алмаячак... – дип, Думага бойкот игълан итәргә тиешлеген сөйли башлады. Менә бу егет – Хәбиб Мансуров иде.

Ул, үзен танытмас өчен, таныш гимназист Тангатаровның иптәшенең киемнәрен алып кигән иде. Башта һәм аны танымадылар да. Ләкин гөнаһ

---

[1] *Хибескә* – төрмәгә.
[2] *Хатиб* – вәгазь сөйләүче, бу урында *чыгыш ясаучы, оратор.*
[3] *Тройка* – пинҗәк, чалбар һәм җилән-жилеттан торган костюм.
[4] *Котелок* – биек, түгәрәк түбәле, тар кырлы эшләпә.

шомлыкка каршы, күптән үк җасуслык[1] белән төһмәт кылынмакта булган[2] карт учитель Әхмәдев, ничектер сизеп алып, палиция колагына минуты белән сүз салган. Ул арада мәҗлестәге халык та, Думага бойкот дигәнгә каршы бик зур тавыш күтәреп, төрле яктан:

– Сөйләтмәңез...

– Лыгырдамасын, хәерсез... Бетмәс монда кызыл авызлар...

– Тотыңыз явызны... – дип кычкырышырга тотындылар...

Тәртип бетте, мәҗлес таяк тыгылган кырмыска оясы кебек бутала башлады. Ул арада бөтен көче белән Мәшрутиять гавамиячеләргә кушылу ягын алга сөргән рәис әфәнде дә хатибка туктарга кушты, ләкин ул рәискә илтифат итмичә, сүзен дәвам иттерде. Шул шау-шу, тәртипсезлек арасында рәис, аякка басып:

– Җәмәгать, мин мәҗлесне яптым, – диде, һәм шул минут сары төймәлеләрнең ашыга-ашыга сәхнәгә менеп килгәннәре күренде, һәммә кеше хатибның тотылачагына, кызык бер эш чыгачагына ышанып торганнар иде...

Ләкин өмидләр бушка булды, бөтен халыкның хәйрәтенә[3] каршы, Сәрүҗи гаҗәеп бер җитезлек белән арадан югалды.

Ул тотылмады, ләкин бу егетнең теге директорга һөҗүм итүдә, тагы берничә эштә гаепләнгән Хәбиб Мансуров икәнендә палитциянең шөбһәсе калмады.

Аны бик ныгытып эзли башладылар.

Ул эз яздыруда бик оста санала, күп урыннарда алдап кача белә, шул сыйфаты өчен аңар шәкертләр “Мәкамәте Хәрири”нең баш каһарманына охшатып[5+], шуның исеме белән Сәрүҗи дип ләкаб[4] тә биргәннәр иде. Ләкин соңгы көннәрдә аның эзенә төшкәнлекләре, озакламый аның өнен килеп басу ихтималлары бик якынайды. Аның эшчеләр арасындагы түгәрәкләреннән беренең җыелган квартирында тентү булды, аның катнашы белән җилем басмада прокламацияләр баса торган татар шәкерте – Баязид карыйда тентү ясалып, шәкертне зинданга алдылар... Кич кунып чыккан фатирында бүген тикшерү һәм сорау булган... Менә болар бар да палитциянең нык керешкәнен, инде эз яздыру мөшкел булачагын күрсәтәләр иде. Шул вакытка тагы Яманташ буендагы крәстияннәр[6+] кузгала башлаган дигән сүз дә чыкты. Комитеттан ярдәм сорап хәбәр бар. Руслардан өченче көн ике адәм китте. Татардан берәү юк. Сәрүҗиның ашыгып поездга төшүе менә шунда китү өчен иде.

---

[1] *Җасуслык* – шымчылык.
[2] *Төһмәт кылынмакта булган* – шик астына алынгана, яла ягылган; гаепләнгән.
[3] *Хәйрәтенә* – гаҗәпләнүенә.
[4] *Ләкаб* – кушамат.

Ул, өйрәтү буенча, шәһәрнең читенә, киң яланга чыгып, почмактан икенче йортның ауган капкасы аша кергән вакыт, күкнең бер чите бераз ачылып, аннан тулы ай карады. Тәүлек буенча яуган яңгырдан киң йорт эчен су баскан, бу су тулы айга каршы түгәрәк күл кебек ялтырамакта иде. Күлнең капка як читендә ап-ак ике каз күренә. Алар башларын канат астына тыкканнар, тыныч йокыдалар. Менә тәбәнәк иске кызыл өй... Урмановның “җәһәннәм базы” шуның асткысы булырга тиеш. “Җәһәннәм базы”на керү өчен, бер сажин кадәр түбән төшәргә кирәк иде. Качкын уйлап тормады, төште дә бусагасы бөтенләй су эчендә булган ишекне шакылдата башлады.

Йорт уртасындагы ялгыз карт каен төшеп бетәргә өлгермәгән сирәк яфраклары белән кызганыч рәвештә шаулый, ялан ягыннан искән куәтле ачы җил өй түбәсендәге тимерләрне шатырдатып каера, җиңә алмагач, “у-у”... “у-у”... дип тавышлана, ачуыннан кемгәдер зәһәр аваз белән сызгыра да яңадан өйнең тимер түбәсенә килеп тотына... Көче җитми, каерып ташлый алмагач, тагы уылдый, тагы зәһәрле ачу тавыш белән сызгыра башлый иде.

Ишекне тиз ачмадылар. Баскыч төбендә җил юк, тәнгә ышык булса да, суык баткакны җырып килгән аяклар туктау белән өши башладылар, бер як табаны купкан итекнең эче лакырдап тора, ниндидер бозлы су аның аяк бармакларыннан башлап, тубыгына, тезенә, аннан бөтен тәненә, тамырлары буйлап, акрын-акрын үрмәләгәне ачык сизелә иде.

Ник ачмыйлар тагы? Әллә бар да дөмектеләрме?.. – диде дә егет бар көче белән яңадан шакылдатырга тотынды. Ниһаять, өйнең эчендә җан иясе барлыгы беленде. Кемдер акрын, бик акрын атлап, ишеккә килде дә үлем алдында торган хәлсез адәм тавышы белән “Аһ, мине ник бу кадәр газаплыйсыз?” – дигән сыман ыңгырашты...

– Кем бар?.. Көн буена кешедән ишек ябылмый... Тагы төндә дә кеше... Сезгә кем кирәк?..

Сәрүҗи мөмкин кадәрле тыныч тавыш белән җавап бирергә тырышты:

– Миңа Урманов кирәк иде... Ул монда торамы?..

Эчтән җавап булмады. Баягы хәлсез аякларның ишектән акрын, бик акрын өстерәлеп ераклашканы ишетелде. Сәрүҗи аптырый калды:

– Чү... ачмады... Ул әллә монда тормыймы?...

Ул арада эчтән икенче аяк тавышы ишетелде. Бусы инде җиңел, егетчә таза атлый иде. Килеп җитү белән:

– Хәбиб, синдер бит?.. – диде.

Ишек ачылды. Аннан кулына шәм тоткан озынча буйлы, ябык, аксыл йөзле, бераз эчкә баткан карасу күзле, киң маңлаена төшеп төзелеп торган зур ук чәчле, кара күлмәкле бер егет килеп чыкты. Ул төнге кунагының яңгырлы суык җилдән күгәргән иреннәренә, күшегүдән вак сары йон

калыккан йөзенә карады да, тиз үк:

– Син гаҗәп өшегәнсен! Әйдә тизрәк керик!.. – диде. Начар бер мөсаһәләсе[1] өчен гафу үтенгән адәм тавышы белән тагын кушты:

– Синең киләчәкне Тангатаров әйткән иде... Мин кич буена йокламый көттем... Бу лампаның мае бетте, караңгыда утыра торгач, киенгән килеш йоклап киткәнмен... Сине озак көттерделәрме?..

Хәбиб бусаганы атлый-атлый җавап бирде:

– Байтак булды... Нинди хәерсез нәрсә ул... Авырыймы? – дим...

– Кемне әйтәсең?.. Карчыкнымы... Ул үләргә ята... Ләкин минем өчен бик яхшы... Күзе җүнләп күрми... Бераз чукрак та, бугай... Монда бомба фабригы корсаң да булачак...

– Мин керәм керүен, сәгать ничә?.. Кара әле...

– Сәгать кайдан килсен... Шулай да өченче бардыр...

Сәрүҗи кире борыла башлады:

– ... Алайса, мин кереп тормыйм... Поездан кичегә башлармын... Мә, тегене ал. Корулыдыр, кара, атылмасын!..

Урманов аның кулындагы төргәкне алды да, култыгыннан тотып, эчкә тартты:

– Юкны сөйләмә, иптәш... Кичексәң, товарный поезд белән китәрсең... Бераз җылынып чык...

Икесе дә эчкә таба атладылар.

Урманов бик аз якты биргән шәме белән алдан китте. Керү белән, Сәрүҗинең борынына әллә ниткән ачылы-төчеле ис бәрелде. Өй карсак, авыр һавалы иде. Ишектән бер адымнан зур, иске мич, аның алдында яртылай ауган күмер чүлмәге, каралып беткән, бер колагы төшкән самавыр. Сул якта начар агач өстәл, аның өстендә калган аш, бәрәңге кабыклары, касмагы кырылмаган ватык чүлмәк, уң якта, җуыныр өчен булса кирәк, мунчала, җепкә асылган бер балчык савыт. Менә шуның белән беренче бүлмәнең күренеше тәмам иде. Бусы карчыкныкы булып, тагы бер ишек ачкач, Урманов тора торган бүлмә иде. Почмакта каралып беткән иске агач тәре. Кайчандыр чобар бизәкле булып та, заманалар үтүе, тузаннар, төтеннәр сылануы белән каралып, буй-буй җыртылып беткән, күп җирләреннән бөтенләй кубып төшкән кәгазьле дивар. Уң якта киң иске агач карават. Сулда, берсе артсыз, ике агач урындык. Өчтән ике өлеше йир астында булган тар озын тәрәзә төбендә өсте китаплар, кәгазьләр белән яңа башланган әчмуха[2] чәй, бераз икмәк, җыелмаган самавыр, тагы ниләр белән тулып яткан кечкенә өстәл – беренче күз йөртүдә күзгә ташланачак җиһаз шуннан

---

[1] *Мөсаһәләсе* – игътибарсызлыгы, мөнәсәбәте.

[2] *Әчмуха* – кадакның сигездән бер өлеше, 50 гр.

гыйбарәт иде.

Сәрүҗи бүлмәгә керү белән караватка сузылды:

– Бик арыдым... Уф, бер йокларга!.. Миңа ашыгырга кирәк... Кичегү ярамый... Кая, алып кердең керүен!.. Ичмаса, тамак җебетергә берәр җылы нәрсәң бармы?.. Ни булсын!.. Юктыр, үзең дә ачсыңдыр әле...

Урманов көлеп өстәлгә килде:

– Ач та түгел, туйган да юк... Менә самавырда җылы су бар... Менә һәйбәт тоз белән кадагы ике тиен ярымга алынган һәйбәт арыш икмәге... Тукта... Ул сүзен бүлде дә, теге бүлмәгә чыгып, нидер алып килде:

– Менә, иптәш, бераз бәрәңге дә бар...

Мансуров, торып, икмәк-тоз белән бәрәңгене барын берьюлы ипләп бөгә башлады. Урманов аның китергән төргәген ачты. Анда бик аз тотылган браунинг иде. Бер секундка егетнең йөзе ачылды, ирененнән шатлык елмаюы йөгерде, ләкин һични димәде, яңадан торып, мич белән түбә такта арасына ярыкка кыстырды.

Сәрүҗи алдындагы бәрәңге белән икмәкне төгәлләде, самавырдан тагы бер чынаяк су эчте дә урыныннан торды:

– Ну, иптәш, шәп төште бу! Кая, син тегеләрне хәзерләдеңме?

Урманов караваттагы мендәр астыннан бер төргән кәгазь алып бирде:

– “Кызыл флаг”ны йөзне куйдым... “Крестьяннарга ни кирәк?”тә илле бар, бугай... “Эшчеләр авазы” белән “Дума ни бирер?”[7+] җүнле чыкмады. Карабыз начар туры килгән... “Безнең юл”ны[8+] баса башлагач, ташладык. “Баязид карыйда тентү булган, үзен алганнар” дигән хәбәр чыгу белән, безгә дә җыенырга туры килде... Ул хәзер юк. Баргач, адресыңны белдерерсең, берәрсен йибәрергә булыр...

– Ну, алайса, мин киттем.

– Әйдә, мин дә чыгам.

## III

Болар чыкканда, җил басыла төшкән иде. Күк яман ачылып, аннан тулы ай, шәфкатькә хәзер булган ак йөзе белән егетләрне каршы алды. Аяк тавышын ишеттеләр булса кирәк, күл буендагы казлар, уйнап, үзара бераз гагылдаштылар да: “Таң да атмаган, әле йөрергә иртә”, – дип, йорт уртасындагы карт каен төбенә күчеп утырдылар. Шәһәр тын, ерак аяз күк үзенең якты йолдызлары белән нидер тыңлый, бөтен табигать гаҗәеп бер серле минут алдындагыга охшаш халәт илә сөкүт итә[1] иде.

Өй эчендәге җиңеллек үзеннән-үзе бетте, егетләр икесе дә үзгәренделәр. Сәрүҗи ят салмак тавыш белән сүз башлады:

---

[1] *Сөкүт итә* – тын тора.

– Мәдрәсә яшьләрен күрдеңме?.. Теге эшләре ничек бара?.. Ул турыда комитетта да...

Ләкин аңа сүзен бетерергә мөмкин булмады. Шәһәр ягыннан ниндидер бер карачкыл күренде. Үзе адәмгә охшый. Болай таба атлый да, бугай. Егетләр һәр икесе: “Палиция түгелме?” – дип уйладылар.

Карачкыл якынайды. Менә килеп тә житә.

Бу – өсте-башы урамга ятып аунаган диярлек мәртәбәдә пычранган, сәләмә киемле, чабата аяклы, яланбаш бер фәкыйрь адәм иде. Ахрысы, нык исергәндер, гәүдәсе як-якка саллана[1] бара, аяклары чак өстерәлә. Бу вакыт Урмановлар капка төбенә килеп житкәннәр иде инде. Исерек, яннарыннан үтсә дә, боларны күрмәде, бугай: бер мәртәбә дә күтәрелеп карамады, ярты русча, ярты татарча кабахәт сүзләр белән мыгырдый-мыгырдый зур каен яныннан үтеп, иң арткы ишекләрдән беренә таба китте. Аның ни дигәне аңлашылып бетми, тик:

– Мин аларны... Покажу... Мин... – кебек берничә сүз генә дошманлык, ачу тулган тавыш белән кат-кат ишетелә иде.

Егетләр сүзсез, ләкин бик дикъкать илән карап, иң арткы ишеккә, түбәнгә төшеп югалганчы, аңардан күзләрен алмадылар.

Сәрүжи:

– Бу кем? Таныйсыңмы? – диде.

Урманов аны таный иде. Ул яртылай руслашкан Абдул (Габдулла) исемле бер татар, агач заводында эшләүчеләрдән. Бер атна элек аны урыныннан чыгарганнар. Хәзер эш табудан гажиз. Шуннан соң эчәргә дә сабышкан. Кичә аның хатыны, Урмановка кереп, үзенең ерак кардәшләреннән беренә хат яздырган һәм:

– Үзем авырыйм, бәләкәй өч балабыз бар. Бер кабым икмәк калмады. Фатирдан да куалар. Нәрсәләрне дә сатып бетә... Ачтан үләмез инде... – дип елап чыккан иде. Исерек түбәнгә, ишеккә төшеп югалгач, Урманов үз эченнән:

– Бичара, исереп, канауда аунагандыр да шунда фуражкасын да төшереп калдыргандыр, – дип уйлады. Соңра Сәрүжи кузгаткан турыда сүз башлады:

– Ул эш яхшы барачак шикелле күренә... Мин бүген аларның берсе белән барып карап кайттым.

“Ул” атнага ике мәртәбә кичке сәгать сигез белән ун арасында ........ бакчасыннан үтә. Аның үтә торган сукмагыннан өч-дүрт кенә сажин баргач, яр астына төшеп китә торган чокыр – текә яр бар. Яр астында ат белән

---

[1] *Саллана* – чайкала.

көтәргә дә уңай. Мөмкин, бераз баргач, көймә белән качарга да...

Тик менә ат мәсьәләсе нишләр...

– Ул турыда тегендә сүз булды. Партиянең членнарыннан бер студент белән бер эшче помещик булып йөриләр. Иртәгә сиңа Булатов килер. Башкасын ул белгәндер... Ну, сау бул, мин киттем...

Ул, берничә атлагач, яңадан борылып килде:

– Әйтергә онытканмын. Син иртәгә Раузаны күрә алырсың бит? Ул Колядагы[9+] нәрсәләрне башка йиргә күчерсен иде. Тентү булмый калмас – эләгеп әрәм итәрләр.

Егетләр сүзсез кул алыштылар. Кояш батышы ягыннан болыт чыгып, күк йөзенә бер буй кара пәрдә сузылды, ай да ёртылай капланды. Качкын вокзал юлына төшә торган тыкрыкка борылып гаиб булгач[1], Давыт үзенең “җәһәннәм базы”на керде. Бүлмәсе караңгы, шәм беткән, лампаның да мае юк иде. Карчыкның лапмасын карап, анда да бер-ике тамчыдан артык нәрсә күрмәгәч, Качкын китергән ливальверын[2] чоланга чыгарып яшерде дә йокыга ятты.

## IV

Ул уянганда, көндезге кояш тәрәзәгә килгән иде инде. Тыш матур, күк аяз, көн якты күренде. Ләкин таш бүлмәнең юеш һавасы белән аның бөтен әгъзасы авырайган, башында ниндидер басынкы томан эчендә кичә башлап та бетерә алмаган мәктүбенең аерым җөмләләре йөри иде. Суынган самавырдан тәмсезләнгән авыз белән берничә чынаяк чәй эчте дә, Булатов килгәнче бетереп куйыйм дип, кулына каләм алды.

Өенә хат язу дигән нәрсә аның өчен һәрвакыт авыр, бик авыр хезмәт иде. Бүген язарга мәҗбүр булган мәктүбе исә башка вакыттагыларыннан әллә ничә кат авыр күренде. Бер-береңне яратасың, аларның хәтерләрен калдырасың килми. Ләкин арада заманнанмы, табигатьтәнме туган шундый зур, аша чыга алмас мәртәбәдә тирән булган дәрья бар ки, үзең уйлаганча язсаң, алар аңламаячак, алар җә үпкәләячәк, рәнҗеячәк, җә сине эштән чыкканга санаячак. Ялганларга тел бармый. Шуңар күрә соңгы көннәрдә һәрбер хат аңар тау күчерү кебек иде. Ләкин язмаска да мөмкин түгел. Сеңелесе Бибизәйнәпне кияүгә бирәләр. Тиздән туе булачак. Аңар өеннән берьюлы ике мәктүб килде. Һәр икесе авылга чакыралар. Зәйнәп, кыз кешегә үзенең кияве, туе хакында язу оят булганга, ул турыда һичбер сүз әйтмәсә дә, чакыруында бик ихласлы:

– Абый, сине бик сагындык... Бер кайтып китәр иден! – ди.

---

[1] *Гаиб булгач* – күздән югалгач.

[2] *Дөресе*: револьверын.

Анасы Фагыйлә карчык исә егетнең иркенә бер дә куймый:

– Гомердә бер килгән шатлык. Сеңелеңне мәхрүм итмә, кайт, ишет бер үк: кайт, сүземне тыңламасаң, мәңге, мәңге бәхиллегемне бирмәм, – ди.

Давыт, моңар каршы ни дисә дә, җуатырлык тапмады... Ни язарга?

– Хәят кайный... Хәзерге көннәрнең бер сәгате бөтен гомергә тора. Мондый вакытта мин, сезнең туегыз дип, көрәш мәйданыннан китә алмыйм, дисәң, бу каты гына түгел, рәхимсезлек тә булачак, сине сөйгән ике җанны бәхетсез ясау булачак...

Ләкин ничек аңлатырга? Адәм телендә нинди сүз бар ки, мин аны языйм да, алар аңласыннар, табигый табып, мине гафу кылсыннар... Андый сүз юк, ни генә язсаң да, коры сүз булачак, аңлашу мөмкин булмаячак, ни генә язсаң да, минем көләч йөзле, әдәбият сөюче, юаш, мөлаем табигатьле Зәйнәбемнең: “Абый мине санга сукмады...” – дип хәтере калачак. Ана, бөтен гомерен шул ике бөртек баласы юлына корбан кылган газиз ана исә:

– Бала, бала, бала, дидем. Алар өчен киясемне кимәдем, ашыйсымны ашамадым. Алар үссеннәр, алар адәм булсыннар, дидем. Үстеләр, адәм булдылар... Инде ни? Менә ул безнең гомеребездә бер килгән шатлыгыбызга кайтырга ун көн вакытын кызгана... Үсте, инде мин кирәкмидер шул... – дип, аның карт күңеле, башка һичбер ни белән төзәлмәс мәртәбәдә сыначак...

Шул уйлар аны туган иленә алып киттеләр. Оренбург губернасында Уралга якын һәйбәт бер йирдә йиденче бабалары Садыйк кантон заманасыннан калган[10+] зур бакчаның карт агачлары арасында сеңелесе Бибизәйнәп белән уйнаган вакытлары, бу ун яшендә чакта атасының вафаты, болар икәү, зиярәткә барып, аталарының кабер туфрагына аунап-аунап җылаулары, бер ачлык елны аналары, кантон заманыннан калып, инде яртылай хәрабәгә әйләнгән зур сарайны, искедән калган сагынмалык иде дип, күз яше белән кызгана-кызгана җимерттергән чаклары берәм-берәм аның хәтереннән кичтеләр. Ул тагы бер сүз табасы, ансыз да боек яшәгән сеңелесе белән анасының күңелен калдырмаска теләде. Ләкин ул юк иде. Ни генә әйтсә дә, аңлашып булмавы ачык хис кылына иде.

– Гафу итегез, бик теләсәм дә кайта алмыйм... – диюдән дә артык нәрсә чыкмады.

Ул язып бетереп конвертлауга, Булатов та килде.

## V

Аның башында кокардасы алынып ташланган учитель фуражкасы, өстендә кызыл күлмәк, билендә зур чугы салынып торган кара зинар[1] иде.

---

[1] *Зинар* – нечкә билбау.

Урта буйлы, киң җилкәле, нык, таза гәүдәле, кара мыеклы, чын ир йөзле бу егет, вакыйгда[1] аннан күп ким булса да, бер карау белән утыз яшьләр бирергә мөмкин булырлык иде. Бүген исә Урманов аны тагы картая, басыла төшкән күрде.

– Ниләр бар, Зариф?..

Ул салмак кул белән чалбар кесәсеннән “Вестник” газетасын[11+] чыгарды.

– Ват[2], мона өченче странитсасын[3] кара... Егор турында бар.

Булатов әле һаман җыеп алынмаган кечкенә өстәлгә килеп, суынган самавырдан чәй ясады. Урманов газетага тотынды. Өченче битнең башында ук эре хәреф белән язылып, өстенә кызыл белән сызылган “Анархист Егорның эләгүе” дигән мәкалә ялтырап ята иде.

Мәшһүр профессорның угылы булу, реальныйда чагында[4] ук күп шау-шулар кузгату илә исеме халыкка мәгълүм булган Егор хакында рус газеталары “бер мәртәбә эләккән” дип, икенче көнне үк “ул түгел, имеш”, дип, берничә мәртәбә төрле хәбәрләр чыгара торганнар иде. Башта бусы да шундый хәбәрләрнең берседер дип күңелгә килсә дә, вакыт чыгу белән Урмановның шөбһәсе үзеннән-үзе бетте.

Бөтен тасвир аңа тугры килә. Хәбәр янында кыскача тәрҗемәи хәле дә бар: аның, реальныйда чагында, алтынчы сыйныфтан ук идарә белән бозылышуы, тик атасының мәшһүр профессорлыгына, Егорның үзенең бик сирәк очрый торган зирәклегенә ригая[5] йөзеннән генә аны кумый чыдаулары, берничә мәртәбә мөгаллимнәр һәйәте аны “киңәш”кә чакырып, юк-бар белән булышмау хакында:

– Үзегезне әрәм итмәңез... Сездән зур фән адәме чыгарга мөмкин... – дип, үгетләүләре, ләкин ул:

– Мин сезнең белән килешә торган адәм түгел... – дип, реальныйдан чыгуы, шулай да, хосусый сурәттә тиз арада имтихан тотып, университетка керүе, ләкин анда 1-2 лекциядән соң укуны ташлавы, соңра бөтенләй сәяси дулкыннар эченә кереп китүе аның, гомумән, кискен, кызу табигатьле идеке, иптәшләре эчендә дә партиянең иң сул канатында торуы[12+], ни сәбәп беләндер партиядән чыгуы, бераз вакытлар кайдалыгы мәгълүм булмавы, тик ... станциясендә җитмеш меңне басучылардан бере сыйфаты илә тотылган егетнең шул Егор булып танылуы язылган, асылачагы ихтималланган иде.

---

[1] *Вакыйгда* – чынлыкта.
[2] *Дөресе*: вот.
[3] *Дөресе*: страница.
[4] *Реальныйда чагында* – һөнәргә өйрәнү мәктәбендә укыган чорында.
[5] *Ригая* – хөрмәт.

Боларның күбе Урмановка мәгълүм иде, шулай да үзе белән байтак вакыт бүлмәдәш, үзенә бер вакытлар репетитор һәм иптәш булган ул яшь студентның асылачак яки асылган ук булу хәбәре аның башына нindидер мәгънәсез бер куәтнең килеп сугылуы кебек тәэсир итте. Аның йөзе агарынды, күкрәге кысылды, үзен басмыйча, урыныннан торып, Булатов каршына килде. Тавышы ят һәм кискен иде:

– Син ни уйлыйсың? Бу да теге хәбәрләрнең берсе түгелме?..

Зариф стаканын куйды:

– Анда... дүртенче страницада ул түгел, имеш, дигән бер нәрсә дә бар... Ну, мин ышана алмыйм.

Чыннан да, дүртенче битнең иң ахырында гәзитәбез басыла башлагач ишетелде дип, эләгүченең Егор булмавы, бәлки, аңар охшаш нindидер бер яһүди егете идеке әйтелгән иде. Булатов шикелле Урманов та бу хәбәргә ышана алмады. Нindидер эчке бер тавыш: “Ул, ул, ул!.. Шөбһәсез, ул!” – дип кат-кат әйтеп тора иде.

Газетада аның партиядән чыгуы “ни сәбәптәндер” диелсә дә, Давыд белән Булатовка бу мәгълүм иде. Ул, гомумән, иң сул канатта тора, партияне сүз белән гомер үткәрүдә, куркаклыкта гаепли иде. Бер ел көз аның тарафыннан бик зур үтереш белән куркыныч талау хакында комитетка план гарыз иттеләр[1]. Комиттетта бу үтмәде. Шуннан соң ул партиядән чыкты. Урманов белән “җәһәннәм базы”нда бергә яшәгән вакыты менә шуннан соң иде. Яшьләр һәммәсе аны яратса да, ул үзе күп кеше белән килешә алмый. Партиядән чыккан соң, инде мондагылар белән бөтенләй диярлек өзелгән иде. Бик ярлы яшәде. Аягына кияргә булмаганлыктан, яңгырлы көннәрдә һичкая чыга алмый, шул өйдә ята иде. Хәбәр Урмановка шул вакытны уйлатты: “Асканнардыр, асканнардыр...”.

Шул уй артыннан аңа Егорның соңгы вакытларда башында ашыгыч план булып, туктаусыз шуны эшләмәктә булган кебек халәттә яшәве, аның гасаби йөзе, кискен, курку белмәс табигате, көне-төне тар караңгы бүлмәнең бер башыннан икенче башына кызу адымнары илә, ут кебек уйнап торган күзләрен ялкынлатып, туктаусыз йөрүе хәтерләнде. Ул тагы “асканнардыр” дип уйлады да әллә кайдан килеп чыккан зур биек дар агачы белән кара йирне, кызыл якалы җәлладны хыялыннан көчлек илә югалтырга тырышты.

Аның хакында артык сөйләшмәделәр. Булатов урыныннан торды:

– Синең квартирда тентү булыр, сиңа тизрәк моннан чыгарга кирәк... Палиция аның монда торганын белми калмас, – мин бигрәк шуны әйтер өчен килдем...

---

[1] *Гарыз иттеләр* – тәкъдим иттеләр.

– Юк, мин күчмим... Мондый уңай квартирны кайдан табасың...

– Алайса, эләксәң, нәрсәләр китә...

– Берсе дә китмәс... Мин аларны күчерәм, үзем монда калам.

Шулвакыт акрын гына ишек ачылды да башларына сай кара бүрек, өстләренә җөббә[1] кигән ике егет килеп керде. Һәр икесе бераз алга таба бөгелгәннәр, ябыклар, күзләре хәлсез карый, йөзләре кәфендәй ак, мөгамәләләре оялчан иде. Урманов боларны ярым көлке рәвеш белән мәдрәсәи исламиянең иң сул, мөтәрәккый[2] шәкертләреннән дип таныштырды.

– Безгә җилем басма кирәк иде... “Ислах мәдарис”нең сигезенче номеры[13+] чыгарга вакыт. Мәкаләләр дә бар... Басмабыз бозылды... Сез биреп тора алмассызмы? – диделәр.

– Бик мөмкин... Бик вакытлы килдегез... Аны да бирәм, тагы берничә нәрсә бирәм... Сез кайда, Нигъмәт казый фатирында басамсыз? Бик тыныч йир.

Ул чоланнан басмасын, зәңгәр кара белән байтак глицерин, бер кочак вак брошюралар, прокламация, револьвер, тагы ниләрдер алып керде дә, караватта аунаган зур рус гәзитәсенә төреп, шәкертләргә бирде:

– Хәзергә шул Нигъмәт казый фатирында торсыннар. Мин аларны тиз арада икенче йиргә күчерермен.

Шәкертләр юаш, акрын тавыш белән исәнләшеп чыгып киттеләр.

Урманов бераз җиңеләйде:

– Менә хәзер тенти бирсеннәр.

Булатов кесәсеннән ике дәфтәр чыгарды:

– Менә теге “Йир” белән “Капитал кайдан туа?”ны алып килдем. Бик күп русчалар китте. Син шуны русчагамы, гарәпчәгәме ясар идең...

Урманов боларны мендәр астына тыкты. Булатов тагын башлады:

– Монда бер егет бар, Маркcның “Капитал”ын[14+] татарчага чыгарсак, ди... Син ни уйлыйсың?

– Кайда Маркс, иптәш? Татар аны укымый да, аңламый да... Сез барыгыз да рус социалистлары калыбыннан сугылгансыз... Татарга ул рамкалар ярамый. Аны кузгату өчен дингә кысынкылыктан, хөкүмәтнең хаҗга йибәрмәскә, Коръәннең кайбер аятьләрен бастырмаска теләвеннән, миссионерлардан, чукындырудан башларга, аннан соң йир-су азлыгы, түләү күплеге хакында, миссионерлар фәлән кебек, иң садә нәрсәләр бирергә кирәк. Маркстан аңа җылы да юк, суык та юк...

Урманов бераз туктаган соң, яңадан башлады:

– Ну, теге турыда нәрсә? Бүген төнлә мин Сәрүҗине озаттым. Ул, синнән хәбәр булыр, диде.

---

[1] *Җөббә* – җиләннең бер төре.

[2] *Мөтәрәккый* – алга киткән.

– Миннән хәбәр шул, – дип, Булатов берничә сүздә анда бу эшкә яхшы карауларын, ат бирәчәкләрен, ләкин акча белән ярдәм булмаячагын, партия боңар үз эше итеп катышырга мөмкин күрмәвен, чөнки аның максаты хөкүмәт белән көрәшү икәнен, әмма бер халыкның руханиларына каршы корал күтәрү партиянең программасына килми диюләрен сөйләде. Урманов, кызып, урыныннан торды:

– Иске әкият... Миңа аны кырык мәртәбә тукыдылар инде... Тоталар да хөкүмәт белән көрәшү диләр, программа диләр, программа хәрефенә килеп бетмәвен мин үзем дә беләм. Ләкин без хәрефкә түгел, рухка карарга кирәк, татар кем кулында? Аны караңгыда, тәгәссыбта[1] саклап, хөкүмәткә терәк булучылар революциягә файдалымы, зарарлымы? Зарарлы булса, аңар каршы авыз ачып торырга, диме? Мин аңламыйм, ничек бу...

– Тукта, син ник кызасың...

– Кызмаска мөмкин түгел... бөтен татар дулкыннан ярлы якта... Мәсҗед мөнбәрләреннән фетнәчеләр арасында бер мөселманның карасы күренмәсен, кызыл флаглылар эчендә бер мөселман күренү – бөтен исламга йөз каралыгы булачак дип вәгазь сөйлиләр... Мин, партия боны үзе эшләргә кирәк, димим, заман рухы белән җанланган мәдрәсә яшьләре бу елда бер эшкә тотынмакчы... Ләкин алар тәҗрибәсез, алар ярдәмгә мохтаҗ... Шулвакыт бу яктан иң ансат җавап: “имеш, программа, хөкүмәт”. Теләсә ни дисеннәр, ләкин мин аңламыйм. Минемчә, мәдрәсә яшьләренең ул дәртләре якланырга тиеш...

– Якламыйлар түгел, ич...

– Ул аз...

– Тагын нәрсә эшләр идең?

– Партия кеше бирергә... Үзе юлга куярга... Коры тел белән түгел, кулы белән дә булышырга.

– Менә син булышасың, ич.

– Бер кеше аз...

– Тукта, миңа шуны объяснить ит... Алар ничегрәк башларга уйлыйлар...

Урманов өстәлдә тузылып яткан китаплар эченнән кечкенә бер кәгазь чыгарды:

– Менә аларның эшли башлаган программалары. Алар аны “Фидаиләр” исеме белән бер партия[15+] рәвешенә кертмәкчеләр... Син теге хәзер төрмәдә утыра торган Баязидны беләсеңме? Бу эшнең иң шәп батыры шул булачак.

[1] *Тәгассыбта* – фанатизмда.

Алар эшләренең бисмиәсенә[1] ...не сайларга уйлыйлар. Ләкин боның белән калмаячаклар... Кавказларның “дифагый”ләрен[16+] ишеткәнең бармы... Ул бит байтак эшли. Болар да үз сүзләре белән әйткәндә “милли террор” нигезләмәкчеләр. Хәзерге планнарында: баш рухани, ике карт ахун, өч зур ишан. Алар иң элек менә шул алты җан белән исәпләшмәкчеләр.

– Аннан соң?

– Аннан соң эшләре бер партия рәвешенә кереп китсә, систематически тотып, татар эчендә караңгылыкның зур баганаларын аудару... Бара торгач, татар дөньясына катышлы хөкүмәт адәмнәренә таба атларга да фаразлары бар...

– Ә син үзең бер эш чыгаруларына ышанамсың?

– Башламас борын, ни дияргә дә авыр. Ләкин бу фикер шәкерт фаразы гына булырга охшамый. Бу берьюлы төрле якта кузгалды. Уфа, Әстерхан, Оренбург, Казан, Троицки кебек йирләрнең барында да мәдрәсә яшьләре эчендә боңа бик ашкынып караучылар бар. Беренче адымнары берничә көннән булачак... Баязидны залог белән чыгарырга булдылар. Ул чыгу белән...

Тегеннән ишек ачылып, почтальон хат кертте.

Булатов, урыныннан торып, фуражкасын алды:

– ... Без... соңга да калабыз... Бүген митинг бар, татарларның собраниесе дә була... Мин киттем.

Булатов киткәннән соң, Давыд бераз хатларын, кәгазьләрен мич алдына өеп, ут төртте. Кайберләрен кесәсенә алды да башына озын җонлы чиркәс бүреге, өстенә чыланмый торган бер катлы җылтыр пальто киеп, урамга чыкты.

## VI

Аңар Фәйруз Ширинскийлар квартирына барып, боларның кызлары Рауза туташка теге студент Колядагы нәрсәләрен күчерү кирәклеге хакында хәбәр итәсе бар иде. Екатеринский белән ике чат баргач, керим дип борылган бер катлы сары өйнең кечкенә капкасы ачылды да аннан башына киң читле арзанлы кара эшләпә, өстенә садә кара кием кигән озын буйлы, кара туткыл йөзле, егерме ике яшьләр чамасы булыр курсистка, бер кулына ридикюль, икенчесенә китап тоткан хәлдә, каядыр ашыккан адәм кебек җилкенләнеп[2] килеп чыкты.

Бу – курслар ябылу сәбәпле, Питербурдан кайтып, хәзер татарлар арасында эшләмәктә, беренче сәяси түгәрәкләрдә, үз тәгъбиренчә,

---

[1] Бу урында *“бисмилласына”* дип аңларга кирәк, ягъни эш башына.
[2] *Җилкенләнеп* – ашкынып, җилкенеп.

рефератлар укымакта, күпләр, бигрәк тә мәдрәсә яшьләре тарафыннан бик сөелеп тыңланмакта булган Рауза туташ иде.

Урмановны күрү белән, аның аяклары тагы җиңеләя төште, карасу йөзе ачылып, зур, кара күзләре матур дустанә елмайдылар. Һичбер сүз димичә, ир иптәшләр арасындагы кебек тәкәллефсезчә кулын бирде.

– Сез каядыр бик ашыгасыз, бугай... Минем Сезгә бик аз гына йомышым бар, – дип, Урманов теге нәрсәләрен күчерү хакында сүз башлады.

Аларның юллары бер якка таба иде. Рауза туташ:

– Бик күп чаптым, страшно арыдым, – дип, егеткә кулын салды. Икесе бергә Вознесенскийга таба борылдылар. Чиркәүгә чаклы бергә баргач, Рауза туташ өч катлы кызыл бинаның тышкы ишеге янына туктады:

– Мин монда керәм...

Урманов аның күзләренә бераз гаҗәпсенгәндәй карады:

– Ничек... митингыга бармыйсызмыни?

Туташ, үз-үзенә хуҗа түгеллегеннән борчылган адәм кебек, кулындагы ридикюлен селекте:

– Әйтмәңез. Үземә дә страшно досадно... ну. Шулай туры килде инде... Без Мариинскаяның гимназисткалары[17+] арасында бер политический кружок ясаган идек... Шуның бүген беренче җыелышы. Мин фарансуз революциясе[18+] турында реферат укырга булдым... Просто досадно... Икесе бергә туры килделәр...

Ул берничә секунд туктап торып, тагын башлады:

– Шулай да мин мөселманнарның собраниесенә барырга тырышырмын... Ну, пока, до свидания...

Туташ, үзенең озын гәүдәсе белән җилкенләнеп, таш баскычтан югары таба очты. Урманов почтага кереп чыкты да, ашыга-ашыга, митингка китте.

## VII

Соңгы көзнең тиз үзгәрүчән һавасы шул арада бозылып та өлгергән, кояш капланып, күкнең бер ягыннан икенче ягына таба куәтле җил белән куылган соры калын болытлардан эре суык яңгыр төшә, иртәнге аяз вакытта бераз сүрелгән аяк асты тагын пычрана башлаган иде. Ләкин бу халыкны тыя алмаган.

Урманов килгән вакыт шәһәрнең киң мәйданы кара болыт кебек халык белән капланган иде инде. Гүя, башка йирдә хәят туктаган, гүя бөтен шәһәр, үзенең көнлек вак кайгыларын ташлап, ниндидер бер куәт белән бу мәхшәргә тартылган диеләчәк рәвештә киң мәйданның бер ягыннан икенче ягына

дулкынланып, гөрләп торган бу халык диңгезе эчендә, ак өстендә кара кебек, бераз мөселман агай-эне дә күренде. Ләкин болар, бердән, азлар, икенчедән, килгәннәре дә үзләрен чит тоталар, без митингның чын әгъзасы түгел дигән кебек күренәләр иде.

Соңга табарак агарынган йөзле мәдрәсә яшьләре белән приказчиклар арта башлады. Урманов белән бергә эшләүче яшьләрдән зур гәүдәле, зур сары мыеклы Госман, нәзек, аристократ кыяфәтле реалист Акчулпанов, гимназист формада, ләкин бик искергән киемле Тангатаров күзгә чалынып үттеләр.

Теге кызыл флагчыларга катнашу өчен тар тыкрыкта кыйналып тәүбә иттерелгән яһүд приказчыгы, Габдрахман да килеп күреште. Ул үзенең озын буе, нечкә, бераз алга яткан гәүдәсен, сирәк сары мыегы, бусы бераз кылый булган соры күзләре, туктаусыз көләргә торган нечкә иреннәре белән ничектер бер хәйләле адәм кебек күренә иде. Нилеп кулын бирүгә сул күзен кылыйлатып көлде дә:

– Ну, малай, яңакны эштән чыгардылар бит, эт авызлар… Җитмәсә тагы кәләш алырга йөргән чакка туры килде… – дип, ике як яңагыннан аша бәйләгән ак яулыгын күргәзде. Урманов моны ишетсә дә күргәне юк, бик ышанып та бетми иде. Габдрахман, ахрысы моны сизде булырга кирәк, кулындагы кечкенә брошюрын кесәсенә тыкты да бик саклап белән яулыкны чиште.

Урманов йөзен чытып, бәйлә, иптәш, диде. Чыннан да, егетнең уң як колак арты чиләнеп, канланып тора, сул як чикәсе күгәреп, кара янып чыккан иде. Габдрахман килеп бәйләде дә, ашыгыч, ярым көлке, ярым ачулы тавыш белән үзенең әүвәлге хуҗасы яһүдтә икәнлеген шәһәрдә пагром була дип хәбәр таралгач, аның магазиннарын ябып, әллә кая качып китүен. шуннан соң болар рус иптәшләре белән урамга чыгып кызыл флагка кушылуларын, шул көн кич өенә кайтып барган вакыт тар тыкрыкта үзенә таныш ике татарның адсыәлае:

– Ник мөселман йөзенә кара ягып йөрисең… – дип һөҗүм кылунарын сөйләргә тотынды. Ул бетерә алмады, моңарчы умарта корты кебек мең аваз белән гөрләп торган мәйдан өстеннән русча: “Иптәшләр, хәзерге көннәр...” дип башлаган калын, куәтле тавыш үтте.

Мәйдан тынды. Хатиб дәвам итте. Аның сүзе – хөкүмәтнең халыкка мөнәсәбәте, парламентаризмның хаятка күрсәтәчәк файдасы, тәэсире хакында иде. Озынча нечкә карасу йөзле, кыска кара сакаллы, зәһәр кара күзле бу яһүди адвокаттан соң, Урмановлар тирәсенә якын билгеле булган студент юрист, теге асылу хакында хәбәре чыккан Егорның туган агасы Коля күтәрелде.

Җитү сары чәчле, соры күзле, сары чын рус йөзле, кызыл күлмәкле бу егет монда партиянең иң эшлекле, тәҗрибәле әгъзаларыннан һәм беренче хатиблардан санала иде. Беренче сүзе белән бөтен халыкны үлем тынлыгы хәленә китереп, сәгатькә якын дәвам иткән кызу хотбәсендә ул, кайта-кайта, бик зур әһәмият илә шул фикерне куәтли:

– Бирукратия[1] кулындагы хәзерге хөкүмәт белән көрәшү – бу тик беренче адым. Түбән сыйныфка канститутсия[2] булды да дөнья тәгалләнде, дип уйларга мөмкин түгел. Хәзерге хөкүмәт безнең дустымыз булмаган кебек, бирукратия кулыннан буржуазиягә күчсә – ул хөкүмәт тә безнең аркамыздан сыйпамаячак. Монда парламентаризм, диләр. Ләкин эшче халык онытмасын ки, бу хөррият өчен көрәшүчеләр эчендә либерал буржуалар бар. Бервакыт килеп, хакимият аларга бирелсә, бүген хөррият каһарманы булган ул либераллар эшче-крәстиян халкына каршы тагын туп, мылтык белән чыгачак... Либерал буржуа – бу безнең явыз дошманыбыз. Мәзмунында[3] сөйләп, эшче-крәстиян, гомумән, түбән сыйныфның көрәшүе кай мәртәбәгә чаклы барырга тиешлеген бәян итте.

Аңар, бөтен дөньяны яңгыратып, кул чаптылар...

Аңардан соң берничә адәм сөйләгәч, Зариф Булатов мендe. Аның башында баягы кокардасыз учитель фуражкасы, өстендә кызыл күлмәк иде. Ләкин Урманов аны чак таныды. Һәм аның төсе үзгәргән йөзендә, ниндидер бер таш диварны сикереп ватарга хәзерләнгәндәй, ачу катыш гайрәт балкый, күзләрендә ут уйный иде. Ул үзенең укуы ягыннан ерак түгел, тик, шәһәр мәктәбен бетереп, ике ел педагогия курсларында булган. Шулай да, рус арасында яшәү сәбәпле, русчасы яхшы, татар яшьләре эчендә хатиблыгы да алдагылардан санала иде. Сүзе хөкүмәтнең халыкка мөнәсәбәтеннән алып, аннан Русиядәге төрле милләтләрнең үткән вә хәзерге хәлләре, Кавказда әрмәннәр белән татарларның бер-берләрен кыруларының[19+] төп сәбәбе кайда, кемдә икәнлеге, гомумән, эчке Русия татарларына каршы хөкүмәтнең нинди мөнәсәбәттә булганлыгы һәм кысылулар хакында тәфсыйл итә башлады. Русчаны аз аңлаган, шуңар күрә әүвәлге хатиблардан күп тәм таба алмаган мәдрәсә яшьләре, алар артыннан приказчиклар, үз татарларыннан Булатов сөйли башлау белән, кысылып-кысылып эчкә тыгылдылар да хатибның авызына карап каттылар. Ләкин аңар күп сөйләргә туры килмәде. Үзенең нотыгында ул:

– Монархиянең егылу сәгатьләре җитү белән, пәрдә астындагы... –

---

[1] *Дөресе*: бюрократия.
[2] *Дөресе*: конституция.
[3] *Мәзмунында* – әйтергә теләгәнендә, эчтәлегендә.

дигән беренче җөмләсе белән иң зур митингларда да сөкүт кылынып[1] үтелә торган мәсьәләгә кагылды. Якындагы палитсә аңар туктарга куша, ләкин хатиб полициягә илтифат итмичә дәвам итә. Ул арада берничә полицейски Булатовның өстенә атыла, халык кайный башлый, тәртип бетә. Полиция Булатовны ала алдымы, юкмы – Урманов буталган халык эчендә аны күрмәде. Ләкин митинг, әүвәлге рәвешен бөтенләй югалтып, тирәдә полиция артты. Полицийскийлар, казаклар, халыкны җырып, уртага керә башлыйлар. Халык таралмый, хатиблар бер-бер артлы сикереп күтәреләләр дә нидер сөйләргә тырышалар. Берничә эшче күтәрелде, аларны алу белән, баягы яһүди адвокат, аның артыннан Коля күтәрелде. Ул шул дәрәҗәдә кызган иде ки, тавышы чыгып өлгерә алмый, бугазына нидер тыгылып, шунардан йөзе кара кызылга әйләнә, сүзләре буылган кешенеке кебек чыга иде... Полиция тагы көчәйде, тирә-якны казаклар чорнап, халыкны көч белән тарта, таптый башладылар.

Арада бәрелешү китте.

Нәтиҗәдә, яһүди адвокат, Коля, өч эшче кулга алынды. Митинг, гаскәр куәте белән таратылып, беразлар аерым-аерым китте. Күбрәге эшчеләрдән гыйбарәт булган бу зур гөруһ[2] исә зур урамга чыктылар да, пплициянең тыюына карамыйча, бөтен шәһәр күтәреләчәкме, йа Ходай диеләчәк бер куәт илән “Выпали жертвой” дип җырлап, соборга таба агылдылар.

Урманов театр ягына борылды.

## VIII

Монда бүген мөселманнарның Думага сайлау алды җәмгыятьләреннән бере булып, Урманов килгәндә театр бинасы галереясенә кадәр бишмәтле, бүрекле әһле ислам белән шыгрым тулган иде. Ул, тыгызлана-тыгызлана булса да, партерга керә алды. Икенче каттагы ложаларның берендә теге аристократ кыяфәтле Акчулпанов, Рауза туташ, гимназист Тангатаровлар күренделәр. Җәмәгать бик чобар[3] иде. Элекке җәмгыятьләрдә халыкның күбрәге мәдрәсә яшьләре белән приказчиклар була килсә дә, бүген кайбер мөтәрәккый[4] имамнарның җомга намазыннан соң: “Җәмәгать, бармый калмаңыз”, – дип вәгазьләүләре аркасында булса кирәк, иң түбән талчокчы агайлар да театрга агылганнар, һәммәсе, авызларын ачып, сәхнәдә президиум янында европеец кыяфәтле, сүзендә, мөгамәләсендә бераз госманлычылык

---

[1] *Сөкүт кылынып* – дәшмичә, әйтелмичә.
[2] *Гөруһ* – төркем.
[3] *Чобар* – чуар.
[4] *Мөтәрәккый* – прогрессив.

әсәре сизелмәктә булган хатибка карап шаккатканнар иде. Урманов бер иптәше белән урындык уртаклашты.

Хатиб дәвам итте:

– Мөхтәрәм Садыйк хәзрәтнең фикере бик тугрыдыр, әфәнделәр. Хәзрәтнең дидеге кеби, безем дини ихтыяҗларымыз бик күп, Думада алар каралачак. Аларның шәригатемезгә муафыйк[1] рәвештә хәл ителмәге өчен барачак мәбгусләремезнең[2] динемездән хәбәрдар улмаклары лязем. Моңар каршы һичбер шәй[3] диячәгемез юк. Фәкать, әфәнделәр, шуны да хәтердән чыгармаялым ки, мәмләкәтемез – рус мәмләкәте. Думада сүз үткәрә белмәк өчен, әфәнделәр, рус лисаны[4] илә бәрабәр заманның әхвәл вә гидешенә вакыйф[5] мәмләкәтемез низам вә каванинә[6] әшнә улмак ляземе[7] дә һәммәңезә мәгълүмдер, әфәнделәр... Әгәр мөхтәрәм имамнарымыз, могтәбәр хәзрәтләребез арасында бу илә икътидарлы[8] затлар булса, мәгалмәмнүниять интихабә[9] хәзермез... Фәкать, әфәнделәр, дин вә милләтемез юлында хезмәтләре сәбәкать итмеш[10], могтәдил[11] фикерле зыялыларымызы сайлаячак улсак, фикер гаҗизанәмә[12] күрә, дәһа[13] исабәт итмеш[14] улачакмыз... Чөнки безнең мөкаддәс динемез...

Хатибның нотыгы ярты сәгатькә якын барды. Аңа бик озак, бик каты кул чаптылар.

Ләкин бу кул чабу арзан үтмәде. Партерның җиденче рәт урындыкларыннан берендә һәммә сулларны гына түгел, җәдид мөтәрәккыйларны да кабахәт сүзләр белән сүгүдә татар базарының каһарманы саналган тиречe Гайнетдин бар иде, халык кул чаба башлау белән, ул җенләнгән адәм кебек урыныннан сикереп торды да, чите камалы тирән бүреген баса төшеп, җиңнәре, күкрәкләре майланып беткән киң казакие белән җилләнгән хәлдә кулларын бутый-бутый, нидер сөйләргә, акырырга, тотынды. Алкыш арасында аның ни дигәне ачык беленми, тик:

– Бу ни эш?!.. Ә?!.. Бу нинди эш, ә?!.. Без урысмыни?.. Сез кайчан

---

[1] *Муафыйк* – яраклы.

[2] *Мәбгусләремезнең* – депутатларыбызның.

[3] *Шәй* – нәрсә.

[4] *Лисаны* – теле.

[5] *Заманның әхвәл вә гидешенә вакыйф* – заманның хәлләреннән хәбәрдәр булу.

[6] *Низам вә каванинә* – тәртип, кануннар.

[7] *Әшнә улмак ляземе* – дус булу тиешлеге.

[8] *Икътидарлы* – булдыра алучы.

[9] *Мәгалмәмнүниять интихабә* – шатланып сайларга.

[10] *Сәбәкать итмеш* – бәяләнерлек, бүләкләнерлек.

[11] *Могтәдил* – уртача.

[12] *Гаҗизанәмә* – көчсезлегемә.

[13] *Дәһа* – аеруча.

[14] *Исабәт итмеш* – дөреслеккә ирешкән.

чукындыгыз?.. Ә?.. Ник кул чабарга... Бу бит урыска охшау була... – дигән кебек аерым җөмләләре генә аңа якын утырган адәмнәргә ишетелә иде. Кул чабу туктагач, ул тагы кыза төште, аның башка вакытта чиртсәң кан чыгар мәртәбәдә кызыл булган йөзе ачудан каралып бүртенгән, күзләрен кан баскан иде. Ул кычкыруында дәвам итте. Башта: "Сез ник кул чабасыз, сез кайчан чукындыгыз", – диде. Аннан соң:

– Сайлау, сайлау, диләр, монда җыен кыска койрык җыелып, эшне кулларына алганнар да хәзрәтләр артта кысылып утыралар... Кыска койрыклар үзләре сайланмакчы да анда Петербург марҗаларына динне сатып кайтмакчы... Голяма барсын... Хәзрәтләр барсын... Безгә дин кирәк... – дип дулый башлады...

Рәис аны көч белән тыеп:

– Сөйләргә сүзеңез булса, нәүбәт алыңыз, агай... – диде, Гайнетдин тагы сикереп торып:

– Мин нәүбәт-мәүбәтеңезне белмим... Петербургка голяма барсын, бетмәс монда кыска койрыклар, – дип кычкырды.

Рәис тагы туктатып:

– Белмәсәңез, тик утырыңыз, юкса мин сезне полиция белән чыгартачакмын, диде.

Гайнетдиннең каны бераз басыла төшкән иде, үзалдына нидер мыгырдады да:

– Чыгартыр, эт, чыгартыр, аның иманы юк, урыс полициясе белән бер кашыктан ашый ул эт... – дип, урынына утырды.

Гайнетдиннән соң нәүбәт Каргалы шәһәреннән килгән мосафир – имамнардан Габдулла әфәндегә иде. Аның киң нурлы йөзе, бик аз чал кергән түгәрәк сакалы, кара юллы ак чапаны, бик шомалап чалган һәйбәт чалмасы, ничектер, һәммә кешедә җылы бер илтифат[1] уйгаттылар. Аның сүзе дә табигый ага, тавышы да ягымлы иде.

Ул, Думага голяма барсын, динебезне белгәннәр барсын, дип сөйләде. Аның өстенә хөкүмәттән имамнарга жалуния[2] сорарга кирәк. Һәрбер имамга үзенең мәхәлләсендәге фисык-фәсадны[3] тыярга, эчкән кешеләрне яткырып суктырырга хокук бирелсен, диде.

Аңардан соң тагы берничә хатиб шул сүзләрне тәкрар иткәч, имамнар арасында инсафсыз телле булуы белән танылган яшь егет Дашкин сүз алып:

– Муллалар анда бер тиенгә дә ярамый... Үзегез уйлап караңыз: монда урядник белән полицийски алдында дер калтырап, куркуыннан иманнарын

---

[1] *Илтифат* – хөрмәт.
[2] *Дөресе*: жалованье.
[3] *Фисык-фәсадны* – бозыклыкны, азгынлыкны.

укый башлаган татар мулласы анда, хөкүмәт каршына барып, ни кыла алыр... Думага халык кирәген алырга баралар. Анда үлек күмәргә адәм кирәкми... Анда хәез, нифас[1] турында фәтва да сорамаслар... Шулай булгач, хәзрәтләр нигә... – дип сөйләде.

Дашкиннан соң Садыйк хәзрәт торып, бик сабыр, бик озын сүзләр белән:

– Җәмәгать, ашыгып карар бирмәңез... Безнең беренче teләгемез – дин... Боны голямадан башка кем белә... – диде.

Секретарь Давыд Урманов исемен кычкырды.

Җылтыр пальтосы, озын җонлы чиркәс бүреге белән Урманов аякка басты:

– Гасырлар буенча голяма, голяма, голяма дип тордык. Һәммә эшне аларга тапшырдык, алардан гына көттек... Нәтиҗәдә, халкымыз менә шул кызганыч хәлгә төште. Ничә еллык тәҗрибә безне уятырга тиеш, халкымыз үзенә кем дошман, кем дуст икәнен аерырга бик вакыт иде, – дип, башта голяма сайлау хакында җавап бирде дә соңра "Иттифак әл-мөслимин" әһеленә[20+] борылды:

– Монда һәммә бүреләр җә сарык, җә куй тиресенә төренеп йөриләр. Бер як дин, ди, шәригать, ди. Шул пәрдә белән капланып, Думага үтмәкче. Икенче як милләт, ди, тәрәккый, ди, игътидал[2], ди, шул аулар белән халыкны үз артына ияртмәкче дә, Петербургка барып, үзенең кадет дустлары арасында хозур вә рәхәттә яшәмәкче... Безгә аңларга вакыт ки, ач, ялангач һәм кысылган халкымызның ихтыяҗларын алу юлында кемнәр...

Урманов сүзенең ахырына таба бер як аяк тибеп сызгырырга, икенче як кул чабарга тотынды. Егет аягүрә баскан хәлдә шау-шуның беткәнен көтә, шау-шу да тынып килә иде, ләкин аңар сөйләргә һаман мөмкин булмады – алгы рәттән бөкре, ябык, яңаклары эчкә кергән, бөтен кыяфәте илә иске татар мәдрәсәсенең җимеше идеке күренеп торган бер адәм калыкты да әллә кайдан кысылып көчләнеп чыккан тавышы белән:

– Мин... җәмәгать... – дип кычкырып йибәрде.

Бу – Вафа хәзрәтнең иң галим пишкадәмнәреннән[3] Кәбир хәлфә иде. Ул шәһәрдә иң мөтәгассыйб[4] кадимнәрдән санала. Мәдрәсәсендәге шәкертләргә, бер җәмгыятькә адым атлаган адәм мәдрәсәдән куылыр дип игълан кылдыгы һәм шул эшләргә хәзер булдыгы хәлдә, ул үзе

[1] *Хәез, нифас* – күрем, аналык каны.
[2] *Игътидал* – урталык.
[3] *Пишкадәмнәреннән* – иске мәдрәсәнең тулы уку курсын бетергән хөрмәтле кешеләреннән.
[4] *Мөтәгассыйб* – фанатик.

җәмгыятьләрнең һичбереннән калмый, һәммәсендә диярлек алгы урыннарга эләгә иде. Ул үз тарафыннан бер фикер әйтәчәк түгел – башкалар бик күп мәгънәсезлекләр сөйлиләр, юк белән халыкның исен китәрәләр.Ул килмәкче дә, үзенең кызу нотыгы белән мәҗлестәге һәммә сүзләрне, фикерләрне рәд кылып[1] ташламакчы. Җәдид Думасын, көрәшен, кул чабуларын, барын, барын юк итмәкче.

Ул мәдрәсәдә вакытта дәресханәне бикли дә нотык хәзерли, үзенең бирәчәк игътиразларын[2] тезә – шәп тә чыга, бөтен халыкның исе китәчәк, тегеләр йөзтүбән капланачак. Ул шулай итеп җәмгыятькә килә, ләкин бинаның артык зурлыгы, меңләп халыктан гыйбарәт җәмгыятьнең мәһабәтеме, яки мәсьәләнең электән бер дә таныш булмавымы, әллә шуларның берлеге җыелыпмы, аның куәтен алалар – ул һәр мәҗлестә ничә мәртәбә аякка басып: “Мине языңыз”, – дияргә уйлый, бер вакыт каршы җавап бирергә бик шәп урын чыкканда, хатибларның нотыгы уртасында ук нидер әйтергә теләп сикереп тора. Ләкин, гөнаһ шомлыгы, һәрберендә нәрсәдер аның бугазын буа, аның тамагы кибә, күкрәге кысыла да сүзе, тавышы чыкмый, ул газап, каһәр эчендә, күз алды томаланып, кире урындыгына ава. Әгәр дә, Хода ярдәм биреп, ул бер мәртәбә сүзен әйтә, ничек кенә булса да, бер-ике җөмлә чыгара алса, аннан соң мәйдан, шөбһәсез, аныкы булачак, аның фикере су кебек агып китәчәк. Голяма мәҗлесләрендә иң зур мөдәррисләрне һәр сүздә элеп алып селкеп салдыгы, аның бу таланты һәммә кеше тарафыннан тасдыйк кылындыгы[3] кебек, бу җәмгыятьтә дә ул зур шау-шу күтәрәчәк, кырык ел мәдрәсәдә ятып, яңаклары эчкә суырылган, күзләре өмидсез карый башлаган, шулай да дөньяга сыймас дәрәҗәдә дәгъвалы, кыскартып, мантыйк моназирларыннан[4] чыннан арыслан кебек саналган бу хәлфә, ихтимал, бөтен җәмгыять алдында да үзенең кемлеген танытачак иде. Ләкин кемдер бугаздан буа, аякка тору белән күз алды караңгылана, күкрәк кысыла, тавыш югала да ул яңадан урынына аварга мәҗбүр була.

Урмановның голяма хакында ачы гыйбарәләр кулланып китүе аны яңадан урыныннан кузгаткан, ул тагы нәүбәтсез[5] булса да, сикереп торып, күп җәмгыятьләрдән бирле беренче мәртәбә: “Мин... җәмәгать...”, – дип кычкыра алган, бу юлы инде, бик мөмкин, аның хәзерләп килгән нотыгы агып та китәчәк иде. Ләкин аның зур бәхетсезлегенә каршы, җиденче рәттән

---

[1] *Рәд кылып* – кабул итмичә.
[2] *Игътиразларын* – дәлилләрен.
[3] *Тасдыйк кылындыгы* – расланганы.
[4] *Моназирларыннан* – бәхәсләшүчеләреннән.
[5] *Нәүбәтсез* – чиратсыз.

баягы Гайнетдин калыкты да, майлы җиңнәрен селкә-селкә, бөтен театрны яңгыратып кычкырып җибәрде:

– Әйтеңез!.. Алла хакы өчен әйтеңез... Бу кем бу?.. Үзе китапча сөйли, тел төбе көфергә бара... Әйтеңез, бу нинди хәл: имеш, йир кирәк, ирек кирәк, имеш, боларны алып бирү өчен, сулларны сайларга кирәк, имеш, мөселманнан андаен[1] адәм булмаса, сул фикерле руслар белән берләшергә кирәк... Әйтеңез, моны кем сөйли, бу ни дигән сүз... Безгә йир дә кирәкми, бернәрсә дә кирәкми... Безгә дин кирәк, шәригать кирәк... Урысны сайлап, дин табыла диме... Урыс синең динең өчен тырыша диме... Тот капчыгыңны!!!

Рәис тагы бик зур көчлек, бик озак шыңгырдатканнан соң аны тыйды:

– Агай, сезгә актык мәртәбә әйтәм, сүзеңез булса, нәүбәт алыңыз, тәртипне бозмаңыз, тагы бер мәртәбә нәүбәтсез сүз башласаңыз, мин сезне чыгартачакмын...

Гайнетдин тагы яман тавыш белән бөтен дөньяны яңгыратып:

– Чыгармагаең! Сүз тапты, чыгарта бир... Минем сүзем шул: монда җыен кыска койрык дин сатарга җыелган, безгә йир кирәкми, дин кирәк... Кадалыңыз барыңыз... Кяферләр... – дип акырды да үзе үк йөгерә-йөгерә чыгып китте.

Кәбир хәлфә шул “мин... җәмәгать...” дигән ике сүзе белән калды. Ул кабат тормады. Тирече Гайнетдиннән соң итче Фәсхетдин, аякка басып:

– Бу хәерсез кызыл авызлар кайдан килеп чыктылар соң, явызлар? Бер көн бер Мансуров дигәннәре, Думага бойкотмы, чуртмы дип, үзен эләктергән иде... Инде болары тагы үз хәзрәтләребез бар чагында урысларны сайларга димлиләр... Нинди акылдан шашкан кызыл авызлар болар? – дип сөйли башласа да, гайрәт, кыюлыкта бу инде тирече Гайнетдиннең баласы гына иде. Рәис аны бер-ике сүз белән урынына утыртты. Секретарь нәүбәтне игълан кылды, тагы теге европеец киемле, кыяфәтендә, мөгамәләсендә бик аз гына госманлычылык тәэсире сизелмәктә булган әфәнде күтәрелде:

– Әфәнделәр, мин яшьләребезнең бер хәленә тәгаҗҗеб итәм[2]… Европада, Америкада капитал бар. Капитализм нигезенә корылган андагы тормыш, халыкны икегә аерып, бер якта Ротшильдлар[21+] вөҗүдкә килгән[3], икенче якта – эшчеләр сыйныфы... Шулай ук бер якта мәмләкәтнең бөтен йир-суын кулларына алып, игенчеләргә, авыл халкына һични калмаган... Анда йир мәсьәләсе, эшче, капитал мәсьәләсе туган икән – бер дә гаҗәпләнергә ярамый, аларда ул табигый, әмма бездә ни бар? Безнең

[1] *Андаен* – андый.
[2] *Тәгаҗҗеб итәм* – гаҗәпләнәм.
[3] *Вөҗүдкә килгән* – барлыкка килгән.

мөселманда кая капиталистлар да, кая зур алпавытлар? Шулай булгач, бездә халкыбыз дин, миллият наменә[1] берләшергә тиешле, сыйныф аермасы баш күтәрергә урын юк иде... Ләкин дөньяда мода белән тәкълид[2] бәласе һәрнәрсәдән көчле, имеш ки, безем яшьләремез дә шул модада тәкълид афәтенә җотыларак...

Берничә яктан бик каты аяк кактылар, кайдандыр берничә авыздан сызгырып йибәрделәр. Хатиб, бераз туктап, рәис мәҗлесне тындыргач кына, сүзен бетерә алды...

Мәҗлеснең барышына караганда, Думага сайлау турында голяма белән зыялыларның өлешне уртаклашачаклары – хәзрәтләрдән берничә, дөньяви адәмнәрдән берничәне сайларга карар бирәчәкләре аңлашылып килә иде... Шулвакыт шул яшьләрнең иң төплеләреннән, партиядә мөселманнардан иң эшлекле әгъза саналып, аның хакында атасыннан калган берничә меңне шул юлга бетергән дип сөйләнмәктә булган, кызыллыгы өчен урыныннан чыгарылган Госман-учитель нәүбәт алды.

Аның ачык, киң йөзе, зур сары мыегы, озын калын гәүдәсе, башка яшьләргә охшамас дәрәҗәдә яхшы – тәмам хәлле буржуаларча киеме, кыска чәч өстеннән салган һәйбәт кара кәләпүше башта бик өмидле күрсәттеләр. Аның тавышы көчле, калын, тыңларга ягымлы иде. Ләкин берничә җөмлә чыгу белән, моның да кызыл авызлардан икәнене беленеп, партер халкының дәртен кайтарды, берничә йирдән сызгыра да башладылар. Госман боңар карамый дәвам итте:

– ... Авыл ач – аңар йир кирәк. Эшче ач – аңар хезмәт хакы кирәк. Бөтен халык авыр түләүләр белән күмелгән – буны җиңеләйтергә кирәк. Бөтен ярлылар, барлык милләтләр кысылганнар – аларга ирек кирәк. Менә шул “кирәк”ләрне булдыру өчен, Дума ачыла. Бездән вәкилләр барачак... Кемнәрне сайлыйк? Кемнәр һәммә халыкка, һәммә милләтләргә бертигез карап, һәммәгә ирек алу юлында җаны, каны белән көрәшкән, көрәшәчәк булса, шул “көрәш”не үзенә мәсләк итеп алган булса, без шуларны...

Госман шул җөмләсен әйтеп бетә алмый, партерның уң як ишеге төбеннән зур шау-шу күтәрелә.

Ниндидер бер исерек:

– Юк, керәм дигәч керәм... Керәм... Керәм дигәч керәм, – дип гырылдый, аңа каршы берничә тавыш: тот, йибәрмә, нинди исерек баш ул, дип кычкырышалар. Халык җыела, зур шау-шу күтәрелә. Шуның эченнән башына ертык фуражка, өстенә пычрак иске сәләмә нәрсә, аягына чабата кигән бер исерек килеп чыга да, туп белән аттырган кебек, урындыклар

[1] *Наменә* – исеменә, бу урында “*хакына*”.
[2] *Тәкълид* – ияру.

уртасындагы юлдан ава-түнә, сәхнәгә таба йөгерә. Хатиб туктый, бөтен халык шаша, мәҗлеснең тәртибе югала, театр гөж килә башлый. Исерек сәхнәгә якын ук килә дә бер кулы белән тактага суга-суга сөйләргә тотына:

– Рәхмәт, энем... Рәхмәт, кем ул әле генә сөйләде?.. Рәхмәт аңа... Җә, әйтеңез, мин кем... Җә, әйтеңез, мин кем...

Рәис бөтенләй агарынды, аптырады, янындагыларга карап, кая соң полиция, буны адәм хурлыгы дип кычкырды. Исерек дәвам итте:

– Җә, әйтеңез, мин кем... Мин авылда идем... Ясакка актык атымны саттырдылар[22+] ... Ачлык елда, өч балам белән хатыным ачлыктан шешенә башлагач, күз яшьләренә чыдамадым. Бердәнбер душамны[23+] саттым... Йир булмагач, авылда ничек торасың... Калага килдем... Өч ел ачлы-туклы тордым... Менә бер атна элек заводтан кудылар, агач заводында эшли идем... Дүрт йөздән иллебезне сезгә эш юк дип чыгардылар... Инде ни эшлим?.. Ә монда мин тыңладым... Фәкыйрь халыкка каршы әйтүчеләр булды...

Бу вакыт ишектән полиция кереп, исереккә атылды, ләкин ул аңар карышып, кулына фуражкасын алды да тагы исерегрәк тавыш белән сөйли бирде:

– Менә урыс фуражкасы... Сез күңел каралыгыннан дисезме – юк, түгел... Бер дә түгел. Алла белә, мин...

Полиция аңа:

– Тукта!!! – дип аяк тибеп кычкырды да өстери башлады. Исерек чыга-чыга дәвам итте:

– Өч ел мәсҗед йөзе күргәнем юк... Ничек күрим... Башта – фуражка... Өстә – урыс калдыгы... Ике тиен сәдакага юк... Мөселманнар гаеткә китә, мин үземнең өч балам белән авыру хатынымны кочаклыйм да бишәүләп җылашабыз... Ә монда фәкыйрьләргә файда кирәкми дип әйтәләр...

Халык берсен берсе таптап юлны буганнар иде. Полиция, бик күп газаплар соңында гына, халыкны икегә аерып, исерекне типкәләп чыгара алды. Театрда һичбер вакыт булмаган шау-шу, тәртипсезлек китте, бу кем, нигә кергән – һәммә кеше, кайнашып, шуны сөйлиләр. Берәүләр моның чын исерек фәкыйрь булуына ышанмый, яшьләрдән берсе юри шулай киенеп кергәндер, ди. Иң күп як исә яшьләрнең үзләреннән бере булмаса, юри сүзләренә куәт өчен берәр исерекне яллап керткәннәрдер, диләр.

Ләкин моның кем икәнен яшьләрдән Урмановка башка берсе дә белә алмады. Бу – теге качкын Сәрүҗине вокзалга озатырга чыккан төндә капка төбендә яланбаш, пычрак сәләмә киемдә ава-түнә өенә кайткан вакыт Урмановларга очраган руслашкан татар Абдул (Габдулла) иде.

Аны типкәләп чыгарган соңында, ничә минутлар театр ут чыккан кебек кайнады, тик бик озак шыңгырдаткан соң гына, рәис, мәҗлестә тәртипне

торгызып, хатибка сүзен дәвам итәргә мөмкин булды. Сүз әле һаман Госманныкы иде. Ләкин Урманов аның беткәнен көтә алмады. Шау-шу басылгач, урындыгына килеп утырган гына иде, арт яктан кемдер сак кына аның кул башына кагылды:

– Давыд, сез кайтмыйсызмы?..

Әйләнеп караса, анда кара эшләпәсен бер яккарак салып, озын кап-кара киемдә Рауза туташ тора иде. Урманов әйләнгәч, ул сүзен тәкрар итте:

– Сез кайтмыйсызмы... Минем бик башым әйләнә... Хәлем бетте.

Чынлап та, аның йөзе агарынган, күзләре талган төс белән карыйлар иде. Урманов торды, икесе бергә театрдан чыктылар.

---

Тышта җил басылган, аяк асты бераз сүрелгән, шәһәр тын, күк аяз, анда караңгы фәзада[1] якты йолдызлар ялтырыйлар, ләкин ай батканмы, калыкмаганмы – дөнья гәҗәп караңгы иде.

Рауза:

– Страшно арыдым... Бу нинди собрание бу... – дип, егетнең беләгенә кулын салды да, бөтен гәүдәсе белән аңа ята төшеп, үзенең кайтырга теләгәнен реалистларга әйтмәвен, әйтсә, озатам дип тагылуларын, шул “нәрсә”ләрнең кыланышларын хәзер бер дә яратмавын сөйли башлады. Аның тавышы йомшак, мөлаем, ләкин бераз ят иде.

Бая митингка барышлый очрашкан бер катлы, карсак сары өйнең кечкенә капкасы төбенә килеп йиткәч, туташ шул йомшак, арыган тавышы белән:

– Иртәгә кружок көне... Сез инде әйтеңез... Алар Җиһангир квартирына дүрттән калмый җыелсыннар, диде.

– Ә... туташ, иртәгә булмый... Мәдрәсәи исламиядә зур скандал бара... Сезнең кружоктагылар – бар да шул скандалларның башындагылар...

– Ул нинди скандал тагы?..

– Анда шәкертләр күптән ислах сорыйлар... Идарә шуңарга каршы, унике кешене куачак дигән хәбәр бар...

Шул турыда бөтен мәдрәсә дулый, ихтилял[2] булмый калмас. Сезнекеләр кружокка барыбер килә алмаслар ул көндә...

Рауза, хәлсезчә елмаеп, аның сүзен бүлде:

– Гәрәпчәңез бик күп... “Ислах”, “ихтилял” дисезме... Болар нәрсә...

Урманов бер сүз белән тәрҗемә итте, туташ: “Алайса ярый, минем өчен барыбер” – дип, түгәрәкне иртәдән соңга калдырырга риза булды.

– Хәерле кичләр...

---

[1] *Фәзада* – күктәге бушлыкта, галәмдә.
[2] *Ихтилял* – фетнә.

Туташ артыннан кечкенә капка ябылды, Урманов үзенә таба юл тотты.

## IX

Ул иртәнчәк Булатовны озаткан соң чыгып киткәннән бирле, өенә кайтмаган иде. Ишекне ачып керү белән, әллә кайдан, мич артыннан, карчыкның ыңгырашканы ишетелде.

– Анда... хат бар... бугай...

Чынлап та, өстәлдә самавыр төбендә алсу төсле тар, озын конверт ята. Тышында шәһәр почтасының мөһере.

– Кемнән булыр?

Егеткә мәктүп тышындагы кул таныш иде. Авыр бер ярасына кагылгандагыга охшаш халәт берлән тиз-тиз хатны ачты да, шунда бусага төбендә үк укый башлады:

“Давыд абый!

Вакытыңыз булса, бер генә минутка килеп китәр идеңез... Кич сәгать уннарда... Беләсез теге “Чокыр урамы”ндагы биек баскычны... Габдрахманнан тагы яучы бар. Актык сүзне ишетәбез дип әйтәләр, ди. Әткәй әле һаман миңа бернәрсә дә белдерми. Мәһәренә килешсәләр, бирергә исәбе бар, бугай... Башкода киткәч, миңа Фәрхи җиңги аркылы әйттермәкчеләр, Ходаем, хайван саталармыни... Тагы ниләр күрәсем бар икән, Илаһым... Вакыт тапсаңыз, килми калмаңыз... Шул турыда бер-ике сүз бар...

Нәфисә”.

Нәфисәнең соңгы хатларының һәрбере шикелле, бусы да Давыдта бер яктан вөҗдани шелтә, икенче яктан кызгану хисе уйгатты:

– Матур... гакыллы ... инсафлы кыз... Укымышы да бар... Әлбәттә, бәхетле булырга, үзе генә түгел, башкаларга да бәхет бирергә тиеш иде... Ләкин ул, бичара, үзенең язмышы алдында көзге суык җилгә каршы ялгызы утырган гөл чәчәге кебек калтырарга, ниһаять, сынып җил астына таба егылырга , тапталырга мәхкүм[1]...

Ашыгыч прокламация бар, шуны бүген кич тәртип итеп, иртә үк басарга бирәсе иде. Ләкин Давыд, барыбер эшли алмаячагын уйлап, үз бүлмәсенә кермичә үк, кире тышка чыкты.

## X

Төн караңгы иде. Шулай да күп тапталган таныш урамнардан бару артык кыен булмады.

[1] *Мәхкүм* – хөкем ителгән.

Менә “Чокыр урамы”... Менә биек баскыч... Әнә баскыч төбендә бер карачкыл күренә... Хатын-кыз шәүләсенә охшаш, ул булса кирәк.

Егет баскычка якынайды. Чынлап та, анда, каршы як өйнең тәрәзәсеннән озаеп чыккан якты эчендә урта буйлы, кызыл күлмәкле, ал яулыклы, кулына ниндидер төенчек тоткан бер хатын тора иде.

Егет, хатынга килеп җитәр-җитмәс хәлдә, мөмкин кадәр сак тавыш белән:

– Нәфисә... синме... – диде.

Хатын, баскан йирендә кузгала төшеп, бераз оялчан, бераз тартынкы тавыш белән җавап кайтарды:

– Ходаем... Нәфисә җиде төн уртасында монда ничек килә, ди... Мин – Зөһрә...

Урмановның сүзен көтмичә үк, Зөһрә тагын башлады:

– Ирләр дисәң, ирләр... Нәфисә синме, ди... Ул кыз башы белән җиде төн уртасында монда ничек килә ала, ди...

Зөһрә – Нәфисәнең яшь анасы, Давыдның якын танышы, арадагы мөнәсәбәттә күп булышлык итүче иде. Ул егетне көтмәде, үзе мәсьәләне чишеп үк бирде:

– Мин Фәрхи җиңгиләргә әйбер итәргә[1] чыктым... Картым “Алмалы”га базарга китте, иртәгәсез кайтмас... Балалар йоклаган... Нәфисә ялгыз... Бар, тиз...

Сүзен әйтеп тә бетерде, почмакка борылып, төннең куе караңгылыгы эчендә юк та булды. Урманов үзенә бик күптән таныш булган биек баскыч белән югары, тауга таба күтәрелде. Менә тау өсте, менә бер яклы Чехов урамы. Менә монда көндез дә атлы йөрми. Көндез дә аулак була. Хәзер исә җан кыеп китсәләр, “әһ” дип эндәшәчәк адәм булмас, шул дәрәҗәдә буш, тын һәм караңгы иде. Вак сатучылар, бигрәк тә талчокчы татарлар[24+] тора торган күбесе ике катлы агач йортлар тын караңгы төндә куркыныч шәүләләр кебек утыралар. Гүя нидер көтәләр, гүя нидер тыңлыйлар.

Тик әнә Гоголь урамына чыга торган чат башы кызыл бинаның икенче катындагы тәрәзәсендә генә ут күренә.

Аның пәрдәсе төшерелгән.

Бу чат башы бинада Урманов моннан ике ел элек алты айга якын яшәгән, ул бөтен урамда ялгызы яктырып торган пәрдә аңар бик күптәнге таныш иде. Боларны күрү белән кайчандыр йөрәгенең беренче дулкыннарын уяткан ерак Төркестан сахраларында:

Матур була Нәфисә,

---

[1] *Итәргә* – илтергә.

Аллы күлмәген кисә...

дип сагынып йырлаган мөлаем кыз һәм аның белән бергә үткәргән беренче бәхетле сәгатьләре хәтеренә килде.

Карт усал талчокчы Сафа “Алмалы”га базарга киткән, ди. Балалар йоклый. Үги ана, гәрчә үги булса да, ихтимал, шул үги булганлыгы өчен, каядыр китә, кем белә тагы, бәлки, беркая да китми, ихтимал, моның артыннан ук кайтыр да, чоландамы, кайдадыр яшеренеп торыр.

Ләкин боларның һичберенең әһәмияте юк иде:

– Нәфисә чакырткан... Бармаска мөмкин түгел...

Балалар уянса, Нәфисәнең башына кыямәт кубачак. Егет моны ачык белә – шуңар күрә ул акрын, сак керү турында бар көче белән тырышты. Кечкенә капканы бер дә шалтыратмый ачты, тышкы ишекне дә мөмкин кадәрле тавышсыз ябып, тар, караңгы, ләкин һәрбер тактасына чаклы таныш баскыч белән югары катка аяк очлары белә генә баса-баса менеп, бик сак кына ишеккә чиертте.

Озак көтәргә туры килмәде, ахрысы, ышанып көткәннәрдер, бер-ике чиертүгә, эчке яктан йомшак табан белән кемнеңдер ишеккә якынайганы ишетелде.

## XI

Ишек акрын гына ачылды да аннан, кулына яшел абажурлы лампа тотып, Нәфисә килеп чыкты.

Кыз – вак сәүдәгәр сыйныфының атасыннан яшерә төшеп, үз көче белән бераз яңарган мөлаем, чибәр татар кызы иде. Озынча буйлы, түгәрәк ак алсу йөзле, өстендә – челтәр аборкалы[1] матур тегелгән карасу күлмәк, коңгырт чәче өстендә, маңгай турында, май аеның матур чәчәге кебек утырган ак энҗеле кечкенә калфак. Бөтен әгъза килешле, чибәр, ләкин иреннәр кансыз, иреннәр һичбер нәрсә сөйләми, кайчандыр туктаусыз уйнап, туктаусыз елмаеп торган карасу мөлаем күзләр бүген Урмановка: “Ходаем, шулай ук мин бетәрменме икәнни?” – дигәндәй караган кебек күренделәр... Караңгы залда лампаның аз яшел яктысы эчендә бераз ерактa басып торган бу кызны җанлы, тулы канлы бер хатын диюдән бигрәк, шагыйрь рәссамның айлы кичтә киң яфраклы агач күләгәсе астына ясаган бер рәсеме түгелме, дип уйларга мөмкин иде.

Ләкин ул җанлы иде. Егетне күрү белән, йөзе ачылды, иреннәренә алсу кан йөгерде, аның бөтен торышы:

– Ах... Сезне... бик көттем... – диләр иде. Ләкин теленнән башка сүз

[1] *Русчадан:* оборкалы – бала итәкле.

чыкты:

– Ходаем, танымый торам... Сез әллә нинди озын бүрек кигәнсез... – Ул Урмановка үзенең аз канлы ак кулын сузды. Егет бөтен тәне илә күкрәгенә сыенып барган кызны таза куллары белән кочагына алды да калфагы яныннан, чәч белән маңлае арасыннан ике мәртәбә үпте.

Залда балалар йоклый иде.

Аяк очы белән генә басып, Нәфисәнең үз бүлмәсенә үттеләр. Һичкем әйтмәсә дә, кыз бүлмәсе икәнлеге әллә кайдан беленеп торган, бай түгел, ләкин җыйнак, пөхтә, һәммә нәрсәсе бик урынлы, бик килештереп җыештырылган, калын пәрдә корылган тәрәзәле кечкенә бер бүлмә. Керү белән җаның эри, ничектер, җиңеллек, табигый матурлык, зәвык, тәмиз[1] хис кыласың. Бүлмәнең кыйбла ягында бик пөхтә, зәвык белән бик актан җыештырылган матур караватъ. Кечкенә ак мендәрләр, челтәрле япмалар. Аның аяк очы башында өсте ак белән ябылган берничә кием. Тәрәзәгә якын куелган кечкенә матур өстәл өстендә аяклы көзге, берничә савыт ислемай, байтак татар әдәбияты, иң матур тышлылары өскә салынган матур китаплар, берничә рәсем, каләм, кара, тагы шундый европа хатынының язу өстәле, туалет өстәле, китапханәсе кебек берничәгә аерыла торган әйберләр монда шул бер кечкенә өстәлгә тезелгән, ләкин һәммәсе матур, килешле карыйлар, матурлык сөйгән бер колның пөхтәлегән сөйлиләр.

Нәфисә, лампасын кую белән, егетнең күзенә текәлеп карап, сүз башлады:

– Растмы?.. Сезнең бер иптәшне асканнар, ди...

Бу хәбәрнең тиз арада таралып җитүенә егет бераз гаҗәпсенә төште.

– Мин... Нәфисә... бер генә минутка дип килдем... Балалар да уяна башлар. Кыз һаман аңар карамыйча, ләкин инде бөтенләй ят тавыш белән:

– Ходаем... утырыңыз әле... – диде.

Аның күзләре агарыналар, ирене кибә, тавышы кылтырый иде. Шул тавыш белән сүзен дәвам иттерде:

– Баягы хатымда да язган идем. Габдрахманнан тагы яучы бар. Актык сүзне ишетәбез, дип әйтәләр, ди... Мәһәрне килешсәләр, эткәйнең бирергә исәбе бар, бугай... Ходаем, хайван саталармыни... Әйтегез, зинһар, ул кем соң?.. Ул бу арада безнең урамнан бик күп йөри башлады. Үткән саен минем тәрәзәгә туктап-туктап карый... Ходаем, нигә ул яңагына яулык бәйли... Астагы итекче хатыны әйтә, аның яңагына, ди, тилчә булган, ди, черегән, ди, шуңар күрә яулык бәйләп йөри, ди... Давыд Габдрахманның яңагына яулык бәйләве теге вакытта тыкрыкта кыйналуыннан эләккәнен әйтте, кыз ярым

[1] *Тәмиз* – ару, пакь, чиста.

аптырау, ярым күз яшьле тавыш белән сүзен бетерде:

– Ходаем, һичбер чынын белер хәл юк... Берәүләр, ул яхшы приказчик, айга йөз сум ала, үзе ялгыз, тик бердәнбер анасы бар, ул да башка каенаналар кебек гыйфрит булмас, ди... Кайбер кешеләр, эшкә ярамагач, урыныннан чыгарганнар, ул хәзер гәлях[1], диләр... Ходай белә, кайсы чын...

Сез аны беләсез, бугай...

– Мин, Нәфисә, аны шулкадәр беләм: ул таза сау бер егет, электә яһүдтә иде, хәзер Кадыйр байга кергән, айга кырык сум ала. Бае: “Өйләнсәң, унны арттырырмын”, – дигән... Менә минем белүем шул чаклы... Соң, Нәфисә, атаң белән ул турыда сөйләшкәнең бармы, ул ни ди?

– Ходаем, ул турыда атаң белән ничек сөйләшәсең... Мин теләсәм дә, эткәй: “Куй, юкны лыгырдама, син катыша торган эш түгел ул”, – дияр дә куяр... Ул миңа ни дисен... Мин озын колактан ишеттем, мәһәренә килешсәләр, бирергә исәбе бар, бугай... Аның бар курыкканы... Ул мине сезгә ябышып чыгар дип коты оча... Шунлыктан кем сораса, шуңар бирергә тора... Тик кыска койрык булмасын да мәһәрне мул бирсен...

Урманов бераз гаҗәпсенгән, бераз кызганычлы тавыш белән Нәфисәне бүлде:

– Кара әле, Нәфисә, мин сине аңлап бетмим... Син яңа фикерле... Менә өстәлең әдәбият белән тулы... Атаңның сатып бирергә хакы юклыгын беләсең... Шулай булгач, нигә...

Кызның күзләре тагы: “Мин ни эшлим соң, Илаһым!” – дигәндәй егеткә текәлделәр, ул кинәт урыныннан торды да, берни эшләмичә, тагы утырды:

– Ходаем, укыйм, аңлыйм... Барын да аңлыйм да... Коры аңлау белән нишлим соң...

Менә үз бүлмәмдә ялгызым утырып барын уйлыйм... Эткәйгә сөйләргә дип фикерләремне тезеп куям... Яхшы сүз белән булмаса, көрәшергә дә ниятләп куям... Инде эткәй янына килсәм, телем тотлыга, сүзем бетә... Бу вакыт мин нинди газапка да риза, тик эткәй белән үземнең киявем-фәләнем турында сөйләүдән генә Алла коткарсын дип калам... Сөйләп, сөйләп тә файда булачак түгел... Бер сүз булса, аның йөзе карала, күзен кан баса да, ул: “Лыгырдама, бар, югал, мин үзем беләм, син тагылма”, – дип, аяк тибеп кычкырыр гына... Аңар ни сөйләргә, мин, көрәшәм дип, ни кыла алам...

Нәфисә, ишекне ачып, залга карады да яңадан утырды:

– Бер көн сез бу урамнан үтеп бара идеңез...

Давыд, аның кулын алып, сүзен бүлде:

---

[1] *Русчадан*: голяк – бу урында *“ярлы”* мәгънәсендә.

– Кара әле, Нәфисә, ничектер кыен тоела... Мин “син” белән сөйлим, син “сез” дисең, без бит инде күптәнге дустлар... Кызның йөзе бик аз гына агарынды, иреннәре дерелдәде, ләкин һаман “сез” белән дәвам итте, ул, гомумән, Давыдка “абый” дип, “сез” дип сөйли иде:

– Бер көн, шулай, сез урамнан үтеп бара идегез, өстегездә кара күлмәк, билегездә каеш – шулай җиңел генә чыккан идегез... Әткәй тәрәзәдән сезне күрде дә әллә нинди мәсхәрәле тавыш белән:

– Шулмы синең башыңны әйләндергән студентың? – диде...

– Син ни дидең?

– Ни диим, бернәрсә дә әйтмәдем... Әйтеп ни файда?.. Ни әйтсәң дә, ул һаман үз сүзендә кала. Бик кызса тагы, шунда ук яңаклап, типкәләп тә ташлар... Ул бит кулга бик, бик харап җиңел: кылына килмәгән бер эш күрсә, хәзер күзен кан баса да, үзен-үзе белешмичә, ни очраса, шуның белән вата башлый... Безнең аста бер итекче тора... Исерек, кабахәт бер нәрсә шунда... Көн буе өйдә утырып ялыгасың, кибәсең, һичкая чыгармыйлар... Мин, аптырагач, шул тегүченең хатыны белән дуслашып, аларга кереп-чыгып йөри башладым... Бер көн балалар: “Апа, апа, тиз чык, әткәй кайта”, – дип акырыштылар... Атлап чыксам, ни күрим, каршымда әткәй тора... Йөзе ачудан кара көйгән, күзләрен кан баскан, үзен чак танырсың, шундый булган... Әллә нинди рәхимсез тавыш белән: “Сиңа ни бар анда... Ә... Сиңа ни бар анда... Ашарың хәзер... Эчәрең хәзер. Сиңа тагын ни җитми... Анда ни калган... Сез анда егет күзләргә, егетләр сөйләргә җыеласыз икән... Бәдбәхетләр!” – дип, аяк тибеп кычкырды да, шул җирдә чәч толымнарымнан алып, югарыга өстерәп мендереп, каеш белән ярырга тотынды... Балалар акырып җылый башладылар... Әни килеп тоткан иде, каеш белән аның йөзен ярып йибәрде... Мин тавыш чыгармадым, Ходаем, битемә генә эләкмәсә ярар иде дип, башым белән аска бөгәрләндем дә яттым... Илаһым, шундый ярды, шундый ярды, тәнемдә кара көймәгән йир калмады... Әле дә битемә тимәгән... Безнең әтинең андый холкын күрше-күлән бар да белә, күргән саен: “Атасы кыйнагандыр”, – дип төртеп күрсәтәләр иде... Менә муенымдагы каеш эзе әле дә бетмәгән.

Нәфисә тартынмады, Давыдка үзенең муенын күрсәтте, чынлап та, нәфис ак тире ияккә таба бармак киңлеге янып тора иде.

Урманов ни дияргә белмәде, ни генә әйтсә дә, бу вәхшәтнең үзендә уйгаткан ачулы, авыр тойгысын ифадә кылып[1] йиткерә алмаячак, ни генә дисә дә, йөрәгендә кайнаганны әйтү булмаячак иде. Торып, кечкенә бүлмәнең эчендә бер-ике әйләнде дә сүзсез, килеп, Нәфисәгә кулын салды. Кыз дәвам

[1] *Ифадә кылып* – аңлатып.

итте. Иң гаҗәбе – Нәфисәнең тавышы гадәтчә йомшак, сүзләрендә атасының шул мөгамәләсенә каршы бераз зарлануга башка һичнәрсәнең ишетелмәве иде.

– Ул үзе мине бик ярата... Элгәре елларда алай кыйнамый да иде, Самардан монда күчеп сәүдәләр начарга киткәч, шулай бозыла башлады... Талчоктагы ике кибетнең берсе ябылгач, бигрәк холыксызлана башлады... Ул үзе мине бик ярата... Шулай кызып кыйнап ташлаганның икенче көнендә үк, теле белән әйтмәсә дә, мине иркәли... Сораганны алып кайтып бирә, йомшак сүзле була... Балаларны, әнкәйне кыйный башласа, мин туктатам... Аңа да сүз әйтми... Ләкин тагы шундый бер эш килеп чыга да, тагы шулай күзен кан баса, үзен-үзе онытып, безне эштән чыгарып ташлый шул, Илаһым... Миңа тагы бер хәл... Әнкәйгә, балаларга бик харап...

## XII

Бу вакыт залдагы сәгатьнең вәкарьле калын моң тавыш белән унберне сукканы ишетелде. Балалардан берсе, әллә уйнап, әллә йокы арасында:

– Әнкәй... су...

– Әнкәй... су... – дип кычкырды.

Нәфисә, ярым куркулы, ярым шаян тавыш белән егеткә бармак селкеде:

– Чү... Балалар уяналар...

Ләкин тавыш тәкрар ителмәде. Нәфисә:

– Саташадыр, хәерсез малай... Бу арада бер дә йокысының рәте юк... – диде дә, өстәленә килеп, аның читенә күкрәге белән таянган хәлдә китаплар актара башлады. Давыд та, урыныннан торып, аның янына килде. Нәфисә берничә рисалә[1] тартып чыгарды:

– Боларны карап беттем... Бу арада укырга бернәрсә дә юк... Яңа чыккан китаплар булса, миңа бер-икене йибәртер идеңез...

Егет: “Бар, җибәртермен”, – диде.

Бу вакыт алар бер-беренә бик якыннар, тәннәре тиешеп тора. Кызның өстеннән, чәчләреннән аңкыган мөлаем хуш исе егетнең каннарын кузгатачак бер куәт белән дулкынланып килеп кагылалар иде. Инде Нәфисә үзе дә баягы агарынган иренле, ак йөзле, хәлсез кыз түгел. Егеткә якынлыктан, аның тәне кыза, каны кайный, йөзендә алсу кызыллык уйный, иреннәре тәмләп кызарып киләләр, күзләре яшь йөрәкнең әллә кай йирләреннән кайнап чыккан бер дәрт белән елмаялар иде. Егет, бу – актык килүем булыр дип, мөмкин кадәр салкын торырга, үзен чит тотарга теләсә дә, акрын-акрын ихтыяры бетә барганын, нindiдер бер куәт аны Нәфисәгә, Нәфисәне – аңа тартканын,

[1] *Рисалә* – кечкенә китап, брошюра.

хәзерге минутта чыгып китә алмаса, һичбер көтелмәгән, ихтимал, бөтен киләчәк хәятне үзе теләмәгән якка борып йибәрергә иҗбар итәрлек[1] булган бер минутның якынаеп килгәнен хис кыла. Чыгып китәргә тели, ләкин нидер тота, аяклар тыңламый, эчендә ике куәт сугыша иде. Бераз вакыт шул ике куәт арасында тарткаланды, ниһаять, үзен җинде: “Нинди мәгънәсезлек, мин шул дәрәҗәдә ихтыярсыз адәмме?” – диде дә, үзенә тәмам хуҗалыгын хис кылган хәлдә:

– Мин китим инде, Нәфисә... Зөһрә апа да кайта башлар... Хәерле йокы!!! – дип кулын сузды.

Кыз аңа үзенең мәгънәле елмайган күзләре белән дустанә карады:

– Китәсез дәме?.. Бик сирәк киләсез... Килсәңез китәргә ашыгасыз...

Аның тавышы йомшак, сүзләре акрын уйналган кайгылы музыка кебек йөрәкне тын гына иркәлек белән сыйпап үтәләр иде. Давыд шул хәлендә ката калды.

Бу минутта Нәфисәнең күз карашы шундый мөлаем, шундый сөеп чакыра, аның бөтен торышында шундый гаҗиб бер җазиб нәфасәт[2] хис ителә иде ки, егет күрешергә кул бирәчәк урында, ни эшләгәнен яхшылап аңлый да алмыйча, Нәфисәнең тар нечкә күлмәк эченә кысылган эссе тәнен үзенең кочагына алды, ике тән куллар аша бергә уралдылар, иреннәр, йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан бер ялкын белән кызган иреннәр, куәтле, озак юлыгыштылар. Тагы бер секунд үтсен, Нәфисәнең хәле китәчәк, дөнья томанланачак. Ул үз ихтыярыннан башка артындагы караватка сузылып төшәчәк иде. Һәм шул секунд җиткән, Нәфисә, һушыннан язган адәм кебек, куллары ике якка йибәрелгән, йөзе гаҗип бер төс белән агарынып, күзләре яртылай йомылган, зур кара чәче ак мендәр өстенә тузылып төшкән, үзе егетнең куәтле кочагында арып, ут булып, кызу ялкыннан кипкән иреннәре белән такатьтән тышын бер ләззәт эчендә егеткә суырылып дөньядан югалган иде. Менә, менә бер секунд вакыт. Ул бетәчәк, һәр икесен караңгы һавия[3] йотачак. Ләкин заман туктады, куркыныч секунд үтмәде. Егет үзенә дә мәгълүм булмаган илаһи бер коткаргыч куәт белән адәм такатенә сыя алмаслык дәрәҗәдә көчләнү соңында ,үзен җиңеп, Нәфисәдән күтәрелде:

– Ах... Мин ни эшлим?!

– Мин... Ни эшлим?!

Егетнең кипкән иреннәреннән көйгән бер тавыш белән әйтелгән бу сүзне ишетүче, уң кулы белән кинәт маңлай чәчен йомарлап алган минутын күрүче адәм булса, тавышына, кыяфәтенә карап, аны, шөбһәсез, мәҗнүн дип

---

[1] *Иҗбар итәрлек* – мәҗбүр итәрлек.
[2] *Җазиб нәфасәт* – соклandыргыч гүзәллек, нечкәлек.
[3] *Һавия* – упкын, тәмуг.

уйлар иде, һәм ул шул минутта мәҗнүн хәленә якын да иде. Шул мәҗнүнгә охшаш халәте белән янганнан, көйгәннән су эзләгән адәм кебек кинәт тәрәзәгә ташланды да, пәрдәне ачып, маңлае белән салкын пыялага сөялде...

Тыш яктырган иде... Әнә ерак күгелҗем күк... Аз яктылы йолдызлар... Әнә тулы, миһербанлы ай...

Инде котылдылар.

Ләкин һаман һәр икесе гаҗиб бер эчке дулкын тәэсирендә. Менә-менә йотарга дип килеп җиткән җәһәннәмнән котылуның шашкан бер минутындалар иде...

Егет өстенә-башына киде дә табигатенең эчке яшерен йирләреннән уйганып күтәрелгән ят, ялкынлы, ләкин акрын тавыш белән:

– Җаным... Газизем... Гафу ит... Сиңа күп бәхет телим... Якты көннәреңне күрәсем килә, – дип, Нәфисәне яңадан кочагына алды. Ләкин бонысы инде бер тәннең икенче тәнне кочаклавы түгел иде. Нәфисә әле һаман да яхшы айнып җитә алмаган, изелгән бер халәттә иде. Күзләре төштә яки томан эченнән кебек хәйранлык пәрдәсе аша карыйлар иде. Гомерендә беренче мәртәбә, үзе килеп, егетнең күкрәгенә башын куйды, аның йөрәк тибүен хис кылган хәлдә хәзерләнгән куллары белән муенына сарылып, иреннәрен аныкына юлыктырган рәвештә катып калды.

Бу – аларның гомерендә беренче иде. Һәр икесе буның һәм актык булачагын да хис иттеләр.

Нәфисә ят, басынкы, йөрәкнең эчке дәрте өзелүеннән килгән мөтәэссир[1] тавыш белән:

– Сау бул, җаным... – диде.

Аның сүзендә, тавышында күп еллар асрап килгән газиз өмиднең гомергә югалуын хис кылганлык һәм шул тәэсирдән туган күз яше ишетелә иде.

Давыд китте. Аның артыннан ишек ябылып өлгерә алмады, Нәфисә, караватына сузылып, тузган чәчләре белән мендәргә йөзтүбән капланды да, күкрәгеннән ташып килгән дулкынны тыя алмыйча, авыр, ачы күз яшьләре белән озак-озак агълады[2]. Монда үткәнне сагыну да, еллар буенча хәятын нурландырып килгән бердәнбер өмиднең мәңгегә сүнү хәсрәте дә, алгы көннәрнең авыр караңгылыгыннан курку да, рәхимсез язмыш алдында ялгыз калуын хис итү дә – белмим, тагы ниләр дә бар иде.

Ул Зөһрә апаны үзенә кертмәде. Утын тиз сүндерде.

Ләкин иртәнге кояшны йокысыз каршы алды.

---

[1] *Мөтәэссир* – тәэсирләнгән.
[2] *Агълады* – елады.

## XIII

Давыд капка төбендә Зөһрә белән исәнләште дә туры квартирына кайтты. Ул үзе арыган, аяклары хәлсезләнгән, ләкин башы яна, йөрәгендә бер-беренә каршы мең төрле хиссият кайный. Ни чаклы гына көчләнсә дә, эчендәге бу ташкынны билгеле бер агымга төшереп йибәрә алудан, хәзерге халәтен аңлаудан гаҗизлек хис итә иде.

Аңа иртән сәгать унбердә, зинданга барып, анда ялгыз утырмакта булган иптәше Баязид карыйны күрергә кирәк. Шунлыктан вакытлы ятып, иртәрәк уянырга тиешле.

Ләкин кызу кан, уянган хыял аңа тиз йокы бирмәделәр.

Башланган прокламациясен алып караган иде, ике җөмләне беректерә алмый аптырап, аны ыргытты. Соңра, озын итеп, Нәфисәгә хат язмак булган иде, монда да: “Газизем... Мине гафу ит... Синең белән гомерлек дус булып калуны өмет итәм. Сиңа күп бәхет телим... Синең якты көннәреңне күрәсем килә...” – диюдән дә мәгънәле сүз таба алмады.

– Часть сәгате өчне суккан вакыт мич артыннан карчык уянып, тышка чыкты. Урманов аңардан: “Әби, иртәгә зинданга барасы бар... Син сәгать унда уята күр”, – дип үтенде дә, язган хаты белән җибәрәчәк ике китабын зур ак конвертка тыгып, ятагына ауды. Ләкин хыял аны тиз тынычландырмады.

Кичә шушы вакытта вокзалга озатылган качкын Сәрүҗи – Хәбиб Мансуров, бүген иртә килгән кызыл күлмәкле Булатов, тар кара киемле, киселгән чәчле, кара эшләпәле, озын буйлы Рауза туташ, мәйдандагы митинг, андагы хатиблар, полиция белән бәрелешүләр, иптәше Егорның асылган булу ихтималы, театрдагы җәмгыять, анда майлы бишмәтле тирече Гайнетдиннең “безгә йир кирәкми, дин кирәк”, дип тавыш чыгаручы, теге руслашкан исерек татар Абдулның башындагы иске фуражкасын кулына тотып, “өч ел мәсҗед йөзен күргәнем юк, мөселманнар гаеткә китә, мин өч балам белән авыру хатынымны кочаклыйм да, гает вакытында бишәүләп елашабыз, ә сез бу фуражканы күңел каралганнан кия дип әйтәсездер” дип елавы кебек бүген булып үткән хәлләр, барлыгы бергә буталып, хыялда кайнашкан, аннан ары “абый, бик сагындык, бер кайтып китәр идең” дип язучы мөлаем сеңелесе Бибизәйнәп, “кайтмасаң, мәңге бәхиллегемне бирмәм”диюче, шелтә катыш җалынучы анасы Фагыйлә карчык, Чокыр урамындагы биек баскыч, кызыл күлмәкле Зөһрә апа, ниһаять, агарынган иренле, кечкенә ак энҗе калфаклы, кайгылы йөзле Нәфисәбану, белмим тагыниләр, тагы кемнәр белән озак газапланганнан соң гына йокыга китә алды.

## XIV

Аларның фамилиясе шул “Тау башы” ягындагы башкортларга кантон булып яшәгән[25+] Урманбай карттан килә, диләр. Урманбайдан соң аның энеләреннән Төхфәт белән Садыйк исемендә ике кантон хакимлек иткәннәр. Садыйк кантонның үзеннән соң өч угылы кала. Кантонлык нәселдән китә. Шуның белән байлык та, игътибар да кими, кантонның вафаты соңында аның угланнары – Вәли, Гали, Сафи – үзара тыныша алмыйча аерылышалар да бабалары заманыннан килгән гаҗәеп киң, зур йортны, һәртөрле карт агачларга бай олуг бакчаны өчкә бүлеп, аерым-аерым оя коралар. Хәзер тик фамилия горуры бар. Әмма куәт тә, әүвәлге дәүләт тә юк. Тик иске сарайлар буендагы карт каеннар гына кайчандыр тирә-якның ханы булган куәтле, шәүкәтле[1] бабаларын сагынып шаулашалар. Әмма кантонзадәләр[2] инде тирә-якта: “Беттеләр, бичаралар”, – дип кенә сөйләнергә калганнар. Менә шул өч кантонзадәнең уртанчылары Галинең карт хатыны Заһидә авырый да, ире аның өстеннән икенче хатын ала. Яшь хатын усал бер нәрсә туры килә. Ул бу йортка төшкән көненнән үк кантонзадә Галине[3], бөтенләй үзенә каратып, карт хатынны җәберли башлый.

Шулай итеп, бу йортта Заһидәнең үзенә дә, кызы Габидә белән угылы Җиһанга да һичбер якты көн калмый, аларга сан бетә, кадер бетә... Гали үзенең яшь хатыны белән ак өйдә майлап, коймаклап чәй эчә, Заһидә исә үзенең ике бөртек баласы белән аш өендә, теге яктан калган чәйне көтеп, зарыгып утырырга мәҗбүр. Ләкин ни эшләсен, ни кылсын: “Барча эшләр – Хакның язмышы”, – дип, үзалдына моңлана да сабыр итә.

Ләкин моның белән генә калмыйлар. Яшь хатынның сансызлыгы чиктән аша. Болар ни эшләсә, ул килешми. Боларга әллә нинди бәлаләр ягыла... Инде Җиһан унбиш яшьләренә килә. Атасы аны күрше авылына укырга йибәрә. Ләкин яшь хатынның моңар ачуы кабара. Аңар су кертергә, утын кисәргә, юынтык суларын чыгарып түгәргә кеше кирәк. Ул карт хатынның улы Җиһанны шунда җикмәкче. Ире Галигә көн-төн сыкрана:

– Үгез кебек угылың бар... Аны мәдрәсәгә йибәрәсең дә, мин монда эт көнендә йөрим... – ди. Инде Җиһанга, мәдрәсәне ташлап, йортка җигелер көн якынаеп килә. Яшь хатын ирен җиңәчәк иде. Заһидә моны ачык аңлый да, үзем ни күрсәм, шул булыр, балам әрәм булмасын, монда калса, ул илле, ун тәңкәлек ялчы көнендә яшәр дип, Җиһанның байтактан бирле сорап килгән рөхсәтен бирә. Көзге караңгы төннәрнең берендә кантоннан калган зур сарай буендагы бакчада угылын хушыннан язар мәртәбәдә агълап үбә, коча да авыр

[1] *Шәүкәтле* – бөек.
[2] *Кантонзадәләр* – кантон булып торган кешенең балалары.
[3] Текстта *Вәлине* дип бирелгән.

юлга качырып озата. Җиһан яшьтән үк зирәк, тырыш бер бала иде. Анасы үзенең дәүләтеннән өзеп биргән тәңкәләрне ала, иске букчага язма “Шәрхе мөлля”сы белән язма “Шәрхе викайә”не[26+] сала да, Аллага тапшырып, Казан губернасындагы олуг бер мәдрәсәгә юнәлә.

---

Әүвәлге елларда мәдрәсәнең өлкәннәренә аш пешереп, самавыр куеп тамак туйдыра. Бераз үскәч, кыш укырлык акчаны Мәкәрҗәдә[27+], фәләндә кәсеп итеп таба. Шулай укый. Егерме дүрт яшендә вакытта риязый кыяфәтле[1], бик дәгъвалы, моталәгасы[2] чыккач, пишкадәм[3] булып, хәтме көтеб кыла[4], соңра остазының даляләте[5] белән Бохарага барып, анда хөҗрәдә[6] дүрт елдан артыграк тәхсыйлдә[7] кала. Бервакыт остазы авырый. Аны кайтырга чакыра. Җиһан да тәмам-тәмамына бер сарт[8] булып, Бохарадан кайта: сакал көрәктәй, башта – ишеп-ишеп чалган зур сары чалма, өстә – яшел-сары юллы бикасап чапан, аякта – яшел читек... Ул монда остазының хәлфәләреннән булып, дәрес әйтә башлый... Мөдәрриснең угылы юк, бер кызы бар. Аның вафатыннан элек үк кызына өйләнә, үзеннән соң урынына утыра, берничә елдан соң ишан була.

Шул рәвешчә, Оренбург губернасында кантон булган бер нәселнең бер ботагы, Казан губернасында тамыр җәеп, зур мөдәррис, атаклы, ничә йөз мөридле[9] ишан булып кала.

## XV

Баязид карый менә шул мәшһүр Җиһан ишан белән аның остазы Габдәһ мөдәрриснең кызы Гайшәдән туган беренче бала иде. Ишанның анасы күптән үлгән, сеңелесе кияүгә чыгып, ул да баладан вафат булган иде. Шулай булса да, Җиһан ишан үзенең туган илен бөтенләй ташламый, ике-өч елга бер мәртәбә анда кайтып зиярәт кыла иде. Шул кайтуларның берендә ул угылы Баязидны да үзе белән алган иде. Давыд белән Баязидның беренче очрашулары менә шул вакыт булды. Болар һәр икесе җиде яшьлек, үткен, уенчак малайлар иде. Халык бу икенең котырып уйнап йөргәннәрен күргән саен:

---

[1] *Риязый кыяфәтле* – артык ябык.
[2] *Моталәгасы* – укуы, уку вакыты.
[3] *Пишкадәм* – мәдрәсәнең тулы уку курсын бетергән хөрмәтле кеше.
[4] *Хәтме көтеб кыла* – укып бетерә, уку йортын тәмамлый.
[5] *Даляләте* – күрсәтүе.
[6] *Хөҗрәдә* – мәдрәсәләрдә бер кеше генә торырлык бүлмәдә.
[7] *Тәхсыйлдә* – гыйлем алуда.
[8] *Сарт* – Октябрь инкыйлабына кадәр үзбәкләрне шулай атап йөрткәннәр.
[9] *Мөридле* – иярченнәре, шәкертләре булган.

– Куш булды бу ике шайтан!!... Бакчадан бакча калмый... Читәннән читән калмый... Башларын, күзләрен чыгарып әрәм булырлар, гөнаһ шомлыклары... – дип, шелтә катыш кызганып һәм сокланып калалар иде.

Давыд Урманов баладан ук зирәк җанлы, гакыллы булу белән бәрабәр, ул кайбер вакыт гаҗәеп сабыр, гаҗәеп уйчан булып китә. Әмма Баязид усаллыкта, куркынычның нәрсә икәнен белмәүдә аны әллә кая калдыра иде. Авыл халкы Баязидның эссе кояшта туктаусыз сикеренүдә кызарган йөзенә, хәзер бер нәрсә белән алып бәрер дә һәлакәт ясар дигәндәй ялкынланып торган күзләренә, кая басарга белмәгән төсле янып, уйнаклап торган гәүдәсенә карыйлар да:

– Ходаем... утмыни?!.. Чәчрәп тора, атакаем... – диешәләр иде.

Җиһан ишан “Тау башы”нда бер айга якын калды.

Матур җәй көне иде. Сабыйлар урманын, яланын калдырмый, ялкын кабындырып, мең төрле уеннар чыгарып, шул бер айны һәрвакыт бергә үткәрделәр, бик дусландылар.

Җиһан ишан Казан ягына китте. Сабыйлар аерылдылар. Соңра икесе ике якка уку юлына бирелде. Шулай итеп, аларга күп еллар очрашырга туры килмәде. Хат та язышмадылар.

Баязид карый быел мәдрәсәгә килү белән, алар яңадан очраштылар. Бу вакыт Баязид карый бөтенләй башка адәм иде инде.

Озынрак нечкә буе, игътибарсызча кырылган сакал-мыек эзе, ниндидер бер куәтле изтыйраб[1] белән кипкән саргылт йөзе, бер һәлакәт кичергән яки һәлакәткә керергә торган кебек карый торган күзләре – беренче очрауда ук Урмановка егетнең бик күп нәрсә кичергәне, хәзердә дә аның эчендә ниндидер куәтләр сугышып, аңар тынычлык бирмәгәнлеген сөйләделәр, аның бөтен торышы, күз карашлары нәрсәгәдер, кемгәдер бетмәс ләгънәт белән караган кебек, басарга тырышылган гасабиять белән[2] чыккан сүзләре, “Ах, Валлаһи, бу да бетмәде инде” дигән төсле кискен мөгамәләсе, ничектер, катыш тәәссер[3] бирә – сизгеч адәмнәрне беренче очрауда ук: “Бу кем, бу куркыныч дошманмы, әллә бик үтә якын дустмы?” – дип аптыраталар иде. Ул башта бик табигый, садә булырга теләп, андагы һаваның начарлыгына карамыйча, Мәдрәсә исламиядә ятып укый башлады. Ләкин күпкә чыдый алмады, аның тышыннан капланган инсафлы гади шәкерт пәрдәсе үзеннән-үзе җыртылды, аның астыннан асыл Баязид карый килеп чыкты – ул, соң кайткан өчен, назыйрның тәнбиһенә[4] каршы үзен көчләп тыйды. Тешләрен

---

[1] *Изтыйраб* – көенү, борчылу.

[2] *Гасабиять белән* – кызып китеп.

[3] *Тәәссер* – сиземләү.

[4] *Тәнбиһенә* – кисәтүенә.

кысып, ачуын басты. Ничектер Ходай ярдәм бирде, бу тыюда муаффәкыять[1] күреп, назыйрны эт урынына сүгеп, ихтимал, битенә бер нәрсә белән бәреп ташлаудан үзен коткарды. Һәм шул, көн идарәдән рөхсәт сорамыйча ук, фатирга күчте.

Шунда берәр атна үткәндер, ул бер көн кич төнге сәгать уникеләрдә Урмановка килде.

Йөзе кара көйгән, күзләрендә ут яна, куллары дерелди, тавышы калтырый иде.

Урманов аны тыныч каршы алды, ләкин вакытсыз кунакның нинди дә булса авыр мәңгелек бер изтыйрабтан туган карар белән килгәнен бераз сизенә иде. Баязид карый аңар карамады, кул бирмәде, өстәл янындагы артсыз урындыкка утырды да, кабызырга дип алган папиросын өзгәләп ташлап, инде мөкаддәмәләп[2], матурлап торырга тәкать калмады дигән бер тавыш белән:

– Иптәш, мин, авылга кайтып, атайны үтерергә карар бирдем, – диде.

Давыд Урманов гаҗәпләнмәгән бер төс белән тыңлады, ул ни дә булса, шундый бер эш көтә иде.

Баязид карый шул йөз, шул тавыш белән:

– Мин мирасны уйламыйм... Аның залим кулында эштән чыгачак сеңелләрем белән бичара мәзлум[3] әни өчен генә дә түгел, – дип, сүзен дәвам иттерде, һәм нинди хәлләр, нинди минутлар, нинди фикерләр соңында бу карарга килгәнен аңлату өченме яки нигә икәнен үзе дә белмичәме, утлы күзләре белән янып, идән буена йөргән хәлдә үзенең бөтен үткәнен сөйләргә тотынды.

## XVI

л яшь вакытыннан ук үзен мәңге котыла алмаслык бер читлеккә ябылган кош кебек сизә.

Йөрәгендә ниндидер бер ашкыну... Канатлары каядыр очарга тели, ләкин бераз селкенә башладымы – читлекнең тимер рәшәткәләре аны кысалар, тыялар. Ул, тугыз яшеннән алып, Оренбург Каргалысының биш йөз шәкертле кадим бер мәдрәсәсендә[28+] яши башлый. Пакь, матур, нәфис, шаян бала атасына хөрмәт йөзеннән, аңар дәресханәдә Хәлим хәлфә янында урын бирелә, якты, шатлыклы дөньяда аның сабый йөрәгенә беренче авыр яра,

[1] *Муаффәкыять* – уңайлык, уңыш.
[2] *Мөкаддәмәләп* – сүз башлап, керешләп (?).
[3] *Мәзлум* – рәнҗетелгән, кыерсытылган.

аның хакында Хәлим хәлфә исеме белән катыштырылып, кабих[1] бер гайбәт туа. Баязид хурлыгыннан утка ташланырлык минутлар кичерә, бераз үскәч, аның өстенә тагы намаз хәсрәте кушыла. Ул намаз укымый, аны бинамаз[2] дип мыскыл итәләр, көчли башласалар, тәһарәтсез укый, моны сизәләр, зур адәмнең баласы булганга, бер-ике мәртәбә гафу кылына. Ләкин Җиһан ишан:

– Бер рәкәгать намаз калдырса, аркасын ярганчы сугыңыз... Ризалыгым юк, гафу итмәңез... Аны үз мәдрәсәмдә тотмавым да шул монда үз итә, анасына таянып, мөсаһәләле[3] була диюдәндер... – дип, хат яза...

Мөдәррис, Җиһан ишанның Бохарада хөҗрәдәше, дусты сабый Баязидны чакырып үгетли, иркәли, бала да тырышып, көчләнеп, намазны калдырмаска башлый... Ләкин тыштан ягылган бу хәл озакка бармый, җае чыга да ул тагын алдашып куя... Аны сизәләр дә атасының сүзе буенча, әчелеккә[4] күлмәкчән яткырып, мәдрәсәнең иң түбән малаеннан, бөтен шәкерт алдында унар камчы суктыралар. Ул көндез һичкем белән сөйләшми, агарынып йөри, төннәрне йокысыз үткәрә, авыр хурлыктан мендәренә каплана да таңгача агълап чыга... Таяк эзе бетә, алдарга җай чыкса, тагы калдыра, тагы эләгә, тагын әчелек, тагы камчы, тагы, мендәргә капланып, хурлыгыннан төн буена җылап чыгулар...

Озын көннең рузасыннан соң дүртәр-бишәр сәгать дәвам иткән хәтем[5] вә тәравихлар да аңа бу газапны китерми калмыйлар. Ул үзе бөтен мәдрәсәдә зирәклеге белән мәшһүр. Шәкерт арасында аны “Илһами” дип, “Авызына Хозер галәйһиссәләм төкергән”[29+], “Ул укымый белә” дип йөртәләр. Һәм, чыннан да, ул дәрес хәзерләп баш ватмый, хәлфә алдыннан чыгуга, китабын киштәгә атып бәрә дә башкалар, почмакка капланып, тәркиб[6] ятлаган вакыт ул, бөтен мәдрәсәнең астын өскә китереп, уйнап, җенләнеп йөри.

Аның тавышы да яхшы. Шәкертләрнең атна кич мәҗлесләрендә ул каһарман була. Ул җырга бик ихласлы. Атна кичләрдә генә түгел, болай вакытта да ашханәгә төште исә көйли, җырлый башлый... Яшьтән үк матур мәкам[7] белән Коръән укырга да ярата. Шул фазыйләте[8] белән ул күп гөнаһлардан гафу да кылына.

Аның унөч яшьләрендә чагында мәчеттә җомгадан соң “Әр-Рахмән”

---

[1] *Кабих* – начар.

[2] *Бинамаз* – намазсыз.

[3] *Мөсаһәләле* – йомшак мөнәсәбәтле.

[4] *Әчелеккә* – мәдрәсәләрдә кергәндә читек-кәвешләрне салып калдыра торган ишек төбе бүлмәсе.

[5] *Хәтем* – Коръән уку.

[6] *Тәркиб* – сүз тезмәсе, бу урында “грамматик кагыйдәләр” дигән мәгънәдә.

[7] *Мәкам* – көй.

[8] *Фазыйләте* – өстенлеге.

сүрәсен Мисыр мәкаме белән укуы шундый куәтле тәэсир калдыра ки, халык, аңача мондый тавыш ишеткәнебез юк иде, диләр, күпләр җылыйлар, Оренбург, Каргалы йирендә зур шөһрәт иясе, Пензалык Бәдри карый шул җирдә ул баланы чакырып ала да, аның башыннан сыйпап:

– Бала... Синдә хәзрәти Давыд тавышы бар[30+], дияр мужиклар... Син әрәм булма, мин атаңа яздырыйм, син Коръән ятла... – ди. Ансыз да матур тавыш белән көйләргә ярата торган Баязидка бу гаҗәеп ошый, атасыннан рөхсәт килгәнен дә көтми, шул мәһабәт, нурлы йөзле, гаҗәеп калын, ләкин гаҗәеп моңлы, мөәссир[1] тавышлы сукыр Бәдри карыйның мактаулы шәкертләреннән Сафый карыйга утырып, Коръән ятлый башлый.

Ел тулар-тулмас бер арада Коръәнне ятлап кына түгел, тәкрарын да бетерә, икенче елның Рамазан шәрифендә хәзрәт аңа тәравихта Коръән хәтем кылырга куша...

Шулай итеп, ул Баязид карый[2] була.

Ләкин болар аны тыя алмый. Ул эчендә Коръән-Кәрим булуына, күп җәмәгатьне оетып хәтем кылуына карамыйча, телгә алу авыр булган эшләрдә йөри – аны Рамазан шәрифнең сигезенче көнендә, иртәгә Коръән багышларга торган бер вакытта, көпә-көндез шәһәрнең читендә бер марҗа белән күрәләр...

Хәбәр тиз тарала. Тегеннән, ачуына түзә алмыйча, атасы Җиһан ишан килеп җитә, ул күрешми, исәнләшми, Баязид карыйны мәдрәсә уртасына яткырып сала да бөтен шәкертләр, хәлфәләр алдында таяк белән эштән чыгарганчы, канга батырганчы яра...

## XVII

Таяк туктагач, ул идәннән күтәрелә дә, җыламый, һичкем белән сөйләшми-нитми, каядыр чыгып китә. Төн караңгы, Каргалының кара урамнары күп. Шул китүдән Баязидның эзе суына...

Кая киткән?

Моны һичкем белә алмый.

Тәравихта Коръән хәтем итә башлагач, карый дип, аны "авыз ачарга" ифтарга чакыралар, садака бирәләр. Шуннан бераз акча җыелган, үзенеке дә бераз бар. Ул шулар белән Оренбургка, аннан Казанга, Казаннан Уфага килә дә, Ходა белсен, ни өчен, Себер ягына китә. Акча бетә. Кулда һөнәр юк. Күп газаплар белән елны үткәрә дә, Рамазан шәриф якынлашкач, тагын шул карыйлыгы белән файдаланырга мәҗбүр була: ул, яңадан Эчке Русиягә

---

[1] *Мөәссир* – йөрәккә үтүче.
[2] *Карый* – Коръәнне күңелдән ятлаган кеше.

кайтып, Чиләбе өязендә яхшы ук атаклы зур бер мәдрәсәгә шәкерт була. Җомгада “Әр-Рахмән”не укый, Бәдри карый мәкаме белән сузылган: “Мәраҗәл бәхрайни йәлтәкыян, фәбиәййи галәйһи Раббикүмә түкәззибән...”нәр[31+] бу авыл халкына, хәзрәткә, хәлфәләргә шундый гаҗиб әсәр бирәләр ки, Баязид тиз арада карыйлык белән исем ала, мәҗлесләргә чакырыла башлый, әүвәлге Коръән укучыларның зур хәсрәтләренә каршы, быел тәравихта хәтем уку аңар бирелә.

Кыш үтә. Аңарда бер азрак акча бар. Ләкин ул шул дәрәҗәдә туя, тыгызлана ки, яз әсәре сизелеп мәдрәсәдән аз-маз шәкерт китә башлау белән, моннан да сыза. Акча бетә, тагы башлана ачлы-туклы көннәр... Ул ничә төрле кәсепкә ябыша: кибеткә керә, аннан бае белән сүгешеп чыга, Байкал буйларында юл төзәтүчеләргә атчы малай булып яллана, Эчке Русия белән Себер арасында елкы сәүдәсе йөртүчеләргә ялланып, көзге суык яңгырларда, караңгы куркыныч төннәрдә, корулы мылтыгын төзәп, ат өстендә якты таңнар көтә... Атлары талана, акчасын ала алмый, аны ташлап, тимер юлга хезмәткә керә... Япон сугышы[32+] ачыла, анда күңеле булып, китәргә уйлый, ләкин яшь дипме, ни диептер, алмыйлар... Ул арада Русия диңгезендә куәтле дулкын күтәрелә... Шул дулкын эчендә татар көймәсе дә кузгала, җанлана башлый...[33+] Дулкын Баязидны үзенә тарта... Ләкин ул кайда да барып керергә, ни белән башларга белми... Ул арада шәкертләр арасында дулкыннар сизелә, үзенең әллә нинди зур программалары, яңа тәртипләре белән мәдрәсәи исламия исеме дөньяга күтәрелә... Баязид карый да, башка җай тапмагач, шунда килеп керә.

Ләкин күп вакыт үтми, ул монда шул тышкы ягыннан бераз буялган, ялтыратылган Каргалы мәдрәсәсе икәнен ачык күрә...

Шулай булса да, моннан китә алмый... Китеп кая барасың?

Беркөн сеңеленнән хат килә... Атай исән, ләкин бөтен гаилә җәһәннәм көнендә икәне аңкый...

Митингларда була, шуларның береннән кайтышлый, юл уңгае туры килеп мәчеткә җомгага керсә, Вафа хәзрәтнең күз яше белән:

– Җәмәгать, заманнар бозылды, урамнар фетнә белән тулды, кем дә кем шул әһле фетнәнең эчендә күренсә, ул бөтен әһле ислам йөзенә кара ягачак, Ходай үзегезгә һидаять[1] бирсен, сакланыгыз, җәмәгать... – дип, вәгазь сөйләгәнен ишетә.

Бу аңар шундый тәэсир кыла ки, ул җомганың икенче рәкәгать фарызына сәҗдәгә яткан йиреннән торып, намаз беткәнне көтә алмый, мәчеттән чыгып китә...

---

[1] *Һидаять* – туры юл.

Моңарчы ниндидер томан эчендә бары бергә кайнашкан ләгънәт, протест, каһәр вә ашкынулар һәммәсе юлга төшә, томан күтәрелә, болардан билгеле бер идея туа.

Аның, Давыд Урмановка килеп, үзенең теге авыр карарын икърар кылуы[1] менә шуннан соң иде.

## XVIII

Күп вакытлардан бирле, эченә җыелып, йөрәгенә кан булып килгән бу хәлләрне сөйләп чыгу белән, ул бераз җиңеләйгән, тынычлана төшкән кебек булды. Гүя эчендәге җәһәннәменә су сибелде, гүя кайдан бәреп чыгарга белми йөргән каһәр, ләгънәт куәтләре билгеле юл тапты, гүя әллә кемнәргә, әллә ниләргә ачудан, көенүдән йөрәккә кан булып урнашкан, туктаусыз газаплый торган изтыйраблар берьюлы тындылар.

Асыл мәгънә ягыннан шуңа охшаш бер идеянең башкаларда да уянганын, Оренбург, Казан, Әстерхан, Уфа, Троицк кебек йирләрдәге мәдрәсә яшьләре эчендә шундый бер дәрт булганлыгын белгәч, бигрәк тә берничә як белән аңлашылып, ул идеяне “Фидаиләр” исеме белән бер партия шәкеленә кертергә карар тугач, ул инде бөтенләй күтәрелде, ниһаять, “Фидаиләр”нең беренче адымнары якынлашып, теге баш рухани, өч ахун, ике зур ишан – барлыгы алты җан белән хисаплашу мәсьәләсе планга кереп үк киткәч, ул яртылай яшәрде... Ул бу хакта сүз кузгалган саен:

– Гомерем буена газап чиктем... Гомерем буена җаным, тәнем белән тыгызландым, кысылдым... Менә беренче мәртәбә үзем теләгән эшкә аяк атлыйм... – дип тәкрар итәргә тотына. Үзе дә, башкалар да бу эштә аның иң беренче барачагын беләләр, артык мәгълүм үк булганга, бу хакта сөйләшергә дә кирәксенмиләр иде. Башкаларның киңәше, үзенең муафыйк табуы буенча ул авылына кайтуны кичектергән, хәзер беренче планда торган эшнең тиз арада дөньяга чыгуы өчен әзерләнә башлаган иде.

Менә берничә көн үтсен, “Фидаиләр” Баязид карый аркылы үзенең “бисмилласын” әйтәчәк иде.

## XIX

Сабырсызлык белән көтелгән сәгать менә бүген килеп җитә, дип торган вакыт качкын Сәрүҗи – Хәбип Мансуровның эзенә төшкәнлекләре, аның эшчеләр арасыдагы түгәрәкләреннән бере җыелган квартирда тентү булып, күп нәрсә алынганлыгы мәгълүм була: шул вакыйгадан хәбәр алу белән,

[1] *Икърар кылуы* – сөйләве, тануы.

безне дә исән калдырмаслар, Баязидка да белдерергә кирәк, дип уйлап торган бер заманда Урмановка, акылыннан шашкандай кычкырынып, бер ярлы авыру хатын килеп керә.

Бу – теге руслашкан татар исерек Абдулның хатыны Хәдичә иде. Аның иске француз күлмәгенең итәкләре, баткаклы урамда ашыгып килүдән булса кирәк, пычранып беткән, яулыгының ярты ягы төшеп, сары чәчләре, тузгып, йөзенә таралган, бите, күзе, Хода белсен, ниндидер зур афәткә очраган адәмнекедәй курку белән, шашкынлык белән капланган иде.

Ул, ишекне кереп җитәр-җитмәс, адәм котын алгыч тавыш белән:

– ... Син утырасың... монда... Харап булды иптәшең... Харап булды... Аны баструкка[1] ристан[2] итеп алып киттеләр... Харап кына булды шул, Илаһым... Нинди егет иде... – дип акырып җибәрде дә Урмановның: “Ни булды, кем харап булды”, – дигән сөален[3] җүнләп аңлый алмыйча, кулын бутый-бутый нидер сөйләргә тотынды... Баязид карый болардан ерак тормый иде. Хәдичә, аның квартирына барып, шимбә саен идәннәр юа, бүген дә шуның өчен дип аңар барган икән. Барса, ни күрсен, капка төбендә күзләре аларган, һәр икесе кылычлы ике адәм тора. Эчкә керсә, анда әллә нинди кылычлы, мылтыклы, сары төймәле руслар, ашыгып-ашыгып, Баязид карый торган бүлмәнең ишеген ачарга маташалар. Баязид эчтән:

– Мин чишенгәнмен, һич булмаса, чалбарымны кигәнче сабыр итегез, – ди.

Ләкин полиция аңар карамый.

– Без кунакка килмәгән, әйдә, тиз ач, юкса ватабыз, – ди дә, теге һаман ачмагач, ишек белән яңак арасындагы ярыкка кылычларының кыныларын тыгып, ишекнең элгечен каера башлыйлар.

Ул вакытта Баязид күлмәк өстенә җиләнгә охшаш озын бер нәрсә сала да яланбаш ишеккә килә. Пристав[4], околоточный[5], өч городовой[6], ике гади киемле адәм аның бүлмәсенә керәләр дә бар йирен, бар йирен актарырга, Хода белсен, нәрсәдер эзләнергә тотыналар... Тапкан бер әйберләрен бер якка куеп, төенчек-төенчек бәйли, ни алганнарын яза баралар...

Урмановның бу хәбәрне тыныч кына каршы алуы, Хәдичәне бераз басса да, ул һаман үзен тыя алмый, егетнең сөален аңлар-аңламас хәлдә:

– Харап кына булды шул..., Илаһым... Нинди һәйбәт егет иде... Иремә

---

[1] *Русчадан*: острогка – төрмәгә.

[2] *Русчадан*: арестант – тоткын.

[3] *Сөален* – соравын.

[4] *Пристав* – 1917 елга кадәр зур булмаган административ берәмлекнең полиция башлыгы.

[5] *Околоточный* – шәһәр полиция участогы бүлекчәсенең хезмәткәре.

[6] *Городовой* – 1917 елга кадәр шәһәр полициясенең иң түбән чины.

бер күлмәген бирде, кечкенә кызыма барган саен акчалар бирә иде... Илаһым, ни булыр, бу заманда андыйларны асалар, ди, бит... Ходаем, ник соң аларга катышырга инде безнең мөселман адәмгә... – дип, үзенекен тезеп алып китә иде.

Сүз арасында Урмановның күзенә керердәй булып карады да ниндидер ят, куркынулы тавыш белән:

– Ходаем, синең иптәшең Ягур дигән урыс малаен асканнар, ди... Син аның белән бергә тордың, сине ничек асмадылар... Аллам үзе генә сакласын, мөселман адәмгә ник шулай юк-барга катышып, үзеңне әрәм итәргә... Илаһым, Ходай, үзең коткар... – диде...

Урманов бер стакан су биреп, ире, балалары хакында сораша башлагач, хатын яхшы ук тынычланды, авыру, кара-саргылт йөзенә төшеп ниндидер аяныч төс биргән сары чәчләрен яулык астына тыкты да инде рәтләп сөйли башлады:

– Үз-үзен бу чаклы харап итәр икән... Полиция кешесе аңардан иплэп сорый, “Бу нәрсә? Буны кайдан алдың? Буны кем китерде?” – ди... Ул көлгән, мәсхәрә иткән адәм кебек, аның күзенә карый да: “Кайдан алыйм, үземнеке, үземнеке”, – ди... Мин ишек төбендә котларым очып торам... “Җә, дим, Ходаем, үземнеке, үзем эшләдем дигәнче, дим, таптым, фәлән кеше китерде, дисә, ни булган иде, үз башын үзе харап итте бит”, – дип, акылымнан яза яздым... Бик күп зәңгәр язулы кәгазьләр чыкты... Полиция кешесе аның күзенә туры карап, “Бу нәрсә, моны кайдан алдың?” – ди... Теге әйтми. Караваты астыннан әллә нинди ак калайга эретеп куелган киң җилем такта килеп чыкты... “Бу нәрсә”, – ди. “Бумы, ди, бу, ди, ничек әйтергә белмим инде, нәрсәдер шунда басарга”, – ди... Мич астыннан бик күп хәрефме, нәрсәме килеп чыкты... “Бу ни?” – ди, моны әйткән полиция кешесе инде кызып, ачуланып бара иде... Баязид аның йөзенә дә карамыйча: “Беләсез, ни икәнен... – ди, – әйтә белмим... Нәрсәдер басарга ясый идем”, – ди... Бар әйберен алдылар, яздылар, сигез төен итеп бәйләделәр дә, ямщикка салып, үзен солдат белән ристан итеп баструкка алып киттеләр... Ходаем, аңар ни булыр... Асмаслармы икән... Нигә юк-барга катышырга... Нигә, Илаһым, барын да дөрес сөйләргә... Моны таптым... Моны фәлән бирде, дип ялганласа, теле калыр идеме... Үзен-үзе харап итте бит... Асмаслармы икән... Синең иптәшең Ягурны асканнар, ди, бит... Син аның белән бергә тордың... Сине ничек асмадылар?..

## XX

Ул көнне Урманов Баязидны күрә алмады, аңа: “Хәзер соң, иртәгә

килерсез”, – диделәр. Иртән барса, частьта шул төнне кунып, сәгать уникедә шәһәр зинданына озатылганы мәгълүм булды. Зинданда исә: “Бездә, тоткыннар белән күрешү өчен, атнада ике көн билгеләгән, шуны көтегез”, – дип җавап бирделәр. Күрешү көнендә барса, “Һәркем кертелми, сез кардәшлегегез хакында шәһадәтнамә китерегез”, – дип кайтардылар. Шунлыктан Урманов тиз арада Баязидны күрә алмады, әхвәлене хатын сүзе белән бәян кылып, адвокаттан ни булыры хакында киңәш сорады. Ул: “Әгәр һәммә нәрсәсе, җавабы Хәдичә сөйләгәнчә булса, аңа җә Себер, җә крепость булыр”, – диде.

Баязидның сәламәтлеге начар, гасабилыгы[1] бик көчле, хыялы авыру икәнен иптәшләре беләләр иде. Җә Себер, җә крепость көтәчәк, эше каралганча шулай ялгыз утырачак булса, аның эштән чыгачагы башка һәркемнән бигрәк Урмановка ачык хис кылына иде.

Эше каралганчы рәһен[2] белән чыгарып тору мәсьәләсен кузгаттылар, ләкин адвокат: “Хатын сүзе дөрест булса, ул үзен куркыныч җинаятьче итеп күрсәткән, аны чыгару ихтималлары юк”, – диде. Ләкин курыккан Хәдичә үз хыялыннан бераз нәрсә кушкан булырга тиешле. Бераз мәшәкатьләрдән соң Баязидны, эшләре каралганчы, алты йөз тәңкә рәһен бәрабәренә чыгарачак булдылар.

Инде эше акчага терәлде.

– Алты йөзне кайдан алырга?

Баязид Каргалы мәдрәсәсен ташлаганлы бирле, атасы белән бөтенләй өзелгән булса да, авырулыгы, ялгыз утыруы, фәләне, ихтимал, бераз йомшатыр дип, Урманов Җиһан ишанга телеграмма бирде. Ләкин бушка, әрәмгә! Беренче, икенче телеграммалары бөтенләй илтифатсыз[3] калдырылды.

Ун сүзгә җавабы түләнгән өченче телеграммага каршы Җиһан ишаннан кыска бер җөмлә алынды:

– Минем андый угылым юк...

Монда “Мин “астыртын кызылмын”, социализм чыкса, барлык малымны ярлыларга үзем өләшеп бирергә әзермен”, – дип йөри торган яшь бай Салихов бар, башка җүн булмагач, шуңар сүз салып караганнар иде, ул кул гына селкеде.

Госман:

– Сез бит ул алты йөзне бер кичтә шансоньеткаларга[34+] да түгәсез... – дип сатулашып караса да, мәгънә чыкмады. Бай, куркынып, тәрәзәгә карады да:

---

[1] *Гасабилыгы* – тиз кызучанлыгы.
[2] *Рәһен* – залог.
[3] *Илтифатсыз* – игътибарсыз.

– Барыңыз... Тизрәк югалыңыз... Сезнең гөнаһ шомлыгыңыз миңа да тия башлар... – дигәнне аңлаткан бер тавыш белән сүзне икенчегә борды. Башка йирдән алырга өмид юк, инде авыру тоткын язмыш иркенә ташланачак иде. Шулвакыт көтелмәгән бер йирдән акча килеп чыкты.

Мәдрәсәи исламиянең баниларыннан[1] Кадыйр байның Йосыфҗан исемле углы бар. Байбәтчәләр тибына охшамаган, акыллы, зирәк, гыйлемгә һәвәсле бу егет кадим мәдрәсәдә чакта Урмановның шәригы (сабакташы) иде. Алар төрле мөнәсәбәттә булындылар. Соңгы вакытта аралары бозылып, хәзер сөйләшмиләр, рәсми дошманнар иде.

Салиховтан буш кул белән кайтып, аптырый төшеп утырган бер заманда Урмановка шул Йосыфҗан килеп керә дә:

– Баязид карыйның сәламәтлеге бик начар, диләр... Залогка акча тапмагансыз, дип ишеттем... – дип, рәһенгә кирәк алты йөзне үз кесәсеннән гарыз итә[2]. Урманов башта егетнең пакь ният белән килүенә ышанмады. Аны салкын, бик салкын каршы алды. Гүя бу байбәтчә үзенең алты йөзе белән боларны тәхкыйр итәргә[3], эченнән көләргә, үзенең зур куәтен күрсәтергә теләгән кебек күренде. Чак калды, аны, кереп авыз ача башлау белән, бүлмәсеннән куып чыгармады. Ләкин Йосыфҗанның яхшы ниятенә шөбһә итәргә мөмкин түгел, аның карашы шундый түбәнчелекле, сүзләре шундый ихласлы, тавышы шундый үтенечле иде ки, Давыд ихтыярсыз аңа җиңелде. Баязид карыйны, эшләре каралганчы, зинданнан чыгарып тору өчен рәһенгә кирәк булган алты йөзне Йосыфҗаннан алачак булдылар. Давыд Урмановның иртә сәгать унбердә зинданга килүе Баязид карыйга шул хәбәрне ирештерү өчен иде.

## XXI

Төн караңгы, дөнья үлем тынлыгы эчендә иде. Шулвакыт кинәт җил кузгалып, кантонның зур бакчасындагы карт агачлар ниндидер бер куркыныч белән шаулаша башладылар. Җил артык көчәйде, бакчаның нәкъ уртасында куәтле өермә кузгалды да ботаклары белән тирә-якны каплап утырган берничә зур агачны төбе-тамыры белән күтәреп ташлады. Баязид, өстенә авып килгән агачлардын котылу өчен, ярым хәрабә хәлендәге зур сарайга сыенырга өлгерә алмады, коточкыч бер тавыш белән күк күкрәде, куәтле яшен үзенең бер секундлы яктысы белән дөньяны ялтыратып урады да коеп яңгыр яварга тотынды.

---

[1] *Баниларыннан* – нигез салучыларыннан.
[2] *Гарыз итә* – тәкъдим итә.
[3] *Тәхкыйрь итәргә* – мыскыл итәргә, хурларга.

Төннең куе караңгылыгы белән яшеннең гаҗиб яктысы бер минутта ничә мәртәбә алмашына, агачлар куәтле җил белән ниндидер куркыныч хакында сөйлиләр иде... Баязид котылмак булып сөялгән сарайның егылырга барганын күргәч, кире агачларга йөгерде. Йөгерсә, ни күрсен, анда өч хатын... Кайсылары яртылай ялангач... Аларның чәч толымнарыннан ниндидер чалмалы адәм урап тоткан да, аяклары белән типкәли-типкәли, каядыр өстери... Хатыннар кызганыч тавыш белән җылыйлар, ялваралар... Егет, куркынып, кире чигенергә өлгерә алмый, тавышларның берсе, юк, барысы да таныш шикелле тоелып, ул алар өстенә ташлана. Ни күрсен, хатыннардан берсе – анасы Гайшә, икесе – сеңелләреннән Маһирә белән Сабира... Чалмалы адәм исә – атасы Җиһан ишан... Җылаудан, куркынудан йөзләре шешенеп беткән Маһирә Баязидны таный да:

– Абзыкай, безне үтерә!!! Коткар, безне үтерә!!! – дип акырып җибәрә...

Баязид:

– Мине эштән чыгаруың җитмәгән... Инде аларга тотынгансың икән... – дип акырып, чалмалы адәмгә ташлана... Ләкин шул секунд зур бакча, хәрабә сарай каядыр югалалар, Баязид үзен ерак Себернең кара ташлы биек таулары арасында әллә нинди чокырда, юеш йирдә күрә... Башының ярты чәче кырылган... Өстендә соры чикмән... Аягында авыр богаулар... Янында үзе шикелле киенгән бик күп адәмнәр бар. Болар һәммәсе дә сүзсез, басынкы, авыр карашлы, караңгы йөзлеләр... Аякларындагы богауны чак өстерәп, арган куллары белән зур ташлар тирәсендә кыймылдыйлар... Өстәрәк яшел читле фуражкалы кешеләр тора... Югары карасаң, ике яклап, әллә кайларга менеп киткән таулар арасыннан ерак күк күренә. Дөнья бераз караңгы... Кояш та, ай, йолдызлар да юк... Көнме, төнме, кичме, иртәме? Белер хәл юк. Баязид калын, озын тимер ломны алды да ишелергә торган зур ташны каера башлады... Таш селкенгәндәй итә. Кемдер: “Сак бул, үзеңне басмасын”, – ди. Аның бу сүзе чыгып бетмәде, таш кузгалды, менә, менә тәгәрәп китәчәк тә Баязидны изеп юк итәчәк... Кемдер: “Үләсең, тиз кач”, – диде. Теге авыр богаулы, караңгы йөзле адәмнәр аңар акрын гына әйләнеп карадылар, телсезләрмедер, һичберсе дәшмәде. Таш авар, менә, менә басачак та юк итәчәк, изәчәк. Баязид куркуыннан бөтен көче белән читкә ташланмак булды, ләкин, гүя нидер баскан, нидер тота, ул урыныннан кузгала алмый... Теге авыр богаулы, караңгы йөзле адәмнәрнең йөзләре тагы караңгыланды. Кылычлылардан кемдер нидер дип кычкырып йибәрде, Баязид тагы омтылды, тагы кузгала алмады, кылычлы адәм тагын кычкырды, ләкин аның авызыннан адәм сүзе чыкмады, ниндидер кыңгырау тавышы килде. Баязид сискәнеп уянып китте. Караса, байтактан ялгызы яшәп килгән зинданның тар, биек, ярым караңгы таш бүлмәсендә тимер караватында ята... Әнә

яртылай диварга кертелеп ясалган тимер өстәл белән урындык, әнә ишек төбендә ләгән, әнә түбә тактаның янына асылып куелган кечкенә фонарь кебек кенә күренгән тәрәзә... Ул әле дә тимер рәшәткәдә... Ул әле дә шулай караңгы, хәсрәтле төс белән карый.

Шыңгырдавык тәкрар ителде. Баязид та, торып, ашыгып киенә башлады. Беренче звонок алтыда була. Бусы – торып киенергә куша. Ун минуттан соң тагын берсе була, димәк, барларга киләләр, тәмам киенгән булып, идән уртасында ишеккә йөзең белән барлаучыларны аягүрә каршы алырга тиешсең... Баязид тиз-тиз киенде дә, караватына басып, тәрәзәгә үрелде. Тышта көн яңгырлы, һава юеш, күк, куе караңгылыклар белән капланып, ачулы, чытык йөзле күренә иде. Үзенең вак, караңгы, тимер рәшәткәле тәрәзәләре белән киң яланның аръягында күренеп утырган тауларга кайгылы йөз белән карап торган өч катлы таш бина, аның тирәсендә мылтыгын җилкәсенә салган хәлдә сак адымнар белән йөргән солдат – табигатьнең ачулы, караңгы йөзен тагы авыррак күрсәтәләр иде. Соңгы көннәрдә әллә нинди мәгънәсез, куркыныч төшләр белән бик борчыла башлаган Баязид карый төшендәге күренешләре белән тәрәзәдән күргән бу ачулы кыяфәтләрне бер-береннән аерып җитә алмады, тегеннән кызыл таш бинаның сул як башындагы капка янында торган солдат, Баязидка карап, мылтыгын төзәде:

– Тәрәзәдән төш, юкса атам...

Карый төшеп өлгерә алмады, тимерле ишек шалтырап ачылды да аннан кылычлы, мылтыклы берничә адәм бусагага килде.

Тәрәзәгә караганын, ахры, күргәннәрдер, калын гәүдәле, ачулы тавышлы өлкән надзиратель:

– Сез бүген килмәгән... Мин ничә әйттем, карарга ярамый дип... Тагы бер күрсәләр, сезне карцерга утыртмый булмас... – дип сукрана башлады.

Ләкин янындагы матур йөзле озын офицер аңар илтифат итмәде, ул тоткынның йөзенә чыккан таргуны[1] күрде булса кирәк, гадәттәгедән дә ригаялерәк[2] рәвеш белән кулын маңлаена куеп исәнләште дә:

– Кәефегез яхшымы... – диде.

Зинданның басынкы, караңгы хәятендә бер якты нур булса – менә шул матур йөзле офицердыр. Ул начальникның могавиннәреннән[3], бугай. Атнага ике-өч мәртәбә күренә һәм, күренгән саен, үзенең мөлаем карашы, нәзакәтле мөгамәләсе, матур йөзе, дустанә сүзе белән күңелләрне йомшартып китә. Аның тәэсире белән боек тоткыннар бераз гына зинданның зинданлыгын

[1] *Таргуны* – борчуны.
[2] *Ригаялерәк* – кайгыртыбрак, хөрмәтләбрәк.
[3] *Могавиннәреннән* – ярдәмчеләреннән.

оныталар.

## XXII

Баязид карый өченче коридорда һәммәсе сәяси тоткыннар белән тулган егерме дүрт бүлмәнең унынчысындадыр. Коридорның сул як башында тәһарәтханә бар. Һәр тоткынның үзен аерып, иртән, кич, көндез – барлыгы өч мәртәбә шунда ләгән түгәргә, җуынырга, бушанырга чыгаралар. Баязид өчен бүген дә шул иртән җиденче сәгатьтә бүлмәсенә кертеп бирелгән чәе, уникедә кәбестәле көндезге ашы, алтыда тагын кәбестә белән карабодай боткасыннан гыйбарәт кичке ашы-чәе, сигездән соң мәҗбүри ятуы, шул мөддәт[1] эчендә дүрт яктан биек таш койма белән әйләндерелгән кечек мәйданда солдат күзе алдында ярты, бер сәгать йөреп керү, өч мәртәбә коридор башындагы тәһарәтханәгә барып килү белән үтә торган басынкы, күңелсез, кайбер вакыт сәгате ел диячәк мәртәбәдә акрын кузгалган көннәрнең берсе булачак иде.

Тик төнге төш белән иртәнге тәрәзәдән карау вакыйгасы аның бүгенге көненә бераз башкалык бирәләр, ул үзе дә башының кызганын сизә. “Бер эш чыгар да, үземне тыя алмам”, – дип, бераз куркыта төшә иде. Һәм чыкмый да калмады. Ул чәй эчәргә генә утырган иде, баягы ачулы йөзле калын надзиратель тимер ишекне шартлатып ачты да ригаясез тавыш белән:

– Теләсәңез, барыңыз... – диде.

Баязид, ләгәнен алып, коридор башына барды. Ялгышып, ләгәнен крантка якын куйган икән – буны күрү белән, надзирательнең йөзе бүртенде дә:

– Мин сезгә ничә әйттем... Анда куярга ярамый дип... Колагыңыз бардыр бит... – дип кычкырды... Баязидның күз алды томаланды, тагы бер генә сүз, ул үзенә хуҗалыгын югалтачак, ихтимал, бер нәрсә белән алып бәрәчәк иде. Надзиратель сизендеме, тәкрар әйтмәде, Баязид үзен көчлек белән тыйды:

– Мин хайван түгел... Сез чигегездән ашасыз... Җүнле сүз белән әйтсәңез дә була...

Надзиратель, тагы башкалар да килде, якындагы камерадагы сәясиләр, ишек дөбердәтеп, надзирательләргә протестларын белдерә башладылар. Нәтиҗәдә, надзиратель Баязид өстеннән начальникка шикаять итәчәген игълан кылды. Шикаять булачак, аны икмәк-су белән яшәргә, берничә көнгә караңгы бүлмәгә – карцерга ябачаклар иде. Ләкин, бәхетенә каршы, янәшә камерадагы яһүди егете: “Мине нәүбәттә кичектердең, тиз ач, мин

[1] *Мөддәт* – вакыт.

тәһарәтханәгә чыгам”, – дип бәйләнде, талаш китте, надзиратель яһүдне “жидовская морда” дип, теге тагын нindидер сүзләр белән җавап кайтарып, ишекне каты дөбердәтеп, скандал чыгардылар. Бөтен коридор шаулый, һәммә сәясиләр үзләренең камераларыннан, эчтән торып ишек суга, кычкырыша башладылар. Нәтиҗәдә, шундый ук могавиннәреннән берен чакырдылар да яһүд егетен биш көнгә карцерга яптылар. Шуның белән надзирательнең ачуы кайтты булса кирәк, ул Баязид хакында шикаять итмәде.

Ләкин бу көн Баязид өчен, гомумән, тынычсыз булып чыкты.

Яһүд егете карцерга алынган соң бераз тынычланып кына киләләр иде, аңсыздан Баязид камерасының калын ишекләре шаулатып ачылды да, аннан биш-алты соры шинель ашыгып килеп керделәр.

Болар – тентү өчен иде.

Гаҗәп бер тәкәллефсезлек белән[1] һәммә нәрсәсен актара, үзенә сүз әйтмичә, сорамыйча ук бармак араларына чаклы һәммә йирен капшый башладылар. Баязид, эч пошканнан, икмәк йомшагыннан вак шарлар ясаган иде. Аңар әһәмият бирүләрен уйламыйча, ул аларны шунда шүрлегенә ташлый куйган... Боларны җыеп алдылар да моңа җәза йөзеннән: “Сезгә иртәгә икмәк бирелмәс”, – дип игълан итеп чыктылар.

Баязид кызган, аның күз алды яңадан томанланган иде. Ул бик зур көч белән үзен тыя алды:

– Икмәк бирмиләр икән... Илаһи, бирмәсеннәр... Адәм бер көн ашамаудан үлми...

Ләкин бу нинди эш? Буны ничек аңларга?.. Кемнәрдер аңсыздан басып керәләр дә синең бөтен нәрсәңне, киемнәреңне генә түгел, тәнеңнең иң нечкә йирләренә кадәр капшап чыгалар... Ул буны аңламый, буның белән үзенең намусы, кешелеге тәхкыйрь ителгән, үзен базарга сатарга чыгарылган хайван мәртәбәсенә төшерелгән кебек хис кыла; гомумән, мондагы басып кереп тентүләр аңа зиндан хәятенең иң авыр минутларыннан иде. Намус хәкарәт ителү[2] бер, үзен тыю, кызып, бер нәрсә белән бәреп ташлаудан саклану – икенче. Бу икенчесе дә аның өчен зур мөшкил[3] иде.

## XXIII

Уникедә көндезге ашны керттеләр. Бүген аңа өйләдән әүвәл йөрергә

---

[1] *Тәкәллефсезлек белән* – тартынмыйча.
[2] *Хәкарәт ителү* – кимсетелү.
[3] *Мөшкил* – кыенлык, проблема.

тугры килгән, шуңар күрә иштиһасы[1] яхшы, аш та тәмле, ботканың ярмасы да иссез күренә иде. Ашарга туры килмәде, ул, үзенең тимер урындыгына утырып, зур кашыгын кулына гына алган иде, надзиратель ишекне ачты да:

– Күрешергә!!! – диде.

– Кем булыр?.. Кем булсын, Давыдтыр...

Ул ялгышмады, анда, күрешү бүлмәсендә, агач рәшәткәнең теге ягында җылтыр пальто белән озын чиркәс бүреге кигән Урманов тора иде.

Надзиратель бик якын килмәскә, татарча сөйләшмәскә кушты.

– Ну, иптәш, хәлләр ничек?.. Ничек киченәсең?

– Хәзергә, зыянсыз... Тик менә кызып, берсен яңаклап ташлаудан куркам... Үземне үзем тыю гына – зур газап...

– Нигә алай... Әллә бик кысалармы?..

– Кысалармы, дип, төрмә – төрмә инде... Ләкин артык тарлык юк... Кыйнаулар, җәберләр сөйлиләр... Мин боларны ялган дип уйлыйм... Чөнки монда аңар бер дә имкян[2] юк... Төрмәнең үзенең низамы[3] бар... Шуны аша чыкмасаң, сиңа сүз тидерергә адәм булмый...

– Китаплар бирәләрме?

– Ун көн бирмәделәр... Ул һәрбер яңага шулай икән... Гарантиясеме, дип атыйлар... Тик кичә генә башлап алдым...

– Алай исә, ару булган...

– Ару булу гына кая! Китап – иптәш, китап күңел ача, диләр... Төрмәдә, ялгызы бер камерада утырмаган адәм китапның нинди юлдаш икәнен һичбер вакыт чыны белән аңлап бетерә алмаячак... Мондагы тарлыклар, идән жуулар, теләгән ашың булмау, ятакның катылыклары, фәләннәре һичбер нәрсә түгел, аңар көне белән өйрәнәсең... Ләкин монда эшсезлек үтерә... Мин җәнлекләр йортында зур бер аюның тар читлектә көн буена туктамый йөрүен күреп гаҗәпләнгән идем... Аны яңа аңладым... Эшсезлектән шул дәрәҗәгә җитәсең, заман туктый, сәгате – көн, көне – ай, ае – ел тоела; әллә кайчан торгансың, сиңа ниһаятьсез вакыт үткән кебек, ә ул төш тә җитмәгән була... Менә шулвакыт тик китап сине жуата... Адәм ышанмас, ишек ачылып китте, беренче мәртәбә:

– Китаплар китердем, – дип кычкыргач, мин һушмнан яза яздым... Ничек сикереп торганмын, Ходa белә, атылып килдем дә, китапларны өчесен берьюлы кочаклап алып, әле катыргаларын, әле эчләрен алмаш-тилмәш үбә, туктаусыз үбә башладым. Надзиратель әле дә сөйләп көлә: “Мин, акылдан шашты, күрәсең, бу, дип торам”, – ди.

[1] *Иштиһасы* – аппетиты.
[2] *Имкян* – мөмкинлек.
[3] *Низамы* – тәртибе, кагыйдәсе, режимы.

– Төрмәнең китапханәсе бармы?.. Ниләр бирделәр?..

– Каталогында бик күп нәрсә бар... Ләкин теләгән берсе табылып бетми, башкалар алган була... Шулай да миңа өчесе дә гаҗәп яхшы нәрсәләр туры килде. Писарев, Чернышевский, иң гаҗәбе: монда Герцен да бар[35+]. Әле Писаревнең "Реалистлар" дигәнен укый башладым[36+] ... Кадалсын бөтен татар дөньясы... Валлаһи... Гомер буена гыйлем артыннан йөреп, шуларны җүнле аңларга куәт юк. Уйласаң, җан әрни...

– Рауза сиңа сәлам әйтте... Минем анархистым, ди...

– Искә алуына рәхмәт әйт...

Урманов алты йөз табылганын, берничә көннән чыгарга мөмкин булуын, Сәрүҗине кичә төндә озатканын, бүген кич Мәдрәсә Исламиядә ихтилял күтәрелү ихтималын сөйләп бетерүгә, надзиратель урыныннан кузгалды:

– Вакытыңыз бетте...

Баязид карый яңадан шул күп тимер ишекләр, күп тар баскыч, ярым караңгы, тар, тын коридорлар аша үзенең тар, биек, ярым караңгы бүлмәсенә кайтты. Артыннан зур тимер ишек шаулап ябылды, йозак шалтырап бикләнде.

Нидәндер аның иштиһасы[1] беткән иде. Ашын каба алмады. Надзиратель коридорның аргы башына таба киткәнен аяк тавышыннан белде дә күрше бүлмәдә шулай ук ялгызы утырган рус студентка Егор хакындагы хәбәрне диварга чиртеп сөйләде. Ул, кыенлык белән булса да, моңар өйрәнгән, бу аңар китап кадәр үк җуаныч биргән иде. Тик сак булырга кирәк, сизсәләр, моның өчен дә рәхмәт әйтмәячәкләр иде.

Дөнья караңгыланан башлады. Зинданның түбә такта янында асылган кечек фонарь кебек тәрәзәсе яктыны саран бирә, кич якынаюы монда тыштагыдан күп тиз сизелә иде. Сәгать алтыларда кич аш, чәй... Тагы бер мәртәбә барлап үтү...

Җидедә төн буе янып утырачак кечкенә лампа кертелде... Сәгать сигездә хәят бетте, зиндан олуг кабер тынлыгы эченә калды; һәммә тоткыннар йокыга яттылар.

Баязид карыйның каны кайный, башы кызган, хыялы уянган. Йоклый алу түгел, бер урында утырып торырга да тәкате юк; ул үзен арыту, әгъзаларын хәлсезләтү өчен камерасы буйлап, кысык читлектәге аю кебек, туктамый әйләнеп йөри иде.

Ишекнең кечкенә күзе ачылды:

– Сез беләсез бит сигездән соң йөрергә ярамаганын... Ятыңыз инде.

---

[1] *Иштиһасы* – ашау теләге.

Баязид карый:

– Мин бит һичкемгә тыгызлык итмим... Йокым килмәгәч нишлим... – дип караса да, надзиратель яңадан сүз әйтергә урын калдырмаячак бер тавыш белән:

– Не по-ла-га-ется, – дип, өзә-өзә тәкрар итте.

Тоткын, йоклый алмаячагын ачык хис итсә дә, чишенеп ятарга мәҗбүр булды. Дөнья тынды.

Зинданда хәят туктады.

## XXIV

Бу вакыт Урманов ирләр гимназиясе пансионының ишеге төбендә иде. Тангатаровның пансионнан чыгарылганлыгын хәбәр бирделәр.

Бу ят күренмәде. Бу ихтимал күптән бар, күптән үк иптәшләренә начар тәэсир итү ихтималыннан саклану өчен бу юлда дәвам итсә, аны пансионда тоту мөмкин булмаячагын, аннан соң, табигый, степендиядән дә мәхрүм кылыначагын, әле хәзергә тик директорга мөнәсәбәте булган карт әбисе, Мәрьямбикә аркасында гына чыгармый тордыкларын сиздерәләр иде. Ләкин Тангатаров үзе моңар салкын карый:

– Чыгарсалар чыгарырлар инде... Стипендия дип, үз идеямә каршы барырга хәлемнән килми... Мондый көннәрдә, укыйм дип, эшеңне ташлау – үзе эгоизм... Мин диплом өчен дөньяда тормыйм... Доктор яисә адвокат булып, халык җилкәсенә утыру, шуннан килгән акча белән зур сарайларда яшәү барыбер миннән булмаячак... Мин халыкка китәм... – ди иде.

– Ни өчен чыгарылды? – дигәнгә каршы:

– Башка ни өчен булсын, билгеле, ни өчен!.. – җавабын алгач, Урманов иптәшләреннән Нәҗип Кәмал дигәннең квартирына китте.

Яшьләр (халык өчен) уку кичәләре ясамак булалар. Бүген анда шул хакта берничә киңәш булачак, Рауза, Госман, Алкин, Булатов, тагын берничә егет катнашачак иде. Тангатаров анда барырга тиеш иде. Шәһәр бакчасының чиркәүгә караган кечкенә капкасы төбендә (яхшы тактика), күн эшләпә кигән, чәче җилкәсенә төшеп торган озынча тар карасу йөзле, сызылып чыккан кара мыеклы бер егет – иптәше Җиһангир очрады.

Урманов чыннан гаҗәпләнә калды:

– Чү... бу ниткән эшең, Җиһангир?! Мәдрәсәи исламиядә шәкерт хәзерге сәгатьтә асты өскә килә... Син шул дулкынны кузгатучылардан берсе, Нигъмәт казый әйтмешли, ихтилял каһарманнарының беренчеләреннән... Ә үзең иң кирәк минутта бакчада йөрисең...

Җиһангир ят, яшеренле бер тавыш белән:

– Алла хакы өчен, юлыма кискә[1] булма!.. Мин хәзер мәдрәсәдән килдем... Хәзер, хәзер тагын анда барып җитәм... – диде.

– Кырынган... Майланган... Хуш ислəнгән... Кулда көмеш башлы таяк... Әйт, пожалуйста, ни көтәсең?..

Җиһангир тагын шул ук ят, яшерүле, инде ярым ялынулы тавыш белән:

– Иптәш, Алла хакы өчен, мине куй... Мин хәзер мәдрәсәгә барып җитәм... Бик кирәксә, әйтим: мин Һаҗәрне көтәм... Аның ире Кадыйр бай хәзер мәдрәсәгә хөкемгә бара... Бу вакыт Һаҗәр җә үзе чыгарга, җә асравын чыгарырга тиеш иде...

– Шәп иттең, алайса!!!

Урам буйлап болай таба килгән бер хатын күренде. Җиһангир бөтен дөньядан яшеренергә мәҗбүр адәм кебек сакланып күз салды да кире чигенде... Аның йөзе, күзе гаҗиб бер көчле көтүне аңлаталар иде.

Урманов, китә башлап, сүзен бетерде:

– Аңла, иптәш, син ике йөз иптәшеңә каршы җинаять эшлисең... Җиһангир аның тәмам әйткәнен көтмәде, инде якынлап ук килгән теге хатынга үтә дикъкать белән күз салды да тагы шул ят, яшерүле һәм ялынулы тавыш белән:

– Алла хакы өчен, мине куй... Син Һаҗәр белән минем мөнәсәбәтне беләсең... Аңла, зинһар, син: “Дөньяда Һаҗәр бетмәс, Аллаһның мең Һаҗәре бардыр”, – дисең... Миңа алай түгел, миңа дөньяда Һаҗәр бер генә... Һаҗәр – минем өчен бөтен дөнья, бөтен хәят... Мин чирек сәгатьтән мәдрәсәдә булам, – диде...

Хатын бакчаның кабырга як капкасыннан керде, Җиһангир кечкенә капкадан борылды, икесе дә бакчаның кыйбла як почмагындагы буш, караңгы агачлыкларга таба киттеләр.

## XXV

Нәҗип Кәмал ике катлы яхшы, бай өйдә тора иде. Ул Урмановны үзе каршы алды. Башында кара кәләпүш, өстенә яхшы тегелгән кара казаки кигән, ябыграк йөзле, озын буйлы бу егет беренче карашта гади. Ләкин аның мөгамәләсендәге табигый нәзакәт, тавышындагы ягымлылык, күзләрендәге ниндидер бер хәссас[2] җан вә хыялый төс тиз арада үзләрен күрсәтәләр иде.

Ул чыга-чыга электр шәмене яндырды да Урмановны култыгыннан алды:

– Иптәш, син бик соңга калдың!..

---

[1] *Кискә* – бу урында: каршылык, киртә.
[2] *Хәссас* – сизгер, хискә бай.

– Килделәрме?..

– Күптән...

Урманов керә башлады. Ләкин Нәҗип Кәмал, аның калошсыз икәнен күреп, кире туктады.

– Иптәш, Алла хакы өчен, чабаталарыңны салыр, һич булмаса, бераз сөртер идең...

– Ул салынмый... Җә, лыгырдама юкны... Хан сарае түгелдер әле...

– Хан сарае булмаса да, ачуланма тагы, синең “җәһәннәм базың” да түгел шул. Урманов, штиблетларын сөртеп, югары атлады.

Зал ашасыннан үтеп, яхшы җыештырылган, ширмалы, китаплары белән тулы этажеркалы, Маркс[37+] һәм хәзрәти Мәрьям рәсемнәре[38+] белән зиннәтләнгән бер чибәр бүлмәгә керделәр.

Анда Рауза туташ, Акчулпанов, Госман, Тангатаров утыралар иде. Булатовны полиция эзәрли икән, шунлыктан ул килә алмаган.

Давыд баш иеп кенә исәнләште дә Госман янындагы буш урындыкка утырды. Сүз Егор хакында иде.

Аның асылу хәбәре чын булган. Инде бүген ачыгы мәгълүм.

Рауза туташ, аптыраган кеше кебек, бик озак Урмановның күзләренә карап катты – ул аны җә күрми, җә танымый иде. Бу вакыт туташның йөзе үлем аклыгы белән капланган, иреннәре дерелди, күзләре ниндидер авыру дәһшәт белән карыйлар иде.

Бераздан телгә килеп, хафалы, басынкы тавыш белән:

– Давыд, ишеттеңезме?.. – диде дә урыныннан торды:

– Иптәшләр... Мин утыра алмыйм хәзер...

– Акчулпанов аны озатмак булган иде, туташ кул селкеде:

– Ах... Куеңыз... юкны... Мин... ялгыз...

Калганнарда да эш җае күренми иде. Һәммәнең зиһене мәсьәләдә туктый алмый, ихтыярсыз караңгы күккә сузылган куркыныч, шомлы дар агачы, кызыл якалы, кара йөзле җәллад һәм шулар аркылы үзенең хәятыннан язачак якын иптәшләре аларның хыялына килә иде.

Госман акрын салмак тавыш вә аз сүз белән приказчиклар җәмгыяте үзенең залын буш бирәчәген, рөхсәтне Ногман учитель алачагын сөйләде. Моңар һичкем һичбер сүз димәде.

Анардан соң нәзәкатьле тавыш белән реалист Акчулпанов кичәдә ниләр уку хакында үзенең программасын ачты. Беренче планда гомуми сайлау хокукы... Икенчесендә – Бөек Франция революциясе... Өченчедә – Бакунинның хәяты, тәгълиматы[39+] иде.

Әүвәлге икесен кирәк таптылар. Нәҗип Кәмал белән Урманов сүзләрне, лөгатьләрне татарчага әйләндерәчәк булды.

Мәсьәлә шуннан артык бара алмады.

Уртада асылган иптәшләренең күләгәсе тора, шуның да хәсрәтеннән телләр бәйләнә, зиһендәге нәрсәләр тарала иде.

Нәҗип Кәмал:

– Иптәшләр, бүген барыбер эш чыкмый, иртәгә калдырыйк! – диде.

Һәммәсе һичбер сүзсез урыннарыннан тордылар да эшләпәләрен-фуражкаларын кулларына алдылар. Тегеләр төрлесе төрле якка таралды. Нәҗип Кәмал белән Урманов мәдрәсә исламиягә киттеләр.

## XXVI

Моннан мәдрәсәгә байтак җир иде. Шул ерак араны егетләр һичбер сүз алышмыйча үттеләр. Икесе дә авыр, басынкы халәттә, икесе дә әллә кайда авыр, караңгы хыял дөньясындалар иде.

Нәҗип Кәмал Егорны хәтереннән чыгара алмады.

Ул аның белән Урманов аркылы танышкан һәм алар тиз арада, ничектер, бик артык якынлашканнар да иде. Әле кайчан гына кайнап, ташып, дөнья җимерәчәк булып йөргән яшь, тулы бер хәятның хәзер үлеменең ниндидер мәгънәсез, буш караңгылыгына җотылуы – аңа аңлап, сүз белән әйтеп булмый торган бер трагедияне хис кылдыра. Ул ни чаклы шул мәгънәсезлекнең эченнән җыртып чыгарга теләсә дә, шул караңгы мәйданда, шомлы баганада бер яктан икенче якка салланып[1] торган куркыныч шәүләдән башка нәрсәне хыялына китерә алмый, ай каплана, йолдызлар сүнә, тик шул куркыныч шәүлә кала иде...

Урманов өчен дар агачы да, Баязид та, зиндан да каядыр югалды, ул киткән йокысыннан уянган адәм кебек, бара торган йиреннән коты очып:

– Ни булачак... Ни булачак иде!.. – дип туктый яза һәм, хакыйкатән дә[2] аптырап, авыр саташу халәтенә килә иде... Чынлап та, ни булачак, әгәр дә кичә Нәфисәне харап иткән булса, ни булачак иде!

Ни булачак!

Ул Нәфисәгә өйләнергә мәҗбүрият[3] күрәчәк, вөҗданы, намусы шуңар көчләячәк... Өйләнмәсә, мәгъсүм[4] бер баланы алдаган, харап кылган булу түбәнлегенә төшәчәк, үзенең гомергә ихтирамы бетәчәк, ихтимал, пакь вөҗданга аны гомер буена газапларлык кара күләгә төшәчәк иде... Ул боларны күтәрмәячәк, табигый, өйләнәчәк, шуңар намусы белән үзен мәҗбүр

---

[1] *Салланып* – чайкалып.
[2] Хакыйкатән дә – чынлап та.
[3] *Мәҗбүрият* – мәҗбүрлек, ирексезлек.
[4] *Мәгъсүм* – гөнаһсыз.

күрәчәк...

Аннан соң ни?.. Аннан соң барына да “вәссәлам”!!!

Хатын алдың... Чәүкә оясы кордың... Аннан соң – аннан соң дөньяда үзе кебек ахмакларны тудырудан башка һөнәре булмаган мещаннарның[40+] бере булдың да!.. Сау бул, идеалың юлына хәятыңны бирү! Сау бул, якты киләчәк юлына хезмәт кыла алу!!!

---

Мәдрәсә яшьләренең күбе кебек, Давыд Урманов та, кыш укырлык акчаны табу өчен, җәйләрдә төрле якка кәсепкә китә иде. Бер ел казакка чыга, икенче ел Мәкәрҗәдә була, кайбер еллар Сембер губернасындагы мөселман фабрикаларына бара иде. Ләкин болар аңар алтмыш-җитмеш тәңкәдән артык бирмиләр иде. Ул шуның һич булмаса егермесен анасына йибәрми түзми, үзе шул калганы белән мәдрәсәдә яшәп чыга иде.

Моннан өч ел элек ул Төркестан кышлакларыннан берендә, җәй буе балалар укытып, ике йөзгә якын акча алып кайтты. Һәм шул акча белән ул, фатирга чыгып, бер башланган ярты юлда калмасын дип, мәдрәсәи исламиягә ирекле тыңлаучы сыйфаты белән дәвам итсә дә, күбрәк гомерен русчага бирә торган булды.

Менә шул елда аның беренче фатиры Нәфисәләр астына туры килде. Алар тиз таныштылар. Бу вакыт Нәфисә яңа чәчәк ярып килгән матур гөл иде. Давыдның беренче мәктүбенә каршы ук садә табигатьле татар кызы гына яза торган сөемле хат белән җавап биреп:

– Тик бер үк саклана күреңез... Әти бик рәхимсез... Сизсә, икебезне дә харап итәр...

“Габдрахман – ике бәхетсезнең җиңелрәге”. Бу уй Давыдны бераз җуатты да, җиңеләйтте дә. Нәфисәгә каршы үзендә хис иткән мәсьүлиятьне[1] дә киметкән шикелле булды.

Бу вакыт алар мәдрәсәгә килеп җиткәннәр иде инде.

## XXVII

Мәдрәсә – кыйблага буе белән сузылган өч катлы киң, озын таш бина. Аның өстке катында парталы, кара такталы сыйныф бүлмәләре, уртанчысында тыгызлаб тутырылган тимер караватлы ятакханәләр. Яртылый йиргә кергән түбәнге катының бер ягы ашханә, утынханә, икенче ягы озын өстәлләр белән тулы киң озын аш-чәй залы. Гадәттән тыш уларак, бүген зур бинаның өч каты да ерактан ук балкылдап тора, әйтерсең, патша туган көн: һәммә бүлмәләр шундый куәтле яктыртылганнар.

[1] *Мәсьүлиятьне* – җаваплылыкны.

Бу яктыртылу мәдрәсәнең тәмам кайнап йиткәнен сөйли иде. Егетләр, ахрысы, соңга калдык дип, ашыгыч адымнар белән алты киртләчле тышкы таш баскычтан менеп, ике катлаулы зур ишекне ачтылар. Башына сары читле фуражка, өстенә татар казакисы, аягына читек-кәвеш кигән швейцар (мәдрәсә теленчә бәүваб[1]) боларны:

– Нихәл, агайлар, исән-сау йөрисезме, – дип каршы алды да, бик җиңгел кузгалмый торган тупсаларны шыкырдата-шыкырдата, ишекне япты. Давыдлар кергәндә бөтен мәдрәсә гөж килә: базар, зур фабрик, умарта корты оясы, әйтерсең. Бары бер йиргә килгәннәр дә берсен-берсе аңлаша алмый гүләшәләр иде.

Бөтен мәдрәсә шундый шау-шу булып, тышкы ишектән туры керелә торган урта катның киң, озын коридоры исә һәммәсе ябык саргылт йөзле, хәлсез карашлы, беразы казакидән, күбе җитү чәчле, иске тужуркалы булган шәкерт җәмәгате белән шыгрым тулы иде. Болар, көчле җил белән кузгалган диңгез дулкыны кебек, коридорның бер башыннан икенче башына тулышып сыеша алмый агылалар. Өстләреннән караңгы төндә урман шаулавы хәтергә китерәчәк тавыш күтәрелә иде.

Давыд белән Нәҗиб Кәмалне күргәч, яшьләрнең бер гөруһы[2] гомуми агымыннан аерылып, боларга каршы килделәр.

– Ну, иптәшләр, ...ниләр бар?..

Шәкерт яшьләр, берсен-берсе бүлә-бүлә, бу көннәрдәге дулкыннарны, көрәшләрне, хәлфәләр белән, назыйрлар белән сүгешүләрне, дәрескә кермәүләрне, хәзер шәкертләрнең күпме нәрсәләрен төенләп бетеп чыгып китәргә хәзер торганлыгын сөйли башладылар.

Давыд:

– Мин хәзер киләм, … иптәшләр, – дип, кыйбла як таш ятакханәгә китте. Килеп ишекне ачыйм гына дисә, арттан берәү кычкырды:

– Давыд, туктаңыз әле...

Әйләнеп карасa, бөтенләй ят киемдә Булатов. Аның киеме башка булган кебек күзе, йөзе дә гадәттән тыш бер ашыгу аңлаталар иде...

– Ни бар?... Ни бар? …

– Мин монда сине эзләп килдем, миндә полиция булды, нәрсәләрне алдылар... Үзем алдалап качтым... Сине, Баязид карыйны, Раузаны бик җентекләп сорадылар... Мин, белмим, таныш түгел, дим... Син өеңдә булдыңмы?...

– Иртәдән бирле кайткан юк...

– Ну, алайса, белмисең... Синдә полиция булгандыр... Син инде анда

---

[1] *Бәүваб* – ишек сакчысы.

[2] *Гөрухы* – төркеме.

кайтмаска кирәк... Электерергә йөриләр, бугай.

– Башка юкмы...

– Юк, мин...

– Ну, иртәгә паркта кич тугызда очрашырмыз... Бар, син тизрәк сыз моннан, – дип тәнбиһ[1] ясады.

Сафа карт каты мөгамәләсе белән бөтен гаиләсен үзенә каршы куйган, һәммәсе һәр турыда аны алдарга, анардан яшеренергә мәҗбүрият күрәләр иде. Балалар апаларының егет белән йөргәнен әләкләячәк булсалар, шул бер кабарган ачу белән карт, Нәфисә һәм Зөһрә апайны гына түгел, үзләрен кыйнап ташлаячагын тәҗрибә белән беләләр, шуңар күрә әйтү кайда, үзләре аны сакларга тырышалар иде.

Зөһрә апай башта белмәмешкә салынды да: «Нәфисә матур кыз, андыйларга һәрбер егет “җаным, бәгърем, сине яратам”«, – ди башлый. Ләкин аз гына аерылсалар, егет оныта да китә. Ул шулай дип уйлады да күз йомды, ләкин мөнәсәбәтнең еллар буенча дәвамын, куәтләнгәнен күргәч, ул моннан Нәфисәгә гомерлек бәхет чыгуын тели башлады. Аның үзен Сафа картка көчләп бирделәр. Нәфисәнең дә шундый бер хәлгә төшүен бик ачык күрә, шунлыктан соңгы вакытларда бу мөнәсәбәтне ачыктан-ачык куәтли иде. Сафа бирмәсә,ябышып чыксын, качырып никах укытсын – Зөһрә монда шатланачак кына. Ата кая барсын, бер кызарыр, бер дулар да ахырдан килешер, Нәфисә бәхетле булыр...

Нәфисә Урмановның беренче хиссияте[2] иде. Бу мөнәсәбәт барган саен куәтләнеп, шул мәртәбәгә йиткән вакытлары булды ки, Нәфисә үзенең якты нуры белән егет алдында башка дөньяны тәмам каплады, юк итте. Егет Нәфисәдән башка нинди дә булса бер хәят булуын уйлый алмас минутларга килде.

Ләкин бу – минутлар иде. Заманнар үзгәрде, дөнья кайный, хәят асты өсткә килә, куәтле дулкын үзенең киң кочагы белән яшь егетләрне эченә суыра башлады. Нәфисә белән бергә корачак алгы матур гаилә хәяты каядыр китә. Егетнең рухында уянган яңа галәмнәр, йөрәгендә кузгалган яңа дәртләр үзләренең куәтле нурлары белән Нәфисәне күләгә эчендә калдыралар. Нәфисә белән бергә аның күп тырышып ирешкән инде олуг фәнни муаффәккыять белән үткән учительлек имтиханы да туктала, кайчандыр карар биреп, менә-менә килеп җитә дип, сабырсызлык белән көткән матур көннәр хыялдан югала да аннан башка идеаллар туа. Бу идеалларның юлы да, әмерләре дә башка... Инде егет гакылы, фикере белән генә түгел, бөтен табигате, йөрәге белән шуларга бирелә...

---

[1] *Тәнбиһ* – кисәтү.

[2] *Хиссияте* – хисләре, мәхәббәте.

Нәфисәгә баргалавы инде теләп түгел, шулай тиеш тапканнан, якын дустның хәтерен кырмыйча гына арадагы төпсез тирәнлеккә аның күзләрне ачу өчен генә иде... Бара торган йиреннән Давыд кинәт туктап тагы уң кулының учы белән маңлаена сукты да:

– Ни булачак? Ни булачак иде, – дип уйлады.

Чынлап та берничә секунд үзенә хуҗалыгын югалтса, аның өчен гаҗәп бер үзгәреш киләчәк: ул җә гомер буена үзенә ихтирамын югалтачак, вөҗданына, үзенә ышанган, үзен сөйгән бер мәгъсум фәрештәне газап итүнең кара күләгәсе төшәчәк, аны газаплаячак, җә өйләнергә мәҗбүр булачак, намусы шуңарга көчләячәк иде. Аннан соң хатын, гаилә, чәүкә оясы... Аннан соң үзе кебек ахмакларны тудырудан башка һөнәре юк мещаннарның бере булып китәчәк, бөтен гомергә үзенең теләген, хөрриятен, хезмәтен, идеалын шул "гаилә" дигән бер йөк юлында фида итәргә[1] мәҗбүр булачак иде... Мең шөкер ки, илаһи бер куәт аны коткарган. Үзен басып мәңгегә имгәтәчәк бер авырлыктан яки йотып алачак караңгы, төпсез тирәнлектән могҗиз куәт белән котылган адәм нәрсә хис итсә, кичәге минутларны уйлаган саен егет тә үзендә шуны хис кыла иде.

Дөрест, Нәфисә бик аяныч, … Габдрахман аның кисеп ташлаган тырнагына да тормый. Ләкин ни эшләргә? Ни эшләргә?

Габдрахман ничаклы түбән булса да, ул, һәрхәлдә, Нәфисәне көткән ике бәхетсезлекнең җиңелрәгедер. Карт шундый үзсүзле ахмак бер хайван ки, ачуы килсә, Габдрахманнан мең мәртәбә җүнсез адәмгә биреп куяр...

Булатов ишеккә китте. Давыд ятакханәгә керде. Бик артык тыгызланып тезелгән тимер караватлар белән тулы бу зур бүлмәнең почмаклары суланып каралган, тәрәзә төпләре юеш, һавасы тир исе, әчегән бәрәңге исе, адәм исе белән катыш ниндидер бер начарлык аңкына иде.

Ишекне ачып йибәрүгә сак кына тартылган музыка ишетелде. Көе поляк маршына охшый иде. Караса, иң читке караватларның берендә җыртык җурган өстендә керле тышлы кечкенә мендәргә кырыная төшеп, кара сатин күлмәктән, ябык йөзле, кипкән ак иренле, унбиш яшьләр тирәсендә булыр, бер шәкерт утыра.

Урманов аңа якын ук килде:

– Ә, Камил туган, синме... Ничек болай хөррият? Назыйр бәйләнмиме?

Камил скрипкасын янына куйды да, Урмановка карап, үзенең бала, шулай да күпне кичергән йөзе белән елмайды:

– ...Җә, кем сорый дисез алардан... Хәзер инде хәлфәләрдән курка торган заман түгел... Аша барса, мәдрәсәдән куарлар... Барыбер мин монда...

---

[1] *Фида итәргә* – корбан итәргә.

Ул сүзен тәмам итә алмады. Ничек итеп әйтергә бераз аптырады, бугай, ләкин аның ни диячәге Давыдка билгеле иде.

– Менә нәрсә, Камил туган: мин синең хакта теге Кадыйр бай баласы Йосыфҗан белән сөйләштем. Ул, үзе кебек берничә байбәтчә белән берләшеп, сиңа урысча укырлык ярдәм бирәчәк булды. Хәзердән үк хәзерләнә башлап, сиңа киләсе көзгә рус мәктәпләреннән берсенә керергә мөмкин булыр...

Камил кинәт урыныннан торды. Аның гәүдәсе җиңеләйде, турыланды, йөзе үткенләнде, күзләре бәхет яше белән ялтырап китте. Тавышы да калтырый иде:

– Ни дисез, ни дисез ..., валлаһимы, чынмы... . Мин бит җаным чыгарга җитенеп...

Бу вакыт югарыгы каттан кемдер, нигәдер бик каты шыңгырдата башлады. Давыд ишеккә борылып:

– Ах, җәмәгать, башлана... Азрактан сөйләшермез... Инде сөйләшәсе дә күп юк... Син минем сүзгә ышан да шуңа хәзерләнә башла...

Камил скрипкасын ташлады да, аяклары йиргә тияр-тимәстәй чабып, югары катка очты. Урманов ятакханәдән чыкканда әле генә шәкертләр белән тулы киң коридор бөтенләй бушаган, агымның койрыгы өстке катка менә торган кебек тимер баскычтан, буаны җимергән язгы ташкындай, бер ашкыну белән югары менмәктә иде.

Ул да монда. Өченче катның җәмгыятьләргә махсус зур залы шул берничә минут эчендә шәкерт белән шыгрым тулып өлгергән иде. Ничаклы тыгыз булса да, әле һаман кысып, берсен-берсе басып, һаман керә, тыгыла баралар иде.

Залда энә ташларлык урын калмады. Һава гаҗәп тиз тарайды, тын алырга авыр булырлык хәлгә килде. Ләкин яшьләр буны сизми, аларның йөзләре җанлана бара, гади вакыт хәлсез, үлек карашлы булган күзләрендә ут уены иде. Арттан кемдер:

– Халык җыелып булды. Мәҗлесне ачарга вакыт, – дип кычкырды.

Залның кыйбла ягында диварга терәлеп куелган, берсе артсыз ике урындык белән өстенә кәгазь, каләм салынган кечкенә өстәл бар иде. Мәҗлесне ачарга вакыт дип кычкыруга каршы, әле күптән түгел бакча капкасы төбендә сөйгәне Һаҗәрне көткән вакыт Урмановка очраган егет – Җиһангир шул өстәл яныннан аякка калыкты. Кысык, күңелсез булган гаилә хәяты, ярлы үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә кәтер кләймәсе суга[41+]. Шат, уенчак, алсу кызыл йөз белән мәдрәсәгә килгәннәр, берничә ел анда яшәсә, гәүдәсе алга ята, йөзе, күп еллар зинданда ятып, якты кояштан, иркен һавадан мәхрүмлектә көн кичергән тоткыннарны

хәтерләтәчәк рәвештә кәфендәй агарып, саргылт була, йөзеннән үлем карый, мөгамәләсендә дәртсезлек, өметсезлек, арыганлык хис ителә, бөтен торышы кызганычлыкны индереп, кыяфәтләре илән мөҗәссәм[1] кайгы, мөҗәссәм кабер тәэсире бирәләр. Мәдрәсә яшьләре тарихында беренче булган бу көннәр, бигрәк тә хәзерге сәгатьләр, аларга бик нык тәэсир иткән булмалы ки, егетләрнең эчендә, табигатьләренең яшерен йирләрендә сакланып кала алган актык куәтләре, гайрәтләре, бу вакыт аларның йөзенә, күзенә чыккан, алар башка һичбер вакыт булмаган мәртәбәдә дәртле, гайрәтле карыйлар иде.

Җиһангир һичбер вакыт чын татар шәкерте булып бетә алмады. Ул үз гаиләсенең төпчеге иде. Аның атасы Пенза ягыннан күчеп барып, Чиләбе өязендә зур базарлы бер авылда сәүдәгәр сыйфаты илә урынлашып калган Гыйбай мишәр төрек сугышында вафат булды. Ире үлгәч, башка балалары зур булгач, Нәгыймә карчык үзенең төпчеген кадерләп, иркәләп үстерде. Төпчекләр һәр гаиләдә шулайрак булалар, шунлыктан Җиһангирның тумышыннан егет вә гайрәтле табигате гаилә эчендә изелмәде. Бик юк кына нәрсә өчен бер яңагыннан сугып, икенче ягыннан ут чыгарулардан котылды. Давыдлар белән бергә яшәгән кадим мәдрәсәдә дә ул башкалар кебек изелмәде, ярлы да түгел иде. Кирәге өеннән җиткезелә. Җәй авылына кайтып хәл җыя иде.

Ул уку белән дә күп ватылмый иде. Аның гыйззәте нәфсе[2] зур. Ул һәр йирдә беренчелекне тели. Ләкин зирәклеге бар, аз арада хәлфәгә җавап бирерлек хәзерли дә аннан соң, мәдрәсә буена шаярып, туры килсә, сугышып йөререгә ярата. Озын төннәрдә шәрехләр[3], хашияләр[4] актару аңар бөтенләй ят иде. Давыд Урманов мәдрәсәдә чагында актык акчасына Бохарадан “Шәрхе мәвакыйф”лар алдыра. Һиндтән “Мәүләви хөсни”ләр китертә, озын төннәрдә таңгача “Сөлләм казый” белән “Шәмсия Габделхәким”нәрен моталәга кыйлып[5] чыга[42+], гомумән, ул алган мәсьәләсенең төбенә төшмәсә, ашыннан, уйкысыннан[6] аерыла иде. Әмма Җиһангир бер вакытта да алай булмады. Аңарда табигать егет, җиңел, гамәли һәм кайнаучан иде. Ул монда килгәч тә сабакны күбрәк биш ярымнан ким алу хурлык булганлык өчен укый, күбрәк вакытын җәмгыятьләргә, талашларга, идарә белән көрәшләргә бирә иде, менә шул рәвешле киченү аны башкалар шикелле иртә картаюдан, кәфен йөзле, хәлсез карашлы булудан, вакытсыз бөкрәюдән коткарды. Ул

[1] *Мөҗәссәм* – зур.
[2] *Гыйззәте нәфсе* – үз-үзен яратуы.
[3] *Шәрехләр* – берәр китапның авыр урыннарын ачыклап аңлатулар.
[4] *Хашияләр* – бер китапның эчтәлеген аңлатучы икенче бер китаплар.
[5] *Моталәга кыйлып* – укып, өйрәнеп.
[6] *Уйкысыннан* – йокысыннан.

бөтен шәкерт эчендә иң җиңел, иң егет, шат, гаюр[1] табигатьләрдән санала. Җәмгыятьләрдә һәрвакыт иң сул якта[43+], һәрвакыт идарәне сүгү ягында була, үзенең ялкынлы нотыклары белән кайбер вакыт бөтен зурларга каршы берүзе сөйләгәне хәлдә, түбәннәр күпчелеге белән мәсьәләне үзе дигәнчә хәл кылдыргалый иде. Аның гыйльми куәтенең чамалы булуы, җәмгыятьләрдә күп вакыт җиңүе өчен, өлкәннәр, бигрәк тә өченче, дүртенче галиләр[2] аңар, мыек астыннан көлеп, малай дип карарга тырышалар, ләкин түбән як, "демократия" бөтенләй аның тәэсирендә була иде. Мәдрәсә яшьләре күптән кайнап килсәләр дә, вакыйгаларның бу рәвешкә керүенең иң зур сәбәпләреннән бере, һәм әле хәзер шыңгырдатып җәмгыятькә чакыручы да ул иде.

Ул, гадәттә, матур киенергә бик яратса да, шәкерт эчендә демократ күренергә тырыша иде. Әле җилкәсенә төшеп торган зур чәче өстенә кечкенә кара кәләпүш кигән, каралы күлмәк эченнән бик аз гына ак яка күренеп тора, тулы канлы, тулы хәятлы карасу йөзе бик аз гына агарынган, күзләре гайрәт белән ялтырыйлар, тавышы бераз калтырый иде. Ул аякка басуга, берничә яктан кул чаптылар. Бу, ахры, урынсыз күренде, башкалар кушылмады, ул, урындыкның артына кулы белән тотынган хәлдә, тавышын мөмкин кадәр сабыр чыгарырга, кызмаска тырышып, сүзендә дәвам итте:

– Иптәшләр..., сез беләсез, моннан бер атна элек мәдрәсәи исламиянең йөз илле шәкерте, имза куеп, берничә төрле ислах хакында идарәгә гариза бирелде. Сораган нәрсәләремез, иптәшләр, егерменче гасыр балалары өчен иң зарур ислахаттән гыйбарәт иде: русчаның мөкәммәл[3] укытылуы, яңа фәннәрнең арттырылуы, схоластиканың бөтенләй себерелеп түгелүе, ике бозауга кибәк аерырга да кулыннан килмәгән кайбер утын мөгаллимнәрнең мәдрәсәдән чыгарылуы, алар урынына моктәдир[4] мөгаллимнәр алынуы, һәр атнада хөр җәмгыятьләр ясалуы, истибдадның[5] бөтенләй бетерелүе, идарәгә шәкертләр тарафыннан кертеләчәк вәкилләрнең арттырылуы... Тагын шундый мөһим нәрсәләр иде. Гаризада бер атна эчендә җавап бирелсен дигән, шул мөддәттә җавап булмаса, дәрес ташлаячагымыз аңлатылган иде. Бүген мөддәт тула. Безгә җавап юк. Җавап урынында милләтнең гайре каһарманнарын мыскыл итәчәк бер эш кылырга хәзерләнәләр, без бер атна эчендә җавап сорадык ... Без ислах көтәмез. Гыйлемгә сусаган, бөтен гомерен милләт юлына корбанга хәзер булган шәкертләр ислах көтә. Ә алар, ул

---

[1] *Гаюр* – булдыклы; кыю.
[2] *Өченче, дүртенче галиләр* – югары сыйныф укучылары.
[3] *Мөкәммәл* – тулы.
[4] *Моктәдир* – көчле, сәләтле.
[5] *Истибдадның* – деспотизмның.

мөстәбидләр[1], ул буржуалар әнә ике стена ашасында кәнсәләриягә[2] җыелганнар, ислах сораудан, шәкерт файдасына көрәшүдән башка гөнаһысы юк унике егетне куарга хөкем чыгаралар. Без ислах көтәмез... Шәкерт гыйлемгә сусаган. Шул юлда ул җаны-тәне белән тырыша... Ә алар, ул буржуалар, безне мыскыл итә, гүя әйтәләр ки, ә, алаймы әле, сез баш күтәрергә, безгә каршы барырга уйлыйсыз икән, менә танытыйк әле без сезгә кирәкләреңезне, дип, ике йөз шәкертне мәсхәрә кылалар, мәдрәсәдән куарга хәзерләнәләр. Ул уникенең гөнаһысы ни? Алар, шәкерт файдасын һимая итеп[3], идарәнең бернәрсә дә аңламаган җуан корсак Кадыйр байларның, туңбаш хәлфәләренең истибдадына каршы көрәшкәннәр.

Иптәшләр, сынашу вакыты килде... Алар безне басмакчы, измәкче. Дөнья көрәш белән тора, көрәшүдә табарсың үз хакыңны, диләр... Бездә җан булса, бездә аң булса, татар милләтенең караңгы киләчәген яктыртырга хезмәт кылу дәрте булса, бездә үземезне адәм дип белерлек, үземезне издермәслек, үземезне җуан корсак Кадыйр байлар белән үзенең корсагына хезмәттән башканы белми торган галә надыр[4] мөстәбидләрдән таптатмасак, мыскыл иттермәслек намус вә куәт булса, без, иптәшләр, берләшергә, бер-беребезгә кул бирешергә тиешле. Менә бу җәмгыять шул турыда булачак... Мәсьәлә мөһим. Иптәшләр, берләшик, көрәшик, көрәшүдә табарсың син үз хаккыңны.

Җиһангир дәвам итәчәк иде, бөтен залны шау китереп, төрле яктан кул чаптылар. Әллә ничә йирдән:

– Яшәсен татар шәкерте, яшәсен көрәшче милләт каһарманнары, – дип кычкыра, тавышлана башладылар.

Хатибның теләге булды, ахры, ул яңадан сүз алмады.

Мәҗлес шулай шаулаша, берничә яктан берничә егет аякка басып, нидер сөйләргә телиләр, башкаларны туктату өчен, иптәшләр, сабыр итеңез әле, бер сүзем бар дип кычкырыналар, монардан тагы тик тавыш кына арта, шау-шу гына көчәя иде. Шулвакыт Урманов һәрвакыт зур тәэсир күрсәтә торган бер рәвеш белән:

– Иптәшләр, болай мөмкин түгел, мәҗлескә рәис сайларга кирәк, – диде.

Мәҗлес тына башлады. Төрле яктан:

– Рәис, рәис, – дип кычкырдылар.

Бик күп тавыш:

---

[1] *Мөстәбидләр* – изүче, деспотлар.
[2] *Дөресе*: канцеляриягә.
[3] *Һимая итеп* – бу урында “кулланып” мәгънәсендә.
[4] *Галә надыр* – бик сирәк очрый торган.

– Давыд Урманов, Давыд Урманов, Давыд Урманов, – диделәр.

Давыд рәис булырга теләмәгәч, әллә ничә яктан берьюлы рәисләр таба башладылар:

– Габдулла, Габдулла...

– Юк, ул юаш, юк, ул булдыра алмый...

– Юк, Хәбибулла булсын...

– Зиннәтулла булсын...

– Вәлиулла...

– Габдрахман...

– Хәлилрахман...

– Садыйк...

– Фәхри... , – белмим тагы кемнәр.

Урманов тагы күтәрелде:

– Нигъмәт казый булсын.

Сакаллы карт кыяфәтле берничә шәкерт:

– Ул кирәкми, Нәҗиб Кәмал булсын, – дип кычкырышсалар да, күпчелек:

– Нигъмәт казый, Нигъмәт казый, Нигъмәт казый, – дип эләктереп алды.

Җиһангирга якын бер йирдән озын буйлы, таза гәүдәле, киң җилкәле, кара-саргылт вә бик аз гына шадралы, киң йөзле, мыеклы, утыз яшьләрендә булыр, ләкин изелмәгән, яхшы, нык сакланган берәү күтәрелде.

Бу – Нигъмәт казый дигәннәре иде.

Гали дүртенче сыйныфның бердәнбер ихтилялчылар яклысы булган бу адәм, кадим мәдрәсәдә чагында, дүрт-биш ел усал казый булып торган, шул сәбәпле әле дә аның исеменә “казый” дип кушалар иде. Мәдрәсәнең соңгы сыйныф шәкертләре һәммәсе диярлек хәлфәләр яклы була, көрәшләргә каршы бара иде. Нигъмәт казый алар арасында бердәнбер булганга, аңардан: “Ат азгыны тайга иярә”, – дип көләләр иде. Ләкин ул моңар илтифат итми, шәрикләре[1], гомумән, картраклары арасында күргән дошманлык бәрабәренә игъдади[2] беренче вә икенче галиләр арасында ялкынлы дустлык таба, һәм үзе дә бөтен йөрәге белән шунда, шулар арасына тартыла иде.

Акрын гына кузгалып, рәискә махсус урынга килде дә, калын, куәтле тавыш белән мәҗлеснең әһәмияте хакында бер-ике сүз әйтеп, үзенә секретарь сайлауны гарыз итте[3].

Тагы тавыш күтәрелде, тагы бер яктан Нәҗиб Кәмал, Җиһангир дип,

[1] *Шәрикләре* – иптәшләре.
[2] *Игъдади* – югары белем алуга әзерлек сыйныфлары.
[3] *Гарыз итте* – теләде.

икенче яктан Габдулла, Фәйзулла, Хәбибулла дип кычкырыша башладылар. Нәҗиб Кәмал белән Җиһангир теләмәделәр. Шуннан соң, юри, көлке санапмы, якында утырган Вәли башкортны берничәсе телгә алу белән, бөтен залны "ярый", "ярый" дип тавыш күтәрде. Әүвәл аптырады, каушады, тагы көчли башлагач: "Мин булдыра алмам бит", – диде. Ләкин аңар карамыйча, төрткәләп урындыкка утырттылар да, кәгазьне алдына куеп, кулына каләм тоттырдылар.

Рәис минутка якын туктамый шыңгырдатып, залны тәмам тындыргач, акрын кузгалып, аягүрә басты да шул куәтле, калын тавышы белән сүз башлады:

– Иптәшләр, замандашлар... Мин һәммәңездән картмын. Бәлки, шуның өчендер, бу көннәрнең, бу дулкыннарның әһәмиятен һичбер шәкерт минем кадәрле зур шатлык белән каршы ала алмыйдыр, дип уйларга батырлык итәм. Яшьләргә, кадим мәдрәсәдәге хәят белән таныш булмаганнарга, бу хәлләр, бәлки, гадидер. Ләкин безгә, безнең кебек егерме бишкәчә схолатистика мотагаләсендә иске мәдрәсәнең тар, тынчу, кыйдыргыч хәятында яшәгәннәргә бу көннәр шундый ят, шундый көтелмәгән хәлләр ки, вакыт-вакыт мин "бу төш түгелме" дигән халәткә килдем. Мин – кадим мәдрәсәнең атаклы моназирларыннанмын[1] – безнең заманда татар шәкерте берсе-берсенең итен чәйнәү, моназарә дип, эт урынына сүгешүдән башканы белми иде. Ләкин заман һәрнәрсәдән көчле, имеш ки, мәдрәсә ничаклы качса, ничаклы үзенең ишекләрен бикләп, тәрәзәләрен томалап, һичбер яңа тавышны ишетергә теләмәсә дә, заман җиңде, без менә бүгенге кебек мәдрәсә яшьләре хәяты тарихында мисле[2] булмаган бер вакытка килдек. Без, иптәшләр, кадерен белик, зур бәхет, гаҗәп зур алмашыну... Бер мин түгел, мондагы иптәшләрнең күбе кадим мәдрәсәдән моназир, мокаррир[3], дәгъвалы хәлфә булып килгәннәр. Ләкин заман безне юды, пакьләде, без әүвәлге дәһшәтләрдән арындык. Бүгенге вакыйга моның ачык шаһиты: безнең унике иптәшемезне куарга уйлыйлар. Иске мәдрәсәдә булса, моңа кызык итеп карарлар, шул "хурлыкка" төшкән иптәшләреннән мыскыл итеп көләрләр, эчтән шатланырлар иде. Ләкин хәзерге татар шәкерте ул – инсан, ул – арыслан, ул – милләт каһарманы – кайда халык, кайда инсаният? Ул буны аера!! Ул белә ки, куылачак иптәшләр кемнәр? Алар нигә куыла, алар нинди гөнаһ кылган? Безнең күз алдымызда ки, аларның шәкерт файдасы өчен идарә белән көрәшүдән баша һичбер гөнаһлары юк. Шәкертне күрә дә үзенең актык көче белән гөнаһсыз куылачак иптәшләрен яклый... Мин үзем кадим

[1] *Моназир* – берәр проблеманы аңлатканда дәлилләр китерепе бәхәсләшүче.
[2] *Мисле* – охшашы.
[3] *Мокаррир* – телдән сөйләп аңлатучы, бәян итүче.

мәдрәсәдә дүрт-биш ел казый булдым. Гадил[1], ләкин рәхимсезсең, диләр иде. Минем тәклифем[2] белән мәдрәсәдән байтак егетләр куылды. Хәзер бу исемә төшсә, миемә кан йөгерә, күземне кан баса, ул иптәшләргә барып аякларына ятасым, гафу үтенәсем килә. Ләкин ул инде үткән... Миннән генә түгел, бөтен татардан үткән... Ул кайтмаячак... Хәзерге шәкерт, хәзерге мәдрәсә яшьләре – меңнәрчә чакрым авыл вәхшәтеннән узган... Без иптәш, димез. Шуны гамәлгә куямыз. Һәм куярга тиешлемез. Адәмлегемез, бердән, буны тели. Менә бу көнге вакыйга безнең бу бөек хисне аңлаганлыгымызны күрсәтә...

"Иптәшлек" – бу бөек сүз. Без моны аңладык. Моның белән тәбрик итәм. Коры "иптәшлек" түгел, милләт юлында, мәдрәсә тәрәккыйсе юлында, фикердә, гали мәсләктә[3] иптәшлек – бу тагы да бөегрәк – без шуны да аңладык. Моның белән безне тарих тәбрик итәр. Инде киләм асыл максатка. Без ислах сорадык. Җавап урынында ислах дулкыннарының башында йөрүчеләрне мәдрәсәдән куарга җыелдылар. Ачыграк аңлашылсын өчен, мин бу вакыйганың тарихын да сөйләп үтәргә тиеш табам.

Вакыйганың төпке һәм иң тирән сәбәбе – татар шәкертенең үз хәленнән риза булмавында, аның якты көнгә чыгарга теләвендә, шул юлда үзенә каршы килгән кара куәтләр белән көрәшүдәндер...

Сез беләсез, мәдрәсәдә исемен телгә алу күпләр тарафыннан мәкрух[4] күренгән бер мөстәбид мөгаллим – Кәрим Гайфи бар.

Истанбулда Габделхәмиднең истибдады астында тәрбияләнеп кайткан[44+] шул диңгез арты мәхлугы белән безнең гайрәтле фидакяр иптәшләребездән Җиһангир әфәнде арасында бер көн юктан гына сүз чыга. Кәрим Гайфинең урынсыз бәйләнүенә каршы Җиһангир иптәш:

– Хәлфәкәй, сез үзеңезнең вазыйфаңыздан чыкмаска кирәк иде. Сез – мөгаллим, вазыйфаңыз – укытмак. Әмма коридорда берәүнең нидер көйләп йөрүен тыю – сезнең эш түгел. Тыярга кирәк булса, аны назыйр карар, – ди.

Җиһангир иптәшнең бу хаклы сүзен "хәлфәкәй" күтәрми, кызып, гасабиланып китә дә шәэне[5] булмаган сүзләр белән: "Мин сине мәдрәсәдән кудыртырмын, ахмак нәрсә, – дип акыра башлый. Җиһангир иптәш кешегә бурычлы булып калырга яратмый торган егетләрдәндер, ул хәлфәнең куркытуына каршы:

– Пожалуста, юкка кызма... Тапкан бер сүз, имеш, мәдрәсәдән куам: үзең – ике тиен, мәдрәсәң – ике тиен, – ди. Сүз зурая, китә талаш,

[1] *Гадил* – турылыклы, гадел.
[2] *Тәклифем* – кушуым, боеруым.
[3] *Гали мәсләктә* – бөек юлыбызда, дөньяга карашыбызда.
[4] *Мәкрух* – бу урында: "начар күрелгән", "читкә кагылган".
[5] *Шәэне* – әһәмияте, дәрәҗәсе.

кычкырыш...

Җиһангир ягыннан башка иптәшләр дә сөйли башлыйлар.

Хәлфәгә сөйләргә бирмиләр... Сызгыралар, йөзенә көләләр. Хәлфә ачуыннан тиресенә сыеша алмастай бүртә дә, үзенең кимия[1] бүлмәсенә кереп китә. Бүлмәнең ачкычын ишекнең тышкы ягында элгән көйгә калдыра. Берничә сәгатьтән соң чыгарга дип ишекне этәрсә, ни күрсен – тышкы яктан бикләгәннәр, тишеккә карый – ачкычы да юк. Дөбердәтә башлый. Тышкы якта шәкерт җыела. Кайсылары көлә, кайсылары, ачарга теләсә дә, ачкыч тапмый.

Гөнаһ шомлыкка каршы, швейцар да каядыр киткән. Хәлфә бик озак дөбердәтеп газапланып арып беткәч, ул кайта, кулындагы һәммә ачкычны яратып карый, юк, берсе дә килми.

Ул арада инде берничә сәгать гомер дә үтә.

Ачкыч ярата алмыйлар. Ниһаять, хәлфә:

– Инде түзә алмыйм... Монда дару исе харап... Һава бетте... Үләм, – ди башлагач, ишекнең тупсаларын җимереп ачалар.

Хәлфәне ямщик белән өенә озаталар.

Ул икенче көнне дәрескә килми, идарәгә, бөтен вакыйгага ялган төс биреп, язу йибәрә.

– Җиһангир мәдрәсәдән куылсын, – ди.

Аны идарәгә чакырып сорыйлар. Ул сүгешкәнен инкяр кыла, әмма кимияханәне бикләп ачкычны яшерүче мин түгел, ди.

Идарә үзенең карарын икенче мәҗлескә калдыра.

Шул көн кич мәдрәсә эченә җилем басма белән таратылган “Без”, “Яшен”, “Чүкеч”, “Сөңге”[45+] гәзитәләрендә һәммә хәлфәләрнең, бигрәк тә Кәрим Гайфинең бөтен кара якларын ачы гыйбарәләр белән ачып биргән мәкаләләр була. Башлана тикшерү: кем язган, кем баскан?

Нәтиҗәдә, фатирда торып шундый нәрсәләрне бастырган өчен – ике, шул мәкаләләрне язган өчен – дүрт, идарәдә хөкем вакытында шәкерт яклап хәлфәләрне сүккән, ахырдан протест рәвешендә идарә мәҗлесеннән чыгып китеп, үзен сайлаучы сыйныфка вакыйганы ачкан, соңра вәкаләтне ташлаган, белмим, тагы ниләр кылган өчен – дүрт, барлыгы ун, Җиһангир белән унбер, так булмасын дип, тагы нинди гөнаһ өчендер, берәүне кушалар да барлыгы унике иптәшне куарга карар бирәләр.

Сез ислах көтәсез... Бүген гаризада әйтелгән мөддәт тула. Әнә бездән ике стена аша кәнсәләриядә җыелганнар, күптәнге карарларын рәсми ясау

[1] *Кимия* – химия.

өчен, “идарәи дахилия вә харижия”[1] берләшеп киңәш итә. Анда шәкерт вәкилләрен кертмәделәр. Тик хәлфәләр дә байлар.

Бу хәбәр сатлыкҗаннар аркылы берничә көн элек безгә мәгълүм булды. Шуны ишетүгә, алты чын әгъза, дүрт наибтән[2] гыйбарәт “Химая комитеты”ның[46+] төн буена ашыгыч җыелышы булды һәм, шул утырышның карары буенча, гали вә игъдадиларның һәрбер сыйныфтан ике шәкерт чакырылып, нинди юл белән каршы тору хакында фикерләре соралды. Нәтиҗәдә, берничә маддәгә карар бирелеп, йөз илле шәкерттән “Ислах өчен көрәшүдән башка гөнаһысы булмаган иптәшләрне кудыртмау юлында актык көчемә, актык каныма кадәрле тырышачакмын” дип имза алынды.

Бик яшьләр җылыйлар, сез чыксаңыз, без монда ни эшләрбез, калмыйбыз сездән, диләр. Шулай да алардан имза алмадык. Картлар эчендә исемнәрен атамасаң да кемнәр идеге мәгълүм булган биш-ун бәндә бар. Алар тиздән мәдрәсә бетерергә дә шунда мөгаллим булып калырга, һич булмаса, идарә аркылы яхшы урын табарга уйлый... Һәрхәлдә алар үзләренең корсакларын милләт кайгысыннан алда тота. Менә шул биш-ун “корсак коллары”ннан башкалар комитетның карарын алкыш белән каршы алды, күпләр имза куйганда, җаным фида, дип яздылар.

Менә бу җәмгыять, шул хакта тагы ныграк уйлашу өчен, үзебезнең курыкмавыбызны, инде качынып-посынып сөйләшергә теләмәвебезне күрсәтү өчен иде.

Минем хәзергә әйтәчәгем шул кадәр... Сүзе бар кеше язылсын...

Рәиснең хотбәсе бетәр-бетмәс, зал күтәреп кул чаба башладылар. Бу озакка барды, рәис кат-кат шыңгырдату аркасында, бик көчлек илә генә мәҗлесне яңадан тындырды.

## XXVIII

Халык тынгач, рәис, вакыт аз, ни теләгәннәр бездә билгеле, шуңа күрә кыскарак сөйлик, дип үтенде:

– Секретарь, нәүбәт кемгә?

– Сөләйман Сәйфуллин!

Иң арттан урта буйлы, җитү чәчле, иске тужуркалы, ябык саргылт йөзле бер егет калыкты да, янындагы тәрәзәнең төбенә басып, бик кинәт, бик кискен һәм кызганыч катыш ачулы тавыш белән:

– Иптәшләр, начар соң безнең хәлләр, – дип кычкырып йибәрде.

Ул кызу, гасаби һәм баштанаяк ләгънәт һәм каһәр белән тулган

---

[1] *Идарәи дахилия вә харижия* – тышкы һәм эчке идарә.

[2] *Наибтән* – урынбасардан.

ялкынлы нотыгында үзенең туганнан бирле рәхәт көн күрмәвен, җиде яшеннән алып татар мәдрәсәсендә изелүен, гыйлем алыйм, адәм булыйм, милләткә хезмәт итим дип, кышын укырга акча табу өчен, җәйләрдә казак сахраларында бет чәйнәп, җирәнеп гомер итүләрен, Төркестан кышлакларында[1] бер яктан мөтәгассыйб[2] караңгы сартлар[47+] белән, икенче яктан ул йиргә татарны кертми торган рус хөкүмәте адәмнәре белән көрәшеп нинди җәфаларга төшкәнен, эссе Дагстан чүлләрендә вәхши кара нугайлар[48+] эчендә нинди газаплар күргәнен бер-бер санап чыкты, соңра мәдрәсә хәятына килеп, мондагы тыгызлыкларны, саусызлыкларны, шуңардан йөзләре саргаеп, күкрәкләре череп, вакытсыз кабергә баруларын, идарәнең истибдадын[3], гомумән, нинди авырлыкларда яшәүләрен ачы вә караңгы картиналар белән тасвир итте, итте дә, бугазына килеп тыгылган күз яшен тыярга такате беткән, кичергән авырлыклары шул сүзләре белән бергә күкрәгенә тулып хәлен бетергән адәм рәвешенә килеп, күзен кан баскан, буылган бер халәттә:

– Инде монда да изәләр... Ах фәләк[4], ашыйсың башларны... Әйтегез, кайчангача түзәчәкмез, иптәшләр!! – дип, үз тавышына үзе капланды, сүзен артык дәвам иттерә алмады, һәм теләсә дә сөйләргә мөмкин булмаячак иде, аның сүзе халыкка, бигрәк тә яшьрәкләргә шундый тәэсир бирде ки, күпләрнең күзе яшьләнеп, Сөләйман артыннан:

– Шулай...

– Бик дөрест... Барымыз да шулай изеләмез... – дип кычкырып, баягы хатибларның һичберенә булмаган дәрәҗәдә куәтле, озак, бик озак кул чаптылар.

Сөләйман Сәйфуллин артыннан тагы берничә хатиб торыб, хәлфәләрне мөстәбидләр, канэчкечләр, залимнәр, дип сүгеп: “Җитәр, иптәшләр, күп изелдек, инде уянырга вакыт, көрәшергә вакыт, көрәшүдә табарсың үз хакыңны, һәрбер сыйныф халык үз кирәген көрәшеп кенә ала, без дә “алма пеш, авызыма төш” дип ятсак, һичнәрсә булмас, татар шәкерте күтәрел, ислах флагы белән көрәшкә чык, издермә үзеңне!” – дип, кызу, ялкынллы нотыклар сөйләгәннән соң, секретарь Нәҗиб Кәмал исемен кычкырды.

Кыска итеп кырылган чәче өстеннән һәйбәт кара кәләпүш, озын кара казаки астыннан бик аз гына чыгып торган ак яка, йөзендәге табигый мәһабәт вә бөтен торышында сизелгән бик аз гына кибарлык[5], ягымлы тавыш –

---

[1] *Төркестан кышлакларында* – Урта Азия авылларында.
[2] *Мөтәгассыйб* – берәр эшкә нык бирелгән кеше, фанат; кире.
[3] *Истибдадын* – һичбер канунга буйсынмый, үзенчә генә хөкем итүен.
[4] *Фәләк* – язмыш, тәкъдир.
[5] *Кибарлык* – горурлык; аристократлык.

гомумән, аның бөтен килеше яхшы тәэсир бирделәр, ул аякка басып:

– Гасырлар буенча җыелып килгән җыен кабәхәт, вәхшәт вә пычраклар эчендә газап чиккән, шунда тончыгып барган татар шәкерте... – дип башлаган әүвәлге сүзләре белән ул шәкертнең йөрәгенә җылы төшкәндәй булды, аны бик үтә дикъкать белән тыңлый башладылар. Ләкин бу дикъкать күпкә бармады, ул мөкаддимәдән[1] үтеп асыл теләгең әйтә башлауга, төрле яктан кузгалырга, тамак кырырга тотындылар.

Берничә почмактан:

– Кирәк түгел, сөйләмәсен, – дип үк кычкыручылар, “долой, долой” диючеләр дә булды.

Бу протестлар көчәеп, хатибның ни сөйләгәне ишетелмәс хәлгә килде, тик рәис көчлек белән туктаткач кына, Нәҗиб Кәмалга дәвам итәргә мөмкин булды:

– Иптәшләр, сез мине яңлыш аңлыйсыз... Мин татар шәкерте тик торсын димим. Татар мәдрәсәсе яхшы, анда ислах-фәлән кирәкми, дигән фикер дә моннан меңәр чакрым җыракта калган. Шәкерт авыр яши, ул, хакыйкатән[2], кызганыч... Татар мәдрәсәсе бер эшкә ярамый, монда җүнле адәм үзен сасы сазлыкка килеп кергән кебек хис кыла... Мин татар булуымны, бигрәк тә мәдрәсәгә бирелүемне үземнең иң зур бәхетсезлегем саныйм – табигать күп нәрсә бирде, күп аң, күп кабилиять[3] бирде, ләкин һәммәсен мәдрәсә алды, һәммәсе бердән ярлылыкта, икенчедән, мәдрәсәдә череделәр..

Шулай була торып та, мин татар шәкертенең идарәгә каршы “Көрәшүдә табарсың син үз хакыңны” дигән сүзләр кулланууын җә көлке, җә аңсызлык табам... Берничә йирдән сызгырдылар, “долой” кычкырдылар, ләкин Нәҗиб Кәмал аңар карамый, сүзен дәвам иттерде:

– Монда хәлфәләрне залимнәр, канэчкечләр, мөстәбидләр, дип сүгәләр. Мин моны һичбер төрле аңлый алмыйм... Кем залим, шул бичара Габдәһләр, Сәйфиләрме? Дөрест, алар наданнар, кызганычлар, тәрбия күрмәгәннәр, фән белмиләр, ләкин залим түгелләр. Залим, мөстәбид булу өчен, куәт кирәк, ә аларда куәт кайда? Алар залим түгел, алар бичаралар, кызганычлар... Без торабыз да шул бичараларга каршы, имеш, ислах флагы күтәр дә көрәшкә чык, дип кычкырабыз һәм чыгабыз. Бу – җә көлке, җә аңсызлык...

Мәдрәсә начар... Мәдрәсә хәяты безнең тәбигатьләремезне эштән чыгара, хисемезне сүндерә, куәтемезне бетерә, без иске чүпрәк булып калабыз, ләкин боның шифасы хәлфәләр белән көрәшеп маташуда түгел,

---

[1] *Мөкаддимәдән* – керештән, сүз башыннан.
[2] *Хакыйкатән* – чыннан да.
[3] *Кабилиять* – сәләтлелек.

бәлки туп-туры мәдрәсәдән чыгып кулларыннан килгән егетләрнең башка бер юлга керүендәдер... Шуңар күрә мин бу көрәшләрне, бу сүгешләрне балалык, сабыйлык дим һәм...

Тагы бик зур шау-шу күтәрелде, инде бусы бөтен мәҗлес тарафыннан иде. “Долой”лар, “кирәкми”ләр белән зал гөр килә башлады. Нәҗиб Кәмал артык исе китмәгән адәм сыйфаты белән кул селекте.

Аңар җәмгыятьләрнең мондый мөнәсәбәте ят түгел, иптәшләрнең бу сызгырулары да беренче түгел иде. Үзенең үтә нәзек аңы, рухындагы галиҗәнаб вә табигый фазыйләте илә балкып, күңелләрне ихтыярсыз үзенә тарткан мәгънәле карашы, гакыллы йөзе, югарылар һәм түбәннәр белән үзен бераз югары, ләкин табигый вә мөлаем тота белүе, һәр турыда шөбһәсез булган намусы, гыйлеме вә фикри истигъдадының мөстәсна дәрәҗәсендә булуы[1] кебек яхшы сыйфатлары илә һәркайда ирексез яратылган, илтифатка алынган[2], сөелгән. Мәдрәсә яшьләренең гыйльми вә фикри мәҗлесләрендә үзенең су кебек табигый аккан мәгънәле, җитди нотыклары илә шәкерт эчендә дә бик яхшы урын тоткан Нәҗиб Кәмал менә бу көнге шикелле баштанаяк идарә сүгү, хәлфәләр сүгү белән тулган җәмгыятьләрдә һичбер вакыт үзен тыңлата алмый, башка вакытта кул чапкан, Франция революциясе хакындагы бер нотыгы өчен кулларга күтәргән иптәшләре мондый мәҗлесләрдә аңар сызгыра, “долой” кычкыра башлыйлар иде.

Җәмгыять тынгач, рәис:

– Сүзеңезне бетереңез, – дисә дә, Нәҗиб Кәмал, аңламаячакларын ачык күргәнгә:

– Юк, сөйләмим инде, – диде.

Аның артыннан тагы берничә егет кузгалып, милләт артталыгын, аны тәрәккый иттерү өчен гыйлем кирәклеген, гыйлем исә мәдрәсәләрдә булганлыгын, шулай булгач, милләт тәрәккый итсен дисәк, мәдрәсәләрне ислахтан башка чара юклыгын, шуңа күрә дә бөтен татар шәкертләре берләшеп көрәшү тиешлеген, үзләренең наданлыгын, изелүен, бернәрсә белмәүләрен, идарәнең изүен, истибдадын төрле сүзләрдән тәкрар иткән соң, секретарь:

– Давыд Урманов! – дип кычкырды.

Ул президиумга якын иде, исеме чыгуга, акрын гына кузгалды. Аның буе бүген гадәттәгедән гүя бераз озынайганмы, турыланганмы кебек күренде, күз карашы җиддият илә[3] ялтырый, гадәттә дә якты киң маңлае бу вакыт

---

[1] *Фикри истигъдадының мөстәсна дәрәҗәсендә булуы* – фикер зирәклегенең аерым дәрәҗәдә булуы.

[2] *Илтифатка алынган* – хөрмәт ителгән.

[3] *Җиддият илә* – җитдилек белән.

тагын да нурлырак шикелле тоела иде. Аның тавышы салмак, ләкин куәт белән чыга иде:

– Иптәшләр, монда сүз бик күбәеп китте. Бу – беренче җәмгыять түгел. Татар шәкерте үзенең хәлен күптән аңлап җиткән. Шуңар күрә озын нотыкларга да хаҗәт юк, бер-ике сүз белән бетерергә тиеш иде.

Мәсьәлә шунда гына... Шәкертләр моннан бер атна элек, үзләре кирәк һәм мөмкин дип тапкан берничә төрле ислах сорап гариза бирделәр. Шуңар җавап урынында идарә унике иптәшне кумакчы... Шәкерт шул ике вакыйгага ничек карарга тиешле? Менә мәсьәләнең төбе-тамыры шунда гына! Шәкертләр ислах теләвендә сабитмы?[1] Шәкертләр үзләренең гомуми теләкләре юлында көрәшүдән башка гөнаһысы булмаган унике иптәшләрен мәдрәсәдән куып чыгарганны читтән карап калырга тиешме? Бу аларның җәмгыятенә сыямы? Егерменче гасырның татар шәкерте моны үзенә хурлык, намуссызлык санамыймы? Әгәр дә аңарда сәбат[2] булса, әгәр дә ул алган юлында көрәшергә теләсә, мәсьәлә үзеннән-үзе бетә; сүз дә кирәкми, нотык та кирәкми!! Шәкерт ни дияр, мин ишетергә теләр идем.

Урманов сүзен әйтеп бетерә алмады, гүя менә-менә тулып, ташып, ут кабынып килгән җәһәннәм машинасы искиткеч бер куәт белән шартлап китте: шул дәрәҗәдә көчле алкыш, тавыш, шау-шу күтәрелде, мәҗлес бөтенләй кайнап, тәртип бетте. Шәкертләр дулаша, үзара нидер сөйләшә, кычкырыша башладылар. Рәис ничаклы тырышса да, тәртипне торгыза алмады, кайдандыр беренче сада, икенче почмактан икенче сада тавышлары ишетелде[49+]. Ул ара да булмый, үз бабында атаклы булган җырчы Сахиб уртадан поляк маршы көенә шул дулкыннарның илһамы белән мәдрәсә шагыйре тарафыннан иҗат кылынган яңа “Чыгабыз”ны җырлап күтәреп йибәрде[50+], ул әүвәлге бер-ике сүзен әйтеп бетә алмады, бөтен залны:

– Чыгабыз... Кузгалыңыз... Мәзлум рафиклар[3], атлаңыз!

Чыгабыз... Кузгалыңыз... Мәзлум рафиклар, атлаңыз! – дип яңгыратып алдылар да, куәтле җил белән ишелгән диңгез дулкыны кебек моңарчы утырган залга сыя алмыйча, киң коридорга чыктылар, анда да шул җырны поляк маршы көе белән дәвам иттереп, аргы башка, хәзерге вакытта байлар, хәлфә вә мөдәррисләр утырган кәнсәләриягә таба киттеләр.

Кәнсәләрия ишеге эчтән ябык иде. Кемдер тартып караса ачылмады, ләкин шәкерт таралмады, агымның мәркәзе шул ишекнең турына туктап, баягыдан да яман тавыш белән көйләп йибәрделәр:

– Аһ, бу татар милләте... бер якты көн күрмәсмени?!

---

[1] *Сабитмы* – үз уенда нык торучанмы.
[2] *Сәбат* – фикердә, эштә нык торучанлык.
[3] *Мәзлум рафиклар* – изелгән иптәшләр.

Күзләгән өмидләре... һич вөҗүдкә[1] килмәсмени!!
Бетте хаклык, калмады шатлык... хакыйкать яклаңыз,
Чыгабыз... Кузгалыңыз... Мәзлум рафиклар, атлаңыз!
Чыгабыз... Кузгалыңыз... Мәзлум рафиклар, атлаңыз!

## XXIX

Тавыш, шау-шу мәдрәсәне күккә күтәрәчәктәй тоелган мәртәбәдә көчле иде. Моны ишетүгә, идарәдәгеләр, кинәт каушап, агарынып киттеләр. Мәдрәсәнең башы Гали мөдәррис чәчрәп килеп чыкты. Аның иреннәре агарган, күзләрендә ут яна, бөтен торышы ачу катыш каушау аңлата иде. Ул чыгып җитәр-җитмәс, алдындагы бөтен бугазларына акырган ничә йөз шәкертне күреп кычкырып йибәрде:

– Әйтеңез, Аллаһ хакы өчен әйтеңез... Ни бар?.. Ни кирәк?..

Арттан кемдер:

– Безгә җавап кирәк... Җавапның мөддәте бүген тулды, – диде.

Мөдәррис дәвам итте:

– Нигә бу чаклы шаулыйсыз?.. Ник тавышланасыз?.. Полиция кертәсез... Мәдрәсәне яптыртасыз...

Әллә кайдан арттан яшеренгән тавыш:

– Ябылсын... Кадалсын мәдрәсәң! Ач калудан куркасыңмыни, ул булмаса? – диде.

Мөдәрриснең йөзе кәфендәй яман агарынды, бу сүз аңа һушыннан язган адәмгә салкын су бирелгәндәй тәэсир итте.

Ул шәкертнең бозау булуын теләми, һәр сүзгә баш июгә караганда, тәнкыйтьле егетләрне эченнән артык күрә, җәмгыятьләрдә үзенең сүзенә карап әйтелгән ачы сүзләргә дә артык исе китми иде.

Ул күпне күтәрә, ләкин бу сүзне көтми иде! Ничек аңар үзенең бөтен хәятын, рәхәтен шул мәдрәсә юлына корбан кылган, хәятта бердәнбер максаты мәдрәсәгә, шәкерт тәрбиясенә хезмәт итүдән гыйбарәт булган Гали мөдәррискә шул сүзне әйтәләрме? “Кадалсын мәдрәсәң, ач калудан куркасыңмыни?.. Йа Ходай, буны кем, кемгә әйтә? Бер шәкерт, ничә еллар аның тәрбиясе юлында рәхәтен фида кылган остазына – миңа әйтә?”

Бер секунд эчендә шул ачы уйлар аның башыннан кичте. Хакыйкатән, бу сүз аңа кайчан да булса ишеткән иң ачы сүзләрдән дә агулырак һәм авыррак тәэсир итте. Ләкин ул үзен тиз җыйды:

– Ни дисез? Кем... Кем әйтә ул сүзне?

Мөдәррис әфәнде сүзен бетерә алмады, шәкерт төркемен икегә ярып,

[1] *Вөҗүдкә* – барлыкка.

аның каршысына Җиһангир килеп басты. Ул һөҗүм итәргә, хәзер атылып, җимереп ташларга торган бер кыяфәттә иде. Килеп тә җитте, кычкырып та йибәрде:

– Хуш... теләсә кем әйтсен!! Хәзер аны тикшерә торган вакыт түгел... Сездән җавап көтәбез, гаризада әйтелгән мөддәт тулды, диделәр, сез менә шуңар ни дисез?

Ике егетнең кулбашына таянып бераз югары күтәрелде дә Җиһангир, кайнашып торган шәкерт өстенә карап, тагын яман, тагын куәтле тавыш белән акырды:

– Иптәшләр!!! Ни торасыз?! Кәнсәләрия алдына садака сорарга килдеңезме??!! Кая телеңез?! Кая сүзеңез?!.

Мәдрәсә яңадан гөжләп китте. Арада берәүсе, югары күтәрелеп, тагы нотыклар сөйләргә, тагы шәкертнең изелүен, идарәнең истибдадын, ислах өчен көрәшәчәкләрен, кудыртмаячакларын кызу, ялкынлы сүзләр белән атарга тотындылар.

Мөдәррис үзен-үзе баскан иде инде. Агарынган йөз, сабырлы тавыш белән:

– Һичкем изми, һичкем кумый... Без хөкемгә җыелдык, гаебе булмаса, берәүне дә чыгармаячакмыз. Ярым сәгатьтән бар да мәгълүм булыр. Алла хакы өчен бераз сабыр итеңез, – диде.

Шәкертләр тагы шаулаша, юк инде, тәкатемез калмады, күп көттек, күп вәгъдәләр бушка чыкты, ди башласалар да, Нигъмәт казый белән Давыд Урманов югары күтәрелеп, бер-бер артлы:

– Иптәшләр, бик аз гына сабыр итүдән һичбер зарар булмаячак, – дип сөйләгәч, бераз тынычландылар. Кайсылары мәсҗед-җәмгыять залына, беразы сыйныфларга таралды, иң күбе киң, озын коридор буйлап йөрүендә дәвам итте.

Биш минут үтү белән, идарәгә теге уникене берәм-берәм чакыра башладылар.

Беренче Җиһангир исеме чыкты. Ләкин ул кәнсәләриядәгеләргә ишеттерерлек мәртәбәдә кычкырып:

– Булмас, мин анда кереп җавап биреп ваксыныр хәлем юк, – диде.

Аның артыннан чакырылган Сөләйман Сәйфуллин да кермәде. Нигъмәт казый керсә дә:

– Чакырткач, кермәүне килештермәдем. Ләкин мин җавап бирмәячәкмен. Әгәр шәкерт алдына чыгып, гомуми җәмгыятьтә мөзакәрә[1] булса, ихтимал, бер-ике сүзем булыр иде, – диде.

[1] *Мөзакәрә* – фикер алышу.

Аның артыннан Давыд Урмановны чакырдылар.

Бу вакыт идарәдәгеләр бик каушаганнар иде, Гали мөдәррис дустанә бер шелтә белән сүз башлады:

– Давыд әфәнде! Ике ел инде сезне дәрестә айга бер-ике мәртәбәдән артык күрә алмыйм. Хәзер дөньяңыз башка, юлыңыз башка... шул бала-чага эчендә кайнарга сезгә ни калган инде...

– Гали әфәнде, сез ул хакта сөйләргә теләсәңез, мине икенче вакытта чакыртырсыз... Дәрескә йөрү хакында шуны гына әйтәм: беләсез бит, мин рәсми шәкерт түгел, мин кайбер максатлар өчен тик самигъ[1] кына булып килгәлим. Самигълар, мәдрәсә низамнамәсе буенча, дәрескә йөрү-йөрмәү турысындагы мәсъүлияттән могафлар[2]...

– Мин аны беләм... Ләкин хәзер шуның өчен дөньяңыз башка, юлыңыз башка... ник шунда пычранасыз, дим.

Мөдәррис дәвам итмәде. Кәрим Гайфи мәсьәләгә кагылып, озынга сүз башлады, хезмәт итәргә теләүләрен, бу хәлләр дәвам итсә, мәдрәсәләр бетәчәген, мөгаллим белән шәкерт яхшы мөнәсәбәттә булуның лөзүмен[3], әгәр дә шәкертләр гафу үтенсә, һичкемне куу булмаячагын сөйләде.

– Караңыз әле, Кәрим әфәнде, сез, гафу, дисез. Шәкертләр нинди җинаятьләре өчен гафу үтенергә тиешләр? Аларның сезгә каршы җинаятьләре, гөнаһлары нәрсә? Сез бик яхшы беләсез, аларның бөтен гөнаһлары – теләк вә карашларының сезнекенә башка булуыннан гына гыйбарәт! Бонда нинди гафу булырга мөмкин?..

Урманов чыкканда, шәкертләр яңадан кәнсәләрия каршысына җыелып өлгергәннәр, сабырсызлык белән аның чыгуын көтәләр иде. Ул ишекне ачуга, төрле яктан:

– Ни бар? Ни диденез? – дип тавышланып калдылар.

Урманов җәмгыять залына таба килде дә, бик аз гына талпына төшеп, идарәдә гафу үтенү мәсьәләсе кузгалганын, үзенең ни дип җавап биргәнен сөйләде... Шәкерттә тагы берничә мәртәбә гайрәт артты, беравыздан “ура” кычкырып, Давыдка:

– Яшә! Яшәсен татар шәкерте! – тавышлары белән аны кулга күтәрделәр.

Анардан соң кергән һәрбер шәкерткә:

– Гафу үтенмәңез, курыкмаңыз, монда сезнең артта ике йөз иптәшеңез хәзер тора... Сез ялгыз түгел... – дип кычкырып кала башладылар... Унике шәкерт берәм-берәм чакырылган соң, назыйр тагы килеп чыкты:

---

[1] *Самигъ* – тыңлаучы.
[2] *Мәсъүлияттән могафлар* – җаваплылыктан азатлар.
[3] *Лөзүмен* – кирәклеген.

– Җиһангир әфәнде белән Сөләйман Сәйфуллин идарәнең чакыруына илтифат итмәделәр. Алар тагы бер мәртәбә чакырыла. Инде бусында да кермәсәләр, мәдрәсә идарәсе аларны үз шәкертләре җөмләсеннән чыгарылганын игълан итәргә мәҗбүр булачак... Керәсезме, юкмы? – диде.

Җиһангир якын иде. Тәхкыйрь[1] катыш мәсхәрәле тавыш белән:

– Бар, бар, әйт үзләренә, теләсә нинди хөкем игълан кылсыннар... Мин анда җавапка керүне үземә хурлык саныйм, – дип кычкырды.

Ишек ачык иде, аның һәммә сүзе кәнсәләриягә ишетелә торды. Назыйр борылуга, ул тагы иптәшләренә хитаб кылды[2]:

– Иптәшләр, актык минутлар җитә. Бездә җан бармы? Бездә шул биш-ун җаһил[3] белән биш-ун җуан корсак алдына тезләнмәслек намус бармы? Бездә үземезнең теләгемез турында көрәшерлек гайрәт, куәт бармы? Булса, ни эшләп торабыз, сез ни көтәсез, алар, ни бирерләр, дисез...

Ул артык ашыга, күзләре канланып, үз тавышына үзе буылып бара иде. Аның бетергәнен дә көтмәделәр, бөтенесе берьюлы:

“Кояш чыкты, нур балкыды – тәрәзәдән өйгә атылды,

Ятма йоклап, уян, шәкерт – кузгалырга вакыт җитте”не күтәреп җибәрделәр.

Бу соңгы тавыш ничектер артык куәтле, артык куркыныч һәм катгый карардан килгән кебек чыга иде. Идарәдәгеләрнең каушавы, ачуы чиккә җитте, ахрысы, Гали мөдәррис түзмәде, яңадан атылып килеп чыкты да, шәкертне җырып, агымның мәркәзе туктаган йиргә, җәмгыять залына килеп, ниндидер бер урындыкка баскан хәлдә, менә-менә һәлакәтнең алдындагы халәткә охшаш бер кыяфәт белән кызып сөйләргә тотынды. Мәдрәсәнең милләткә кирәклеген, кулларыннан килгән кадәрле тырышуларын, һичбер нәрсә тиз генә вөҗүдкә килмәвен, вакыты белән һәммә ислахлар да эшләнәчәген, бу юлда эшче белән фабрикант белән көрәшүдән файда чыкмавын, бәлки, шәкерт белән хәлфә кулга-кул тотышып бару лөзүмен мөәссир гыйбарәләрдә[4] тезеп китте. Ул, гомумән, сүзгә шәп санала иде. Ләкин аны бер минут та җүнләп тыңламадылар, тик карагруһлардан[51+] саналган биш-ун шәкерт кенә куркына-куркына:

– Дөрест, бик дөрест, бик хак мөдәррис әфәнденең фикере... – дип, тавыш бирделәр.

Ләкин бу шәкертне җенләндерде генә. Каралар мөдәррискә бер-ике йирдә кул чабарга өлгерә алмыйлар, тагы башлана төрле яктан нотыклар,

[1] *Тәхкыйрь* – мыскыл.
[2] *Хитаб кылды* – эндәште.
[3] *Җаһил* – надан.
[4] *Мөәссир гыйбарәләрдә* – тәэсирләндерүче, йөрәккә үтүче сүзләр белән.

тагы кызу вә ялкынлы сүзләрдә иттифак кирәклеге, һәр милләт иттифак аркасында гына тәрәккый итә алганлыгы, һәр сыйныф үзенең сыйнфый файдасын күзәтү өчен, үзара берләшү, берлектә көрәшү лөзүме, көрәшү аркасында гына хокук алынуы, егерменче гасырда һәр милләт тәрәккыйгә, хөррияткә тырышкан бер заманда татар шәкертенең йоклап, изелеп ятуы оят булганлыгы тәкрар ителә...

Бераздан Нигъмәт казый сүз ала:

– Сүзем аз. Әйтәчәгем кыска. Мин утыз яшьтәмен. Русия татрларының иң шәп, иң мәшһүр кадим мәдрәсәләрнең берендә егерме яшемдә вакытта “Мөлля Җәлал”, “Хикмәт әл-гайн”[52+] бетереп, хәтме көтеб кылдым[1]. Соңра анда биш ел кадәр калып, казый булып, мөтәгаләдә яттым. Заман килде, мине уятты. Мин җәдид мәдрәсәләрнең иң шәбе, иң атаклысы булган мәдрәсәи исламиягә шәкерт булдым. Төпле, нигезле булсын дип, дүртенче игъдадидан башладым. Бу ел гали дүртенчедәмен. Язга бу мәдрәсәнең беренче дәрәҗәдә мәэзүннәреннән[2] булачакмын... Күп дәресләрем биш белән бара. Тәфсир, гарәбият биш ярымнан ким булганы юк. Духовный собрание[53+] миңа имам хатиб вә мөдәррислек бирәчәк. Ләкин болардан ни чыга? Менә мин хәзер бөтен вөҗүдем белән руханилыктан бизгәнмен, үземне ничаклы көчләсәм дә, мин мулла, имам була алмыйм. Моңар гакылым, нәзариям[3] түгел, бөтен вөҗүдем, табигатем, вөҗданым каршы... Мондыйлар бер мин түгел, болар йөз дә түгел, мондыйлар меңнәр... Бу хәлне тарихи зур хата тудырган. Мөдәррис әфәнде безне кул кулга тотынып барырга, ди. Көрәшү мәгънәсез, ди. Ләкин без икенче төрле карыймыз. Бөтен татар көтү белән китерә дә үзенең угылларын мәдрәсәләргә тыга. Һәммә мәдрәсәләр – дини. Менә без моны зур тарихи хата саныймыз. Безнең көрәшләр, безнең мәдрәсә ташлаулар бу зур хатага милләтнең дикъкатен алыр. Без, чыгабыз, дибез, һәм чыгудан кире тормыйбыз. Бу чыгуның үземезгә файдасы булырмы, юкмы, ләкин бу чыгулар, бу кузгалулар белән без шул тарихи хатага протест итү хезмәтен үтәячәкмез...

Тагы кемнәрдер хәлфәләрне сүгәргә, идарәне гаепләргә, бөтен бәхетсезлекнең башын хәлфәләрдән, идарәдән күреп сөйләргә тотынган, арада бик ачы сүзләр куллана башлаган иде. Гали мөдәррис түзмәде, хатибларның сүзен бүлде:

– Әй җаным... Бик артык баласың, артык сабыйсың... Бир миңа берничә миллион акча, менә мин, Парижның беренче мәдрәсәсе рәвешенә кертеп, ислах ясыйм... Ул кирәк, бу кирәк... Без – ачмыз... Моннан чыккач, бер эшкә

[1] *Хәтме көтеб кылдым* – укып бетердем.
[2] *Мәэзүннәреннән* – берәр эшкә хокук бирелгән кешеләреннән.
[3] *Нәзариям* – дөньяга карашым.

ярамыйбыз... Руслар фәлән кыла, төгән кыла, дисез... Мин аны үзем дә беләм... Кулдан килгәнне эшлибез. Тиз арада гына барын кайдан җиткерик... Кая яхшы мөгаллимнәр? Кая яхшы китаплар! Кая һәртөрле фәнни әсбап алырга дәүләт? Кая акча?.. Татар галәмендә булмаганны бүген генә мин кайдан алыйм... Алар күктән яумый... Сез тотасыз да бөтен гаепне идарәгә, хәлфәләргә аударасыз!

Мөдәррис әфәнде бетәр-бетмәс, Давыд күтәрелде:

– Бер-ике генә сүзем бар. Монда кайбер иптәшләр һәммә бәхетсезлекне хәлфәләрдән күреп сөйли. Бу, әлбәттә, балалык, сабыйлык... Мәсьәләгә тирәнрәк карарга кирәк: мәдрәсәләр һичнәрсәгә ярамый, моннан чыккан яшьләр халыкка хезмәт итү кайда, киресенчә, аңар авыр йөк булып яшиләр. Нинди генә шәп егет булмасын, татар мәдрәсәләрендә алган гыйлеме аңар муллалыктан башкага ярамый. Ул мулла булса да, тамак туйдыру өчен, ансыз да ач, ялангач, йирсез булган, ансыз да түләүләр белән күмелгән ярлы мужикның җилкәсенә утырсын! Гошере, фитры, садакасы дип, бичара мужикның хөкүмәттән калган икенче тиресен тунасын! Бу – хәят түгел, намуслы егетләр моны адәм хурлыгы саный. Хәлбуки, нинди генә булса да, мәдрәсә дә аңа шуннан башканы бирә алмый. Хәзерге шәкертнең күзе ачылган – ул башка милләтләр яшьләренең хәлен күрә, үзе гыйлем вә хөррият нигезенә корылган якты вә матур киләчәк эсти[1]. Шул аны югарыга – еракка чакыра... Шул аны берләштерә, көрәштерә... Аларга берәм-берәм таралырга мөмкин, ләкин мондый җыелып көрәшүләре тагы мәгънәлерәк... Таки татар халкы күрсен ки, аның яшь угыллары хәзерге хәлләреннән риза түгелләр, күрсеннәр дә ул хакта җитди уйларга, җитди эшләргә тотынсыннар. Гомумән, бу кузгалулар, бу дулкыннар берничә хәлфәгә, үзе дә гаҗиз идарәгә каршы түгел, тыштан шулай күренсә дә, аның төп сәбәбе тирән: мәдрәсә яшьләре, Нигъмәт казый әйтмешли, тарихи зур хатага протест өчен кузгалалар. Гасырлар буенча җыелып килгән зур бәхетсезлекләр инде чигенә җитте. Түзәр мәртәбәдән үтте – һәм менә шул ихтиляллар рәвешендә дөньяга бәреп чыга...

Давыд артыннан тагы Сөләйман Сәйфуллин сүз башлап, артык кызып, тәмам буылып, тавышына тыгылып, баягы нотыгын, татар шәкертенең нинди авыр, кызганыч хәлдәлеген тәкрар итте.

Бөтен шәкертнең куәтле дулкыны астында ул йөрәкләрне ярып төшәчәк бер тавыш белән:

– Аһ, фәләк! Ашадың башларны!.. Әйтеңез, иптәшләр, инде тагы ни көтәбез? Тагы ни көтәбез? Җитәр... Җитте... Күп изелдек... инде артык

---

[1] *Эсти* – тели.

түзәргә такать калмады... – дип, сүзен бетерде.

Мәҗлестә тәртип калмады, берәү сөйли, берәү нидер, кемгәдер кычкыра, кемнәрдер “туктаңыз, болай бернәрсә аңлар хәл юк” дип, шәкертләрне туктатырга телиләр, ләкин моңардан гомуми шау-шу гына арта иде.

Мөдәррис агарынган, ярым һушыннан язган, кайдалыгын оныткан адәм рәвешендә тора, идарә яклы биш-ун карагөруһ белән, җасус[1] Миһраннар, яшеннән качкан шайтан кебек, әллә кая артка яшеренгәннәр. Нә бер сүз әйтүдән, нә бер кул кыймылдатудан гаҗизләр...

Шул шау-шу эчендә башкаларны җиңеп, тагы Сөләйман Сәйфуллинның ачы, куәтле авазы ишетелә башлый:

– Әйтеңез, без ниләр теләдек? Безгә ничә мәртәбә вәгъдәләр бирделәр... Бар да бушка чыкты. Инде тагы алданабыз. Тагы ышанабызмы... Юк, булмас, инде өмид бетте!!!

Аны бүлеп, төрле яктан тагы нидер кычкырынырга тотыналар, уртадан җырчы Сахиб тирәсенә җыелган берничә егет тагы “Чыгабыз”ны көйләп йибәрәләр... Алар бер-ике сүз әйтеп өлгерә алмыйлар, бөтен шәкерт беравыздан кушылып акырышырга тотыналар. Шулвакыт тегеннән Кадыйр бай килеп чыга:

– Бу ни тавыш... Бу ни башбаштаклык... Сезгә ни кирәк...

– Ни кирәк булсын! Кирәкләребезне әйтеп, без бер атна элек гариза бирдек... Инде мөддәт тулды.

– Безгә җавап кирәк... ислах кирәк...

– Ислахны шулай сорыйлар димени? Укыткан хәлфәләрегез ни кирәген белмиләрмени? Бар... Барыңыз... Таралыңыз... Остаз юк, итагать юк... бу нинди адәм хурлыгы тагы... Гали әфәнде, мин кайтам. Минем актык сүзем: ул унике ахмакны бүген, менә хәзерге сәгатьтән калдырмый, мәдрәсәдән куыңыз! Безгә андый дәһри[2] башлар кирәкми! Андый итагатьсезләргә безнең бер тиенемез әрәм!!.

Бай сүзен бетерә алмый, якындагы биек урындыкка, зур чәчләрен туздырып, ут кебек янып, Җиһангир сикереп менә дә:

– Иптәшләр... күрәсезме?! Ишетәсезме?! – дип, бөтен шау-шуларны кинәт җиңеп ташлаган бер аваз белән кычкырып йибәрә һәм сүзен дәвам иттереп, шәкерт каһарманның авыр язмышын, анда изелүен, шуның өстенә тагын ниндидер җаһил корсаклар тарафыннан тәхкыйрь ителүен, намуслы егетләр өчен моны күтәрү такатьтән тыш икәнен, җан булса, хәмиять[3] булса,

---

[1] *Җасус* – шымчы.
[2] *Дәһри* – Алласыз, динсез.
[3] *Хәмиять* – саклау.

үз теләгемез юлында көрәшерлек гайрәт булса, хәзер актык минут җиткәнен янып торган утлар рәвешендә иптәшләре өстенә ата да, иң соңгы сүз итеп:

– Күтәреләңез... Кузгалыңыз, иптәшләр, милләт каһарманнары! – дип сикереп төшеп, якындагы диварга атыла.

Шау-шу эчендә ни эшләгәнне карарга да өлгерә алмыйлар, ул шунда диварга алтын рамкалы зур пыяла эченә асылган низамнамә тактасын иптәше Сөләйман Сәйфуллин белән яшен тизлегендә тартып төшереп, күз ачып күз йомганчы өченче каттан түбәнгә, баскыч төбендәге таш идәнгә атып бәрәләр...

Шәкерт тагы бер исткиткеч ашкыну, дулау белән хәрәкәткә килә, бер як бетсен, кадалсын, ват барын, яшәсен егетләр, дип кул суга, "ур-ра" дип кычкыра башлый, икенче як зур шау-шу эчендә тагы садаларны күтәреп йибәрәләр.

Низамнамә, ташка төшеп, ун булды. Шул минутта игъдадиның[1] ике сыйныфында урындыклар белән тәрәзә ватылган тавышы, берничә йирдә зур лампаларның шалтырап очуы ишетелде, шәкерт дөнья күтәреп җырлый; тегеннән байлар, мөгаллимнәр килеп чыкты. "Йа Ходай, бу нихәл? Кыямәтме? Мәхшәрме?" диячәк минутка киленде. Һәр ике як гадәттән тыш бер минут кичерделәр.

Менә-менә батып һәлак булып барган корабның командирлары ни-нәрсә хис итсә, мөдәррис һәм мөгаллимнәр бу вакыт шул халәткә килделәр. Шәкерт исә менә-менә зур канлы сугыш соңында артык мөһим крепостьны алып килмәктә булган гаскәр ашкынуы белән очалар иде, гүя бөтен бәхетсезлекләрнең актык минуты килде, гүя шул алтынлы рамкалы пыяла эчендәге зур низамнамә тактасын түбәнгә атып көл итү белән, аларны изгән, аларны кан-яшь агълатып килгән тарихи каһәр чигенде, гүя шуның белән үзләрен баскан, бәхетсез ясаган иске тормыштан мәңгегә котылып, шул минуттан соң якты, ирекле, матур, яңа хәятка, яңа бәхеткә чыктылар, гүя күптән көтелгән сәгадәтләренә кавыштылар.

Ләкин бу бер минуттан артыкка сузыла алмады. Низамнәмә төшеп ватылып та өлгерде, шул ук минутта ватылган рамкалар өстенә аксыл-соры шинельле, җиз төймәле, кылычлы ике адәм килеп тә бастылар:

– Бу нихәл? Бу нинди скандал?

Ул арада кылычлылар, мылтыклылар артып, берничә городовой, егермеләп солдат, берничә казак аптыраган күзләре белән як-ягына карана-карана, югарыга, шәкертләр янына менә башладылар.

Бу һәммәгә салкын су сипкәндәй тәэсир итте.

---

[1] *Игъдади* – мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары.

Шау-шу кинәт басылды, дулкын һичбер булмаган дияр дәрәҗәдә тынды. Башта бераз аптырап, югалып калган Гали мөдәррис тә тиз айнып, монда менеп килгән приставка каршы барды:

– Гаҗәпләнмәңез, үзара бераз аңлашылмау гына бар иде.

Ни булганын, бу вакыйгаларның төшме, өнме икәнен аерып җитә алмый аптырау халәтендә почмакка сөяләә төшеп торган Кадыйр байны күрүгә, пристав бераз басылды, бераз иелде, аңар килеп кул бирде дә:

– Гафу итеңез... Югарыдан әмер буенча, мәдрәсәне тентергә мәҗбүрмез, – диде.

Бай, кул селкеп, түбәнгә төште. Башка байлар аңар ияpделәр. Пристав, Гали мөдәррискә якынаеп, ни өчен килгәнен тәкрар итте дә хәзер тентү башланачагын игълан кылды.

## XXX

Бу вакыт мәдрәсәнең тирәсе тыш яктан йөзләп атлы солдат белән чорналып алынган иде инде. Һәр якта ишекләрдә дүртәр солдат мылтык белән тора. Алар һичкемне кертмәскә һәм чыгармаска тиешлеләр. Пристав исә хәлфә, мөдәррис, назыйрләрнең һәммәсен мөгаллимнәр кәнсәләриясенә кертте дә алар янына дүрт солдат куйды. Таки үзара сөйләшмәсеннәр, кесәләрендәге нәрсәләрен ташламасыннар. Шәкертләр, туры килгәнчә, төрле бүлмәләргә таратылды да, ишекләргә сакчылар куелып, тентү башланды. Иң әүвәл парталар, андагы язулар, дәфтәрләр алынды, соңра һәммә кесәләр бушатылды, аннан кәгазьләр, хатирә дәфтәрләре җыелды.

Аннан соң ашханә, ятакханәгә төшеп, сандыклар актарылды. Ике револьвер табылырга тиеш иде. Ничектер туры килмәгәннәр. Сөләйман Сәйфуллин кесәсендәге кечкенә бер дәфтәрдә теге мәфруз[1] партия “Фидаиләр”нең програмы белән бомба ясарга өйрәткән бер кәгазь, тагы кемдәдер Рауза туташ түгәрәкләре хакында язылып та йибәрелми калган хат бар икән. Хатның иясе башта аны чәйнәп карады, җота алмады, соңра солдат икенче якка караган вакыт форточкага ташларга уйлады, аны күрделәр дә, кулыннан тартып алып, фәлән кәгазь фәләннән фәлән рәвешле алынды дип, аерым яздылар.

Бу хат белән Рауза туташ та арага алына дип, бик куркыштылар. Өч йөзгә якын шәкертне тентеп бетеп мөгаллимнәр кәнсәләриясенә килгәндә, таң якынлаган иде инде. Пристав янындагы ике городовой бер околоточный белән керде дә яшел постаулы өстәл янындагы урындыкка утырды. Ул бик арыган, бөтен торышы белән “кайчан гына бетәр бу гөнаһ шомлык” дигән

---

[1] *Мәфруз* – уйланылган.

кебек күренә иде. Киерелә төшеп утыру белән, озак күтәререргә мәҗбүр булуы өчен гафу үтенде дә бәрәмләп сорый, тикшерә башлады.

Мөгаллимнәр йокысыз үткәрелгән төннән бик артык арыганнар, мәдрәсә ябылу, үзләре хибескә[1] алыну кебек куркыныч уйлардан бик борчылганнар иде. Беренче Гали мөдәррискә мөрәҗәгать итте.

Аның русчасы мәшәкать беләнрәк булса да, җавап бирерлек иде.

Гали мөдәрристән соң башкаларны сорый башлады.

Һәммәсе арыганнар, каушаганнар, русчалары бик зәгыйфь иде. Шунлыктан боларның җавапларында Гали мөдәррискә булышлык итәргә күп туры килде.

Иң соңгы нәүбәт мөгаллим Кәрим Гайфи әфәнденеке иде.

Околоточный башка мөгаллимнәрнең кесәләрендәге хат, кәгазь, дәфтәрләрне җыюда дәвам итте. Пристав Кәрим әфәнденең кызыл фәсе белән озын Истанбул җөббәсенә[2] аеруча дикъкать иткән хәлдә сорарга тотынды:

– Кай йирлек?

– Кайда укыган?

Боларга ничектер Ходай ярдәм бирде. Ләкин нәрсә, нинди китаплар, кем әсәрләреннән укыту тирәсенә килгәч, ул бөтенләй аяктан егылды. Әфәнденең русча белмәве турында усал тел шәкертләр:

– Ул фатирында марҗасына самавыр куй диясе урында авызына бармагын тыгып аңлата, имеш, – дип көләләр иде.

Бу, бәлки, бик дөрест үк булып бетмәс. Аның Истанбулдан кайтканына байтак бар, русчага такырлыгы мәгълүм исә дә, инде ул, һич булмаса, “самавыр куеңыз”ны өйрәнә алган булыр.

Ләкин фәнни исемнәргә килгәч, аның күз алды караңгыланып ук китте.

Үчеккән кебек приставы да үзенең сөален тәкрар итә бирә:

– Сез кайсы фәннәрне, кем әсәрләреннән укытасыз?

Аның күз алды караңгылана, тез буыннары тагы ныграк йомшый төште; шулай да егылмады, үзен-үзе бик аз белгән хәлдә әллә кайда көчләнеп, каушап килеп чыккан тавыш белән:

– Мы учим һәндәсә[3], – дия алды.

Пристав аңламады:

– Ни дисез?

– Мы учим һәндәсә...

Кәрим Гайфинең гыйльми һәйәт[4] эчендәге югары урынына хәсәденнән[1]

---

[1] *Хибескә* – төрмәгә.
[2] *Җөббә* – җиләннең бер төре.
[3] *Һәндәсә* – геометрия.
[4] *Һәйәт* – коллегия, җәмәгатьчелек.

яныл йөргән мөгаллим Фәйзи буны ишетү белән, үзен-үзе тыя алмый, мәсхәрәле тавыш белән көлеп йибәрде.

Пристав, ахрысы, моннан эш чыкмас дип уйлады булса, Гали мөдәррискә мөрәҗәгать итте, мөдәррис русчага тәрҗемә итеп бирде.

Мәдрәсәдән алынган нәрсәләр алты-җиде йөк булды, шәкерт кайгырмый, күпләр ябылу-ябылмавына салкын карый, кайберләре эчләреннән ябылуын ук тели иде.

Ләкин Гали мөдәррис белән мөгаллим Кәрим Гайфи шул бер төн эчеендә ничә еллык картайдылар. Өстәвенә, шул көн һәммә мөгаллимнәрдә, мөдәрриснең үзендә тентү булып, бик күп мисыр, Истанбул басма сары кәгазьле калын китапларны төяп алып киткәннәр.

Эшнең ахыры мәгълүм булгангача, Гали мөдәррис йокыдан, аштан калды. Шундый зур фидаилык белән алып барган[2], шуның белән бергә милләткә һәм дингә зур файда итәм дип ышанган бер кеше өчен шул мәдрәсәсенең ябылу ихтималы, табигый, җиңел түгел иде. Шул бераз заман эчендә аның йөзе кара сарыга әйләнде, күз төпләре кара көйде, күзләре эчкә батты, яңаклары суырылды – аның бөтен торышы йөрәгендә авыр яра барлыгын сөйлиләр иде.

Ләкин нәтиҗә яман булмады. Шәкертнең һәммә нәрсәсе кире кайтты. Сары кәгазьле китаплардан да тик берничә данә “Рәдде нәсара”[3] гына калган. Теге Сөләйман Сәйфуллинның бомба ясау хакында кәгазе “Фидаиләр” програмы, Рауза туташның түгәрәге хакындагы хат та исән-сау кире ияләренә тапшырылды! Аларны, ахрысы, укымаганнардыр.

## XXXI

Тентүләрнең иң авыр нәтиҗәсе мөгаллим Кәрим Гайфи әфәндегә төште. Кечерәк буйлы, нәзек гәүдәле, кызыл-саргылт йөзле, гасаби табигатьле, ләкин якты күзләре җитди фикер, җитди игътикад төсе белән ялтырап торган бу зат чын мәгънәсе белән фән кешесе иде.

Яшьтән үк артык тырышлыгы, мөстәгыйдлеге[4], җитдилиге аркасында илтифатка алынып, остазының дәляләте[5] белән шәһәр байларыннан Камалов аңар ярдәм бирәчәк булды. Шуның белән ул, Истанбулга барып, рәсми мәктәпкә керде. Ул анда әүвәлге елыннан ук беренче барды. Мәктәпне алтын

---

[1] *Хәсәденнән* – көнчелегеннән.

[2] *Фидаилык белән алып барган* – үз-үзен аямыйча чын күңелдән эшләгән.

[3] *“Тәдде нәсара”* – китап исеме (“Христианлыкны кире кагу, дөрес түгеллеген күрсәтү”

[4] *Мөстәкыйдлеге* – булдыклылыгы.

[5] *Дәляләте – бу урында*: димләве.

медаль белән тәмам итте.

Төркиядә калса, фән галәмендә яхшы урын тотачагына шөбһә итмиләр, теләсә, дәүләт хисабыннан Европага да йибәреләчәк, кайтып, Төркиядә профессор булачак иде.

Башта ул үзе дә шул уйда иде. Мәсләк җәһәтендә[1] исламчы булганга, татармы, төрекме, гарәп, һиндмы – аермый, мөселман булса, барыбер, кайсына хезмәт кылсаң да идеалына барып була, аңар һәммә мөселман милләттәш, аларның кайсына хезмәт тә мөкаддәс иде.

Ләкин чыннан ихтирам иттеге[2], күп турыда үзенә мәгънәви остаз таныдыгы[3] Әхмәд Мидхәт[54+] әфәнде аңа, мотлак[4], мотлак, Русиягә кайтып хезмәт итәргә димләде. Ул арада берничә мәдрәсә арасыннан мөдәррислеккә чакырып, хат та язалар, болардан Русия мөселманнарының фәнгә бик артык сусаганлыклары аңлашыла иде.

Бу ике сәбәп өсенә[5] тагы өченче бер хәл: җиде елдан бирле мондагы якын вә кардәшләрен зиярәт иткәне юк иде.

Гали мөдәрриснең тәфсилле хатын алгач, риязыят[6], табигыят[7] мөгаллиме уларак, мәдрәсәи исламиягә кайта салды.

Ул французчага шәп санала, дәресне француз әсәрләреннән карап килә, фикри интизамы[8] куәтле, күпләрнең гаҗәпләнүенә каршы, аз бер вакытта онытылган татарчасын да тергезеп килә иде.

Беренче дәрестән үк шәкертләрне тәмам сихерләде. Моңарчы Төркиядә, берничә еллар каңгырып йөреп, үзеннән-үзе яки ун грошлык[9] репетиторларыннан аз-маз нәрсәләр алгалап кайткан Истанбул “иштә әфәнделәр”еннән соң Кәрим Гайфи дәресләре тамактан үтмәслек начар сулар белән интеккән вакытта, кинәт саф тау елгасы суына ирешү кебек тәэсир итте.

Берничә көн үтмәде, мөгаллим Гайфи шәкертнең иң сөйгән остазы булып китте.

Кайчандыр[*] үзенең бик сул күрелгән дини әфкяре[10], йөрәкләргә үтеп төшкән ялкынлы нотыклары белән әллә кайда югарыда ялтырап торган Гали

---

[1] *Мәсләк җәһәтендә* – дөньяга карашы ягыннан.
[2] *Ихтирам иттеге* – ихтирам иткән.
[3] *Остаз таныдыгы* – остаз дип таныган.
[4] *Мотлак* – һичшиксез.
[5] Бу урында *өстенә* дип укырга кирәк.
[6] *Риязыят* – математика.
[7] *Табигыят* – табигать фәннәре.
[8] *Фикри интизамы* – фикер тәртиплелеге.
[9] *Ун грошлык* – бик арзан, ун тиенлек; бу урында “*аз белемле*” мәгънәсендә.
[*] *Г.Ибраһимовта*: качандыр.
[10] *Дини әфкяре* – дини фикерләре.

мөдәррис инде гадигә әйләнә башлаган иде.

Кәрим Гайфидән соң, ул бөтенләй төште, искерде.

Мөгаллим Кәрим хәзер адәмлектә, мөгаллимлектә идеал, һәр турыда ул нәмунә[1] иде. Ләкин бу дәрәҗәдә тиз кабынган ихтирам ялкыны шулай ук тиз сүнде дә. Бер ай үтәр-үтмәс, аның исеме начар як белән телгә алына башлады.

Инде мәдрәсә дулкыннарына каршы йөри торган биш-ун карагруһ “ганка”дан башкалар, анардан суынып, Кәрим Гайфи дигәндә, артлары белән борыла торган булдылар.

Урыны туры килгәндә анардан:

– Фәс дип, җөббә дип, иштә, шәйдер[2] әфәндем... – дип көлә, җәмгыятьләрдә йөзенә карап сүгә башладылар...

Гайфи бу хәлләрдән эчке бер ачу белән калтырый, үзен начар хис кыла, шулай да тоткан юлыннан борылмый, вакыты белән җиңүенә ышана иде. Мәдрәсәнең һәйәте хариҗиясе[3] бар. Анда байлар, мөгаллимнәр. Һәйәте дахилия[4] бар. Ул үзе гыйльми белән идаригә бүленә. Әүвәлге елларда шәкерт һичберсенә катыштырылмаса да, соңгы вакытларда күп тартышлардан соң, шәкерт һәйәт идаригә үзеннән вәкил кертергә муаффәкъ булган[5]. Мөгаллим Гайфи килгән чорларда шәкертләрнең гыйльми һәйәткә дә үзләреннән вәкил кертергә теләп тавыш чыгарган заманнары иде.

Кәрим Гайфи моны һичбер төрле башына сыйдыра алмады:

– Ничек?... Шәкерт үзенә программа төзиме?... Бу ни дигән сүз?

Бу хакта күп җәмгыятьләрдә талаш булды. Шәкертләр безгә фәлән укылсын, фәлән дәрес ташлансын, киләсе елның программы фәлән рәвеш төзелсен дип күп тавыш кузгаттылар.

Ул моны һичбер төрле аңлый алмый. Аныңча, шәкертнең вазыйфасы – укымак, укымак, укымак!!

Шәкерт укысын, гыйлем алсын, әмма фикер, тәнкыйть анарда шул алган гыйлеменең заруры нәтиҗәсе уларак үзеннән-үзе килеп тора. Бик күп җәмгыятьләрдә ул шул фикерен куәтләп сөйләде. Шәкерт укудан, гыйлемнән башканы белмәсен, диде. Шул юлда һәртөрле җәмгыятьләрне яптырырга да теләде. Һәйәте гыйльмиягә шәкерттән вәкил керттерү түгел, һәйәте идаридәгеләрен дә чыгару ягын алга сөрде.

Шулар һәм аны харап та иттеләр. Анардан суындылар, дәресенә

---

[1] *Нәмунә* – үрнәк.
[2] *Шәйдер* – әйбер-нәрсәдер.
[3] *Һәйәте хариҗиясе* – тышкы комитеты.
[4] *Һәйәте дахилия* – эчке комитет.
[5] *Муаффәкъ булган* – ирешкән.

илтифатсыз була башладылар гына түгел, мәҗлесләрдә аның сүзенә сызгыра торган булдылар.

Ул инде хәзер идеал түгел, залим, мөстәбид[1], канэчкеч, диңгез артыннан истибдад[2] төяп кайткан “иштә” һәм “шәйдер әфәндем”[55+] иде.

Мәдрәсәдә чыга торган газетада, журналларда иң күп мыскыл ителгән кеше хәзер ул иде. Болар аны бик борчыйлар, ул:

– Таләбә[3] белән остаз арасында бу илә мөгамәлә булынса, тәгълим[4] вә тәрбиянең нинди тәэсире булырга мөмкин! – дип аптырый, ләкин өмиден өзми, шәкертне акрынлап җиңәргә һәм җигәргә – табигый юлга төшерергә булыр дип ышана иде. Шәкертләрнең “Дуэль” исемле журналында[56+] аның рәсемен төшерделәр:фәс, җөббә кигән бер адәм ашыга-ашыга өч катлы таш бинаның нигезен чукый. Бина бераз чалышайган, тагы бераз чукыса егылачак.

Рәсемнең астына “Кәрим Гайфинең мәдрәсәгә мөкаддәс хезмәте” дип язылган.

“Чеметкеч”тә шул ук өч катлы таш бинаның нигезен чуку сәбәпле, ул бөтенләй ауган, тау астына таба тәгәрәп, ишелеп бара. Шуның янында ук Кәрим Гайфи кыяфәтле бер адәм кулына бик зур гармун тоткан, үзе уйный, үзе:

– Әй дөнья, вай дөнья...

Шәкерт изү бик уңай!! –

дип такмаклап, шул такмагы уңаена кыска аяклары белән бии. Башка мөгаллимнәр читтән:

– Яшә, Гайфи! – дип кул чабып торалар.

Боларның һәр номерын почта белән аның квартирына җибәрәләр, ул барын күрә, барына хафалана, ләкин һаман да өмид өзми иде.

Тентүдән соң чыккан газеталар исә бөтенләй харап иде.

Әүвәлге дүрт-биш газета, журнал һәркаюсы баштанаяк анардан көлү белән тулганнар иде. Башка вакыт мәдрәсә эчендәге төрле партия, шәхси дошманлык интригаларына үзара сүгешүләргә күп урын биргән бу газеталар, бүген, сүз берләшкән кебек, һәммәсе аның пристав алдында каушавы рәсемнәре белән тулы, бары да баш мәкаләләренә “Мы учим һәндәсә…” – дип исем бирәләр дә тотыналар ямьсез сүзләр белән көләргә. “Кара күз” дигәннәре соңгы номерга ашыгыч гыйләвә дип шул “Мы учим һәндәсә…” белән аерым бер табак чыгарган.

---

[1] *Мөстәбид* – изүче, деспот.
[2] *Истибдад* – деспотизм.
[3] *Таләбә* – шәкерт, студент.
[4] *Тәгълим* – укыту, дәрес бирү.

Монда Кәрим Гайфине кара буяулар белән тасвир итеп килә-килә дә һәрбер мәкаләнең нәтиҗәсендә:

– Сез, зате гали, бурая риҗгатеңез белән хата япмышсыз… Монда сезнең кебек әһле истибдадә базар имәс... Сез, әфәнде хәзрәтләре, госманлы мәмләкәте галиясенә барып, урада зыйлле Габделхәмитнең асаяшь бер кәмал улан йирендә таләбәе мөкаддәс истибдадыңыз тәхтендә тәрбияя чалышмалыйсыздыр... Әфәндем, ихтирамәтеме кабулеңезе риҗа итеб, әлләреңездән[57+]… – дип, сүзен бетерә. Полиция хафасы, мәдрәсә ябылу куркусы өстенә болар да кушылып, аның төннәрен йокысызга әйләндерделәр. Аның эчендәге көчле иманын каушата башладылар.

Ул эшләрнең бу дәрәҗәдә анархиягә килеп җитүендә, башка һәркемнән бигрәк, Гали мөдәррисне гаепли:

– Башта ук җөгәнләргә кирәк иде... Бары да иске мәдрәсәдә кысылып, казыйның калын таягыннан котлары очып яшәгәннәр. Монда ул таяклар булмагач, бәйләүдән ычкынган этләр кебек котырышалар, – ди иде.

## XXXII

Гавам тарафыннан мәдрәсә исламиянең ихтилялы[1] башта бик кызу телгә алынса да, полициянең анда тентү ясау хәбәре ихтилялны җиңде, тегесе, ничектер, арткы планга төшеп калды. Мәдрәсәнең тирәсе атлы гаскәр белән камаланып, эченә күп солдатлар ни эшкәдер кереп тулуы шул минутта ук шәһәргә таралган иде. Берничә сәгать үтмәде, вакытның соң булуына карамыйча, мәдрәсә тирәсе балалар, баласын күтәргән хатыннар, авызын ачып хәйран булып торган гавам егетләре, хәерлегә булмас, ата-бабадан күрелгән эш түгел бу, дип хафаланып караган картлар белән кыямәт кебек тулды.

Гәп-әңгәмәнең исәбе-саны юк иде.

Башта һәммәсе куркынган йөз, каушаулы тавыш белән:

– Ни бар?

– Ни булган? – дип сорыйлар. Шуннан китә берсе берсеннән куркыныч төрле ихтималлар... Имеш, мәдрәсәдә шәкертләр белән хәлфәләр арасында сугыш булган; имеш, Кадыйр байны кыйнаганнар, бер мөгаллимне имгәткәннәр; имеш, ул хәзер больницада, ди; имеш, шул сугышны басарга гаскәр килгән; имеш, мәдрәсәдән дүрт бомба, ике әрҗә алтатар[2] тапканнар; имеш, Гали мөдәррис богауланган, аңар начар булачак, мәдрәсә ябылачак, мөгаллимнәр бар да хөкемгә биреләчәк, шәкертләр сөреләчәк, белмим, тагы

[1] *Ихтилялы* – баш күтәрүе, бунт ясавы.
[2] *Алтатар* – наган, револьвер.

ниләр... Шул арада кайдандыр икенче хәбәр дә туа. Имеш, Вафа хәзрәт, Гали мөдәрриснең бик шәбәюенә эче янганлыктан, мәдрәсәнең поварын яллаган да анда бомба белән мылтык куйдырган, үзе полициягә барып:

– Алар бомба ясыйлар... Алар патшага каршы баралар, – дип әләкләгән, шуннан соң полиция килгән, диләр.

Ни булса да, мәдрәсә тирәсен сырып алган күпсанлы татар җәмәгате гаҗәп куркыныч бернәрсә көтәләр иде. Шул хәлдә, ишекләр ачылып, эчтән берәм-берәм арыган солдатлар, городовойлар, пристав, околоточныйлар чыгып, атлы гаскәргә таралырга әмер булгач, иң гаҗәбе Гали мөдәррис богаусыз-нисез үзенең фәсе, җөббәсе белән килеп чыккач, халыкның дәрте сүнеп үк китте.

Күпләр эчләрендә канәгатьсезлек сизенделәр, һәммәсе: "Әй хәерсезне, юкка көттем, юк өчен төн йокымны калдырдым ла", – дип үкенеп таралдылар.

Бу вакыт кояш чыгып килә, көн аяз, якты, матур булыр кебек күренә иде.

## XXXIII

Җиһангир уянганда, караңгы төшеп киләдер иде инде. Ул сәгатьләрчә урыныннан тормый ятты. Тән арыган, әгъзалар кузгалырга теләми, ләкин зиһен ачык, якты, җан шат иде.

Мәдрәсә ябылырмы, юкмы – аның өчен ике ягы бер. Ләкин кичә мәдрәсә яшьләре хәятының, бәлки, бөтен тарихларында иң матур, иң һәяҗанлы[1] бер минуты килеп үтте.

Ул шуның башында булды.

Чыгылганмы, юкмы – анысы иттифакый[2]. Барыбер актык минут килгән, иртәдән үк төенләнеп куйган нәрсәләрне ямщикка төяп, йөз илле шәкертнең зур кызыл сарайны ташлыйсы гына калган иде. Чыгу-чыкмауның фактысы[3] мөһим түгел. Мәдрәсә яшьләре үзләренең үлмәгәнлекләрен күрсәттеләр, хәятлары, теләкләре юлында көрәшә алырлык куәтләре бөтенләй бетерелмәгәнлеген исбат иттеләр...

Нәтиҗә ни булыр – анысы әһәмиятсез, ләкин кичәге дулкын әле дә акрын гына кагылып, йөрәкне иркәли, җанга шатлык, бөтен табигатькә дәрт, рәхәт бирә.

Шулай акрын гына уйлары белән ләззәтләнеп яткан вакыт, ул кинәт,

---

[1] *Һәяҗанлы* – дулкынландыргыч.
[2] *Иттифакый* – очраклы.
[3] *Дөресе*: факты.

кичә мәдрәсәдә тентүләр бетәр алдыннан кемнеңдер Һаҗәрне телгә алуын хәтерләде.

Тукта, ул кем иде? Миһран, бугай! Тукта, ул җасус кайдан, ничек белер? Тукта, ул ни диде?

– Бишәү җитмәгән... Инде алтынчыга кеше хатынын алдый башлагансың икән! – диде, бугай.

Егет ятагыннан ничек сикереп торганын сизми дә калды.

Кемдер анда бакча як тәрәзәсен ачкан. Бүлмәдә һава күп, саф, ләкин бераз юеш, бераз авырга тартым иде. Җиһангир ялангач тәнгә накидка япты да ачык тәрәзәгә килде. Ах, һава тагы бозылган икән... Иртә белән мәдрәсәдән кайтканда нинди матур көн булмакчы иде. Хәзер тышта җил уйный, күк ачулы, чытык йөзле. Куе кара болытлар, салынкы корсаклары белән менә-менә шул минутта шәһәр өстенә түгелеп китәргә хәзерләнгәндәй, түбән иелгәннәр. Бакчадагы ялангач агачлар көзге ачы җилгә каршы, урманда адаштырылган җен баласы кебек, ыжылдап җылыйлар, шаулашалар. Ахшам караңгылыгы эчендә агачларның шулай, үзара кемнәндер шикаять итешеп утырганга охшаш әрнеп шаулашулары уңаеннан, аның зиһененә кичәге вакыйгалар, мәдрәсәдәге дулкыннар, тавышланулар низамнамәне күтәреп бәрү, полиция, гаскәр керүләр килә башлады.

Ләкин болар тиз үттеләр.

Менә бөтен бер атна инде ул Һаҗәрне күргәне юк. Өч мәртәбә үзе әйтеп чакырган йиргә күрешергә килә алмады. Кичә тәмам ышанып көткән вакытта асрауның китергән язуы тагы шөбһә катыш хафага төшерде:

– Ирем сизенә, шикләнә башлый, бугай, – ди. – Тирәмезне карчыклар белән тутырды. Аяк атлап чыгар хәлем юк, ни генә кылыйм соң, илаһым, – ди.

Ничек, кайдан, кем аркылы сизәр? Менә җиде ай инде нинди куркыныч минутлар килде, менә-менә эләгәләр, харап булалар дигән вакытлар булды. Ләкин һәммә эштә Аллаһ ярдәм биргән иде. Бу арада бит очрашканнары да юк, хатларны яндыра барам, ди... Кайдан белер?

Шул арада тагы Миһранның сүзе!! Бу эт авыз җасус, ни ди?

– Биш җитмәгән, алтынчыга кеше хатынын алдарга, харап итәргә тотынгансың икән!.. Нинди биш!.. Нинди алтынчы!.. Нинди алдау!.. Мин аны сөям, без сөешәбез, бу – алдау буламы?..

Тукта, мәдрәсәдә кем дә булса шундый сүз әйттеме? Кем дә булса Һаҗәр исемен телгә алдымы? Әллә барын да минем шөбһәчел хыялым гына уйлап чыгарамы? Юкса мин боларны төшемдә генә ишеттемме?! Юк, шөбһә итәргә мөмкин түгел, Миһран кичә тентү бетәр алдыннан мәсҗед бүлмәсендә ярым мәсхәрәле, ярым куркытулы тавыш белән шул сүзне әйтте...

Җиһангирның кичәге муаффәкыятьләренә[1] эче янгандыр этнең... Шәкерт арасында минем тәэсиремне бетерер өчен, ул серне ачкандыр... Танытырмын мин эт авызга үзенең кем икәнен!

Ул ялгыз түгел, янында берничә иптәше дә бар иде... Кайсыдыр көлә төшеп, ләкин ул да эчке агу белән җасусның сүзен куәтләде:

– Безнең Җиһангир, ди, һәр көн биш кызга хат җибәрә... Аларның һәрберенә: “Җаным, бәгърем, сиңа гашыйкмын, тик сине генә сөям, дөньяда тик синең өчен яшим, син булмасаң, якты дөнья кара кабергә әйләнә”, – дип яза. Һәрберсеннән шундый җаваплар ала, ди. Моңарчы Җиһангир тирәсендә койрык болгап йөргән казый да шунда тыгылды:

– Егет ул, безнең Җиһангир! – ди. – Һәр көн биш кызга хат яза, аларның һәрберсе белән күрешә... Гайнине азбар артында үбә, Маһруйны баскыч төбендә кочаклый, Миңҗамалны төнлә капка төпләрендә куенына ала...

Тукта! Тагы кайсы эте Җиһангирның матур кыз Бибиәсмага Самарда очрап, үзе Казанга барырга тиеш булдыгы хәлдә, кыз артыннан түбәнгә, Әстерханга китеп барганын, шунда нинди авырлыкларга төшкәнен сөйләде.

Менә көчекләр! Менә эт авызлар!! Кеше, теләсә, ун белән йөрер, теләсә, кыз артыннан җәһәннәмгә китәр – анда аларның ни эше бар?!

Болар бит инде һәммәсе үткән эшләр. Хәзер Гөлзифа да, Зәйнәп тә, Гафия дә, башка берсе дә юк, хәзер бөтен дөньяда хатын – тик Һаҗәр генә, тик ул гына!

Ләкин Җиһангир алар алдында акланырга теләмәде, теге йөземгә үрелеп тә, “әле яшь икән, эчкә зарарлы булыр” дип киткән төлке хикәясен уйлады да, кызганыч бәндәгә карагандай, югарыдан салкын карашлы бер караш ташлады:

– Ә сез, бичаралар, урамда күренгән һәрбер кызыл яулык артыннан чабасыз да, эләкмәгәч, гомер буена селәгәйләреңезне агызып йөрисез...

Чыннан да аңар күп хатын белән мөнәсәбәттә булырга тугры килә. Аның егет табигате, сылу йөзе хатын-кызга ошый*. Ул бу турыда үзе дә киң карый. Чынлап та берьюлы ничәсе белән йөрешкән, катнашкан, караңгы төннәрдә, качып, һәрбере белән кочаклашкан заманнары булды. Мәдрәсәи исламиягә килеп яши башлагач, юллар тагын киңәя төшкән иде.

Ләкин болар бар да үттеләр инде.

Һаҗәр килде – шуның белән бар да югалды.

Гүя кояш чыгу белән йолдызлар сүнделәр. Инде башкалар онытылган, дөньяда тик Һаҗәр калган иде.

---

[1] *Муаффәкыятьләренә* – уңышларына.

* *Г.Ибраһимовта*: охшый.

Ләкин усал телләр аны элеккеге Җиһангир итеп сыйфатлауда дәвам итәләр, кайбер якын иптәшләре дә аның хакында бу сүзләрне ишетеп:

– Тирә-якның кызлары белән йөреп, гавамны, бигрәк тә егетләрне, шәкертләргә дошман ясыйсың... Мәдрәсә иптәшләреңне каралыйсың... – ди башлаганнар иде. Җиһангир тагы кичә мәдрәсәдә сөйләнгән гайбәтләргә килде.

– Гоголь урамында бер бүлмә бирелә, бик матур яшь хатын да бар... Җиһангир, квартирыңнан күчмисеңме, – дип шаярганнар иде, икенчеләр, көлеп, бу сүзне эләктереп алдылар:

– Ә... әлбәттә, күч, Җиһангир!

Тагы кемдер:

– Егет ул, анарда Гыйбай каны кайный... Аларның бөтен нәселләре тирә-якта шуның белән мәшһүр... – дип, апасы Фатиха романы белән теге бабалары Исмәгыйльнең җитмеш яшендә вакытында уналты яшьлек кызны ябыштырып чыгаруы хакындагы гайбәтне сөйләп китте.

## XXXIV

Бу ике нәрсәнең бөтенләй үк төпсез түгел икәнен Җиһангир үзе дә белә иде.

Ул бик озын ак сакаллы көләч йөз Исмәгыйль бабасын бик аз хәтерли. Үзе үлгәч, аның өч яшьлек углы белән унтугыз-егерме яшьләрендә матур, яшь хатыны калды. Карт бу хатынны чынлап та аналарыннан качырып, ябыштырып чыгарып алганмы, әллә бу гайбәт кенәме – Җиһангир аны белә алмады, тик халыкта бу сүз бар. Усал телләр Исмәгыйль хакында уналты яшьлек Маһитаб белән булган эшләрен көлкеле күренешләрендә тасвир кылалар, бу көлкеләрнең һәрберен: “Егет ул, Гыйбай нәселләре!!” – дип нәтиҗәлиләр иде.

Моның күпмесе чын, күпмесе ялгандыр – Җиһангир аера алмады, ихтимал, һәммәсе дә уйдырмадыр, ләкин апасы Фатиханың романы бу инде чын гына түгел, монда Җиһангирның үзенең дә күп катышы бар. Шунардан балалыкның ул көннәре егетнең хәтерендә мәңге җуелмаслык булып киселеп кергәннәр иде.

Җиһангирның Саҗидә һәм Фатиха исемле ике апасы бар иде. Болардан кечесе Саҗидә яше тулар-тулмас кияүгә бирелде, зурысы – озын, ябык инсафлы кыз Фатиха исә бик күп еллар кызлыкта утырды.

Аңа күп яучы килә, ләкин ул һаман кияүгә чыкмый, һаман “утыра” иде. Чиләбе өязенә, зур базарлы авылга килеп яши башлагач, тирә-якның яхшы сатучыларыннан, имамнарыннан күп башкода тол карчык Фәризәнең маен-

каймагын, симез итен ашап китте, ләкин һәммәсе буш кул белән кайталар.

Фатиха һаман “утырып” кала иде.

Күп еллар “утырган”, күп егетләрнең башкодасын кире кайтарган менә шул Фатиха хакында халык телендә бик куркыныч гайбәт туа...

Гүя ул авыл егетләреннән кемнедер сөя, гүя һәрбер башкода килгән саен “бармыйм, бирмәңез” дип, анасына ялына, еглый. Фәризә карчык балаларын бик яратканга, кызының күз яшенә җиңелә, “алыш-бирешемез күп, чыгу зур, бу елга бирә алмыйбыз” дип кайтара, имеш... Гүя Фатиха үзенең сөйгән егетенең солдаттан калганын көтә, ләкин, бәхетсезлеккә каршы, егет һәр ел яшелгә калдырыла[1], ләкин кыз, саргайса, кипсә дә, шуны көтә, төннәрдә күп вакыт шуның белән саташа да, имеш, диләр.

Кайберәүләр тәфсыйлгә[2] дә керешә... Имеш, Фатиха егетенә чиккән яулыклар бирә... Имеш, егет тугайга куна барган йирендән таң алдында, авылга кайтып, Фәризәләр буендагы тыкрыкта атка менгән хәлдә көтә, шунда бик акрын гына сызгыра да төн буена зарыгып көткән Фатиха үзенең сердәш җиңгәсе Гыйлменур белән азбарга чыгалар... Егет белән кыз шунда кавышалар... Имеш, егет Фәризәләр турысыннан ястү вакытларында акрын гына җырлап үтеп бара икән, шуны ишетү белән кыз кулындагы самавырын төшереп җибәргән...

Фатиханың сабыр, кайгылы йөзе чыннан да саргаеп, кибеп баруы, уен-көлкегә катышмавы ил гайбәте өчен тагы зур материал, зур куәт булалар... Усал телләр шулай сөйли. Аналар үз кызларының шундый хараплыкка төшүеннән “Ходай сакласын” диешәләр. Иптәш кызлары исә Фатихага чыннан да бик авыр бәхетсезлеккә, куркыныч хәсрәткә төшкән адәм кебек мөгамәлә кылалар. Ул аларга чит, ләкин кызганычтыр. Йомшак күңеллелек күрсәтәсе, аңар бер сүз әйтәсе, аны җуатасылары килә... Якын ахирәтләр эч серен белергә, бергә кайгырышырга телиләр... Ләкин Фатиханың йөрәге ябык: анда ни бар – һичкем белә алмый! Сөяме, юкмы – моны дөнья белә алмаячак.

Кояш йөрүеннән туктар, бу – мөмкин. Ләкин Фатиханың авызыннан ул турыда бер сүз алу имкяннән тыш[3]. Илнең бу ачы гайбәте Җиһангирларның бөтен гаиләсен хафага төшерә. Агалары ачыктан-ачык Фатихага ачулы шелтә белән, усал күз белән карыйлар, каты сүз белән дәшәләр.

Анасы Фирәзә карчык хәйрәттә[4], авыр хәйрәттә. Шулай да ул кызына

---

[1] *Яшелгә калдырыла* – нинди дә булса сәбәп белән бер елга солдат хезмәтеннән азат ителә.

[2] *Тәфсыйлгә* – җентекләп аңлатуга.

[3] *Имкяннән тыш* – мөмкинлектән тыш, мөмкин түгел.

[4] *Хәйрәттә* – аптырауда.

ихтыярсыз авыру кебек кызганулы, шәфкатьле карый.

Бу вакыт Җиһангир тугыз яшьләрендә булыр.

Ил гайбәтен иң ачысын татучы ул иде.

Урамга чыкса, берәү белән талашыр, кычкырышыр хәл юк, хәзерләп әйтеп китереп басалар:

– Борыныңны бик күтәрмә!! Апаңның кем икәнен бел!

Һәр турыда иптәшләренең башыннан сикергән, кая гына барса, нинди генә уенга, нинди генә эшкә керсә дә, башында, беренчедә торган сабый Җиһангирга болар бик яман тәэсир итәләр. Ул ачуыннан, хурлыгыннан йир тишегенә керергә җитешә:

– Йа Ходай!.. Нинди зур хурлык!.. Нинди мәсхәрә, имеш, апаң егет сөйсен!! Имеш, апаң гыйшык булсын!! Ходаем, дөнья йөзенә ничек күреним!..

Ул үзен-үзе өзгәләргә җитешә, менә хәзер бер нәрсә алыр да барын ватып һәлак итәр...

Апасының егете авылның шәпләреннән. Матур, уенчак, үткен, җырчы, биюче, шәп гармунчы. Ләкин болар баланы куркытмый. Ул Закирдан үч алу, аны кыйнау, үтерү дәрте белән яна башлый.

Көз килә, никрутлар[1] йөри башлый. Закир белән Фатиха тагы да телгә төшәләр. Әллә кем күргән, имеш, Фатиха һәр көн үзенең егетен, тәрәзә ачып, янына кертә, имеш, егетне эләктергәннәр, ул, кесәсендәге барлык акчасын биреп, чак котылган. Җиһангирның түзәрлек чамасы калмый, ул көндездән карап, хәзерләнеп куя да, өйдәгеләр йоклагач, акрын гына өйнең очырмасына менә. Башка вакыт булса куркыр, аяк атлый алмас иде, ләкин аның хәзер хәтеренә дә килми. Ул озын көзге төннәрне шунда, өй башында – очырмада, апасына егет килгәнен саклап үткәрә башлый, янында адәм башы хәтле берничә таш... Егет киләчәк тә, Җиһангир шул таш белән югарыдан аның башын ярачак:

– Йөрмәсен, апайны хур итеп...

Ләкин Җиһангирга баш ярырга да, үтерергә дә тугры килмәде. Бер ел үтәр-үтмәс, ул апасын үзе үк яклый башлады.

---

Халык: “Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә!” – дип җырлый.

Җиһангирның кинәттән апасы ягына чыгуы да үзе аның хәленә төшүеннән булды. Аларның авылларында “көтүче Сафый” дигән картның, тугыз яшьләр чамасында булыр, кечкенә, ләкин гаҗәеп мөлаем, гаҗәеп

[1] *Дөресе*: рекрутлар – солдатлар.

моңлы алтын сары чәчле, җәнүб[1] күкләре кебек матур күгелҗем күзле Миңлекәй исемле бер кызы бар. Яше белән шунарга якын булган сабый Җиһангир бер вакыт күңеленең шул алтын сары чәчле кызга тартыла, үзе шул хакта уйлана башлаганын сизә... Шулар торган урынга барасы, Миңлекәй белән уйныйсы, аның күзләренә карыйсы килә... Бара... Хәйранлыкта йөри... Инде барып та очрата алмаса, җә кыз уйнарга теләмәсә, сабыйның күңеле төшеп, боегып кайта...

Чыдамый, тагын бара...

Миңлекәйнең зур кызларга ияреп суга киткәнен күрсә, кулына озын чыбык ала да, каз бәбкәләре эзләгән кеше булып, шунда, чишмә буена йөгерә... Миңлекәй, хатыннарга ияреп, урманга җиләккә бара икән – Җиһангир да, туз тубалын әләктереп, артларыннан чаба...

Шулай йөри, нидер аны Миңлекәйгә тарта, ләкин янына килсә, теле баглана, күзләре йиргә төшә, күтәрелеп карый алмый, сүз дә әйтә алмый... Бервакыт балалар чәчәк белән авырый башлыйлар. Бу Миңлекәйгә дә җитә. Күгелҗем күзле, алтын-сары чәчле моңлы кыз берничә көн эчендә караңгы гүр иясе була. Инде сабый Җиһангирга оят калмый, ул җылый-җылый Миңлекәйнең җеназасы артыннан йөгерә, халык моны күрә дә көлә, мәсхәрәгә ала башлыйлар:

– Кара, бусы да Гыйбай нәселе... Кара, бу да Фатиха туганымыни..., – диешәләр.

Үзенең романы башлану белән үк Җиһангирның апасына мөнәсәбәте үзгәргән, Закирдан үч алу дәрте ничектер үзеннән-үзе сүнгән иде. Миңлекәй үлеп, аның җеназасы артыннан җылап йөгерүеннән халык мыскыл итеп көлгәч, ул бөтен дөньяда апасы Фатихадан якын кешесе калмаган кебек хис итте. Һәм шул көн Фатихага:

– Апай, мин бүген синең яныңа ятар идем, – диде.

Үзенең тирән хәсрәтендә моңарчы ялгыз булган Фатиха, эчтән елмаеп, туганын куенына ала, һәм шул төндә сабый Җиһангир, апасының күкрәгенә капланып, эссе яшьләр белән озак-озак җылый:

– Абыстакаем, инде мин сине яклыйм... Мин абзыйлардан да сиңа тел тидертмәм... Мин инде Закирны да яратам, – ди.

Сердәш апасының куенында беренче сөю яшен түгеп, бергә аглашып үткәргән бу кичә ул мәгъсум[2] кыз белән Җиһангирның үткән гомере эчендә ниндидер бер илаһи нур илә балкып торган якты сәхифәләр булып калдылар. Аннан соң күп еллар узган, күп матурлар белән мөнәсәбәттә булган... Ләкин һичберсе ул төнне, ул алтын-сары чәчле, күгелҗем күзле көтүче кызын

[1] *Җәнүб* – көньяк.
[2] *Мәгъсум* – гөнаһсыз.

оныттыру түгел, бераз көләгәле дә алмаганнар.

Җиһангир кинәт урыныннан торды. Шөбһә юк, ул Һаҗәрне дә сөя... Сөелүенә дә ышана... Ләкин бу сөюнең биргәне бөтенләй башка... Монда агу белән ширбәт бергә катыш... Монда шатлык белән көенеч бергә баралар... Бу беренче сөелү кебек хыялый нур эчендә түгел... Беренче очрады, беренче күреште... Шулвакыт ул үзенең ихтыярсызлыгын, бу сөю белән янәшә үк кемгәдер һәлакәт, кемгәдер үлем барлыгын да сизде. Гүя йөрәккә агулы хәнҗәр тыктылар. Аны алырга көче юк, теләми генә түгел, аны үзе эчкәрәк батыра, хәнҗәр йөрәкнең төбенә төшә, агуы белән ихтыярны югалта, ләкин шул агуда ниһаясез[1] ләззәт тә бар. Ул үзе шуны тели... Шуңа сусый... Җиһангир буны сизә, ләкин ачык уйлый алганы юк иде, Миңлекәй хатирәсе аңа моны ачык күрсәтте.

Һаҗәр!

Миңлекәй!

Бу икенең арасында йир белән күк бар.

Егет Миңлекәйдән Һаҗәргә килде. Күгелҗем күзле мөлаем сабый – җәннәт былбылы, гареш[2] йолдызы. Һаҗәр дә гаҗәеп, ләкин ул йир чәчәге, матур, аһ нинди матур, ләкин йир чәчәге!!

Соңгы көннәрдә үткәргән авыр шөбһәле минутлары, Һаҗәрне күрә алмавы аның соңгы хаты Җиһангирның хәтереннән кичтеләр. Шулвакыт ул бөтен рухы белән үткән көннәргә, сабый Миңлекәйгә тартылды. Шул ерак хыялны кайтарасы, мәгъсум бала хәлендә аңар күз күтәреп карый алмыйча, алдында калтырап торасы килде.

Ләкин ул үткән иде инде. Яше егермеләрдән ашкан, эчендә пакь фәрештә белән кара иблис янәшә яталар.

Көн агъла! Төн агъла! Күз яшеннән томан күтәрелсен, ләкин ул мәгъсум көннәр кайтмаячак...

## XXXV

Бу вакыт кемдер Җиһангирның ишеген шакылдатты.

Марҗа икән:

– Мин театрга барам, чыксаңыз, ишекне бикләп, ачкычын яныңызга алыңыз, – ди.

Ул чыгуга, егет бүлмәсе буйлап бер-ике әйләнде, Һаҗәрләрнең бакча ашасыннан күренеп торган тәрәзәләренә озак карады, анардан килгән хатны яңадан бер укыды да, өстәленә килеп, тиз-тиз кулына каләм, кәгазь алды.

[1] *Ниһаясез* – чиксез.

[2] *Гареш* – күкнең иң югары катлавы.

Ул үзе ашыга, әгъзалары калтырый, кулы дерелди, йөрәге ташып бара, каләм тәртип итеп өлгерә алмый иде.

“Газизем Һаҗәр!

Бөтен дөньяга ләгънәт укып, бөтен галәмнең өстенә төкереп, һәммәсен күңелемнән чыгарып, бөтен изелүләрне, бөтен ачы, зәһәрле кайгыларны очырып, һичкемне бар дип белмичә, дөнья йөзендә миңа хаким, миңа баш тапмыйча, һичкемне үземә тиңдәштермичә, бер генә минут һаваланган, бер генә минут җаныма тынычлык алган, бер генә минут язмышка кол булмаган һәм дөньяда мин генә, үзем генә дип барчасына кул селтәгән вакытым – яңа ут алган, яңа гына бакчада шыбырдап яңгыр ява башлаган кичке сәгать җиденче заманы иде. Шул минутым, шул сәгатем кемгә тиеш? Моны кемгә һәдия итим[1], ни эшлим? Аһ, мин ни өчен сорыйм, ни өчен күңелемә шикшөбһә китерәм? Ни өчен вакыт сузам? Бер генә бит, бер генә һәм ул гына – бу минутым аңа булсын, ул хаким, ул курыкгучым: аның өчен булсын... бөтен фәләкләргә[2], барча мәләкләргә[3] алмаштыра алмаячак Һаҗәрем өчен булсын!!

Газизем, чыннан да күңелемә башка һич бервакыт булмаган бер хозур, бер дәрт, ашкыну килде. Үзем белмим... Үзем сизмим... Моның кайдан икәнен төшенә алмыйм...

Ләкин бөтенләй бушка, бөтенләй юкка булмагандыр... Барлык иптәшләрне, барлык яр, юлдашларны, бөтен мәләк, Аллаһларны уйлап утыра идем... Аллаһыга намаз укымаганга, пәйгамбәрләргә, фәрештәләргә салават әйтмәгәнгә, дустларга хат-хәбәр йибәрмәгәнгә, сиңа җавап кайтармаганга да бик озак, бик күп вакытлар булган иде... Мин шушыларны тикшереп, җон шикелле тапаган идем. Кайсын уйлап төкерә, кайсын нәфрәтләнә, кайсын атып чәнчелдерә идем... Ах, дидем, ах, берсе дә кирәкми, ах, мин, кайда каләм, кайда кәгазь дидем, бөтенесенә төкердем дә сиңа, бөтен дөньяга, күктәге бөтен ай-йолдызларга алмаштырмаячак син газизем, син сөйгәнемә, син Һаҗәремә хат язарга тотындым...”

Шул йиргә йиткәч, егетнең кулы үзеннән-үзе туктады. Каләм аның ихтыярыннан башка өстәлгә төште, ул нидер сизенгәндәй булды. Чү!.. тышкы ишек ачылды, бугай. Чү, кемдер сак, ләкин таныш адымнар белән моның бүлмәсенә якынлый. Егет һичбер вакыт сәбәбен аңлап җитә алмаячак бер сизенү, шул сизенүдән туган бәхетле ашкыну белән урыныннан торып борылырга өлгермәде, кинәт бүлмә ишеге ачылды, ул да хәйрәтеннән[4],

---

[1] *Һәдия итим* – бүләк итим.
[2] *Фәләкләргә* – җир-күкләргә.
[3] *Мәләкләргә* – фәрештәләргә.
[4] *Хәйрәтеннән* – гаҗәпләнүеннән.

көтелмәгән вакыйгадан шашып ката калды: бусагада – Һаҗәр иде. Бу – урта буйлы, тулы, ләкин җыйнак тәнле, килешле мөтәнасиб[1] әгъзалы, калку күкрәкле, бөтен торышында хәят, куәт кайнап торган егерме сигез яшьләр чамасы булыр бер хатын иде. Өстендәге яңа мода пальто аның гәүдәсенә аерым бер матурлык бирә, башында кара шәл астындагы кечкенә калфак аның ләтафәтен[2] тагы бер кат арттыралар. Йөзе алсу нур белән яна, бит алмаларында, иреннәрендә гаҗиб куәтле хатынлык дәрте, уены, күз карашлары бер үзенә чакыра, бер, йөрәгеңә төшеп, каныңны кайната, хәлеңне бетерә иде...

Җиһангир, ишек ачылып бусагада ул күренү белән, күзләренә ышанмады, "юк, булмас, саташамдыр, күземә күренәдер" дигән уй секунд эчендә аның башыннан кичте һәм шул секундта ук тагы үзен-үзе онытып, бөтен куәте белән ишеккә ташланды да:

– Аһ... Тәңрем... Аллаһым!.. Синме... синме? – дип, хатынның муенына асылды, кочакларына атылды. Шул йирдән кузгалырга тәкатьләре җитмәде, ишек янында ике җан беректе, ике тән, куәтле куллар белән уралышып, бергә эределәр, иреннәр атна буенча сусап яткан иреннәр, йөрәк төбеннән актык тамчы канны тартып алачак куәт белән бер-беренә суырылдылар, җотылдылар.

Һаҗәр берни дия алмый, тик сирәк-сирәк аның "аһ җаным... үләм" дигән хәлсез тавышы ишетелә.

Егет:

– Тәңрем, Һаҗәрем... Бер атна җиде көн түгел, җиде ел булды, – дип тәкрарлый, аның саен хатынның калку күкрәкләренә кысыла, эссе кочагына керә, онытыла бара иде. Шул халәттә бер-ике секундмы яки бөтен әбәдиятьме[3] үткәндер – алар белмиләр, бергә эри баралар, югала баралар, менә-менә тәкатьләре китеп егылачаклар иде.

Иң элек Һаҗәр искә килде.

– Йибәр, җаным, капка төбеңнән үтә алмадым... түзә алмадым, кердем... Ахирәтем почмакта көтә. Без берәүгә бирнә багарга китеп бара идек...

Хатын газап белән ишеккә якынайды. Аның калку күкрәге калтырый, иреннәре янып кипкән, күзләре агарынган, ләкин анда эчке дәрт, эчке ут ялтырый иде. Ишек тоткасына кулын салгач:

– Озатма, чыкма, җаным, шик төшерерсең, – диде.

Ләкин үзе китә алмый иде.

Озак кочаклашып, тагы шул хәлдә каттылар.

---

[1] *Мөтәнасиб* – тигез, туры килгән.
[2] *Ләтафәтен* – гүзәллеген.
[3] *Әбәдиятьме* – мәңгелекме.

Чыга башлады, ләкин һаман китә алмады, тагы кушылдылар. Тагы ишекне ачты, тагы, туктап, озак-озак үбештеләр дә Һаҗәр “аһ, соңга калам, эләгербез, харап булырбыз” дип, үзен бусагадан аша ташлады:

– Җаным, иртәгә ястүгә азан әйткән вакытта Монасиповларда бул!

## XXXVI

Кайбер табигатьләр сөю колы булып яратылалар.

Безнең каты шималь буларга бай түгел; татарның тупас, басынкы хәяты бу тойгыны яшьтән үк томалый – эшлә дә аша, аша да йокла, башка юк!!

Ләкин арада язмышның, хәятның бөтен таптауларына җиңелмәстәй куәт белән дөньяга килүчеләр була.

Һаҗәр – шуларның бере иде.

Ул җиде ел шулай сөйде. Җиде ел шул сөюен йөрәгенең төбендә яшереп саклады. Аның яшь, нурлы йөзе саргайды, күзләре эчкә батты, шунда да дөнья анардан “сөям” дигән сүзне ала алмады.

Ул – йомшак күңелле Сара карчыкның бердәнбер баласы, бердәнбер кызы иде. Ана гомерендә күп бәхетсезлекләр күрде, ире яшеннән үлде, җиде баладан тик шул Һаҗәре калды.

Аның хәятының бөтен мәгънәсе – кызы Һаҗәрдә иде. Тәңре Һаҗәрне алсын – аның өчен дөнья, хәят бетәчәк иде.

Шул ананың бетмәс-төгәнмәс сөюле һавасында, сөюле кочагында Һаҗәр иркә, иректе һәм бәхетле үсте. Матур курчак, бакчадагы зур кызыл чәчәк – аның яраткан юанычы иде.

Киң җәнүб сахрасында җитешкән кызыл гөл кебек табигый иркен үскән Һаҗәр җиде ел берәүне уйлады. Сигезенче елны шәһәрнең атаклыларыннан Кадыйр байга аны хатынлыкка сорадылар.

Бай яшь түгел иде. Инде аның Һаҗәргә яшьтәш диярлек угылы да бар иде. Ләкин карт байның матурлап төзәтелгән ак сакалы Һаҗәрне куркытмады. Ул анасының шатлыгына, үзенең аңына каршы уларак:

– Алса, барам, – диде.

Бай гакыллы шәрык карты иде. Матур, дәртле Һаҗәрдән дөньяны кызганмады, аны алтыннар, ефәкләр эченә күмде. Һаҗәрнең һәр теләге, үзе әйтмәс борын, йиренә җиткерелә торган булды.

Һаҗәрнең теләге – канун һәм куәт! Ни теләсә, шул хәзер: тик байны иркәләсен дә, дөньяда анардан башка ир затына күз салмасын! Һаҗәрнең һәммәгә югарыдан карый алырлык бикә мәртәбәсенә ирешүе күпләрнең эчен яндырды. Кадыйр байның аңа өйләнү хәбәре чыккан көннән алып, Һаҗәр тирәсендә моңарчы кузгалмый яткан гайбәтләр терелеп чыктылар, телдән-

телгә йөри, аны нindидер бер әкиятләрдәге кыз кебек сыйфатлый башладылар. Аның җиде ел дәвам итеп, җиде ел буена йөрәгенең төбендә саклап килгән сөюенең соңы хакында адәм ышанмаслык гайбәт таралды.

Гүя, иртәгә Кадыйр бай белән зөфаф булачак дип торган төндә Һаҗәр үзенең сөйгәнен чакырта да, аны караңгы төндә бакча як тәрәзә ашасыннан кертеп, таңгача янында калдыра:

– Сине җиде ел сөйдем, беренче кичәм сиңа булсын, – ди. Бу вакыт аның сөйгәне күптән өйләнгән, бала-чагалы, хатынлы, инде сакаллы да бер ир булган була.

Ул Һаҗәрнең бу эшенә хәйран кала, ник күптән белдермәдең, алай сөйгәч, мин сине көткән, сиңа өйләнгән булыр идем, ди. Ләкин Һаҗәр кул гына селкә:

– Аһ... ул кайда!! Мин аны теләмәдем... Мин ирексез идем... Сине онытырга теләдем. Төннәрдә елап чыктым... Җиде ел сөйдем... Җиде ел яшердем... Сине сөйгәнлегемне дөнья белү – миңа зур хурлык булачак иде... – ди. Бу гайбәт колактан-колакка йөреп, Кадыйр байга да ирешә. Ул ачуыннан хәзер, менә хәзер Һаҗәрне куалап чыгарырга, ялангач урамга ташлатырга карар биреп, өенә кайта...

Ләкин Һаҗәр шундый матур, шундый оста иркәли, шундый елмая ки, байның ачуы бу минутта эреп юк була, һәммә шөбһәләр, Һаҗәрне күрү белән, үзеннән-үзе оча.

Таза, куәтле тәннән тышкы авырулар тиз арада юк булган кебек, Һаҗәр тирәсенә уралган гайбәтләр дә, бара торгач, үзеннән-үзе беттеләр, югалдылар.

Ул һиммәтле, атаклы Кадыйр байның бикәсе...

Аның йөрәге ябылган, ул хәзер сөяме, юкмы – моны һичкем белми иде.

---

Бервакыт Һаҗәргә көймә белән киң елга ашасыннан чыгарга туры килде. Язгы көн, һава яхшы, йөрәккә сөю дәрте сала торган матур, бераз караңгыланып килгән ахшам вакыты иде.

Йөрәккә акрын-акрын гына йомшак куллары белән кагылган бу рәхәт минутлар Һаҗәргә нindидер хыялый бер төш халәтен биргәннәр иде. Шулвакыт ул куәтле бер карашның үзенә текәлгәнен сизенде. Янында ире бар иде, Йа Ходай, бу ни, дип куркынды, шулай да керфекләренең очы белән генә сөзеп, шул караш сизелгән якка күз салудан үзен тыя алмады.

Бу – чибәр киемле, сызылып килгән мыеклы, мөлаем карасу бер егет иде.

Хатын нидер хәтерләгән кебек булды:

– Тукта... Мин соң бу егетне кайда күргән идем... Егетне кайчандыр, кайдадыр күргәнен Һаҗәр бер вакыт хәтерли алмады. Әмма шул көннән соң урамнарда, почмакларда, бакчаларда, капка төпләрендә аны бик еш очрата, шул куәтле карашның ерактан үзенә текәлгәнен күп вакыт хис итә башлады...

Бер көн ахирәтләре белән театрга барганнар иде. Шунда уйнаучылар арасында аңар охшаш, кем белә, әллә тагы шул үзе үк булган бер егет күрде.

Берәр айдан соң ул Һаҗәрләрнең төньягындагы бакчалы кечкенә өйдә күренә башлады. Ахрысы, шул өйнең бакчага караган бүлмәсенә квартирга күчкәндер. Анда элгәре калын җилкәле бер адәм – шәкертме, хәлфәме тора иде, хәзер ул юк. Бу, күрәсең, шуның урынына кергәндер.

Ничектер бу егетнең хыялы һичбер сәбәпсез үк башына килгәли, мондый вакытларда ул ихтыярсыз:

– Тукта... бу кем? Мин аны әллә кайчан, бик күптән, кайдадыр очраткан кебек булам... Ул егет миңа бик якын шикелле тоела... Тукта, ул кем булыр соң?! – дип уйлана башлый иде.

## XXXVII

Кадыйр байга хатын булганнан соң үткән әүвәлге еллары, ничектер, тыныч, рәхәт кичкәннәр иде.

Зур таш биналар, яхшы атлар, кыйммәтле ефәкләр, алтыннар, зур байның кадерле бикәсе булу мәртәбәләре – аз түгел иде. Тик менә соңгы елларда йөрәктә нидер кузгала, эчтәге моңарчы басылып яткан табигать уянырга башлаган кебек бер минутлар булгалый.

Байның бу йортка килеп йөри торган яхшы приказчикларыннан Фәхри бар. Таза тәнле, ачык йөзле бер егет. Ул Һаҗәргә дәртен бик суза, бугай, ничектер, шулай сизелә. Байның үлгән хатыныннан Йосыфҗан исемле угылы бар. Ләкин ул «әни» ди, «әнкәй» ди.

Кая барсаң, кая чыксаң да, ирләр, егетләр очрыйлар. Күпләре күз кыса, каш сикертә... фу, тәрбиясезләр. Кайберләре Һаҗәрнең тәненә, тәненең иң яшерен йирләренә үтә төшкән бер караш белән аңа карыйлар... Менә шулар, ничектер, куркыныч. Шул карашлардан Һаҗәрнең эчендә нидер уяна, кан кызулана, чигә суга башлый...

Менә көймәдә очраган теге егет тагы куркынычрак тоела башлады. Һаҗәр куркына һәм аптырый. Гомер шулай үтәрме? Ничек, бөтен гомеренчә шулай калырмы...

Тукта, байның угылы Йосыфҗан ничек дөньяга килгән? Үлгән хатын бик суфый нәрсә... Аның хакында андый-мондый сүз дә юк... Әллә юкса,

Кадыйр бай ул заманда ир булганмы?.. Кем белә тагы, карт хатын да фәрештә түгел, кем белә тагы, Йосыфҗанның атасы әллә бөтенләй башка кешедер... Моңарчы ничек күрмичә йөргән, Ходаем, Йосыфҗан бит атасына аз гына да охшамый... Төсе генә түгел, һичбер йире: холкы, сүзе, тавышы, буе – һичбер йире атасына якын да килми... Ходаем, ул хатынның яшь заманы булгандыр... түзмәгәндер... гөнаһ кылгандыр... Ходаем, кем түзсен, хатын булып яратыл, гомергә ир кочагында ят та, һичбер мәртәбә хатынлыкны белмә!!

Карт хатын Фәрихә дә шундый авыр төннәр кичердеме икән? Ходаем, гомер үтәрме!! Илаһым, түзем бир, сабырлык бир!!. Тәрбиядә, наз, нигъмәт эчендә торган яшь кан таша, яшь йөрәк нидәндер сорый, каядыр чакыра, нидер тели, тели, тели, куәтне бетереп, сабырыннан язып тели!! Шундый тели, шундый кайный, артык түзәргә тәкать бетеп, шундый минутлар килә ки, Һаҗәр мышнап яткан ул сакаллы «хатын»нан, аның җонлы беләгеннән этелеп чыгасы да шул яланбаш көе урамга йөгереп чыгып, анда иң беренче күзгә күренгән ирне кочагына аласы, яшьлекне татыйсы килгән түземсезлеккә төшә...

Менә язлар килә, дөнья яшел хөлләгә[1] төренә, һәркайда яңа хәят хис кылынып, табигать йөрәге яшь сөю дәрте белән тибә башлый... Төннәр, төннәр, аһ, бу язгы төннәр! Ялкынлы бер үбешү, сөйгәне кочагында мәсгудиятьле[2] бер минут үткәрү – Ходайа, моның өчен мәңге үкеним, мәңгелек җәһәннәмгә сал, ләкин шуны бир, миңа шул минут сәгадәтне насыйп ит! – Һаҗәр менә шул хис, шундый дәрт белән исергән, ихтыярын югалткан минутларның бере иде.

Ястүгә азан ишетелде. Ире Кадыйр бай, соңга калдым, бугай, дип, ашыга-ашыга тәһарәт алды да мәсҗедкә китте.

Һаҗәр яшь канның ташуыннан, язгы кичләрнең тәэсире илән йөрәк ашкынуыннан башын кая куярга белмәс бер халәттә иңенә кара шәлен салды да бакчага караган тәрәзә төбенә килде.

Килсә – ай яктысында агачка сөялә төшеп, теге егет тора, хатын коелып төште. Күптән хис ителеп йөргән һәлакәт менә килде, каршы торырга тәкате булмаган бер куәт, яшь йөрәк дулкыны аны каядыр эләктереп алып китте.

Һаҗәр дә, ни эшләгәнен белмәс бер хәлдә, егеткә башы белән урамга таба ишарә кылды.

---

[1] *Хөллә* – чапанга охшашлы җиңел өске кием. Бу урында: *табигать яшел киемгә төренә* мәгънәсендә.

[2] *Мәсгудиятьле* – бәхетле, рәхәт.

Җиде ел дәвам итеп, җиде ел яшерелгән әүвәлге сөюнең хәзер тик хатирәсе калган, шулай сөя белгән кыз Һаҗәр инде каядыр күмелгән иде.

Халык гайбәтендәгечә, теге караңгы төндә, бакча ашасыннан кертеп, үзенең беренче кичәсен һәдия кылганнан бирле[1] сөю өчен ябылган йөрәге яңадан ачылды.

Ләкин Һаҗәрнең бу сөюе – башка иде. Аның бу сөюе – йир сөюе, тән сөюе иде. Инде бусын үзенең сөйгәненнән яшерергә кирәк тә – теләми, анарга куәте дә җитмәячәк иде.

## XXXVIII

Күп вакытлардан бирле янып йөргән Җиһангир, Һаҗәрнең "урамга чык" дигән мәгънә белән баш селкүен күргәч, башта күзләренә ышана алмады, бу Һаҗәрме, хыялым түгелме, дип уйлады. Ләкин аңар уйлап торырга да юк иде инде. Алдында җәннәт ачылып, шуңар ашыккан адәм кебек, аның аяклары үзеннән-үзе урамга атылдылар.

Ул шулай кызуланып капкадан чыкты да кыйблага таба бара башлады. Анда ике йорт аша аптек бар. Һаҗәр үзенең гади һавалы йөреше белән, салмак атылып, шул аптекка керде.

Егетнең йөрәге суга, аяклары атылып барырга телиләр, чигәләренә кан һөҗүм итә иде. Башта аптырый калды, ни эшләргә? Ләкин ник уйлый – бәхет кошы килә, барып тотасы гына! Ул, Йа Ходай, үзеңнән ярдәм, үзеңнән куәт дип, Һаҗәр артыннан аптекның ишекләрен ачты. Хатын нидер ала иде. Егет тә актык акчасына, җүнләп кирәге булмаса да, алтын пинсәне[2] сорады. Аның тезләре калтырый, теленә сүз килми, ул өч яшьлек кыз кебек, аңар күтәрелеп карарга куәте җитми иде. Үзе: "Чыгып китә, ахрысы, бер сүз дәшә алмый калам инде тагы, Ходаем, бир батырлык", – дип коты очып бара иде... Ихтимал, шулай калган да булыр иде, ярый Тәңре аның ярдәменә җитеште. Хатын үзенең шул һавалы кузгалышы белән кассага акча түләргә баргач, егеткә бик аз гына да борылмыйча, ярым шелтәле, ярым кызганырга теләүле, ләкин ниндидер ихтыярсызлыкны аңлаткан бер тавыш белән:

– Сез ник минем артымнан йөрисез болай... Мин бит кеше хатыны... – диде.

Инде дөнья егетнеке иде. Гомумән, аңар хатыннар белән мөнәсәбәттә беренче сүз, беренче адым мөшкил. Ул булса, егет үзенә, үзенең җиңәчәгенә ышана... хатын сүзен әйтеп бетмәде, егет аңа таба бер генә атлады, аның

---

[1] *Һәдия кылганнан бирле* – бүләк иткәнннән бирле.
[2] *Дөресе:* пенснене.

күзләренә йотылып керердәй йотылып карады да каушап ашыгып сөйләргә тотынды:

– Гафу итегез... сез кемдер... кем хатынидыр, мин белмим... белергә дә теләмим... мин йөрмим сезнең... мин … мин ихтыярсыз...

Хатын аңар әйләнде. Йөзе авыр, җитди. Күз карашы, инде Ходайга тапшырдым, ни булса, шул булыр, ди иде. Тавышы исә тагы да ихтыярсызрак иде:

– Уң якта... беренче капкадан кер дә мине шунда көт!..

Егеткә гүя җәннәт ачкычы тоттырдылар. Ул хатынга баш иде, нидер әйтте дә тышка очты. Хатын әйткән йир бер ташландык йорт икән!

Һаҗәр тиз чыкты. Аның йөзе һаман шелтәле, җитди, ләкин күзләрендә эчке ут кабынып килә иде инде. Гадәтенчә, калку күкрәген бераз киергән, башын артка салган, тулы, килешле тәне, киберле[1] йөреше уңгаена бик аз гына саклана, ләкин бөтен торышы көрәшергә теләгән эчке бер куәт белән тартылган кебек хис ителә. Егеткә якын ук килде дә, кинәт йомшарып:

– Ходай хакы өчен мине куегыз... Мин харап булам... Мине ташлагыз... Мин бит кеше хатыны! – диде.

Ләкин ул актык сүзе әйтелеп беткәндә, егетнең кочагында иде инде. Җиһангир күп кайгы, күп шатлык күрде, төрле мөнәсәбәтләр тәэсирендә төрле минутлар кичерде. Ләкин Һаҗәр белән бу ташландык йортта беренче күрешүләре башка һичбер хәлдәгегә охшамый иде.

Гүя аяк баскан йир каядыр шуды, гүя дөньялар бары бергә буталып, зиһен тирә-якны аермас булды. Шул дәрәҗәдә ки, ахырдан ничаклы тырышса да, ул үзенең Һаҗәргә ни дип җавап биргәнен, аннан соң ниләр булганын һичбер вакыт яхшылап хәтеренә китерә алмады.

Тик җәйге төннәрдәге хыялый төшләр кебек Һаҗәр аның муенына сарылуы, соңра һәр икесенең ихтыярлары югалып, хатын аның күкрәгенә кысылулары, ниндидер алсу томан эчендә күренеп калгандай булалар да, әллә кайдан, ерактан, түбәннән, ут эченнән килгәнгә охшаш бер тавыш белән Һаҗәрнең:

– Аһ... кеше килеп чыгар... эләгербез... харап булырбыз... – дию е, шуннан соң икесенең дә хәлсезләнгән көендә икесе ике якка аерылып китүләре генә күптәнге төш кебек аның исенә киләләр иде.

Шул очрашудан соң, алар бер-берсе өчен, бер-берсе белән яши башладылар. Ул очрашудан бирле алты-җиде ай гомер үтте. Үткән һәрбер көн егеткә Һаҗәр табигатендәге гаҗиб якларны ача, хәйран итә бара иде. Ләкин бүген аның квартирына килеп керүе – Җиһангир өчен чынында

---

[1] *Киберле* – һавалы, тәкәббер.

могҗиза иде.

Ул бу квартирга Һаҗәр өчен күчкәнен, монда әүвәл торган Нигъмәт казыйны нинди хәйләләр белән алдап чыгарганын берничә мәртәбә хикәя кылса да, кайчан да булса Һаҗәр аның бүлмәсенә килә алыр дип өмид итми, буны кыюлыкның аргы ягында саный иде.

Куркыныч караңгы төндә болыт чыга. Дөнья мөҗәссәм[1] каралык булып китә, адәмнәр юлларыннан язып, хәйранлыкта калалар. Шулвакыт яшен яшьни, йир күкне ялтыратып яктырта да шунда ук тагы юк була, тагы каралык эчендә калына.

Һаҗәрнең көтелмәгән, өмид ителмәгән бер вакытта аның бүлмәсенә кереп, бер-ике минуттан тагы чыгып юк булуы Җиһангирда шуңар охшаш тәэсир калдырды. Әле генә караңгы, авыр, басынкы, кайгылы иде. Ишек ачылды. Калфаклы матур хатын бусагада күренде, шуның белән дөнья яктырды, җан илаһи нур белән тулды. Йөрәк шатлыгыннан ярылачак бер халәткә килде. Ләкин болар һәммәсе бер-ике секундта булып үтте.

Инде бүлмә тагы буш, тагы караңгы, инде бакчада шыбырдап яңгыр яуганы, тышта көзге җилнең җылавы ишетелә иде. Ләкин болар җанга керми, йөрәккә һичбер нәрсә сөйли алмыйлар иде.

Һаҗәр килде!

– Иртәгә ястүгә азан әйткән вакытта Монасиповларда бул!! – диде. Бу булгач, башка һәммә нәрсә әһәмиятсез, вак-төяк һәм тәэсирсез иде.

## XXXIX

Икенче көнне Җиһангир ахшамнан ук киенеп чыкты да, мәсҗед буенда йөреп, ястүгә азан әйткәнне көтә башлады.

Заман, гүя туктаган иде. Ул мәсҗеднең якынында ук йөрсә дә, бүген мөәззин азан әйтмәс, җә, әйтсә дә мин ишетми калырмын дип, шөбһәгә төшә иде.

Йа Ходай, мәсҗедтә фарыз бүлмәсендә ут күренде. Димәк, ястүгә килә башладылар... Әнә манарада ниндидер карачкыл бар. Күзгә күренәме, әллә чыннан мөәззин менгәнме? Егет, мөәззиндер дип уйлап шатланып та җитә алмады, азан ишетелде: “Аллаһу әкбәр... Аллаһу әкбәр...”.

Мөәззин азан әйтеп бетергәндә, егет Монасиповларның капкасы төбендә иде инде.

Монасипов – зиярәт мәхәлләсе мәктәбендә мөгаллим. Кадыйр бай тарафыннан тәрбияләнә торган бу мәктәпкә мөгаллимлек урыны аңа хатыны Фатиханың үтенүе буенча, Һаҗәр тәэсире илә бирелгән, тагы берничә яктан

[1] *Мөҗәссәм* – зур, мәһабәт.

да Һаҗәрнең аларга файдасы тия, шунлыктан болар Һаҗәр кулындалар иде.

Җиһангирның Һаҗәр белән көрәшү өчен монда килүе беренче түгел иде. Ул, гадәт буенча, арткы як капкадан акрын гына керде дә кечкенә тәрәзәгә чиертте. Өйдәге ут ишеккә таба кузгалды. Эчтән сак тавыш ишетелде:

– Мин, акыллым, мин...

Ишек ачылды. Анда Һаҗәр иде:

Үзең дә егетсең... Минутын яңлыштырмый киләсең... Мин азанны тыңлап тордым...

– Мин ахшамнан бирле көтеп йөрим... Котым очты, бүген азан әйтмәсәләр, ни эшләрмен, дим.

...Чолан үтә эчкә керделәр.

Бай түгел, ләкин бары белән пөхтә генә җыештырылган кечкенә квартир. “Залда булса, тәрәзәдән утны күрәләр”, – дип, Һаҗәр Җиһангирның тәгаҗҗебенә[1] каршы, туры, тәрәзәсез, киң караватлы ятак бүлмәсенә алып керде. Хатынның өстендә тулы тәненең һәммә сырларын үтә күрсәтеп торган нечкә тик бер кат алсу күлмәк, башы ялангач, кулары көйдереп бара, иреннәре кызарып уйный; йөзе-күзе эчке ут белән яна, ләкин тавышы акрын, сүзе, мөгамәләсе, киявен каршы алган назлы кызларныкыдай, бөтен торышы дустча, иптәшчә тәкәллефсез[2] иде.

Кадыйр бай мәдрәсәдәге вакыйганы сөйләп өлгергән булырга кирәк. Һаҗәр, лампасын шундагы кечкенә өстәлгә куеп, беренче үбүдән, беренче кочактан айну белән, кулын егетнең муенына салды. “Бик сагындым, төннәр бик артык озын шул, илаһым”, – дип, аның күзенә карады да мәдрәсә вакыйгасын кузгатты:

– Кара әле... син анда ни эшләдең? Ирем, синең исемеңне телгә алып, нидер тиргәнде. Җиһангир, үзенең андагы ролен мөмкин кадәрле югары, якты һәм беренче урында күрсәтә төшеп, ләкин кыска рәвешчә мәдрәсә ихтилялын, низамнамә ватуларны, полиция керүен, тентүләрне сөйләде. Һаҗәр аның күзләренә текәлеп тыңлый, ләкин сүзләрен аңламый, тик егетнең көмештәй шыңгырдап аккан саф ачык тавышын ишетә иде. Ләкин сүз кирәксез хис кылына иде. Һаҗәр кинәт нидер хәтерләгән адәм кебек, егеттән кулын алып, залга чыкты, аннан, ишеккә барып, элгечне тартып карады да яңадан килде. Ул бүген гадәттәгедән дә артык дулкынлана, сабырсызлана иде. Залдан кергәч, Җиһангир аны кочагына алырга өлгермәде, Һаҗәр ут кебек яндырып барган тулы тәне белән егеткә кысылды да:

– Аһ, белсәң... белсәң..., – дип, аның йөзеннән, күзеннән, иреннәреннән

---

[1] *Тәгаҗҗебенә* – гаҗәпләнүенә.

[2] *Тәкәллефсез* – тартынусыз.

башка һичбер вакыт булмаган кызулык белән үбәргә, үзеннән, акылыннан югалып кочакларга тотынды...

Бу вакыт Һаҗәр бөтенләй башка, бөтенләй икенче иде. Егет менә гомеремдә бер хатын күрәм дип хис итте.

Минут үтте, ялкыны белән яндырып барган Һаҗәр бөтенләй изрәп, хәлсезләнеп төшүе, аның кан йөрүенә кадәр сиздереп торырлык мәртәбәдә нечкә күлмәк эчендә үзеннән-үзе дулкынланып, янып торган тулы тәне гаҗиб тиз суынды, йөзе агарынды, күзләре хәлсез карый башладылар.

Ул үткәнне уйладымы, бу минутларның яңадан килмәвен, иртәгә аны зур һәлакәт көтүен сизендеме – нидер булды, ул бөтенләй үзгәреп, томан арасындагыга охшаш бер караш белән егеткә озак-озак текәлде, шуннан, кинәт торып, киенергә тотынды.

Ләкин киенеп тә бетә алмады, яртылай киенгәч, яңадан хәлсезләнеп, тузган чәчләре белән егетнең итәгенә чалкан төште. Җиһангир борчыла башлады:

– Җаным, ... ни булды?.. Ни булды?.. – дип иркәләп, аны кочагына алды.

Һаҗәр бер сүз дә әйтмәде. Җавап урынында куллары белән егетнең муенына сарылып, яңакларын аның күкрәгенә куйды. Бервакыт аның күзләре яшәрәләр, эре бөртекле яшь тамчылары төшәргә керфек очына килә башлыйлар иде.

Җиһангир хатынның йөзен якын алды, иреннәре юлыктылар, егет белән Һаҗәр дөнья беткән, хәят туктаган диячәк бер тынлык халәттә катып калдылар.

Ләкин бу минут кыска булды.

Бай утарга киткән, иртәгәсез кайтмаячак, болар бүген озак бергә булырга өмид итәләр иде, ләкин насыйп түгел, имеш. Алар бер-беренең кочагында дөньядан ваз кичкән хәлдәләр икән – тегеннән кемдер тәрәзәгә чиертте, Һаҗәр кинәт егетнең кочагыннан читкә ташланды: “Йа Ходай, бу кем булыр?”.

Ишеккә барса, анда мөгаллимнең хатыны Фатиха икән:

– Байның ике приказчигы белән бер шәкерт өч мәртәбә безнең тәрәзәгә карап уздылар, хәерле булмас, Һаҗәр, – ди.

Тиз-тиз киенделәр. Һаҗәрнең йөзе үлде, иреннәре катты, күзләре дәһшәт белән агарындылар.

Болар чыкканда Фатиха ишек төбендә иде:

– Приказчиклар янындагы шәкерт теге Миһран дигәнеңез, бугай, – ди. Ул Һаҗәрне күрше рус йорты ашасыннан озата китте, Җиһангир урамга чыкты. Яңгыр туктаган, күк ачылган, төн аяз, ләкин үтә караңгы иде.

Егет акрын, хафалы һәм авыр йөреш белән бакча ягына китте. Ул күп куркынычларга җан биреп, каршы барудан тартынмый, шуңа күрә юк-бардан каушап калмый торган иде. Ләкин бүген йөрәгендә ниндидер бер һәлакәт сизенгәндәй була. Ике приказчик, өченче мәдрәсәдә Миһранның инде алтынчы харап итәсеңме дигән сүзе, шул җасус этнең бүген приказчиклар белән монда искәнеп йөрүе – болар якты күк йөзендә төн ягыннан күтәрелгән кара болытлар иде. Бу болытлар һаваны үзгәрткән кебек, яшь, үлем, һәлакәт килгән кебек булды.

Җиһангир үзе өчен каушамый. Аңа дөнья – Һаҗәр. Ләкин Һаҗәр ил гайбәтеннән, халык теленә төшүдән артык, бик артык курка, роман дөньяга фаш була калса, ул үзен мәңгегә һәлак булган итеп хис кылачак... Аның хәяты җәһәннәмгә әйләнәчәк. Ничек итеп аның язмышына җиңеллек бирергә мөмкин? Аңа ничек аңлатырга мөмкин ки, ул халык сүзенә, ил гайбәтенә төкерсен!! Аңар ничек төшендерергә мөмкин ки, безнең өчен хәяттә иң мөһим – сөю!

Бу бармый. Без сөябезме?! Башка һәммә нәрсә вак, түбән: халык чәйни, куркыныч гайбәтләр туа, Кадыйр бай аерамы – һичберенең бер тиенлек әһәмияте юк. Дөнья бар, хәят бар, без яратышабыз, димәк безнең сәгадәтемез камил. Кадыйр бай аера икән, бу безне мәңгегә берләштерәчәк, без бергә якты, матур, мәсгудиятле хәят белән яши башлаячакмыз!.. Дөньяда сөймәү – һәлакәт. Ике җан бер-берсен сөяләр икән, алар ил гайбәтенә, халык сүзенә югарыдан төкерергә генә тиешлеләр...

Ләкин Һаҗәр – хатын! Ул буны аңлармы? Дөньяда сөюгә каршы торып та җиңелмәячәк һичбер куәт юклыкны төшенеп җитә алырмы? Шөбһәсез, аларның романы дөньяга фаш була! Ходай белсен, моннан нинди нәтиҗә чыгар?! Хода белсен, иртәге көн Һаҗәргә ниләр китерер!!

## XL

Шул уйлар белән бакчага җитеп, керергә дип борылса, аннан Давыд Урманов белән Баязид чыгып киләләр. Үзләре арыганнар, өстләре чыланган, Давыдның чиркәс бүрегеннән тамчылар тама.

Ул, Җиһангирны күрү белән, аңа дәште:

– Менә үзе дә! Без әле сиңа бармакчы идек... Урманда эшчеләр җыенында булдык... Син һаман гыйшык артыннан йөрисең. Сине һичбер эштә күргән юк. Җиһангир, зинданнан чыккан[1] соң, Баязидны күрмәгән иде. Урмановка:

– Ну, нихәл иптәш... Сине гаҗәп сагындым... Кайчан чыктың, үзеңне

[1] *Дөресе:* чыкканнан соң.

бик пешермәделәрме? – дип, үзенең сагынуын, зинданга берничә барса да, кертмәүләрен, ул булмагач, “фидаиләр” эше бөтенләй тукталып калганын сөйләргә, зиндандагы хәятны сорашырга тотынды.

Ул гүя Һаҗәрне бөтенләй онытып, шул мәсьәләгә бирелгән иде инде. Өчесе бергә, бакча буйлап, югары таба юнәлделәр.

Урманов Кадыйр бай приказчиклары хакында сөйли башлады. Күптән бирле төрлечә телдә йөргән бу егетләр, ниһаять, теләгәннәренә ирешкәннәр: егерме биш приказчиктан уникесе, сораганнары бирелмәсә, яңадан бармаячак булып, эш ташлаганнар.

Бу – соңгы хәбәрләрнең иң яңасы, барысы өчен дә иң мөһиме иде.

Ләкин Җиһангир монда туктый алмады, шул хәбәр мөнәсәбәте белән аның хәтеренә икенче нәрсә килде:

– Мин бүген теге Габдрахманны күргән идем. Ул, өйләнәм, Нәфисәне алам, ди. Бу ничек, Давыд, расмы, мин ышанмадым...

– Рас булыр, Нәфисәдән хат бар иде, ул да шулай, ди.

Җиһангир ярым хәйрәт белән Давыдның күзләренә карады:

– Ә соң син?!

– Миңа ни булсын!!

– Ни булсын түгел, ләкин мин сине аңлап җитә алмыйм... Син бөтенләй чит бер нәрсә кебек сөйлисең.

– Соң ни эшләргә кушасың, Габдрахман өйләнә дип җылыйммыни?

– Мәсьәлә Габдрахманда түгел, Нәфисәдә! Ул бит сине өч ел көтте, диләр. Син моны үзең дә беләсең...

– Беләм, бик беләм... Мин аны бәхетле итәсем килә, аның бер тамчы яшен күрү дә миңа авыр. Ләкин “ул көтте, ул начар иргә барып, бәхетсез була” дип, минем бүгеннән аңа өйләнеп, балалар ясый башлаудан меңнәрчә чакрым ерак икәнемне син үзең дә аңларга тиеш...

– Соң, мөнәсәбәт!!! Өчьеллык сөю!!

– Ни эшлим, иптәш, анардан көчле нәрсәләр бар.

– Син – таш йөрәксең, иптәш!

– Бәлки, шулайдыр.

Давыдның бу сүзе Җиһангирга Һаҗәрне хәтерләтте. Менә аның өчен Һаҗәр – бөтен хәят. Һаҗәрнең аяк астына ул барлык дөньяны ташларга хәзер. Урмановка каршы җавап урынында аның теленә бер мөнәсәбәт килгән иде, Баязид карый булгач, кире тукталды. Ул үзенең Һаҗәргә мөнәсәбәтен Давыдтан башка һичкемгә белдерми иде.

Баязид карыйның хәяты романнардан мәхрүм. Ул шул яшькә җитеп,

хатын-кыздан һич берәү белән мөнәсәбәттә булганы юк, бу бабта[1] үзен бөтенләй чит, хәбәрсез саный иде, шуңар күрә Җиһангирларның сүзенә катышмады.

Аларның сүзе беткәч, кесәсеннән татарча гәзитә чыгарды:

– Давыд, укыдыңмы? Монда сине бик пешергәннәр...

Урманов, чебен каулагандай, кулын селекте:

– Укыдым. Кадалсынчы барлык милләтче чуашлары!!

– Җавап язасыңмы?

– Яздым, иртәгә чыга.

Бу вакыт бакчаның төньяк почмагына килеп җиткәннәр иде инде. Урманов як-ягына йалт-йолт каранды да чалбар кесәсеннән күк кәгазьгә төрелгән кечкенә бер револьвер чыгарып, Җиһангирга бирде. Ул тиз генә эчкә, култык астына тыкты. Егетләр аерылышачак булды.

Яшьләр тарафыннан “Кызыл байрак” исемендә сул журнал[58+] чыгарылырга уйлана. Бүген Акчулпановларда шул хакта киңәш булачак. Рауза: “Төндә ялгыз баруы кыен. Үтешли миңа кереп чыгыңыз, бергә барырмыз!” – дигән иде.

Давыд иптәшләренә кул бирде дә туташның квартирына таба китте. Җиһангир белән Баязид карый бакчаның зур агачлары арасына кереп, куе караңгылык эчендә юк булдылар.

## XLI

Мәдрәсәдән чыгу да, чыгарылу да булмады.

Ихтиляльның, тентүнең өченче көнендә үк, ярым-ярты булса да, дәресләр башланып, хәят тагын үзенең иске эзеннән китәр төсле тоелды. Ләкин бу тышкы яктан гына шулай иде. Эчтә исә нидер җимерелгән, нидер һичбер төрле ябыша алмаслык булып купшыган иде. Хәлфәләр дәрескә керә, ләкин аларда әүвәлге дәрт юк, шәкерт тә үзенең ни хәлдә, инде ни эшләргә тиеш икәнен аерып җитә алмый, ярым аптырау халәтендә.

Низамнамәнең ватылган пыяла кисәкләрен чыгарып түктеләр. Ләкин аны, яңадан шундый ук пыяла эченә салып, яңадан алтын рамкалар белән диварга асу, ничектер, гаҗәп тоелачакмы, килешсез булачакмы кебек күренде. Ул, төрелеп, кәнсәләрия өстәленең яшел постауы астына тыгылды! Мөдәррис, мөгаллимнәр, назыйрлар – һәммәсе шәкерт белән нинди мөгамәләдә булырга аптыраган рәвештәләр. Бөтенләй ирек бирсәң, эштән чыгарачаклар, тыярга, каты куллы булырга куәт юк. Шәкерт исә, көтүчесе егылып калган көтү кебек, һәрбере үз юлы белән йөри, үзе теләгән якка китә

[1] *Бабта* – өлкәдә.

башлады.

Назыйрның тәнбиһләренә[1] сызгыралар, ул низам, канун ди икән: “Ул ни дигән сүз? Син аны Кәрим Гайфигә сөйлә!”– дип кычкырып көләләр. Дәресләрдә шәкертнең яртысы да булмый.

– Садыйк кая?

– Белмим.

– Заһид кая?

– Белмим.

Дәрескә кермәгәннәр хакында шул “белмим”нән башка җавап булмагач, мөгаллим каршыдагыларны тыңлата башлый. Бик артык юаш берике бичаралардан башкалары дәресне хәзерләмәгән. Остазның соравына каршы:

– Кичә җәмгыять булды, дәрес артыннан утырырга вакыт тапмадым, – ди. Мөгаллим бик зур иттереп, 1 не куя. Теләсә “ноль” куйсын, хәзер шәкерткә аның әһәмияте юк. Мөгаллим үзе дә моның куәте беткәнлеген күрә, шулай да гадәт буенча куела инде.

Азрак хәле булганнар фатирга күченделәр, күбесе идарәдән дә сорамаган. Мәдрәсәдәгеләр дә сыйныфта җүнләп утырмый. Киеме булса, шәһәр буена йөрергә чыга, митингларга бара, сәяси түгәрәкләрдә була. Кич соң кайталар, назыйр да, швейцар да аптырый, кертсәң дә вай, кертмәсәң дә вай. Башкалары исә иртәдән кичкәчә садалы, марсельезалы[59+] җырлар, музыкалар белән, әдәбият белән вакыт үткәрәләр.

Мәдрәсәгә кайчан гына барып кермә, өч катлы таш бина гөрләп тора. Шәкертләр яңа уяна башлаганда бик зур дәрт белән: “И Илаһым, бир тәрәккый исламә!” – дип, бер мөнәҗәт көйлиләр иде, хәзер ул инде артта калды. Шәкерт аны узып, беренче вә икенче садаларга, “Инсан улан”га җитте, бер төрлеләре тагы ныграк тәрәккый итеп,

> “Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
> Ул тормыштан илгә файда юк,
> Булса, байлар илә тик түрәләр,
> Аркабызда рәхәт күрәләр”

не җырлыйлар, ул бетми, “Похоронный марш”, тагы кайдандыр алып, “Җаным-тәнем фида булсын хөрриятнең юлында”ны күтәрә, шулвакыт ук икенче бер йирдән авыр моң белә: “Кайгылы җилләр исәдер өсткә, каты куәтләр безне черетә!” – дип яңгыратып йибәрәләр.

Тегеннән назыйр килә, “туганнар, һич булмаса, акрынрак”, ди. Ләкин аңа каршы җә кычкырып көләләр, җә “ташлыйк, туганнар, иске дөньяны”

---

[1] *Тәнбиһләренә* – кисәтүләренә.

дип, бары берьюлы күтәреп йибәрәләр.

Ул арада иң ярлы, ләкин бик уенчак табигатьле бер шәкерт “Икмәк беткән көй” дип, бер нәрсә чыгарган. Моның көе дә, җыры да үз иҗаты.

Аның кебек ачлар мәдрәсәнең ярымыннан күбе булганга, бу җыр шәкертнең рухына бик якын төште. Кичке чәйне шикәрсез, икмәксез эчкән вакыт коры су тамакларыннан үтми башлагач, арадан берсе акрын, басынкы, бераз кайгылы тавыш белән башкортның озын моңына салып: “Ярлы хәле авыр икән, каткан икмәк кимертә”, – дип сызып йибәрә, аңар тагы шундый бик күп каткан икмәккә тилмерүчеләр кушылалар, аш-чәй залы авыр кайгылы моң белән күмелә. Мәдрәсә шулай гөж килеп яши.

Ул арада артист табигатьле берничә егетнең башлавы белән, атна кичне көтмичә үк, “Әдәби кичә” ясарга уйлаганнар. Җыр, музыка, Галиәсгар Камалдан[60+] бер пәрдәлек спектакль булачак. “Вәли башкорт” яки “курайчы Вәли” дип йөртелгән башкорт шәкерте авылыннан махсус курай алдырган. Башка һәр турыда түбән, соңгы рәттә басылып йөргән бу егетнең шатлыгын әйтеп бетерәсе түгел. Әүвәл төнә генә[1] кайдандыр теге Габдрахман приказчикны әләктергәннәр. Ул башта, минем тиздән туем була, дип карышса да, ирегенә куймаганнар, китергәннәр. Ул “Татар бае” дигән бер көлке укый. Үз иҗатыннан “Икмәк беткән көй”не чыгаручы Хәйри янә көлке рәвештә фәстән, җөббәдән мөгаллим Гайфинең полиция алдында каушавын, аның “мы учим һәндәсә” дип торуын, фатирында хуҗага самавыр куй диясе урында баш бармагы белән авызына тыгып аңлатуын тәкълид кылмакчы[2], кайдандыр хатын-кыз киеме дә тапканнар. Спектакльдә Камил – яшь кыз ролен, җырчы Сахиб – яшь киленне, Сөләйман Сәйфуллин мөтәгассыйб кадимне[3] уйнамакчы, Нәҗиб Кәмал баш мәсьүл[4] һәм режиссёр булачак.

Монда элек астыртын яшәп, соңра рәсмигә әйләнгән, ниһаять, мөгаллим Кәрим Гайфи тәэсире белән яңадан ябылган “Хөр фикер” атлы атналык бер җәмгыять бар иде. Тентүдән ихтилял көннәреннән соң, бу җәмгыять үзеннән-үзе терелде. Моңар низамнамә төзеделәр. Юлларын ачтылар. Җәмгыять атнага бер мәртәбә дүшәмбе көн кич сәгать сигездән соң булачак. Һәркем шунда үзенең фикерен телдән яки язып укыячак. Ни тугрысында сөйләргә? Бу иттифакый[5] булмаячак.

Моның өчен Җиһангир, Нәҗиб Кәмал, Нигъмәт казый, Сөләйман Сәйфуллиннан гыйбарәт бер комиссия сайладылар. Бу әгъзалар җыелып

---

[1] *Төнә генә* – кичә генә.
[2] *Тәкълид кылмакчы* – охшатып эшләп күрсәтмәкче.
[3] *Мөтәгассыйб кадимне* – элеккеге фанатикны, иске фикерлене.
[4] *Мәсьүл* – җаваплы кеше.
[5] *Иттифакый* – очраклы.

киңәшәчәкләр дә һәр дүшәмбедә бу атна кич нәрсә хакында фикер сөйләнәчәк икәнен биш көн элек шәкерткә игълан кылачаклар. “Хөр фикер” җәмгыятенең ихтиляддан, тентүдән соң булган беренче мәҗлесендә мәүзугъ[1] итеп татар шәкерте, татар мәдрәсәсе, боларны ничек ислах кирәклеге мәсьәләсе куелып, бик зур шау-шулар белән үткәрелде. Икенче атнага “Безнең милләт ни өчен артта калган?” дигән мәсьәлә билгеләнгән иде.

## XLII

Давыдка беренче мәҗлестә булырга туры килмәгән иде. Икенче мәҗлестә кузгатылачак мәсьәлә мөнәсәбәте белән берничә сүз әйтеп үтәргә тугры килер дип, барырга карар бирде. Камилне дә күрәсе, кайбер иптәшләре белән хосусый йомышларын да бетерәсе бар. Яңадан анда булырга тугры килмәс, берьюлы барын өзеп кайтасы дип, ул иртәрәк бармакчы иде.

Сәгать җиделәрдә Госманнардан кайтты да, кайнаган самавыр бар икән, шунардан чәй ясап алып, җәмгыятьтәге мәсьәлә хакында әйтәчәгенең планын сызгаларга тотынды.

Бу вакыт кемдер ишек какты. Карчык, гадәте буенча: “Бетмәделәр, Илаһым”, – дип сукрана-сукрана барып ачса, аннан башына урыс бүреге, өстенә иске пальто кигән, озынча буйлы, бераз нечкә гәүдәле, бик аз гына сипкелле, саргылт йөзле, ниндидер изтыйраб[2] белән карый торган зур соры күзле егет килеп керде. Бу – Баязид карый иде.

Ул бусаганы атлады да ниндидер шат, ләкин шул шатлык астында яткан авыр яралы да булган бер табигатьтән килгән тавыш белән:

– Җә, синең “җәһәннәм базы”нда хәтфә келәм түшәлмәгәндер, аяк пычрак булса да үтә бирим, – дип килеп, Урмановка кулын бирде.

Ул, өстәлгә килеп, кая, миңа бер чынаяк чәең чыгамы дияргә өлгермәде, тагы кемдер ишек шакылдатты. Карчык, тагы сукранып, ишеккә өстерәлде. Аннан икенче берәү керде.

Буе, гәүдәсе белән Баязид карыйга охшый төшкән бу егет кыяфәте, табигате белән беренче караштa ук анардан күп аерыла иде. Аның башында кыйммәтле каракуль бүрек, өстендә артык ятымлы тегелгән яхшы пальто, аягында америкaн итек иде. Аның бөтен торышы дөнья кайгысы һәм юк-бар михнәт белән ватылмаганлыгын сөйли, озынча тар кара туткыл йөзе белән елмаеп торган гакыллы кара күзләре, гел бертөрле тигез, бераз салкынча, үзенә ышаныч белән чыга торган саф тавышы нинди дә булса артык көчле рухани изтыйраблар белән бик борчылмаганлыгын аңлаталар иде.

---

[1] *Мәүзугъ* – тема, проблема, төп мәсьәлә.
[2] *Изтыйраб* – дулкынлану, көенү, аптырау.

Ул ишектән керү белән, бик артык үзләшеп җитмәгән, шулай да садә[1] иптәшчә мөгамәләдә булырга тели торган адәмнәрдәй, Давыд белән Баязидка тәкәллефсез рәвештә кул бирде дә, ярым көлеп:

– Кайда торасың бит, Давыд... Чыннан җәһәннәм базы, – дип, каләм сабы белән кыйммәтле трико пальтоның итәгенә чәчрәгән баткакны кырган хәлдә, сүзгә кереште. Бу – теге алты йөзне бирүче Йосыфҗан иде.

Баязид карый, зинданнан чыкканлы бирле, аны күргәне юк иде, аның сүзен уртадан бүлде:

– Иптәш, сезне төрмәдән чыкканлы бирле очрата алганым юк. Мин сезгә ничек рәхмәт укырга да белмим. Сез минем гомеремне озайттыңыз. Эш юлда калачак, чахотка мине җотачак иде...

Баязид аңа килеп кулын кысты, Йосыфҗан бик чак кына елмаеп:

– Нигә рәхмәт әйтергә!! Без – иптәшләр. Сез йөргән эшкә минем чын күңелдән ислахым[2] бар. Ләкин башкача хезмәт итә алмыйм. Һич булмаса, шул юлга акчам белән файдам тисен!!

Давыд сүзне Камил тугрысына борды. Ул эш төгәлләнгән. Камил бик шат. Иртәгә мәдрәсәне ташлый. Аңар квартир хәзер. Репетитор бар. Моңар каршы Йосыфҗан кайсы байбәтчәләрдән нинди юл белән акча җыелганын сөйләде дә, калын алтын чылбырындагы асылташы артык ялтырап торган кыйммәтле сәгатенә күз салып, урыныннан торды: "Да... иптәшләр, сәгать сигезгә җитә... Миңа магазинга кереп чыгасы бар... Капка төбендә атым көтә", – дип, ашыгыч исәнләшеп чыгып китте.

Анардан соң бүлмәдә хуш ис тулып калды.

Егетләр мәдрәсәгә барачак булып, урамга чыктылар.

## XLIII

Мәдрәсәләрдә шәһәрнең үзеннән йөреп укучы – "кала баласы" дигән бер тип була. Болар һәммәсе диярлек шаян, азгын, усал булалар. Сабакка мөсаһәлә кылалар[3]. Уйнарга, туры килсә, сугышырга хәзер торалар. Гаепләрен азайту, хәлфәне йомшату, зурлардан тиз-тиз үзенең сабагын өйрәттерү өчен, болар өйләреннән төрле ашамлык әйберләр китерә, кирәк кешене сыйлыйлар. Ләкин алар һаман мәдрәсә телендә "кала баласы" булып йөри, азгынлык та, усаллык та мисалга тотыла.

Кадимнәрнең мәшһүре булган Нури хәзрәттә дә хәл шулай. Кала баласының сыйфаты анда да шундый иде. Ләкин Йосыфҗан баладан ук шул

---

[1] *Садә* – гади.
[2] *Бу урында*: теләгем.
[3] *Мөсаһәлә кылалар* – әһәмият бирмиләр.

гомуми тип кала балаларыннан аерылды. Ул пакь яши, яхшы киенә, садаканы зур бирә, шуның белән кала баласы икәнен күрсәтә. Ләкин моннан башка якларда ул бөтенләй икенче иде. Анарда яхшы кабилиять[1], тырышлык белән бергә гаҗиб дәрәҗәдә көчле горур бар иде.

"Кала баласы" диләр дә шуны начарлыкка мисал урынында тоталар. Шуларның бере булу Йосыфҗанның гакылына түгел, бөтен табигатенә каршы, бу үзе өчен кимлек күренә. Ул тәнгә ябык, шаярырга гайрәте дә аз, шуның өстенә югарыгы инстинкт та кушылып, аны бөтенләй икенче якка сөрделәр.

Кала баласы берничә ел укый, өстерәлә дә мәдрәсәне ташлый, сатуына-ниенә китә.

Йосыфҗан табигате белән үк уку ягына борылды. Ул Урманов белән мәдрәсәдә, "Шәрхе Габдулла"дан[61+] ук сабакташ булып, "Сөлләм"гәчә[62+] бергә бардылар. Менә соңгы елларда, заман үзгәреп, Нури хәзрәтне ташлагач, мәдрәсәи исламиядә яңадан очраштылар. Бу ун елга якын бергә үткәрелгән гомер Урманов белән Йосыфҗанның һәр икесенең рухында тирән эз калдырды. Ләкин Баязид аны аз белә иде. Күбрәге "шантан кошы"[63+] булу белән танылган байбәтчәләр эченнән берәвенең шундый егетлек кылуы, җитмәсә, тагы Камилне гимназиягә хәзерләү турында байтак акча тотуы карыйга аңлашылып җитми, аны гаҗәпсендерә иде.

Мәдрәсәгә бару өчен урамга чыккач, тәмәкесен кабызды да Йосыфҗан хакында сүз кузгатты:

– Йосыфҗанның бу эше нәрсә? Бу – дуңгыздан бер кылмы? Әллә чын күңелдән эшлиме? Урам пычрак, аяк асты тайгак иде. Ике чат барып, ташлы тротуарга борылгач, Давыд аңа Йосыфҗанның бу егетлегендәге төп сәбәбен сөйли башлады.

## XLIV

Иң элек син шуны хәтереңнән чыгарма: ул табигате белә гаҗәп эгоист нәрсә. Ул гакыллы, нечкә аңлы, тумыштан нәзакәтле, мантыйгы дөрест уйлы, суык мөхәкәмәле[2], зирәк, тырыш, кыскасы – бик шәп буржуй малае. Шул көнгәчә халыкның "тәүфикъ" дип атый торган нәрсәсеннән аша атларга батырлыгы җитми. Кеше күзендә үзен төшерүдән курка, шуңар күрә эчми, тартмый, җомгаларын да калдырмый. Тик бер гөнаһысы – хатынпәрәст[3]. Ләкин ул моны шул дәрәҗәдә яшереп эшли ки, аның якын иптәшләре дә

---

[1] *Кабилиять* – сәләтлелек, булдыклылык.
[2] *Мөхәкәмәле* – бу урында: фикерле.
[3] *Хатынпәрәст* – хатыннар яратучы.

Йосыфҗан кыз бала кебек гакыллы, күгәрчендәй пакь дип йөриләр.

Үзендәге бөтен шул куәтләрне, тырышлыкны ул тик бер нәрсәгә карата: аның исеме югары асылсын, намусы пакь булсын, аны һәммә кеше яратсын, кайда гына барса да, аны якты йөз белән каршы алсыннар, һәр турыда аны кәмаләтнең[1] мөҗәссәм[2] мисалы итеп тотсыннар. Дисеннәр ки, менә Йосыфҗан гаҗәп бер егет, бай, инсафлы, фәлән; балаң булса Хода шундыйны бирсен!

Мин аның белән җиде ел Нури хәзрәттә булдым. Монда да байтак заманнар бергә без... Ләкин ачык аңладым: гаклый[3], ирекле теләве түгел. Бөтен табигате белән ул дөньядагы һәрбер эшен, һәрбер кыймылдавын шул югарыгы ноктага каратып эшли. Анарда яхшылык, фәзыйләт исеменә эшләнгән, китапча әйткәндә, "лә ризаэ Аллаһ"[4] булган һичбер эш табарга мөмкин түгел.

Баязид аның сүзен бүлде:

– Син артык тирәннән аласың... Мин монда теге эшнең сәбәбен күрмим... Ул нәрсә, дуңгыздан бер кыл булып каламы?

– Дуңгыздан бер кылмы, башкамы, ләкин яхшы ук саран булган ул буржуйның безгә меңнәр түгүе – аның минем белән булган үткән мөнәсәбәтенең һәм шул үткәннең хәзер килеп чыккан нәтиҗәсенең әсәредер.

– Мин аңламыйм...

– Менә нәрсә! Сиңа Адәм пәйгамбәрнең җәннәттән куылу тарихыннан башламый булмас, ахры... Без аның белән ун яшьтән үк сабакташ булып яшәдек. Баштан ук бик артык якын, бик куәтле дустлыкта булдык. Мондый мөнәсәбәт алты ел дәвам итте. Җиденче елда без "Сөлләм"гә төштек. Син беләсең, мантыйк шәп укылган кадим мәдрәсәдә "сөлләм хан"[5] кем була? Табигате белән дә дәгъвалырак егетләр бу вакыт айга карап сикергән арысланнан яман кылыналар. Ул бераз дәһриләнә, мөтәкәллиминнән[6] хөкәмаи фикерен[7] алда тота. Аның чәче җитә, кәләпүше кырын төшә башлый. Яшеребрәк булса да, читеккә каты үкчә куйдыра, чалбарны аяк йөзенә салындыра, кайбер вакыт моназара арасында аның хәлфәгә катырак сүз әйтүе, мунчага барганда качып тәмәкене тарткалуы да артык гаҗәпкә салынмый: "Җә, "Сөлләм хан" чакта андый хәлләр булгалый инде!" – диләр.

"Сөлләм хан"нан югарылар – карт санала, алар инде олыгайганнар.

---

[1] *Кәмаләтнең* – кимчелексезнең, бар яктан килгәннең.

[2] *Мөҗәссәм* – артык зурайтылган.

[3] *Гаклый* – акыл белән.

[4] *Лә ризаэ Аллаһ* – Аллаһ ризалыгы өчен.

[5] *"Сөлләм хан"* – "Сөлләм" укучы.

[6] *Мөтәкәллиминнән* – сөйләүчеләрдән, биредә: логика галимнәреннән.

[7] *Хөкамәи фикерен* – галимнәр (философлар) фикерен.

Түбән дәрәҗәләр – әле маңка малай гына, тик болар гына шәп егетләр. Бу вакыт моназир[1] шәкертнең кояшы төшлектә була. Ул элеп ала да селкеп сала, үз мәдрәсәсенә сыймыйча, каланың башка мәдрәсәләренә барып, эт урынына сүгешеп, кирәксә, сугышып кайта. Ул ирешмәс бер мәсьәлә калмый, ул җиңмәс бер куәт очрамый.

Табигате белән дә кабил гаюр егетләр бу дәвердә, чыннан да, дөньяга сыймый, айга ыргыган арысланны хәтерләтәләр.

Безнең алты ел буенча дәвам иткән үтә кызыл дустлыклы мөнәсәбәт[2], "сөлләм хан" булуыбыз белән, бераз уңа башлады. Без барыбыз җиде шәрик идек. Ләкин башкалар – "маңка"лар. Һәр турыда безнең авызга карап торалар. Безнең арада ярыш китте, моназаралар башланды. Элек без һәр турыда икемез бер яклы булып, башкаларга каршы төшә, бер-беребезне яклаша идек. Хәзер дәресләр безнең икемезнең үзара талашуы белән үтә торган булды. Нәтиҗәдә, без тарала, сыеша алмый башладык, ничек мөмкин: "ике арыслан бер урманга сыярмы?".

Мин бер якка, ул икенчегә карый, ике партия туарга зәмин[3] хәзерләнеп килә. Дошманнар шатланалар, арага ут салалар. Бигрәк тә аңарчы гел бер булып, бөтен түбән дәрәҗәләрне үз кул астымызда тотканга, эче янып йөргән "тәүзыйх хан"нар[4] эченнән аксак Хәбир дигән бер явыз бик бутый башлады.

Бервакыт "гакаид хан"нарның[5] дәресен тыңларга кердек, китте моназара, мин хәзрәткә каршы ачыктан-ачык:

– Хәзрәт, мин "җөзәи әлләзи ля йәтҗөзи"гә[6] ышанмыйм. Мөтәкәллиминнең[7] җәүһәре фәрдне[8] исбат юлында китергән дәлилләре мине канәгатьләндерми. Мин "тәшәккел[9] галәм" турында хөкәма фикерен муафыйк[10] табам. Галәмнең һәйүлә[11] белән сурәттән мөрәккәб[12] булуы хакындагы исбатлары минем гакылымны җиңәләр... – дия салдым.

Хәзрәт кинәт кызды:

– Чү, ахмак, тәүбә диң!! Кяфер булырсың!..

---

[1] *Моназир* – бәхәсләшүгә, сүз көрәштерүгә оста кеше.

[2] *Үтә кызыл дустлыклы мөнәсәбәт* – артык дус булу.

[3] *Зәмин* – җирлек.

[4] "*Тәүзыйх хан"нар* – "Тәүзыйх" укучылар. "Тәүзыйх" – иске мәдрәсә программасында зур урын тоткан бер китап исеме.

[5] *"Гакаид хан"нарның* – "Гакаид" укучыларның. "Гакаид" – ислам дине кануннары, аның төп нигезе – тәрәкләре турындагы гарәпчә дәреслек.

[6] "*Җөзәи әлләзи ля йәтҗөзи"гә* – бүленми торган кисәккә.

[7] *Мөтәкәллиминнең* – сөләүченең.

[8] *Җәүһәре фәрдне* – атомны.

[9] *Тәшәккел* – формалашкан.

[10] *Хөкәма фикерен муафыйк* – галимнәрнең фикерен яраклы, дөрес..

[11] *Һәйүлә* – материя, матдә.

[12] *Мөрәккәб* – укмашкан.

Йосыфҗан, хәзрәт фикерен куәтләп алып, бик зур дәрт белән мине рәд кылырга[1], җәһәннәмгә салырга тотынды. Аксак Хәбир дә аның ягыннан төште:

– Йосыфҗанның, ди, сүзе хаклы. Ул Давыдны тәкфир итә. Чынлап та галәм һәйүлә белән сурәттән мөрәккәб булса, бу игътикад – "нәфи хәшер"не мөстәлзим[2] була. Истилзам[3] көфер – гайн көфер[4]. Бәс[5] Давыд хөкәма мәсләге белән барып, "галәмнең тәшәккеле" хакында һәйүлә вә сурәттән тәрәккеб белән каил булса[6], ул – кяфер була.

Мин кызып киттем. Ләкин аларга тугры җавап бирмичә!

– Лыгырдама, аксак! Синең кебек мие черегәннәр аңлый торган нәрсәләр түгел... Бичара Йосыфҗан син дә шәйнең[7] булмаган йиргә тыгыласың... Ул сез аңлый торган мәсьәлә түгел, аңар акыллы баш кирәк, – дию белән канәгатьләндем.

Кемдер: "Азан әйткән, өйләгә вакыт", – дип кычкырды, без таралдык. Һәм шул сәгатьтән бер атна Йосыфҗан белән сөйләшми йөрдек. Минем сүзнең ярасы бетте, без тагы килештек, тагы дустлаштык. Ләкин моназаралар дәвам итә, һәр моназараның ахыры сүгеш белән, йөрәкләрне яралый торган сүзләр белән бетә. Без тагы, үпкәләшеп, атналар, унбиш көннәр сөйләшми йөримез... Тагы килешенә, тагы үпкә, тагы сүгеш. Көннән-көн арта, ара суына, инде үпкәләр ачуга, дошманлык төсенә әйләнә башлый. Мин аңарчы дөньяда мантыйктан башка кәмаләт[8] табу мөмкин түгел дип, барлык хәятымны шул мантыйк, схоластика юлына корбан итүдә булсам да, бу игътикадның, бу дөньяның тыгыз, җүеш һәм иске һавасы мине тончыктыра башлаган иде инде. Мин иптәшләрем арасына Рәшид казыйның "Миръат"ларын[64+], Габдулла Бубыйның "Хакыйкать"ләрен[65+], Риза казыйның "Асар"ы[66+] белән Күлтәсинең "Һәйят җәдидә"ләрен[67+] яшертен тарата, ысулы җәдид[9], йир түгәрәк, фәлән дип сөйләү өчен, "дәһри", "кяфер", "миссионер" исемнәрен дә ишеткәли идем.

Аксак Хәбир тыштан һаман кадим булса да, астыртын, минем тирәдә койрык бутый башлады. Ул бик еш, аулакта мине очратып, Йосыфҗанның

---

[1] *Рәд кылырга* – кире кагарга.

[2] *"Нәфи хәшер"не* *мөстәлзим* – "үлгәч терелү"не инкяр итүгә сәбәпче.

[3] *Истилзам көдгер* – бер эшнең нәтиҗәсе буларак килеп туган каршылык.

[4] *Гайн көфер* – үзе каршылык.

[5] *Бәс* – әгәр.

[6] *хөкәма мәсләге белән барып, "галәмнең тәшәккеле" хакында һәйүлә вә сурәттән тәрәккеб белән каил булса* – галимнәрнең каршына кушылып "галәмнең формалашуы" турында материя һәм сурәттән берекккән дип расласа, шул фикер белән килешсә.

[7] *Шәйнең булмаган* – биредә: *белмәгән* мәгънәсендә.

[8] *Кәмаләт* – тулылык.

[9] *Ысулы җәдид* – яңа метод.

миңа каршы кылганнарын сөйли:

– Ул, – ди, – барыбер байбәтчә. Хәзрәткә ярар өчен, ул анасын сатар. Синең хакта ул җасус булырга кирәк. Ул хәзрәткә: “Безнең Давыд шәрик, йир түгәрәк, аның астында Америка бар, анда кешеләр йөриләр”, – дип сөйләгәнен ишеткәннәр... фәлән, фәсмәтән, – дип лыгырдый иде. Өстәвенә, хәзрәт тә миңа караңгы йөзле күренә.

Йосыфҗанның шпионлыгы хакында мин, чынлап, шиккә төштем. Мантыйк моназарасыннан туган дошманлыкка бу да катышты. Дөрест, минем инде низамлы мәдрәсәләрнең беренә китәргә карарым иде, ләкин язны көтәсем килә, мәдрәсәдән куылу исеме анама начар тәэсир итәчәк булганга, миңа бераз яшеренергә туры килә иде.

Шулвакыт көтелмәгән бер вакыйга чыкты: мәдрәсәдә пакь киемле, матур йөзле Мәхбүб исемендә унөч яшьлек бер бала бар, без аның белән яхшы мөнәсәбәттә һәм өстәлдәшмез. Бер көнне, һичкемгә белдермичә, Мәхбүб белән кинематогрофка киттек. Кайтсак, минем өстәлдә танытмаска тырышылып язылган берничә кәгазь ята. Укысам: “Давыд Урманов белән матур Мәхбүб каядыр бик еш китеп югала башладылар. Боларның дустлыгы “Әбугалисина” хикәясендәге Хәлвәфрүш вакыйгасын[68+] хәтерләтә”, – диелгән.

Секунды белән миемә кан тыгылды, күз алдым томанланды, башымда чите камалы бүрек, өстемдә бишмәт, муенымда шарф иде, чишенә-нитә тормадым, Йосыфҗанның кайдалыгын сорап белдем дә аның артыннан дәресханәгә атылдым.

Анда хәзрәт чалма-чапаннан кыйблага каршы аяк бөкләп утырган, “Гакаид”тән “хөдүсе галәм” дәресе[1] [69+] бирә. “Гакаидхан”нар[2] артыннан безнең шәрикләр “Тәүзыйх”[3], “Тәһзиб”[4], “Мелла җәлал ханнар”[5], ярым түгәрәк ясап, саф-саф хәзрәткә каршы идәнгә тезләнеп утырганнар.

Мин, ахры, ишекне бик кызу ачканмындыр, барып керүемә, һәммәсе китапларыннан башларын күтәреп, “ни булды” дигән төсле хәйран күз белән миңа карадылар. Мин ишек яңагына якын ук тукталдым да мөмкин кадәрле һади тыным[6] чыгарырга тырышылган тавыш белән:

– Йосыфҗан, кил әле монда!.. Сездә йомыш бар, – дидем. Хәзрәт тә, баш күтәреп, миңа карады: “Бу ни эш? Ни дип тагы дәрес бүлдерәсең?” – ди,

---

[1] *“Хөдүсе галәм” дәресе* – Галәмнең яратылышын өйрәтүгә багышланган дәрес.

[2] *“Гакаидхан”нар* – “Гакаид” гитабын укучылар.

[3] *“Тәүзыйх”* – иске мәдрәсә программасында зур урын тоткан бер китап исеме. Тәрҗемәсе: ачык аңлату. Биредә: *«Тәүзыйх” укучы»* мәгнәсендә кулланылган.

[4] *Тәһзиб* – тәрбияләү, бу урында “*тәрбия дәресен укучылар*” дип аңларга кирәк.

[5] “*Мелла җәлел ханнар”* – “Мелла җәлал”китабын укучылар.

[6] *Һади тыным* – җитәкчеләргә хас тон.

бугай.

Йосыфҗан кинәт агарынды, йөзе тартылды, күзенә курку төсе чыкты. Шулай да, торып, миңа якынайды. Мин баягы кәгазьне суздым:

– Моны кем язды?.. Бу ни дигән сүз?

Ул бераз чүкте, биленә басылган җылан кебек бераз боргаланды, елмаюы белән минем күземә карап чигәргә уйлады, ләкин минем ачудан көйгән йөземдә рәхим әсәре күренмәгәч, марҗача куштан бер тавыш белән авыз ачты:

– Мин... аны... болай... уйнап...

Мин аның сүзе беткәнне көтмәдем:

– Синме?.. Синме?.. Миең черегән, явыз хәсид!.. Мине ашавың җитми, инде унөч яшьлек мәгъсум[1] баланың намусына кара тап ташлыйсың икән, явыз хәсид!!. – дип, яшен тизлеге белән уңлы-суллы яңагына салганымны үзем дә сизми калдым.

Һичкем ни булганын аңларга өлгерә алмады, мин:

– Кирәксә, мине хөкемгә чакыртырсыз! – дип чыгып киттем. Мин һичнәрсәне күрә дә, ишетә дә алмадым, тик хәзрәтнең генә артымнан ишек ябылган вакытта: “Бу нинди ахмаклык!!.” – дип урыныннан сикереп торуын шәйләп калдым.

Дәресханәгә кергәнче үк мәсьәлә Җиһангирга аңлатылган иде. Ул мине кочаклап каршы алды:

– Әйдә, нәрсәләрне җыйыйк. Сине барыбер куарлар... Мин дә синнән калмыйм... Бу схоластика җәһәннәмендә ми черегәнче!.. – диде.

Мин үзем дә кууны көткән идем. Ахырдан мәгълүм булды: мин дәресханәдән чыгу белән, хәзрәт янындагы яшел таягын алган да:

– Бу нинди ахмаклык? Кая, китерегез... мәҗнүнне! Кабыргасын ярыйм!.. – дип кычкырган. Ләкин Йосыфҗан: “Куй, хәзрәт... Без үзебез килешербез!..” – дип ялынып туктаткан.

Бу – мәдрәсә өчен зур вакыйга булды. Анда сугышлар еш була, ләкин алты ел шундый дустлыкта яшәгән ике иптәшнең бу дәрәҗәгә җитүе вакыйгага аерым төс бирә иде. Безнең дошманнар бәйрәм итәләр. Бигрәк тә аксак Хәбирнең шатлыгына чик юк. Безнең йолдызның яктылыгына күзләре чагылып йөргән хәсидләр буңа бик зур әһәмият бирделәр. Һәм моның табигый сәбәбе дә бар иде.

Без, Йосыфҗан белән икемез – ничектер, хәзрәтнең зур өмидләре идек. Безгә зур өмид белән караганын ул үзе дә бик артык яшерми, шуның сәбәбеннән югарыларның эчләрен яндыра иде.

---

[1] Мәгъсум – гөнаһсыз.

# XLV

Бервакыт шулай “Сөлләм” дәресендә тәүзыйхханнар үзләренә икенче ай инде дәрес бирелмәүдән зарландылар. Арада кызуырак канлы берәүсе хәзрәткә каршы:

– Хәз[1], вакытым җитми, шәкерт күп, дисез... Әнә Давыдларга вакытыңыз табыла. Алар унбиш көн кичекми дәрес ала торалар. Без бөтен кыш буенча алты дәрес белән калабыз!.. – дип ычкындырды.

Хәзрәт урынынан ук торды:

– Ни дисең?! Игътираз кыласыңмы?[2]

Сүз зурайды, тәүзыйхханнардан ике егет телләшә башлады. Хәзрәт кызып-кызып сөйләргә, шелтәләргә тотынды. Ниһаять, шул дәрәҗәгә җитте ки, яртылай бирелгән дәресен бүлде, алдындагы “Казый мөбарәк”не[70+] шартлатып япты да:

– Мин Аллаһ өчен хезмәт итәм. Минем күңелемне Ходай күрә. Бәндәләр каршында минем хезмәтемне күрсәтәчәк, минем йөземне агартачак бер-ике шәкертем бар. Мин ышанам: ул зур мөдәррис булачак, аларның гыйлеме минем хезмәтемне бәндәләр алдында исбат итәчәк, – дип минем исемемне зикер итте[3] дә, тунының бер җиңен киеп тә бетермичә, ачуланып чыгып китте.

Аның йөзен агартачак, зур мөдәррис булып, аның иҗтиһадын дөньяга күрсәтәчәк шәкерте – мин булам. Һәммә зурларга, бигрәк тә минем белән ярышып, өстен чыгарга, төн йокламый тырышып килгән Йосыфҗанга хәзрәтнең бу сүзе бик артык начар тәэсир итте. Алар, гүя, минем аяк астымда тапталып юк булдылар. Хәзрәтнең кайчандыр шундый югарыга күтәргән Давыды бүген үзалдына кызып бер шәкертен яңаклап чыккач, зурларның башы күккә тиде, инде аларның дошманы мәдрәсәдән куылачак, куылачак!

Монда алар өчен зур мәгънә бар.

Ләкин куу түгел, сугу да булмады.

Без Йосыфҗан белән гомергә килешмәслек дошманнар булып киттек. Ул – бик артык гарьчел нәрсә. Миннән яңаклангач, өч көн мәдрәсәдә күренмәде, дүртенче көн мин капка төбендә тора идем, ул мәдрәсәгә килде, янымнан якын үтте, ләкин дәшмәде, күтәрелеп карамады. Инде безнең өчен бер-беремезнең зарарына йөрүдән башка эш бетте. Элек үпкәләшсәк,

---

[1] Бу урында “*хәзрәт*” дип укырга кирәк.
[2] *Игътираз кыласыңмы* – “дәлилләр китерәсеңме” мәгънәсендә.
[3] *Зикер итте* – искә алды.

моназарада дәвам итә идек, инде беремез булган йиргә икенчемез килми, моназарага катышу түгел, иң гади турыда сүз алышу да юк.

Аксак Хәбир бу елдан соң минем Нури хәзрәт мәдрәсәсенә килмәвемне беләә. Ләкин аңа бу гына җитми. Аның ничек кенә булса да Йосыфҗанны да моннан озатасы, һич булмаса, базарын бетерәсе килә. Ул һәр көн миңа Йосыфҗанның җасуслыгы хакында тукый. Башкалар да шуны тәкрарлыйлар.

Башта шөбһәдә булсам да, бер вакыйга мине бик уйлатты.

Бер көн Фатих Кәрими[71+] белән урамда сөйләшеп торганымны Йосыфҗан күреп кала. Беләсең, ул вакыт кадим галәмендә Фатих Кәрими исеме кяфердән яман ишетелә, анардан иблистән качкан кебек качу лязем, аның исемен, әсәрен, фикерен телгә алу – дини җинаять санала иде.

Минем бу зур җинаятем хәзрәткә ирешкән. Мин аның өчен җавапка, җәзага тартылам. Хәзрәт кайдан белгән, мине бит Йосыфҗанга башка һичкем күрмәде. Шулай итеп, Йосыфҗан минем кашымда җасус, шпион булып калды.

Мин инде тагы җенләнә төштем. Аңарчы үз мөнәсәбәтем белән канәгатьләнгәнмен икән, аннан соң даирә киңәеп, мин аны иптәшләргә, бөтен мәдрәсәгә җасус, шпион дип, чиркен кыяфәттә сурәтле һәммәнең күңелендә аңар каршы начар хис уйгата башладым.

Шәкерт белән хәзрәт арасы төрле сәбәпләрдән бераз керләнгән вакытлар иде. Бу хис гаҗәп тиз арада шәкерт йөрәгенә тамыр җәеп, яфрак яра башлады. Шул дәрәҗәгә җитте ки, һәркем тарафыннан сөйләүне табигате белән тели торган Йосыфҗан бөтен мәдрәсә тарафыннан үзенә “җасус, шпион” дип нәфрәт белән каралганын сизә һәм Кирам атлы бер шәкерттән башка һичкем янына барып сүз кушарга, иптәшлек күрсәтергә батырлык кыла алмый торган булды.

Мин әле хис кылам, ул көннәр Йосыфҗан йөрәгендә мәңгелек агу калдырганнардыр. Ул көннәр аның өчен чынлап та җәһәннәм, җәһәннәмнең дә артык яманы иде. Ләкин минем үземә дә җиңел булмады.

Без шулай дошманлыктамыз... Ләкин бу мөнәсәбәт – гади дошманлык түгел иде.

Достоевскийның[72+] бер сүзе бар: “Бер-беренә гашыйк булган ике дошман”, – ди. Без дә менә шундый хәләттә идек.

Мин аны изәм, дошман мөгамәләсе кылам, шул ук вакыт аны гаҗәп сөям дә. Шул дәрәҗәдә ки, еракта аның йөзенә карап туя алмыйм. Аның һичкемгә якын барырга теләмичә, ялгызы бер почмакта утырган хәләттә, миңа карап, миннән күзен ала алмый торганын хис итәм, шуңар шатланам. Шуның белән бергә аны изүдә дәвам итәм. Үзен сөям, кызганам, “дустым” дип кочагыма аласым килә, шулвакыт ук аны бөтен мәдрәсәгә чиркен

кыяфəттə сурəтлим. Аны бөтен шəкерткə хур, кара йөз күрсəтүемне арттыра бирəм. Бу – ниндидер газап катыш сəгадəт. Дошманлык эчендə гыйшык иде. Кыш шулай үтте. Яз хозурга чыктылар.

Мин китəргə җыендым. Инде бу мəдрəсəгə яңадан килмəскə карар биргəнмен. Иптəшлəр белəн күрешергə дип, шəкертнең хозурга чыккан йиренə, тугайга бардым.

Кояш баеп килə. Бик шаулашып, мине елга аша чыгара торган көймə* янына иптəшлəр – бөтен мəдрəсə җыелды. Һəммəсе белəн юри, артык дустча күрешеп, үбешеп, кочаклашып чыктым. Шул арага, ничектер, Йосыфҗан да килеп чыккан. Мин аның янындагы нииндидер бер “ганка”[1] белəн кочаклашып, хат язышырга вəгъдə кылыштым.

Көймəгə утырдык. Йосыфҗан килеп баскан йирендə катып калды. Аның йөзе кара көйгəн. Гүəдəсе селкенми. Миңа дəшмəде, күтəрелеп карамады.

Мин тыштан – җырлап, эчемнəн җылап аерылдым.

## XLVI

Мəдрəсəи исламиягə килеп, бераз вакытлар үтү белəн, мин газаплана башладым. Иске тəрбиянең калдыгы булган бер кабахəтлектəн пакьлəнергə телəү, аннан да бигрəк эчтə ялкын əүвəлгечə булган алты еллык дустлык – мине Йосыфҗан алдында бик гөнаһлы итеп күрсəтə торган булдылар.

Йосыфҗан үзе дə тыныч булмаска кирəк. Җəдидлəр арасында иң шəп саналган бу мəдрəсəгə керүемне тəбрик итеп, ул миңа открытка йибəрə: тимер рəшəткə эченə йозакланган кайгылы йөзле яшь кыз сурəте. Теге ягына: “Тəбрик итəм, шəрик[2], җасусың Йосыфҗан” дип язылган.

Башка иптəшлəр аркылы, мин киткəч, Йосыфҗанның яңа фикергə ауганын, хəзер үзе хəзрəткə каршы якта йөрегəнен ишеттем.

Шуннан соң тотам да бик озын итеп хат язам. Үткəн дошманлыктагы һəммə гайбəтне өстемə алам, үземнең вөҗдани газапны сөйлим, күз яше белəн гафу үтенəм. Əүвəлгечə дустлар булуыбызны үтенəм.

Бер ай үтте. Бервакыт икенче галиядə шəриклəр белəн “Мəкамəт Хəрири” укып утырабыз, назыйр керде дə: “Давыд əфəнде, сезгə бик зур хат бар, юри үзем керттем”, – диде. Карасам, зур калын конвертның тышында миңа кадерле булган кул ялтырый – ничек торганымны хəтерлəмим, кулдагы

---

* *Г.Ибраһимовта*: кимə.

[1] *Ганка* – исеме бар, үзе юк бер мифик кош исеме. Бу урында “*билгесез бер кеше*” мəгънəсендə.

[2] *Шəрик* – иптəш.

китап парта астына төшеп китте, җенләнгән адәм кебек, “мин хәзер укый алмыйм” дидем дә аулак бүлмәгә хат укырга йөгердем.

Ләкин хат мин көткәнне бирмәде.

Минем бөтен ялынуларыма каршы, ул таш кебек каты, авыр гыйбарәләрдә: “Сине гафу кылырга минем тәкатем җитми… Ләйүкәллифуллаһ нәфсән әл вусгаһә…” мәфһүмендә[1] җавап язган.

Мине нидер басты, мин шул вакытта дөньяда иң беренче сөйгәнем шул кешегә каршы нинди авыр җинаять эшләгәнемне ачык, үтә каты хис иттем. Иске тәрбия, иске татар хәяты, кадим мәдрәсә, мантыйк схоластика һавасы үземне харап кылуы, шунда күп нәрсәм югалуы хакында уйланып, мин күп авыр минутлар кичердем, ләкин Йосыфҗанның мәктүбен укыган соң эчемдә уянган каһәрләр, ләгънәтләрем аннан әүвәлдә, аннан соң да һич вакыт булмагандыр.

Баязид карый Давыдны бүлде:

– Син, ахрысы, көчле генә сантименталистсың[2] да?

– Юк, иптәш, ул сантименталистлык түгел, ул авыр трагедия иде… Аны хис итү өчен, адәм үзе шуны башыннан кичерергә кирәк. Берәүне яшьлегеңнең бөтен куәте белән сөйгәнсең, сөясең, сөясең… Ләкин синең ихтыярыңда булмаган каһәрле бер куәт сезнең бер-берегезне тыштан дошманлык мөгамәләсе күрсәтергә мәҗбүр итә. Йөрәкләрегез мәгъсум сөю белән тулы булганы хәлдә, сез бер-берегезне изәргә, хурлыкка төшерергә тырышасыз… Бу – сиңа газап. Ләкин теге каһәрле куәт синнән көчле, ул сине кол иткән, син тышкы дошманлыкларның кара пәрдәсен киеп, йөрәк дустыңны изүдә дәвам итәсең. Бер вакыт килә, син ул каһәрле куәттән азат буласың, синдә адәмлек, дустлык җиңә, син үзеңнең кылган кабәхәт җинаятеңнән вөҗданыңны котылдырасың килә… Аның алдында тезләнеп: “Мин күп газапландым, мине кичер, без әүвәлге көннәрне кайтарыйк”, – дип ялварасың, ләкин ул: “Йөрәгемне шул дәрәҗәдә агуладың ки, дөньяда һичбер нәрсә, ахыр чик, үлем исереклеге дә сине гафу иттерә алмаячак, сине гафу кылырга минем тәкатем җитми, лә йүкәллифуллаһ нәфсән әлвусгаһә!!!” – ди…

Адәм вөҗданы өчен моннан авыр бер минут бардыр дип, мин уйлый алмыйм.

---

[1] .*“Лә йүкәллифуллаһ нәфсән әл вусгаһә…” мәфһүмендә* – “Аллаһ җаннарга (кешеләргә) үзләре күтәрә алмаганны йөкләми...” эчтәлегендә.

[2] *Дөресе*: сентименталистсың да – артык хискә бирелүчән.

## XLVII

Бу вакыт егетләр мәдрәсәгә якынаеп киләләр иде. Баязид карый: “Яныңда юкмы, хатын күрсәтмисеңме?” – диде. Урманов кесә дәфтәре эченнән өчкә бөкләнеп салынган зур конвертлы хат чыгарды. Якында фонарь бар иде. Шуның баганасына сөялде дә Баязид карый Йосыфҗанның мәктүбен укый башлады.

“Бәгъдә әлхәмдүлилләһи әлләзи лә йүкәллифуллаһу нәфсән иллә вусгаһә вә бәгъдәт-тәслияти галә Мухәммәдин әлләзи әгъҗәбә күллә гакыйлин мунсыйфин бигадәтиһи вә мугамәләтиш-шәрига. Иннә кальбән мәликүн мутагу нәфизүл-хукмә вәл-әгъза рагыйә вә хадәмүн. Фә изә түкыйрү һәза фәнәкулә[73+].

Хөрмәтле газиз бөрадәр[1], шәригем Давыд! Җәнабеңезә сәлам бәгъдендә фатиха хәйрияңезне риҗа идәрем[2].

Әгәр безем тарафтан истигълям хәл кылына калса[3] – мәгълүмеңез шул кадимге мәдрәсәдә ятмакымыз булсын – үзеңезнең фәлән числода язган мәктүбеңез биламан[4] ирешеп, моталәгадә булындык[5]. Безнең аңладыкымызга бинаән[6], бездән ризалашуны теләгәнсез икән. Әлбәттә, бу тарика[7] мөгамәләңез, әгәр чын калебтән булса, гүзәл мөгамәлә, ләкин чын күңелдән булмакында – вә фиһи[8].

4... Гаҗәб дәгел, әфәндем, бер эш җәмигъ әгъзага мөтәсарриф[9] булган, җәмигъ әгъзага хәким булган, үзе ни теләсә шуны булдыра торган – калебкә тәмам урнашмаган булса, калебнең иң эчке тарафына (питнә[10]) булмаган булса, бәлки калебтә вөҗүде сатхи гына булса[11], яисә һич вөҗүде булмыйча булган сурәттә генә (кылынса), ... шик юк ки, үз-үзенә заил булачак[12] һәм сәбатыны ирадә кылынса да[13] тормаячак.

Ләкин, әфәндем, безнең рәибезгә бинаән[14] (рәнҗеш, риза, гафу)ның

---

[1] *Бөрадәр* – кардәш, дус.

[2] *Сәлам бәгъдендә фатиха хәйрияңезне риҗа идәрем* – сәлам соңында хәер-фатихагызны өмет итәм.

[3] *Истигълям хәл кылына калса* – аңлатма таләп ителсә.

[4] *Биламан* – иминлектә.

[5] *Моталәгадә булындык* – укыдык.

[6] *Аңладыкымызга бинаән* – аңлавыбызга нигезләнеп.

[7] *Тарика* – ысул, юл, алым.

[8] *Вә фиһи* – эчендә.

[9] *Җәмигъ әгъзага мөтәсарриф* – бөтен әгъзага хуҗа.

[10] *Русчадан*: пятно – тап.

[11] *Калебдә* в*өҗүде сатхи гына булса* – күңелнең өстендә генә булса.

[12] *Заил булачак* – бетәчәк.

[13] *Сәбатыны ирадә кылынса д*а – ныклыгы теләнсә дә.

[14] *Рәибезгә бинаән* – каршыбыз, уебызгача.

хакыйкый, тәмам әмер мәгънәви булып, биззат калеб тәсаррыфында[1] булганга, һәм дә безнең шул кабәхәт мөгамәләдә булмакымыз, безнең шулкадәр инсаниятсезлекемез, безнең шулкадәр әхлаксыз, мәгърифәтсезлекемез кабәхәтлекнең иң ниһаять дәрәҗәсенә ирешкәнгә күрә, калебемезнең иң дирүненә[2], иң уртасына, иң эченә, белмим, әллә каюларына урнашып, үз-үзеннән заманнар тәгакыбы[3] бәгъдендә, череп, шарт итеп өзелеп төшмәсә, һич әсбаб заһирә илә[4] үз ирадәм берлә төшерә алмам, зан идәрем[5]...

4... Бинаән галәйһи[6] мондый мөгамәлә сатхи[7] булып, ике бала сугышкан тәкъдирдә, вагыйз[8] хәлфәнең ризалатуы, вагыйз хәлфәнең истигъфа кылдыруы кабиленнән[9] генә икәнчелеген белдерәсем килә. Ләкин бу ризалыкларның һич ризалык булмавы шикелле бундый рәнҗеш тә дәгелдер. Яки рәнҗүләр булына калса да, ризалык булмыйча, бәлки фәкать бер рия яки итагать, яки җиңеллек, балалык вә җыраклыкдыр.

Гафу боерасыз, әфәндем, минем вөҗданым, минем мовазәнәм[10], минем сәгатьләрчә фикерем сезнең бу мөгамәләңезне (4) цифры белән ишарә кылынган җөмләләр арасында мәнгы[11] хөлү[12] дип әйттерәселәре килә.

Моннан аңгарту мәкъсуд булган нәрсә мәсә йүзкәрдер[13].

Әфәндем, хакыйкый[14] ризага мокабил[15] булган хакыйкый рәнҗешнең әүвәлдә итдегемезчә, калебнең фәлән-фәлән йирләренә тәмам-тәмам урнашканга, сеңешкәнгә риза булу шул җәрәхәтне, шул питнәне кесәдән чүп, аштан күб[16], баштан кәләпүш, авыздан төкерек ташлау кабилендә генә булмыйча, бәлки карбызның орлыгын, күкәйнең сары сул канҗәләрен[17] ярмыйча гына ташлау кабиленнән булганга, карбызның кабыгын ярмыйча, икенче бер кешенең алуы мөмкин булмаганга, калебтә булган җәрәхәт, калебтә кортлап, сасып беткәнен искә төшерсә, костыра торган кортлар үз-

---

[1] *Биззат калеб тәсаррыфында* – турыдан-туры күңел хөкемендә.
[2] *Дөресе*: тирәненә.
[3] *Тәгакыбы* – берсе артыннан берсе килү, "*заманнар үтү*" мәгънәсендә.
[4] *Әсбаб заһирә илә* – тышкы сәбәпләр белән.
[5] *Зан идәрем* – дип уйлыйм.
[6] *Бинаән галәйһи* – шуңа күрә.
[7] *Сатхи* – өстән генә (тирән булмыйча).
[8] *Вагыйз* – вәгазь сөйләүче, үгетләүче.
[9] *Истигъфа кылдыруы кабиленнән* – ризалаштыруы кебек.
[10] *Мовазәнәм* – тигезлек саклавым.
[11] *Мәнгы* – тыю.
[12] *Хөлү* – ләззәтле.
[13] *Мәсә йүзкәрдер* – искә алынды, түбәндә китерелде.
[14] *Хакыйкый* – чын.
[15] *Мокабил* – кара-каршы.
[16] Бу урында "*күбек*" дип аңларга кирәк.
[17] *Канҗәләрен* – кабыкларын.

үзенә тәгакыба коелып бетмәсә, бәнем үз ирадәмдә булмыйча, бәлки мин үзем аның идарәсендә булган калебтәге нәрсәләрне кулым берлә үзем өзеп алып ташларга имкян хариҗендә зан идәрем[1] – мәсә йүзкәр менә шушы.

Хасыйл әлкәлям[2], ризалык телдән генә "риза, риза" дип әйтүдән генә гыйбарәт булса, мин дә "риза" диячәкмен һәм дидем, мең мәртәбә дидем.

Әгәр риза гыйбарәт булса, без югарыда бәян кылган нәрсәдән ул вакыт (мәгъзүрем[3], әфәндем)...

Иштә шәригем, бу җөмләдән, зинһар, вә, зинһар, "Йосыфҗан ялындыракчы була" дип уйлама, юк, шәрик, мең мәртәбә юк, һич заляләткә[4] чумма, һич фаразыма[5] да кереп чыкмый, максудым фәкать ма сәбәкъ[6].

Ләкин, әфәндем, гафу боеруңыз, кыйтга әминем[7] ки, гүя бәнем шпион булып, җасус булып, сезләрне кудырту сәдәдендә[8] йөрдегем сәбәпле, сез бәне бөтен мәдрәсәгә дошман ясап, мине изү фаразында, мине кыйнау фаразында булу гына түгел, шуны үзеңез билфигыль[9] иҗраэ иттеңез вакыт[10] хамил булган[11] җәрәхәт һичбер вакыт китәчәк дәгел, фараз кылыйм ки, нисфе мәүт[12] булган сәкран[13] хәленә керсәм [дә], зиһенемдә булачак.

Кәбир, Галләм, Гарифулла, Габдеррәфыйк абзыйлар һәр каюсы сәламәт булдыклары кеби мәдрәсәдә тормактадырлар.

Гафу боерасыз, газизем, моңа башка әхвале язмага[14] кулымы никадәр йөртсәм дә, никадәр тартсам да, никадәр язмакчы булсам да, әлеге нафизел-хөкем хакимел-әгъза булган кальбем, нәфесемнең мәнфисе[15] һәм аларның һичбер бирмәстәй тотып тормакы – һәркаюсы болардан да кувән[16] булганга яза алмадым. Гафу боерасыз, әфәндем.

Әфәндем, арамызда шундый бер салкынлык булмыш ки, һич җылынмаячак, һич кызмаячак...

---

[1] *Имкян хариҗендә зан идәрем* – мөмкиннән тыш, мөмкин булмаган.
[2] *Хасыйл әлкяләм* – сүзнең кыскасы.
[3] *Мәгъзүрем* – мин гафу итәм.
[4] *Заляләткә* – ялгышлыкка.
[5] *Фаразыма* – уема.
[6] *Мә сәбәкъ* – алда булган хәлләр.
[7] *Кыйтга әминем* – нык ышанам.
[8] *Сәдәдендә* – ниятендә, теләгендә.
[9] *Билфигыль* – чынлыкта.
[10] *Иҗраэ иттеңез вакыт* – үтәгән, башкарган вакыттан бирле.
[11] *Хамил булган* – барлыкка килгән, сакланып йөртелгән.
[12] *Нисфе мәүт* – ярым үлек.
[13] *Сәкран* – исерек.
[14] *Моңа башка әхвале язмага* – моннан башка хәлләрне язарга.
[15] *Нафизел-хөкем хакимел-әгъза булган кальбем, нәфесемнең мәнфисе* – эчемдәге уй-фикерләр барлык әгүзаларга хуҗа булган – йөрәгем, күңелемнең моны кире кагуы.
[16] *Кувән* – куәтле, көчле

Газизем, саг бул[1], күп яшә. Хода арамызны ислах кылсын[2]. Мәктүб күндереңез, әфәндем.

Кятиб[3] шәрик җасусыңыз Йосыфҗан бин Кадыйр әл-Хәсиби.

Мәктүбне ашыгыч укып бетерделәр дә, соңга калабыз дип, тагы тизрәк атлап, мәдрәсә ягына юнәлделәр.

## XLVIII

Алтын сәгатьле буржуй егет эчендә кайчандыр менә шундый җәүһәрләр ята иде, иптәш...

– Юк, мин аны яңа төшенәм... Ул үтә нечкә аңлы, намуслы җан күренә... Байбәтчәнең бөтен хәяты аның табигатен бозачак рәвештә була. Бу, ничектер, сакланган.

Байбәтчә дип, элек аларда әллә нинди байлык юк иде. Аларның ике йортлары бар иде. Берсендә үзләре тордылар, икенчесендә фатир йибәрделәр, шуның акчасы белән үзләре шәһәрнең урта хәлле буржуасы кебек яшиләр иде... Тик менә соңгы елларда кинәт күтәрелде... Син теге сары Сабирны беләсеңме? Аның анасы шул байның кызы икән... Ул үлгәч, зур мирас тиде. Шуның белән эш башлап, тиз арада зур-зур файдалар итеп ташладылар... Менә алар “Кадыйр бай” булды. Ә элгәре тик “Саран Кадыйр” дип кенә йөртәләр иде...

– Йосыфҗанның бу мәдрәсәгә килүенә байтак булды. Син ничек аның алты йөзен алмаска, үзен куып чыгарырга уйладым, дисең...

– Шулай туры килде ул. Чөнки Йосыфҗан бу мәдрәсәгә килгәч, миңа бармады, очраганда икенче якка борыла иде. Мин дә бу егеттә нәселенең каны кайный, ахры, дип, үзем аяк атламадым. Ул, монда килгәч, үзенә бер партия ясап, безгә каршы якларның башында торырга уйлады, бугай. Ләкин аның тирәсенә җыелганнар бар да җәмгыятьләрдә безнең тарафтан хур ителеп ташланган бичаралар иде. Болар белән маташырга аның гарьчел табигате теләмәде. Ул тагы ялгызлыкка бирелде... Һәм күрә ки, аңа үзе белән көрәшеп маташуда газапка башка нәрсә чыкмаячак... Мәйданга кереп, Нури хәзрәттәге кебек, минем белән яңадан көрәшү мөмкин булмаячак... Ләкин, килеп, кул бирергә кибере[4] йибәрми... Бераз вакытлар ул монда да бик начар хәлдә калды. Ул башкалар тарафыннан дустлыкны, илтифатны, кадерне теләүчән.

---

[1] *Саг бул* – сау бул.
[2] *Ислах кылсын* – килештерсен, дуслаштырсын.
[3] *Кятиб* – язучы, *бу урында*: хатны язучы.
[4] *Кибере* – үзен олылавы, тәкәбберләнүе.

– Син төрмәгә кердең... Ул кайдандыр сине коткарырга акча эзләп тә таба алмый гаҗиз булуымызны ишеткән. Беркөн иртә белән өйдә утырсам, Йосыфҗан килеп керде. Күрешмәдек, мин аңа урын күрсәттем. Утырдык. “Баязетдиннең хәле начар дип әйтәләр, акча тапмагансыз, дип ишеттем. Мөмкин түгелме, шул тарафтан минем иптәшлекне кабул итәргә?”– ди. Мин башта аңар ышанмадым, бу бичара үзенең кодрәтен күрсәтергә тели, сез хәерчеләр, миннән башка әллә кая китә алмыйсыз, дигәнне аңлатмакчы була дип уйладым. Ләкин аның күз карашы шундый түбән, тавышы үтенечле иде, мин каршы тора алмадым. Икенче килеп, акчасы алынгач, ул бөтенләй ачылды:

– Иптәш, бетсен бар да... Мин күп газапландым... Кадимлектән килгән бер кабәхәтне, сәбәбе әллә кайчан беткән дошманлыкны ташлыйк... Ислах теләсәң, бир кулыңны, – диде.

Без килештек. Син аның хакында: “Намуслы җан!”– дидең, бу бик тугры, ләкин шуның белән бергә анарда мине хәйран иткән мәртәбәдә табигый эгоистлык бар. Аның яңадан килешүендә эчке хис белән янәшә үк шул гарьчеллеге, горуры, кибере, эгоизмы да зур роль уйнаган булыр.

– Ничек ул?

– Менә ничек... Ул күрә, безне мондагы яшьләрнең бер төрлесе мәркәз итеп алган. Һәм бу яшьләр хәзер иң модада, игътибарда, аның буе җитәрлек нинди генә эшкә катышырга уйласа да, безгә кагылырга мәҗбүр булачак... Ул боларның һәммәсенә төкереп, башка байбәтчәләр кебек шансоньеткалар артыннан чабып, гомер үткәрә алмый. Аның табигате үк моны күтәрми... Дөрест, ул аларны гаҗиб ярата, аларның калку күкрәкләреннән, алсу иреннәреннән күзләрен ала алмый. Ләкин ачыктан-ачык ул юлга бирелү аны халык кашында шул тәүфикъсыз, фасикъ байбәтчәләрнең рәтенә, түбәнгә төшерәчәк. Йосыфҗан өчен бу – үлем!! Шуңа күрә ул аларга кулын бирми, аның горуры халык һәм хөррият юлында йөрүче яшьләрнең бере, яхшысы булырга тарта... Моның өчен безнең арага керүдән башка чара юк. Менә шул сәбәпләр тәэсире белән килеп, ул кулын бирә, меңнәрен кызганмый... Һәм акыллы, безнең арада Йосыфҗанга булдыра алырлык мәртәбәдә акыллы эшли. Мин ачык күрәм: ул бу меңнәрне җылап бирә. Ләкин аны нәтиҗә җуата: ул – хәзер шул модадагы яшьләрнең берсе, мөһиме.

Ул тагы бөтен табигате белән эстәлгән[1] мәртәбәгә ирешә: аны илтифатка алалар, мөмтаз[2], кадерле урынга куялар, ягъни аңа шулай мөгамәлә итәләр. Ул болай да һәркемгә яраучан, сөелүчән, болар өстенә шундый егетлеге дә кушылгач, җитә кала... Сине коткарган, Камилне юлга

---

[1] *Эстәлгән* – үзе теләгән.
[2] *Мөмтаз* – башкаларга караганда өстенрәк булган.

салган ул меңнәрнең төп сәбәбен менә шундый психологиядә эзләргә кирәк!... Ах, без мәдрәсәгә килеп тә җиттек. Зур залда ут бар. Ахры, җәмгыять башлангандыр.

## XLIX

Болар, мәдрәсәнең ике катлы тимер ишеген ачып кергәндә, югарыдан үзенең артык чибәр, бөдрәле каракуль бүреге, ерактан яңарып торган килешле тегүле трико пальтосы белән Йосыфҗан төшеп килә иде. Күрү белән, боларга таба ашыкты:

– Валлаһи, урам шундый пычрак, әйткән булсаңыз, юрга белән җилдергән булыр идем!..

Баязид карый аның күзләренә текәлде. Югарыда, җәмгыять залында, кычкырып дәвам иткән хатибның нотыгы ишетелә иде. Карый күптән күрә йөреп тә кем икәнен аңлап җитмәве яңа гына булган иптәш сыйфаты белән Йосыфҗанның кулын кысты да:

– Бик күптән җәмгыять күргәнем юк... Анда хатиблар язалар... Хәзергә сәламәт булыңыз. Сезгә тагы бер мәртәбә рәхмәт!.. – дип, тимер баскычтан өскә йөгерде.

Икәү калгач, Йосыфҗан бераз үзгәрде. Аның шома кара туткыл йөзе, ничектер, артык ягымлы карый, гадәттә җылан күзен хәтерләтә торган карашы йомшара, тавышы яңа бер карар белән дәртләнгәнгә охшаш чыга иде. Давыдның биленнән алды да:

– Ул җәмгыятькә бик ашкынмыйсыңдыр әле, миңа бер ун минут вакытыңны һибә кыл[1]... Сиңа берничә сүзем бар, – диде.

Киң, озын, буш, ярым караңгы коридор буйлап йөргән хәлдә, ниндидер ятрак тавыш белән Йосыфҗан сүз башлады:

– Менә, иптәш, сезнең кебек кешеләр бик бәхетлеләр. Үз көчеңез белән табасыз да үз чамагызга карап яшисез... Үзеңезгә үзеңез хуҗа буласыз... Ачмы, тукмы – хәлеңезне үзеңез генә беләсез!.. Аның урынына сезгә “бу – ярый, бу – ярамый” дип торган кеше булмый... Менә безнең хәл начар... Читтән караучылар Кадыйр бай углы Йосыфҗан булырга, аның кебек, йөз илле тәңкәлек сәгать тагып, кыйммәтле аргамакта йөрергә кызыгалардыр... Ләкин шундый вакытлар килә ки, син, һәммәсен ташлап, ач-ялангач хәлдә, буш сахрага ялгызың чыгып китәргә җитешәсең.

Давыд иптәшенең күзләренә карады:

– Синең бу сүзләрең яңа, иптәш. Ниләр бар ул чаклы?..

– Бар, иптәш, бар. Күп нәрсә бар... Атай картның бу арада

---

[1] *Һибә кыл* – багышла.

гасабилануына чыдар хәл калмады... Теге көн мәдрәсәдә булган ихтиляллар, тентүләр, низамнамәне ватулар... Шул арада тагы приказчикларның баш күтәрүе... Инде, җитмәгән кебек, Җиһангир белән яшь әни арасындагы романның дөньяга фаш булуы – картны эштән чыгардылар... Беләсеңме, Һаҗәр әни гайбәте белән хәзер бөтен шәһәр тулды... Кайда барсаң – шул, кайда барсаң – шул. Инде болары да чигеннән арткан иде, шулар өстенә тегендә Баязид карыйның атасы Җиһан ишан: “Сине Аллаһ каһәрли, син әһле бидгатькә[1] иганә кыласың[2]... Һәрбер тиенең кыямәт көнендә мизаныңның[3] гөнаһ табагына салыныр... Дөнья йөзендә дә хурлыгын күрерсең...”, – дип яза.

Картның бу ел кәефе яхшы иде. Ун ай эчендә Мәкәрҗәсе, игене, тиресе белән йөз меңгә якын табыш иткән. Шул шатлыктан Җәмгыяте хәйриягә, кызлар мәктәбенә, тагы әллә кайларга, менә бу мәдрәсәгә дә күп-күп ярдәмнәр бирмәкче иде... Теге әйткән вакыйгалардан соң, бөтенләй эштән чыкты. Көн буена яшенле кара болыт кебек куркынычы белән баса да тора... Сүз юк, ни юк. Инде авыз ача икән – һәммәбезне, бөтен дөньяны сүгәргә, “мин мал табам, алар кадерен белми”, дип каһәрләргә тотына... Кичә мине чакырып алды да:

– Моннан соң мәдрәсәи исламиягә аяк басачак булма!! Моннан соң ул кызыл авызларның берсе белән катышачак булсаң, балам дип аямам, җә, сугып, муеныңны сындырырмын, – ди. Мин әйтәм:

– Бик яхшы, мин мәдрәсәдән туктыйм, алайса, миңа русча укырга рөхсәт бир, мин надан калырга теләмим, – дим.

Ул тагы җенләнеп китте:

– Урысчасы да җитәр, мөселманчасы да җитәр!! Урысны укып, писарь буласың, гыйлем укып, мулла буласың юк. Егермегәчә укыдың, бары белән гамәл кыла алсаң да бик җитәр, – дип, өсткә акырды... Ни сөйләргә, бөтен өй җәһәннәмгә әйләнде.

– Аның шулай буласы табигый иде... Соң, син үзең ни уйлыйсың?

– Синнән яшерер хәл юк... Мин, иптәш, түзәр дәрәҗәдән үттем инде... Мин Төркиягә китәргә уйлыйм!..

Урманов гаҗәпсенде:

– Китүең – табигый... Ләкин ник Төркиягә? Аларның үзләренә юк гыйлемне...

– Әй иптәш, анысы шулай шулаен... Ләкин Русиядә торырга һич имкян юк... Кайда гына яшәсәм дә, атай беләчәк, артымнан кеше йибәрәчәк, үзе

---

[1] *Әһле бидгатькә* – элеккесенә каршы килә торган яңа бер эшкә ияручеләргә.
[2] *Иганә кыласың* – ярдәм итәсең.
[3] *Мизаныңның* – үлчәвеңнең.

барачак, миңа тыныч укырга җай булмаячак... Ә Төркиягә ул икенче төрле карый... Ислам йире, хәлифә, фәлән-төгән, дияр. Мин Гали мөдәррискә хат язачакмын, ул этине ризалата алыр, ихтимал... Истанбулда урта мәктәп бетергәч, Яурупаның кайбер университетларына алалар, бугай... Минем Свичрәгә[1] барырга дәртем зур... Ләкин, иптәш, билет ягы бар. Менә шул турыда, ихтимал, синнән берәр ярдәм булмасмы, дигән идем... Атай миңа паспорт бирдертмәячәк... Ансыз китәргә батырлык җитми... Урманов тиз җавап бирмәде:

– Синең егетлегеңне Госман тәхсин итте[2]. Ул “тегеннән” юнәтеп алып бирер, ихтимал...

Йосыфҗан күзенә кинәт җылан карашы чыкты, ләкин шунда ук тагы сүнде дә аның гәүдәсе күтәрелде, тавышы җиңеләйде, ике кулы белән Урмановның беләгеннән алды:

– Ә иптәш!.. Мин моңа ышаныйммы?.. Качан ачыгы беленер?..

– Иртәгә Рауза туташта мин Госманны күрәчәкмен... Ихтимал, шулвакыт аның белән сөйләшергә туры килер.

– Алайса, мин сиңа иртәгә кич керим... Сәгать уннарда өйдә буласыңмы?

– Юк, сигездән соң минем барасы йирем бар. Син миңа сәгать җидедә кер!!

Йосыфҗан яңадан үзгәрде, Давыдка кысыла төште, аның тавышында ихлас катыш йомшаклык арта бара иде:

– Сиңа бик рәхмәт укыячакмын, иптәш!.. Бер вакытлар атайның елдан-ел баеп баруына шатлана идем... Хәзерге көннәрдә шундый минутлар килә ки, Ходаем, мине ник хәерче баласы итеп яратмадың, дип җылар хәлгә җиттем... Һәммә нәрсә камил, һәммә нәрсә җитә, тик бер нәрсә юк: хөррият юк, хөррият юк! Хөррият юк иде, инде, насыйп булса котылам, иптәш...

Югарыда бик каты кул чаптылар. Хатиб яңа дәрт белән үзенең нотыгын дәвам иттерә башлады. Урманов: “Ну, хәзергә фатиха!” – дип кул бирде. Йосыфҗан:

– Монда яралар, валлаһи. Менә шул халык эчендә үз кешеләре булып кайнашасы килә. Булмый бит...

Иптәшенең кулын кысты да, урамга чыгып, мәдрәсә ишеге төбендә көткән күк аргамакны Екатеринскийга таба юргалатты.

Давыд югары менә башлады. Ләкин, икене дә атлый алмады, әллә кайдан швейцар килеп чыгып, чалбар кесәсен актара-актара, хат кисәге, бугай, дип, аңа бөгәрләнеп беткән конверт тоттырды.

---

[1] *Свичрәгә* – Швейцариягә.
[2] *Тәхсин итте* – хуплады.

## XLIX

Хат Җиһангирдан иде. Давыд, баскычтан менә-менә, аны укып чыкты: “Иптәш, дөньялар әйләнде. Һаҗәр, минем көнем – җәһәннәм, мин тора алмыйм, дип яза. Сиңа ничә бардым – өйдә юксың; монда көттем – никтер соңга калдың... Гаҗәпләнмә, без китәбез! Һәммәсе хәзер, мин дүшәмбе көн Йосыфҗаннарның иске дачасы артында төнге сәгать унда аны пар[1] белән көтәчәкмен... ”

Урманов уйланып тормады, мәктүбне күкрәгенә тыкты да җәмгыятькә керде. Зур зал шәкерт белән шыгрым тулы. Тик уртада гына түгәрәк ачыклык бар. Шул ачыклыкның кыйбла ягына яшел постаулы өстәл куелган, аның өстендә каләм, кәгазь, кара савыты тора. Өстәлгә терсәге белән таяна төшеп, рәис урынында Нәҗиб Кәмал, аның янында секретарь Җиһангир утыралар. Халыкның артында, ниндидер урындыккамы, нигәдер баскан, озын буйлы, иске сары казакилы, такыр башына иске соры кәләпүш кигән, саргылт карасу йөзе, хәлсез, ярым үлек карашы белән иске татар мәдрәсәсендә күп еллар уздырганлыгы күренеп торган, бераз бөкрерәк, шәкерт Хәким Кадыйри, сирәк-сирәк җүтәлләп, үзенең нотыгын дәвам иттермәктә:

– Һәрбер милләт, әфәнделәр, тәрәккый вә тәгали кылып[2], рәфаһәт[3], сәгадәт үзәренә хәят сөрә белүе иттифак[4], иттихад[5], гайрәт вә сәбат[6] аркасындадыр. Әфәнделәр, иттифак вә иттихад аркасында, гадәтләре аз булган гарәп милләте нәҗибәсе көррәи әрызның там нисфына хаким уларак[7], заманнарында дәһшәт биргән Рум вә фарсы дәүләтләрен зир-зобыр кылып, галәмнең ярымына хуҗалык итмеш... Галәмнең нисфына хәкаик исламия нуры нәшер идәрәк[8], рәфаһәт вә сәгадәт үзәренә[9] хәйат кичермеш... Иттифак вә иттихад аркасында, әфәнделәр, һичкемгә нам вә нәшьәне[10] мәгълүм булмаган кечек япун милләте бөтен җиһанга шәүкәте чәчелгән олуг Русиягә галәбә кылды[11]... Иттифак... Иттихад... Иттифак... Иттихад... Әфәнделәр, һәр

---

[1] *Пар ат* дип аңларга кирәк.

[2] *Тәгали кылып* – бөек булып.

[3] *Рәфаһәт* – муллык.

[4] *Иттифак* – бер сүздә булу.

[5] *Иттихад* – берләшү.

[6] *Сәбат* – ныклык.

[7] *Гарәп милләте нәҗибәсе көррәи арызның там нисфына хаким уларак* – гарәп милләтенең тәрбияле (намуслы) анасы Җир Шарының бөтен яртысына баш булып.

[8] *Хәкаик исламия нуры нәшер идәрәк* – ислам хакыйкатьләрен таратып.

[9] *Рәфаһәт вә сәгадәт үзәренә* – муллык һәм бәхет эчендә.

[10] *Нам вә нәшьәне* – исеме һәм барлыкка килүе.

[11] *Галәбә кылды* – өстен булды.

миллəт болар аркасында тəрəккый вə тəгали итеп, əүвеҗ сəгадəтə[1] ирешə. Без, иттифак вə иттихад булмаганнан, бу пришанлыга[2] төштек... Тəрəккый вə тəгали итеп, рəфаһəт вə сəгадəтə восулымыз[3] да фəкать, фəкать иттифак вə иттихад саясендə[4] генə улачакдыр... Безем бөек фидаимез мөхтəрəм Рəшид казый үзенең "Өлфəт"ендə һəм "Миръат"ларында тəкрар би тəкрар...[5]

Хатибка озак кул чаптылар. Төрле яктан: "Яшəсен иттифак! Яшəсен иттихад!" тавышлары күтəрелде.

Хəким Кадыйридан соң Əхмəров торды:

– Əфəнделəр, һəр миллəтнең мəртəбə галиясе[6] хатыннарының тəрбия вə тəрəккыйлəре мəртəбəсенə мөсави[7] була. Хатыннар – миллəтнең аналары. Ана ничек кылса, бала шулай була. Безнең миллəтнең артта калуы фəкать, фəкать хатыннарымызны дүрт стена эченə ябып, хиҗаб астында черетүемездəндер. Бетсен хиҗаб, безне шул артта калдырды. Һəр миллəтнең тəрəккый итүе хатыннары аркасындадыр. Нитəкки, Мисырның мəшһүр галимнəреннəн Касыйм Əмин бəк хəзрəтлəре үзенең "Тəхрир əл-миръат" нам əсəре галиясендə[74+] димеш...

Ул бетəр-бетмəс, секретарь Габдулла Хəлиминең исемен кычкырды. Аның нотыгы кыска иде:

– Əфəнделəр, һəр миллəтнең тəрəккый вə тəгали итмəге – балаларның гүзəл тəрбия кылынуына баглыдыр[8]. Бүгенге балалар – килəчəк көндə миллəтнең аталары, юлбашчылары, көтүчелəре булачак. Көтүче кая кауласа, көтү шунда барачагы мəгълүм. Шуңа күрə, əфəнделəр, диямен ки, һəр миллəтнең тəрəккый итүе – балаларның мотлак[9] тəрбия кылынуы саясендə генə мөмкиндер...

Бөтен галəм исламның мəбиһилифтихары[10] булган төрек фəйлəсуфы Əхмəд Мидхəт əфəнде хəзрəтлəре үзенең "Чучук", "Ана" һəм "Пəдəр улмак сəнгате" исемнəрендəге нəзыйрсез əсəрлəрендə[75+] бу хакта...

Габдулла əл-Хəлимидəн соң Хəлил Кəримов торып, ярлылык – динсезлек, йирсезлек – йитешсезлек, безнең барлык һəлакəтемез ярлылыгымыздан, йирсезлегемездəн, сəяси җиһəт[11] белəн кысылуыбыздан

[1] *Əүвеҗ сəгадəтə* – бəхетнең иң югары ноктасына.
[2] *Пришанлыга* – һəлакəткə, таркаулыга.
[3] *Сəгадəтə восулымыз* – бəхеткə ирешүебез.
[4] *Саясендə* – күлəгəсендə.
[5] *Тəкрар би тəкрар* – кабат-кабат
[6] *Мəртəбə галиясе* – югары дəрəҗəсе, бөеклеге.
[7] *Мөсави* – бəрабəр, тигез.
[8] *Баглыдыр* – бəйледер.
[9] *Мотлак* – һич шиксез.
[10] *Мəбиһилифтихары* – мактанычы, горурлыгы.
[11] *Җиһəт* – як, тараф.

дип, бик озак, бик ялкынлы нотык сөйләп: “Адәм балаларының сәгадәте тигезлек һәм хөррият аркасында гына мөмкин, без хөррият булмаганнан беттек...” – җөмләләре белән куәтле алкыш эчендә хотбәсен тәмам итте.

Аннан соң бер-бер артлы өч шәкерт торып, беренчесе: “Һәр милләтнең тәрәккыйсе фәкать хатыннары аркасында”, – дип; икенчесе: “Һәр милләтнең тәгали вә рәфаһәте фәкать, фәкать балаларының гүзәл тәрбия ителүенә баглы”, – дип; өченчесе: “Һәр милләтнең әүеҗ сәгадәтә[1] ирешә белмәге фәкать иттифак вә иттихад аркасында, сәгый[2], гамәл, сәбат вә мәтанәт[3], гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнәгать саясендә генә”, – дип.

Тарихи, иҗтимагый дәлилләр белән “исбат” кылган соң, кызу нотыклары белән танылган Сөләйман Сәйфуллин күтәрелде. Аның өстендәге кыска тужуркасы, җитү чәче, үткен карый торган күзләре, ялкынланып чыккан сүзләре чыннан да шәкерт фидаисе төсен бирәләр иде. Ул кычкырып кызып башлады:

– Иптәшләр!! Һәр милләт руханилар кулында. Безнең халык бигрәк тә!! Һәр татар мулланың авызыннан ни чыгар дип көтеп тора, ни чыкса – шуны хакыйкать дип кабул итә. Без артта калдык, без беттекме? Кем дисез? Безне кем бетерде дисез? Безне муллалар бетерде!! Без йокладык. Гасырлар буенча йокладыкмы? Безне муллалар йоклатты! Чөнки йоклаган гавамның гошерен, фитырын, садакасын, зәкятен, фидиясен талау җиңгел иде... Бездә муллалар наданнар, җаһилләр, гыйлемсез вә фикерсезләр... Болар – милләт микроблары... Болар – безне гасырлар буенча ашап, әүвәлге шәүкәтемезне бетергән, безне аяктан еккан зарарлы кортлардыр. Без милләт өчен тырышсак, без милләтемез тәрәккый итсен дисәк, тәрәккый вә мәдәният юлына аркылы кискә булып яткан ишаннар вә мөтәгассыйб муллалар белән көрәш башларга. Аларны бара торган юлымыздан читкә алып ташларга тиешлебез. Без мөфтине сайлап куярга, киләчәк муллаларның хөр фикерле, милләткә хадим булып чыгулары өчен тырышырга, аның өчен мәдрәсәләрне ислах итәргә кирәк... Шунсыз милләт тәрәккый тапмас... Милләтне ишаннар, муллалар батырды, бетсен андый муллалар! Бетсен милләт микробы булган ишаннар, бар да кадалсын!..

Хатибка озак кул чаптылар. Аның артыннан берничә оялчан кыюсыз шәкерт торып:

– Әфәнделәр, мин үз фикеремне әйтермен, дигән идем. Инде аны әүвәлге хатиблар әйтте.. Минем сөйләргә сүзем юк, зинһар гафу итә күреңез, – дип, кире утырдылар.

---

[1] *Әүеҗ сәгадәтә* – бәхетнең иң югары ноктасына.
[2] *Сәгый* – тырышлык.
[3] *Мәтанәт* – куәтлелек, түземлелек; эшендә, урынында, фикерендә нык тору.

Болардан соң теге “Икмәк беткән көй”не чыгаручы Хәйри аякка басты. Аның бик озын бишмәте, тары белене кебек ямьшәйгән кәләпүше, өсткә чыгып торган керле якасы, карасу шадра йөзе белән зур соры күзләре бигрәк тә зур борыны белән ничектер мыскылларга хәзер торгандай ике катлаулы иреннәре – сөйли башламас борын ук көләсене китерә иде. Эшләп арган картлар кебек бик акрын гына кузгалды да:

– Балалар, мин инде карт кеше... Миңа мәшәкатьләнмәгәндә дә ярар иде... – дип сүз башлады һәм берничә җөмлә әйтергә өлгерә алмады, бөтен зал белән көләргә тотындылар.

Рәис халыкны тынычландырды, хатиб дәвам итте:

– Мин, балалар, русча хакында берәр сүз әйтер идем. Безнең Төркиядә профессор булырга ярарлык табылган бер хәлфәбез Кәрим Гайфи бар. Шул зат үзенең “Мы учим һәндәсә” диюе белән приставның котын очырган... Монысы тагын бер хәл, бер урысның коты очудан дөнья җимерелмәгәндер, ләкин аның квартир марҗасына самавыр куй диясе урында авызына баш бармагын тыгып, ишарә белән аңлатырга тырышып газаплануын мин үз күзем белән күрдем... Монда милләт кайгырталар, татар милләте нидән артта калган, диләр. Мин әйтәм: милләт артта калган, без артта булганга; без артка калганбыз – бөтен гомеребезне истинҗа[1], хәез[2], нифас[3] укып үткәргәнгә, русча белмәгәнгә. Шуңар күрә дә мин әйтәмен: Аллаһ Тәгалә үзегезне Кәрим Гайфи көненә калудан сакласын дисәңез, балалар, русчага тотыныңыз...

Русча кирәк, гыйлем руста. Фән, һөнәр руста. Милләт шуның аркасында тәрәккый итәчәк... Безгә фарыз гаенне[4] кырык дип ятлаттылар. Инде ул кырык бер булды. Фарыз гаеннең кырык беренчесе – русча, русча, русчадыр, балалар... Сүзем шул, җитәр, хәлем бетте... Моңа бөтен зал күтәрелеп кул чапты. Русча гыйшкы һәммәнең күңеленә ерак, ләкин бердәнбер идеал кебек ашкындырып тартканга, Хәйри сүзе артык йөрәкләренә төште. Ләкин рәис Нәҗиб Кәмал аны нәфрәт белән тыңлады: русча уку кирәк, инде аны Мәнди анасы да белә[5], ләкин аның кирәклеге турында ник Кәрим Гайфине китереп тыгарга? Ул, хатибның сүзен бүлеп, берничә мәртәбә:

– Хәйри иптәш, фикереңез туры, ләкин сез юкка хәлфәне китереп кушасыз! Кәрим Гайфи безенең тарафта көлкегә мисал итеп сөйләнерлек адәм түгел. Сезнең белән мин мең ел тырышсак та, аның чаклы була

---

[1] *Истинҗа* – тәһарәт (тәрәттән соң пакъләнү).
[2] *Хәез* – күрем (менструация).
[3] *Нифас* – аналык каны.
[4] *Фарыз гаенне* – үтәлергә тиешле эшләрне.
[5] *Мәнди анасы да белә* – “*һәркем белә, һәркемгә билгеле*” мәгънәсендә.

алмаячакмыз, без аның кисеп ташлаган тырнагына тормыйбыз дияргә уйлады, ләкин үзен-үзе тыйды. Чөнки яңадан мәсьәлә кузгалачак, шау-шу китәчәк, Нәҗиб Кәмал мондый турыдагы мәҗлесләрнең күбендә булган кебек, Кәрим Гайфи хакында да ялгыз калачак.

Хәйри артыннан бөтен кыяфәте чыннан моталәга кешесе[1] икәнен сөйләп торган риязый[2] йөзле, ләкин яшь, күзлекле бер егет сүз алды:

– Әфәнделәр, һәрбер милләтнең тәрәккый итүе – матбугат вә әдәбият аркасындадыр. Мин кадим мәдрәсәнең схоластика диңгезендә ята, җәдидләргә һәр искелек – мөкаддәс, һәр яңа – гөнаһ вә бидгать, көфер вә заляләт[3] дип, көфер пичәте баса идем. Беренче милли шагыйрь мәшһүремез Мәҗит әфәнде Гафури хәзрәтләренең “Себер тимер юлы”атлы шигыре[76+] минем күземне ачты, мине искелекнең хатасыннан якты юлга күндерде... Бездә элгәре матбугат юк, әдәбият юк иде, без Гуҗ бине Ганк экиятләре белән тулган Рабгузый тарихларын[77+], әхлак өзгеч “Таһир-Зөһрә”, “Бүз егет” кебек нәрсәләрне[78+] укып гомер үткәрдек... Милләт әдәбият аркасында гына тәрәккый итә... Шуңар күрә без, милләтемезне тәрәккый итсен дисәк...

Риязый егет артыннан тагы берничәләр торып, бере – әдәбият, икенчесе хиҗаб дип, өченчесе балалар тәрбиясе дип, дүртенчесе хатыннар дип, бишенчесе иттифак вә иттихад дип, кайберәүләр русча дип, мәдрәсә ислахы дип, озын-озак нотыклар сөйләгән соң, рәис Нәҗиб Кәмал мәҗлесне ун минутка япты. Шәкертләр залдан чыгып, мәдрәсә вә коридор буена таралдылар.

## L

Тәнәфестән соң беренче нәүбәт Нигъмәт казыйга иде. Ул озын буе, калын гәүдәсе белән рәиснең янына ук килде дә калын, куәтле бик җитди тавыш белән сүз башлады:

– Безнең милләт ни өчен артта калган? Авыр, тирән һәм бик мөһим мәсьәлә! Боңар төрле сәбәпләр күрсәттеләр. Һәммәсе дөрест, ләкин шул сәбәпләрнең барын тудырган төп сәбәп бар. Мин шул, баш ватып, булган сәбәп хакында сөйләргә телим:

– Без ник беттек? – Авыр, куркыныч, шуның белән бәрабәр баштан чыгару мөмкин булмаган, еллар буенча газапланып, күп төннәрне йокысыз кичерергә мәхкүм иткән дәһшәтле бер сөаль!! Без беттек! Әйе, без беттек! Безне кем бетерде? – Һичкем бетермәде, без үзебезне үзебез бетердек. Бер сүз

[1] *Моталәга кешесе* – укучы, студент, белем алучы.
[2] *Риязый* – ябык.
[3] *Заляләт* – туры юлдан язу, ялгыш юлга керү.

белән әйтү кирәк булса, без гайн[1] мәдәният, гайн тәрәккый булган гали ислам динен хата аңлау аркасында беттек... Безнең бабаларымыз тарихта якты сәхифәләр...

Кемдер, кайдандыр сак кына сызгырды, Нигъмәт казый ул тарафка әйләнмәде, сүзен дәвам иттерде:

– Исламны гали, дим, гайн мәдәният, гайн тәрәккый, дим. Кемдер моңа сызгыра... Ләкин мин, бөтен дөньяга каршы чыкса да, фикеремдә сабит[2] калачак, исламның бөтен тәгълиматы вә рухы мәдәният белән кул кулдан барачак икәнен исбат кылачакмын...

Һәр каюңыз беләсез: исламның нигезе булган Коръән-Кәримнең иң беренче иңгән аятенең иң беренче сүзе "Икъраэ"[79+], кәлимәи таибәседер[3]. "Икраэ" димәк, "укы, бел, гыйлем ал" димәктер. Күренә ки, ислам диненең иң беренче кушканы, иң беренче сүзе, әмере "укы, бел, гыйлем ал" димәктән гыйбарәт. Башка һичбер дәлил булмаса, ялгыз шушы бер сүздә исламның мәдәнияткә, гыйлемгә дәгъват кылучы, аларга хезмәт итүче бер дин икәнен исбатка җитәр иде. Ләкин мин моның белән тукталмаячак, икънагый[4] дәлилләр вә исбатлар китерәчәкмен.

Хатиб сүзен дәвам иттереп, дәгъвасын исбат юлында "һәл йәстәүилләзинә йәгъләмүнә вәлләзинә лә йәгъләмүн"[80+], "таләбуль-гыйльми фаридзатүн галәл муслимин вә муслимәт"[*], "әл-хикмәтү дзалләтүлмуэмин, йәэхузуһә әйнә вәҗәдәһә"[**], "утлубуль-гыйльмә вә ләү биссыйн"[***] кебек бик күп аять вә хәдисләр китергән соң, тарихка күчте, ислам тарихының әүвәлге шәүкәтле[5] дәверен йөреп чыгып, Мәэмун, Һарун Рәшид заманнарын[81+], Әндәлес мәдәнияте[82+], мөселманнарның табигыят[6], риязият[7], тарих, җәгърафия[8], сәнәгать, тиҗарәт[9] вә әдәбиятта ни дәрәҗә тәрәккый итдекләрен, моның җанлы шаһиты уларак хәзерге көнгәчә сакланып, Европаның гакылын хәйран итмәктә булган "Әл-Хәмра", "Әл-Бәйда" сарайлары[83+] барлыгын Европа галимнәреннән фәләннәр исламның борынгы мәдәнияте хакында

---

[1] *Гайн* – үзе.

[2] *Сабит* – нык.

[3] *Кәлимәи таибәседер* – яхшы сүзедер.

[4] *Икънагый* – ышандырырлык.

[*] Хәдис. *Тәрҗемәсе*: Гыйлем эстәү – һәр мөселман һәм мөслимәгә фарыз".

[**] Хәдис. *Тәрҗемәсе*: " Хикмәт – мөэминнең югалткан нәрсәсе, кайдан тапса да алсын".

[***] Хәдис. *Тәрҗемәсе*: "Кытайга барып булса да гыйлем эстәгез".

[5] *Шәүкәтле* – көчле, бөек.

[6] *Табигыят* – табигать турындагы фән.

[7] *Риязият* – математика.

[8] *Җәгърафия* – география.

[9] *Тиҗарәт* – сәүдә.

ниләр сөйләгәнен берәм-берәм тәфсыйл итте вә шул сүзләр белән нәтиҗә бирде:

– Менә элек шулай иде, күзләреңезне тарихның шул нурлы сәхифәләреннән алып хәзерге көнгә баксаңыз, ислам дөньясы аталган ул гаҗәеп бакча урынында – олуг каберстан, олуг бер хәрабәдән башка нәрсә күрмәячәксез. Бу вәйранлык[1], бу пришанлыкны[2] күреп, күз яшьләреңезгә дәһшәтле бер сөаль туа:

– Бу нидән? Без ник беттек?

– Без ник беттек? Ул могҗиз бакчаны нинди явыз куәт караңгы хәрабәгә, пришан каберстанга әйләндерде?

Җавап кыска һәм ачык:

– Әүвәлгеләр мөселман иде. Алар исламның чын рухын аңладылар, шуның белән гамәл кылдылар, шуның аркасында заманнарының хакиме булдылар, мәдәниятнең югары дәрәҗәсенә менеп, тарихта мөкаддәс исем калдырдылар. Гасырлар үтте, ислам белән яһүд вә исраилият[3] бутала башлады. Бу соңгылар гакылларга хаким булды. Коръән-Кәрим баштанаяк тәгәккыл[4], тәфәккер[5], сәгый[6], гамәл, кәсеп вә тиҗарәткә тәшвикъ[7] белән тулы икән – мөселманнар моны онытып, яһүд әкиятенә бирелде, йирне үгез мөгезенә куйды, дөньяның гомерен җиде мең елга калдырып, тиздән кыямәт булуын көтә башлады. Дин бетте, калды тик заһири[8] гыйбадәт; ислам бетте, аның урынына каберләрдән ярдәм көтәчәк мәҗүсият калды, машинача үтәлгән намаз белән садака, зикр һәм тәсбих, исламда хәрам булган рәһбанийять[9] – дәрвишлек каплады: иҗтиһад мөнкариз[10] диделәр, гакыллар туктады, вөҗданнар сүнде, һәрбер тәҗәддед һәм тәфәккер капулары[11] бикләнде – ислам бетте, калды мәҗүсият, шуның белән без дә беттек, шуның аркасында җаһилләр мәйдан алды, гыйлем тапталды, шуның аркасында үзенең югарылыгы белән гакылларны хәйран калдырган ислам мәдәнияте бакчасы караңгы хәрабәгә, вәйран каберстанга әйләнде. Мин каты күңеллемен, ләкин хәзерге минутта күземә килгән яшьне такатем җитми... Ләкин җылау авыру хатыннар эше, без җылап гомер үткәрергә тиеш түгел,

---

[1] *Вәйранлык* – җимереклек.
[2] *Пришанлыкны* – таркаулыкны, һәлакәткә төшүне.
[3] *Исраилият* – яһүдләрнең дини әдәбияты.
[4] *Тәгаккыл* – акыл йөртү, аңлау.
[5] *Тәфәккер* – фикер йөртү, уйлау.
[6] *Сәгый* – тырышлык.
[7] *Тәшвикъ* – өндәү.
[8] *Заһири* – тышкы.
[9] *Рәһбанийять* – монахлык.
[10] *Иҗтиһад мөнкариз* – тырышлык юкка чыккан.
[11] *Тәҗәддед һәм тәфәккер капулары* – яңару һәм фикерләү ишекләре.

милләт төшкән икән, аны күтәрергә, аны күтәрүнең чарасын эзли башларга кирәк.

– Чара кайда? Нидән гыйбарәт?

Моның җавабы да ачык һәм кыска. Мөселманнар исламның рухын аңлап, шуның белән гамәл итү аркасында бу вакыт мәдәният вә хакимият баскычының иң югарысына менделәр. Яңадан тәрәккый итү, яңадан яшәп мәдәниятле булу өчен, бердәнбер чара шул гали исламиятне яһүдият вә мәҗүсияттән кергән хорафатлардан яклау, аны Хәзрәти расүл тәгълим итмеш[1] әүвәлге сафлыгына кайтарудыр. Исламны хата аңлау безне бетерде, яңадан күтәрелүемез дә шул хатаны ташлау аркасында гына мөмкиндер.

Хатибка, бөтен залны күтәреп, кул чаптылар, күпләр аны тәбрик итеп кулын кыстылар, үзенә мактадылар.

Сәгать ярым дәвам иткән бу нотык сүнде, куәтле тәэсир бирде ки, шәкертнең һәммәсе диярлек "инде мәсьәлә төбе-тамыры белән ачылды, яңадан сүз әйтерлек урын калмады" диеләчәк бер хәлгә килделәр.

## LI

Шуңар күрә дә секретарь Җиһангирның "Давыд Урманов" дип кычкыруына каршы һәммә шәкертләр ишек яңагына сөялә төшеп торган Урмановка хәйрәт белән[2] карадылар. Гүя:

– Ничек?! Инде тагы ни сөйләргә мөмкин? – диләр иде. Урмановның якын дустлары да: "Юкка башлый, кирәкмәс иде инде", – дип уйладылар. Ләкин Давыд аңа карамады. Аның йөзе агарынган, күзләре куәт белән, җиддият белән карыйлар иде. Гадәттә дә якты булып, бүген ниндидер аерым бер нур илә балкыгандай күренгән кебек, маңгаена төшкән чәчләрен сул кулы белән сыпырды да, акрын, сабыр, ләкин эчке тәэсирле тавыш белән сөйләргә тотынды:

– Без ник беттек? Бу мәсьәлә шундый тирән, шундый мөшкилләрдән ки, моны шәкерт мәҗлесендә кузгатып, һәркемнән фикер саттыру түгел, бөтен гомерен мөселманнарның дине, тарихы, иҗтимагый, сәяси, иктисадый хәлләрен тикшерү юлына корбан кылган фән әһеле дә бу мәсьәләгә тиз генә ачык бер җавап биреп ташлаудан тартынырга мәҗбүрләр... Һәркем белгәнен ата... Мин дә бер-ике сүз әйтеп үтәргә мәҗбүрмен. Минем сүзем бигрәк тә Нигъмәт казый тарафыннан сөйләнгән гомуми фикер мөнәсәбәте белән булачак...

Сүзем кайбер иптәшләргә ятрак тоелуы мөмкин. Шунлыктан мин бик

[1] *Хәзрәти расүл тәгълим итмеш* – пәйгамбәребез өйрәткән.
[2] *Хәйрәт белән* – аптырап, гаҗәпләнеп.

аз гына мөкаддимәләргә[1] тиешлемен. Бу мәҗлестә сөйләүче хатибларда мин үземнең кичердегем[2] дәвердә инкыйлабларны күрәм. Сезнең кебек мин дә иске татар гаиләсендә, иске тәрбиядә яшәгәнмен. Сезнең кебек мин дә кадим мәдрәсәләрнең берендә, бәлки, иң мөтәгассыйбләреннән[3] саналган мәшһүр Нури хәзрәттә егермегәчә тәхсилдә[4] булганмын. Риязый иптәшемез кәрамәтнең[5] дидегенчә, мин дә бер вакытлар һәр искелек мөкаддәс, һәрбер яңалык көфер вә бидгать игътикатында[6] идем. Мантыйк белән кәлямдә мөмкин кадәр югары ашу – минем гаям[7] иде.

Һинднең мәшһүр галимнәреннән Мәүланә Габделхәйне[84+] ишеткәнсез... Мин шуның белән ярышу дәртендә идем. Бу вакытлар дөньяда хәят хакындагы тасвирым миңа үзебезнең дин китапларыбыздан алынып, намазлыктан төшми, тәсбих тартып утырган әбиләрнеке белән бер төсле иде. Аллаһ "кун фәйәкун"[8] әмере белән җиде көн эчендә йир-күкне яраткан, кяинатның[9] үткән гомере җиде мең ел, инде тиздән ахырзаман киләчәк. Кайдандыр бәни Әсфәр дигән кавем[85+] чыгачак, йир йөзен алачак, хәлифә "ливауль-хәмде"не күтәрәчәк[86+]. Мөселманнарга мөкаддәс җиһад фарыз булачак. Дәҗҗал, Мәһди, Гайсә[87+], белмим тагы кемнәр киләчәк, йир йөзенең кара туфрагын яәҗүҗ-мәәҗүҗләр[88+] ашап бетерәчәк. "Даббәтүл-әрдз" чыгып, бер кулында Сөләйман йөзеге, икенчесендә Муса таягы булдыгы хәлдә[89+], "син – кяфер", "бу – мөселман" дип, һәркемнең маңгаена мөһер басып чыгачак. Соңра хәят бетәчәк. Һәммә җаннар алыначак... Аннан соң кыямәт... Пәйгамбәремез: "Бәдәэль-исламу гарибән, сәягуду гарибән"[10], – дигән. булгач, мөселманнар хур, зәлил[11] бетәргә мәхкүм[12]. Инде башка юк, намазыңны укы, садакаңны бир дә, зикер вә тәсбихтә дәвам итеп, Ходайдан Дәҗҗал гаскәренә иярмәүне, дөньядан иман белән үтеп, кабердә Мөнкир-Нәкиргә[90+] җиңгел җавап бирә алуны, гамәл дәфтәрең уң кулга бирелүне, сираттан яшен кебек кичеп, оҗмахта хур кызлары белән мәңгелек сәгадәткә чумуны сора... Чын мөселманга шуннан башка нәрсә калмаган иде.

---

[1] *Мөкаддимәләргә* – кереш сүз әйтергә.

[2] *Кичердегем* – кичергән.

[3] *Мөтәгассыйбләреннән* – фанатикларыннан.

[4] *Тәхсилдә белганмын* – укыганмын, гыйлем алганмын.

[5] *Иптәшебез кәрамәтнең* – хөрмәтле иптәшебезнең

[6] *Игътикадында* – ышануында.

[7] *Гаям* – төп теләгем.

[8] *"Кун фәйәкун"* – " 'бул' дисә була".

[9] *Кяинатның* – галәм, бөтен дөньяның.

[10] "*Бәдәэль-исламу гарибән, сәягуду гарибән"* – "Ислам чит булып башланды, чит булып кайтачак" (*хәдис*).

[11] *Зәлил* – хурлыклы, түбән, кадерсез.

[12] *Мәхкүм* – хөкем ителгән.

Яшь вакыт тирә-ягыңның колы булсаң, мин дә шул игътикадта булдым. Күк капуларын көттем, догалар укыдым. Ләкин болар мине, бара торгач, тончыктырдылар. Күзне ачып дөньяга үземчә карый башлау белән, минем бу “бетәргә, дәҗҗал көтәргә” мәхкүм ясаган игътикадым каушый башлады.

Аннан соң шул табигый дәверләр. Мин ислахый шәкерт: мәдрәсәләр начар, милләт артта, безне схоластика харап иткән, мәдрәсәгә яңа низам булсын, тәфсир, хәдис, гарәбият, русча, тарих, җәгърафия укылсын, дим. Шундый үзем кебек, киртекле якалы казаки киеп, чәчне кире сыпыра төшеп йөри башлаган мөтәрәккый иптәшләр белән караңгы тыкрыкларга качып, тәмәке тартам, фикер сатам, хәлфәләр сүгәм...

Шулвакыт кулыма эләккән әдәбият китапларыннан, исламны тәрәккый иттерү өчен, яңа тәртипле мәдрәсәне, тәфсир вә фәлсәфәи динияләр[1] кирәген аңлыйм. Коръәнгә гыйшкым чиксез була... Анда милләтне тәрәккый иттерәчәк бердәнбер хикмәт күренә.

Киләм мәдрәсәи исламиягә. Иң беренче гаям – ислам тарихы, фәлсәфәи диния һәм Коръән тәфсире. Мин яңа фикерлемен, ләкин игътикадым бик камил. Шул дәрәҗәдә ки, бу мәдрәсәнең кайбер мөгаллимнәре хакында “ул мизан белән сиратка да ышанмый, имеш” дигәнне ишеткәч, әгәр дә шул сүз дөрест булса, беренче дәрестән үк бу мәдрәсәне ташларга карар бирәм.

Мәдрәсә, мондагы ислам, Коръән хикмәте хакындагы дәресләр миңа шундый охшыйлар ки, мин шатлыктан, сәгадәттән бөтенләй исерәм, бөтен игътикадым белән фәзаиле исламия гашыйгы[2] булып, актык акчаларыма шул шул хакта китаплар җыя башлыйм. Мәдәният вә ислам, ислам вә тәрәккый, Коръән вә фәлсәфә, ислам вә голүм – болар белән мин бөтенләй җенләнеп бетәм.

Алган дәресләрем, бигрәк тә Әфгани, Габдеһ, Тантави, Фәрид Вәҗди[91+], Әхмәд Мидхәт[92+] кебек галимнәрнең гыйшык вә сихер дип аталырга ярарлык бер ашкыну белән моталәгә иткән һәммә әсәрләре миндә шундый бер ачык вә катгый игътикад тудыралар.

Ислам – мәңгелек бер нур. Ул үзенең могҗиз бер яктысы белән бәни адәмгә тугры юл күрсәтә, бу юлдан баручылар ахирәттә җәннәт нигъмәтенә, дөньялыкта мәдәният вә хакимияткә ирешәчәкләр. Борынгы мөселманнар һәм шулай булдылар да. Ләкин соңгы берничә гасырда ул мәңгелек бер нурны исраилият һәм дә мәҗүс хорафаты[3] болыты каплады. Мөселманнар хакыйкый исламнан яздылар, шунлыктан һәлак булдылар. Ислам милләтен аякка бастыру, аны яңадан тәрәккый вә мәдәниятле ясау өчен, шул мәңгелек

[1] *Фәлсәфәи динияләр* – дин фәлсәфәсе.
[2] *Фәзаиле исламия гашыйгы* – исламның өстенлекләрен хөрмәт итүче, сөюче.
[3] *Мәҗүс хорафаты* – потка табынучыларның ышанулары, гадәтләре.

нур булган исламны каплаучы яһүд мәҗүсият болытларын таратып, саф вә хакыйкый исламга кайтудан башка чара булырга мөмкин түгелдер...

Мин шулай игътикад кылдым. Мөхәммәд Габдеһ вә Әфгани – минем идеалым, мин үземне шуларның өченчесе ясарга тели идем. Бая Нигъмәт казый бәян иткән дәлил вә исбатлар минем телемдә тәсбих урынында йөри иде. Ләкин ул минем фикри тәкәммелемнең[1] күп баскычларыннан бере булып калды. Мин монда туктамадым. Тагы югары атладым, миңа яңа галәм ачылды. "Без ник беттек? Без нинди юл тотарга тиеш?" сөаленә минем алдымда ачылган яңа фикердә хәят галәме:

– Безне ислам бетерде, дин бетерде, залим хөкүмәт бетерде, – дип җавап бирде. Сүзем яңлыш аңланмасын, һичбер халыкның бер генә сәбәп белән күтәрелеп китүе мөмкин булмаган кебек, нинди дә булса бер милләтнең төшүе, бетүе дә тик бер генә сәбәптән дип әйтү – сабыйлык, балалык булачак. Күтәрелүдә дә төшүдә тарихи, җәгърафи, иҗтимагый, сәяси вә икътисадый, белмәм, тагы бик күп сәбәпләр роль уйный... Мөселманнар бервакыт күтәрелгән... Инде төшкән. Моның безгә мәгълүм сәбәпләреннән башка дәхи[2] адәм күзе серенә төшенә алмаслык мең, миллион вак сәбәпләр бар ки, болар, барлыгы җыелып, бик мөһим куәт ясыйлар. Тарихи як бар, җәгърафи як бар... Сәяси, икътисадый яклар бар. Боларның һәрбере менүдә дә, төшүдә дә зур роль уйныйлар. Ләкин хосусый бу матдә, хосусый бу безнең милләттә башка меңнәрчә сәбәпләргә дә тәэсир кылган, аларны тудырган куәтле төп бер сәбәп эзләүчеләр, югарыда әйттегемчә, диндер, исламдыр, хөкүмәттер, залим иске идарәдер, дип җавап бирәчәкләр... Диннең мондый тәэсиренең бөтен чиркен[3] йөзе белән мәйданга чыккан урыны шөбһәсез...

Ләкин аңар сөйләргә ирек бирмәделәр. Күпләр баштан ук аның тел төбе кая барганын сизәләр, ләкин моңарчы бик артык яратылып килгән бер хатиб булганга, тавыш кузгатырга, туктатырга батырлык итә алмыйлар иде. Давыд, үзенең мөкаддимәсеннән үтеп, асыл фикерен ачыктан-ачык әйтә башлагач, сабырлары төгәлде. Иң элек дүртенче галинең[4] өлкәннәре, алар артыннан башкалар да бик каты сызгырырга, аяк тибәргә тотындылар... Хатиб: "Минем хакым бар, сөйләргә бирегез!" – дисә дә, шау-шу аны каплады, төрле яктан:

– Кирәкми, сөйләмәсен!!

– Долой... Долой!! – дип шаулаша башладылар.

Урманов, бәлки, үзләре үк тынарлар дип, шул ишек яңагына сөялгән

---

[1] *Фикри тәкәммелемнең* – фикер үсешемнең.
[2] *Дәхи* – тагын.
[3] *Чиркен* – начар, яман.
[4] *Дүртенче галинең* – югары сыйныфта дүртенче ел укучыларның.

хәлдә сабыр итеп торса да, җәмәгатьтә туктау чамасы күренмәде. Ахырда рәис, аякка басып:

– Иптәшләр, без көн-төн хөррият, димез... Шуның өчен идарә белән көрәшәмез, ә үземез бик аз гына яңа фикер әйтүчене дә тыңлый алмыйбыз. Бу – безгә оят, бик зур оят. Сез беләсез, мәҗлес хөр, һәркем үз фикерен сөйләсен, хата булса, дәлил белән рәд кылырсыз[1]. Хатиб әфәнде, дәвам итеңез! – дигәч кенә, халык бераз басылды. Урманов яңадан башлады:

– Мин бер динне икенчесеннән аерып сөйләргә лөзүм[2] тапмыйм. Ислам белән христиан голямасы арасында байтактан бирле кызык бер моназарә дәвам итә: бу ике диннең кайсы мәдәнияткә, гыйлемгә дошман, кайсы – дуст? Бу хакта күп китаплар язылган. Табигый, мөселман голямасы исламны мәдәнияткә өндәүче, христианны аңа каршы баручы дип исбат итә. Христианнар киресенчә. Һәр ике як меңнәрчә аять вә хәдис китерә. Исламның мәдәнияткә мөнәсәбәте хакында Нигъмәт казый күп ныклы дәлилләр китерде. Теләсәм, мин шул ук Коръән вә хәдистән нәкъ аның киресенчә меңнәрчә аять вә хәдис табар идем. Һәм Ишмөхәммәт дамелла кебек галимнәр шулай әйтәләр. Исламның мәдәнияткә каршы икәнен Коръән вә хәдис белән исбат кылалар. Шул дәлил ныклы һәр ике якка табылачак. Шуңар күрә мин аны бер якка куям, мин исламның хәят вә мәдәнияткә мөнәсәбәте хакында мөселманлыкның мең өч йөз еллык тарихи килешен ялангач фактны алам.

Диннәр җөзьи[3] канун вә тәгълиматлары белән бер-береннән ачык аерылсалар да, үз әһелләренә булган тарихи мөнәсәбәтләрендә алар бер-беренә бик охшыйлар. Һәрбер дин үзе эчендә туган кавемне башта күтәрә, аңа зур куәт бирә. Ләкин шул ук дин заманнар үтү белән кыса, үз әһелен тәрәккыйдән тыя башлый. Бу факт һәм табигый факттыр. Сез Аурупада дүртенче гасырдан алып, уналтынчы гасырга кадәрле гыйлем белән католик арасында нинди көрәш дәвам иткәнен ачык беләсез. Озын сүзгә хаҗәт юк, тарихи вакыйгалар күз алдыңызда... Тарих ул вакытта гыйльме тәхкыйкат[4] белән мәшгуль булудан башка гөнаһысы булмаган меңнәрчә фән әһелләренең, католик диненә каршылыкта гаепләнеп, утка ягу вакыйгасы белән тулы...

Алыңыз берничә затны... Һич булмый икән, иң мәгълүм Бруно, Галилео, Ньютон, Коперник кебекләрнең исемен, мәшһүр инквизиция

[1] *Рәд кылырсыз* – кире кагарсыз.

[2] *Лөзүм* – кирәк, тиеш.

[3] *Җөзьи* – өлештә, ягъни “*кайбер нәрсәләргә бәйләнешле*” мәгънәсендә.

[4] *Гыйльме тәхкыйкат* – бер нәрсә яки мәсьәләнең дөреслеген тикшереп табу, хакыйкатен эзләү фәне.

җәмгыятьләрен[93+], аларның фәнгә каршы нинди кан дәрьялары агызганын искә төшерегез!.. Католик дине башта адәмнәр өстендә хакимият сакларлык мәртәбәдә көчле иде, шул көч вә хакимияте кулында бар мөддәттә ул фән вә гыйлемне басты, әһле фәнне яндыруда дәвам итте. Ләкин, бара торгач, католик дине үз эченнән череде, көч, хакимият бетә, әһле фәнне җиңә алмый башлады. Менә шуннан соң гына гыйлем мәйдан ала алды. Гыйлем вә һөнәрнең хәзерге камил хөррияте католик дине тарафыннан адәм гакылына вә адәм рухына салган авыр богауларын өзгәннең соңында күп корбаннар бәрабәренә генә насыйп булды.

Бездә, ислам йортында да, шул ук хәл. Борынгы мөселманнарда мәдәният бар иде. Аны инкяр кылмыйм. Ләкин сез шунарга дикъкать итеңез: ул мәдәният ислам диненең теләве, исламиятнең кушуы һәм өндәве сәбәпле дөньяга килдеме, әллә аның ихтыярыннан башка, ихтимал, аның теләвенә каршы улаpакмы?.. Уйлаңыз, Әмин, Мәэмүн хәлифәләрнең йир шарын үлчәвенә каршы дини голяманың көфер мөһере басуларын!.. Хәтерләгез, фәннең иң садә тәшәббесе[1] булган шул эшкә каршы Сакытдин исеме илә мәшһүр булган берәвенең[94+] башлавы белән дини голяма тарафыннан нинди гаугалар, тәкфирләр күтәрелүен!.. Хәтерләгез ибн Рөшдне!.. Шул мактаулы мәдәниятле Әндәлестә шул бөек мәдәниятнең якты йолдызы булган ибн Рөшд[95+], шул хөр уйлаудан башка гөнаһысы булмаган ибн Рөшд ниләр күрмәде?! Дини голяма, җыелып, ничә мәртәбә тәкфир кылдылар гына түгел, аны, мәсҗед алдына утыртып, үткенче дәрвишләрдән йөзенә төкерттеләр! Бер ибн Рөшд түгел, теләсә кай заманда, теләсә кайбер шәһәрдә бер мөселман галиме бөтен хөррияте белән гыйлемгә, фәнгә, табигатьне аңларга, үзе аңлаганча игътикад кылырга бирелә икән, дини голяманың аңа көфер мөһерен баса торганын, беренче гасырдан алып иң мәдәни вә иң мөтәрәккый көннәрдә дә шул хәлнең гомуми рәвештә дәвам иткәнен ислам мәдәниятенең сирәк фән йолдызы – Ибн Сина, Фараби, Ягъкуб Кинди, Рази[96+] кебек һәммә фән әһеле дини голяманың туктаусыз тәкфире астында яшәгәнен сез бик ачык беләсез...

Дин сакчылары һәрвакыт шул рәвеш фән хадимнәрен басарга һәм тәхкыйкатьтән туган гыйльми нәзарияләрне тәкфир куәте белән капларга тырыша бирде.

Ләкин бу эшендә тиз генә муаффәкыять күрә алмады. Чөнки ул заманда мөселман исеме астына кергән халыкларда гыйлем вә мәдәният тудыра торган хәят көче диннең куәтеннән өстен иде. Шуңа күрә фән һәм мәдәният хадимнәре бөтенләй җиңелмиләр, дини голяма тыпырчына, ләкин куәтле

[1] *Тәшәббесе* – бер эшкә тотынуы, керешүе.

чишмә кебек бәреп торган табигый хәят көчен бөтенләй каплый алмый, мәдәниятне туктатырга хәле килми иде... Заманнар үтте. Дин белән аның каршысында булган мәдәниятне тудыручы хәят көче арасындагы бу муазәнә[1] алышынды, бәреп торган чишмәнең төптәге куәте кимеде, халыктагы хәят көче сарыф кылынып бетте. Инде дин куәте өсткә чыкты, мәйдан аның хакимиятенә бирелде һәм, шул вакыттан башлап, дин үз хакын күрсәтә, фәнне таптый, мәдәниятне сүндерә башлады. Шул дәрәҗәгә йитте ки, шул мактаулы, бөек мәдәниятле Әндәлес хәлифәләреннән кайбере дин голямасының хәтере өчен хөр уйлаучы мөселман мөтәфәнниннәренең[2] асары[3] белән тулган йөзәр мең җилдле[4] кыйммәтле китапханәләрне утка ягудан кире тормадылар. Моңар кан-яшь агълаучылар булды, ләкин каршы торучы чыкмады. Чөнки хәзер муазанә алышынган бер вакытлар шул китапханәне тутырган фән әһелен тудыручы хәят көче сарыф кылынып, бизмәннең дин ягы күтәрелгән иде инде...

Инде намаз, руза, тәсбих, садака дәрвишлек вә ма әшбәһегә[5] нәүбәт...

Нигъмәт казый түзмәде, хатибны бүлде:

– Болар һәммәсе дөрест, ләкин без боларга: “Юк, дин голямасының ул эше, ул тәкфире исламны аңламаудан яки шәхси гарызыннан иде”, – дип җавап бирәмез...

Урманов дәвам итте:

– Бик яхшы! Бик яхшы! Сез гаҗәп кызык ноктага китереп терәдеңез! Сез шулай җавап бирәчәксез, мин аны беләм, ләкин бу җавап бик иске шул. Аны католиклар сөйләде, әле дә сөйлиләр. Алар гына түгел, моннан егерме биш гасыр элек юнан мәдәнятенең алтын дәверендә[97+] без дин әһеле шулай дип үзен акларга тырышканын күрәбез. Ислам голямасының бер төрлесе – ислам гайн[6] мәдәният, гайн тәрәккый, аны мәдәниятебезгә каршы күрсәтүчеләр динемезне аңламыйлар, диләр. Моны һәрбер дин үз башыннан кичерә. Хәзер безгә нәүбәт, күрәсең... Диннең шундый кызык бер табигате бар. Ул башта милләтнең куәтен арттыра. Урыны белән хакимият тә бирә. Соңра шул ук дин, бөтен куәт вә хакимиятне үз кулына алу өчен, башка һәрбер көч белән, шул җөмләдән фән белән дә көрәшә башлый. Үзендә куәт вә хакимият бар мөддәтен көрәшүне дәвам иттерә, дин сакчылары Аллаһ исеменнән хөр уйлауны, фәнни мәдәниятне хәрам ясыйлар. Бер вакыт килә, диннең көче кими, кулыннан хакимият алына, хөр уйлаучыларны таптау

---

[1] *Муазәнә* – тигезлек.
[2] *Мөтәфәнниннәренең* – күп фән белүче галимнәрнең, энциклопедистларның.
[3] *Асары* – әсәрләре.
[4] *Җилдле* – томлы.
[5] *Ма әшбәһегә* – шуның кебекләргә.
[6] *Гайн* – Үзе.

мөмкин булмый башлый – гыйлем вә мәдәният өсткә чыга... Шуннан соң, әле күптән түгел Аллаһ исеменнән фәнне хәрам ясаган дин әһеле: юк, безнең динемез мәдәниятkә каршы түгел, динемез – гайн мәдәният, гайн тәрәккый. Борынгылар яңлыш аңлаган, шуңар күрә каршы барганнар, ул – хата, гыйлем белән дин бертуган кардәшләрдер, – дип, килешү юлына төшәләр. Бу хәл табигый да. Еллар буенча ике дәүләт сугышкан. Каюсы җиңелсә, шул солых сорый. Гыйлем белән дин дә шулай. Юнанның иске дине башта каршы торды. Ләкин Арасту[1] заманнарына килгәч, ул үзен гыйлемгә татбикъ кылырга[2] мәҗбүрият күрде. Европада католик унике гасыр гыйлемне таптады, фән әһелен утка якты, бер вакыт килеп, хакимият кулдан киткәч, шул ук католик галимнәре үз диннәренең гыйлемгә, мәдәниятkә каршы булмавын, ул гайн мәдәният, гайн тәрәккый икәнен сөйли, исбат итә башладылар. Бу көнгәчә бөек католик галимнәре шул хакта калын-калын китаплар язуда, католикны мәдәниятkә татбикъ итеп, ике араны килештерергә тырышуда дәвам итәләр. Могҗиз бер куәт мәйданга килеп, гыйлемнең хәзерге куәте кимесен, рум папасы яңадан уникенче гасырдагы дәрәҗәдә хакимият алсын, шул ук католик исеменнән фән әһеле утка ягыла башланачак, тагы инквизицияләр күтәрәчәк... Ислам галәмендә Габдеһ, Әфгани, Фәрид Вәҗди вә Әхмәд Мидхәт кебек галимнәр нык динемезнең һәрбер хөкемен фәлсәфәләп, хикмәтләп, мәдәниятkә татбикъ итәргә маташулары, шул юлда җилдләрчә[3] китаплар язулары, бар көчләре белән, искеләр динне яңлыш аңлаган дип, ислам белән мәдәниятне килештерергә тырышулары – бу яңа һәм безгә махсус эш түгел. Моны Юнанның мәҗүсияте Арасту дәверендә кичерде, буны католиклар рум папасының әүвәлге хакимияте беткәч башлап, хәзергәчә дәвам иттерәләр. Бездә дә Европаны аңлау, гыйлем вә мәдәният ниһаясез[4] булган авторитетын күрә башлаудан соң камил җиңелүнең мәҗбүрияте белән килеп чыккан табигый бер хәлдер. Фән хәзерге бер мәртәбәдә бөек авторитетлы булмаса, фәнгә каршы булу – хаталык дип аңлау гадәт хөкеменә кермәсә, Әхмәд Мидхәт тә, Габдеһ белән Фәрид Вәҗди дә ул дәрәҗәдә көчәнмәсләр, ул дәрәҗәдә җан тирләрен чыгара-чыгара исламны мәдәниятkә муафыйк ясарга, гыйлем белән исламны татбикъ итәргә азапланмаслар иде. Бер як җиңелгән, шуңа күрә солых сорый; фараз итеп, гакыллар да авторитеты фәннекеннән югары булса, эшләр киресенчә булыр, ислам үзен мәдәниятkә татбикъ белән маташмас, бәлки гыйлем вә фән, үзенең базары бөтенләй югалмасын өчен, һәрбер хөкем вә

---

[1] *Арасту* – Аристотель.
[2] *Татбикъ кылырга* – яраклаштырырга.
[3] *Җилдләрчә* – томнарча.
[4] *Ниһаясез* – чиксез.

канун шәригатькә, аның тәгълиматене татбикъ кылырга тырышыр иде. Чөнки җиңелгән дәүләт солых сорарга мәҗбүр. Нигъмәт казый тагы сабырсызланды:

– Бу, иптәш, тарихи сукырлык! Бер уч бәдәви гарәпнең куәтле дәүләт ясап, ярты дөньяга хакимлек итүләре – фәкать ислам тәэсире белән идекен Европа мөәррихләре[1] дә тасдыйк кылалар[2]. Аны мин дә инкяр итмим. Бер ислам түгел, һәр дин шулай. Һәр диннең әүвәлге көннәре бар, һәр дин шул эчендә яшәгән халыкның куәтле ихтыяҗыннан туганга, шул халыкка шул яңа туган тәэсир белән бик зур куәт була. Ул халыкны күтәрә, гарәпләр шикелле, дөньяга хаким ясый. Моны инкяр сукырлык булачак. Бу тарих белән сабит[3]. Ләкин дингә мәңгелек төс бирәләр. Хатаның зурысы менә шунда! Дин килә, зур куәт бирә, халыкны күтәрә, ләкин ул, шул башта килгән калыбында катып, тәмам эшләнеп кала. Хәят исә тик тора алмый, ул көннән-көн үзгәрә, үсә. Моны шулай аңларга мөмкин. Сезгә җиде яшегездә чакта бик матур тирән бүрек текteләр. Ул сезнең башыңызга үлчәнгәнгә, шул вакыт бик ярый, суыктан саклый. Ләкин сез үсәсез, ун еллар үтә, башыңыз зурая, бүркеңез исә әүвәлге хәлендә. Шул вакыт бүрек сезнең башыңызны кысачак, ярамаячак. (Минем мисалым бик артык тупас булды... Ләкин мисалга мөнакашә[4] юк, диләр). Дин дә шулай. Моннан өч йөз еллар элекке бер вакытның, шул эчендә яшәгән бер халыкның ихтыяҗыннан туган бер дин инде унөч гасыр буенча туктаусыз үзгәрә, үсә килгән бер хәятка ярамый, тар була. Моннан баш изелергә, җә бүрек җыртылырга мәҗбүр. Күрәмез, бүрек исән, ләкин баш изелгән, мөселман беткән. Әйтергә телим ки, диннең тарихи бер дәвердәге куәтен инкяр сукырлык булачак, ләкин аңар һәр йирлек, мәңгелек төс бирү – зур хата. Әйтергә телим ки, дин билгеле бер калыпка сугылган, эшләнгән, беткән. Хәят исә туктауның, мәгълүм бер шәкелнең ни икәнен белми. Ул дию адымнары белән баруда дәвам итә... Мәдәният вә тәрәккый менә шул туктаусыз аккан, җәелеп күтәрелеп барган хәятның терәге я куәтләредер. Дин белән мәдәниятне татбикъ[5] бу икенең асыл рухларын аңламаудан башка нәрсә түгелдер. Әгәр дә мин хакыйкый мөселман булсам иде, динемез гыйлемгә каршы түгел дип, динне мәдәнияткә татбикъ кылып маташуда исламга зур, бик зур тәхкыйрь бар, дияр идем. Чөнки бу татбикъ исламның җиңелүен игътирафтыр[6]. Инде нәтиҗә: “Без ник беттек?” сөаленә биреләчәк җавапта бу бетүнең күп сәбәпләре тәфсыйл кылыначак булса, иң мөһим

[1] *Мөәррихләре* – тарихчылары.
[2] *Тасдыйк кылалар* – раслыйлар.
[3] *Сабит* – ачык, бу урында “*тарихтан күренә, тарих шуны күрсәтә*” мәгънәсендә.
[4] *Мөнакашә* – бәхәс, сүз көрәштерү.
[5] *Татбикъ* – яраклаштыру, килештерү.
[6] *Игътирафтыр* – таный.

сәбәпләрдән берсе итеп, диндер, исламдыр... иске хөкүмәттер... диючене хата санамас...

Хатибка сүзен әйтергә мөмкин булмады, тагы берьюлы берничә яктан:

– Юк, кирәкми, сөйләмәсен!

– Долой... Долой!!

– Бетмәс монда чабаталы дәһриләр... – дип, шау-шу күтәрелде.

Әллә ничә йирдән Давыдка җавап бирмәк булып, “һәл йәстәүилләзинә йәгъләмүн... икъраэ гыйльмү әүләдәкүм”[1] дип, аять вә хәдисләр укый, икенче яктан “Әндәлес, Әл-Хәмра, Багдад[98+], Граната[99+] һәм Кортүбә[100+]” дип, өченче яктан “сукыр дәһри, бозау, дәһри малае, мөкаллид[2], чабаталы дәһри” дип акырышырга тотындылар. Зал тавыш белән тулды. Җәмгыять буталды, мәҗлеснең тәртибе бөтенләй югалды. Бар да Давыдка каршы баралар, тик Баязид карый, җырчы Сахиб, Камил, Хәйри, Сөләйман Сәйфуллин кебек берничә егет кенә:

– Юк, иптәшләр, болай шаулашуда мәгънә юк! Фикере хата булса, җавап бирергә кирәк! – дип, халыкны тынычландырырга тырышалар иде.

Озак шаулап, арый башлагач кына, бик күп мәшәкатьләр белән рәис мәҗлесне яңадан тәртипкә кертте. Шулвакыт кемдер:

– Дини мәдрәсәдә дәһрият[3] сату егетлек түгел, – диде. Тагы берсе:

– Чабаталы дәһри.., бозау, мөкаллид, чабаталы социалист, – дип кычкырды.

Урманов:

– Иптәшләр, бер-ике генә сүз, – дип авыз ачса да, берничә яктан:

– Кирәкми... Сөйләмәсен!.. Долой!.. Һичкем тыңламый... Һичкем теләми! – дип акырындылар. Боларга каршы Җиһангир, үзенең секртарьлык вазыйфасын онытыпмы, кинәт сикереп торды да ачы, куәтле тавыш белән:

– Һичкем тыңламый, дисез!.. Менә без тыңлыйбыз!.. Безгә кирәк!.. Сөйләсен, без телибез! – дип кычкырып йибәрде. Аңар Баязид карый, җырчы Сахиб, Сөләйман Сәйфуллин кушылды.

Тагы берничә яктан тавыш бирделәр. Тәртип торгызылды. Урманов яңадан сүз алды.

## LII

– Иптәшләр, соңгы ике-өч ел эчендә мин сезнең арада аз яшәдем. Бу җәмгыятьләрдә сезнең белән бу, бәлки, актык булынышымдыр. Шуңар күрә

---

[1] *“Һәл йәстәүилләзинә йәгъләмүн... икъраэ гыйльмү әүләдәкүм”* – “Укытыгыз... өйрәтегез балаларыгызны”.

[2] *Мөкаллид* – иярүче.

[3] *Дәһрият* – динсезлек.

минем адресыма әйтелгән берничә сүзгә җавап бирергә телим. Моннан сезнең кашта аңлашылып җитмәгән хәлдә аерыласым килми. Иптәшләрнең кайбере минем хакта “Чабаталы социалист” диде. Моның “чабатасы да”, “слциалисты да” миңа бик кадерле, бик газиз нәрсәләр. “Чабаталы дәһри” сүзенә дә игътиразым[1] юк. Тик шуны әйтәм: без көн-төн хөррият димез, мәдәният димез... Мәдәният белән хөррият һәркемне үз теләгәнчә уйларга, ышанырга хаклы күрә. Шулай ук һәркемгә үзенең ышанганын сөйләргә хак бирә. Башкаларның икътикадын мөхтәрәм күрмәк – хөрриятле, мәдәниятле адәмнең беренче вазыйфасыдыр. Берәү дәһри икән, берәү үзе файдалы дип ышанганны яшерми сөйли икән – хөрмен, мәдәнимен дигән адәм, аңар каршы күсәк күтәрүдән, һөҗүм башлаудан ерак булырга тиеш...

Моны сүз уңае килгәнгә генә сөйлим. “Чабаталы дәһри” дисез икән, аңар каршы диячәгем юк. Монда кемнәрдер миңа “бозау” дип, “мөкаллид”[2] дип кычкырды. Бу минем хакымда түгел, үзенең фикере вә икътикады белән бераз алгарак атлаган яшьләрнең һәрбере хакында бу сүз әйтелә килә. Мәдәниятлелек дәгъвасында булган матбугат әһеле дә үзен бу вәхшәттән югары тота алмый...

Хосусый мин үзем күп начар ләкабны[3] күтәрәм. Ләкин “бозау” һәм “мөкаллид” булу дигән нәрсәләр минем гакылыма, фикеремә генә түгел, бөтен табигатемә каршы. Бу – минем намусымны тәхкыйрь итә[4]. Шуңа күрә баягы мәсьәләне ташлыйм, чөнки сөйләргә бирмисез, бер мәртәбә сүз киткәч, тик менә шул ямьсез ике ләкаб мөнәсәбәте белән бер-ике сүз әйтеп узарга мәҗбүрмен. Өмид итәм, бу, ихтимал, кайбер иптәшләрнең фикри юлына тәэсирсез калмас.

Бервакыт, саф кадим булып, дәҗҗал чыгуын, кыямәт җитүен көтеп ятучылар белән игътикаддәш[5] булганымны, соңра ислахчы шәкерт булганымны, ниһаять, Габдеһ, Әфганиләр юлына кереп, бөтен дөнья мөселманын кайгыртучылар җөмләсенә кергәнемне әйтеп уздым. Әле дә хәтерлим: ул вакытларда мин Әл-Хәмра сараеның сурәтенә карап, сәгатьләрчә шуңардан күземне ала алмый, авыр кайгыда кала идем. Ләкин тарих һәм хәзерге хәятның барышы миңа хәзерге заманда “дин” үзенең “җәмгълек”[6] сыйфатын югалтканын, хәзер дин белән милләт аерылганын әйтте. Бу заманның халыклары диннән бигрәк, “миллият” флагы астына җыелырга мәҗбүр булуларын ачык күрсәтте.

---

[1] *Игътиразым* – каршы сүзем.
[2] *Мөкаллид* – кемгәдер иярүче, охшарга тырышучы.
[3] *Ләкабны* – кушаматны.
[4] *Тәхкыйрь итә* – мыскыл итә.
[5] *Икътикаддәш* – бергә ышанучы, фикердәш.
[6] *Җәмгълек* – бу урында “*бергәлек*” мәгънәсендә.

Шуның белән бергә миңа “мөселманнар” йиренә “татарлар”, Багдад, Кортубә, Граната, Әндәлес, Һарун әр-Рәшид урынына Алтай, Алтын Урда һәм Чыңгызлар күренә башлады[101+]. Әл-Хәмра, ничектер, икенче планга күчеп, мин Сөембикә манарасының ташларына яшьлек көнендә генә була торган эссе күз яшьләремне түгә торган булдым.

Ләкин монда туктый алмадым, бу минем фикри тәкәммелемнең[1] баскычларыннан бере иде.

Кемнәрдер әйткәнчә, мода, тәкълид бәласе белән түгел, бәлки, азат гакылының хәят вә тарих фактлары күрсәткән юл буенча туктамый үсүне үзенә мәҗбүр күрүеннән, игътикадым[2] тагы икенче төс алды. Миллият ни–нәрсә, аның тарихта хәзердә уйнаган роле нидән гыйбарәт? Ул нинди афәтләр тудырган вә тудыра? Аның исеме астына яшерелеп, нинди затлар түбән сыйныфны канлы сугышларга илтәләр? Гомумән, миллиятнең бәни адәм[3] хәятында тоткан урыны миңа чын кыяфәте белән ачылды. Миллият астына яшерелгәннәр чиркен йөзләре белән мәйданга чыкты, шуның белән милләтләр бетте. Татар, рус, алман югалды. Калды тик “бәни адәм”! Элек кешеләр икегә: мөселманга, мөселман түгелгә, аннан соң татарга, татар түгелгә бүленә иде. Күземне ачкан куәткә, мең шөкер булсын, инде бу тарлыклардан мин котылдым. Берәүнең татар я рус булуы, мөселман яки христианлыгы – хәзер минем аларга мөнәсәбәтемне үзгәртми, бу сыйфатлар кардәшлек тә, дошманлык та уйгатмый. Син кем, адәмме? Без – кардәш, бир кулыңны: Габдеһ белән Иван кочаклашалар...

Хәзер инде адәмнәр эшләүче белән эшләтүчегә, бай белән ярлыга, ач белән тукка, мәшһүр сүз белән әйтсәк, буржуазия белән пролетариатка, талаучы белән таланучыга бүленәләр. Түбән сыйныф ач – аңа икмәк кирәк, һәммә халык кысылган – аларга ирек кирәк. Һәрбер дин үз заманындагы куәтле ихтыяҗдан туган бөек бер идеянең гамәли татбигыннан гыйбарәттер. Бу заманның хәят агышы ач белән тук, эшләүче белән эшләтүче арасында хөкем сөргән җәберле нисбәтнең тәэсире сәбәпле яңа бер идея – социализм идеясе тудырды. Һәм, тарихта күрдегемез кебек, бүгенге хәят барышы да шул бөек идеянең гамәли тәтбигын эшләячәк[4] пәйгамбәрләр бәни адәмгә тигезлек, туганлык, азатлык нигезенә корылган яңа бер дин – социализм китерделәр. Һәрбер дин, һәрбер бөек идея кебек бер дин вә корбаннар тели. Үзен ихтирам кылган намуслы җаннар әнә шул корбаннардан бере улмакны дөньяда яшәүләрендә бердәнбер идеал итеп тоталар һәм шуңар баралар...

---

[1] *Фикри тәкәммелемнең* – фикерем үсешенең.
[2] *Игътикадым* – ышанычым.
[3] *Бәни адәм* – адәм балалары.
[4] *Гамәли тәтбигын эшләячәк* – практик яктан килештерәчәк.

Картлар картайган, динме, миллиятме, тагы анардан да түбәнрәк һәм таррак булган бер рамка эченәме кысылып катканнар. Ләкин намуслы яшь җаннар бу бөек идеянең якты нуры алдында сәҗдә итүне үзләренә...

Давыдка тагы сүзен бетерергә бирмәделәр. Дүртенче галинең сакаллылары башлады, аларга башкалар кушылды. Зал тагы тавыш, шау-шу белән, сызгыру вә аяк тибү белән, "долой, кирәкми, бетмәс монда чабаталы социалистлар" дигән кычкырынулар белән тулды. Тәртип бетте, мәҗлес бер кыяматкә, мәхшәргә әйләнде. Рәис ничаклы көчләнсә дә баса алмады.

Давыд:

– Бер сүз ташлау кирәк иде! Инде сүгенә бирсеннәр!! – дип кул селекте дә ялгызы үзенең "җәһәннәм базы"на кайтып китте.

---

Ун минутлык тәнәфестән соң, мәҗлесне яңадан ачтылар. Нигъмәт казый:

– Урманов бу игътикадында ялгыз түгел. Күп егетләремез, рус яшьләренә ияреп, дингә, миллияткә каршы баралар. Бу безнең өчен хәерле фал түгел. Миллият, милләтче сүзе хәзер күпләр тарафыннан тәхкыйрь[1] урынында кулланыла. Гомумиләшеп барган бу зур халәткә каршы бик җитди чаралар ляземдер, дип сүз башлады. Мәсьәләнең бу турыда булачагын аңлау белән, Җиһангир һәм Нәҗиб Кәмал урыннарын ташладылар. Яңадан рәис вә секретарь сайланды. Беренче нәүбәтне Нигъмәт казый алып, ул яшьләргә миллият лөзүме, башка халыкларның, бигрәк тә мәхкүм милләт яшьләренең үз миллиятләре өчен ни дәрәҗәдә тырышуы, безгә гыйбрәт булырга тиешле болгар яшьләренең бу юлдагы фидакарянә хәрәкәтләре, башка милләтләрнең эшләре, миллият юлында каһарманлыклары хакында тоташ ике сәгать сөйләде. "Тәрҗеман" бабага[102+] "Ура, яшәсен карт милләтче!" сүзе белән тәмам булган бу нотыгы баягысыннан күп тәэсирле чыгып, бер яктан унбиш кешелек бер гөруһның сызгыруына карамыйча, башкалар бик озак кул чаптылар, тәбрикләрдән аның куллары талды.

Мәҗлес төнге сәгать өчтә генә ябылды. Башка вакыт мондый кичке җәмгыятьләр халыкны бик ялыктыра, шәкертнең яртысыннан күбе түбән төшеп ятып бетә иде. Бүген һичкем ялыгу сизмәде. Төшеп ятуны хәтеренә китерүче дә булмады.

Нигъмәт казый үзе бик артык арыган иде. Квартирына кайта алмады, иптәшләреннән беренең ятагын уртаклашып, мәдрәсәдә кунды.

## LIII

"Яманташ" буйлары качкын Сәрүҗигә электән дә таныш, башка

[1] *Тәхкыйрь* – хурлау, мыскыл итү.

һәркайда булган кебек, мондагы авылларда да халык ярлы, йир аз, урман юк, печәнлек, болын имана башына ярты сажиннан артык тими. Бу хәлдән җөдәгән[1] халык, авыр көннән гаҗиз булгач, үзара йир бүлешү – яңа рәвиз, иске рәвиз[103+] дип талашып, гомер үткәрмәктәләр идеке аңа билгеле иде. Тик ышкулда[2] вакытта бик кызылланып йөргән Бәдри учитель кебек берничә иптәшләрнең байтактан бу тирәдә яшәүләре генә бераз өмидне арттыра, алар тик ятмаганнардыр, бераз зәмин[3] хәзерләгәннәрдер, дип уйлата иде.

Теге төнге сәгать өчтә Урмановтан китеп, поезд белән монда килгәч, ул туры Бәдригә төште. Башта ничектер аптырый калды. Учитель дә баеп килә. Алты почмаклы өе, әйбәт киләте, ике аты, яхшы бакчасы бар. Хатыны кача булырга кирәк, ләкин Бәдри үзе Сәрүҗине ачык, шат, тик бик аз гына эчтә куркыну белән каршы алды. Эшнең кая барачагын сизенгәч, бу эчке куркыну, икенче рәвешкә кереп, тышка чыкты. Сәрүҗи шәһәрдәге хәлләрне, үзенең ниләр кылуын, монда ник килүен сөйләп бетүгә, Бәдри:

– Мин синең алдыңда рия сатасым килми. Үзең күрәсең: хатын бар, бала-чага бар. Миңа бик сак булырга кирәк. Кулдан килгән ярдәмне аямам, ләкин үзем читтә калам, – диде.

Һәм ярдәмен итте: кунакка килгән иске иптәшләреннән бере сыйфаты белән аны өендә асрады. Акрын-акрын авылның егетләре белән очрашырга имкян[4] бирде.

Халык бер яктан, патшадан йир чыга, имеш, боярның йирен, урманын боларга бүлеп бирәләр, имеш, дип ишетә. Бигрәк тә картлар бу хәбәргә каршы: “Булыр, булыр, Аллаһе Тәгалә күңелләренә миһербан салса, бар да булыр, еракта торсак та, безнең авыр көн итүемез бар да аңа билгеле, ул безне кызгана, имеш”, – дип сөйлиләр. Икенче яктан әллә кайда да халыкның күтәрелүе, тирә-як авыллар берләшеп, күрше боярның йирен, суын, урманын талаулары, үзенә һөҗүм итүләре дә аларның колагына керми түгел иде.

Әүвәл танышкан егетләрнең күбе Сәрүҗи хакында үзара: “Йир чыгарырга өйрәтә, имеш”, – дип сөйли башладылар. Арадан Шакир солдат дигән берәүсе Качкынны беренче сүздән үк аңлады, ул бер таяк йирсез, шуның өстенә бераз аңлы да. Шул аңы өчен солдатта бер ел дициплинарный батальонга да эләккән иде.

Сәрүҗи белән танышканнан соң, ул төннәрен Бәдри учитель өеннән китми торган булды. Сәрүҗи язу-сызудан мәхрүм бу таза, куәтле мужик егетенең белергә тырышуына, шул йир-су турында ни генә сөйләсә дә, аңлау

[1] *Дөресе*: йөдәгән – аптыраган.
[2] *Русчадан:* школада – мәктәптә.
[3] *Зәмин* – җир, җирлек.
[4] *Имкян* – мөмкинлек.

гына түгел, йөрәге, мие белән тәмам җотып алуына, сорашудан арымавына чыннан хәйран иде. Ул качкынның беренче юлдашы, беренче агенты булды. Серне кемнәргә ачу, кемнәрне чакыру – һәммәсе аның кулына бирелде. Һәм шуның ярдәме белән монда авыл яшьләреннән бер түгәрәк тә ясалды.

Беренчедә – дүрт, икенчедә – ун, өченчедә – унбиш, шулай түгәрәкнең әгъзалары көннән-көн арта башлады. Бара торгач, авыл эчендә урын табу да кыен, сизүләреннән дә куркыныч бар дип, читтә ясарга булдылыр. Авылның буеннан кечкенә генә елга ага, шуның аръягы зур гына болын. Анда таллык. Билгеле вакытка чамалап, егетләрнең берсе, кулына җөгән тотып, ат эзли. Икенчесе адашып калган бозавын карый. Өченчесе, биленә балтасын кыстырып, чыбыркы саплык тал алырга бара. Шулай төрле юл белән мәгълүм урынга, тал арасына җыелалар.

Монда картлар, ир уртасы адәмнәр дә аз; шулай ук өйләнмәгән яки, хатыны булса да, дөнья көтү үз өстенә төшмәгән – әле атасында яши торган яшьләр дә күп түгел. Буңар иң чын әгъзалар – атасыннан аерылып чыгып, авылның бер читенә мунча кебек кечкенә өй салган эшлекле, баерга тырышучан, ләкин йирсезлектән, ничаклы тырышса да, һаман тамагын да туйдыра алмый гаҗиз булган, шулай да бирешергә теләми торган таза, куәтле, батыр егетләр.

Сәрүҗи боларның күбенең ни дәрәҗәдә дикъкать белән тыңлавына, йир дигән, йир бүлү дигән бер сүзне кайта-кайта, ул ничек, менә болаймы дип аңларга җан атуларына чыннан да исе китә иде. Таллар эчендә ике мәртәбә җыелдылар. Өченчесендә, Шакир солдатның әйтүе белән, күрше авылдан да ике егет бар иде. Инде эшне алар зурайтмакчы. Шул ике егет аркылы ул авылның үзендә түгәрәкләр төзи башламакчылар иде. Берничә авылда шулай аерым-аерым эшләгән соң бер җыелыш ясаячаклар да аннан соң Алланың ярдәме белән “хәерле юлга” диячәкләр, аннан соң ни эшләүне үзләре беләчәкләр...

Ләкин эшләр уйлаганча бармады. Шул өченче җыенда качкын чит мәмләкәттәге игенчеләрнең хәле, Русиядә күпме йирнең кемнәр тарафыннан биләнүе, кайбер кулларда ничә йөз мең дисәтинәшәр йир барлыгы, гарби[1] губерналарда крәстияннәрнең кузгалуы хакында кызып сөйли, егетләр үлеп тыңлыйлар, тик сирәк-сирәк кенә:

– Абзыкаем, безгә бер генә сүз булсын!.. Күсәк тотып чыгарга әзербез... – дип, хатибның сүзен бүләләр дә тагы аның сүзләренә җотылалар иде.

Шул вакыт авыл ягыннан берәү йөгереп килде. Үзе мышкылдап беткән, сулышын чак алган хәлдә:

---

[1] *Гарби* – көнбатыш.

– Учительгә урәдник килде, безгә төшкәннәр, дип әйтә Бәдри абзый... Тиз, бик тиз таралсыннар, дип әйтә – диде. Егетләр тугайга, тал арасына таралды, Сәрүҗи авылга кайтмады, туры Йомранга китте. Аңа: "Абзыкай, безне ташлама", – дип калдылар.

Азактан беленде, урәдник килгән дә: "Син өеңдә студентлар асрыйсың икән, кая, чыгар аларны", – дип, Бәдригә бәйләнгән. Учитель: "Юк, ул студент түгел, ул – учитель, минем кунагым иде, китте инде", – дигән.

Йомранның яшь мулласы Заһидны Бәдри учительгә бик дәртле нәрсә, тик кайдан башларга гына белми дип сөйләгәннәр иде. Үткенче шәкерт кыяфәте белән Сәрүҗи туры аңа барды, ләкин мәгънә тапмады. Мулланың сүзе икеле генә түгел, шөбһәле дә күренде. Мулланың "Бәдри учительгә урәдник китте, анда кызыллар ята, имеш" кебек сүзләре, шуны әйткән вакыт аның йөзенә, күзенә чыккан куркыну эсәре Качкынның өмиден бөтенләй өзделәр. Ул тышка барачак булып йортка чыкты да, комганын азбарда калдырып, арт яктан тыкрыкка төшеп, акрын гына сызды.

Эзгә төшүләре ачык иде. Бераз суынганчы югалырга кирәк дип, ул яңадан калага кайтты.

## LIV

Качкынның Яманташ буендагы эшләр хакында ясаган доклады бетеп, Урманов өенә кайткан вакыт сәгать җиде булып килә иде.

Карчык: "Эчсәң, чәй бар", – диде. Давыд чәй ясап, бүген сигездән соң булачак җәмгыятьтә сөйләргә дип, өстенә алган мәүзугысы[1] хакындагы материалларны тәртипкә куярга тотынды.

Госманның башлавы белән шәһәрнең иң читке мәхәлләләреннән... хәзрәтнең арткы мәдрәсәсендә бүген җыен була. Госман үзе халык һәм хөкүмәт хакында сөйләячәк. Качкын, җиңгел кулдан гына булса да башкарырмын дип, "Партияләр һәм йир мәсьәләсе"н алды. Җиһангир "Йирсезлек, динсезлек" исеме белән авыл халкының йир азлыгыннан нинди азап күрүе, бер сәбәптән ярлылыкка төшеп, үзенең иң ихлас ниятләрен, дәртләрен, тойгыларын барлыкка китерүдән гаҗиз булуы хакында сөйләмәкче булды. Урмановка диннең хөкүмәт кулында ничек корал булып йөрүе хакында сөйләүне тәклиф иттеләр[2].

Чәен эчеп планын сызгалауга, франт киемле, күзлеген бик күәз[3] генә таккан бер егет килеп керде.

---

[1]*Мәүзугысы* – темасы.
[2] *Тәклиф иттеләр* – тапшырдылар.
[3] *Дөресе*: көяз.

Бу – теге Кадыйр байдан чыккан приказчикларның башлыкларыннан Фәхри иде. Аның күптәнге танышы булдыгы хәлдә, үзен һаман тәкәллефле[1] тотуы, бик артык ялтыраган ал галстугы Урмановка охшамыйлар[2], анарда ачык, бизенү тойгысы уйгаталар иде. Әле дә приказчикның: “Мөмкинме, эшегезне бүлмимме, тартырга ярыймы”, – кебек сүзләрне әллә нинди фәзыйләт[3] белән шәплек эшләгәндәй кылынып әйтүе, аның тартмавын күптән белсә дә, бик нечкәләп: “Рәхим итегез”, – дип, иң элек, көмеш портсигарын ачып, хуҗага тәкъдим итүләре, ничектер, мәгънәви бер җирәнеч[4] тәэсирен бирделәр. Давыд үзен көчләде, тик садә иптәшчә мөгамәлә күрсәтте.

Ну, иптәш, түгәрәк ни хәлдә бара?! “Ярдәм”нең эше пешәчәкме? Ах, сез бит миңа үзегездәге кузгалышның тәфсыйлен сөйләмәкче идеңез!..

Фәхринең килүе бигрәк шуның өчен. Ул ничек кенә булса да, үз кашында артык мөһим булган шул вакыйганың газетага кереп калуын, Кадыйр байның әче тел белән сүгелүен тели иде. Давыдның сөаленә каршы, тәмәкесен сүндереп мичкә ташлады да, аягүрә басып, урындыкның артына тотынды:

– Атна кич, – ди, – бай, зур корсагын киереп, магазинга килеп керде дә кул куяр өчен өстәленә салынган кәгазьләрне актара башлады. Үзе ачулымы, ниме, һичкемгә һичбер сүз әйтми, кибәк ашап күбенгән сыер кебек, “пуф-пуффф” итеп тора. Безнең доверенный бик ялагай нәрсә, намазга торган кебек олуглап, байның каршысына барды да, бөгелә-сыгыла, нидер сөйләргә тотынды. Әмма Кадыйр аңа күтәрелеп тә карамады: “Бар, әле, бар, соңыннан карарбыз”, – дип кулын гына селекте.

Инде көн дә кич иде. “Ул болай да магазинда озак тормый, җә чыгып китә башлар” дидем дә, мин аның алдына барып: “Бай абзый, сезгә бер-ике сүз бар иде”, – дидем. Ул миңа карамады: “Бар, кит әле, кәефем юк, иртәгә”, – дип, кул гына селекте.

– Юк, мин әйтәм, минем йомышым иртәгә калдыра торган түгел.

Ул, ахрысы, минем тавышка гаҗәпләндеме, ачу белән башын күтәрде. Мин яңа тройкадан, ак яка, кара галстук, баш ялангач, чәч кирегә таралган иде. Бай һичбер вакыт мине мондый кыяфәттә күргәне юк иде. Күтәрелеп карагач аптырап китте, шунда ук йөзенә ачу каны чыкты да:

– Бу ни эш? Бу нинди сыйфат? Бар, күземнән югал! – дип, минем өстемә җикеренде.

Мин урынымнан кузгалмадым, мин әйтәм, минем зур йомышым бар.

[1] *Тәкәллефле* – ясалма, кыланчык.
[2] *Дөресе*: ошамыйлар.
[3] *Фәзыйләт* – яхшы эш.
[4] *Дөресе*: җирәнгеч.

Мин, дим, сезгә ялланган вакытта озын бишмәт, җәенке кәләпүш белән саурылы читектән башканы кимәскә сүз бирмәдем, дим... Ул тагы кызды, күзләре акайды, хәзер бер сүз белән юк итәргә ышангандай:

– Ишетәмсең, күз алдымнан югал дигәнне!! Бу нинди ахмаклык тагы!! – дип кычкырды. Миннән ерак түгел, постау әрҗәсен бушатып, Гыйльметдин тора иде. Байның кызганын күргәч:

– Сез анның берүзен гаепләмәңез... Ул үзеннән түгел... Без аны сезнең белән сөйләшергә сайладык... Болай булса, безнең яшәр хәлемез калмады. Кичә тугыздан ишекне бикләделәр, өченче көн театрдан кайткан ике иптәшне ятарга кертмәделәр, Кәримгә, ниндидер ысчут[1] тактасы язган өчен, ике тәңкә ыштраф салганнар. Болай булса, без ничек торыйк? Без адәм түгелме, безнең дә дөньяга карыйсымыз килә! – диде.

Бай тагын җенләнде:

– Тагы ни лыгырдыйсыз! Дөнья иркен, ачтан үләсеңез килсә, бар, йөреңез! Китеңез... Кергәндә ялынып керәләр, аз гына тамак туйса лыгырдый башлыйлар, – ди.

Башка иптәшләр дә килде, мин байның ачуына карамадым. Без, дим, болай булса, яши алмыйбыз, дим. Без, дим, ике магазиндагы егерме биш приказчик җыелып киңәштек. Безгә, дим, хезмәт хакы арттырылсын, төнге сәгать уникегә кадәрле чыгып йөрергә рөхсәт булсын, бәйрәм көннәрендә, дим, арткы ишектән кереп эшләтү бетерелсен, безгә, дим, атнага бөтен бер көн ял итәргә бирелсен, эш сәгате, дим, сигез сәгатьтән артмасын, безнең белән, дим, кеше кебек мөгамәлә кылынсын; без, дим, барыбер адәмнәр, безнең өсткә гөнаһсызга аяк тибеп акырмасыннар, безне, дим, хатын-кыз йомышына йөртмәсеннәр; без, дим, боларны требовать итәмез, дим...

Бай мәсхәрә итеп көлде:

– Ни дисең? Тагы бер ишетим, ни дисең? – ди.

Мин әйтәм, требовать итәмез...

Бай тагы мәсхәрә белән көлде. “Син бичараны кем адәм итте, беләсеңме, – ди. – Сине, ди, анаң аягына ятып елагач алдым. Маңка малай идең... Инде минем кулда адәм булгач, оялмый требовать итәмез, ди. Бар, китеңез, кәефем юк, ахмак булмаңыз, бастовайт[2] итәргә сез урыс түгел,”– ди.

Иң артта байның бик яратканнарыннан карт приказчик Тимербай тора иде. Бай кыза башлагач, ул да түзмәде. Сезгә, ди, кәефем юк, ахмак булмаңыз, сез урыс түгел дияргә җиңгел. Әмма безнең көн итүемез җиңгел түгел шул. Менә мин, ди, унсигез ел хезмәт итәм. Шул кадәрле еллар сезнең йортыңыз белән магазиныңыздан башка дөнья күргәнем юк... Сез калыная

[1] *Дөресе*: счет.
[2] *Дөресе*: восставать.

барасыз... Сезнең йортлар, магазиннар арта бара... Ә без көннән-көн, ди кибә барамыз... Менә мин, ди, җиде тәңкәлек квартирдан чыга алмыйм. Бердәнбер кызым бар. Хәл җитмәгәннән, аны хәзерләп җиткергәч, гимназиягә бирә алмадым. Кызым, мәхрүм калгач, күз яше белән җылый да... ни эшлим соң?

Фәхринең хикәясе шул йиргә җиткәч, кемдер ишек шакылдатты. Элмәгән булса кирәк, карчык ачарга дип барганчы, аннан, үзенең яңа киемнәре белән ялтырап, Йосыфҗан килеп керде. Аның бөтен торышы бик дустанә, тавышы көлеп чыга иде:

– Ә, Давыд, сиздем эшеңне!.. Син икән боларны аздыручы! Исәнмесез, нихәл, Фәхри?

Фәхри бераз чүкте, басылды, хикәясенең тәфсыйлен дәвам иттермәде, ике сүз белән:

– Шуннан соң икенче көнне яңадан киңәш булды, башкаларның күбе җәмәгатьле, бала-чагалылар иде. Үзем генә булсам, берни түгел, балалар бар, ачмы, тукмы инде бездән булмый туганнар, дип, анда калдылар. Без, унике егет, соралганнарыбыз бирелгәнче эшкә бармыйбыз дип игълан кылдык, – дип тәмам итте дә исәнләшеп чыгып китте.

Анардан соң Давыд чәен эчеп бетерде дә:

– Синең ат бардыр бит. Мин иртәдән бирле һавада җүнләп булганым юк. Әйдә, атың белән бер-ике әйләник, шунда теге хакта да сөйләшермез, – диде.

Йосыфҗан риза булды.

Болар чыкканда ак аргамак, башын салындырып, алгы аяклары белән баскан йирен тырнап тора иде. Утырып, Николайский һәм Екатеринский буенча берәр әйләнгәч, дүртенче часть сәгатенең сигезне сукканы ишетелде.

– А, сәгать сигез... син, иптәш, мине Җамали хәзрәт мәдрәсәсенә таба илт инде.

Йосыфҗан борылды, шәһәрнең читенә якын егерме сажиннарда мәсҗед, аның янында мәдрәсәнең тәбәнәк агач биналары күренә иде. Атны туктаттылар:

– Җитте, инде артык барырга ярамый. Сиңа, иптәш, хәерле юл! Йосыфҗан Давыдның кулыннан алып, күзләренә карады:

– Алайса, мин бу эшне булганга саныйм. Син иртәнге сәгать унда дисеңме әле?.. Мин Госман белән аз таныш. Ну, син сөйләгәч, белгәндер инде... Алайса, мин ышанам...

– Әлбәттә, ышан... Андый турыда ике сүз булырга мөмкин түгел...

Йосыфҗан шат һәм бәхетле иде. Чыннан да, мөтәэссир[1] тавыш белән:

---

[1] *Мөтәэссир* – тәэсирләнгән.

– Иптәшлегеңне мәңге онытмам. Инде һәммә нәрсә хәзер... Насыйп булса, берсекөнгә мин юлда булам!.. – дип, Давыдны кочаклап үпте дә, утырып, ак аргамак белән шәһәрнең караңгы урамнарыннан беренә кереп гаиб булды.[1]

## LV

Мәдрәсәнең эче ярым караңгы иде. Анда керү белән, Давыд ни барын тиз генә аера алмады. Тик берничә секундтан соң гына тавышы почмактан ишетелгән хатибның качкын Сәрүҗи икәнлеге, башта тезеп утыртылган агач бүкәннәре кебек күренгән нәрсәләрнең монда җәмгыятькә җыелган халык идеке ачык танылды.

Җәмәгать бик чобар иде. Иң элек Габдрахман белән Фәхри күзгә чалынды. Алар артында утызга якын башка приказчиклар утыралар иде. Хатибның янында ук, авызы белән тыңлагандай алга сузылып, теге татар эшчесе Абдул утыра. Урманов Йосыфҗан аркылы аңа тире заводында урын табып биргәннән бирле, бу эшче бөтенләй төзәлгән, эчүен куеп, бик ихластан яшьләр белән эшләшә башлаган иде. Әле дә үзе белән егермеләп эшчене монда алып килгән. Алар да хатибның янына ук тезелешкәннәр, арада берничә тегүче, эшче бар. Калганнары һәммәсе – шәкерт, моның да күбрәге мәдрәсәи исламиянеке иде.

Мәдрәсә бу халык белән шыгрым тулы булганга, Урмановка эчкә барырга мөмкин булмады, ул, ишекне ачып, бер-ике генә атлады да мичнең кабыргасына сөялде.

Хатиб дәвам итте.

Тәртип буенча, Качкыннан соң Җиһангир белән Госман сөйләделәр. Арада Абдул белән Фәхринең берничә сүзе, үз хәятларыннан алынган фактлар булды. Соңра нәүбәт Давыд Урмановныкы иде.

Ләкин ул озак бара алмады, хотбәсен башлап берничә сүз әйткән генә иде, кинәт ишек ачылды да аннан, атылып, Рауза туташ килеп керде. Аның күзләре зураеп чыгарга җитешкән, йөзе куркыну һәм ашыгу белән карый, тавышы бик ашыгыч һәм каушап чыга иде. Атылып, бусаганы атлар-атламас:

– Иптәшләр, тиз... тиз таралыңыз!.. Полиция баса. Тиз! – дип кычкырып йибәрде.

Бөтен халык хәйран күз белән аңа карап катты, гүя һичнәрсә аңламыйлар, һични эшләргә кирәген белмиләр иде. Шул ук тавыш белән Рауза туташ тәкрар итте:

– Аңлыйсызмы... полиция баса, дим...

Ул арада Качкын якындагы тәрәзәне бәреп төшерде дә:

---

[1] *Гаиб булды* – юк булды.

– Иптәшләр, тиз таралырга... Таралырга!! – дип акырды, үзе шул секунд тәрәзәдән сикереп чыгып юк булды.

Мәдрәсә эче батып барган кораб рәвешен алды. Кычкырыш, тавыш, тегендә-монда этәреш, тапташ, кысылыш, белмәм, тагы niләр булып, дөньяның астын өсткә китергәндәй кабалану белән берәр минур вакыт үткән соң, өч-дүрт йөз кешеле җәмәгать ишектән, тәрәзәдән качып чыгып бетәргә өлгерә алды. Полиция килгәндә, мәдрәсәнең тупсасы каерылып, артка егылган ишеге белән, дүртесе тыш якка бәреп төшерелгән тәрәзәләреннән, идәндәге бер бүрек, ике таяк, берничә русча гәзитәдән башка нәрсә юк иде. Җәмәгать чыннан да тизләде, ләкин полиция дә җитезлек күрсәтте: ул монда кеше калмавын күрү белән, үзенең агентларын, әгъзаларын ашыгыч сурәттә чатларга, почмакларга җәмгыятьтән таралучыларны тотарга таратты. Госман шул мәхәлләнең мөәззине белән якын мөнәсәбәттә иде. Тиз генә шунда яшеренде. Давыд та җиңел котылды, ничектер туры килде: мәдрәсә чатыннан борылуга, ул Рауза белән очрашты. Туташ арыган, каушаган, шулай да һаман ашыга иде, Давыдны күрүгә:

– Сезме? ... Сезме? ... Тотылучы юкмы икән?.. – дип аның кулына асылынды.

Алар бергә кайттылар. Рауза, шәһәр эченә кереп эләгү куркынычы беткәч, полиция басачагын кайдан белгәнлеген сөйләде:

– Бүген, ди, анакайның кәефе начар... Питердан ике иптәш курсистка килгән... Шулар мине туктатты, теләсәм дә, анда барып булмады. Сәгать уннан соң, бераз һава алыйк дип йөрергә чыксак, артымнан, җенләнгән кеше кебек, теге карт городовой Кәмали килеп тотты. Мин аңа ачулана яздым... Шундый каты килеп кагылды... Үзе ахылдап беткән... “Туташ, ... туташ, ...син беләсеңдер... теге безнең мөселман яшьләрен... Алар кайдадыр җыелган икән... шунда... аларны басарга полиция китте... Ябарлар инде, барын ябарлар”, – ди. Мин, ни сөйлисең дип, аның кулларына ябыштым... Ул тагы ашыга-ашыга: “Полиция басар, ябарлар, кем булса да, барыбер үз мөселманыбыз бит”, – дип сөйли башлады. Мин ни эшләгәнемне белмәдем, ридикюлемне ачтым да, күпме барын карамыйча, портманиты белән бар акчамны аңар ташладым. Ни күрим, картым акчаны алмый, юк, кирәкми, башка чакта бирерсең, гомеремдә бер изге эш булсын, ди. Көчләсәм дә алмады. Менә бит татарның алтын йөрәге кайда! Ә без аны адәмгә санамыйбыз... Карт үз юлына китте. Мин шул минутта ук извозчик алдым да тегендә чаптым.

Бу вакыт алар Раузалар тора торган тәбәнәк сары өйгә килеп җиткәннәр иде инде. Туташ, кайта-кайта, кем дә булса эләкмәдеме икән, дип борчылды, хафалы бер хәлдә Давыд белән исәнләшеп, тоткага кулын салды, ләкин ул

ачарга өлгерә алмады, Екатеринский ягыннан, йөгерә-атлый, Фәхри килеп чыкты!

– Ишеттеңезме... Качкынны эләктерделәр... Мин аның артыннан килә идем... Ул ике чатта хәйләләп качты, өченчедә тотып алдылар.

Рауза кинәт агарынды, ләкин һичбер сүз әйтмәде, тик үз эченнән: “Шулай булыр ук, эләктерерләр үк дигән идем”, – дип уйлады.

Болай җыелып озак тору куркынычсыз түгел иде. Егетләр кул бирделәр. Туташ, иртәгә иртә үк, шул мәдрәсә караган бишенче частька барып белешергә Давыдтан вәгъдә алып, кечкенә капкасы белән эчкә кереп китте.

## LVI

Полицийскилар Качкынны бишенче частька китергән вакыт – сәгать беренче иде инде. Төнге нәүбәткә калган ачулы йөзле карт околоточный, аңа текәлеп карап: “Ә, эләктеңме, йөри торгач!” – дигән кыяфәт белән каршы алды. Җентекләп сораштылар. Җавабын яздылар. Шулар белән бер сәгатькә якын вакыт үткәндер. Соңра, дикъкать белән тентеп, кесәләрендәге һәммә нәрсәләрен алгач, околоточный:

– Дүртенче номерга илтергә!! – диде.

Ике полицийски аны тузанлы, ярым караңгы таш баскыч белән түбәнгә алып төшеп, буш, аз яктылы коридорның сәясиләргә махсус камераларыннан дүртенче номер дигәненә кертеп яптылар. Бу – гади часть камерасы иде: пыялалары тузанланып беткән, вак рамкалы, тимер рәшәткәле ике кечкенә тәрәзә... Ишек төбендә сасы ләгән... Чүпле, тузанлы асфальт идән... Мичкә сөялгән озын саплы себерке... Бүлмәнең ике дивары буйлап сузылган озын киң сәкеләр – менә шуның белән андагы җиһаз тәмам булды. Качкын кергән вакыт сәкеләр өстенә бүлмәнең аз яктысы белән каралып ташланган гаскәр кебек күренгән тезелешеп, бер-беренә кысыла-кысыла яткан адәмнәрдән кайберләренең гырылдавы ишетелә – тик шул гына җан әсәре күрсәтә иде. Ишекнең шалтырап ябылуына уяндылар булса кирәк, Качкын күз йөртеп алырга өлгермәде, сәкенең түр як почмагыннан берәү баш күтәрде:

– Сез кем? ... Ә?.. Коллега... Тәмәкегез бармы? Зинһар, берне бирә күреңез... Дүрт сәгать тартканым юк, үләм инде!..

Аның тавышына башкалар да уянып, берәм-берәм баш күтәрә башладылар. Сүз берләшкән кебек, болар һәр каюсы урынынан кузгалып җитми: “Коллега, тәмәкегез бармы? ... Һич булмаса, бер генә суырырга бирә күреңез!” – дип, ихлас күңелдән теләнергә тотыналар. Качкын: “Ай, булсачы, югарыда алып калды, каһәрләр... ” – диюдән башканы белмәгәч, тагы үзара

эзләнергә керешәләр иде. Тиз арада бар да уянып, яңа коллега янына җыелышып җиттеләр. Болар бар да студентлар, эшчеләр булып чыкты. Гадәтчә, тиз үк аңлаштылар.

Бүген күбрәге ... землячествосының әгъзалары булып, сәяси түгәрәкнең яшерен мәҗлесен килеп басканнар да боларның егерме алтысын берьюлы монда китереп тутырганнар. Ике курсистка да эләккән, алар хатыннарга махсус янәшә камерадалар, ди.

Студентларның егерме дүртесе шундалар. Артта берсе Качкынның якташы булып чыкты. Ул күптән түгел атасы Гомәр картны күргән. Бик кайгыра, һичбер йирдән Хәбиб хакында ачык хәбәр булмагач, әллә астылармы юкса дип, көн-төн хәсрәттәбез, анасы шунардан авыруга сабышты, хәзер түшәгеннән тора алмый, ди.

Бу якташ бик артык тәмәкече нәрсә икән. Ичмаса, тәмәке вагы юкмы, кәгазен әллә табар идек дип, Хәбибнең барлык кесә төпләрен какты. Ләкин һичкайдан һичбер нәрсә чыкмады.

Әллә кемнәрне аталары, аналары белән сүктеләр, ләгънәтләделәр дә, һәммәсе яңадан шул нечкә киемнәренә төренеп, каты сәкегә сузылдылар. Ул арада ишек ачылды да тагы бер бәндә килеп керде. Ябык, кечкенә юаш бер адәм. Ул һичкемгә һичбер сүз әйтмәде, белергә тырышкан кеше кебек артык илтифат та күрсәтмәде, ләкин керүе белән һәммәнең күңеленә шик төште. Аяк атлавымы, күз карашымы, почмакта тезләрен кочаклап ялгыз утыруымы – белмим ни-нәрсәсе белән ул егетләрдә үзенә каршы шөбһә уйгатты. Студентлар бер мәртәбә күтәрелеп карагач ук: “Эшпиктыр[1], эшпиктыр”, – дип үзара пыш-пыш сөйләшә башладылар.

Качкынның якташы Гриша түзмәде, яткан йиреннән торды да теге бәндәдән нидер сорарга, аны сөйләтергә, ниһаять:

– Син кем?.. Чиновникмы? Чиновник особых поручениймы? – дип, аны мыскылларга тотынды.

Ләкин “бәндә” урынынан кузгалмады, сөальләргә җавап бирмәде. Һаман, тезен кочаклап, почмакта ялгыз утыруында дәвам итте. Арадан кемдер Гришага:

– Кайдан белергә? Нигә юк белән маташасың! – диде.

Ул да, ахры, йомышы төште:

– Сез нигә бер сүз дә әйтмисез... Мин сезне эшпик дип уйладым. Безнең серне аңларга юри кертелгән шпион дип белдем. Шуңар күрә шаярдым. Әгәр дә сез намуслы гражданин булсаңыз, мин гафу үтенәм.

“Бәндә” һаман бер сүз дә дәшмәде. Студентлар тындылар, качкын да,

---

[1] *Дөресе*: шпиктыр – шпиондыр.

ике студент арасында калган буш урынга юка пальтосын түшәп, ау салды[1]. Аңа да каты иде, ләкин соңгы ике тәүлектә, җүнләп баш куярга тугры килмәгәнгә, ул моны сизәрлектән үткән иде: иплэп ятып та җитмәде, үлек кебек йокыга китте.

Ләкин бу халык аңа тынычланып озак йокларга бирмәделәр. Таң сызылу белән, бөтен төн буена тузанлы, борчалы, кандалалы каты такта өстендә аунап газапланып чыккан студентлар, төрле яктан баш күтәреп, сүгенергә, җырларга, ишек дөбердәтергә тотындылар.

Качкын да торды.

Һәммәнең чәчләре тузылган, ләкин тарарга хәтерләренә килми, мыеклары сынган, ләкин аны төзәтеп маташырга дәрт төшми иде. Күзләре канлы, йөзләре йокысызлыктан, тәмәкесезлектән, уңайсыз ятудан тәмам бозылган иде. Тору белән тагын кесәләрен актардылар. Ләкин һичнәрсә чыкмады.

Булмагач, читлеген тешләп каерган ач җанварлар кебек, ишек кагарга тотындылар. Тегеннән кып-кызыл йөзле полицийски килде:

– Егетләр, акрын, бу ни эш? Кирәк булса, вакыты җиткәч, йомышчы (вестовой) килер... Алдыртырсыз... Студентлар: “Безгә хәзер кирәк”, – дип, тагы дөберди башладылар.

Ләкин мәгънә чыкмады, инде үзләре дә бу котырыну белән бераз онытканнар иде, кемдер сәяси җырлардан берен сузды, аңа башкалар кушылдылар, ләкин шунда ук тагы теге кызыл полицийски килде:

– Бу ни эш? Акылыңыз бармы? Үзеңезне үзеңез тоттырасыз!..

Ләкин, моңа карап, бөтенләй тынмадылар. Сәяси җырлар ярамагач, студентлардан берсе “Налей, товарищ!”ны[104+] башлады, арада бик шәп тавышлылар бар иде, хорга һәммәсе ярады. Тотындылар ачудан, ачлыктан, тәмәкесезлектән бөтен бугазларына акырырга...

Бу җырга инде полицийски да бәйләнмәде, тик: “Акрынрак-акрынрак, югарыда әфәнделәр йоклый”, – дип, кайта-кайта тәнбиһ[2] ясый гына торды.

Сәгать унгача шулай үтте. Унберенчедә тышка чыгардылар. Аннан кергәч, шаяра-шаяра су сибеп, асфальт идәнне озын саплы себерке белән себерергә тотындылар. Ләгәнне, гади җинаятьчеләр камерасыннан килеп, кемдер тышка чыгарды. Тәрәзәдән кояш карады, һава бераз җиңеләйде. Тагы бер нәрсә булса, дөнья төгәлләнәчәк иде. Аны да озак көтәргә тугры килмәде, сәгать унберне суккан вакыт ике йомышчы, кочакларын тутырып, кәгазь каплар, төргәкләр алып керделәр.

Бу – студентларга иректә калган иптәшләре тарафыннан китерелгән

---

[1] *Ау салды – үзенә йокларга урын әзерләде* мәгънәсендә..
[2] *Тәнбиһ* –кисәтү.

ашамлыклар иде. Иң әүвәл һәммәсе: “Тәмәке бармы? Тәмәке бармы?” – дип атылыштылар. Бар, тәмәке дә бар, күмәч, булка да бар, сыр, май, йомырка, ветчина да, белмәм, тагы ниләр дә бар иде. Ул арада зур чәйнек белән бераз гына суына төшкән булса да, кайнаган су керттеләр. Берничә тимер касә дә табылды.

Җүнләп тамак туйдыру сирәк бәхет булган Качкынга болар ярый калды. Ул студентларны:

– Өч ел элек пикникка чыккан вакытта гына мондый сыйланган идем, – дип, көлдерә-көлдерә бөгәргә тотынды.

Эш шул дәрәҗәгә җитте, уңган Гриша, теге кызыл йөзле полицийски белән дустлашып алып, анардан байтак ук эчемлек тә китерттеләр. Пикник дияргә елга белән урман җитми, ләкин һәрхәлдә бу бүлмә участокның тимер рәшәткәле сакчылар камерасы булудан чыгып, ярлы студентларның җыелып яши торган ирекле квартирына (общежитие)га әйләнгән иде инде.

Тәмәке булды, тамаклар да туйды, кәефләр дә килде, инде участкадалыкны[1] бөтенләй онытып, “Налей, товарищ”ны сузарга, аның артыннан башкаларны да кушарга тотындылар – уен, ниһаять, тансаларга барып җитте. Ләкин бу хәл озакка бармады. Аларны бишенче частька карый торган квартирда тотканнар, шунлыктан һәммәсен монда китергәннәр. Сәгать берләрдә, берәм-берәм югары чакырып, кайда торуларын язып алгач, һәркемне үз частена озата башладылар. Монда тик квартирлары бишенче частька караган икәве генә калды.

Хәят кинәт сүнде, бүлмә яңадан тимер рәшәткәле зур йозак белән бикләнә торган калын ишекле тузанлы, сасы ләгәнле камерага әйләнде.

Качкын кичә килгәч үк, Гришадан күрше камерадагы ике курсистканың берсе татар икәнлеген ишеткән иде. Студентларның шаулавы, алар тулы вакытта полициянең ишектән китмәве аңа туташлар белән сөйләшергә җай бирми иде. Студентлар таралгач, палицийскиның вакытын чамалап торды да, ишекнең ачылмалы тишегендәге капкачны тышкы якка этәреп, авызы белән шунда тыгылган хәлдә, күрше камерага тавыш бирде. Ахры, андагылар да ишек яныннан китә алмый торганнардыр, тиз үк аннан, шыңгырдап, ачык матур музыка авазы белән җавап килде.

Бу тавыш Сәрүҗигә таныш иде. Ул аптырый калды:

– Гәүһәр туташ... мин ни ишетәм?.. Сезме?

Матур музыка яңадан шыңгырады:

– Сез кем?.. Хәбибме әллә?..

– Ул үзе!!

[1] *Участкадалыкны* – участокта булуны.

Бервакыт полиция үтте. Алар бераз эчкә тартынырга мәҗбүр булдылар. Полициянең аяк тавышы ерагайгач, Хәбиб ачты.

– Сез ничек монда?

Качкын берничә сүз белән монда ничек эләккәнен аңлатты да шаярганын ачык белдереп:

– Сезне монда керүеңез белән тәбрик итәм... Яхшы йокладыңызмы? Кабыргаларыңыз исәнме? – диде.

Гәүһәр, йөрәге өзелеп, чын мөтәэссир[1] тавыш белән җавап кайтарды:

– Ай... Әйтә күрмәгез!.. Кайда йокы!!. Монда тузан да пычрак. Мин башымны да куймадым... Качкын ярым көлке рәвешеннән чыкмады:

– Алайса, тагы тәбрик итәм... Сезнең монда керүгә мин бик шат... Ярлыларның хәлен якыннан күрәсез!!

– Ай, әйтә күрмәңез... Миңа ни булса, ул!! Анакай ишетсә, үләр инде!

Полицийски тагы килеп, ачу белән тишекләрне шартлатып каплады. Гәүһәр белән яңадан сөйләшергә тугры килмәде. Ике сәгатьтән соң Качкынны охранный отделениегә алып киттеләр. Андагы сораулар өч сәгатькә якын барды. Соңра шул ук полицийскиләр аны шәһәр зинданына китерделәр. Күптән түгел Баязид карый торып чыккан өченче коридорның алтынчы камерасында бер яһүд адвокаты утыра иде. Башка урын булмагач, аны гомумига чыгардылар да Качкынны ялгызын шуның камерасына яптылар.

## LVII

Җиһангир ике ай көтте. Ләкин Һаҗәр, гүя бу дөньяда юк иде. Шул озын мөддәттә анардан нә бер хат, нә бер хәбәр!! Инде кыш. Инде бөтен дөнья тирән кар эченә күмелде. Бакчада хәят бетте, анда олуг агачлар яшел хөлләләре, көзге сары киемнәре урынына ак кәфенгә төренеп каттылар. Шулар белән бергә Кадыйр байның бу якка караган кечкенә тәрәзәсе ике катлауланды. Аның тышкы катлавы туңа, бу – егетне күп вакыт ишарәләр белән аңлашырга хезмәт иткән актык чарадан мәхрүм итте.

Монасыйповны Кадыйр бай урыныннан куды. Бөтен бәхетсезлегенең сәбәбе Һаҗәр белән Җиһангир мөнәсәбәтендә ара булу икәнен ачык белгәнгә, ул көне белән боларга явыз дошман киселде. Инде алар аркылы бер-бер хәбәрнең алуның да имкяне калмады. Шәһәрдә исә башыңны ал да кач: кая барсаң, анда Һаҗәрләр гайбәте.

Вафа хәзрәт мәдрәсәсендә җäен, кышын һичкая чыкмый ята торган бер гарип аксак шәкерт ул хакта, бөтен табакны тутырып, бәет чыгарырга да

[1] *Мөтәэссир* – кайгылы.

өлгергән.

Халык эчендә еш-еш:

“Кадыйр байның аргамагы улак башы кимерә,

Кадыйр байның яшь Һаҗәре Җиһангир дип тилмерә...” – охшашлы нәрсәләр ишетеләләр. Шул аксак иҗатыннан булган бу бәетләр бигрәк тә түбән сыйныф арасына, гавамга, нык тарала. Кайберәүләр, бу бәетне дошманлык йөзеннән теге Монасыйпов яллап чыгарттырган, имеш, дип тә сөйлиләр.

Аны кемдер җилем басма белән күп итеп басып та тараткан. Озын колактан моны басучы теге Җиһангирның дошманы шпион Миһран икәнлеге дә аңлашыла иде. Миһранны Җиһангир тарафыннан издерергә теләүче кайбер шәкертләр аны шулай дип исбат итәргә дә маташтылар. Ләкин егет боларның беренә дә илтифат итмәде. Аны халык гайбәте куркытмый, хәтта Кадыйр бай кебек берәүнең Һаҗәрдәй яшь матур хатыны белән исеме баглану аның горурын бераз күтәрә дә иде.

Халык сөйли, бер аксак бәет чыгара, бер шпион аны басып тарата икән – боларның әһәмияте зур түгел. Һаҗәрдән бөтен ике ай буена һичбер җавап, һичбер хәбәр юк – менә мәсьәләнең авыры кайда!! Һаҗәрнең үз кушуы буенча, Җиһангир аны иске дачаларының артында өч төн көтте – килмәде. Башка вакыттагы кебек асрауны да йибәрмәде. Ярый, бер эш чыккандыр, җае булмагандыр, ләкин бит, һич булмаса, күрешү мөмкин түгел, шундый-шундый хәлләр дип, бер хәбәр язарга кирәк иде, ул да юк.

Мәдрәсә вакыйгалары, приказчиклары хакында күтәрелгән шау-шулар, болардан бигрәк, бердәнбер углы Йосыфҗанның качып китүе – ансыз да юкка кәефе китеп барган үзсүзле түземсез картны бик артык борчыдылар – моны халык шулай сөйли. Бунлар өстенә Һаҗәр романы да дөньяга фаш булгач, картның гасабилыгы бик җитди, куркыныч авыру мәртәбәсенә җиткәнен аны караган докторлар ачык икърар иттеләр.[1]

Урам теле бу хәбәрләрне Җиһангирга да ирештерде.

Аңа боларның һәммәсе мөмкин һәм табигый иде. Болар Һаҗәрне кайда булса да чыгарга, күрешү өчен барырга тыюы да бик ихтимал иде. Ләкин бит ике юллык бер хат язып ташлый алмаслык бер хәлгә төшүне һичбер төрле башка сыйдырыр хәл юк.

Юкса, Һаҗәр үзгәрдеме? Юкса, теге азан вакытларында күрешергә чакырып, аулак өйләрдә үтә нечкә көлмәкләрдән каршы ала торган гаҗиб Һаҗәрнең күңеле егеттән суындымы?

Җиһангир ике ай шул газапта үткәрде.

---

[1] *Икърар иттеләр* – таныдылар, сөйләп бирделәр.

Ләкин дөнья аңар карамады, хәят үз юлы белән баруда дәвам итте.

Бу ике ай эчендә Качкынның зинданнан качарга теләп тә беренче мәртәбәдә булдыра алмавы, бу аның язмышын тагын да авырайта төшкәнлеге, ләкин икенче мәртәбә көтелмәгән бер вакытта качканлыгы мәгълүм булды. Гимназист Тангатаров мәктәбеннән куылды. Госман шөбһә эчендә яши башлады. Булатов шәһәр читендәге мәдрәсәдә җыелыш мөнәсәбәте белән егерме дүрт сәгать эчендә шәһәрдән сөрелде.

Аңа ике пайтәхет, Казан, Уфа, Оренбург һәм Әстерхан губерналарыннан башка теләгән йирен сайлау хокукы бирелгән иде. Ул Пермьне ихтыяр кылды. Нина атлы учительница белән аның мөнәсәбәте сөйләнә иде. Булатов артыннан ул да китте. Хәзер аларны бергә торалар, дип сөйлиләр.

Шәкерт галәме эчендә кинәт зур-зур кузгалышлар булып алды. Шәһәрнең иң кадимнәреннән Вафа хәзрәт галим, могтәбәр, ләкин гаҗиб иске һәм бик артык мөтәгассыйбләрдән[1] санала, һәммә мәхәлләдәге шәкертләрнең берләшеп кузгалу хәбәре уйдырма булса да, һәр мәдрәсәнең иске диварлары чатный башлаган, һәркайда иске хәлдән ризасызлык тавышлары ишетелмәктә, тик шул Вафа хәзрәтнең шәкертәре генә бик артык тыныч күренәләр иде. Күптән түгел, каберстанга үлек ташу хурлык дип, искедән килгән хәмелгә[2] бөтен шәкерт тарафыннан бойкот ясадыгы хәлдә, бу мәдрәсә шәкертләре Садыйк байның анасын күтәреп зияратка барганнар, аларны күргән икенче бер мәдрәсәләр тарафыннан “Хәмел бәете” илә мыскылланып, барабаннар сугып, каршы да алынганнар иде. Бу мәдрәсә ничектер шулай заманның хөкеменә бирешмәгән кальгаләрнең бере булып тора иде. Моңа да Вафа хәзрәтнең үзеннән бигрәк Кәбир хәлфә сәбәп, диләр иде.

Үзенең артык каты куллылыгы һәрбер яңалык әсәрен минуты белән таптап юк итүе, шәкертне әдәбияттан, катнашудан, җәмгыятьләрдән үтә бер кысу белән тыюы аркасында моңарчы мәдрәсәне иске хәлендә тыныч саклап килә алган менә шул Кәбир хәлфә, исемнәре яшерелеп, номер белән кырык шәкерт тарафыннан имза кылынган бер мәктүп ала. Анда шул сүзләр язылган була: “Җитәр, канымызны күп эчтең!! Җитәр, күп гомеремезне схоластика белән харап иттең. Миемезне, чүп-чар белән тутырып, күп череттең!! Инде вакытың үтте!! Җитәр, милләт тамырына балта чабудан тукта! Син хәзерге көндә умарта каравылыннан башкага ярамыйсың! Сиңа бер атна вакыт: шул мөддәт эчендә мәдрәсәдән кит!! Без ислах сорыймыз, без теләгемез юлында фида буламыз, барачак юлымызга кискә булма: мәдрәсәдән кит, кит. Яхшы сүзне тыңламасаң, атна эчендә мәдрәсәдән югалмасаң, сине дөмектерәчәкмез.

---

[1] М*өтәгассыйбләрдән* – фанатиклардан.

[2] *Хәмел* – иске мәдрәсә шәкертләренең зияратка байлар өчен үлек күтәреп илтүләре.

Кырык адәм берләштек, шобага салачакмыз”...

Карт хәлфә бу хатны хәзрәткә укыгач, үлек кебек агарынды, теле тотлыкты, бераздан соң гына:

– Минем кырык ел мәдрәсәдә ятуыма мөкяфәт[1] шул, күрәсең! – дип, куллары белән йөзен каплады, ди.

Хәлфәнең кырык елы дөрест иде. Ул җиде яшьтә мәдрәсәгә бирелеп, егерме сигез елын төрле мәдрәсәләрдә уку белән уздырды, калганын шәкерт укытуга бирде. Ул зирәк түгел, ләкин бик үтә тырыш, дөньяда шул китап моталәгасы белән, мантыйк, кәлям моназарасыннан башканы белми, аның хакында, бик зур имтияз төсле итеп[2] “Шәрхе мәвакыйф”ны баштанаяк ике мәртәбә моталәга кылып чыккан, имеш, дип сөйлиләр иде. Кадим голямасы кашында игътибары яхшы, моназарада җиңүчән иде. Мәмләкәттә дулкыннар күтәрелеп татарлар селкенгәли башлагач, ул голяма мәҗлесендәге кебек, шәһәр җәмгыятьләрендә дә җәдиден, Думасын, сайлавын юк итәргә ашкына, шәкертне тыйса да, үзе нотыклар әзерләп бара, ләкин сөйли алмый. Бервакыт шәһәр театрында: “Мин... җәмәгать...”, – дип авызын ачса да дәвам итәргә мөмкин булмаган иде.

Аның яше иллегә якын булса да, ул яхшы урын, бай кыз көтә, шунлыктан һаман өйләнми, беркая да чыкмый, мәдрәсәнең дәресханәсендә яши иде.

Югарыгы хат аны чыннан каушатты, ул кич һичкая булмый торган булды, бик кирәк булса, янына сакчыга ике шәкерт алып йөри, диләр.

Бу хәбәр тиз арада бөтен шәһәргә таралды. Мәхәллә байлары җыелып, бу хакта киңәшәчәк булдылар. Күп шәкертнең куылу ихтималын сөйлиләр. Бу – кем эшедер, башта ачык беленмәде, иске яклар моны яңалардан күрә, яңалар “без түгел, безне каралар өчен, иске фикерлеләр юри йибәргәннәрдер”, диләр.

Халык, мәдрәсә галәме бу хәбәр белән чобалышып торган вакыттагы тентү сәбәпле, нәтиҗәсез булып калган беркөнге мәдрәсәи исламия ихтилялы яңадан гөлт итеп күтәерлүе, шәкерт белән идарәнең тагы бозылышканлыгы, нәкъ ул вакыттагы рәвешчә, яңадан ихтиял хәзерләнгәнлеге сөйләнә башлады. Ләкин күп сөйләргә тугры килмәде, бер көнне мәдрәсәи исламиядән чыгарга дип хәзерләнгән йөз илле шәкертнең җитмеше дөнья җимерәчәк мәртәбәдә тавышлар, сүгешләр, җыеннар, садалар, ислах сораулар идарәне сүгүләр, шау-шу, кырылышлар белән мәдрәсәдән чыгып, шәһәрне ду, галәмәт китерделәр. Сүз берләшкән кебек, шуның икенче көнендә Вафа хәзрәт шәкертләренең кырыгы, үзара җыен ясап, унҗидесе калды, егерме өче

[1] *Мөкяфәт* – хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк.
[2] *Зур имтияз төсле итеп* – өстен булып, зур дәрәҗә санап.

хәзрәтнең күз алдында, сораганнарны бирмәсәң вәссәлам дип, садалар, марсельезалар белән мәдрәсәдән номерга агылдылар.

---

Шәһәр шәкерт белән тулды. Номерларда урын җитми. Телләрдә башка мәсьәлә бетте, матбугатта чыгучыларны, милләт каһарманнары дип, алкыш белән каршы алдылар, бик кызу иганә җыярга тотындылар – татар галәме төбе-тамыры белән кайный, кузгала башлады.

Ул арада зыялылардан берничәсенең ярдәме, катнашы белән чыккан шәкертләр тарафыннан зур җәмгыять ясалды. Монда халыкның күплеге искиткеч дәрәҗәдә иде. Бик зур шау-шулар булды. Мәдрәсә идарәләрен якларга азапланган биш-ун кешелек кечкенә бер гөруһтан башкалар шәкертне хаклы тапты, аларның сораганнары милләт өчен су белән һава дәрәҗәсендә кирәкле, алар үзләре өчен түгел, милләт өчен тырышалар:

– Яшәсен ислах, яшәсен татар шәкерте, яшәсен милләт каһарманнары!! – дип күтәрделәр.

Шәкертләр арасыннан сөйләүчеләр байтак булды. Алар чыннан кызганыч сүзләр белән үзләренең авыр хәлләрен, чыгарга niләр мәҗбүр иткәнен тасвир иттеләр. Иң кызу нотык Җиһангирныкы булып чыкты. Ул шул дәрәҗәгә җитте һәм җиткерде ки, татар шәкертенең авыр, кызганыч язмышы хакындагы соңгы сүзләре тәэсирендә үзе дә йомшарды, җәмгыять эчендә дә күпләрнең күңеле тулды, күзләренә яшь килде, арада түзми егълаучылар да булды.

---

Зур крепостьны алган гаскәрнең әүвәлге сәгатьләре ничек булса, шәкер тә шундый хәлдә иде. Аларны тәбрик итәләр, каһарман, диләр, кайда барса, кул кысып, мактап, шат каршы алалар. Эчләрдә дәрт, өмид ташый, йөзләр көлә. Алда үзенең якты нуры белән матур киләчәк ялтырый. Мәдрәсәне ташладылар, инде бәхетле булачаклар, инде үзләре теләгән юл белән яңа хәятка, сәгадәтле хәятка барачаклар.

Ләкин бу озакка бармады.

Икенче көнне үк чыгучыларның уникесе, без белмәдек, безне котыртттылар дип, Гали мөдәррискә барып тәүбә иттеләр, ялындылар. Аларны гафу итеп, һәрнәрсәгә буйсыну шарты белән, яңадан алды. Берничәсенең атасы килеп, эт урынына кыйнап, типкәләп, мөдәррис алдына китереп, анардан гафу үтендереп, яңадан мәдрәсәгә биреп киттеләр. Башкаларның да күбе аталарыннан бөтенләй өзелде, “яңадан кер, сүземне тыңламасаң, бала итмәм, мәңге күземә күренмә, сиңа бер тиен юк”, дип, хатлар алдылар, табигый, кермәделәр, акча килмәде, ач калдылар, сатарга да,

рәһенгә[1] салырга да бернәрсә юк – ләкин алар һаман бәхетлеләр иде.

Берничә егет, чыгу белән, Истанбулга китте. Икәве Бәйруттагы "Америка көллиясе"[105+] белән хәбәрләшеп, шуңа керү өчен хәзерләнергә тотындылар.

Башкаларның дәрте русчада, рус мәктәпләрендә иде.

Бик артык ашкынулы әүвәлге атналар үтү белән, ун егет берләшеп, шәһәрнең читеннән җиде тәңкәгә квартир алдылар. Аның идәнен себерү, мичен ягу өчен, күршедәге бер хатынны ае ике сумнан яллыдылар да, шунда торып, барысы бергә айга утыз биш сум түләп, бер студенттан русча укырга башладылар.

Акчасы барлары, башкалары да шулай төрлечә йирләште, беразы читкә китте, калган иң күп өлеше, гәрчә русча уку дәрте белән янсалар да, гәрчә кайсы дарелфөнүнне[2], кайсы институтны, байтагы учительлекне, кайберләре фәкать рус әдәбияты белән танышуны арзу кылсалар да[3], шуңар ашкынсалар да, акча булмаганга, китәргә җүн күренмәгәнгә, әле хәзергә шулай шәһәр буенча йөреп, табан шомарту, күбрәк вакытны, җыелып, Марсельеза җырлау белән гомер үткәрергә мәҗбүрләр, ләкин һаман көенмиләр, һаман алдагы матур киләчәк өмиде белән шат яшиләр иде.

---

Шәкерт һәм мәдрәсә галәмен вакытлыча күкләргә ашкындырган бу дулкын кайтып хәят әүвәлге эзенә төшә башлагач, Җиһангир өчен дөнья тагы Һаҗәр генә булып калды. Ул арада Кадыйр байның каты авырулыгы, бу авыруның рухи гасаби чир икәнлеге мәгълүм булды. Шуның белән бергә Һаҗәрнең ире алдында егълап гафу үтенүләре, төннәрдә "мин җиңелдем, минем ихтыярым киткән иде", дип саташулары хакында сүзләр таралды.

Җиһангир башын югалткан, ышанырга да, ышанмаска да аптырый, ләкин күңеле ни дә булса шундый бер хәл булырын сизенә иде.

Бөтен ике ай буена көткән туктаусыз ялварулары, илтифатсыз бик күп озын мәктүпләре җавапсыз калган, инде аптырау хәленә төшкән соң, Һаҗәрдән хат килде. Бу – гади хәбәр рәвешендә кыска, ләкин ихласлы һәм күз яше тулы иде. Егет аны шулай дип аңлады:

– ... Мин синең алдыңда бик гаеплемен. Ләкин, дустым, мине әүвәлге Һаҗәрең дип белмә. Элек Кадыйр бай өстемдә падиша, мин аның җариясе идем. Шунлыктан аны алдау, аңа хыянәт итү – миңа үч алу шатлыгы бирә иде. Хәзер дөньялар үзгәрде, ул көн-төн ятагында, йөзе кәфен кебек, күзләре, яшь белән тулып, миңа ялынган, ялварган төсле итеп карыйлар... Мин аны

[1] *Рәһенгә* – закладка.
[2] *Дарелфөнунны* – университетны, югары уку йортын.
[3] *Арзу кылсалар да* – теләсәләр дә.

бик кызганам... Бервакыт миңа бөтен бәхет синең кочагыңда иде... Бер-ике айны авыр үткәрдем. Нәрсәләремне җыеп чыгып китәргә җиткән минутлар килде, ләкин аның шул җылаулы тавышы, шул ялынулы карашы минем такатемне бетерде: мин аны кызганам, бу кызгану эчемдәге теләгемне сүндерә, вакыт-вакыт аягына ятып, гафу үтенәсем килә...

Ләкин, җаным, йөрәгем синең белән тулы, ышан, сине ихлас белән сөйдем, дөньяда сиңа башка нәрсә калмаган, мең Кадыйрны аяк астында изеп, синең кочагыңа атылудан башканы уйламый торган идем – инде бары да бетте, бар да, ерак бәхетле төш кебек, сагынып уйларга, сагынып җыларга калды.

Үтенәм, моннан соң миңа хат язма, очрашырга сорама. Күңелем синдә, ләкин мин аның хатыны, Аллаһ шуны теләгән. Ир хакы – Тәңре хакы, диләр. Йөрәгемдә – син, сине мәңге сөячәкмен, ләкин ни эшлим? Мине кичер, тәкъдирем башка икән...

Җиһангир ике көннән соң аңа ошбу хатны язды:

"Һаҗәрем, дөньяда син бар идең, мин синең өчен яши идем. Син матур идең, синең тавышың – былбыл сайравы, синең кузгалуларың – аккош йөреше иде. Синең йөрәк хур кызын хәтерләтә, синең кочагың җәннәтне оныттыра иде.

Инде боларның бары да үтте. Без аерылыштык, яңадан кавыша алмабыз һәм теләмим дә. Мин сине аңлыйм, дип уйлый идем, ләкин зур ялгышуда булганмын. Соңгы сүзләрең белән минем рухым алдында яңа Һаҗәр ачылды. Аның белән бергә минем сиңа булган тойгым да икенче төс алды. Табигать синең кебекләрне сирәк ярата. Инде мин яңа Һаҗәрне яңа сөю белән сөям. Әүвәлге сөюем – агу эчендә ширбәт, җәннәт эчендә җәһәннәм иде. Анда якты кояш, хыялый таң нуры бер-бер артлы алмашыналар иде. Инде боларның бары да бетте. Инде язгы төн белән тын айлы кичәләр: шулвакыт мин, урманлы биек* таулар арасындагы күл буена барып, таш өстенә ялгызым утырам да, татлы хыялга батып, дөньядан кичәм – яңа сөюем миңа хәзер менә шулай булып хис кылына..."

## LVIII

Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр файдасына әдәбият кичәсе ясарга уйлыйлар. Бүген репитиция була. Җиһангир да катнашачак иде. Мәктүбен тәмамлап конвертка салды да, шунда бармак булып, урамга чыкты.

Тыш аяз, якты, ләкин нечкә киемнәрне дер-дер калтыратачак мәртәбәдә зәһәр суыклы кышкы төн иде. Дөнья кар белән ялтырый, аяк астында таза

---

* *Г.Ибраһимовта*: бөек.

суык шыкырдый, кашлар, мыеклар бәсләнеп бара, эчтән чыккан сулыш куе ак төтен кебек күтәрелә иде.

Ике чат барып Екатеринскийга борылуга, озын җонлы биек чиркәс бүреге белән Давыд күренде. Аның янында Нигъмәт казый белән, дер-дер калтырап, нечкә киемле Баязид карый да бара иде.

Зур толып эченә күмелгән Нигъмәт казыйга ачы суык сизелми булса кирәк, ул килеп җитүгә туктады да:

– Теге турыда иртәгә җыелыш була, сине күрергә йөри идем, – дип, Җиһангирга сөйләргә тотынды:

– Мин, – ди, – үз тарафымнан мәгърузә[1] сыман бер нәрсә хәзерләдем, баш идеясе шул: мәдрәсәләрнең эшкә ярамавын, аларны нигезеннән ислах кирәклеген барыбыз да беләмез. Ләкин коры белү җитми. Хакыйкый ислах өчен, күп парә[2], бөтен гыйльми икътидар лязем[3]. Хәзерге кебек һәр мәхәлләдә ибтидаидан алып галигәчә[4] сыйныфлар булса, моңа татар байлары түгел, Ротшильдлар[106+] дә акча җиткезә алмас. Бу хәл, әлбәттә, бетерелсен, һәр мулла үзенең шөһрәте өчен, “Халидия”, “Заһидия”, “Фәйзия”, “Сәгъдия”, “Госмания”, “Шәйтания”, белмәм тагы niләр дип, вывеска асмасын. Бу эре хәрефле вывескалар бар да алып ыргытылсын да, бөтен мәдрәсәләр бер кулга, бер идарәгә җыелып, шәһәргә бер гали, ике игъдади[5], берничә рөшди[6] калдырылсын, болар гомуми булсын, аерым бер муллага карамасын, һәр мәхәлләнең үзенә ибтидаи дәвам итсен... Мөхтәрәм хәзрәтләр, мөгаллим вә мөдәррисләр исә, икътидарлары булса, шул бер җепкә тезелгән мәдрәсәләргә кереп, үзләре әһел булган фәннән дәрес бирер, булмый икән, тамагын туйдырырга башка кәсеп эзләр...

Нигъмәт казый дәвам итте, баядан бирле баскан йирендә түзә алмый үзәгенә төшкән суыктан биеп, туктаусыз колакларын уып уылдап торган Баязид карый, ахры, чыдамады, өшегән тамактан килгән дерелдәвек тавыш белән:

– Валлаһи, тунга уралган да акрынлап изә бирә... Түзәр хәлем калмады, туңып үләм... – дип, әйләнеп-әйләнеп алга таба йөгерә башлады.

Нигъмәт казый һаман сүзендә иде:

– Зыялылар, – ди, – бу фикергә яхшы карыйлар... Шәкертнең һәммәсе шул якта булуы табигый... Шәһәрдәге бөтен мәдрәсәләрне берләштереп, гомуми шәкерт исеменнән шул югарыгы максат юлында хәрәкәт башлыйсы,

---

[1] *Мәгърузә* – доклад.
[2] *Парә* – Төркиядә акча исеме.
[3] *Икътидар лязем* – көч кирәк.
[4] *Ибтидаидан алып галигәчә* – башлангычтан алып югарыгача.
[5] *Игъдади* – хәзерлек сыйныфы.
[6] *Рөшди* – урта мәктәп.

аннан соң...

Урманов та көтәргә теләмәде, Нигъмәт казый сөйли калды, Давыд:

– Үзең итсәң соңга кала, син моны иртәгә үк почтага сал! – дип, Качкын өчен үз арадан җыелган алты сум акчаны Җиһангирга тапшырды да, иптәшләре белән күрешеп, Баязид артыннан китте.

---

Бу йирдән Госманның квартиры ерак түгел иде. Баязид карый, вокзалга төшеп менгәнче дип, анардан берәр җылырак кием алмакчы иде, бүлмәсен кереп карасалар да, киярлек нәрсә күренмәде – буш кул белән кире чыктылар.

Давыд теге эшче Абдул белән “Кире авыл” буе крәстияннәре арасына бара. Поезд сәгать уникедә китәчәк, әле уннан артык булмас. Квартирларына кайтсалар бик ерак булганга, бераз җылынып чыгарга дип, егетләр якындагы пивоханәләрнең беренә керделәр.

Монда да артык җылы түгел, монда да тәрәзәләр кар, боз белән бизәкләнеп туңган иде. Шулай да монда урам суыгы юк иде инде. Буфетта калгып-калгып утырган фәлән марҗа боларга бер бутылка пива белән суга бүрттерелгән борчак, тозлы сохари китерде.

Ләкин егетләр күп эчмәделәр, Урманов бер-ике йотты да кире куйды. Баязид карый күбекләнеп торган стаканны бер тын белән эчеп бетерде дә яңадан пиво салмады.

Ул, гадәттәге шикелле, әле дә гасаби, әрнүле бер хәлдә иде. Кемгәдер ачуланган, кемнәндер шикаять иткән тавыш белән үзенең шундый дәрт белән керешкән эшендә һичбер нәтиҗә күрелмәвен; теге “Фидаиләр” партиясенең һаман телдә генә, зиһендә генә икәнен; тегеннән ат ышандырсалар да, ун көн буена бүген-иртәгә дип көттерүләрен, аннан соң помещик студентның авырганын, учительнең ябылганын; алардан рәт чыгар җае калмагач, ялгыз үзе тәвәккәлләргә карар бирүен, ләкин бу вакытларда “корбан”ның ай буена авырыпмы, ни эшләптер, һичкая чыкмавын, авыруыннан терелде дигән хәбәре белән бергә үк аның Питербургка киткәне ишетелүен, шулай итеп, үзенең ике ай гомере әрәм булганын, хәзер әүвәлге карарын кичектерүенә үкенгәнлеген һәм һичбер нәрсәгә карамыйча, хәзер яңадан шул карарына кайтканлыгын, теге вакытта Давыдка сөйләгән карарын барлыкка чыгару өчен, сиһшәнбедән[1] калмыйча авылга китәчәген, шунсыз җаны түзмәвен сөйләргә тотынды.

Калын марҗа килеп, ябарга вакыт җитүен белдерде. Егетләр дә туры вокзалга киттеләр. Болар килгәндә, вокзалның эче-тышы халык белән тулы –

---

[1] *Дөресе*: сишәмбедән.

бар да йөгерә, кабалана, теге якта пыш-пыш локомативның ыжгыруы ишетелә, һәрхәлдә поездның китәргә торганлыгы ишетелә иде.

Давыдлар туры дүртенче классларга махсус залга керделәр. Анда пычрак, сасы, тын алырга мөмкин булмаслык дәрәҗәдә тыгызлык иде.

Ул арада икенчегә сызгыртканы ишетелүе белән мондагы ярлылар, зур киндер капчыкларын өстери-өстери, платформага чыгарга ашыга, тапташа башладылар. Тегендә, кассада исә, билет алучылар, әллә кайдан уралып-уралып, озын койрык булып, нәүбәткә тезелешкәннәр иде. Эшчеләр һәм озын капчыклар арасыннан кысылып, тапташып кассага якын килгән вакыт, алар сәләмә киемле, җыртык бүрекле Абдулны күрделәр. Ул икесенә дә билет алган, акчасын санап тора иде. Кечкенә төенчекләрен култыкка кыстырдылар да тагы шул сасы, пычрак, тыгыз залдан, ярлы мужиклар белән тапташа-тапташа, тышка, платформага йөгерделәр.

Болар чыгып җиткәндә, анда халык, бигрәк тә дүртенче класс вагоннары алдындагы ярлылар, ут чыккан кебек кабаланалар, кайнашалар иде. Абдул Урманов култыгындагы төенчекне эләктерде дә шул җәмәгать белән бергә вагонга керер өчен кысылыша башлады. Өченчегә сызгыртты. Кондукторлар: “Тизрәк, тизрәк, каласыз, юкса”, – дип кабаландырырга, калучыларны юлдан читкә кауларга тотындылар. Беренче, икенче классның яхшы вагоннары алдындагы пакь киемле аля франк әфәнделәр, ханымнар арасында кемнәрдер җылаша, үбешә, онытма, хат яз, озын яз, дип кычкырыша, кайберләре кочаклаша башладылар.

Вагоннар бер-бер артлы урыннарыннан кузгалды.

Локоматив “Әһә” дип, авыр йөкне тартып алган ат кебек омтылды да жыы-ыы итеп ыжгырып йибәрде, тагы кызулады, вагон тәгәрмәчләре тизләделәр. Тегеннән: “Каласың, җә!!” – дип, Абдул кычкырды. Давыд шул эшчеләр, крәстияннәр белән лыгрым тулган үгез вагонының баскычына сикерде дә бер эшченең ишеккә кертә алмый азапланган зур киндер капчыгын эчкә этәреп, Абдулга кулын бирде.

Вагоннар тагы кызуладылар, китүчеләрнең гәүдәсе яшеренде, тик Абдулның җыртык киеме белән Урмановның чиркәс бүреге генә күренә иде.

Баязид башындагы фуражкасын алып селкә калды:

– Хәерле юлга!!

Давыд белән Абдул киткәч, Баязид карый аптырап уйга батты:

– Әле яңарак кына бу Абдул исерек татар иде. Эш тапмый, артык нәрсәсен сатып эчә иде! Ел да үтмәде, хәзер ул партиянең иң ныклы кешеләреннән булып бара. Эш таба. Эше белән гаиләсен туйдыра, аның өстәвенә, эшчеләр, крәстияннәр арасына революция рухы сала, аларны хөкүмәткә каршы бер организация хәленә куеп йөри! Ә без, ә мин ни эшлим?

Сүгенәм, рич[1] сөйлим? Бу эшмени? Абдул ник эшли дә, мин ник булдыра алмыйм? Аерма нәрсәдә? Шул авыр уй белән, акрын атлап, шәһәргә менеп китте.

## LIX

Җиде яшькә җиткәч, Сахибны әбисе карчык авылның мәчете каршындагы кечкенә мәптеккә китерде дә, кулына ике йомырка тоттырып, ишектән төртеп кертеп йибәрде. Анда кечкенә тыгыз бүлмәдә siksәнләп бала: "Әлиф-сен-ә, бисен-бә, тиясен-ти, тисен-тә"[2], – дип шаулый, уртада, озын чыбык тотып, бер күзе кылый хәлфә утыра иде.

Ишектән Сахиб килеп керү белән, мәптек шым булды, хәлфә аңа текәлеп карады:

– Сиңа ни кирәк?

Сахиб оялды, башы белән бер якка каранып, җиң очын авызына капты да тик торды.

Хәлфә тагы:

– Кем углы? Укырга килдеңме? "Әлебби"ең[107+] бармы? – диде.

Сахиб култык астыннан апасы биргән иске "Иман шарты"н[108+] чыгарды, ике йомырканы хәлфәгә китереп төртте.

– Кем баласы? – дигәнгә кашы[3], тагы муенын кыйшайтып, җиңен чәйнәде, авыз ачарга курыкты, яңлыш әйтер дә хәлфә үзенең озын чыбыгы белән шыелдатыр кебек тоела иде.

Хәлфә, яңадан аңа күзләрен текәп, ачуланган тавыш белән:

– Ник дәшмисең, әллә телсезме син? – дигәч, Сахиб пес-пес җылый башлады. Ул арада малайлардан берсе бик кабалан[4] тавыш белән:

– Хәлфә абзый, мин аны беләм: ул – Кәримә әбинең кызының улы... Аның ата-анасы юк, ул – ятим... Алар түбән очта, күпер төбендә торалар... Мин беләм, аларның мөгезсез кәҗәләре бар иде, былтыр көз "Әшкүл" буенда бүре ашады... Мин беләм, печән өстендә алачыклары янды... – дип такылдап китте.

Хәлфә Сахибкә утырырга кушып:

– Бисмилланы беләсеңме? – диде.

---

[1] *Дөресе*: речь.

[2] *"Әлиф-сен-ә, бисен-бә, тиясен-ти, тисен-тә"* – монда иҗек системасы белән укырга өйрәнүне авторның көлкегә алуы аңлашылып тора, ул аны шәкертләрнең иҗекләрне әйтү үзенчәлекләренә бәйле белдерә. Язучы моны алга таба да төрлечә куллана.

[3] Бу урында *каршы* дип укырга кирәк.

[4] *Кабалан* – ашыгыч.

Бала, муенын кыйшайтты, җиңен чәйнәгән килеш, ишетелер-ишетелмәс, авыз эченнән:

– Писмер-рахмән… – дип мыгырдады.

Хәлфә:

– Җиңеңне чәйнәмә, ачык әйт, кычкырып әйт!! – дигәч, Сахиб тагы пыскылдап җылады. Малайлар көләргә тотынды, хәлфә озын чыбыгы белән бер уңга, бер сулга ши-ши иттереп тартты. Берничә яктан:

– У... у... беләккәем... У-у..., Аллакаем...

– У-у... у муенкаем..., – дип сызлана, безелдәп җылый башладылар. Үзләренә чыбык эләкмәгән малайлар бу җылаучыларны:

– Ә, алаймы?! Үзәгеңә үттеме? Бая миннән көлгән идең! Икенче шаярмассың!! – дип үртиләр иде.

Хәлфә сабак бирде. Сахиб, уң кулы белән аяк табанын кашуда дәвам итеп, күзләрен мичнең ярыгыннан сузылып чыккан төтенгә юнәлдергән хәлдә: “Әлебсен-ә... бисен-бә... биасын-би, тисен-тә”не яттан тәкрар итә башлады.

Көн шулай үтте. Кич булды. Кылый күзле хәлфә урынына калган зур аксак шәкерт: “Ятыңыз, ятыңыз!” – диде.

Менә бервакыт сәндерәдән мендәрләр, бишмәтләр оча башлады. Ансыз да тыгыз, һавасыз мәктәптә тын алырга җай калмады: тузан күтәрелде, шау-шу кузгалды; кемнең аягына басканнар, кемнең мендәрен җыртканнар, аннан мәптек эче җон белән тулды; кемнең юрганын пычракка ташлап таптаганнар, кемнең бишмәтен урлаганнар... Бер сәгатькә якын шау-шу, тузан, җон белән ду, галәмәт килгән соң, мәптек бераз тынды, ишекне ачкач, тузан бураны да басылып, һәркем урынлы – урынына сузылды. Арадан алты малайга урын калмаган. Алар, зур аксак шәкерткә барып:

– Без кая ятыйк?.. Урын юк… Апрайлар безне кысып чыгарды!! – дип җыларга башладылар. Шәкерт озын чыбыгын алды да яртылый йоклап беткән малайлар өстеннән: “Әлиф, ят!! Әлиф, ят!!” – дип бер уңга, бер сулга шыпылдата башлады. Тагы кемнәрдер “У-у... у... беләккәем... колаккаем...” дип сызланып җыларга тотындылар.

Әлиф яткач, урын киңәйде, теге алты малай да арага сыйдылар. Ут сүнү белән, төрле яктан: “Әкият, әкият”, – ди башладылар. Бик күп ялындыргач, Садыйк таз дигән берәү:

– Борын, борын заманда бар ие, ди, бер патша, аның бар ие, ди, өч улы, таз ие, ди, кече улы... – дип сөйләргә тотынды.

Ул бик майлап, матурлап, килештереп сөйли иде. Сахиб теге кылый күзле хәлфәне дә, тыгызлыкны да, аксак шәкертне дә, уңлы-суллы чыжылдап торган чыбыкны да онытты, шул әкияттәге патшаның кече улы белән китеп,

җиде диңгез кичте, җен патшасының җитмеш катлы бүлмә эчләренә кереп, анда сакланган матур кызларны күрде, алар белән яңадан чыгып, Каф тауларын үтте, адәм колагы ишетмәгән, күз күрмәгән кошларның канатында очып, патшага кайтырга чыкты – шул арада үзенең йоклап киткәнен дә сизми калды.

Иртән тагы шул озын чыбыкның шыелдавына уянды. Башкалар торганнар, тәһарәт алып, мәчеткә дә киткәннәр, беразы уяна алмый ята икән, аксак шәкерт:

– Ни эшләп ятасыз, бинамазлар! – дип кычкырды да буй-буй сыдыра башлады. Сахиб ничек торганын белми дә калды. Мәптектә тагы кичәге тыгынлык, шау-шу һәм тапташ иде. Кемнең комганын алганнар, кемнең тәһарәткә дигән суын урлаганнар, кемнең башмагын киеп чыкканнар, кычкырышалар, тиргәшәләр. Кызып китеп, Апрай Хәлкәйнең башына биреп ташлаган. Берсе, җылап, казыйга барды. Шунда ук тегене яткырып суктылар. Ләкин тавыш моңар карап басылмады. Монда Апрай аркасын ачып ята, тегендә тиргәш, кычкырыш дәвам итә, көче җитмәгәннәр җылашалар иде. Сахиб ни эшләргә белми каушап, аптырап торды да шунда яткан агач табанлы, җүкә йөзле бер сыңар башмакны, уң аягына эләктереп, башка малайлар артыннан, дәңгезли-дәңгезли, якындагы елгага китте. Көн суык, башмак кар эченә батып-батып китә иде, ләкин бала аны сизмәде, елгага килеп, боз тишегеннән (бәкедән) ашык-пошык бит-күзен чылатты да тәһарәт алган төс белән мәптеккә йөгерде.

Кайтып керсә, анда астлы-өстле куелган өч мендәр өстендә, кулына озын чыбык тотып, чалма-чапаннан мулла абзый утыра.

Сахиб барып керүгә, мулла абзый аңа текәлеп карады да:

– Бу дамы? – диде.

Бала, куркуыннан ни эшләргә белмәде, җылый да алмады, дер каушап, ишек янында ката калды. Кемдер:

– Ул ятим бала... Кичә генә килде... Аның аягына кияргә юк, – дигәч, мулла абзый аны сукмады, янына чакырып алып сорашты да:

– Тырышып укы! Шаярма!! – дип, бер тиен көмеш садака бирде. Моның белән Сахиб йомшарып, бәхетлеләнеп үк китте. Инде аңа дөнья башкарак иде, нидәндер күзләре яшьләнде. Иртә намаздан калган малайларның, аркаларын ачып, идәндә тезелешеп ятулары, мулла абзый кулындагы озын чыбык шыелдавы аңа төштә кебек тоелалар иде.

Сахибкә ишек төбеннән урын бирелде. Шул көннән алып, ул мәптектә ятып укучы[109+] булып калды.

# LX

Авыл мәптегендә биш кыш ятып “Шәрхе Габдулла”га төшәрлек булгач, сабакка тырышлыгы, зирәклеге, үзен карарга һичкеме булмаганлыгы өчен, мулла абзасы аңар шәһәр мәдрәсәсенә китәргә фатиха бирде.

Анда ни белән яшәячәк, кем ашатачак, кем киендерәчәк – моны бер Аллаһ кына белә иде.

Озаткан вакыт мулла абзый аңа, үзенең дә шулай бер тиенсез чыгып китеп, зур мәдрәсәдә егерме ел укып кайтуын, данлыклы Шакир ахунда көтүче баласыннан шундый бөек дәрәҗәгә ашканын, аның да шулай һич караучысы булмаганын хикәя кылды. Аллаһ ярдәм бирер, талибелгыйлемнәргә[1] шулай йир йөзенә таралырга пәйгамбәремез дога кылган дип сөйләп, аңа егерме тиен садака бирде:

– Сиңа бер арба гошер[2] куйдым. Игеннәр суккач, сатып, акчасын йибәрермен. Бәхетеңнән, җиде пот чыкса, ике тәңкә ярымлар чамасы булыр, - диде.

Соңгы көзнең яңгырлы бу көнендә, кичкә каршы, Сахиб авылыннан чыгып китте.

Бу вакыт аңар унөч яшь иде.

Бу – 1898 нче елда иде.

---

Шәһәр Сахибның котын алды. Ничә катлы зур таш биналар аның өстенә җимерелер, шул исәбе-хисабы юк һәммәсе бер-беренә охшаш өйләр, урамнар арасында аның башы әйләнер, адашып үләр кебек иде. Элгәре Вафа хәзрәтнең мәсҗеден, аннан соң мәдрәсәсен эзләп каңгырап беткәч, кемдер аңа: “Менә шунда булыр!” – дип күрсәткән капкадан керде. Анда бер-берсенә якын салынган әллә ничә кызыл таш, ике агач бина, өем-өем киселмәгән бүрәнәләр ята. Бер озын пычкы күренә иде. Кая барырга, кайсы ишеккә кагылырга тагын аптырады, ул арада якын мәсҗедтә мөәззиннең өйләгә азаны ишетелде. Кайдадыр чиркәүме-ниме кактылар. Сахиб, Аллага тапшырып, асткы катка керә торган ишекләрдән беренә килде дә, баскыч белән түбән төшеп, ишекне ачты. Ул кая барып кергәнен белмәде: бер тирән базмы, мунчамы, башка нәрсәме – һич белер хәл юк, анда бик күп авыздан чыккан катыш гөрләү ишетелә, ләкин төтен һәм бу[3] белән тулганга, кем, нәрсә барын күрергә имкян юк иде. Ишек яңагына тотынып бер-ике атлагач, күз өйрәнә төште. Күргән йире ниндидер зур ук бер асткы өйгә охшашлы нәрсә икәне беленде. Анда ни-нәрсәләр бар икәне дә аерыла башлады.

[1] *Талибелгыйлемнәргә* – шәкертләргә, гыйлем эстәүчеләргә.
[2] *Гошер* – уңышның уннан бер күләмендә бирелә торган садака, дини налог.
[3] *Бу* – пар.

Ишектән керү белән, дивар буйлап, кырыклап казан тезелеп киткән. Боларның астлары ягулы, өстләреннән бу чыгып тора, берничәсе ит куырганга охшаш чыжылдый, май, көек исе чыгара. Шул казаннарның янында, һәммәсе кулларын сызганып, зурлы-кечеле бик күп шәкерт кайнаша: кем бәрәңге турый, кем токмач сала, кем ашның тозын карый, өресен түгә... Сахиб үзенең ашханәгә килеп кергәнен аңлады, инде күзләр дә өйрәнделәр, аңа ашханәнең зурлыгы, киңлеге, идәнендә яткан бәрәңге кабыкларына, баткагына, түгелгән суларына чаклы күренә башлады. Ике почмакта тактадан ясалган ике госелханә бар. Аларда берничә егет нәүбәт көтә. Ике госелханәнең уртасында бик озын буй булып, чүгәләп, комганнар белән тәһарәт алып торган шәкертләр тезелгәннәр. Аларның артында тагын бик күпләре, муеннарына сөлге тагып, комган бушаганын көтәләр. Кемнәрдер: “Комганыңны кешегә бирмә, суы миңа да калсын”, – ди. Берсе, госелханә эчендә коенып ятучыларның ишеген кагып: “Әллә үлдеңезме, тизрәк чык”, – дип кычкыра. Ул ара да булмый, казан янындагы тирләп, пешеп, кызарып беткән шәкертләрдән берсе ут чыккандай кабаланырга тотынды, әллә нинди ашыгыч тавыш белән:

– Куырдагым[1] яна, итем көя... харап булдым, казаным шартлый, казаным шартлый!! Су, су, су!! – дип акырып җибәрде дә, якында су тапмагач, учагындагы кисәүләрне барын берьюлы тартып, идәнгә төшерде. Алар гөрлиләр иде, аягы белән таптый башлады. Кемдер су биргән икән, аны казанына салган уңайга, гөлт итеп, майдан ут күтәрелде, ләкин бу озак булмады, шунда ук сүнде.

Казан шартламады, ләкин ашханә май исе белән, төтен белән тулып, тамакны ачыта, җөткертә, күзне баягыдан яман кисеп ашый башлады. Кемнәрдер сүгенергә, адәм үтерәсез, кем ул, дип тиргәргә тотынды; ишекне, тәрәзәне тутырып ачтылар, аннан салкын һава кереп тулды, берничә шәкерт күзләрен уа-уа чыгып киттеләр... Шулардан берсе Сахибны таптый язды, аның аягына басты, беләкләренә килеп тотынды да:

– Бу кем? – дип, кулыннан алган хәлдә, аны тышка өстерәде.

Бу – Сахибның бәхетенә каршы, аның якташларыннан бер шәкерт булып чыкты. Кулында комганы бар иде, ашханәдән сукрана-сукрана, башта тәһарәт алды да Сахибны үзе белән бергә югары катка, үзе тора торган мәдрәсәгә алып керде. Ашханәдәге май исе белән ачы төтен мәдрәсәгә дә менгән иде. Мәдрәсәнең почмаклары юеш, тәрәзә төпләреннән су ага, кемдер коридорда, бик тузанлап, киез кага иде. Шәкертләр ябык, саргылт йөзлеләр иде, ләкин Сахиб боларның берсен дә күрмәде. Авыл мәптегенә караганда,

---

[1] *Куырдак* – кыздырылган ит.

монда һәммә эш хәйран шәп иде, һәммә эш үзенең мәһабәте[1] белән аны баса иде.

Мәдрәсәгә керү белән, ул ишеккә якын мич буена тезләнеп утырды да, шәкертләр өйләдән кайтканчы, урыныннан кузгалмады. Якташы үзләреннән калган ашны бирде, ул берсүзсез аны ашады да:

– Табак-савытыңызны төшеп җуыйммы? – диде. Якташ:

– Белсәң, ярый, – диде. Яңарак “Шәрхе Габдулла” башлап, әле тик “Әкъсами сәбга”гә[2] җиткән шәкертләр бар икән. Икенче көн Сахиб шуларга сабакка кушылып, мәдрәсә шәкерте булып китте.

## LXI

Еллар үтте.

Кышкы челләнең күз ачкысыз ачы суык, куәтле буранлы көннәреннән берсе иде. Өйлә җитәр алдыннан гына, Заһир хәлфә чыгып, кичә вафат булган Насыйр байның җеназасын күтәреп зиярәтка барырга язылган утыз шәкертнең исемен игълан кылды. Арада Сахиб та бар иде.

Ул күп ярлылык күрде. Мәдрәсәдә аның кебек ятимнәр байтак бар, ятим булмаганнарның да күбе, өйләреннән алса ел буена биш-ун сум ала, тагы шулкадәр хосул[3] кирә – алар шуның белән кыш чыгарга тиешле. Тамак – ашка, өст киемгә туймый, шулай ачлы-туклы яшиләр.

Сахибның дөньяда һичкеме булмаганга, аңа бер тиен киләчәк йир юк, булса, шул бәйрәм, хәтем, зиярат, аз-маз зәкят хосуллары иде, ул күп еллар шуның белән кичендe. Бер хәят аны, башка шәкертләр кебек үк суырган, тумыштан таза, киң күкрәкле һәм гайрәтле бала саргылт кипкән егет хәленә әйләнергә якын иде. Үзе үсеп дәрәҗә күтәрелә башлагач, аның урыны ишек төбеннән югарыгарак күчте, җәй, кәсеп итеп, бераз акча таба торган булгач, бигрәк дәрәҗә зураю, “мантыйк хан”[4] булу сәбәпле, кирәчәк хосуллар да мулая башлаган иде.

“Гакаид”кә төшкәннән бирле[110+] ике бәхетле үлем булды. Һәр икесендә җеназа күтәрергә язылып барып, өчәр тәңкә алдылар. Насыйр бай мәхәлләнең иң зурларыннан, анарда һәркем инде өчтән дә ким булмас, ди. Утыз язылган, ләкин язылмаганнарның да һәммәсе бара. Шәкертләр генә түгел, аксак кизү дә, калмыйм, дип йөри. Башка вакыт бармаучылар була, көн суык чакта алардан кием алырга мөмкин иде, бүген кием алу мәсьәләсе бик үткенлеккә

---

[1] *Мәһабәте* – олылыгы, күрер күзгә шәплеге.

[2] *“Әкъсами сәбга”гә* – җиденче бүлеккә.

[3] *Хосул* – керем, садака.

[4] *“Мантыйк хан”* – мантыйк (фәлсәфи логика) укучы.

ireште. Авылның бер карчыгы, Коръән чыккан өчен, аңа бер ак киез итек биргән иде. Гөнаһ шомлык, кичә әллә кайсылары аны ашханәгә киеп төшкәннәр дә, манма су ясап, пычракка ташлап менгәннәр. Ул кияргә яраклы түгел. Шәһәрдән читтә бу мәдрәсәдә 5-6 чакрымлык йирдә булган зиратка шундый кышкы суык буранда чалыш ката, нәзек бишмәт, башка җылысы тимәгән чалма белән бару – бу җиңел эш түгел, инде Ходай үзе ярдәм бирсен!! Ләкин бармаска мөмкин түгел. Бу әллә ничә елга бер туры килә торган бай җеназа – өч тәңкә уенмыни? Ачы буран шәкертләрнең үзәкләренә суга иде. Гөнаһ шомлыкка каршы, күмү озак булды, хәзрәт Коръәнне акрын, озак укыды. Күп шәкертләр туңуларыннан сикереп торып кайтырга йөгерә башлар хәлгә җиттеләр, ләкин түзделәр.

Сахиб җилгә каршы иде, аяклары, читеге, катасы, чолгавы – бары бергә оешып туңды, арка үзәкләре катты, куллар тоймый иде, ләкин килгәч, күбенә түзгәч, тагы бер-ике минутка түзми хәл юк иде инде. Буранга яны беләнрәк борылды да, бармак очларына өрә-өрә, дерелдәвендә дәвам итте. Аңа күп өшергә тугры килә, яшь вакытында кышкы көндә, яланаякка ката киеп, күрше кибеткә йөгереп чыгуда, мунчадан кайтуда ул еш-еш суык тидерә иде. Ләкин, мәтрүшкәме, карлыган кагымы эчеп, тирләп йокласа, иртән сәламәт уяна иде.

Насыйр бай җеназасы карлыган кагы белән генә үтмәде. Зираттан кайтып чәй эчүгә бөгәрләнеп ятты һәм шул ятудан ул тик өч ай үткәч, иптәшләре табып биргән урынга, казакка муллалыкка китү өчен генә торды.

Доктор китерделәр. Ул, мәдрәсәдә ятса, тагын начар булачагын, аны иркен йиргә кую лөзүмен сөйләде, ләкин монарга парә булмаганга, ул өч ай шул шау-шулы мәдрәсә почмагында ятарга мәҗбүр булды. Күпләр аның терелүенә дә шөбһә белән карый башлаганнар иде, ләкин казак сахрасы, иркен һава, куәтле кымыз аңа шул дәрәҗәдә килеште ки, көз кайтканда ул танылмас мәртәбәдә тазарган, кызарып тулган иде.

Моназарәләр, озын төн моталәгалар, мәдрәсәнең барлык торышы кыш буена аны яңадан суырды, ләкин ул һаман зыянсыз күренә иде. Каралыр вакыт керде, алар җиде шәкерт риязәт[1] чигә башладылар. Гөнаһ шомлыкка, Сахиб өч ел каралды, һәр өч елның ике аен көненә ике бәрәңге, ике кипкән клиндер белән үткәрде. Казак кымызы аны яңадан төзәтте, шулай да Вафа хәзрәтне ташлап, мәдрәсәи исламиягә килгән заман аның йөзе-күзе хәятының ниндидер эчке бер куәте, мае алынган төсле карый иде.

---

Шәкерттән теләсә кем генә докторга бармасын, ул уку ташларга,

---

[1] *Риязәт* – ашау һәм эчүдә үзеңне чикләү.

мәдрәсәдән чыгып, иркен һавада яшәргә куша. Ихтилял белән мәдрәсәдән чыгып, ничектер, бер сум акча арттыра алгач та, Сахиб тә докторга күренде. Аңа инде кискен рәвештә:

– Сездә кан әсәре калмаган... Сездә хәят бетә, – диделәр.

Сахиб доктордан көлеп чыкты: аның ашарына юк, ул арыш икмәгенә акча тапмый; доктор аңа, бик гади эш төсле итеп: “Һәр көн иртә-кичә йомырка ашаңыз, сөт-каймак өзмәңез, кош ите, яшь тавык шулпасы файдалы булыр”, – ди.

Сахиб иптәшләренә моны сөйләп көлде. Ләкин алар бу көлүгә кушылмадылар: күбесе шулай ябык, саргылт, кансыз булган татар шәкерте эчендә дә Сахибның йөзе үзенең үтә хәятсызлыгы, иреннәре, күзләре үзләренең селкенми, кузгалмый, ничектер катып калган үле саргылтлыклары белән куркыта, гүрдәге кыяфәтне искәртә иде. Ләкин егет үзенең хәле бу дәрәҗәгә җиткәнне сизеп бетми иде, бугай. Сизсә дә, инде хәзер генә кулыннан һичбер эш килә алмаячак иде. Дәрте русчада, идеалы студент булмак исә дә, акча булмаганга, хәзергә укый алмый – молдакә[1] булудан ничаклы бизенсә дә, хурланса да, башка чара табылмаганга, ул яз җитү белән тагы казакка китәргә карар бирде: анда тазарачак та, кыш кайтып, русчага тотынырга акча да табачак!

---

Мәдрәсә яшьләренең байтагы кебек, Сахиб тә бераз шагыйрь, бераз мөхәррир, ләкин бик шәп җырчы иде. Сүз берләшкән кебек, туган авылында, мәптектә, Вафа хәзрәттә, Мәдрәсәи исламиядә, хәзер инде яшьләр арасында – һәркайда аны “җырчы Сахиб” дип йөртәләр иде.

Шуңа күрә, мәдрәсә атнакич мәҗлесләрендә үзенең җыры, гаҗиб тавышы белән патшалык сөргән бу егет шәһәрдә татарча кәнсирт[2], әдәбият кичәләре дигән нәрсәләр телгә алынган көннән үк бу эшкә катнашучыларның алгы сафында тотыла иде. Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр файдасына дип соралган “кичә”гә башта рөхсәт бирелмәде, Ногманнан Габдрахман исеменә күчереп карадылар, анда да файда булмады. Ахыр беленде: бирелмәвенең сәбәбе – ихтилялчы шәкертләр файдасына ясалуда икән.

Мәдрәсә ихтилялларының дулкыны басылып шәкертнең күбе таралгач, җырчы Сахиб, бер көн урамда Фәхрине очратып, шул турыда сөйләште дә, өченчегә, теге сигезенче сыйныф гимназиядән куылган Тангатаровны арага алып, үзләре файдасына кәнсирте, әдәбияты катыш бер кичә ясарга карар бирделәр.

Тангатаров гимназистларны, реалистларны китерәчәк, Фәхри

[1] *Молдакә* – казак балаларын укытучы.
[2] *Дөресе*: концерт.

приказчиклар җәмгыяте залын сорау, рөхсәт алу, афиша чыгару кебек рәсми эшләрне башкарачак, Сахиб исә шәкертләрне чакырачак, кичәнең бөтен эчке эшләрен үз өстенә күтәрәчәк.

Мәдрәсә яшьләре эшләшергә ашкынып торалар, Камил, Хәйри, Җиһангир катнашырга сүз бирделәр. Нигъмәт казый белән Нәҗиб Кәмал да булышачаклар. Саф табышның өчтән берен сәяси тоткыннарга бирү шарты белән, Госман һәм Давыд Урманов та кушылырга булды. Халык күзенә тулырак күренсен өчен, Рауза туташ белән Алкин да арага алынды. Башта март эчендә уйланган иде. Залның көне туры килмәү, рөхсәт ала алмау кебек сәбәпләр белән, апрель урталарына кадәр кичегеп, беренче репитиция Госман чыгарылгач, аның урынына утырган Ногман учительнең русча-татарча мәктәбе бинасында 14 нче апрель көненә билгеләнде.

## LXII

Сәгать кичке сигез иде.

Давыд Вафа хәзрәтнең мәсҗеде каршысында урамга буй салынган кызыл түбәле озын, тәбәнәк бинага килеп туктады. Ул арада тышкы ишек янындагы багана артыннан бер карачкыл чыгып, башы белән капкага ишарә кылды:

– Күрүләре мөмкин... Әнә, капкадан кергәч, беренче ишеккә барыгыз!..

Ул капкадан урап, арткы ишеккә килгән вакыт кемдер: “Тукта”, – диде.

Бу – приказчик Габдрахман иде.

Еректан ук авызын җәеп килде дә: “Нихәл, ниләр җимереп кайттың”, – дип, Давыдның аркасыннан сугып күреште. Урманов аны туйдан бирле күргәне юк иде, ишекне ача-ача сораштыра башлады:

– Ну, эшләр ничек, иптәш?.. Матур көн итәсеңме?

– Әйбәт, бик әйбәт, иптәш! Бары да майлаган кебек бара. Бай сүзендә торды, иллегә мендерде, фатирдан да уңдык...

– Соң, бикә – Нәфисә ханым ни хәлдә?

– Ал да гөл кебек, пар күгәрчен кебек гөрләшеп торабыз... Тик ул сиңа бик үпкәле... Безне бөтенләй ташлады, ди...

– Әйтә күрмә, туганкай, үземә дә бик уңайсыз... Ләкин ни эшләргә? Яңарак авылдан кайттым. Эш баштан ашкан... Ничек кенә булса да, шул арада кереп чыгармын... Миннән бикәгә сәлам әйт, гафу үтенә, диген...

Чолан караңгы иде. Габдрахман, кесәсеннән электрик шәм чыгарып, юлны яктыртты. Икесе бергә эчкә үттеләр. Болар кергәндә, озынча дүрткел сыйныф бүлмәсенең кара парталары, дивар буйлары төрле киемдә, төрле кыяфәттәге татар яшьләре – гимназистлар, приказчиклар, шәкертләр белән

тулып гөж килеп тора иде.

Иң якында франк киемле, ерактан ук хуш ис бәреп торган Фәхри белән гимназист форма, ләкин иске киемдә сипкел йөзле озын буй Тангатаров күренде. Алар белән күрешеп, алга җәмәгать эченә киттеләр. Кирәк кеше килеп беткән диярлек иде.

Бер-берсен кочаклап, тыгыз җәмәгатьне ярып, биш-алты яшь гимназист, реалист идән буена йөриләр иде. Бүлмәнең яртысын тутырып тезелгән күп парталарның бер читенә кысыла төшеп, ябык саргылт йөзле, күбе җитү чәчле, кыска тужуркалы, һәммәсе бераз тартына, басыла төшеп, мәдрәсә яшьләре утыралар. Рауза үзенең алышынмас тар, озын кара юбкасы, кызыл кофточкасы белән, урам як тәрәзәгә сөялгән кара тактага нидер яза, кыска калдырып киселгән кара чәчен тузгый-тузгый, ярым көлеп, сөйләвенә караганда каршысындагы Нәҗиб Кәмал белән җырчы Сахибкә нидер аңлатырга – исбат итәргә тырышкан кебек күренә иде.

Давыд алар янына барып Раузаның кулын кысуга, эчке ишектән төз-таза һәм озын буйлы Госман белән бөтен торышында табигый нәзакәт хис кылынмакта булган аристократ кыяфәтле, аля франк киемле реалист Акчулпанов килеп чыгып, боларга якынлаштылар. Алкин Давыдтан “Кире авыл” буендагы йөрешен, андагы эшләрне, алган тәэсирен сораша башлады. Урманов, ярым көлеп, ярым җитди йөргән йирендәге кайбер мужикларның “миңа күпме йир бирерсең” дип сорауларын, үзенең бер авылда урядниктан котылуын сөйләргә тотынган гына иде, тагы ишек ачылды да бусагада озын таза гәүдәсе, каты, ләкин тыштан бераз елмаючан йөзе белән Нигъмәт казый күренде. Аның артыннан бөтен кыяфәте илә: “Ходаем, ни генә күрәм инде монда”, – дигәндәй каушап торган Вәли башкорт –мәдрәсәи исламиядән ихтилял белән чыгучы курайчы Вәли керде.

Вәли башкортның мондый җәмәгать эченә беренче катнашуы иде. Килеп керүгә аның башы шаулады, күз алды бераз томанланып аптырый төште. Аның үтә ялтыраган дөм кара чәче, бераз кысыла төшкән ялкынлы кара күзе, бераз кытайны хәтерләтә торган киң йөзе, җәенке борыны, тычкан койрыгы шикелле чылгыйлары[1], ике якка киткән нечкә кара мыегы күренү белән, һәммәнең диккатен алдылар, җәмәгать күбе аңар борылды. Бу аны тагы каушатты. Ул ялгызы килгән булса, ихтимал, “Ходаем, үзең коткар” дип, кире дә чыгып китәр иде, ләкин, гөнаһ шомлыкка, бусагадан бер-ике атлау белән, Нигъмәт казый аның култыгыннан алды да:

– Иптәшләр, менә сезгә Ашказар буе асаба башкортларының беренче курайчысы – минем иптәшем Вәли әфәнде... – дип кычкырды.

---

[1] *Чылгыйлары* – очы бөтерелгән мыеклары.

Инде ни эшләргә, Вәли бөтенләй коелып төште. Ярый Нигъмәт бар, ул күрешә башлады. Вәли башкорт та аныңча кылынырга теләде, ләкин ул зур бәлаләргә очрады: кемнеңдер аягына басты, Раузага күрешергә барганда, өстәлгә бәрелеп, андагы кара савытны тәгәрәтте, чак калды, өстәл үзе аумады. Инде бу гына җитмәгән кебек, күз алдындагы егетләргә кулын төрткәләп якындагы урынга сыеныйм дисә, купшы приказчик Фәхригә кагылды, шулай да баш-күз чыкмады, ул байтак газаптан соң, өченче партаның бер читенә барып сыенды.

Маңлаеннан салкын тир чыккан, үзе шул ике минутта җилкәсендә тау-таш күчергәндәй арыган иде, һәммә нәрсә ят, өйрәнелмәгән. Барып кул биргән кайбер гимназистлар, реалистларның Мәхмүд Тангатаров, Заһир Кәримов, Садыйк Дибирдиев дигәндәй исемнәр, фамилияләр әйтүе аңар бөтенләй аңлашылмады. Тик ахырдан гына иптәшләре аңа руслашкан яшьләрнең яңа танышкан адәмгә үзләрен тәкъдим итүләре икәнен төшендерделәр.

## LXIII

Киләсе кеше килеп беткән иде. Фәхри: “Башларга вакыт”, – диде. Җәмәгать тынды, төрлесе төрле йиргә урынлаша башладылар. Давыдны рәис ясадылар. Ул шул парта почмагына утырган йиреннән кузгалмыйча ук:

– Алайса, башлыйм, – диде.

Ясалачак “кичә” өчен кемнең дә булса, хәзерләп килгән программасы юкмы, булса, гарыз кылуларын[1] үтенде. Өченче партадан Җиһангир торды. Аның йөзе бик тыныч түгел, тавышы бераз калтырый иде. Шулай да бик артык каушап, сер бирерлек хәлгә төшмәде:

– Минчә[2], безнең “кичә”без дүрт бүлектән ясалырга тиеш: 1) матбугаттагы әдәби вә шигъри әсәрләрдән сайлап алынган кисәкләр; 2) халык җырлары; 3) бер пәрдәлек спектакль; 4) үз арамыздан язучылар булса, аларның кулъязмалары.

Нәҗиб Кәмал болар өстенә гел музыкадан гыйбарәт бер бүлек арттырырга, диде. Нигъмәт казый белән җырчы Сахиб, Алкин ни шуны мәгъкульләп сөйләделәр.

Тангатаров, нык хәзерләнеп, матбугаттан күп нәрсә сайлап килгән икән. Аның аркасында беренче бүлек бик җиңел үтте.

Спектакль өчен Галиәсгар Камалдан бер пәрдәлек сайладылар. Халык җырлары җырчы Сахиб белән Вәли башкортка тапшырылды. Алар киләсе

[1] *Гарыз кылуларын* – тәкъдим итүләрен, җиткерүләрен.
[2] *Минемчә* дип аңларга кирәк.

репитициягә чаклы бу хакта бераз нәрсә хәзерләп куярга тиешлеләр. Шуның белән өч бүлек тәмам булып, кулъязмаларга күчтеләр.

Арада байтак мөхәррирләр, шагыйрьләр бар икән. Язадыр дип, һичкемнең хәтеренә килмәгән егетләр берәм-берәм күкрәк кесәләреннән дәфтәрләр суырап чыгара башладылар.

Беренче Габдрахман торды. Аның "Татар бае" исемендә бер һәҗүви[1] әсәре бар, имеш. Теле начар, ләкин мәузугысы[2], кайбер аерым сүзләре гаҗиб көлке иде. Үзенең укуы да кызык кына чыкты.

Ул мәнзумәсендә бер татар бае, үзенең корсагы тау чаклы булып үскәнен төшендә күргәнлеген тасвир кыла. Шулвакыт байга приказчиклары киләләр дә: "Ә, нихәл, корсак шештемени?"– дип, чиртеп китәләр. Ул арада байның күз алдында ук аның яшь хатыны матур бер егет белән үбешә башлый, ләкин бай бернәрсә дә кыла алмый. Торырга теләсә, корсагы йибәрми... Ул һаман газап чигә, корсак шешкәннән-шешә бара, ниһаять, ярылыр минут җиткәнен хис итеп, кычкырып йибәрә дә уянып китә...

Бөтен җәмәгать, бигрәк тә яшьрәкләр тарафыннан туктаусыз көлке тыңланган бу мәнзумәне сәхнәдән укырга ярап-ярамавы хакында зур ук тавыш күтәрелде. Иң беренче Нигъмәт казый каршы төште:

– Безнең, – ди, – хәзинәмез юк, дәүләтемез юк. Милләтнең барлык матди ихтыяҗын үтәү байларыбыз кулында. Мәктәпме, мәдрәсәме, җәмгыяте хәйрияме, башка нинди дә булса, бер тәрәккый вә мәдәният эшеме – һәммәсе-һәммәсе байларымызның һиммәте[3] белән генә бара!.. Моны күрмәсәк, без сукыр булачакмыз... Күрә торып, сәхнәдән шундый тәхкыйрьләр[4] күрсәтсәк, бу артык зур ахмаклык булачак...

Берничәләр бу фикерне хаклаган да иде. Ләкин Җиһангир, аякка басып, кызу вә куәтле тавыш белән: "Байларның барлык юмартлыклары – дуңгыздан бер кыл. Алар бичара халыкларның актык канын эчәләр, баласы ач, үзе ялангач булган эшченең маңлай тире белән җыелган хәрам маллардан сарайлар салалар да, адәм күзе буяр өчен, эшче тапкан миллионнардан бакыр бер тиеннәрне садака кылалар. Имеш, юмартлар садака алу хурлык, имсал кылу[5] – адәмнең адәмлеген кимсетә... Моны аңларга да, ул җуан корсакларның "Сахиб хәйратлык" маскалары нидән гыйбарәт икәнен ачарга вакыт...", – дип сөйләгәннән соң, яңадан игътираз итүче булмады.

"Татар бае"ннан соң Алкин русчадан тәрҗемә "Тоткын" исемле бер

---

[1] *Һәҗүви* – көлкеле, сатирик.
[2] *Мәүзугысы* – эчтәлеге.
[3] *Һиммәте* – тырышлыгы.
[4] *Тәхкыйрь* – мыскыллау, мәсхәрә.
[5] *Имсал кылу* – мисал итү.

нәрсә укыды. Монда Эшлиссабор[1] крепостендә[111+] сәяси җинаять сәбәпле бер уңгайдан егерме биш ел яткан берәүнең фөрьяды[2] тасвир ителә. Яшь егет тимер рәшәткә эчендә картайган. Инде аның чәчләре агарган. Ләкин ул һаман әүвәлге идеалына табына:

– Кояш бардыр, сандугач сайрыйдыр, ай әле дә шулай үзенең гаҗәеп серле хыялый нуры белән бетмәс сөю дәртләре илһам итәдер, ләкин минем күңелем аларда түгел... Чыгарга телим, ләкин иркен һава, зур кала рәхәтләре күрү өчен түгел, юк, мин алардан ерак... Мин зинданда күп гомер яттым, дөнья үзгәргәндер, дим, халыкларыбыз теләгән якты, киң хөррият белән яшиләрдер, дим... Сөйләңез, шулаймы, адәмнәр хөрриятkә ирештеме... яки һаман да шималь[3] боз сахралары ялкынлы хөррият коллары белән тулымы? Юкса, һаман да тәңренең азат коллары авыр богаулар эчендә ыңгырашаларммы?.. – дип тәмам булган бу әдәби кисәк синзурдан[4] үтсә, әлбәттә, программага керергә тиеш табылды. “Тоткын”нан соң Җиһангирның “Хатын язмышы” дигән мәкаләсен тыңладылар. Ул хатыннарның хәзерге хәятындагы вә кызганыч авыр көннәрен тасвир итә дә аларга азатлык вә тигезлек бирелү тиешлеген исбат белән тәмам кыла.

## LXIV

Бераз төрләндереп алу өчен, кулъязмаларны ахырга калдырып, Җиһангирныкыннан соң җырларга, көйләргә күчтеләр. Җырчылар да байтак икән. Камил яңа көйләрне, бигрәк тә “Баламишкин” белән “Ижбулдин”нарны матур сыздырды. Приказчиклардан Фәхри, мәдрәсә яшьләреннән Сахиб – болар инде кичәнең җыр бабында беренче каһарманнары иде. Алкин билмөнтәфидән[5] тәрҗемә “Сахра җиле” исемендә бер шигырь, Тангатаров Некрасовның “Несжатая полоса”сының[112+] һәр җөмәсен[6] декламировать иттеләр. Тагы бер гимназист Валерий Брюсовның “Ташчы”сын[113+] яттан укыды.

Болардан соң кемдер:

– Җә, Нигъмәт казый, нәүбәт синеке: һөнәреңне күрсәт! – дигән иде – ул бөтен йөзе белән көлеп:

– Мин җырлармын җырлавын, егетләр!... Ләкин мин җырлый башласам, һәммәңез чыгып качар, – диде.

---

[1] *Дөресе*: Шлиссельбург.
[2] *Фөрьяды* – аһ-зары.
[3] *Шималь* – төньяк.
[4] *Дөресе*: цензура.
[5] *Билмөнтәфидән* – күптән онытылып беткән; тыелган.
[6] “*Җөмләсен*” дип укырга кирәк.

Тагы кемдер:

– Безнең чыгып качу тагы бер хәл... Казармага тавышың ишетелеп, аннан гаскәр килә башлар, – дип шаярды. Ул хорда гына катышты. Тавышы, чыннан да, казармага ишетелеп гаскәр китерерлек иде. Калын, куәтле, ләкин ягымлы күкрәк авазы анардан шундый булып чыга иде ки, гүя караңгы төндә еракта тау елгасы гөрли яки калын моржа бар куәтенә улый иде. Иң ахырдан Вәли башкорт белән җырчы Сахиб, курайга салып, “Ашказар”ны суздылар. Аларга ара-тирә Фәхри дә кушылып алды.

---

Җырлар, көйләр шуның белән тәмам булып, яңадан кульъязмаларга кайттылар.

Җәмәгать тынып Давыд нәүбәтне белдерүгә, җырчы Сахиб аякка басты да, бераз гына гаепле йөз, бик чак кына тартынулы тавыш белән:

– Башкорт җырлары артыннан сезне Башкортстанның үзенә илтсәм, ничек булыр икән! – дип, кесәсеннән бер дәфтәр чыгарды.

Төрле яктан: “Укыңыз, укыңыз!!” – диештеләр.

Сахиб бераз гаепле елмаю, бераз тартынулы тавыш белән:

– Ялыксаңыз, озын күренсә, тәкәллефләнмичә[1] туктатуыңызны үтенәм дип, дәфтәрене ачты.

Урманов аның бу хикәясен күздән кичергән һәм аның хәрефе хәрефенә икәнен, үз башыннан үткән нәрсә икәнен дә белә иде. Байтакка сузылачак булганга, өстәл янындагы аркылы урындыкка күчеп, озак тыңларга җыенгандай бик ипләнеп утырды. Сахиб укый башлады.

## LXV

### Башкорт кызы Гөлбикә

(*хикәя шул исемдә иде*)

Берәү сөйли, шәһәремездә татарча зур концерт бирмәкче булдылар, иске яңа куәтләрнең күбе катышырга вәгъдә кылды. Эшнең башында татарлашырга, үзенең, сүзенчә, әйтсәк, татар халкы эченә керергә тырышып йөри торган бер мирза тора. Шул кемнәндер, “Ашказар”, “Тәфтиләү” көйләрен бездә яңлыш җырлыйлар, имеш, боларның төп ияләре булган башкортларда бөтенләй башка, имеш, дип ишеткән дә, нинди зур чыгын ясап булса да, шунда кеше йибәреп, “Ашказар”ларның дөрестен алдырырга карар биргән.

Ул белгән җырчылар эчендә, күрәсең, иң шәбе мин булганмын. Бер көн өенә чакыртты да:

---

[1] *Тәкәллефләнмичә* – тартынмыйча.

– ... Әфәнде, ди, вакытыңыз булса, – ди, – Яманташ буе башкортларына барып, милли көйләремезнең чынын өйрәнеп кайтыр идеңез, – ди. Үзем белән бергә башкорт шәкертләреннән берәр иптәш алуны муафыйк күрә, юллык егерме биш сум акча бирә. “Ярый, – дим эчемнән генә, – әзер акча булгач, дим, кайда йөреп кайтырга мөмкин... Син әйткәнчә, ул көйләрнең чыны булса, отармын, ота алмасам, үземнең белгән озын көйләрем күп, шуларны боргалармын да менә сиңа милли “Ашказар”ның дөресте булып чыгар... Барыбер, дим, монда аларның асылларын белүче юк...”

Шулай итеп, мин Башкортстанга китәргә булдым. Яныма, юаш дип, һәр такмагыма биер дип ышынган бер җырчы башкорт шәкерте алдым.

Һәйбәт язгы көннәрнең бере иде. Җыендык та вокзалга киттек. Юлдаш башкорт сөйләнә бара:

– Иптәш, – ди, – аксаны күп бетермәек, һис булмаһа, яртыһы үземезгә калһын, – ди.

– Ярый, – дим тыштан, әмма эчтән икенчене уйлыйм. Ләкин эш мин дигәнчә чыкмады. Мин, акчаны үземнеке ясап, кирәк йиргә тотарга да бетү-бетмәве турында иптәшемә исәп бирмәскә уйлаган идем. Начар заман бит, халыкның башында әллә нинди фикерләр йөри.

– Безнең, – ди, – эшләребез бертигез... Шулай булгач, хезмәткә каршы бирелгән малны да уртак бүләек, – ди.

Ни эшлисең, сүз көрәштереп, үзеңне ваксытыр хәл юк инде. Аның дигәненә каршы китмәдем. Без вокзалга җиткәндә, поезд да кузгалырга якын иде, юлдашыма:

– Бар, син урын ала тор, мин билетка йөгерим, – дидем.

Башкорт тилереп китте:

– Куй, куй!! Ул ни эштәгәнең? Билет алмаек... Әйттем кый, аксаны янда калдыраек, дип, – ди.

Мин дә күп вакыт арыш икмәгенә зар калган күп егетләрдән беремен. Биш-ун тәңкә кесәдә калса, минем дә эчне тишмәячәк.

– Ярый, – дим, – алмасак алмыйк!

Поезд кузгалды. Сикереп мендек тә, кондукторны күреп, ярты хакны төртер өчен, вагон ишеге төбендә йирләштек.

– Ваши билеты? – дип кычкырды берәү.

Кинәт әйләнсәм, ни күрим: ике кондуктор бер күз карашы белән ашарга органдай ачулы йөзле контроль безне ике яктан кысып алганнар. Иптәшем боларны күрүгә агарынды, теле бәйләнде, бер сүз дәшә алмый, ирексез артына таба чигенә бара, чигенә бара...

Теге куркыныч тавыш тагы тәкрар ителде. Мин күземне өч зобаниның[1] әле берсенә, әле икенчесенә йөртсәм дә, һичберендә мәрхәмәт әсәре күренмәгәч, ялганларга тотынам:

– Без, – дим, – вокзалга килеп төшкәндә, поезд, дим, кузгалган иде. Билет алырга өлгерә алмадык, киләсе стансада алыр идек...

Контроль, бик ачуланып, безгә:

– Молчать! – дип кычкырды да, янындагы ике кондукторга безне саклап алып барып, киләсе стансада штраф түләтергә әмер бирде.

Без баскан йиремездә ката калдык.

Стансада безне сакчы белән жандармскийга кертеп, ике хакын түләттеләр. Барачак йиремезгә чаклы билет алдырдылар.

Моңа минем эчем бик сызланды. Иптәшем, акча күп чыгуга зарланыр, дигән идем. Зарлану кайда!

– Әмма явыз нәрһәләр икән! Котым осты... Ябып кыйнайлар икән инде дип торам, – ди. Үзе һаман бөтенләй котылуына ышанып җитә алмаган кебек, капкыннан ычкынган куяндай як-ягына карана.

2

Икенде вакыты иде. Мөәззин манарадан азан әйтә.

Без, Марти белән Таптыдай җитәкләшеп, бер ягы зур урманлы, икенче ягы әллә кайдан-кая яшәреп яткан киң болынлы елга буена утырган бер авылга барып кердек. Тугайда өер-өер җылкылар күренде. Берничә йирдә башкорт хатыннары, бәйле колыннар янына китереп, бия савып йөриләр иде. Иптәшем: “Менә шул инде Таштамак дигәннәре”, – диде.

Авыл кечкенә. Урамнар кәкре-бөкре. Йортлар тигезсез... Кайбер өйләрнең башы тимер белән ябыла башлап та бер почмагы бетми калган. Инде ябылган йире дә череп килә. Кайбер биналарның түбә тимере яртылай буялган, калган ягы буяусызлыктан яңгыр белән күгәреп ята. Шулар белән янәшә үк бик күп өйләр түбә-кыексыз, тәрәзәләре карындык. Шул ук түбәсез өйләр янында яхшы аргамак муеныннан җеп белән ялгыз казыкка бәйләнгән. Аның артында яхшы көймә[2], зур яшел дуга тора. Минем аптыравыма каршы юлдашым:

– Ни булсын, башкортлар яңарак йир сатканнар, – диде.

Урамда, көннең эссе, бөркү булуына карамыйча, бик яхшы камчат бүрекләр кигән башкортлар очрады. Юлдашым һаман шул сүзне тәкрар итте:

– Ни булсын, йир сатканнар!

Бик күп исерекләр дә күрдек. Бер башкорт малае пешкән бәрән ботының очыннан эләктергән дә артык симез бер этне шул ит белән шаярта.

---

[1] *Зобани* – газап фәрештәсе.

[2] *Көймә* – бу урында: дүрт тәгәрмәчле, бөтен яктан да ябык арба.

Аның өстендә кыйммәтле атлас камзул, ләкин ботлары ялангач, башы ачык... Шунардан ерак түгел, бик зур бер кисмәк янында буй-буй ялтырап торган кыйммәтле бохара бикасабы[1] киеп, бер хатын алачык янындагы зур казанда сары май кайната. Иптәшем һаман: “Йир сатканнар”, – ди иде.

Ниһаять, көтү-көтү этләрне өрдереп, башкорт хатын-кызларының безне дәҗҗал күргәндәй бер ис китү белән, хәйранлык илә әллә кая чаклы карап калган күзләреннән котылып, авыл читендәге кечкенә бер бинага барып туктадык.

Ике сажин ара ясап, урам буена ике казык кагылган. Иптәшем, менә бу – башкортның капкасы булыр, диде. Читән, киртә дигәннең исеме дә юк. Капкадан керәбезмени дип көлә-көлә, юри шул ике казык арасыннан үттек. Бераз эчтә бер бина утыра: бу йирме яки агач булып та балчык белән сыланганмы – аерыр хәл юк. Иптәшем: “Менә бу өй инде”, – диде. Ул адәм буеннан бик аз гына бөек, чолан-фәлән юк, ишеге туры киң сахрага карый. Ике ягында кечкенә ике тәрәзә сыман нәрсә бар. Кыйбла як, ахры, йомшара башлагандыр, берничә урыннан терәүле, түбә-кыек башта ук ясалмаганмы, яки, ясалса да, башкорт хатыны май кайнатырга кирәк булган саен, аны алып яга-яга бетергәнме, анысын Аллаһ белә. Хәзер аның өстендә кеше биеклеге яшел алабуталар гөрләп утыралар.

Өй ялгыз: якын-тирәдә азбар, келәт кебек каралты юк. Һәр башкорт хатынына лязем булган төтенле читән алачык та күренми. Тик өйнең кыйбла ягында, тәрәзә турында, бик яхшы тимер тарантас тора. Кертеп куярга урын булмаганга, тәгәрмәчләрне кояш какшатмасын дип, аның өстенә иске мунчала чыпта[2] ябылган. Аның өстендә бер кыңгыраулы яхшы дуга, кыйммәтле чыбыркы ята... Мин бераз аптырансам да, иптәшем үз йортында шикелле иде. Мал иясенә охшый, диләр. Ләкин башкортның эте һичбер вакыт үзе кебек ялкау булмый. Авылга кергәч үк, шундый хөкем итә башладылар ки, мин, йа Ходай, өзгәләп ыргыталар, күрәсең, дип котым очты. Бу йортның да күпме ит ашаганлыгы кабарып торган сыртыннан, җилкәләреннән ачык беленгән зур ала эте бар икән. Бәхеткә каршы, ул ераграк булды, күреп, һам-һам дип безгә сикергәнче, ишектән кереп өлгердек.

Өйнең эче татар авылының иске кара мунчаларын хәтерләтә иде. Тәрәзәсе ачылмый – күтәрмәсе бозылган икән. Килеп кергән уңгайга кап-кара төсле булды. Өйнең дүрттән бер өлешен зур мич алган. Аш пешергәннәрме, мичкә якканнармы – өйдә бик эссе, тын алу читен булыр

[1] *Бохара бикасабы* – Азия халыклары куллана торган буй-буй ярым ефәк тукыма; шул тукымадан тегелгән кием.

[2] *Чыпта* – мунчала тасмаларыннан сугылган тупас тукыма.

дәрәҗәдә бөркү иде. Мич алды як такталар белән бүленгән. Бу якта, ишек төбендә, зур сандык, аның өстендә агартылмаганнан каралган, ләкин бик яңа өлкән самавыр кырынаеп ята. Аның янында яхшы чәйнек, чынаяк, берничә озын һәйбәт пычак күренәләр. Түрдә өйнең дүрттән берен каплаган сәке ясалаган. Анда берничә кара тышлы мендәр ауный, шулар янында кыйммәтле атластан бөтен төше алтынга манылган тәңкәләр белән тулы хатыннар киеме тәпәрләнеп[1] ята. Минем аптыравыма каршы, юлдашым һаман бер сүзне тәкрар итә иде:

– Йир сатканнар.

3

Хуҗалар өйдә икән. Безне бик ачык йөз белән:

– Ходай кунаклары... мөсафирлар, – дип, бик шат каршы алдылар.

Ач бүредән яман ачыккан идек, тамак туйдыра алудан өмид өзүемә карамый, әллә кайдан майлы күмәч тә, йомшак корт белән куе каймак та чыкты. Баягы сандык өстендә аунап яткан зур самавыр да, тиз арада кайнап, гөж итеп безнең алдымызга килеп утырды.

Сәкегә юрганнар, мендәрләр өстенә тәмам җәелеп, аякларны бөкләп утырдык та башкортта гына табыла торган тәмле ашамлыкларны бөгә башладык.

Юлдашым үзенең башкортлыгы белән, йир сатып алган акчадан актык тиеннәре дә очканын сизенде булса кирәк, кунакчыл башкортның кәефен кырмаска, мөкаддәмә урынында ниндидер бер экият сөйләде дә үз кесәбездән кымызга йибәрде. Ул арада казаннан ит исе дә чыга башлады.

Тотындык итләп, кымызлап сыйларга һәм сыйланырга.

Хуҗабызның элекке хатыннарыннан Кәримә үлгән, Сафия белән Уразбикәне аерган, бу хатынына күптән түгел өйләнгән икән.

Үзе Җомагыл исемендә, карсак кына, ябык кына сөйкемсез бер адәм. Кыяфәтендә башкортлык юк: ияккә таба очланып килгән тар йөз, су төсле күз, ул да эчкә баткан. Бите сары шадра, ияк очында бер-ике бөртек кенә сакалы җилтерәп тора; өстендә камзул белән буй-буй җыртылган керле күлмәк.

Әмма хатыны бөтенләй башка иде. Аның яшь, таза һәм төз гәүдәсе, ничектер, кан белән тулышып, биергә торгандай кузгалалар. Калку күкрәге, үзалдына майланып көләргә, кочагына алырга торгандай дәртле күзләре, ихтыярсыз, тамырдагы канны кузгаталар.Ул миңа бик охшады шул дәрәҗәдә ки, ишектән керү белән диккатемне алып, мин аңа башка кайгыны бөтенләй оныттым. Кымыз арасында, сүздән-сүз китеп, мич почмагына сөялгән хәлдә,

---

[1] *Тәпәрләнеп* – бөгәрләнеп, бөрешеп.

бу хатын иреннән зарланып та өлгерде. Йир саткач, мең сум акча тигән икән. Шуңа, кулга кермәс борын, бурычка батып, ун тәңкәлек киемгә илле сум вексель, утыз тәңкәлеккә – йөз, йөзлеккә өч йөз сум вексель биреп әрәм итүен, акча чыккач, калага барган йирендә авылның ун башкорты, кайтмый, атна буена эчеп ятуларын, акча алдыртуын, кулларына ике йөз дә кермәвен, аны да эчеп бетерүен, өй дә салдыра алмауларын, сөрдергән йирләрен дә чәчтерә алмый калуларын, инде шул меңнән тик бер арба белән шул атлас бишмәте генә калуын сөйләп чыкты. Ләкин Җомагыл хатынының зарларына каршы:

– Эшең түгел, ырылдама!! – дип кенә куйды.

Башкортның сатылган киң яланнарыннан, анда килмешәк хохоллар салган зур сарайларыннан, савым бияләренең азаюыннан, борынгы куәтле кымызларның бетүләреннән килә-килә, сүзне милли көйләр мәсьәләсенә якынлаштыра башладык. Ләкин һаман да турыдан-туры: “Без көй отарга килгән идек”, – дияргә мөмкин түгел иде.

Болай кинәт кагылсак, башкорт агай табагачын алыр да:

– Сез әллә ниткән нәмәләр икәнһез... – дип куып чыгарыр. Юлдашым моңа бик нык ышана.

Шунлыктан мәсьәләгә ерактанрак урап килергә мәҗбүр булындык. Башта үземезне сәүдәгәр сыманрак, соңра шәкертрәк, хәлфәрәк ясап: “Без мәдрәсәдә чакта атна кичләрдә җыелышып җырлаулар була иде, анда “курайчы Вәли” дигән шәп җырчы башкорт шәкерте бар иде”, – дип, төп теләккә китереп терәдек.

– Җырчы дигәнең бездә инде ул, – диде хуҗабыз, – бездә бер агай бар, шул, – ди, – өч мәртәбә Питербурга барып, падишаһ хәзрәтләренә җырлап кайтты, әллә ничә медале бар. Азаккы баруында: “Монда кал, үзеңезне акчага күмәрбез”, – дигәннәр икән, тыңламаган, башкортымны, сахрамны, кымызымны сагынам, дип кайтып килгән.

– Соң, ничек, Питербур шәп диме?

– Харап, ди, инде! Ул йортлар, ул өйләр, сарайлар, ди, мин һиңа әйтһәм, шундый бөек, ди, түбәһенә караһаң, башыңдагы бүрекләрең төшәр, ди.

– Патшаның үзен күргәнме?

– Күрмәгән кая!.. Күргән, әллә нисә рәт күргән!... Патша хәзрәтенең туры үзенә алып баралар, ди... Патшаның һарае, ди, үзе бер кала һаклы бар, ди. Идәннәре, ди, көзге кебек шома, ялтырап тора, ди... Таеп егылып, башымны яра яздым, ди. Патша хәзрәтләренең хатынын да күргән... Адәм әйтеп, адәм бетерә алмастай уңган икән, ди... Мин, ди, китәргә булган көндә үземне сарайга чәйгә алдырттылар... Ул аш-һыу, ди, ул кәнфитләр, ди, аша да

үл, ун башкортны кушсаң да, ашап бетерә алмаслар, ди... Патшаның хатыны, ди, “Җитеш, кунак!” дип өлтерәп тора[1], ди...

– Ул Питербурга барган җырчы кайда?.. Аны монда китереп булмасмы?..

– Булыр иде дә, ул әле авылда юк. Мөфтинең бикәләре курай уйнарга чакыртып алганнар иде, әле шуннан кайтмаган, ди...

– Авылыңызда башка җырчыңыз юкмыни?

– Ниткәнең? Булмаган кайда! Кирәк булһа, унны табарга мужны.

Башкортыбыз җиңеләеп, мәсьәләне очлап ук куйды, күршесендә генә тирә-якның атаклы җырчы, курайчыларыннан санала торган Хуҗабай бар икән. Ике минут үтмәде, ишеккә буе белән сыя алмыйча, бөгелә-сыгыла, җырчымыз килеп тә керде. Кулында курае да бар.

Исеме чын асабача[2] булган кырык яшьләр чамалы бу адәм бөтен кыяфәте илә дә чын башкорт иде. Майланып, җылтырап торган киң кара йөзе, кош йомыркасындай зур кара уенчак күзе, бер дә пәке тиерелмәгән[3] зур чылгыйлы кара мыегы, өстендәге киеменең сәләмә булуына карамыйча, башындагы чын камчат бүреге белән билендәге көмеш кәмәре – боның рус гаскәренең алгы сафында Парижга барып кереп тә, аннан итек урынына чикмән җиңе киеп кайткан мәшһүр тарихи каһарманнарның калдыгы икәнен ачык күрсәтәләр иде.

Ул килеп керүгә, безне үзе белән баладан ук бергә уйнап үскән адәмнәрдәй күреп көлә-шаяра башлады. Ахры, тирә-яктагы мишәрләр белән кабилә талашы бардыр. Утырып хәл-әхвәл сөйләштерүгә, шул мәсьәләне телгә алды:

– Менә, – ди, – бездә дә мишәрләр бар. Үзләренә дә әйтәм, һез кунак һыйлый белмәйһез дип, ди... Кунакка барһаң, – ди, ситләрен мунсала белән бәйләп куйган зур бәлеш китереп утырталар... Аның эсендә пешмәгән тары ярмаһы белән тозлы суга башка берни булмай. Менә мин, ди, аларга әйтәм: сезне, дим, бер сакырып, башкортның һары майда эркелдәп пешкән бәлешен ашатаем әле... Телеңезне йотып, аннан соң башкортның кем икәнен таныр һыз..., дим... Шулай итһәм, ярый бит, муллалар...

Мин сөйләргә сүз тапмадым. Иптәшем аның белән бик килешеп китте. Алар мишәрне, татарны яманлауда икесе бөтенләй бер авызлар иде.

Каймаклы чәй уңгаена без аны, читләп-читләп, җырлар тирәсенә тарта башладык. Дөрестме, ялганмы – йөгенә керер хәлем юк, әмма бу ирнең үзенең бер җырчылыгы хакында сөйләгәннәре бер башкорт өчен аз түгел иде.

---

[1] *Өлтерәп тора*– кунакчыллык күрсәтә, нәрсә дә булса эшләргә әзер тора.
[2] *Асабача* – Асаба башкортларынча.
[3] *Тиерелмәгән* – тидерелмәгән, тимәгән.

Оренбургта бер йирдә туры килеп, аның җырына Әхмәд бай хәйран булган. Каргалы байларыннан кемнәрдер аны туйларына махсус чакыртканнар... Троицкида кымыз мәҗлесләрендә ничаклы акчалар җыйган, Сембер фабрикантлары, алдырып, нинди зур хөрмәтләр күрсәткәннәр... Мөфтинең Өршән буендагы утары үз кулында чакта, аның бикәләре, кызлары, алдырып, күпме вакытлар курай уйнатканнар, ничә урыс байлары тройка белән йибәреп алдырганнар – белмәм тагы ниләр, тагы ниләр!!

Күп сүздән соң, бер уңгай табып, мин аның җырлавын үтенгән идем, ахры, җайсызрак кагылдым:

– Юк, – ди, – безнең кебек кешегә алай тиктән-тик җырлап утырып булмай ул, – ди.

Без бу сүзнең мәгънәсен аңлый алмадык, ярый хуҗабыз ярдәмгә җитеште:

– Тиктән-тик җырланмай инде... Тамак бераз йомшаргач, әллә булыр да иде, – ди.

– Башта ук шуны әйтәләр аны, хәерсез, – дим эчтән генә.

– Мә, – дим, – Җомагыл агай, безгә кәрзинкә пива китер, – дим.

Җомагылның кабак астына яшерелгән су күзләре ялтырый башлады. Минем кесәдән акча чыкканны сабырсызлык белән көтеп, карчыгадай эләктерде дә йөгерә-йөгерә чыгып ук китте. Биш минут эчендә читәне белән бөтен кәрзинне өстерәп кайтты. Самавыр, чәй, бушаган кымыз ужаулары[1] алынып, алар урынына ачылган пива бутылкалары белән стаканнар килде. Аякларны суза төшеп, төрлемез сәкенең төрле ягына кырынайдык та тотындык эчәргә, тотындык эчәргә!! Стаканнар туктаусыз шакылдыйлар, бутылкалар кәрзиннән сәкегә менә, тиз арада бушап, мич астына тәгәри торалар.

Бераз эчкәч, җырчы Хуҗабайның тигезлек хисе уйганды булса кирәк:

– Болай, – ди, – үзебезгә эчеп утыру килешмәй... Бичәләргә бал алдыргай идең[2], – ди.

– Күптән әйтәләр аны, – дим.

Акча бирдем, кайдандыр ике чирек әчегән бал да килеп чыкты. Пивога түккән акча әрәм китмәде, өй җанланды, җырчымыз үзе сизмичә үк сахра угылларында гына була ала торган киң күкрәк авазы белән озын башкорт моңын сызып та йибәрде:

> Сары да гынай җылан ай туз башлы,
> Сызгырадыр камыш буенча...
> Карада гынай кашлар... газиз башлар...

---

[1] *Ужҗаулары* – чүмечләре.
[2] *Алдыргай идең* – алдырыр идең.

Йөри икән язмыш буенча...
Исем китә, үземнең ай азуыма –
Һич чара юк хакның язуына...

Мәҗлес шулай дәвам итә. Халык кызганнан-кыза бара. Ләкин мин мөмкин кадәрле исермәскә тырышам. Бераздан хуҗа хатын Гөлбикә каядыр барып килде. Азрак торгач, аның артыннан кап-кара йөзле, ямьсез генә җылгыр гына кыяфәтле, керле күлмәкле бер кыз керде. Буйга җиткү, дәртле, кыю күренә. Ләкин минем күңелемне бер дә тартмады. Бу – җырчы Хуҗабайның туган кызы икән. Гөлбикә, аны, ахры, чакырып китергәндер. Кыз, ишек төбендә торып, нидер сорады, нидер эзләгәндәй булды. Шулвакыт хуҗа хатын кулындагы стаканына бал тутырды да кызга бирде.

– Мә әле, Уразбикә, татып кара: балы бик һәйбәт күренә, – ди.

Уразбикә, мич почмагына сөялеп, бер тында стаканны каплады да ишеккә таба барды. Тагы нидер сорады, эзләнде дә, шулай әрле-бирле йөренгәли торгач, сиздермәстән утырып ук калды. Хуҗабай җырлый, бутылкалар кәрзиннән сәкегә, аннан мич астына йөрүдә дәвам итәләр, халык кызганнан-кыза бара. Минем юлдашым белән Җомагыл инде камил исереп киләләр.

Ни сөйләгәннәре дә җүнләп аңлашылмый, үзләре һаман нидер лыгырдыйлар. Ләкин җырчы ныклы ир икән, тик кәефләнә генә бара. Кыз белән Гөлбикәнең дә балдан күзләре ялтырый башлый.

Бара торгач, Хуҗабайның җырына алар да катнаштылар.

Мин җырда, көй бабында җәяүле түгелмен. Русның театрында, концертларында, опералрында булганым бар. Исерекменме яки хакыйкате шулаймы, ни дә булса бар, аңарчы ишеткән һәммә нәрсә югалды, юк булды, Гөлбикә тавышы белән барлык җырчылар аяк астына төшеп тапталды. Мин аның авызына карадым да каттым:

– Йа Ходай, бу хатынга биргән моңың белән музыкаң дөньяда тагы кемгә дә булса насыйпмы, – дип хәйран булдым.

Гөлбикә мондый вакыт тәне, дәрте белән яраттыра торган хатын иде. Бер-ике көй сызу белән, мин анарда бөтенләй икенче адәм күрдем. Бу вакыт аның авазы фаҗигый бер фөрьяд белә аглый, йөзенә, күз карашына гаҗиб бер илаһи матурлык балкый, ниндидер хыялый галәмнең нуры белән яктыра иде.

4

Юлдашым белән хуҗа бер якка авып гырылдый башладылар. Без җыр белән эчүне дәвам иттердек. Кәрзинкә бушарга якын. Мин инде шуның белән фатиха бирү – яңадан алдырмау ниятендә идем. Гөнаһ шомлыкка каршы, юлдашым уянды да, кызарган күзләре белән бер миңа, бер бушаган бутылкаларга карап, исерек тавышы белән: “Без йоклаганда пиваны

бетергәнсез”, – дип, дау куптарды. Аның тавышына хуҗа да уянды.

Ул күзләрен җүнләп ача алмый, гәүдәсе авып-авып китә, шунда да үз сүзендә:

– Һи... тинтәкләр!.. Бу... нихәл? Бу эсү мени? ...Дабай...дабай... пива, – ди. Бирмәскә мөмкин түгел инде, гөнаһ шомлыкка, вагы да юк, бар, кадал, дип, актык алтынны тоттырдым да пивога йибәрдем.

Башкорт бөтенләй айнып ук китте:

– Мин, – ди, – кеше малына тия торган имәсмен... Миңа, – ди, – һинең бер тиенең дә кәрәкмәй. Ун бутылка пива алам да калганы үзеңә кайта, – ди.

Ул бая берничә минут эчендә кайтып җиткән иде. Әле исә, ничектер, бик озаклады. Ярты сәгатькә якын вакыт үтте. Җомагыл һаман юк. Бер сәгать тә үтте, һаман юк – көтәбез, юк, көтәбез, юк.

Ирендерә, иснәтә башлады. Җылгыр кара кыз: “Карап керим әле”, – дип, әкрен генә шылды. Кайткач, чакыртырсыз дип, җырчымыз Хуҗабай да тайды.

Мин бераз хафалана башладым. Ләкин безнең белән берүзе калган Гөлбикә мине чыннан да гаҗәпләндерде. Ире чыгып югалды, шуның белән гүя аның өстеннән авыр йөк төште: ул аны авызга да алмый, кайда китте, тизрәк кайтса ярар иде, дими. Калган балны ялгызы эчеп, ниндидер бер мөлаем, йомшак моң белән акрын гына көйләвендә дәвам итә. Без аның белән берничә мәртәбә бик мәгънәле карашып алдык. Ул миңа дәрт бирәчәк рәвештә елмайды. Егет йөрәге сизмәсенме, егетнең гакылы, күңел дәртенә булышмасынмы?.. Мин бөтенләй чын төс белән иптәшемне: “Үз бәлаң, үзең йибәрдең, бар, хуҗаны эзләп кайт”, – дип чыгарып йибәрдем. Беләм, ул исерек һичнәрсә булдыра алмаячак. Эш анда түгел – ул чыксын да, без Гөлбикә белән икәү генә аулакта калыйк.

Юлдашым, абына-сөртенә чыгып китүгә, Гөлбикә белән сүз башлап, Җомагылның кайтмавыннан зарландым. Соңра, сүзне Гөлбикәнең үзенә китереп, аның тавышын мактадым, мондый матур, музыкалы тавышны һичкайда ишеткәнем юк иде, дидем. Ул җылы сүз, мәгънәле елмаю белән җавап бирде.

Ниләр булып үткәндер, ачык хәтерләмим, тик шул ядымда[1]: юлдашым кайтып, исерек кулы белән ишек тоткасын таба алмый азапланган вакыт Гөлбикә минем кочагымда, ул, башын минем күкрәгемә куеп, күз яшьле тавыш белән нидер сөйли иде.

Исерекнең ишек төбендә капшануын ишетүгә сикереп торды. Күз яшен сөртте дә, бөтенләй икенче хатын кыяфәте белән барып, ишек ачты.

---

[1] *Ядымда* – исемдә, хәтеремдә.

Юлдашым Җомагылны эзләмәгән, нитмәгән, кесәсендә егерме тиен акча бар икән, шуны бетергән, аның өстенә, билендәге каешын салып эчкән дә кайтып килгән. Аягына баса алмый, авызы чабата кебек җәелгән.

– Мммин... мммин... тегене... тттаптым... таптым... ул... ккайта... хәзер кайта!... – дип мыгырдый. Нидер сизенергә итә, бугай. Ансыз да колакларына җиткән авызын тагы җәя төшеп, миннән көләргә, күз кысып, бармак янарга көчләнә... Ләкин изелүе чигенә җиткән иде инде, җылы өйгә керү белән тагы йомшарып, шулай бераз мыгырдады да, идәндәге киезгә йөзтүбән капланып, хор... хор...йокыга китте.

– Күптән шулай кирәк иде сиңа, башкорт угылы башкорт! – дидем эчтән генә.

5

Мондый авылларда манарада ястүгә азан әйтелеп бетү белән, хәят туктый. Тиздән безнең өй дә тынды, ишек бикләнде, ут сүнде, юлдашым үлек кебек йоклый. Җан иясе – тик Гөлбикә дә мин генә калдык.

Минем гомерем бер-бер артлы тезелгән мәхрүмлекләр белән тулы. Мин – дөньяда кулындагы таягы белән аркасындагы капчыгыннан башка һичнәрсәсе булмаган юлчымын. Юлым караңгы, ярдәмчем юк. Күпләр балалык вакытын сагыналар. Ләкин мин сабый көннәремне уйласам, анда ачлык белән хурлыктан, түбәнсетелүдән башка һични күрмим.

Ата белмәдем, ана бәхетеннән мәхрүм яшәдем. Миңа күңелдән бер иркә сүз әйтүче булмады – гомерем шулай бер-бер артлы тезелгән мәхрүмлекләр, караңгы хурлыклар белән үтеп бара иде. Киләчәге дә үтәр, мин гүргә керер, ихтимал, шул авыр моңым, караңгы ялгызлыгым белән Тәңрегә барыр идем, ләкин язмыш мондый рәхимсезлегеннән үзе оялды булырга тиеш. Ниндидер бер мирза мине монда йибәрде, ниндидер бер көтелмәгән эш мине бу өйгә туры китерде – мин дә бүген кич авыр, кара кайгы хәятымның яңа ачылган нурлы, мәсгудиятле бер сәхифәсе каршында булдым.

Мин дә шул көтелмәгән эш аркасында бүгенге кичемне бер күргән, бер күрү белән сөйгән Гөлбикәмнең кочагында үткәрдем.

Рәхәт минутлар тиз кичәләр. Менә яңа гына ишекләр бикләнгән, яңа гына утлар сүндерелгән иде әле – ни арада төн үтеп тә киткән. Әнә тау артыннан таң сызылды, әнә якындагы әрәмәлекләрдә сандугач үзенең гыйшкын сайрый башлады. Сайра, былбыл, моңлан былбыл! Музыкаңда сөю дәрте ишетәм. Син сөясеңдер, таң матурлыгы йөрәгеңдәге гыйшкыңны уйгатадыр, мин моны хис итәм, чөнки үзем дә сөям, чөнки үзем дә йөрәгемнең төбеннән илаһи бер дәрт кузгалуын, шуның куәте белән хәят йөзе матур елмаю илә мине каршылаганын хис итәм.

Сандугач, ахры, ерагайды, инде акрын ишетелә. Таң нуры да күкнең шәрык ягын алып бетеп килә. Әнә манарадан мөәззиннең иртә намазына азаны да ишетелә башлады. Ләкин Гөлбикә кузгалырга теләми әле. Аның эссе күз яше белән чыланган яңаклары минем йөземә тиеп торганын хис иттегем хәлдә, мөлаем, ләкин эчке кайгылы тавышы белән дәвам иткән сүзен тыңлый идем:

– Ул, – ди, – һәркасан шулай йөри... Кулына ни керһә, шуны һатып эсә дә минем киемнәремне һала башлый... Бирмәсәм, кыйнай... Һинең аксаңны алып китәрен күңелем сизгәйне[1]... Бер төн булһа да, җаным тыныч кунһын дип, юри әйтмәнем[2]... Төн буена дәвам иткән зарларыннан мин Гөлбикәнең бөтен хәяты белән танышып чыктым. Аның күп җылкылы бай башкортның кызы булуы, авылларындагы бер хәлфәне сөюе, ләкин аталары, ул татар дип, аңа бирмәүләре, көчләп, җылатып, Карман бай дигән берәүгә яшь хатынлыкка сатулары, андагы көндәшлек хәяты, иренең эчеп кайтып кыйнавы, ахырдан аның урыстан эчеп кайткан вакыт, аты-арбасы белән тирән чокырга төшеп үлүе, аннан соң менә шул Җомагылга бирүләре, аның бар малын, йортын эчеп бетерүе, сугышуы, аны бер дә яратмавы – һәммәсе күз яшьле кызганыч сурәтләр белән минем күз алдымнан кичтеләр.

Ул сыер саварга чыкты. Мин үз урыныма барып яттым. Бу вакыт кояш күтәрелеп килә иде инде.

6

Иртә сәгать уннар чамасында уяндык. Без торганда Гөлбикәнең самавыры кайнаган, коймагы пешкән, комганына җылы су салынган, кайдандыр исле сабын белән ап-ак сөлге дә табып чыгарылган иде.

Күтәрелү белән аңар карадым.

Аһ, яшь йөрәк!..

Аның йөзендә яңа бер нур уйный, күзләре үткән кичнең шатлыгы белән ялтырый иде. Ялкау гына аның белән күңелле көлкеләр сөйләшә-сөйләшә җуындык та чәйгә утырдык. Ул мөлаем көлә, җиңел шатлана, ләкин боларның астында ниндидер бер җитди куәт хис кылына иде.

Аның чәе шундый шәп хәзерләнгән иде ки, минем юлдашым капкан саен: “Мондый сыйларны дүрт ел мәдрәсәдә ятып кайткач, сагынып көткән әниләреңдә генә күрергә мөмкин”, – дип тәкрар итә иде.

Чәй арасында Гөлбикә куе каймакны минем алдыма таба этәрә дә: “Ашаңыз, куәт кертә ул”, – ди. Үзе акрын гына елмая. Чәйдән соң казан асып, ит салды. Безне аш белән сыйламакчы, ләкин бу насыйп түгел икән.

Гөлбикә самавырын, ашъяулыгын алып бетеп кенә тора иде, ава-түнә

[1] *Башкортчадан*: сизгән иде.
[2] *Башкортчадан*: әйтмәдем.

ире Җомагыл кайтып керде.

Өстенә карар хәл юк, йөзе пычрак, күлмәгенең бер җиңе бөтенләй өзелеп төшкән, күзләре канлы, бүреге белән казакисы да юк. Мин сораштыра башлаган идем, җавап бирергә дә теләми, әйтерсең, берни булмаган, әйтерсең, ул безнең актык алтынны алып китмәгән.

Ахырдан беленде: ул кичә, капкадан чыгу белән, кемнәргәдер очраган да бергә-бергә шунда акчаны төгәлләгәннәр. Ул гына җитмәгәч, бүреге белән казаки да шунда җотылган. Җомагыл үткән төн хакында нидер шикләнә, бугай. Атап әйтмәсә дә, үзалдына сукрана башлады. “Акча бир”, – дип, хатынына бәйләнде. Бусы: “Юк, булмаганны кайдан алып бирим”, – ди.

Зур савыт белән әче әйрән сыеклатып эчте. Ахрысы, шул бераз хәл кертте булса кирәк, моңарчы сабыр гына торган башкортымыз кабәхәтләп сүгенергә, хатынына аяк тибеп кычкырырга тотынды. Без бераз уңгайсызрак хәлдә калдык. Яклашсаң, шөбһәне арттырасың, тик торырга җан түзми. Ләкин башкорт мәсьәләне тиз өзде. Мин ни булганын аңлап та бетә алмадым, Җомагыл йөгереп барып, Гөлбикәнең биленә төшеп торган зур кара чәч толымнары эченә тагылган яхшы чулпыларын өзеп алды. Шул секунд аны этәргәләп кертеп, мич алды як аш бүлмәсенә ябып, өстеннән йозак салды, каядыр кабалангандай ачкычын кесәсенә тыкты да, җил кебек очып, урамга таба йөгерде. Шуның белән вәссәлам, чулпылар да китте, Җомагыл да!!

Без шаша калдык. Йа Ходай, хатыным янында егетләр кунган дип, авыл картларын чакырырга китте, күрәсең, димез.

– Юк, – ди Гөлбикә, – аның, – ди, – картлар белән эше юк, минем һулпыларымны һатып эсәр дә мине кыйнарга тагы кайтыр, – ди. Үзе көлә:

– Атын урлаткач, капкасын бикләгән адәм шул булды инде, – ди.

7

Без китәргә җыендык, Гөлбикә шул өстеннән йозак белән бикләнгән бүлмәсенең ишеге ярыгыннан күз яшьле тавышы белән миңа, ни өчендер рәхмәт укыды. “Бу авылга килсәң, безгә керми китмә, хәлдә барынча кунак итәрбез”, – диде.

– Баш өсте, баш өсте!.. Мин сине мәңгегә онытмам, – дидем. Такта ярыгыннан исәнләшеп, кунак кылуы өчен күп изге теләкләр теләдек тә чыктык. Менә инде дөнья хәсрәтенең зурысы: кесәләрдә бер тиен акча юк. Ни белән кайтып җитәргә?

Ходай җан биргәнгә җүн бирә, диләр. Минем башка бик шәп бер фикер төште. Монда без торган шәһәрнең бер мәхдүме кымызда ята. Үзе бераз таныш та егет. Юлдашымны көчләгәндәй кылып, шуңа йибәрдем:

– Бар, – дим, – Самардан кайтып килә идек, төнлә акчабызны да, поезд билетымызны да алдырдык. Безгә кайтырлык акча бир, тиздән йибәрермез,

диң, – дим.

Юлдашым, гел мине җигәсең, дип сукранды, бераз җилкәсен кашыды, шулай булса да карышмады, мәхдүмгә китте. Менә, егетләр, дөньяда һичбер кайгырырга ярамый. Әбиләр, илдә чыпчык үлми, дигәннәр, чыннан, үлми: мәхдүм безгә дүртенче класс белән шәһәремезгә кайтып егылырлык акча биргән.

Эшләр пеште, безне генә көткән поезд да бар икән, утырдык та бояр булып юнәлдек.

8

Сәфәрнең бөтен мәсьүлияте[1] минем өсттә, юлдашка җил дә, яңгыр да булмаячак. Ул көй отарга килүемезне бөтенләй онытты, ахры. Аны телгә дә алмый. Ләкин мин хафалана башладым. Вагонга кереп утыру белән, мине яңа кайгы басты: ничек, дим, берәр нәрсә ота алганбызмы, юкмы?

Нидер бар кебек, ләкин бик ачык түгел, томанлы, бик мәшәкать белән чыга. Җитмәсә тагы, үземнең борыннан белгән озын көйләрем дә теге башкортныкы белән буталып беткән. Башта нык борчылган идем, ләкин тиз җуандым да. Ник юкка кайгырырга, дим, озын моңнарыбыз бар, шулардан оештыргалап, елга буе берәр көй тезәрбез дә – менә сиңа милли көйләремезнең асыллары булыр, дим.

Шәһәр вокзалында бер иптәш очрады, анарда акча бар икән. Юлдашымның башы бик авырый иде. Кәеф төзәтергә дип, егерме дүрт тиен алды да бакчалы пивнойга кердек. Ул эчә, мин мин җыр оту хәзинәмне актарам. Кая, синдә ни бар, дисәм, ул кул гына селкә – һичбер нәрсә хәтерләмим, миңа бар да төш кенә, ди.

Бакча һәйбәт. Тирәдәге агач яфраклары акрын искән җил белә ни-нәрсә хакындадыр җилфер-җилфер сөйләшәләр.

Шагыйрьләргә – илһам, пәйгамбәрләргә вәхи килә, диләр. Табигать безнең кебек җырчыларны да бондан бөтенләй мәхрүм итмәгән, ахры.

Зур агач күләгәсендә, яшел үлән өстендә ятып, үзалдыма, ниндидер, ят озын көйләрне моңлап, тукта... тукта... болайрак... менә... менә... эзгә төшә дип газапланган вакытымда хәзрәти Мөхәммәдкә вәхи белән килгән Җәбраилдәй[114+], минем хыял күгем ачылып, анда гаҗиб бер нур тулды, шул нур эчендә үзенең көләч йөзе, матур елмаюы белән минем вәхи фәрештәм Гөлбикә заһир булды[2].

Мин аны күрдем, күреп таныдым гына түгел, үткән кичәгә яңадан кайттым, аның айлы кичәдә ерак күктән килгәнгә охшаш гаҗиб моңын яңадан ишетәм, үземне белмәдем, аңа кушылып җырлап та йибәрдем һәм

---

[1] *Мәсьүлияте* – җаваплылыгы.

[2] *Заһир булды* – ачык күренде, килеп басты.

шул минут минем шөбһәләрем дә очты – минем эзләгәнем шул икәнен хис кылдым.

Кайтып җырлагач, мирзабыз шаша калды.

– Менә, – ди, – ничек икән ул чын “Ашказар”лар!! Безнең монда, ди, бер дә алай җырламыйлар, хезмәтеңезгә рәхмәт, ди.

Концерт тә бөтенләй икенче төс алды. Аңа катышучыларда дәрт артып, чын милли җан белән тырыша башладылар. Кемдер:

– Бу вакыйга татар көйләре тарихында зур урын тотарга тиеш, – дип йөри.

Икенче көн шәһәр урамнары безнең афишалар белән тулды. Анда, бик эре иттереп, шул сүзләр язылган иде: “Башкортстанның үзенә махсус кешеләр йибәреп, оста җырчыларымыздан чын “Ашказар”, асыл “Сакмар” көйләрен алдырдык...”

Билетлар җитмәде, халыкның күбе, урын булмаганнан, керә алмый мәхрүм калды.

Без дә, ахрысы, чын “Ашказар”ларны моңлаганбыздыр, халык дәрттән, ашкынудан кая басарын белми, чәчәкләрне җыеп бетәр хәл юк, тәбриктән – куллар, мактаудан колаклар талды.

Күп могтәбәрләр безне: “Милли көйләремезне чын юлга салучыларымыз”, – дип сәламлиләр. Кемнәрдер мал бүлгәндә безгә зуррак өлеш чыгарырга, тагы кайсыдыр кулларга күтәреп йөрергә димли башлаган иде. Мин һәммәсенә кул гына селкедем.

Шул мең төрле халык белән тулган олуг театрда, шул шау-шулар эчендә минем хыялымда Гөлбикәнең фаҗигый[1] матур йөзе, колагымда аның авыр моңлы музыкасы иде. Һәммә тәбрикләргә каршы:

– Юк, сез мине сәламләмәңез, мине тәбрик итмәңез!.. Сезгә мин җырламыйм, сезгә башкорт кызы булып тууга башка гөнаһысы булмаган фаҗигый язмышлы Гөлбикә моңлана, – диясем килә иде.

---

Ни, дим, сине ни белән җуатыйм, бәгърем Гөлбикә!!

Мин – бәхетсез бер җырчымын. Күңелем кайгылы, шуннандыр җырларым моңлы. Ана кем – белмәдем, бөтен гомеремә бер сүздән, дустанә бер караштан мәхрүм яшәдем. Шул авыр моңлы, бетмәс караңгы кайгы белән тулы гомеремдә сиңа очравым һәм синең самими иркәң, җылы кочагың эчендә үткәргән сәгатьләрем минем боек күңелемне күтәрде. Яралы йөрәгемә илаһи бер тамчы булды.

Башка ни диим, сине ни белән җуатыйм, бәгърем Гөлбикәм! Без икемез

[1] *Фаҗигый* – аянычлы, фаҗигале.

дә ходайның үги балалары!.. Безгә язмыш рәхимсез... Ерак күк безнең фөрьядларымызга колак салмый... Безнең караңгы күңелсез хәятымызда бергә үткәргән шул бер кичә мәңгелек нур, онытылмас җуаныч булып калсын!!”

## LXVI

Хикәя тәмам булып, әдәбият кичәсендә укырга ярарлыкмы, түгелме мәсьәләсе уртага куелу белән, иң элек Җиһангир аякка басты:

– Әсәрдә, – ди, – аз сүз белән безем хатыннарның авыр язмышы ачык күргәзелгән. Мин, әлбәттә, укылсын ягындамын.

Аңар каршы Нигъмәт казый күтәрелде:

– Хикәя бик озын. Сәхнәдән укылса, халыкны ялыктырачак. Бу – бер. Икенчедән, монда нindидер башкорт хатыны Мөхәммәд галәйһиссәламгә килмеш Җәбраил фәрештәгә охшатыла. Халыкта дингә җиңел карый башлау уйгата торган мондый мәгънәсезлекне үткәрү – безнең тарафтан җинаять булачак. Шулар белән бәрабәр хикәядә бик мөһим нокталар бар. 1) Көн-төн социализм, диләр, эшче белән капиталны сугыштыралар. Яшьләр арасында бу йогышлы чир булып китте. Моның бер мәгънәсез тәкълид һәм мода бәласе икәнен Сахибның хикәясе ачык күз алдына китерә. Монда башкорт сөйләнгән, ләкин йир сатуларын бер якка куйсак, башка һәммә сыйфатлары бөтен милләткә гомуми хәлләрдәндер. Бер башкорт түгел, мишәре, татары, алатыры, типтәре, кәчиме[1], нугае – болар бары да шул Җомагыл, Хуҗабай, Гөлбикәләрнең үзедер. Үзенең халкы шул Җомагыл дәрәҗәсендә булган бер егетнең, социализм дип, эшче дип, капитал дип лыгырдавы – иң әдәби тәгъбир кылганда, әлифба белмәгән ач мужикка Ницше фәлсәфәсе[115+], юнан трагедиясе хакында дәрес бирү белән бердер яки аннан кирерәк бер эштер... Урынымы, юкмы – йөрәгем әрнегән бер мәсьәлә булганга, моны әйтми үтә алмыйм; 2) әсәрдәге икенче нокта: башкорт кардәшләремезнең ата-бабаларыннан килгән йирләреннән аерылулары, алар кулыннан алынган табигый хәзинәдән кайдандыр агылган хохолларның сарайлар салдыруы, башкортның ач калуы мәсьәләседер. Милләтемезнең башына килгән бу зур афәт бер минут безнең хәтердән чыгарга тиеш түгел, шуның өчен мин бу әсәр укылсын, дим. Ләкин бөтен көенә түгел – башкорт хатынын Җәбраилгә охшаткан нindидер әхлак бозгыч рәвештә булган тасвирлар ташлансын да йир сату маддәсе тагы бераз киңәйтелсен. Ул вакыт хикәя зур дәрес булыр...

Госман даим утырмады, керә-чыга йөрде, шунлыктан хикәяне бөтенләй ишетмәгән иде.

[1] Касыйм татарлары турында сүз бара.

Нигъмәт казый сүзен бетерүгә, ул, бик аз гына калка төшеп:

– Хикәянең әдәбият кичәсенә яравы-ярамавы ягына керешмим. Тик Нигъмәт иптәшнең фикеренә каршы бирәр генә сүзем бар, – дип башлап, йир, эшче, милләтләр, халыкның наданлыгы, эчүе хакында байтак сөйләп, шул рәвеш тәмам итте:

– Монда социалистлар, һич булмаса, шулай уйларга тырышучы егетләр җыелган, болар арасыннан беренең бик аз гына да тартынмыйча "башкорт кардәшләремез", "әллә нинди хохол килмешәкләр" дигән кебек сүзләрне әйтә алуы – мине чыннан гаҗәпләндерде. Башкорт йиреннән аерыла икән – аерылсын, аерылырга тиеш. Тегендә, Орловский губернада Иван белән Василийның унбиш җанлы җәмәгатенә бер колач йире юк. Ә монда үз яланының иге-чиге кайда икәнен дә белмәгән башкорт, агач күләгәсендә кымыз эчеп, дүрт хатын асрап, хайванланып яши, башкортмы, хохолмы – без моны белмибез... Гадаләт[1] моны танымый. Тигезлекнең, гадаләтнең сүзе бер: кем ач, кем эшли – йир шуныкы...

Күпләр Госманга кул чапты. Ул бетүгә, тагы берничә яктан сүз башланган иде, Рауза туташның нидер әйтергә теләгәнен күргәч, башкалар һәммәсе туктады. Туташ урыныннан бик аз күтәрелде, күкрәге белән партага ята төште дә нидәндер җирәнгәнне белдерер тавыш белән:

– Сез әллә кая кереп киттеңез!.. Җәбраилме, башкортмы, хохолмы – боларның беренә дә барасы юк. Сахиб иптәш ачуланмасын, иптәш булганга, мин уемны яшермим: аның хикәясе оста язылган, ну шундый урыннар бар, анда мин кызардым. Нинди эчүләр, нинди ямьсез утырышлар, тагы ниндидер исерек хатыннар, гомерләрендә бер күргән ирнең кочагына атылулар... Боларны укыганда, мин кызардым. Мондый нәрсә укылса, мин катнаша алмыйм, – диде.

Боңар каршы Сахиб үзе күтәрелгән иде, баштан бирле һичбер мәртәбә авызын ачмаган Вәли башкортның нидер әйтмәк булып урыныннан торганын күргәч, һәммәнең күзе аңа юнәлде, Сахиб кире утырды.

Вәли башта каушады, тавышы җүнләп чыкмый, сүзләре бутала, аңлашылмый иде. Шулай да берничә җөмләдән соң, табигыйләшеп китте:

– Сез, – ди, – монда юкка талашасыз... Сахиб әфәнде ялганламаган, ул барын да күргәнчә язган. Аның белән Ямanташка көй отарга баручы башкорт шәкерте мин идем... Ул ялганламаган, йир сатуы да, Җомагыл Гөлбикәсе дә – бары да бар, тик ул никтер минем исемне генә әйтеп язмаган, – ди.

Вәлинең бу игъланы һәммәгә ялангач тәнгә бозлы су койган кебек тәэсир итте. Һәммәсе аның өчен кызардылар.

---

[1] *Гадаләт* – турылык, гаделлек.

Һичкем нә көләргә, нә бер сүз әйтергә җай тапмаган хәлгә килде. Бары Урманов җитди итәргә, көлмәскә көчләнгән тавыш белән бу гомуми уңайсызлыкны арадан алды:

– Вәли иптәш, – диде, – ул шулай дөрестер, анда йир сатуы да, Җомагыл Гөлбикәсе дә бардыр. Таштамакка Сахиб белән баручы да сез булгансыздыр, ләкин мәсьәлә анда түгел. Без бу хикәя әдәбият кичәсе өчен озынрак булмасмы, димез, сүз менә шул хакта иде.

Урманов бетәр-бетмәс, Вәли башкорт яңадан торды. Йа Ходай, инде тагы нинди уңайсызлык чыгара дип, ярым хәйрат, ярым кызыксыну белән һәммәнең күзе аңа кадалды. Ләкин ул бу юлы зарарлы сүз ычкындырмады:

– Ә, алаймы... Алай булса, ярый... – диде дә сүзеннән тукталды. Ул, гүя, урынына утыруны оныткан иде, сүзен әйтеп байтак вакыт үткәч кенә, исенә килеп, кире чүкте.

Аның мәсьәләсе бетүгә, яңадан туташның сүзенә кайттылар. Ул, ахры, яхшы тәэсир калдырган. Иң элек хикәянең мөхәррире Сахиб, торып:

– Мин Рауза туташның сүзен хаклы таптым. Чынлап та, сәхнәдән укыганда, мондый нәрсәнең халык колагына ятрак тоелу ихтималы бар, – диде.

Башкалар да шуңа кушылдылар.

## LXVII

Актык нәрсә гимназист Тангатаровныкы иде. “Башкорт кызы Гөлбикә” хакында сүз бетү белән, ул аякка калыкты да акрын, эчке, бераз хисле тавыш белән укый башлады...

“Алдымда ике тормыш...

Менә сезгә шау-шулы, бетмәс-төгәнмәс хәзинәле бай шәһәр... Әнә берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе олуг сарайлар... Әнә алтын-көмешләр, гәүһәр-якутлар, күз камаштырып торган ефәк атласлар белән тулы магазиннар!!

Уйлаңыз: боларны кем эшли, кем тудыра?!

Ә болардан кем файдалана?! ...”

Шуннан соң ул үзенең бөлгән дворяннар (мирзалар)дан беренең углы булганлыгын, заманында бабалары үзләренең байлыгы, меңнәрчә коллары, иге-чиге күренмәгән йир-сулары, урманнары белән тирә-якта зур шөһрәт тотканлыгын, болар халык кашында тирә-якның падишаһысы саналганлыгын, кыш көне пайтәхеттә үткәргән мирза, яз бу йиргә кайткач, авыл халкы аңа әллә кайлардан бүрек алып килеп, аз бер йомыш өчен сәҗдә кылганлыгын, болар бөлеп йир-сулары китсә дә, ул халыкка бирелмичә,

эшче-крәстиянне остарак, хәзерге заманчарак талый торган икенче кулларга гына күчкәнлеген, әле дә кайдадыр рәхәт, сәгадәттә, алтын-көмеш, уйнаш, отыш эчендә яши торган берничә ак кул өчен бөтен тирә-як халкы мәңге эшләп, мәңге ач-ялангач, мәңге кол, караңгы яшәгәнлеген, бу хәл бөтен Русиядә, киңрәк алсак, бөтен дөньяда шулай барганлыгын, бу газапка, бу коллыкка артык түзәргә такате беткән халык хәзер баш күтәргәнлеген, дәрьяларча каннар түгеп, меңнәр, йөз меңнәрчә корбаннар биреп, эшче-крәстиян халык, шул богаулардан котылу өчен, залимнәр белән көрәшкәнен тасвир итеп килә-килә дә, революция дигәнемез менә шулдыр: халыкның ачуыдыр, колның тимер богавын өзәр өчен җан ачуы белән омтылуыдыр, дип бетерә.

Тангатаров укып бетәр-бетмәс, эчке бүлмәнең ишеге ачылды да, кечкенә бер кыз чыгып, Госманның колагына нидер әйтте. Ахрысы, сүз бик кирәкле нәрсә хакында булгандыр, Госман, ашыгып, теге як бүлмәгә кереп китте. Рәислекне Җиһангирга биреп, Давыд Урманов та аның артыннан сызды.

Бу озын хикәяләр, әдәби парчалар Раузаны бик туйдырганнар, китәргә күптән теләсә дә, килештермәгәнгә генә һаман утыра иде. Ике иптәше кузгалгач, түзмәде, мөмкин кадәрле сиздермәскә тырышып, акрын гына теге бүлмәгә таба шуды.

Чыкса, ни күрсен!

Госманның ярым караңгы кабинетында, тирән креслога чума төшеп, үзенең зур трубкасын кабып, Булатов утыра.

Аның сөргенгә йибәрелүенә байтак вакыт үтсә дә, моңарчы һичбер хәбәр-хәтәр юк, иптәшләре, качарга теләп тә, эләгеп үтерелмәгән булса ярар иде, дип, авыр хафадалар иде. Ә ул, хәбәре генә түгел, үзе кайтып килгән.

Бер карауда һич тә танырлык түгел: аягында озын чобар киез итек, өстендә билле тун, башында тирән татар бүреге. Кулында яхшы күн бияләйләр, әйтерсең, коеп куйган авыл бае, аның да бераз ачылганы, заманачарак булганы!! Киемендә генә түгел, йөзендә, бөтен торышында бераз гына мәдәниятләшкән авыл кулагының төсе бар!

Чыгып күрешеп, беренче шатлыкларны, беренче тәбрикләрне әйтешүгә, ирләр эш турында, нәүбәттәге мәсьәләләр турында сөйләшә башладылар. Булатов үзенең даими елмаюы, саф, акрын, тигез тавышы белән берничә сүздә ничек качуын сөйләп бирде.

Рауза шатлыгыннан ни эшләргә белми иде. Ходаем, бу нинди бәхет, нинди бәхет, сез тагы безнең арада, тагы бергә эшлимез, дип, кат-кат сөйләнеп, очынып, бик озак егетнең кулларын йибәрми торды. Кочаклап үбәргә бик теләсә дә, батырлыгы җитмәде. Шулай да Булатовның креслосы

читенә утырып, бер кулын аның җилкәсенә салды, икенчесе белән егетнең яңа гына күпереп үсеп килгән түгәрәк матур, кара сакалын яратып, сөеп, туктаусыз сыйпап торудан үзен тыя алмады. Электән сакал-мыегын бөтенләй кырып йөргән матур йөз хәзер кара ефәк сакал белән ничектер тагы да матуррак, сөйкемлерәк күренә иде. Туташ боны әйтергә теләсә дә, Давыд белән Госманның үз эчләреннән балалык дип көлүләрен уйлап, телен тешләде.

Кайдандыр сизенеп, Җиһангир, Нигъмәт казый, приказчик Фәхри, җырчы Сахиб та килеп керделәр.

Иптәшләрнең һәммәсенең йөзендә шатлык балкый иде.

Госманнан башкаларның күбе эсер булсалар да, Булат татар социал–демократлары эченнән һәр ике гөруһның[1] бер дәрәҗәдә мәхәббәт казанган көчле, ныклы егетләреннән санала, киләчәктә анарга зур өмид баглыйлар иде.

Бүген Госманда, иртәгә Давыдта, аннан соң Абдулда куначак булды. Кирәк-ярагына тотарга бераз акчасы да бар икән әле. Бик кирәк булса, менә боларны сата башларга мөмкин, дип, өстендәге киемнәренә күрсәтте.

Булатны күреп туймасалар да, анардан аерыласылары килмәсә дә, залдагылар сизенә башлар дип, егетләр берә-берәм теге якка чыктылар. Иң арттан чыгып барган Рауза, ишеккә җиткәч, кире килде дә, күзләренә җотылып карап, Булатның култыгыннан алды:

– Минем анакай имениегә китә. Сез дә кайттыңыз... Шул ике бәхеттән файдаланып, мин үземдә җыелыш ясарга уйлыйм. Ике якның да: эздикларның[2] да[116+], эсерларның[117+] да активный работникларын җыймакчы булам...

Булат туташның күзләренә шөбһә белән карады. Һәр ике гөруһның телдә революция дип, сугыш, тартыш дип сөйләп тә, гамәлдә шул зыялылар, укучылар тирәсеннән күп чыга алмаулары, сүз белән, шәһәрдә митинг, түгәрәкләр белән күп вакыт үткәрүләре күптән үк аның эчен пошыралар иде. Раузаның сүзен тагы шундый бер “аңлашу” дип карады. Ике гөруһның, бигрәк тә аларның мәсьүл[3] эшләүчеләрен чакыру җыелышның нинди булачагын бер дәрәҗәгә кадәр алдан белгертеп торалар иде. Шулай да кырт өзмәде:

– Җыелыш ни турыда?

Туташ, бераз иркәләнеп, башын чак кына кыйшайтып, егетнең күзләренә җотылып елмайды:

– Анысы хәзергә секрет! Баргач күрерсез!!

---

[1] *Гөруһның* – төркемнең.
[2] *Дөресе*: эсдекларның – социал-демократларның.
[3] *Мәсьүл* – җаваплы.

Егет вәгъдә бирде. Давыд яисә Госман аркылы көнен, сәгатен хәбәр итәрсез, диде.

---

Булатовның кайтып керүе репетициянең бөтен мәгънәсен югалтты. Госман, Давыд, Рауза үз эчләреннән буңа тел сатып утыру дип карадылар. Инде кирәге эшләнгән дә иде, бугай. Кичәне башкару өчен, өч кешелек комиссия төзелде, аңа җырчы Сахиб, приказчик Фәхри, гимназист Тангатаров сайланды.

Мәҗлес ябылды, тарала башладылар.

Реалист Акчулпанов камил тәрбияле бер кавалер сыйфаты белән, Раузага килеп, озатырга гарыз кылган иде. Туташ эченнән чирканып куйды, фи...балалык... дип, чак әйтеп ташламады. Ләкин тыштан белдермәде, егет өстенә югарыданрак карап:

– Сез, иптәш, андый буржуазный предрассудкаларны һаман ташлап җитә алмыйсызмыни әле! – дип, бераз мәсхәрәле, ләкин матур елмайды да: “Рәхмәт, минем Давыдта эшем бар, аны көтеп бераз калам”, – диде.

Бу – Акчулпановны чәнечте. Ул үз эченнән: “Бусы артык кылану инде! Имеш, буржуазный предрассудок!! Социалист булгач та, грубый мужикка әйләнү кирәк түгел икәнен ул кыз аңламыймы”, – дип уйланды.

Аның Раузада күңеле бар, Раузаның зифа буе, алга бераз бәреп торган күкрәге, үбешү өчен яратылган кебек җазибәле[1] алсу иреннәре егетне тарталар. Эшчеләр, крәстияннәр яки шулар эченнән яңа гына чыккан бу “тәрбиясез” егетләр – социалистлар арасында туташ аңа бердәнбер сөйләшерлек, үз итәрлек кеше булып күренә, аңа якынлашасы килә иде.

Раузаның болай кырт кисүе аның горурына кагылды. Арада башка берәр туташ булса, ул Раузага ничек җавап кайтарырга белер иде. Ләкин юк бит! Тангатаровны барып култыклады да бергә кайтырга чыктылар.

Бусы тагы шул приказчикларны, шәкертләрне ияртеп, кочаклашып, юл буена шулар белән сайрашып бара.

Фикерләре, юллары, идеаллары бер. Акчулпанов үзен җаны, йөрәге белән Николай истибдадының[118+] гына түгел, бөтен капитализмның, буржуазиянең дошманы саный. Революция кермәстән күп еллар элек үк, реальныйның бишенче сыйныфында чагыннан башлап, ул Марксны, яшерен әдәбиятны укый, буның өчен әллә ничаклы шелтә, җәза булачагын белсә дә, үзенә иптәшләр – фикердәшләр арттыра иде. 904 нче ел кергәнче үк, ул инде үзе төзегән сәяси түгәрәктә рәис иде. Әле хәзер дә болар арасында сәяси, иктисадый мәсьәләләрдә үзенең гыйльми хәзерлеге белән бу халыкның

---

[1] *Җазибәле* – үзенә тартып тора торган.

күбеннән югары тора.

Ник соң алай булгач, шушы йолкыш Тангатаров чаклы да болар арасында үз кешесе булып китә алмый? Әнә кара, керләнеп беткән фәкыйрь шәкертләрне кочаклап алган да рәхәтләнеп серләшеп бара. Әйтерсең, алар аның гомерлек юлдашлары!

Ә мин ник шулай була алмыйм?

Реалист бер сүз дәшмәде. Тангатаровның шәкертләр, приказчиклар белән шаулашып, бер чынлап, бер уйнап, нәрсә сөйләшкәннәрен тыңлап, авыр уйда барды:

– Ник соң мин шулай була алмыйм?

## LXVIII

Тангатаров Акчулпановны, тагы бер көтү шәкертләр белән приказчикларны алып чыгып киткәч, зал бушап ук калды. Алардан бераз соң Нигъмәт казый, җырчы Сахиб, Дашкин, Җиһангир үзләренә бер төркем булып киттеләр. Алар артыннан приказчик Фәхри көзгедә бераз ипләнде, галстукларын төзәтте дә, көмеш портсигарын ачып, калганнарны яхшы тәмәке белән сыйлап чыгарга җыенды. Габдрахман, Давыд Урмановка килеп:

– Нәфисәгә сине алып килермен, дигән идем, ул самавыр куеп көтәдер, әйдә безгә кереп чыгыйк! – дигән иде, егет авыр ярасына чәнчелгән кеше кебек бераз чигенде дә гафу үтенде:

– Рәхмәт, бүген эшем бар, башка бер вакыт керермен, – диде.

Фәхри бик тәкәллефләнеп[1] исәнләште дә Габдрахман белән чыгып китте.

Рауза Урмановка килде:

– Төн бик караңгы, мине бераз озатыгыз!

Булат янына кереп, берничә минут утырдылар да кайтырга чыктылар.

Төн чынлап та бик караңгы иде. Фонарьлар никтер җүнләп янмый, урамнарда кеше юк. Тик ара-тирә почмакларда үзләренең калын киемнәренә төренгән стражниклар күренгәли, сирәк-сирәк казачийлар, атларын җилдереп, яшен кебек чабып үтеп киткәлиләр.

Рауза, урамга чыгу белән, Давыдка кулын салды:

– Бик арыдым... Әллә ни дип, шулчаклы озакка сузасыз!

Бүген туташның сүзендә, тавышында, үзен тотуында ниндидер бер аерым якынлык сизелә иде. Байтак вакыт сүзсез бардылар. Кыз шелтә катыш иркәләнү белән:

– Ходаем, бер дә генә тота белмисез инде! – диде дә егетнең култыгына

---

[1]*Тәкәллефләнеп* – ясалма, кыланып.

ипләбрәк керде.

Ул нидер әйтергә тели, ләкин кайдан башларга белми торган кебек күренә иде.

Гимназиядәге, мәдрәсәдәге приказчиклар арасындагы сәяси түгәрәкләрен сөйләде. Шәкертләрнең һәрбер сүзеңне авызлары белән җотып алырдай бер ихлас белән тыңлауларын, аз бер вакыт эчендә әллә ничаклы нәрсә белүләрен, алар белән эшләү бик артык күңелле икәнен хикәя кылды.

Шәһәрнең яңа гайбәтләреннән дә хәбәре бар икән. Кадыйр байның гаиләсе җәһәннәмгә әйләнгән, ди. Аның углы Йосыфҗаннан телеграм килгән. Одессадан Истанбулга бара торган корабтан йибәргән, ди.

– Ач калырмын, юк хакка эшли торган көнлекче булырмын, шунда да байлык дип, синең коллыгыңа кайтмам, дип язган, ди. Һаҗәр хакындагы гайбәт тә бөтен шәһәрне кайната икән. Бу ике фаҗига Кадыйр байны түшәккә егып салган, ди. Хәзер ул беркая чыкмый, һичкемне кабул итми, бикләнеп ята, ди. Мин маңлай тирем белән миллионнар җыйдым, боның өчен кеше дә рәнҗеткәнмендер, ә алар шул майга чыдамыйлар. Эт симерсә, иясен тешли дигәннәре шул, күрәсең, дип әйтә, ди. Азрак акылына да зыян килгән, бугай, дип әйтәләр, ди.

Урманов боларның фәлсәфәсен ачты:

– Шулай булмый хәл юк инде... Кадыйр бай капитал көче белән дөньяны кол иткән – мулласын, шәкертен, приказчигын, хатынын, баласын үз кәефенә табындырган иде. Революция һәммәсен юкка чыгарды. Хәзер бусы да баш ими... Бары да сугыш ача... Монда Кадыйр бай авырмый, ул җигелми, бөтен иске тормыш җимерелә... Яшь, яңа хәят азатлык ала, хакимият эсти...

Сүз белән кайтып җиткәннәрен тоймый да калдылар. Кечек, матур, җыйнак өйнең капкасына килеп туктагач, туташ егетне өйләренә керергә чакырды:

– Мин, ди, чыгып китәм дә көн буена югалам... Анакай мин кайткан саен борчыла... Минем яңа иптәшләремне әллә нинди җыртыкчылар, юлбасарлар, дип уйлыймы... Бер кереп чыгар идең, – ди...

Урманов кырт кисте:

– Бик-бик рәхмәт. Ләкин хәзер мөмкин түгел, мине көтәләр!

Рауза аптырый калды... Күзләре зурайды, ашыгып, Двыдка килеп тотынды:

– Кем көтә?.. Нинди эшкә? Әллә берәр хәл бармы?

Егет көлеп җавап бирде:

– Юк, курыкмаңыз, сез уйлаган түгел, бөтенләй башка эш. Авылда минем бик дуст әнкәм белән бик артык сөекле сеңелем Зәйнәп бар. Сеңелем кияүгә чыккан. Мине туйга бик чакырса да, кайта алмаган идем. Кичә генә

анардан хат алдым, үпкәләп яза, безне оныттың, туган итмәдең, кеше арасында йөземез кызарды, өзелеп көткән идем, ди. Миңа казлар, казылыклар, чәкчәкләр, тагы әллә ниләр йибәргән. Абдулла иптәштә бүген шуларны җыелып ашыймыз... Ачлыктан өзелгәннәрне генә чакырдым. Иптәшләр, анда җыелып, мине көтәләрдер. Ашыгуым шуның өчен, – диде.

Егетнең сүзе бетәр-бетмәс, Рауза кечкенә капканы шалтыратып япты да кире чыкты. Ярым русча, ярым татарча кызып шелтәләргә тотынды:

– Үпкәлим, бик нык үпкәлим... Кайчаннан бирле бергә эшлимез, телдә иптәш, дисез, карасаң, мин сезгә бөтенләй чит кеше икәнмен, башкалар булган йиргә миңа ник барырга ярамый? Моны ничек аңларга, бу ышанумы?

Давыд, якын ук килеп, ике кулы белән кызның дулкынланып торган гәүдәсен кочаклап алды:

– Акыллым, иркәм, алай дисәң, әйдә киттек! Сине чакырмау чит күрүдән түгел, бөтенләй башка сәбәптән иде!

– Нәрсәдән?

Артык күп сөйләргә ирек бирмичә, биленнән кочаклаган көенчә, үзенең гозерен аңлата башлады:

– Хәтерегездәме, Думага сайлау, кайсы партияләр белән катнашу хакында ясалган зур җыелышта бер «исерек» татар эшчесе кереп, бик зур скандал кузгаткан иде, тыныч йир, дип, без бүген шуның өендә җыелмак булдык. Ул хәзер безнең бик якын иптәш, бик нык эшләүчеләрдән... Ләкин аның өе каланың читендә... Кечкенә, пычрак, сасы булыр... Сезне чакырсак, мине кая алып килгәнсез дип шелтәләрсез, сезгә күңелсез булыр, дип уйладым...

Рауза чын ачу, чын шелтә белән егетнең сүзен кисте:

– Йа Ходай! Сез мине һаман ак кул аристократка карыйсызмыни әле!! Мин иптәшләр белән булгач, теләсә кая да барам... Сезгә яраган йир миңа ник ярамый, ди!! Әйдә киттек!!

---

Рауза юл буена үпкә катыш шелтә белән, бераз әрнүле иркә белән сөйләп барды. Үзе барган саен Давыдка кысыла, җылыша бара иде.

Сүз сүзне тартты, теләмәстән, гүя, үзеннән-үзе артык эчкә киттеләр. Һәр икесе өчен дә көтелмәгән рәвештә бер-беренең йөрәкләрен ачып ташладылар.

Рауза үзенә үзе хуҗалыгы, ирләргә йөрәгендә ни булганын белдермәве белән эченнән бераз горурланып йөри торган табигатьләрдән иде. Нидер булды. Бүген хуҗалыгын югалтты:

– Мин, ди, иптәшләрнең һәммәсенә күңелемдә зур урын бирәм. Безнең партиядән булмаса да, Зариф Булатов миңа татар пролетариат гаскәрен

башкалар белән берләштереп, дошманга каршы сугышка алып баручы генерал кебек күренә. Качкын Хәбиб Мансуров, ул инде олуг бер каһарман... Үзе ач, ялангач, шулай да һаман көрәшә... Мин аны тимердән ясалгандыр, дип уйлыйм... Анардан азрак куркам, шулай да яратам... Атасының байлыгын, рәхәтен ташлап качкач, Йосыфҗан да минем кашымда күтәрелде... Тангатаров бичара революция өчен гимназиясеннән куылды, стипендиясеннән мәхрүм калды... Өстенә карар хәл юк – җиңнәре, тезләре җыртылып беткән... Шулай да һаман чаба... Нигъмәт казый дигәнеңез фикере белән безгә каршы булса да, ул да миңа бик охшый, әйтерсең, җил-давылга бирешми, дулкыннарга җиңелми утырган таш скала; шулай нык тора, шундый көчле күренә... Барысын да яратам... Ләкин син син инде, бөтенләй башка!..

Туташ, әйтимме, юкмы дип, берничә секунд уйланып торды да кинәт карарга килде, егеткә тагы сыена төшеп, үзе бөтенләй башка кеше хакында сөйләгәндәй, ләкин эчке хисле тавыш белән:

– Син инде минем өчен революционер гына түгел... Как человек, как личность та син миңа бик, бик, бик якынсың!.. Беләсең бит, безнең среданы: каннан, тәрбиядән шулай урынлашкан инде, нинди генә бер кругка барып керсәң дә, күңелең берәүне эзли башлый, бер ир иптәшне, пошлый выражение белән әйтсәң, бер кавалерны тапмый тынычлана алмый... Акчулпанов типлары хәзер минем ачуымны гына китерәләр... Аңлыйсың бит мине?

Давыд Урманов тиз җавап бирмәде:

– Аңлыйм, бик артык аңлыйм, иркәм, бу хакта сүз кузгалуын көтә идем, ләкин кузгатмаска тырыша идем. Бер башлангач әйтми үтә алмам инде, ахры. Күптән сизенәсеңдер, Рауза, мин сиңа каршы, синең алдыңда җиңелмәс өчен, үзем белән, йөрәгем белән байтактан бирле көрәшеп киләм. Акылым, фикерем белән революционермын, шул юлда эшлим... Ләкин йөрәгемдә революциягә башка кайбер нәрсәләр калган әле. Мин сине күптән уйлыйм, үзеңне һәрвакыт күрәсем килә, күрмәсәм сагынам... Ләкин үземне боның өчен шелтәлим... Беләсең бит, Йосыфҗан дөньясын ташлады. Баязид карый көн-төн бомба, браунинг, җәһәннәм машинасы, яшерен басмаханә хәзерләү, шулар белән бөтен дөньяга каршы сугыш ачу, туган атасы шул искечеләрнең зур терәге булганга, иң элек аны үтерү планнары белән саташа... Дөньяда шуңа башка нәрсә күрми... Хатын-кыз дигәнең аның өчен бөтенләй, бөтенләй юк... Булат татар халкын пролетариат белән крәстиян диктатурасы фикеренә хәзерләү, шул юлда оештыру белән яна... Качкын Хәбибне әйтәсе дә юк, аның өчен дөньяда тик бер нәрсә – революция бар. Аның өе, сүзе, тормышы бөтенләй шуңа багышланган... Һәммә нәрсәгә шул ноктадан карый, шуның

буенча үлчи... Хатын-кыз, дустлык, кардәшлек – һәммәсе шуңа корбан... Әмма менә мин шул дәрәҗәгә җитә алмыйм... Сине күптән яратсам да, йөрәгемдә син булсаң да, үзеңә әйтмәдем, әйтергә теләмәвем менә шуның өчен, җаннан, йөрәктән революциягә башка һәммә нәрсәне куып чыгару өчен иде...

Алар килеп җиттеләр.

Рауза бераз күтәрелгән, үзендә җитдият арткан кебек күренә иде. Капканы атлап эчкә керәм дигәндә:

– Тукта! – диде.

Егет туктап, туташның йөзенә карады. Рауза акрын, салмак рәвештә перчаткасын салды. Бик гади кузгалып, уң кулы белән Давыдның муеныннан үрелеп кочаклады, бик аз гына да тартынмыйча, шикләнмичә, егетнең йөзен үзенә тартыйм дигән секундта Давыд, көчле куллары белән туташны кочаклап, тулы алсу ялкынлы иреннәрен суырып алды. Берничә секунд дөньядан югалдылар.

Иң элек Рауза уйганды. Кинәт, кире чигенеп, русча:

– Башы, ахыры шул булсын! – диде.

Егет тагы бер мәртәбә кочаклап, озак ялкынлы үпте дә кызның сүзләрен тәкрар итте:

– Башы, ахыры шул булсын!

Рауза ашыгыч, шат, җиңел адым белән капкадан кереп, Давыдтан кайсы ишеккә барырга икәнен сорамыйча ук, үз сизенүе белән йортның эчендә йирдән бик аз гына күтәрелеп торган кечкенә тәрәзәнең актысына таба китте. Давыд аны куып тотты да, култыклап, караңгы тар җимерек баскычлардан җайлап, акрынлап, Абдулның квартирына – каядыр базга алып төште.

Керсәләр аптырап калдылар, анда Качкын Хәбиб утыра.

Рауза аны күрүгә, русча:

– Йа Ходай! Мин кемне күрәм! Сез ничек биредә? – дип кычкырып йибәрде дә Габдәһ абзыйдан, аптырап карап каткан Заһидә җиңидән*, әллә ничаклы иптәшләреннән оялуны аз гына да хәтеренә китермичә атылып барып, Хәбибне кочаклап, йөзеннән, маңлаеннан, күзләреннән кат-кат үбәргә тотынды.

Һәммә кешеләр аптырады. Качкын Хәбиб, туташны ярым кочаклап, шат, уенчак, көлкеле тавыш белән:

– Рауза, Рауза иптәш, сез мине буып үтерәсез, хәлдән тайдырасыз, – ди иде.

* Алды геройларның исеме Габдулла абзый һәм Хәдичә җиңги дип бирелгән.

Кочагыннан чыгарып үбүеннән туктагач, берничә минут кулларыннан йибәрмичә, күзенә җотылып карап торды:

– Тагы бер карыйм, яңлыш түгелме, бу сезме?..

Хәбиб Мансуров гади вакытта тупасрак мөгамәләле, каты сүзле кешеләрдән булса да, вакыты белән гаҗиб бер мөлаемлык, якынлык та күрсәтә белә иде. Авыр, караңгы ялгыз тормышында якын иптәшләр белән рәхәтләнеп утырган чаклары шундыйрак була иде.

Рауза бераз айнып үзенә килгәч, аңа бирер өчен урыныннан торды, киемен салырга ярдәмләште, аны элеп куйгач, туташны үз урынына утыртты да, болай яхшы шат каршы алуы өчен, кулын кысып рәхмәт укыды. Бөтен гомере революциягә багышланган кешеләр өчен якын дустлар белән очрашып, бергә үткәргән сәгатьләр – хәятның иң матур якты минутларыннан булалар, дип сөйләп алды.

Рауза, шатлыгыннан айнып җиткәч, иң элек, мине алып килмәскә теләп, шундый зур бәхеттән мәхрүм итә яздыңыз, дип, Давыдка бәйләнде. Һәммә иптәшләр җыела торган бер йиргә мине чакырмаган, дип, аның өстеннән иптәшләргә, бигрәк тә Хәбиб Мансуровка шикаять кылды. Аннан соң, урыныннан торып, ялкынлы учак янында тирләп-пешеп нидер хәзерләмәктә булган Заһидә җиңи янына барып, гафу үтенде.

– Хәбиб – безнең каһарман иптәшемез... Аны күргәч, мин дөньяны оныттым, сезнең белән исәнләшә дә алмадым, – диде.

Заһидә җиңи бераз тартына төшә иде, шулай да фикерен тулы итеп әйтә алды:

– Сөйләмә инде, туташ, – ди, – аны күргәч, үзем дә акылымнан шаша яздым... Теге Баязид карый дигән иптәшеңезне тотып алып киткәндә мин булган идем. Алар җырткыч кебек кыланалар бит. Хәбиб ябылганын ишеткәч, картым белән бергә балалар кебек җылаштык.

Качкын Хәбиб урыныннан торды, эчкәрәк баткан усал соры күзенә, бик аз гына шадра катыш йөзенә җиңел нур, бераз йомшак төс чыкты, рәхмәтле тавыш белән:

– Заһидә җиңи, шундый хәл инде ул. Ябылу, сөрелү, атылу – ревалюционер өчен гади нәрсәләр. Аңа ис китәргә, артык борчылырга кирәк түгел...

Җиңи туктамады, күзеннән яшен сөртеп:

– Сез шулай дисез дә бит, безгә, монда калганнарга бик авыр шул. Элек андый ябуларны ишетсәм, юкка фетнә чыгарып йөрмәсеннәр, бик яхшы булган, дип кенә куя идем... Хәзер инде аларның ни өчен йөргәннәрен аңлый башладым. Һәрберен ишеткән саен, үз балаңны алып киткән кебек була...

Сүз икенчегә күчте. Заһидә җиңи, Раузага карап, гафу үтенгәндәй

булды:

– Ярлылыгымыз зур... Фатирымыз да бик начар инде, иптәшләр өйрәнгән кешеләр, алар гаеп итмәсләр. Сез килерне белсәм, азрак җуган, җыештырган булыр идем, ичмаса, – ди.

Туташ шелтә катыш үпкә белән җавап бирде:

– Ходаем, бу нинди хәл бу! Әле килгәндә юл буенча Урманов белән талашып килдем. Мине ник аералар, башкаларга яраган ник миңа ярамасын!.. Бик матур, бары да бик матур... Кадыйр байның йорты бик шәптер дә бит, менә бу иптәшләрдән, ул чакырса, һичбере бармас иде...

Фатир чыннан да бик үтә фәкыйрь иде. Барлыгы ике тәрәзә, аларның да тик иң югарыгы өлгеләре генә йирдән өсткә күтәрелгәннәр. Тар гына ишек алдын үтеп кергәч, уң якта бик зур мич, аның акбурлары кубып беткән, ятагы, аш бүлмәсе – бары да бергә, тик мич алды ягы чаршау белән бик аз гына бүленгән. Түрдә агач өстәл, ике артсыз урындык та бер озын сәке.

Фатир кечкенә караңгы, җиһазлары бик артык ярлы, иске булса да, иптәшләр һәммәсе дә үзләрен бик яхшы хис итәләр иде.

Габдәһ абзый белән Заһидә җиңи бу кадәрле дустларына карап туя алмыйлар. Икесенең дә йөзләрендә шатлык балкый иде. Җиһангир, җырчы Сахиб, мәдрәсә шәкерте Сәйфуллин, Урманов аркылы Йосыфҗаннан ярдәм алып, русчага бирелгән яшь Камил, тыгызлана төшеп, эскәмиягә утырганнар. Давыд, ничектер хәйләсен табып, кырын ятарлык урын ясаган. Рауза, Заһидә җиңинең рөхсәте белән, савыт-саба хәзерләргә, аш өлгертүдә аңа булышырга тотынды, аның бәхете һәммәнекеннән артык иде. Әйтерсең, сөйгәненең йортына бүген генә чыгып, беренче мәртәбә гаилә хезмәтенә керешкән, шундый бер мәсгудиять[1] белән, кул сызганып, алъяпкыч ябып, эшләшеп йөри.

Беренче сүз итеп, һәммәсе дә Хәбибнең ничек качуы хакында сөйләвен үтенделәр. Урманов аңа, бөтен тәфсыйлатны[2] сөйләп бетермә, дигән мәгънә белән күз кысты. Ул әйтмәсә дә, Хәбиб боны үзе үк белә иде. Кыска бетерде:

– Софья Перовская[119+] бервакыт Кырымда тотылып ябылды да Питерга озатылды. Юлда барганда аңа, бик артык әһәмият бирү йөзеннән, поездда купе эченә дә ике сакчы куеп, анардан күз алмаска, һәрбер кузгалышын тикшереп торырга куштылар. Жандармнар күз алмый карап бара торгач, тынып йоклап киттеләр. Бүлмәнең ишеге тышка ачыла иде. Сакчыларның гырылдаган вакытын күзәтеп торды да ишеккә аркылы яткан жандарм ашасыннан чыгып качты. Хәбәреннән элек Питерга иптәшләре янына килеп җитте... Бу вакыйганы һәммәңез беләсездер, әгәр дә мин сөйләсәм,

[1] *Мәсгудиять* – рәхәтлек.
[2] *Тәфсыйлатны* – аңлатманы.

ышанмассыз, Перовская хакында укыгансыз да шуны безгә үзеңезнеке итеп сөйлисез, диярсез... Ләкин ул иң вак тәфсыйлатынача шулай – шуның копиясе булды. Качып котылгач кына, ул Кырым вакыйгасы минем хәтеремә килеп, шатлыгымнан кычкырып көлеп йибәрдем...

Иптәшләр, бигрәк тә Рауза, Хәбибнең иркенә куймады, безнең шикелле яшь революционерларга сабак булыр, сөйләңез, сөйләңез, – диде.

Сөйләп биргәч, чыннан да ике арада зур охшаш барлыгы күренде.

Аш өлгергән иде инде. Рауза һәммә иптәшләрен яңадан кузгатып, ипләп утыртты, тәрилкәләр юк иде. Алга агач кашыклар тезелде. Күп итеп икмәк килде.

Ашны сосып китерер вакыт җиткәч, Хәбиб элгәре Заһидә җиңидән гафу үтенде дә, Габдәһ абзыйга карап:

– Боларга кирәкмидер, ләкин мин бик ватылганмын, аш алдыннан берәр яртыны төшерсәң, ару булыр иде, – диде. Урманов, кешене юк белән мәшәкатьлисең, дип бәйләнә башлаган иде, Рауза аны кырт кисте:

– Җаным, абзыйкаем, табыңыз, тап. Ул шулай арыган, ватылган, аңа файда булыр!

Габдәһ абзый күп сөйләтмичә:

– Һичбер мәшәкате юк. Ике адымлык йир, күрше Петрушкада була торган иде, – диде дә, чикмәнен җилкәсенә салып чыкты. Никтер аның артыннан Заһидә җиңи дә чыгып керде. Боның сәбәбен Урманов кына аңлады. Иренең эчәргә яратканын, аракы күрсә, тыела алмау ихтималын Заһидә яхшы белә иде. Петрушкага китәргә булгач, артыннан чыгып: «Син, Алла хакы өчен, дип әйтәм, үзең эчмәссең бит, мин тагы элеккеге кебек булудан куркам», – диде. Ире аңа вәгъдә биргәч, шатлыгыннан канатланып керде, Ходаем, нинди бәхет, кешеләр эчәләр, алдында аракы тора, ә аның Габдәһесе кыстасалар да эчми! Йа Ходай, бу төш түгелме?

Петрушка чыннан да якын икән, биш минут та үтмәде, элекке гадәтенчә, ярты кызылбашны чалбар кесәсенә тыгып кайтып керде.

Аш утырды. Хәбиб алдына азрак кәбестә, зур чынаяк чокыры куелды. Ул моның өстенә җиңидән бер бәрәңге белән ит сорап алып, азрак суытты да, чынаякны тотып, су эчкән кебек кенә йотып йибәрде.

Башкалар кызулап ашыйлар иде. Давыд Габдәһ абзыйны аңларга тырышты. Ул бөтенләй котыла алганмы, әллә һаман да җәберләп кенә тыеп торамы? Юк, ул тыныч күренә, алдындагы аракыга күз дә төшермичә, рәхәтләнеп ашый, димәк, бөтенләй котыла алган...

Калдыгын икенче мәртәбә сала башлагач, Рауза Хәбибкә бәйләнде:

– Сез бигрәк харап инде, үзеңез генә бетерәсез... Миңа да салсаңыз, брудершафт эчмәкче идем, – диде.

Җиңи, Габдәһ абзый һәм башка иптәшләр, гаҗәпсенеп, туташка карадылар:

– Ул шаярамы, чынын сөйлиме?

Хәбиб үзенең иң яхшы, иң дустанә елмаюы белән туташка карады:

– Башкаларның эчмәве миңа мәгълүм, сез дә кабул итмәссез, дип уйладым. Күтәрә алсаңыз, рәхим генә итеңез! Сезнең белән эчү минем өчен бик-бик хозур булыр! – диде.

Кечкенә чынаяк өсте бирделәр. Рауза үзе берәр рюмка кадәрле салды да кулына алды. Башкалар һаман аның эчүенә ышанмыйлар иде әле. Ул Хәбиб белән чәкәштерде дә, бөтен шартларын китереп:

– Самодержавие кулыннан котылып, яңадан безнең янга кайткан революционер иптәшнең исәнлегенә эчәм! – дип, бер секундта авызына каплады. – Бик ачы, диләр иде, әллә нәрсә түгел икән, – ди. Үзенең күзләреннән яшьләр килә.

Ул брудершафт дигән иде, никтер анардан киреләде.

Аш күп хәзерләнгән, ит тә олы табак белән өелеп килгән иде. Ләкин егетләрнең ачыгуы бик җиткән булырга тиеш ки, килгән бере югала барды. Хәбибнең ашавы бигрәк харап иде. Ул:

– Мондый сыйланулар безгә корбан бәйрәмнәрендә генә эләгә! – дип, иптәшләрен көлдерә-көлдерә, иң ахырга калып ашады.

Мәҗлес кызык үтте. Бераз эчеп кәефне төзәтеп алгач, Хәбиб Мансуров үз тормышыннан, бигрәк тә качып йөрүе вакытындагы хәллләрдән күп нәрсә сөйләде. Рауза аны буңарчы усал телле, каты күңелле кеше дип кенә белә иде. Бүген туташ алдында егетнең тормышка киң каравы, гаҗәеп бер тасвир белән җанлы итеп сөйли белүе, ерактан, тирәннән күрүе ачылды. Үзе аның янында кечкенә генә булып калды.

Әгәр мәҗбүр булмасалар, таңгача утырачаклар, Мансуровның кызыклы һәм мәгънәле хикәяте аркасында вакытның ничек үткәнен тоймаячаклар иде.

Башлап, Давыд кузгалды:

– Таралырга бик вакыт! Берәмләп чыга башлыйк, – диде.

Рәхмәт укып, башта яшьрәкләр китте. Мансуров бүген Габдәһ абзыйда йокларга булды. Рауза аны иртәгә үзенең дустларыннан беренә күрешергә вәгъдә бирде. Китәсе бер дә килмәгәнен сөйләп, һәммәсенә рәхмәтләр укып, кат-кат кулларын кысып, хәерле йокылар теләп, иң ахырдан Рауза кузгалды.

## LXIX

Рауза белән Давыд Габдәһ абзыйдан чыкканда күк йөзе ачылган, йолдызлар үтә якты бер нур белән ялтырыйлар. Ярты ай да үзенең тонык

нуры белән дөньяга ниндидер бер серле хыялый төш бирмәктә иде.

Туташ, киң сулыш алып, Давыдның култыгына керде.

Габдәһ абзыйның кечкенә тар хәрабә фатирында шатлыгыннан канатланып очкан кыз хәзер танылмас дәрәҗәдә үзгәргән – басылган, күңеле әллә кая киткән иде. Бик озак сүзсез бардылар. Икесе ике нәрсә уйлый, ләкин уйларының төбе бергә кайта иде.

Капкага килеп исәнләшә башлагач, Раузаның йибәрәсе килмәде, барыбер йоклап булмас, бераз һавада утырыйк, дип, йортка алып керде. Анда кечкенә генә бакча бар. Ялангач агачлар тын төндә гүя нидер тыңлыйлар иде. Ниндидер бер урындык табып, шуңа килеп аудылар. Егет тышкы киемен салып, туташны кочагына алып урады.

Давыд башлады, Рауза җавап бирде, һушларыннан язганчы үбешүдә катып калдылар, тагы һәр икесе:

– Башы, ахыры шул булсын! – дип аерылдылар. Аерылып, капкага җиткәч, тагы «Давыд» дип дәште, тагы бер-беренең кочагында хәлдән тайганчы үбештеләр. Кыз кинәт сикереп торды, бер сүз әйтмәде, кесәсеннән ачкычын алып, ишегенә килде. Давыд, үз-үзен аңлап кузгалганчы, Рауза ишек эченә кереп югалды.

Туташ акрын керергә, һичкемне уйгатмаска тырышты.

Ишектән кергәч тә уң якта анакае (Кытай сугышында һәлак булган полковник Сәлим мирзаның хатыны Алмасбикә) бүлмәсе иде. Туктап, аңа колак салды: тигез сулыш алып, тыныч, рәхәт йоклый.

– Ходаем, дөньяда нинди бәхетле җаннарың бар?

Һичкемне уйгатмыйча, үз бүлмәсенә үтте. Бүлмә матур. Һәммә нәрсә урынында. Хадимә, тәрәзәнең калын пәрдәсен төшереп, челтәрле кардай ак ятакны тыныч йокыга хәзерләгән. Өстәлгә, гадәттәгечә, ач кайтыр дип уйлап, сөт, йомшак булки, атланмай куелган. Бөтен бүлмәдә тынычлык, матурлык, тәртип, гаҗәеп хуш бер ис аңкый.

Башка көннәрдә кайтып керә дә, ашап, чишенеп бетәргә дә өлгерә алмый, тыныч, рәхәт тирән йокыга китә иде.

Бүген юк!

Акрынлап чишенә башлады. Яртылый чишенгәч, уйга батып тукталды... Йокы каядыр качкан. Чишенеп ятканнан соң да йоклый алмады...

Тышкы дөньяда түгел, аның үз эчендә нидер җимерелә, нидер туа.. Дөньяның, мәдәниятнең барлык байлыклары белән бизәлгән заллар... Алтыннар, бриллиантлар, ефәк, атласлар эченә чумган матур ханымнар, алтын погонлы, гаҗәеп тәрбияле, нәзәкатьле кавалерлар... Музыка уйный... Матур күзләр сөеп карыйлар. Тулы алсу иреннәр матур елмаялар... Тәмле эчемлекләр... Чәчәкләр... Баллар, театрлар, кичәләр, ложалар, погоннар...

Юк.

Эшчеләр, солдатлар, крәстияннәр, бичара шәкертләр, приказчиклар, җиңе, тез башы җыртык Тангатаровлар, Абдулкалар... Кирәксә, зинданнар, сөргеннәр, бәлки, дар агачлары, баштанаяк кызыл киенгән җырткыч кара йөзле палачлар...

Рауза кинәт сикереп торды да, иң эчке киемнәренә чаклы салып ташлап, бөтенләй анадан туган хәлендә калды. Эленеп торган ефәк халатны иңенә салып, залга чыкты. Түбә түшәмнең уртасына асылган люстраны якса, бик артык якты булачак, альбомнар белән тулып яткан өстәл өстендәге кечкенә лампаны яндырды да көзге алдына килеп басты!

Ул үз тәненә үзе гашыйк иде. Бүген бу хис бигрәк артты:

– Йа Ходай, ничаклы матурлык! Мәрмәр ташына җан биреп, тарихта мәңгелек урын алган һәйкәлчеләр бармы? Аларның мәрмәр тәннәре үтә ак, ләкин Рауза үзендә шул гаҗәеп ак мәрмәргә бик аз гына алсу кан йөгертелгән күрде. Кулбашлар түгәрәкләнеп, тулып киләләр. Күкрәк тә ике данә зур алсу алма. Аның башларында кечкенә генә кара бөртекләр. Шул гаҗәеп тән ниндидер эчке куәт белән үзеннән-үзе дулкынланып тора. Бөтен тәндә бер генә данә миң, яра эзе юк! Венера[1] үз тәненә дөньяны табындырды, ләкин ул хәзерге вакытта мине күрсә, оялыр, үз шөһрәтен хаксыз табар иде!

Йөз үтә матур түгел, уртача. Әгәр дә ул тагы бик-бик аз гына озынчарак булса, борын бик-бик чак кына биегрәк булса, ул вакыт иске юнан матурларын хәтерләтер иде... Ләкин зыян юк, бу ике кимчелекне һәрвакыт нурланып торган зур кара күзләр, сызылып төшкән озын керфекләр, тулы алсу иреннәр артыгы белән тутыралар... Кара ефәк чәчләр, кайчандыр бөтен иңне, күкрәкне каплап, дулкынланып торалар иде. Хәзер кыскарганнар, ләкин бу кыскару матурлыгын гына арттырган...

Ана, бичара ана бу тәнне кызының үзеннән дә артыграк ярата. Раузаның акылы, җитдилеге үзен бик артык яхшы тотуы зур өмид баглаталар. Маллы, дәрәҗәле, тәрбияле һәм акыллы бер пар табып, карчыкны тынычлатачагына ышандыралар иде. Рауза тирәсендә уралган офицерлар карчыкның үткен күзеннән үтәли, ләкин һичбере күңелгә тулмыйлар, кайберенең озаграк, ешрак йөрүе карчыкны бераз шөбһәгә төшерә. Бу кыз шул тән, шул акыл белән бу егетне үзенә юлдашлыкка сайламаска тиеш, дип уйлый. Бераздан тегеләр югалгач, Рауза алардан көлеп сөйли башлагач, карчык тагы тынычлана иде. Әле ашыгырга кирәге юк. Кызының яше яңа егермегә җиткән.

Рауза да анасының фикерен сизә, үзенең карашы да шуңа якын иде...

---

[1] *Венера* – Рим мифологиясендә матурлык алиһәсе.

Ләкин бу хакта алар һичбер мәртәбә сөйләшмәделәр. Аны кирәк тә тапмыйлар иде.

Рауза кинәт уйганып китте. Көзгедә үзенең гаҗәеп сылу тәнен күреп, тиз генә халатка төренде дә:

– Болар бары да әллә кайчангы ахмак уйлар иде. Революция килде. Аның дулкыны белән һәммәсе таралды, бүтән тар кара киемгә төренде. Кирәк булса, ул зинданнарда черер яки палач кулыннан үтеп, чокырга ташланыр! – диде дә, залдагы утны сүндереп, яңадан бүлмәсенә килде.

Ләкин йоклый алмады.

Бондый акылсызлыклар яңадан кайтмаска тиеш. Үткәнне бөтенләй күмеп, аны онытырга кирәк. Кемнән куәт алыйм? Иртәгә кем белән бу хакта ераклабрак сөйләшим. Давыдмы, Хәбибме, Булатмы?

Булат мондый фаҗигаләрне аңламас, бәлки үз эченнән, зыялы кыз фаҗигасе, дип көләр генә.

Давыд тирән уйлый, киң карашлы, ләкин йомшаграк...

Хәбиб кызгануны белми, хәнҗәр белән йөрәгеңне тереләтә ярып кисеп ташлар. Шул яхшы да: шуннан берьюлы җиңеләеп үк каласың... Әйтерсең, рәхимсез оста доктор бер секундта авыру әгъзаны ярып йибәрә. Юк, шуңа барам, аның белән бер сөйләшеп үтәм...

Ләкин баруда ни файда? Аның ни әйтәчәге алдан билгеле бит: бер дә исе китмичә тыңлар, кыскарак сөйләңез, дияр, сөйләп беткәч, начар тәмәкесен зур итеп төреп тартыр да:

– Бик табигый эш... Бер сыйныф үзенең тарихи ролен үтәп, урынына башкалар килер вакыт җитсә, аның үз эченнән үз кешеләре яңа мәйданга чыккан сыйныфка килеп кушылалар... Сез дә иске аристократия, буржуазия сыйныфыннан пролетариат сафына чыгучы элементларның берсе... Сезнең трагедия дә шунда... Ләкин нык булыңыз: интеллигенция берничә ел кызарып, социализм дип йөри дә, ахырдан барып, мещанлык сазына бата... – диләр.

Үзен күреп сөйләшсәң, сөйләшмәсәң дә, әйтәчәге мәгълүм.

Юк, миңа берсен дә күрергә, бу хакта һичкем белән дә сөйләшеп торырга хаҗәт юк.

Минем юлым ачык, иманым көчле. Ул иске тормыштан мин киттем. Анакай уйлаган Рауза хәзер дөньяда юк. Аның урынына башка Рауза туды... Мин – революционер, мин социализм байрагын күтәреп, капиталга бөтен буржуазиягә каршы көрәшүчеләрнең берсемен...

Хуш, бәхил бул, иске дөнья! Мин сиңа мәңге кайтмаячакмын... Алдымда яңа дөньялар, яңа идеаллар!

Шулар белән саташып йоклап китте.

Кызының бик соң ятуын Алмасбикә төндә үк сизгән иде. Иртә белән гадәттәгедән озак йоклагач, түзмәде, берничә мәртәбә Раузаның бүлмәсенә кереп карады, йөзләре тыныч, ләкин башы ут кебек яна иде.

Ана йөрәге нидер сизенде, ни булган бу балага, дип авыр хафага калды.

---

Сәгать унберләр иде инде. Туташның торганын белгәч, аңа хадимә керде:

– Анакаеңыз кәефсез, башы авырый, сезне үз бүлмәсенә чакыра, – диде.

Рауза бетен тәнен салкын су белән сөртеп алды да анасы янына барды.

Карчык, бер төндә ун еллык картаеп, саргаеп киткән иде. Кызын салкын гына үпте дә, кара кофены болгый-болгый:

– Кызым, сиңа ни булды? – диде.

Рауза боны көтә иде. Хәзерләнгән иде. Ничаклы сөйләшсәң дә аңлашып булу ихтималы юклыгын белгәнгә, сүзне озайтмаска теләде:

– Һичнәрсә юк, анакаем! Мин хәзер собраниегә китәм, сиңа аптекадан кирәк нәрсә юкмы? Кайтышлый алырмын! – дип, урыныннан торды.

Карчык ачуыннан, кайгысыннан катты, җыерчыклар бөтен йөзен каплады, ләкин сүз белән белгертмәде:

– Юк, рәхмәт, кирәк булса, мин Гайнидән алдырырмын!

Рауза ашыгыч киенде дә чыгып китте.

Бикә акылыннан шашып калды: собрание, собрание, реферат, партия, ниндидер эшчеләр, Давыдлар, Абдулкалар... Митинглар, социализм... Революция... Бу ни эш бу?

## LXX

Полковник Сәлим мирза үзе исән чагында Ширинскийлар гаиләсе, шәһәрнең аристократиясе эчендә беренче урынны тотса да, иренең вафатыннан соң Алмасбикә имениенең дә килере нидәндер азайганын күрә. Үсеп килгән кызы Раузаның укуы, киемнәре дә күп акча алалар. Пенсия генә боларны каплап җитә алмаячак. Алдан күрүчән саф ханым, бу хәлләрне исәпләп, элекке зур йортны яхшы шартлар белән якыннарыннан беренә квартирга бирә дә шәһәрнең тыныч таза урамнарыннан бакчалы, артык зур түгел хәзерге фатирга күчә. Ләкин җиһазның һичберен калдырмый, сатмый, үзе белән ала. Элекке зур өйнең иң кадерле нәрсәләрен тезеп, бу яңа квартирны картина кебек матур рәвешкә куя.

Революционерлар Раузаны байтактан белсәләр дә, һичберәве аның өенә кергәне юк иде. Бу хәл Раузаны бераз борчый. Иптәшләр белән үз арасында ниндидер бер дивар торган тойгысын бирә иде. Шуңа күрә дә ул үзендә

булачак җыелышка эченнән зур мәгънә бирде. Аны ашыктырырга тырышты. Тагы шул да бар: Булатов белән качкын Хәбибнең язмышы, биредә күпме тора алулары бер дә билгеле түгел бит. Эзләренә төшелгәнлек сизелсә, алар сызачаклар, алардан башка яшәүнең мәгънәсе бик зур түгел.

Гөнаһ шомлык бит, тагы кичәге төннең фаҗигасе анакайны бик артык борчыган булырга кирәк. Ул түшәккә сузылды, шул сәбәптән имениегә китүе дә кичекте. Кыз, анасының авыруы күңелдә булганын ачык белгәнгә, эшләренә бераз кимчелек китереп булса да, аның янында озак булырга, аңа иркәләнергә, күңелен табып тынычландырырга тырышты һәм бер атна дигәндә, карчык, терелеп, имениегә китә алды.

Инде вакыт җитте, дип торганда әллә кайдан бер-бер артлы митинглар, ашыгыч җыеннар, кичекми торган мәсьәләләр килеп чыгып, тагы берничә көнне үтерделәр.

Җә, менә бары да бетте, дүшәнбене Рауза үзенә сугышып алып, иптәшләренә кич сәгать җидедә бер чынаяк чәйгә, дип хәбәр итте. Татарны алдан билгеләнгән вакытта җыелышка китерү – бу, тауны урыныннан кузгатудан да авыррак эш. Нинди генә хәлсез булмасын, аның 2-3 сәгать кичегеп башлануы гадәткә кергән инде.

Ләкин туташ бу турыда бәхетле икән.

Сәгать җидене сугуга, Давыд белән Булат килеп керде. Алар чишенеп, исәнләшергә өлгерә алмадылар, үзләренең гимназист реалист формаларын киенгән Тангатаров, Акчулпанов, болар артыннан ук Җиһангир белән җырчы Сахиб килделәр.

Озак та үтмәде, үзенең ярым яурупача, ярым татарча итеп, бик килешле киемнән, түбәтәйдән Госман, зур итектән, кара сатин күлмәктән качкын Хәбиб Мансуров залга үттеләр.

Хәбиб, керә-керүгә, туташка текәлеп карады. Ул Раузаны, әйтерсең, гомерендә беренче күрде, туташ шулчаклы башкарган[1] бүген: зур кара күзләр гадәттәгедән көчлерәк яналар, иреннәр тагы да тулырак, тагы да алсурак төс алып, бертуктаусыз елмаялар, бу елмаю туташның йөзенә гаҗәеп бер сөйкемлелек бирә, энҗе кебек ак саф тешләрне ачып, күзне камаштыралар, колактан түбәнгәрәк төшкән зур кара чәчләр бүген Раузаның байтак вакытын алган булырга тиешлеләр ки, ефәк көлтәсе кебек күперенеп торалар, туташның болай да артык зифа буе, килешле сыны бүген сылана төшеп торган кара платье эчендә үзеннән-үзе дулкынланып, йөрәкне үзенә тартып алып тора.

Качкын, туташтан айнып, өйнең, залның матурлыгына күз салгач

[1] *Башкарган* – бу урында “*үзгәргән*” мәгънәсендә.

хәйран булды.

Тыштан гади күренгән бу өйнең эче үзенең кыйммәтле җиһазлары, идәннән түшәмгә күтәрелгән көзгеләре, кыйммәтле паласлары, гаҗәеп гөлләре, боларның һәммәсенә нур сибеп торган зәвыклы тәртип – беренче карауда җәннәт почмагына килеп кергәнлек тойгысын уйгаталар иде.

Утырып сәламләшеп бетәргә өлгерә алмадылар, туташ Хәбиб белән Давыдка чыннан да әрнүле шелтә белән бәйләнергә тотынды:

– Әйтегез Габдәһ абзый кая? Ул булмаса, җә мин акырып җылыйм, җә үзегез чыгып китегез, – ди.

Давыд кыска гына: «Ул килә алмый», – диде. Рауза буңа каршы тагы катырак һөҗүм башлагач, качкын Хәбиб үзендә бик сирәк була торган яхшы елмаюы, дустлык тавышы белән туташны тынычландыру өчен аның килә алмавының сәбәбен сөйләп бирде.

Кавказдан Гәрәй Солтан дигән бер татар эшчесе килгән. Яманташның Шакир солдат берничә көн элек килеп тә, безнең беремезне дә очрата алмый аптырап беткәннән соң, бүген сәгать бишләрдә Заһидә җиңине базарда туры китергән. Болар икесе дә – безнең өчен алтын тавыннан да кыйммәтле кешеләр. Бигрәк тә Кавказныкы. Габдәһ абзый боларга бер сүздән үк шулчаклы ябышты ки, һичнәрсә белән тартып алу хәл юк. Ничаклы әйтсәм дә, аларны ташларга риза булмады. Туташ мине гафу итсен, бара алмыйм, ниләр булганын иртәгә сөйләрсез, ди.

Моңарчы сүзгә аз катнашкан Булатов кавказлы Гәрәй Солтанга аеруча әһәмият бирде: «Ул кем, аңлымы, кайсы партиядән?» – дип сорады. Качкын кинәт суынды:

– Ул күптәнге социалист икән... Революциягә чаклы меньшевиклар[120+] белән эшләгән... Хәзер максималист[121+], бугай... Артык гайрәтле, артык кискен кеше күренә... Безнең монда киткәнне белгәч, әле сез һаман шулай чәй янында киңәшләр белән вакыт әрәм итәсезмени? – дип, чәнчеп көлде.

Рауза тыштан тынычланды. “Кичә аларда шундый күңелле булган иде, бүген үзе миңа килмәгән. Һич тә онытмам”, – диде дә, ишекләрне үзе бикләп, кунакларын аш бүлмәсенә чакырды.

Өстәл гаҗәеп бай, ашамлыклар бик төрле. Һәммәсе үтә нечкә зәвык белән тезелгәннәр иде. Утырып җитәр-җитмәс, кемдер: “Теге милли террор”, “Фидаиләр” партиясе төзү белән янып йөргән Баязид карый хакында чыккан хәбәрнең дөрест булмавын, ул иректә икәнлеген, тиздән бирегә килү ихтималы барлыгын сөйләде.

Хадимә кайнар пәрәмәчләр китерде. Рауза иптәшләренә ашамлыклар тәкъдим итеп, берәр чынаяк ясады да, чәй беткәнне көтсәң, җә берәр уңгайсыз хәл чыга башлар. Хәзерге вакытта бондый эш булгалый, дип уйлап,

сүз башлады. Әйтергә теләгәне шул иде:

– Дошман көчле. Куәтләремез аз. Шул азны да төрле гөруһларга бүлеп, үзара талашка, тартышка вакыт, көч әрәм итү – дошман тегерменәнә су кою. Революциягә каршы җинаять итү була. Без үзара аңлашырга, берләшергә тиешле.

Качкын Хәбиб үз эченнән: “Өй бик матур, өстәл бай, пианино бар. Әгәр дә бондый һичбер төрле нәрсә чыкмый торган сүзләр белән вакыт әрәм итмәсәк, тагы да яхшырак булыр иде”, – дип уйлады. Башка чак булса, ул, бәлки, бу уен әйтер дә иде. Ләкин бүген анарда ничектер йомшаклык, каты бәрелмәүчелек рухы көчле иде. Шуңа күрә дәшмәде. «Сөйләсеннәр, яңадан бондый мәсьәлә белән баш ватмаслык итеп тәмамлармыз», – диде. Акчулпанов тәкъдиме буенча, сөйләү тәртипләрен алып бару Раузага тапшырылды.

Беренче сүз Тангатаровныкы иде. Ул, кызып, ялкынланып, туташның фикерен куәтли, революция өчен һәммә нәрсәне, кирәк булса, партия фанатиклыгын да корбан итәргә чакыра.

Акчулпанов та шуңа кушыла. Беренче интернационал дәверендә проданистлар[122+], лассалианистлар, тридивнианист, марксист кебек төрле мәсләк социалистларының бер организация эчендә эшләүләре безгә гыйбрәт, ди.

Госман да буңа каршы түгел. Ләкин аңлашу, берләшү дигән белән эш бетми. Нинди нигезләрдә берләшү мөмкин? – Аныңча, мәсьәләнең төбе шунда.

Болардан соң Зариф Булатов аякка басты.

Бу көннән үк сөйләгәне юк иде. Һәммә иптәшләр гадәттән тыш зур дикъкать белән аның ни әйтәчәген тыңларга хәзерләнделәр.

Ул башта социализмны, сыйнфый көрәшне гыйльми рәвештә тигезләде. Пролетариат хәрәкәтенең тарихи дәверләрен тәфсыйль итте.

Беренче интернационалны[123+], Париж коммунасын[124+], Яурупада, аннан соң Русиядә социал-демократиянең тууын, народниклар белән тирән ихтиляфны[1] капитализм, эшче-крәстиян сыйныфлары хакындагы ике гөруһның карашын, бу икенең хәзерге тактикасын сөйләп, шундый бер күренеш китереп куйды ки, ерак идеаллары бер булган бу ике агымны берләштерү дигән сүзнең мәсьәләгә өстән карау яки аңламаудан башка нәрсә түгел икәнлеге үзеннән-үзе килеп чыкты. Ахырдан, бераз көлеп, берләшү дигән сүз эсэр иптәшләрнең безгә кушылуы дигән мәгънәдә булса гына, без ул сүзне аңлыймыз, башкача ул безгә буш аваз дип бетерде. Ул үзенең сүзе,

---

[1] *Ихтиляфны* – каршылыклы булуны, килешмәүне.

фикере белән зур көрәш мәйданында җиңелмәс сыйфат белән торган каһарман кебек булып күренде. Буңа каршы эсэрләрдән Хәбиб Мансуровның җавап бирәчәге үзеннән-үзе билгеле иде. Ул үзе дә боны сизеп, зур иттереп, тәмәкесен төрә башлады.

---

Татар яшьләре социализмга революция дулкыны белән килеп кергәннәр, боның да башы Казанда, Казанның да Учительский школасы[125+] тирәсендә булган татар пролетариатының беренче дустлары шуннан чыкканнар булса, Зариф Булатов бу юлга башка яшьләрдән алдарак төшкән, 1903 нче елда ук инде рус студентлары түгәрәкләрендә эшли башлаган иде. Тиз арада ул бу түгәрәккә бүтән яшьләрне дә берәм-берәм тартты. Күп үтмәде, болар үзара берләшеп, татарлар арасында эшләү өчен аерым түгәрәкләр төзеделәр.

Башта һәммәсе бергә иде. Син – с.д.[1], мин – с.р.[2], теге – большевик, бу – меньшевик, яки уң, урта, сул с.р. дип аерылулар сизелми иде. Булат үзе социал-демократ (аның да большевигы) булганга, яшьләрнең һәммәсен шул байрак астына җыярга тырыша иде. Госман, Акчулпанов меньшевиклар булсалар да, Булат белән бергә эшләделәр, башкалар да кушылып бара иде; моңа каршы иң элек баш күтәрүче качкын Сәрүҗи Хәбиб Мансуров белән Урманов Давыд булды. Тангатаров, Җиһангир боларга кушылды, Рауза да тиз арада болар белән эшләшә башлады.

Баштагы аерылу үзара талашуда гына булса да, бара торгач тирәнәйде, төпләнде. Һәр ике як үзләренең гомуми партияләре белән берләшеп, организация өчен газета чыгару, матбугат тарату өчен, партиядән акчалар алдылар.

Эсерлар[3] – Идел, Кама буен, бигрәк тә Казанны, эздеклар[4] Уралны, бигрәк тә Оренбургны мәркәз итеп, аерым оештылар. Аерым эшли башладылар.

Арада руслардагы кебек кызу талаш юк, һәр икесе, башлыча, көчләрен истибдадка, буржуазиягә, бигрәк тә “Иттифак әл-мөслимин” партиясенә юнәлдерәләр. Демократлар эчендә Булат, революционерлар эчендә Урманов кебек һәр ике яктан бертигез диярлек мәхәббәтен казанган иптәшләр булуы бу ике партия кешеләренең береннән гамәлдә күп ераклашмавына сәбәп була иде.

---

[1] *с.д.* – социал-демократлар партиясе әгъзасы.

[2] *с.р.* – эсерлар партиясе әгъзасы.

[3] *Эсерлар* – Россиядәге буржуаз демократик партия. Алар шәһәрдә һәм авылдагы вак буржуазия интересларын яклыйлар.

[4] *Эздеклар* – эсдек, социал-демократлар.

Ләкин Рауза уйлаганча, “аңлашу-берләшү” фикерләреннән һәр икесе ерак иде. Шуңа күрә Хәбибнең нәрсә әйтәчәге алдан мәгълүм иде. Ул акрын башлады. Башта ук бу мәсьәләнең кузгалуына гаҗәпсенгәнен аңлатты. Аннан соң, партия белән тормыш һәм сыйныфлар арасындагы мөнәсәбәтне Русия үзенең икътисадый, сәяси хосусиятьләре белән гаребтән аерылуын, бу хәл партияләрнең программасында, тактикасында Яурупа социал–демократиясеннән аерымлык теләвен, шуның нәтиҗәсендә Герцен, Чернышевский, Михайловскийлар[126+] тууын, революция тарихында мәңгелек урын алган мәшһүр “Халык азатлыгы” партияләре[127+], Перовская[128+], Желябовлар[129+] мәйданга чыгуын, шул күп тәҗрибәләрне, шул миражларны җыеп, эсерлар партиясе дөньяга килүен, аның йир, идарә, крәстиян, миллият, тактика мәсьәләләрендә генә түгел, идеологиясендә дә демократлар белән килешә алмый торган күп урыннары барлыгын сөйләде. Ахырда ул да, көлә төшеп, Булат белән берләшү – безнең өчен аның эсэрларга кучүе рәвешендә генә мөмкин, дип тәмам итте.

Акчулпанов белән Госман яңадан үзләренең меньшевик булганнары хәлдә, революция намenә[1] большевиклар белән бергә эшләүләрен, бунда да аңлашу мөмкинлеген сөйләделәр. Җиһангир үзенең гыйльми мәсьәләләрдә көчле түгеллеген сизә иде. Халык алдында, митингта боларны таптап узачагын яхшы белсә дә, үзе көчле булмаган бер мәсьәләдә сүзгә катнашып, серне ачарга теләмәде, ләкин эченнән Раузага каршы иде.

Давыд бер-ике сүз әйтмәк булып авыз ачкан гына иде, тегеннән ишек шакылдаттылар. Иптәшләр, полиция булмасын, диештеләр. Рауза бераз кызарып: “Юк, булмас, иптәшләрдән берәүдер”,– диде дә, йөгереп, ишеккә китте.

Ни күрсеннәр, зур калын гәүдәсе белән дулкынланып, ишектән үк калын тавышы белән нидер сөйләнеп, Нигъмәт казый килеп керде.

Туташ иптәшләреннән гафу үтенде дә, ярым әрнүле, ярым көлке тавыш белән:

– Мин бер мәсьәләдә эштән чыгып егылдым. Инде тагы ни диярсез, шуңа охшаш тагы бер мәсьәлә бар, – диде. Нигъмәтне утыртып, аңа чәй ясады да сөйләп бирде.

“Иттифак әл-мөслимин” партиясенең мәркәзенә якын кешеләрдән берәү, туташны махсус күреп, анардан татар социалистлары белән бераз аңлашу мөмкин булса, үзара урынсыз талашуларны куеп, милли, мәдәни теләкләр намена бергәрәк хәрәкәт итү мәсьәләсе хакында ярдәм итүен үтенгән. Мәсьәлә хәзергә рәсми түгел, алдан аңлашу гына. Нигъмәт казыйны

---

[1] *Наменә* – атына, исеменә.

туташ шуның өчен ахыргарак булса да чакырган. Казый бу мәҗлестә шул якның вәкиле сыманрак икән. Моңар каршы Давыд Урманов ачулы кискен сүзләр белән җавап бирә:

– Туташ, сез бүген бөтен дөньяны берләштермәк булгансыз, ахры. Эздекләр белән эсерларны кушу, ул гына җитмәсә, буржуазиянең "милләт, диянәт" пәрдәсе астына яшеренгән ялчылары, үзләренчә, имеш, милләтчеләр белән безне берләштерергә өстеңезгә алгансыз... Бунда нииндидер бер аңлашылмау бар. Алар белән берләшү, тирәндәрәк алганда, сыйнфый көрәштән ваз кичү дигән сүз була.... Мәгълүм ки, мәсьәлә Романовлар[130+] тәхетен җимерүдә генә түгел, без Николай белән бер дәрәҗәдә үк капиталга, буржуа, алпавытка каршы да сугыш ачамыз... – ди.

Соңра үзен "милләтче" дип атаган гөруһның партиясе – "Иттифак әл-мөслимин"нең программасына күчә, аларның сәяси идеалы – хокукы бераз чикләнгән, падиша, йир программасы – алпавытның йире өчен крәстияннән акча түләтү – үзләренчә, гадел бәһа. Димәк алар крәстияннән ике тире суярга тели торган монархистлар...

– Ә сез шулар белән нииндидер аңлашу, берләшү хакында сүз кузгатасыз... Барын себереп түгү – менә безнең мөнәсәбәт! Моңа каршы Нигъмәт казый сүз алып, бездә буржуазия юк, пролетариат юк, булса да бик артык аз, без миллият наменә арадагы аз-маз ихтиляфны ташламалы, – дип озын, куәтле нотык сөйләде.

Җиһанһир Нигъмәткә кызып җавап бирмәкче, аны рәд кылмакчы иде.

Урманов моны сизенде дә: "Кыска тоту өчен безнең караш ачык, бу хакта ике сүз юк. Мин мәсьәләне нәүбәттән[1] алырга тәкъдим итәм", – диде.

Һәммәсе риза булдылар. Нигъмәт казый ашап туйды, туташка рәхмәт укыды.

– Дөньяда сезнең кебек кире кешеләр аз булыр, сыйнфый көрәшләреңез, социализмыңыз, буржуа, пролетарыңыз белән барыңыз бергә җәһәннәмгә китеңез,– дип, көлә-көлә исәнләште дә чыгып китте.

Рауза иптәшләре каршында бераз төшкән кебек сизенде. Бусы тагы бер хәл, Хәбиб Мансуров үзенең ачы авыр сүзе белән үтереп ташламасын инде! Ләкин ул-бу булмады. Туташ Нигъмәт казыйны озатып кергәч, залга чыгып утырдылар, кузгалган мәсьәлә мөнәсәбәте белән качкын Хәбиб "Иттифак мөслимин"челәр хакында кызык нәрсәләр сөйли башлады. Ул алар белән күп талашкан, бигрәк тә Мәкәрҗәдә булган съездларында[131+] аңа каты тартышырга тугры килгән иде. Боларны шундый кызык сөйләде ки, Раузаның, аңламыйча, шундый мәсьәләгә тыгылуыннан оялып, яңаклары

[1] *Нәүбәттән* – чираттан, бу очракта, көн тәртибеннән.

кыза, яки күзенә яшь килгәнче рәхәтләнеп көлә иде.

Рауза пианинога утырды. Сахиб үзенең авыр тирән моңы белән “Бөдрә тал” белән “Ашказар”ны җырлады.

Талашлардан соң берничә матур, күңелле сәгатьләр үткәреп, бик мәсгуд[1] бер рух белән төнге сәгать бердә таралдылар. Иптәшләрен озаткач, туташ бик озак уйда утырды. Егетләр берәм-берәм аның күз алдыннан үттеләр. Арада бик якты, бик ягымлы сурәт Булатныкы иде. Ходаем, йөзе матур, күзләре, әйтерсең, нур чәчәләр. Тәрбиясез дә түгел, теләгәндә киенә дә белә икән. Бераз елмая төшеп, күкрәк тавышы белән сөйләве, сүзендәге акыл, тирән уй!

Шулардан соң кинәт аның Нинасын хәтерләде. Гүя туташның тәненә суык су белән койдылар... Шулай чирканып китте... Фу! Шундый томшыкның нәрсәсенә исергәндер, ирләрдә зәвык дигәнең юк, бугай, шул!

Рауза сикереп торды да бүлмәсенә килде. Дөньяны белер хәл юк, революционерның язмышы бик артык билгесез: иртәгә үк, онытмыйча, иптәшләрнең, бигрәк тә Давыдның рәсемен алырга кирәк. Ичмаса, сагынганда карарга булыр!

## LXXI

Төн, бәхеткә каршы, бик караңгы иде. Якын-тирәдә күзәтеп торучылар күренмәде.

Раузадан чыгу белән, егетләр икегә аерылды – эсдеклар Госман квартирына таба, эсерлар, үзләренә бер төркем булып, сулга борылдылар.

Качкын Хәбиб Мансуров белән Зариф Булатовның бүген монда актык төннәре иде.

Булатов иптәшләре белән бераз барды да извозчикка очрагач туктады. Ул, Чиләбе төбәгендәге шахталарга китәр өчен, вокзалга төшәчәк. Нинага иртәдән калдырмый (Вася сәламәт. Хат яз.) дип телеграм бирүне Госманга тапшырды. (Бу – электән аңлашу буенча, мин киттем, әйтеп калдырган адрес белән хат язарсың, димәк иде).

Почмактан ике шәүлә килеп чыкты. Егетләр тиз, тиз исәнләштеләр. Булатов извозчикка утырды да вокзал ягына юнәлде.

Мансуровлар компаниясе, шәһәрнең уртасыннан бераз китеп, бер постоялый дворга якынлашкач тукталдылар.

Качкын Хәбибкә партия тарафыннан Каманың югарыгы баш төбәгенә бару тапшырылган. Ул бүген шунда китәргә тиешле, шул ук поезд аңа ярыячак булса да, вокзалдагы шпионнары да, жандармнары да аны

[1] *Мәсгуд* – бәхетле.

танучылар булганга, шәһәрдән, һич булмаса, бер стансаны ат белән китәргә туры килә, постоялый дворда көндездән яллап куйган ат бар, бераз йокларга да таң алдыннан чыгып китәргә уйлый. Бунда килүләре шуның өчен иде.

Эсерларга кайбер хезмәтләр тапшырды. Давыдка аеруча:

– Раузаны күзәтергә, аны яңлыш адымнар ясаудан сакларга киңәш бирде. Әле бөтенләй утырып җитмәгән, ләкин безгә бик кирәк кеше. Түгәрәкләрдә бик яхшы эшли, әйберләр саклату өчен, ул – алтын... Шулай да сак булырга кирәк, бик артык яшерен планнарны белдереп бетмәскә дә ярый, – диде. Бер сүз белән кул бирешеп аерылдылар.

Җиһангир яңадан шәһәр уртасына барып, Кадыйр байның йорты каршысына туктап, Һаҗәрнең бүлмәсенә карап, бик озак торды. Бөтен өй караңгы, һичкайда ут юк.

Тукта, бүлмәләренең берендә кинәт ут яндырылды. Бу якты, бераздан югалып, күрше бүлмәгә килеп чыкты. Әнә инде Һаҗәр бүлмәсенә керде... Ләкин озакка бармады, яңадан сүнде дә бөтен өй яңадан тирән караңгылык эченә чумды.

Ходаем, ниләр генә булды икән соң?! Нигә мине болай газаплыйсың!

Язга каршы төннең зәһәр салкыны үзәгенә үткәнче торды да өшеп, калтырап кайтып китте.

Давыд Урманов үзенең җәһәннәм базына кайтып җитәм дигәндә, капка төбендәге эскәмиядән кемдер күтәрелеп, сак тавыш белән:

– Давыд, синме, тукта!– диде.

Егет башта танымады:

– Бу кем? Габдәһ абзый, синме?

Габдәһ җавап бирмичә үк Урмановның култыгыннан алды да, акрын гына атлап, кире якка таба алып китте.

– Бүген берничә йирдә тентү булачак икән. Теге полицийский Камалинең охранкада дустлыгы бар, ахры. Шуннан белеп, миңа килеп әйтте. Ул минем белән бу арада якынлашып бара. Бүлмәңдә бик кирәк нәрсәләрең булмаса, кереп торма. Иртәгә кайда очрашырга икәнен әйт тә, бүген берәрсенә барып кун. Хәзер зинданга эләгеп, хәл җыеп ятар чак түгел... Сине дә алсалар, без бөтенләй башсыз калабыз монда... Ул-бу булмаса, иртәгә кайтырсың. Эзләсәләр, нелегальный булып яшәрсең, берәр рәтен табармыз...

Давыд тентүдән, зинданнан, полиция эзләвеннән, бигрәк бу эшче хакында уйга китте: “Нинди яхшы, гамәли, акыллы сөйли, нинди рәвештә әмер бирә! Әле кайчан гына бу – исерек Абдул иде. Әле кайчан гына бу – хатынының актык нәрсәләрен сатып эчеп, урамда пычракта аунап, яланбаш сүгенеп кайта иде! Әле кайчан гына бу – падишаһка каршы сугыш, капитализмны җимереп, адәмне үзенә-үзе хуҗа, азат итү хакындагы бик гади

сүзләрне дә миенә сыйдыра алмыйча, ниндидер караңгы бер шөбһә белән башын кашый иде! Ә хәзер кем булган? Гаҗәп могҗизаларың бар синең, әй, революция!”

Почмакка җиткәч: “Безнең бергә баруны күрсәләр шикләнә башларлар, мин кайтам, иртәгә сине кайда күрим?”– диде.

Давыд шәһәр читендәге бер чәйханәне әйтте. Исәнләшеп аерылдылар.

– Инде кая барырга? Иң яхшысы Раузада булыр иде: ул фамилия, ул йорт полициядән дә әмин[1]. Бүлмәләре дә, бер рәхәтләнеп йокларга йомшак ятаклары да табылыр иде! Фу, ләгънәт, бу мещанның атадан калган хаталарына! Рауза үзе дә эченнән шатланыр иде! Ләкин ник бондый юк хыял белән баш ватарга? Ничек кенә дисәң дә, барып чыкмый торган эш: Алмасбикә боны ишетү белән, һушыннан язып үләчәк. Бөтен мещан сазлыгы Раузаның пакь намусына үзенең барлык пычрагы белән ташланачак!

Тукта, Нәфисәне күптән күргән юк. Вакыт соң-соңын, ләкин ни зарар: ул бит ире белән бергә тора. Габдрахман үзе дә бик чакырып йөри!

Егет килеп җиткәнен сизми дә калды. Бәхеткә, капкалары бикләнми икән. Әнә йорт уртасында ике катлы агач өй. Шуның түбәнгесе дигән иде, бугай. Ут та бар. Димәк, ятмаганнар. Бик аз гына шакылдату белән, эчтән берәү, йомшак, сак басып, ишеккә килде дә бераз куркынган тавыш белән:

– Кем бар?– диде.

– Мин, Давыд. Сезгә килдем.

Эчтәге кеше аптырап калды. Бер ачарга теләп тоткага тотынгач, куркып, тагы кире чигенде. Ачкыч өйдә калган икән дип каушап, калтырап яңадан эчкә йөгерде. Хәлбуки, ачкыч ишектә иде. Нәфисәнең болай каушавы – ире өйдә булмаудан, аның ахмакча көнләшүеннән иде. Туп-туры кертсә, ире дөнья куптарачак, кертми йибәрергә көче йитми – чөнки ишеккә аның беренче мәхәббәте, әле дә йөрәгендә изге дога кебек кадерләп саклаган Давыды килгән... Ни эшләргә белми аптырап өйгә йөгерсә дә, анда да киңәшергә һичкем юк... Җиде яшьлек Фәтхия белән ни киңәшәсең!

Давыд шунда торганда, артыннан берәү килеп, бик каты биленнән кочаклап алды:

– Менә рәхмәт, рәхмәт! Безне искә төшерми дип, Нәфисә үпкәли иде! Рәхмәт дигәч, рәхмәт!

Габдрахман ишекне бик каты дөбердәтте. Тегеннән бөтенләй икенче аяк басып килде, катырак тавыш белән:

– Рәхми, синме?– диде.

– Мин, Нәфисә, мин. Тизрәк ач, үзеңә кадерле кунак алып килдем.

---

[1] *Әмин* – тыныч, имин.

Беләмсең кем? Давыд иптәш, Давыд!

Керделәр. Нәфисә шатлыгыннан сүзен дә әйтә алмас булды, йөзе бер агарды, бер кызарды. Тыннары кысылды.

Урманов: “Сез тазаргансыз, чибәрләнгәнсез”, – дип, гади мактау сүзләре белән исәнләшеп, килә алмау өчен кат-кат гафу үтенде. Нәфисәгә дә бераз җан керде, бераз тынычлык килде.

Өе матур, бар кадәре белән бик пөхтә җыештырылган. Алгы бүлмә, зал, альбомнар белән тулы бер өстәл, граммафон, “Таң”[132+], “Урал”[133+] номерлары, боларның нәшрияты, тагы әллә ничаклы сәяси, әдәби рисаләләр тезелеп куелган кечкенә матур этажерка.

Давыд, сүз булсын дип, ханымның күңеле ачылсын дип, китапларга, газеталарга күз салды. Нәфисәнең шатлыгыннан йөзе балкый, күзләрендә нур уйный иде. Әллә нинди сүзләр әйтәсе, элекке кебек егетнең киң күкрәгенә, көчле beләкләр эченә акрын гына кереп, дөньядан югаласы, сүзсез, хәрәкәтсез шул хәлдә озак калып онытыласы килде. Ләкин, ләкин бу мөмкин түгел икән шул! Ашханәгә чыкты. Тиз арада аннан самавыр гөжләгән тавыш, май исе, кызган камыр исе килә башлады.

– Ни сөйләргә?

Ләкин Габдрахман аптырамады. Мәдрәсәдән, шәкертләрдән, приказчиклар хәленнән, кичә таралган прокламациядән, җиде революционерның асылуыннан, Думада Церетелиның[134+] шәп нотыгыннан башлап, Кадыйр байга, Һаҗәр-Җиһангир гайбәтенә, Баязид карыйга күчте. Истанбулга качкан Йосыфҗанның атасына телеграммы боларга да ирешкән икән. Кадыйр бай шул угылына, баш күтәргән шәкертләргә, приказчикларга, Һаҗәргә, Җиһангирга ачуыннан шартларга якын, акылыннан шашып бара имеш, ди. Боларның барына да сәбәп шул Давыд Урманов дигәннәре булды – безнең мөселман арасына фетнәне шул салды, шуны ник асмыйлар, дип әйтә, имеш, ди.

Баязид карый үз планнарын яшерергә тырышса да, без капчыкта ятмый икән шул. Габдрахман башта аның хакында акылдан язган, үз атасын үтерергә йөри, имеш, дип әйтәләр, диде. Аннан соң үз сүзен үзе үк төзәтеп: “Юк, анысы ялган инде, ул “Фидаиләр” партиясе төзеп, мулла козгыннарының башлыкларын бетермәкче. Бу эш башланса, үзем дә кушылам. Валлаһи, кушылам”,– дип бетерде. Тагы кинәт урыныннан сикереп торды, бөтенләй башка тавыш белән:

– Караңыз әле, чынмы икән, аны тотып япканнар, дип сөйлиләр, – диде.

Давыд бер-ике сүз белән хәбәрнең ялганлыгын аңлатты. Габдрахман шатлыгыннан кулларын чаба башлады:

– Менә рәхмәт сезгә! Яшәсен Баязид карый. Тизрәк килә генә күрсен.

Үзем беренче язылам, үзем беренче уларак мөфтине үтерергә барам...

Габдрахман сөйләнгәләп торганда, Нәфисәнең самавыры, сыйлары өлгереп килгән иде инде. Майлап, баллап, коймаклап бик озаклап, чәй эчтеләр. Ул арада Нәфисә эчке яктан ширма чыгартып, кәнәфидә Давыдка, мендәрләр, йомшак юрганнар эчендә югалырлык итеп, урын хәзерләде.

Нур белән, сөю белән мөлдерәп торган күзләрен ала алмыйча, бераз каушап, бераз калтыраган тавыш белән Давыдтан:

– Сез ничәгә чаклы йоклыйсыз? Иртән ашыгыч эшегез юктыр бит? – дип сорады.

Габдрахман аны кырт кисте:

– Ни юк-барны сорап йөрисең! Туйганчы йоклар. Бар, ят!

Нәфисәнең бирешәсе килмәде:

– Ходаем, җүнләп дәшсәң булмыймы? Сәгатьле хезмәте булып, безгә шелтәсе төшмәсен, дип кенә сорыйм.

Урманов рәхмәт укыды.

– Унда торсак ярар,– диде.

Габдрахман яңадан бер мәртәбә ятарга кушса да, Нәфисә тыңламады:

– Йокым килми, сезнең сөйләшкәнне тыңлап утырасым килә минем,– диде.

Давыдта Габдрахман өчен сүз юк. Ул гына булса, бер-ике җөмләдән соң, исни башлап, йокыга ятар иде. Нәфисә, җилкәсенә мамык шәл салып, бик рәхәтләнеп тыңларга әзерләнгән кеше кебек тирән креслога чумгач, егет ничек сүз башлаганын сизми калды. Ул гади вакытта матур сөйли алмый. Тасвирларында буяу сыек була. Ләкин үзе кичергән мөһим нәрсәләрне тыңлаучының йөрәгендә эз калдырачак рәвештә хикәя кыла торган чаклары да булгалый иде.

Нәфисәнең эчке бер ләззәт белән тыңлавы, аңа шундый чакларның берен бирде. Ул бер дә көчләнмәстән, йөрәгендә бик тирән эз калдырган вакыйгаларны – бигрәк тә беренче мәртәбә зинданда утырган заманын чыннан да матур, тәэсирле итеп сөйләде. Нәфисә сүзләрне ишетәме, аңлыймы, яки егетнең су кебек аккан тасвирияте эченә кереп югалып, икенче дөньяларга китәме, шундый бер хәлдә иде.

Бүген аның йөрәгендә үзеннән-үзе бер карар туды: иртәме-соңмы, теләпме-куылыпмы, һәрхәлдә ул боннан китәчәк.

Давыдның сөяркәсеме, асравымы, хатынымы, иптәшеме, яки этеме булып, һәрхәлдә аның янында, аның белә бергә яшәячәк, үзен аңа багышлаячак, аның авыр, ялгыз, мәшәкатьле көннәрен җиңеләйтергә тырышачак.

Нәфисә буңа план кормады, ничек булырын да уйламады – шулай

үзеннән-үзе килеп чыгар!

Болар ятканда таң якынлашып килә иде инде.

Нәфисә өчен бүгенге төн авыр газап булды. Габдрахманны яратмау бу төндә чигенә йитте.

Иртәнге сәгать унга өй йомшак җылынган, самавыр кайнап, коймаклар өлгергән иде.

Нәфисә агарып көйгән, иреннәре кипкән иде. Давыдка күп карамаска тырышты. Сүзгә аз катнашты. Тик ире бер генә минутка каядыр чыгып киткән арада, ихтыярын югалтып: “Ходаем, ниләр генә кылыйм, Давыд абый, миңа бигрәк кыен шул!” – дип, йөзе белән егетнең күкрәгенә егылды. Ләкин бу – бер секунд булды. Тиз айнып, яңадан өстәле янына йөгерде.

Давыд чыгып киткәндә, сәгать уникенче ярты иде инде. Яшерен басмаханәне күчертәсе, Шакир солдат белән кавказлы Гәрәй Солтанны күрәсе бар.

Үзенең хәле мәгълүм булмаганга, кичсез урамда күренмәскә, хәзер иптәшләрдән беренә барып, югары эшләрнең җаен карый башлар өчен, Тангатаровны чакыртырга булды.

Көн аяз, якынаеп килгән яз кояшы күз камаштыргыч бер нур белән балкый иде.

## LXXII

Яшерен басмаханә бик мәшәкать белән торгызылган. Боның өчен татар хәреф җыючыларыннан берничә иптәш, айлар буенча һәр көн азлап, үз матбагаларыннан урлап, хәреф ташыганнар. Шуның өчен икесе шөбһәгә эләгеп, берәр атна ятып чыккан, урыннарыннан куылган иде. Башта тырышып карасалар да, станок таба алмадылар. Ахырдан моның кирәге дә булмады: рус иптәшләренең яхшы ук тулы куелган яшерен матбагалары бар, болар шунардан файдаландылар. Моның өчен, ике татар хәреф җыючы егет берләшеп, шәһәрнең читендә бер өйгә, квартирга чыктылар. Шуның җылы базында төндә басар өчен, русларның яшерен басмаларына тапшыралар иде. Бер мәртәбә татар матбагаларындагы басучы (печатнигы) белән килешеп, Сафаровның зур матбагасында да бастыра алдылар.

Давыд Урманов белән сөйләшеп чыккач, Тангатаров русларга барып, хәлне белеште. Куркыныч чыннан да бар икән. Аларның басмаханәләрен табып, квартир хуҗасын, хәреф җыеп торган бер кызны алып киткәннәр. Анда татарча басылган прокламациянең таратылмаган наборы чыккан. Берничә йирдән боларның яшерен басмаларында эшләүче Гали белән Садыйкның адресын сораганнар.

Давыд тиз генә Җиһангирны чакыртты, басмаханәне ашыгыч рәвештә

җыеп алып күчерергә кушты.

Көн шулар белән үтте. Кичә Габдәһ абзый белән вәгъдәләшкән чәйханәгә барырга чыкса, юлда Заһидә җиңинең кызы Нурдидә белән зур гәүдәле, озын сары мыеклы бер авыл кешесенә очрады. Кыз якын ук килеп, әкрен генә тавыш белән:

– Абзый, тукта әле! Әткәй менә бу кешене сиңа йибәргән иде. Аның йомышлары бар икән, – диде.

Бу зур буйлы, сары мыеклы кеше – качкынның Шакир солдаты икән. Бер сүздән үк үрәдникне сүгәргә, йир юклыктан зарланырга, халыкның бик теләвен, ләкин кайдан башларга белми торуларын сөйләргә тотынды. Китаплар, язулар булмасмы, безгә кеше йибәрә алмассызмы, диде.

Аулаграк урамга борылып, бер пивныйга керделәр. Егет бер минут та уйлап тормыйча, ике иптәшенә үзләренең яшерен теле белән хат язды.

Тангатаровка: “Бу иптәшне бер йиргә утыртып куй да, һич кичекмичә Раузадан алып, һәммә китаплардан, прокламацияләрдән унарны бир!” Җиһангирга тагы катырак язды: “Шәкерт, приказчик белән ерак китеп булмаячак. Революция сиңа халык эченә китәргә бурыч йөкли. Венераларыңны ташла да Шакир абзый белән крәстияннәр арасына китәргә хәзерлән. Иртәгә китәр алдыннан миңа кереп чык. Кайдалыгымны Заһидә җиңи, яисә Рауза әйтер”.

Бу кыз, 12 генә яшьлек булса да, почта, йомышчылык хезмәтендә гаҗәп булдыклы, иптәшләрнең һәммәсенең диярлек квартираларын да белә иде. Хатларны шуның кулына тапшырды да Шакир солдатны Тангатаровка алып барырга кушты.

Чәйханә халык белән, зур ак чәйнекле өстәлләр белән, тәмәке төтене белән тулы иде. Иң эчке почмаклардан берендә Габдәһ абзый күренде. Аның янында үткен, усал карашлы, кипкән карасу йөзле, дегеткәме, башка бер майгамы буялып беткән кыска тунлы бер татар эшчесе утыра иде. Давыд: “Кавказлы Гәрәй Солтан шул икән”, – дип уйлап, туры яннарына барды һәм яңлышмады.

Өстәлләренә якынлашу белән Гәрәй үткен, усал күзләрен Давыдка юнәлтте, кинәт көлә төшеп:

– Сез Давыд иптәшме? Көтәбез,– диде, икенче өстәл янындагы буш урындыкны Урманов өчен китереп куйды.

Гәрәй Солтан берничә сүз белән үзенең кем икәнен, нәрсәгә хәзерләнгәнен аңлатты.

Ул Минзәлә өязенеке булып, ун елдан бирле Бакуда нефть базларында эшли икән. Бер хезмәт белән монда кайткан. “Таң”ны, “Урал”ны күреп, бик шатландым, ләкин эшегез бик артык ярлы күренә, ди. Бу хәлләр аның

йөрәген әрнеткәннәр. Партия ягыннан, кичә качкын Хәбиб әйткәнчә, элек меньшевиклар белән эшләгән, хәзер максималист икән.

Боны сөйләп бирде дә, суынган стаканын берьюлы эчеп, урыныннан тора башлады:

– Мондагы хәлләрне күргәч, мин Кавказга китмәскә булдым. Зур бер эш бар. Кәгазьләремне күрсәтермен, сезнең белән сөйләшәсе бар, монда куркыныч, әйдәгез аулак бер йиргә барыйк! – диде.

Һичкем игътираз итмәде[1], өчесе дә торып чыктылар.

Давыдта тентү булмаган, ләкин Габдәһ абзый: "Шундый бер ис аңкый, безнең квартирга бару куркынычсыз түгел, башка бер урын табыйк", – диде.

Иң уңае Җиһангир бүлмәсе иде.

Аңа барып, үзен бер йомыш белән Раузага йибәрделәр дә ишекләрен бикләп утырдылар. Гәрәй, торып, тәрәзә пәрдәләрен төшерде.

Давыд Габдәһ абзыйга гашыйк булып йөри иде. Кавказлы иптәш тагы башка күренде.

Бу тартыну белми, озаклап исбат итеп тормый, ике-өч җөмлә белән сүзен бетерә. Уе, планы гаҗәп ачык: организацияләр хәерче, гәзитә, китап таратырга акча йитми. Әгъзалык хакы, әдәбият кичәсе белән яшәү – бу адәм көлкесе. Монардан котылу өчен, эшне киң кую өчен, башка чара кирәк... Габдәһ абзый да белә, Ивановның агач заводындагы берничә эшче белән без сүз берләштек: якын арада кантор кассасын басарга булдык, ни дисез, ни ярдәм бирә аласыз, ди.

Давыд тиз җавап бирмәде.

Бу хакта ике сүз булырга мөмкин түгел. Кулдан килгәннең һәммәсен эшләрмез. Үзем бөтен авырлыгына катнашам. Тагы дүрт-биш бирә алырмыз. Партия белән сөйләшеп үтәрмен. План, ат кирәксә, бераз корал табылыр... Кайчан керешәмез?

Гәрәй Солтан бераз әрнүле җавап кайтарды:

– Партиягездән күп эш чыкмас, план дигәннең көче зур түгел, утка-суга курыкмый барырлык кешеңез булса, бер-икене биреңез... Извозчик белән корал кирәк булыр. Ачык, актык җавап өч көннән калмасын, юкса мин берүзем керешәм.

Габдәһ абзый Давыдның үзенең катнашуына каршы торды, без үземез башкарырмыз, сезне эләктерсәләр, эш башында кеше калмый, ди.

Гәрәй дә буңа кушылды, тыштан Габдәһ фикерен куәтләсә дә, эченнән: "Укыган халык бундый эштә файдасыз, әмма зарар итсә, бик мөмкин", – дип уйлады.

---

[1] *Игътираз итмәде* – каршы килмәде.

Өч көннән яңадан шул бүлмәдә очрашачак булып таралдылар.

Давыд Урманов бу төндә йоклый алмый, озак газапланып чыкты. Солтан Гәрәй аның күз алдыннан китми иде. Озын күн итеге, майланган кыска туны, күн фуражкасы, сөякләренә ябышып кипкән карасу үткен йөзе, усал кискен карый торган күзләре белән бу эшче аның алдында басып тора. Әрнү катыш кызганулы елмаюы белән гүя, боларны шелтәли: шәкерт, приказчик, гимназист атнага бер дә җүнләп чыга алмаган гәзит, әллә нигә бер прокламация, түгәрәкләр, "Иттифак әл-мөслимин" белән талашу – имеш, шулар белән революция тудыр! Имеш, истибдадның авыр туплар белән сакланган чуен диварларын, кәгазь мылтыктан атып җибәрергә маташ! Нинди көлке!

## LXXIII

Июньнең беренче атнасы, җәйнең матур көннәреннән, шуның белән бергә сәяси һаваларның бик куерган һәр ике якның актык көрәшләр якынаюын сизеп, артык дулкынлана башлаган чакларыннан бере. Күптән көтелгән атаклы революционер (пайтәхеттәге эшчеләр советы әгъзасы) Разин кичә генә килеп төште. Ашыгыч җыелырга куша. Үзара киңәшкәннең соңында, аның гомуми доклады-лекциясенә һәр ике партиянең дә кешеләрен чакырырга, Раузаның тәкъдиме буенча, елга аръягындагы урманга чыгарга, күз буяр өчен, бик шәп "пикник" төсе бирергә булдылар. Бунын тышкы эшләрен башкару Госман, Акчулпанов, Нәфисә, Заһидә җиңи һәм Раузага тапшырылды. Алар әллә ничаклы ашамлыклар алдылар, савыт-сабалар җыйдылар, берничә зур кимә хәзерләделәр, мәгълүм хәреф җыючылардан, шәкерт, приказчиклардан гармунчылар таптылар.

Шөбһә астында булмаганнар пикникка чыгучылар сыйфаты белән, шул савыт-сабалар, ашамлыклар, гармуннар күтәреп, һәммәсе бергә китәчәкләр. Күптән түгел кайткан качкын Хәбиб Мансуров, Зариф Булатов, Давыд Урманов, Баязид карый кебекләр төрле юллардан, берәр, икешәр кеше аерым кимәләр белән чыгачаклар.

Җиһангир, җырчы Сахиб, "ашказарчы" Вәли башкорт, гармунлы Сәйфуллин, алдан барып, урын сайларга, бертуктаусыз "Мәдинәкәй"не уйнап, җырлап торырга тиешлеләр.

Башкалар шуның буенча җыелачаклар.

Җыелгач та ашау-эчүне, уен-көлкене дәвам иттерергә, тирә-якта күзәтчеләр йөреп, аз гына куркыныч булса, гармунда "Ашказар"ны уйнарга тиешләр.

Разин иң соңыннан Габдәһ абзый белән барачак.

Булат белән Тангатаров бераз кичегә төште. Болар елга аша чыгып, кимәне яр буендагы агачларга бәйләгәндә, тегеннән гармун, скрипка, җыр, уен-көлке тавыш ишетелә, чыннан да пикник рухы килә иде.

Бераз читтәнрәк барып компаниянең өстенә килеп чыккач, аптырый калдылар.

Рәхмәт төшсен оештыручыларга, бигрәк тә ханымнарга, бу чын мәгънәсе белән пикник төсе алган икән. Киң яфраклы, карт куе агачлар уртасында йорт урыны чаклы ачыклык. Һәйбәт яшел үлән, чәчәкләрдән хуш ис аңкып тора. Шуның өстендә әллә ничаклы зонтиклар, киемнәр тезелеп ята. Урта бер йиргә зур ашъҗаулыклар җәеп, табын ясаганнар. Кем утырган, кем кырын төшеп яткан, кем уйный. Сахиб белән бер наборщик туктаусыз җырлый, башкалар хор белән күтәреп йибәрәләр. Кемдер, нидер сөйләп, ачык күңелле тавыш белә көлә...

Исәнләшеп, кайберләр белән күрешеп бетүгә, Булатның күзе беләкләре, күкрәкләре бик матур, ләкин бик артык ачык булган яшь, чибәр бер марҗага төште. Бу марҗага нидер сөйләп, көлдереп маташкан Гриша Булатка якын иптәш иде. Бармак ишарәсе белән аны чакырып алды да ачык күкрәкле чибәр ханымны күрсәтеп: “Бу кем, аның килүе хата түгелме?”– диде.

Бу – Гришаның сөяркәсе икән. “Курыкмаңыз, башым белән җавап бирәчәкмен, мин аны күренеш тулылыгы өчен алып чыктым”, – ди.

Ләкин Зарифны бу җавап канәгатьләндермәде. Ул кайбер кешеләрдән һичбер сәбәпсез шөбһәләнә, шул шөбһә күп вакыт урынлы чыга иде. Иптәшенә ышанып бетмичә, тагы текәлә төшеп карады.

Ханым сизенде булса кирәк, болар ягына борылды, күзләрен Булаттан алмыйча, Гриша янына килеп, аның кулындагы ридикюленнән нечкә ак кулъяулык алган булып, егет янында ялагайлана, иркәләнә башлады. Булат белән таныштылар. Исеме Вера икән. Кечкенә буйлы, нечкә, нәфис гәүдәле гаҗәеп кечкенә, гаҗәеп ак нечкә куллы бу ханым сәяси яктан гөнаһсыз бер бала икән. Танышу белән Булат хакында күп ишеткәнен, күптән танышырга теләвен сөйләде. Яңлыш бер сәяси мәсьәлә кузгатылгач, ай Ходаем, куеңыз, күңелсез, мин аны аңламыйм да, яратмыйм да... дип, музыка тавышы белән кәһкәләп көлде. Гришага иркәләнеп, сыенып, Булаттан күзләрен алмыйча, матур елмайды...

Беренче күрү белән Давыд та Хәбиб тә бунардан бераз шөбһәләнгәннәр иде. Ләкин Вераның матур күгелҗем күзләре белән мәгъсум[1] балалар кебек туры өзеп каравы, чәчәктән чәчәккә очып йөргән ак күбәләк кебек очып, канатланып, уйнап йөрүе, матур-матур елмаюы, аз гына бер сәбәптән дә

[1] *Мәгъсум* –гөнаһсыз.

көмеш тавыш белән аланны яңгыратып көлүе куркыныч бернәрсә юклыгын аңлаттылар.

Ләкин Рауза бу хатынны алып чыгуларын да, ир иптәшләренең, бигрәк тә Булатның аның белән кыланышуларын да гафу итә алмады. Ул үзе бүген артык җитди күренә, бөтен компаниягә тон бирә бара, тик шул күбәләкне җиңә алмавыннан гаҗиз иде.[1] Тыштан мактап, ирләрдән эш чыкмагач, үзе белән бер мәртәбә биеп тә алды, ләкин эчендә аңа дошманлыгы артканнан арта иде.

Мансуровның күзләре гадәттәге кебек усал түгелләр, йөзендәге катылык та дустанә елмаю белән бераз йомшара. Ул, бу компаниягә караган саен, иптәшләренә: "Бу тыштан гына түгел, эченнән дә пикник булып китте, бугай", – ди иде. Рауза бүген Булатовны берничә чәнечте, Хәбибкә бик яхшылап бутерброд ясап биргәч, Зарифка килеп: "Мескенкәем, Нина булмагач, боегып тора, ичмаса, үзем ухаживать итим",– дип, тәмле ашамлыклардан авыз иттерде.

Туташның җаны тыныч түгел иде. Түзмәде, һәркем бернәрсә белән мәшгуль вакытта, сиздермәстән генә, Давыд белән берничә минутка агачлар арасында югалып килде. "Күңелем нидәндер курка, ул-бу булса, мине калдырма, бергә кайтырмыз, синнән башка егылып үләрмен кебек тоям", - дип, ниндидер эчке бер куркыну белән егеткә сыенды. Урманов ничаклы тырышса да, туташ тынычланмады.

Егет белән кыз гомуми компаниягә килеп кушылганнар гына иде, күзәтчеләрдән бере килеп, бер көтү казачиның, атларын кыйный-кыйный, каядыр бик ашыгып чапканын хәбәр итте. Качкын, Раузаны чакырып: "Уенны, җырны көчәйтергә тырышыгыз", – диде. Булат, Баязид һәм Давыдка башы белән ишарә кылып, агач арасына кереп китәргә кушты.

Рауза, Давыд белән Нәфисә арасында кайчандыр, ниндидер бер роман булганлыгын ишеткән булса да, моны яшьләр арасында килеп үтә торган җиңел дулкыннарның бередер, дип уйлый иде. Бүген ул уенның хата икәнен, Нәфисә күңеленнән күренмәс бер ефәк җеп Давыдка таба сузылганын хис итте. Күзәтче хәбәреннән соң, Давыдлар агач арасына кереп югалгач, Нәфисәнең йөзе, иреннәре үлем кебек агарынганын күргәч, бунда шөбһәсе калмады. Ләкин көнләшү ихтималы юк иде. Киресенчә, матур йөзле, акыллы карашлы, сабыр, сөючән табигатьле бу яшь ханым аның йөрәгендә кызгану хисе уйгатты. Эш ташлап, Нәфисәнең янына барды, биленнән кочаклап алып:

– Ханым, иркәм, яшьләр бары да уйный, көлә, мин берүзем башкарып бетә алмыйм, миңа азрак булышсаңчы! – дип, кәгазь капларда тулып яткан

[1] *Гаҗиз иде* – көчсез иде.

ашамлыкларга, тәртипсез өелеп яткан савыт-сабаларга китерде дә үзе белән бергә эшләргә кушты.

Нәфисә бәхетлеләнеп үк китте. Туташ белән ханым бер минутта бер-берен чын күңелдән яраттылар. Рауза белән Нәфисә сөйләшеп, бик күңеллеләнеп, әйберләр рәтләгән вакытта агачлар арасыннан бер баш күренде. Карасалар, ашыга-ашыга Габдәһ абзый килә икән. Туташның йөрәге шу-у итеп китте. Нәфисәгә: "Акыллым, син бушата тор",– диде дә, йөгереп барып, ни бар, ни бар, дип, эшченең ике кулбашыннан алды. Аның йөзе үлем аклыгы белән кипкән, тыны кысылган иде. Әллә нинди авыр кайгылы тавыш белән:

– Сөйләмә, туганкаем, хәбәрләр бик артык күңелсез, – диде.

Рауза тәфсыйлен сорарга курыкты, Габдәһне ике кулыннан эләктереп алды да, ашыгып, куркып:

– Әйдә, әйдә, анда сөйләрсең! – дип, Хәбиб Мансуровларга таба алып китте. Озак эзләргә туры килмәде. Бер агач төбеннән аз гына төтен чыга иде, шуңа йөгерделәр. Анда Булат, Хәбиб, Давыд сузылып ятканнар, икесе тәмәке тарта, Давыд нидер сөйли иде. Раузаның куркып агарынган йөзен күрүгә, Давыд сикереп торып, аның кулыннан алды:

– Ни бар, Рауза, нидән бу чаклы курыктың?

Туташ, бүген иртәдән үк күңелем бер хәл сизә иде, мин белмим, әнә ул сөйләсен, диде. Үзе, кулларын өзгәләп, ни эшләргә белмичә, аптырап катты.

Давыд аны кочаклап утыртты да башын күкрәгенә алды. Кыз тартынмады, оялмады, шул хәлендә калды.

Габдәһ абзыйның хәбәре чыннан да күңелсез иде:

– Разин эләккән, Дума куылган, Думадагы социал-демократия фракциясенең илле әгъзасы кулга алынган[135+]... Столыпин[136+] диктатор...

Бу хәбәр революционерларны яшен суккан кебек ясады... Берничә минут, әйтерсең, телләре киселде, һичкем, һичнәрсә әйтә алмады. Иң элек качкын телгә килде:

– Тукта, иплэп сөйлә әле... Урам хәбәрләре генә түгелме? Габдәһ абзый, тын алып, тәфсыйлгә кереште.

Ул пикникка алып чыгарга дип, Разинның квартирына барганда, аны бер көтү жандармнар бүлмәсеннән алып чыгып килә булганнар, кулы артка каерып богауланган, ди.

Социал-демократлар фракциясенең кулга алынуы, икенче Думаның куылуы хакында да хәбәр кичә үк килгән булса да, губернатор, ни эшләптер, аны бүген сәгать икегәчә игълан кылмый торган...

Булат бер сүз белән вакыйганы аңлатты:

– Димәк, государственный переворот ясалды![137+] Димәк,

контрреволюция җиңде!!

Качкын Хәбиб Мансуров урыныннан сикереп торды, аның күзенә бөтен усаллыгы, ачу уты чыкты, йөзе ачудан кара көеп, иреннәре дерелди башлады. Бу минутта ул дошманы өстенә һөҗүмгә хәзерләнгән арысланны хәтерләтә иде:

– Ярар, – диде, – кусалар кусыннар, озакка түгел, менә без куганда үзләре чыдасыннар!!

Аннан соң бераз тынычланып, иптәшләренә карады:

– Менә нәрсә, иптәшләр: җылаудан, көенүдән файда юк, эшкә тотынырга кирәк... Иң беренче эш: теләсә ничек кенә булса да, Разинны коткарырга, качырырга, урларга кирәк... Теләсә ничек кенә булса да, күпме корбаннар биреп булса да...

Качкын, сүзен бүлеп, туташка карады:

– Рауза, сез тегендә барыңыз да пикникны туздырыңыз, кайтсыннар... Аннан соң Гришага әйтеңез, бире килсен!

Кыз бу әмерләргә авырсынмады:

– Гришаны чакырам, ләкин пикникны таратмыйм... Столыпин ачуын яшьләрдән алмаңыз, алар ике сәгать алдан белсә ни дә, соң белсә ни!! Уйнап-көлеп туйгач кайтырлар...

Хәбиб кызды:

– Мин сезгә әйтәм, кайтарыңыз, дип, ишетәсезме, кайтарыңыз!

Туташ үзенекендә нык торды:

– Ә мин әйтәм, кайтармыйм, хәзергә белмәсеннәр.

Бу мәгънәсез талаш кызачак иде, арага Урманов катнашты:

– Рауза, ник юкка киреләнәсез, без китәбез, сез дә калмассыз... Алар барыбер куркуга төшәрләр...

– Сез кайтыңыз, мин калам...

– Ах, ташлаңыз юкны!.. Сез монда калып та, барыбер уйнап-көлеп йөри алмыйсыз бит, калуда ни мәгънә!

– Ә... сез мине белмисез... Мин – артист... Мин йөрәгемдә кара җәһәннәм уты булса да, йөземә кояш нуры чыгара алам...

Хәбиб талашны куйды:

– Ну ярый, Рауза, калсаңыз калыңыз... Киткәндә сезне яңадан чакыртырмыз... Гриша килсен!!.

Рус бу хәбәргә катып калды. Разин кичә рус иптәшләренә ашыгыч доклад ясаган иде, шунда булучылардан берәү хакында, мәҗлес таратылгач, кемдер шөбһәле адәм дип сөйләде, шул харап иткәндер, ну, ни эшлибез, ди.

Качкын сүз алды:

– Менә нәрсә: безнең күбемез нелегальный, артымыздан күзәтәләр, син

бүген партия комитетын җыярга тырыш... Без дә барырмыз... Разинны, теләсә ничек кенә булса да, теләсә күпме корбан бирергә кирәк булса да коткарырга – качырырга кирәк... Партиядә карыйк та эшкә тотыныйк... Булмаса, мин үзем керешәм... Бетсәм бетәрмен.

Гриша вәгъдә бирде дә компаниягә китте. Хәбиб яңадан сүз башлады:

– Разинны партия ярдәме белән коткарырмыз, ләкин кавказлы Гәрәй Солтан ята бит. Аны асачаклар... Мин тәкъдим итәм: аны коткару чараларына керешергә... Хәзер миннән, сездән бигрәк, Гәрәй Солтан кебек каһарманнарның дәвере килде...

Моңа һәммәсе риза булды. Тәфсыйлен бүген кич үк эшләргә карар иттеләр.

Ул арада тегеннән, канатлары сынган кош кебек, йөрәгеннән имгәнеп, Рауза килде:

– Булмый, булмый, иптәшләр, әйдәгез кайтамыз, мин тегеләргә әйттем... Таралалар, – диде.

Җиһангир, Баязид карый, җырчы Сахиб, Акчулпанов, Госман, Тангатаров, Габдрахман, Фәхри, Нәфисә, тагы башкалар да, йөрәкләреннән яраланган кешеләр кебек агарынып, болар янына килә башладылар.

Булат бер-ике сүздә вакыйганың мәгънәсен аңлатты. Хәбиб, таралып, төрле йирдән кайтырга кушты. Ахыр сүз итеп:

– Иптәшләр, үзегездәге нәрсәләрне төрле кулларга бирегез, ныграк яшерегез: хәзер тентүләр, тотып ябулар, асу-кисүләр башланыр, – диде.

Революционерлар, вак-вак төркемнәргә бүленеп, төрле юллар белән таралдылар.

**II**

# I

Сафа карт капканы үзе ачты.

Йорт уртасында арба майлап торган зур ялчы эшен ташлады да, кунакларга каршы йөгереп килеп, атларны җитәкләп кертте. Кыңгырау тавышына өйдән бер кыз бала атылып чыкты да яңгыр белән юешләнеп беткән атларга, баштанаяк пычранган тарантаска, өстләре, йөзләре балчык белән чобарланып беткән кунакларга карап аптырап калды, таныгач, иң элек:

– Мулла абзыкай, мулла абзыкай! – дип, атларга каршы очты. Абзыкасы янында ниндидер ят кеше утырганын күргәч:

– Җиңги, сөенче, җиңи сөенче: мулла абзыкай кайтты! Мулла абзыкай кайтты!! – дип, кире өйгә йөгерде.

Нигъмәт казый белән җырчы Сахиб арбадан төшәргә дә өлгерә алмадылар, аларның тирәсен күршедән, урамнан җыелган әллә ничаклы бала-чагалар, яшүсмер егетләр чолгап алды.

Сафа карт, аягында читек-кәвеш, чалбарсыз, тезенә төшеп торган аксыл күлмәктән, өстендә буйлы бикасап камзул, башында бохара кәләпүше, кулында комган булдыгы хәлдә, балаларны: “Бер читкәрәк китеңез, аттан тапталырсыз”, – дип куа, ләкин ачуланмый, аның йөзе, күзләре бертуктаусыз көлә, зур, таза гәүдәсе бундый шатлык сәбәбеннән яшьләрчә җиңел кузгала иде.

Нигъмәт хатыннар ягына, Сахиб кунаклык ягына кереп исәнләшеп, сәлам биреп чыктылар да җуынырга тотындылар. Аларга җиз комганнарга салып, җылы су хәзерләгәннәр, ялчы биш көре[1] белән эшләнгән өр-яңа сөлге тотып тора, кайдандыр исле сабын да тапканнар иде...

Карт үзе икендегә тәһарәт ала, кычкырып, догаларын укый, шулар арасында ук:

– Рәхмәт, бик рәхмәт инде, угылым, вакытында кайтуыңа... Без генә түгел, сине бөтен ил көтә иде!.. – дип, Нигъмәткә рәхмәт әйтә...

Җуынып, сөртенеп беткәч, үзенең кунак иптәшенә карап: “Менә шул инде безнең атайның дөньясы”, – диде... Йортка күз йөртеп, гүя беренче күргәндәй:

– Аба... әткәй, син бик баегансың икән ләбаса... Капканы тимер белән ябып, яшелгә бояткан... Өйләрнең икесен дә яңадан сипләтеп, тимер белән яптырган... Җитмәсә, тагы бер келәт арттырган... Мунчаны да яңарткан... Күз тимәсен, бакчаны да рәшәткә белән әйләндергән... Харап икән синең эш...

Карт кәефләнде:

---

[1] *Көре* – туку станогында, буй җепне күтәрү-төшерү өчен, җеп элмәкләр беркетелгән кыса.

– Тәңренең биргәненә шөкер, балам... Үткән ел Михаилдан унике сажин урман алган идем. Синең бәхетеңә каршы, бик яхшы чыкты... Осталар да ару кешеләр туры килгәч, бер кузгатканда, барын да эшләтим, дидем... Өстәвенә, мәсҗедкә, мәптеккә дә әллә ничаклы агач ботагы бирдем... Бакчаның рәшәткәсе, дисең... Рәшәткә – рәшәткә инде ул, син аның эченә керсәң, тәүбә эстәгъфируллаһ, оҗмах бакчасы дип уйларсың: килен, син кайта дип, көн-төн бакчада эшләде, аны йимеш агачлары белән тутырды, чәчәкләр үстерде.

Картның күңеле өчен, бакчаны килеп карадылар.Ул чыннан да чибәр иде. Йимешләр өлгереп утыралар, байтак ялан чәчәкләре дә бар иде. Бер башлагач, карт бакча белән генә тукталмады, бөтен йортны, яңа ясалган ныклы эш арбаларын, келәтләрне, анда ашлык белән тулы өсәкләрне[1] күрсәтте, ындыр ераграк иде, бармадылар, карт анда утырган өч зур кибәнгә бармагы белән ишарә кылып:

– Әнә саклыгым да бар, өч кибән еллатам. Ходаныкын белеп булмый, кайбер елда чәчәсең, чәчәсең дә, бөтен ялан кара кала... – диде.

Нигъмәтнең яшь әнисенең кызы Мәргубә килеп:

– Әткәй, чәй өлгерде, кереңез инде, – диде.

Нигъмәт сеңелесен аз гына, салкын гына сөеп, кесәсеннән конфет чыгарып бирде. Бала шатлыгыннан канатланып очты.

### II

Нигъмәт хатын-кыз ягына китте. Сафа карт Сахибне: “Әйдә, шәкерт, рәхим ит”, – дип, туры урам як өйгә алып керде.

Йорты, келәтләре, ындыры кебек, хуҗаның өй эче дә бик тулы иде. Ишек буенда уңда да, сулда да әллә ничаклы туннар, толыплар, бишмәтләр эленгән. Бик яхшы агартылган мич буена ярты баш шикәр, кадаклы чәйләр, буй-буй сабыннар тезелгән. Мич белән ишек арасында зур җиз таз, эреле-ваклы берничә җиз комган тора. Сул як почмакта һәртөрле савыт-сабалар, тәрилкәләр, чынаяклар, таш табаклар, бал, май савытлары белән тулы шкаф. Шуңа терәлеп, түргә таба кызыллы-сарылы калайлар белән чобарланган ике зур сандык. Аның аръягында үзенә күрә чибәр генә өстәл, зур ук көзге, сул якның түр почмагында киҗеле чаршау корылган киң карават, аның өстендә матурлап өелгән түшәк, ястык, әллә ничаклы мендәрләр, өйнең бөтен диварлары диярлек авыл кызының бик мәшәкать белән чибәрләп нык итеп эшләнгән киҗеле сөлгеләр белән асулы[2]... Идәнгә киез, аның өстенә авыл эше

---

[1] *Өсәк* – келәттә ашлык, он һ. б. ш. салып саклау өчен, такта белән бүлеп ясалган урын яки зур әрҗә.

[2] *Асулы*, ягъни *асылган*. Бу урында *эленгән* мәгънәсендә.

келәмнәр җәелгән, аның өстенә кара юрганнар түшәп, кечкенә табынлык ясаганнар.

Болар кергәндә, шул идәндәге табынлыкка чәй, ашамлыклар куелган, зур ак самавыр гөжләп кайнап тора иде.

Сахиб, гадәт буенча, сәлам бирде дә өстендәге иске юка пальтосын салды. Карт аны: “Түргә уз, шәкерт, түргә”, – дип, өстәлгә китереп утыртты.

Ул арада Нигъмәт казый килеп керде дә кунакны чәйгә утырырга чакырды:

– Әткәй, мин сиңа үземнең якын шәригем Сахиб иптәшне алып килдем. Бу – ятимлек, фәкыйрьлек белән тырышып укып, кеше булган бер егет. Миңа ни булса ул, сез аны кунак итегез, – диде...

Карт рәхмәт укыды:

– Рәхим итсен, рәхим итсен, без талибелгыйлемнәр[1] фатихасы белән торабыз, – диде.

Болар чәйгә утыргач, манарада мөәззин күренде, ахшамга азан әйткәне ишетелде. Карт эчке акрын тавыш белән:

– Аллаһ гафу итсен, ахшамга азан әйтә, шулай да сезне ташлап китәсем килми инде! – диде.

Ул арада ишектән бер бала кереп:

– Сафа бабай, әткәй сезне ашка чакырды, кунагын да, Нигъмәт казыйны да калдырмасын, дип әйтте, – диде.

Сахиб карышса да, ихтыярына куймадылар. Мәҗлестә кеше күп, урын тыгыз, ит бик артык симез, бәлеш май эчендә йөзә иде.

Сахиб сөйләргә сүз тапмады, ләкин Нигъмәт казый йөзде: икенче Думаның куылуыннан, социалистларның ябылуыннан, Столыпинның диктатор булуыннан, хәзер эшләр кире китүеннән башлап, Садыйкның атына, Вәлинең йиренә, Шәймәрданның бозавына чаклы барып җитте. Мужиклары да, мулласы да авыз ачып тыңлыйлар иде. Сахиб Нигъмәт казыйның сәяси мәсьәләләрдәге сүзләренә бераз гаҗәпсенеп карады: ул бунда ничектер сулрак күренә, социалистларны яхшы яктан күрсәтә, Столыпинны урыс бояры дип атый, өмиднең зуры эшчеләрдә икәнен аңлата иде.

Бондан чыккач, тагы ике йирдә аш бар икән. Сахиб иптәшенең колагына: “Бара алмыйм, карыным шартлый бу сыйлардан”, – дип караса да, Нигъмәт: “Юк, юк, ярамый, түз, әйдә барамыз”, – диде, иркенә куймыйча алып китте.

Боларда да кеше күп, урын тыгыз, ит симез, бәлеш майлы иде. Бонда да

---

[1] *Талибелгыйлемнәр* – укучылар, шәкертләр.

Нигъмәт казый сәясәттән башлап, тавык-чебешләргә барып җитте. Мужиклар аңа бөтенләй гашыйк булып, безне искә төшереп кайтуыңа мең рәхмәт, дип кайта-кайта сөйләделәр.

Итләрдән, бәлешләрдән котылып өйгә кайтканда, сәгать унике иде инде. Ни күрсеннәр, өйдә тагы, җиңел аш дип, сөтләп, дөгеләп, тавык итеннән өйрә пешергәннәр, май-бал, майлы коймак, вак бәлеш белән чәй хәзерләгәннәр.

Ни чара, тагы утырдылар.

Сахиб бик аз гына шулпа белән сөтсез куе чәйдән башка нәрсә каба алмады, Нигъмәт күп ашамады, ләкин карт, юрганга аяк бөкләп, тавыкка да, майлы коймакка да кирәген бирде. Үзе авыз тутырып чәйнәгән хәлдә:

– Мәдрәсәдә ач ятып, эчеңез кыркылып беткән, шуңа күрә ашый алмыйсыз... Бездә күбрәк торсаңыз өйрәнерсез әле! – дип, туктамый сөйләнә иде.

## III

Чәйдән соң өчесе өч якка мендәрләр өстенә аудылар. Карт авыр, басынкы тавыш белән сүз башлады:

– Нигъмәт, синең белән сөйләшермен, дигән идем, теге карт туры бия ябыграк, җирәнен суярмызмы икән? Аның аягы да имгәнгән!

Нигъмәт казый аңламады:

– Җәй көне ник бия суярга? Аның ите бозыла бит, кышка да өлгерерсең әле!

Карт җиңелчә көлде:

– Бозылу кайда ул? Бер бия җитмәс тә әле: монда бөтен тирә-як синең кайтуыңны дүрт күз белән көтте...

– Син ни сөйлисең, мин аңламыйм...

–Нәрсә аңламаска, ди: син бит мөфти хәзрәткә кереп, имтихан тоткансың, мөдәррислек алгансың... Укуыңны бетерден, мин монда, син кайтканчы, тамга җыеп куйдым... Указ котлау өчен, бия суеп, туй ясыймыз... Башкортлар болай ди: “Сафа карт, син бу елларда бик саранландың, күптән сыйлаганың юк”, – дип йөриләр.

Нигъмәт агарынды, мендәргә кырын яткан йиреннән кинәт йөрәгенә чәнчелгән кебек сикереп торып утырды.

– Чү, атай, син нәрсә сөйлисең? Нинди указ, нинди тамга да нинди туй!!

Карт аптырамады:

– Нинди тамга була димени? Сине югары мәсҗедкә мулла итеп

сайладылар... Бөтен мәхәллә, берсе дә калмыйча, тамга салды... – дип, урыныннан торды да, дивар буендагы сандыкларның берсен бик каты шыңгырдатып ачып, олы табаклы кәгазь китерде. Анда: “Кулым куйдым”, “Тамгам салдым”, – дип, йөзләрчә кешенең исеме язылган, чүкеч, урак, дага, ыргак сурәтләре төшерелгән иде...[138+]

Егет тагы үзгәрә, кискенләшә төште:

– Атай, бу ни кылганың синең? Миңа хәбәр итү юк, сорау юк, буласыңмы дию юк, имеш, тот та имам яса, тамга җый! Бу ни эшең бу? Теләсәң, мең тамга җыйна, мин барыбер мулла булмыйм әле!!

Сафа, күзләрен дүрт итеп, урыныннан торды:

– Бу нинди сүз тагы! Йөрүең аз булдымы? Минем сакалым агарды, хатының менә сигез ел инде туктаусыз җылый... Кодалар белән үпкәләшеп беттек. Килгән саен, бер угылыңа баш була алмыйсың, артыңы белмәгәч, өйләндермәскә кирәк иде, дип әрлиләр... Син әле һаман дөнья гизмәкче буласың, һәр эшнең бер чиге була, мине кая куясың, хатыныңның күз яше кемгә төшәр, дип уйлыйсың?!

– Атай, уеныңмы, чыныңмы? Ишетәмсең, мин мулла булмыйм әле!!

Атаның күзе, үткенләнеп, угылына карады, тавышы кискенләнде:

– Тукта, син кайчан дөнья көтә башларга әйтәсең: яшең утыздан артты. Каргалы Садыйк хәзрәт мәдрәсәсендә хәтме көтеб кылдың[1], остазың: “Нигъмәтнең моталәгасе чыкты, хәзер аның өчен һичбер мөшкил мәсьәлә юк, ни алса, шуны белә”, – ди торган иде. Аның белән канәгатьләнмичә, җәдидкә – мәдрәсәи исламиягә күчтең... Моны тәмам итәм дә мулла булам, дидең... Без көттек, мин синең өчен, карт башым белән дөнья кудым...

– Көттең, бик рәхмәт, ләкин мин ике генә көнгә кайттым. Иртәдән соң китәм...

Атаның күзе дүрт булды:

– Ул ни дигән сүзең тагы? Кая китәсең? Ике зур мәдрәсәдә “хәтме көтеб” кылдың, моталәгаң чыкты, мөдәррислек алдың, болар аръягында тагы гыйлем бармы?

– Бар, әткәй, бар. Тагы бар... Мин, русча укып, учительлеккә имтихан бирәм...

Карт ачу катыш мәсхәрә белән көлде:

– Менә сүз: имеш, учитель була! Нәрсәгә исе киткән, учитель булып, айга утыз сум алырсың, кирәк икән, мин сиңа бүгеннән үзем айга алтмыш сум бирәм.

Нигъмәт тиз җавап бирмәде. “Эш акчада түгел, гыйлемдә, әткәй”...

---

[1] *Хәтме көтеб кылдың* – укып тәмамладың.

Карт дәшмәде, авыр сулап: “Уффф...”– дип куйды.

Сәгать икене сукты. Нигъмәт, Сахибкә хәзерләнгән урынны күрсәтеп, хатыны янына йокларга чыкты.

---

## IV

Угылы чыгып китүгә, карт, әрнеп, рәнҗеп, аптырап, тагы сүзгә кереште:

– Балам Сахиб, акыллы күренәсең, җаным әрнегәнгә сөйлим, гаеп итмә. Ата-анаң булмаса да, йөрәгең сизәр. Менә бердәнбер угылым Нигъмәт, аны егерме биш ел укытам... Үзем көн-төн дөнья куам, мал җыям... Намазга, дога укырга вакытым да җитми. Динемә кимчелек китереп бетәм... Инде тынам дип торганда, ул тагы китмәкче! Әйтеңез, сез нинди халык, сезнең кашта[1] ата-ана хакы юкмы? Сезнең хәлфәләр, сез укыган китаплар ата-анага каршы барырга, аларның сүзенә колак салмаска кушамы? Нигъмәт акылсыз бала түгел. Гыйлеме дә зур, бөтен тирә-якта аны пәйгамбәр кебек йөртәләр... Борын шәкерт вакытта мәҗлесләрдә муллаларны тетеп сала иде, хәзер аны куйды, инде күбрәк дөнья көтәргә өйрәтеп сөйли... Бер кайтканда, халыктан гошер җыеп, алты почмаклы зур мәктәп салдырып китте. Икенче берендә, башкортлардан йир вәкыф[2] кылдырып, мәсҗед, мәдрәсәне юлга салды, мөгаллим китереп, аңа жалунья бирдерде... Халык үзен бик ярата, ул ни кушса, шуны эшли. Менә күрерсең, ул кайтканын ишеткәч, иртәгә өйлә намазына килгән халык мәсҗедкә сыймас...Ә башка вакыт карт-корыдан башка һичкем булмый. Бары да анардан файдалы сүз ишетергә, аның вәгазен тыңларга дип киләләр...

Менә шул бала, иленнән бизеп, әллә кая кача... Бу ни дигән сүз? Минем башым боларны сыйдыра алмый... Хатыны сигез ел буенча җылап көтә... Ходайга шөкер, дәүләтем бар. Бу дәүләтне җыю өчен, мин ниләр күрмәдем, кеше рәнҗеткән чагым да булды... Без үзебез, асылда, Пенза ягыннан. Ун яшьтә чагында агам мине Себер ягына алып китте. Шунда сатуга өйрәндем... Агай үлде... Бераз мал җыйгач, менә шул Орски өязенә килеп, йир алдым, сәүдә башладым. Шунда, хатын алып, йорт кордым... Дөньяда мин эшләмәгән эш калмады. Барын маңлай тирем белән таптым... Инде ул шул дәүләтне ташлап китә. Борынгылар, Мисырда патша булганыңнан, Кәнгандә гидай[3] булу артык, диләр иде. Сезнең китапларда бу сүз юкмыни? Ул урынлашса, мин дөньяны аңа тапшырыр идем дә, үзем гыйбадәтем белән

---

[1] *Кашта* – биредә: *карашыгыз буенча* мәгънәсендә.
[2] *Вәкыф* – җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.
[3] *Гидай* – хәерче.

үткәрер идем... Үлем-җитем бар бит, сакал агарды, газраил дә ерак йөрмидер... Иртән торсаң, намазга барып, ишракны тутырып[1] кайтсаң, Коръәнеңне, догаларыңны укып ятсаң, аннан, йорт-йиргә азрак күз салып, өйләгә барсаң, икенде, ахшамын, ястүен догасы, нәфелләре белән ашыкмый, иркенләп үтәсәң, рамазан шәрифләрдә мәсҗедкә игътикафка[2] керсәң, насыйп булып, хаҗга да барып кайтсаң, миңа артык бер нәрсә дә кирәкмәс иде. Ә мин хәзер намазның фарызларын чак-чак үтим... Кайбер вакыт ашыгыч бер эш хәтергә килә дә сәҗдәгә яткан йиреңнән йөгереп кайтасың... Ә ул шуларны аңламый...

Сахиб ни дияргә белмәде. Аңа бу сүзләр бик иске, аның иптәшләре бары да мондый фаҗигаләрне үткәргәннәр, кайберләре, җиңелеп, аталар сүзенә буйсынганнар да иде. Ләкин Нигъмәтнең җиңелмәячәге анарга мәгълүм иде. Ул картны җуатырга тырышты:

– Аңламый түгел, аңлый, бик аңлый...Ул озакка китмәс... Күп булса, бер ел йөрер, – диде.

## V

Карттан котылып йортка чыкса, анда Нигъмәт казыйны күреп аптырый калды. Бу бер генә минутка һава алырга чыккан икән.

– Менә, Сахиб, күрдең инде минем тормышны, – ди, – бер яктан әти, мулла бул, дөнья көт, ди. Икенче яктан хатыным, бу бәхетсез җан үкереп җылый: сигез ел көтәм, яшьлегем үтә, син булмагач, дөньяның ни тәме бар, китмә, китмә, дип ялвара...

Егетләр тиз аерылыштылар.

Сахиб иптәшенең хатыны белән булган фаҗигасен күптән белә иде. Үзе мәдрәсәдә чакта, аңа кыз ярәшеп, эшне бетереп куйганнар. Бу, яшьлек белән, каршы бара алмаган. Сигез ел элек кәләше куенына кергән, хатын ямьсез түгел, ләкин артык надан, артык авылча. Башка хасияте дә юк. Ике арада бөтен мөнәсәбәт – тик хайвани якынлык.

Нигъмәт аерылу фикере белән кайткан иде. Теләсәң торырсың, ләкин сине бәйләмәс өчен, теләгән вакытта китәргә хаклысың дип, язу калдырмакчы иде. Буны әйткәч, һушыннан язды, яшьлегемне син дип үткәрдем, инде мине куарга уйлыйсың икән, дип, акырып җылый, ди.

## VI

Иртәнге чәйгә хәзерләнгән сыйларның исәбе-хисабы юк иде. Көн тагы ашка йөрүләр белән үтте.

---

[1] *Ишракны тутырып* – иртәнге намазга барып, кояш чыкканчы мәчеттә булып.

[2] *Игътикафка* – гаепләреңне, гөнаһларыңны танырга, тәүбә итәргә.

Төнге уникедә өйгә кайтып, ахыргы чәйгә утыргач, кичәге мәсьәлә тагы кузгалды. Ләкин бу юлы артык кызмады, тиз киселде.

Сүзне ата башлады:

– Угылым, синең чыныңмы, уеныңмы, кичәдән бирле мин акылдан шашам инде...

Нигъмәт мөмкин кадәрле тыныч, ләкин яңадан сөйләргә урын калдырмаска теләп җавап бирде:

– Әткәй, син минем ике сөйләмәүне беләсең бит, нигә юк өчен кан бозасың... Мин иртәгә өйләдән соң китәм...

Карт угылының табигатен яхшы белә иде, сүз көрәштерүнең файдасызлыгын аңлады... Шулай да тагы бер талпынды:

Мин йибәрмәсәм!

– Ничек тотасың, бәйләп куя алмыйсың бит! Киленеңезне аналарына илтәм дә кайткан юлымнан кире китәм!!

– Ә безне ни эшләтәсең?

– Хәзергечә торырсыз шулай. Җәй, иген җыйган вакытта, бер-ике айга кайтырмын...

Карт җиңелде:

– Ярый, угылым, ярый... Тәүфигыңда бул, бала түгелсең, юкка йөрмисеңдер инде... Ахырдан, кайтып, мулла булырсың бит?!

– Әлбәттә, булам, мулла да, мөгаллим дә, учитель дә булам. Шулай итмәгәндә, бу халыкны җиңеп тә, агартып та булмый...

Карт, бераз җиңеләеп, тын алды:

– Ярар, балам, ярар, хәерлегә булсын! Хатының бик җылый, аны җуатырга тырыш. Акчаң бармы?

– Аны сорама инде! Булса бир, булмаса, азактан берәр нәрсә сатып йибәрерсең!

– Ник сатарга, ди? Әлхәмделиллаһ, кул буш түгел әле. Дәүләт синең үзеңнеке инде. Яшь анаңда бераз кәгазьләр бар, шуннан кирәгеңне алырсың!

Икенче көнне өйләдән чыгуга, байның яхшы тарантасына шәп пар ат җигелгән, кыңгыраулар тагылган иде.

Нигъмәтнең фән ягы учительлектән әллә никадәрле югары булса да, русча аны бик артык газаплый иде. Шул явыз дошманын җиңү, һәрвакыт русча гына сөйләшү өчен дип, татар аз, танышлар бер дә юк шәһәргә – Самарага барырга уйлады.

Нигъмәт казыйның китү хәбәре байтак кешене, кыңгырау тавышы бөтен тирә-якның бала-чагасын җыйган иде.

Кемдер азан әйтә, хатыны кеше алдында, аз гына да тартынмыйча, акырып җылый, атасы, хатыңны еш яз, укуыңны тизрәк бетереп кайт, дип

вәгазьли... Кайберәүләр белән күреште, барыңыз да исән булыңыз, диде, сәламәтлән, нык аша, хат язармын дип, Сахиб белән үбеште дә арбага утырды.

Атлар кузгалды, балалар кычкыра башлады, җылавы бик авыр рәвешкә кергән хатынны йитәкләп алып керделәр.

---

Сахиб башта кунакка бер тамак туйдырырга дип кенә килсә дә, Нигъмәт аны бу авылда мөгаллим булып калырга димләде. Бу ел русчага тотынырга сәламәтлегең дә, акчаң да юк, бунда торсаң, икесе дә булыр иде. Сафа карт: “Кал, шәкерт, кал, үз угылым кебек тәрбияләрмен, син булгач, миңа да җиңелрәк булыр”, – диде.

Сахиб калды.

Бу көн 1907 нче елның 10 нчы июле иде.

## VII

Сахиб бу авылда елдан артык торды.

20-25 ел буена сузылган ачлык, мохтаҗлык, ахрысы, аның әллә кай йирләрен өзгән, киптергәндер: карт үзе дә, ил халкы да бик кадерләсәләр дә, артык тазара алмады, шулай да адәм төсе керде. Матди як та начар булмады. Ул монда бик артык ярлы килгән иде, баштанаяк киенде, калага баручы бер кеше табып, байтак китап та алдырды, шулар өстенә, йөз егерме сумлап акчасы да җыелды. Бу аңа 6-7 ай укырга җитәчәк иде. Тик картның бер дә йибәрәсе килмәде, Нигъмәтнең дә, мин кайтканчы китмәсәң иде, дип, хат саен үтенүе генә аны бунда тота иде.

Көтелмәгән бер бәхет аны коткарды.

Тирә-яктагы берничә мөгаллим өстеннән ниндидер бер карт мулла, алар кызыллар, алар падишаһка каршы халыкны котырталар, дип әләкләгән, имеш, дигән хәбәрләр йөри. Шуларның иң алдагысы Сахиб дип күрсәтелә иде.

Көннәрдән бер көнне Сафа байга үрәдник килеп төшә дә, бакчага үзен генә алып кереп, картка нидер сөйли.

Чәй эчәргә керми, пот ярым бодай оны белән биш кадак сары май, ике такта[1], берничә баш мунчала ала да кайтып китә.

Анардан соң бай Сахибкә серне ача.

Үрәдниккә югарыдан әмер килгән: Сахиб өстеннән күз-колак булырга, аның үткәнен, хәзер ниләр сөйләвен тикшерергә, аз гына бер нәрсәсе сизелсә, тотып, Орскига озатырга ... Ләкин Сафа карт күз күргән кеше булганга, үрәдник моны алдан хәбәр итә, Сахибны озатырга куша...

---

[1] *Такта* – такта чәй турында сүз бара.

Карт чыннан да кайгырды, ләкин мондый куркыныч булгач, китмә, дияргә дә батырлык итә алмады.

Бер көн эчендә Сахибның керләрен юдылар, әллә ничаклы юл азыгы хәзерләделәр, тимер юлга илтергә дип, пар атны солыга куйдылар. Карт үзеннән, килене, ике хатыны исеменнән садака бирде, ике арба арыш гошере дип алты сум, дога кылдырды.

Таң алдыннан Сахиб юлга чыкты, биш көннән барып җитте.

Көзнең яңгырлы, бик пычрак көннәреннән бере иде. Ләкин бу Сахибка аз гына да әсәр итмәде[1]. Сәламәтлек ярыйсы, өст-баш бөтен, тамак тук, кесәдә йөз сумлап акча бар – Сахиб бит бундый бәхетне гомерендә дә күргәне юк иде. Җитмәсә, үзе Казанда, татар революциясенең учагында, менә бүген үк иптәшләрен дә күрер!!

Шундый күтәренке рух белән урамга чыгып, гәзитә сатучы малайлардан “Таң”[132+] белән “Урал”[133+] сорады. Болар аңламады, бер-берсеннән, андый гәзитә бармыни, дип сораша башладылар. Алар урынына пиво, сабын игъланнары белә тулган “Бәянел-хак”[139+], “Йолдыз”[140+], “Вакыт”[141+] тәкъдим иттеләр. Егет: “Болар ни белсен соң”, – дип, татар китап кибетенә керде. Каракуль бүрек кигән бер егет сату итә икән.

– Сездә “Таң” белән “Урал” бармы?

Сатучы егет елмайды:

– Сез әллә теге дөньядан кайттыңызмы? Хәзер ни эшләп андый гәзитәләр булсын!

Сахиб, бераз уңгайсызланып, үзенең шәһәрдән, почтадан да ерак йирдә, Урал башкортлары эчендә булганын икърар итте[2].

– Ул гәзитәләр булмаса, аларның нәшриятыннан китаплар бардыр, шуларны биреңез...

– Ул китапларны хәзер сораучы юк. Шуңар күрә алдырмыймыз, тентүләр була икән дигәч, үземез дә бар кадәрлесен дә яндырдык!

Сахиб, аптырап, бернәрсә аңламыйча чыгып китте дә иптәшләрен эзләргә тотынды.

Иң элек Давыд Урмановның “җәһәннәм” базына барды. Ни күрсен: әллә нинди бер ярлы итекче, ул да исерек, бернәрсә аңламый да, аңлата да алмый... Шул ук йортта Габдәһ абзый бар иде бит, аның квартирына төште – бер хатын җылап утыра: кайда икәннәрен белмим, алар хәзер порох заводында эшлиләр, бугай, квартирлары да шул тирәдә булыр, ди.

Егет тагы аптырый төште: кемгә барырга, кайдан табарга?

Йөри торгач, ак юртак белән акрын гына атлатып барган бер кешегә

---

[1] *Әсәр итмәде* – тәэсир итмәде.
[2] *Икърар итте* – сөйләп бирде.

очрады. Йа Ходай, бу – Йосыфҗан бит, менә бәхет!!

Сахиб, аз гына да тартынмыйча: “Йосыфҗан, тукта!”– дип кычкырды. Теге әллә танымады, әллә танымамышка салынды, туктап сөйләшәсе урында, атын сугып чаптырды!

Йөри торгач, Җиһангирга очрады. Әллә ничаклы урыс дәреслекләре тоткан, каядыр ашыгып бара иде, бусы качмады, бик шатланып, үбешеп күреште. Ләкин монда да элекке дәртле, канатлы Җиһангир күренми иде, арыганмы, сүнгәнме – ничектер рухсыз!! Почмакта туктап, бераз сөйләштеләр, Давыд монда, ләкин адресын белмим, ди. Үзенең адресын әйтте, килеп утыр, диде. Сахибныкын сорамады, русча укыйм, аттестатка хәзерләнәм, университетка керәм, ди. Габдәһ абзыйны бу да белми, күптән күргәне дә юк икән.

Бу ни хәл?

Эзләп, арып, һичберен таба алмыйча, бернәрсә аңламыйча, эштән чыгып, ватылып, номерына кайтып, ач көенчә, караватка ауды. Үзе дә сизмәстән, үлек кебек йокыга китте.

Торса, караңгылы-яктылы вакыт. Икендеме, ахшаммы, әллә, төн үтеп, иртәнге намаз чагымы?

Чыкса, ни күрсен: тоташтан унике сәгать йоклаган, төн үтеп, икенче көн туган икән.

## VIII

Өмид Габдәһ абзыйга багланды: ничек кенә булса да, аны табарга кирәк. Ул белер, анардан бер нәрсә алып булыр.

Шул уй белән кичә җылап утырган хатын әйткән заводка китте. Бер төркем эшчеләргә очрады. Алар бер сүз белән Габдәһ абзыйның квартирын өйрәттеләр.

Ашыгып, тыны бетеп барып керсә, ни күрсен: кечкенә генә, җыйнак кына квартир, урам як тәрәзә төбендә Заһидә җиңи нидер тегеп утыра. Аны күрүгә, егет:

– Әй җиңгәкәем, җиңгәкәем, синме? Габдәһ абзый исәнме? Иптәшләрдән һичкемне таба алмыйча газап чиктем... – дип шатланып, сикеренеп күреште, кат-кат исәнлек сорашып, бик озак кулын йибәрмичә торды. Заһидәнең йөзе ачылып китте, ул да бик шатланды:

– Искә төшереп килүеңә, – ди, – бик рәхмәт. Габдәһ абзаң көн саен зарланып утыра. Элек ду күчереп, шаулашып эшләп йөргән егетләр әллә кая югалдылар, әйтерсең, карчыгадан куркып кошлар качып бетте, иптәшләрнең берсен дә табар хәл юк, дип аһ итә... Сине күрсә, шатлыгыннан башы күккә тияр аның...

Заһидә жиңи Сахибкә иренең заводта эшләгәнен, кайтыр вакыты җиткәнен әйтте дә, аны күрми китмә бер үк дип, урыныннан торды. Мич алдына килеп, казан астын төзәтте, самавырын куя-куя, акрын, салмак, кызганулы тавыш белән, Сахибның сөальләре буенча, иптәшләре хакында сөйли башлады:

– Шулай, төрлесе төрле якка таралып, бер-берсен ташлап беттеләр инде... Элек шундый шәп егетләр иде, шундый эшлиләр иде, абзаң һәр кайткан саен мактап бетерә алмый иде... Ә хәзер ул көн саен күңелсез хәбәрләр генә алып кайта: кемне тотып япканнар, кемне сөргәннәр, кемне асканнар (хатын күз яшен сөртте), һәр көн менә шундый авырлыклар ишетәсең дә торасың... Монда калганнарның кайсы байлар ягын каера башлаган, кайсы эчүгә сабышкан, иң күбе элекке юлны бөтенләй ташлаганнар...

Сахиб элекке иптәшләренең исемен атап сорады. Җиңинең боларның һәммәсе хакында азмы-күпме хәбәре бар икән:

– Теге Гәрәй Солтан дигәннәре ике елдан бирле зинданда утыра... Аны асарлар, диләр... Тик әллә нәрсә өчен генә кичектерәләр, имеш, ди. Качкын Хәбиб ел ярым крепостьта утыргач, сөргенгә йибәрелде. Бик салкын йиргә, ди. Булатны яптылар... Эше бик каты түгел, чыгаралар, имеш, дип сөйлиләр дә, әле һаман ни булуы билгеле түгел... Гәрәй Солтан эше белән эләккән ике мөселман эшченең берсе зинданда вафат булды, Аллаһның рәхмәтендә булсын, бик әйбәт кеше иде, безгә килә иде... Тагы кем бар? – Давыд Урманов монда тора, байлар акчасына чыга торган гәзиттә эшли, бик эчә, ди... Ирем аны һәрвакыт, канаты сынган кош, дип кызганып сөйли... Аңа да суд буласымы, булганмы дип сөйлиләр... Теге Рауза дигәнеңезне әйтәсе дә юк инде. Ул очраганда исәнләшми дә, ди... Канатлы эшләпәләр, каракуль туннар, бриллиант йөзекләр киеп, офицерлар белән биеп йөри, диләр... Үзем күргәнем юк, гөнаһысына керер хәлем юк... Кеше сүзен генә әйтәм...

Сахиб, аптырап, сөальләрен бирүдә дәвам итте:

– Кадыйр бай, аның Йосыфҗаны, Һаҗәрләре ни хәлдә икән? Теге вакыт алар бик телдә иде бит...

Җиңи монда да гаҗиб садә, гаҗиб ачык җаваплар бирде:

– Алар ни эшләсеннәр: байныкы уңга да, сулга да бара инде. Кадыйр бай терелде, хәзер сакалларын буяп, яшәреп, яшь бикә Һаҗәр белән пар атта гуләйт итәләр... Һаҗәр теге вакыт Җиһангир дип тилмерсә дә, инде оныткан, ясанып, бизәнеп, бай ире алдында куштан кәнизәк[1] кебек кыланып тора, ди... Тиздән баласы да булачак, имеш!! Угыллары Йосыфҗан Истанбулга киткән

---

[1] *Кәзинәк* – хан сараена яки ханның берәр якынына хезмәткә алынган кол хатын яки кыз.

иде, аннан аңличангамы, французгамы барам, дип әйтә, диләр иде. Атаң хәл эчендә дип телеграм биргәч, кайтты да яңадан китмәде... Абзаң көлдерәдер иде: безнең Йосыфҗан шәп акыл тапкан, ди, ул, ди, ник яңадан китмәдең, дигәч: “Укып, ни чыга? Миеңне черетеп, яңадан 5-10 ел укысаң, бер доктор, бер адвокат, бер мөхәррир буласың икән, иң күбе елга өч мең алырсың, мин моны бер бармак селкетүдә табам”, – дип әйтә икән, ди... Башка ни булсын, асылына кайткан шул... Хәзер атасының барлык эшләрен диярлек ул йөртә. Бик үткен, бик каты сәүдәгәр, дип сөйлиләр... Кичә генә безнең күрше кибетче кереп җылап утырды:

– Карт бай, – ди, – ачуы килгәндә кыйнап чыгаргаласа да, ялынып барсаң, түләвеңне азрак кичектерә иде... Йосыфҗан дигәне харап икән, ди, векселем буенча алтмыш тәңкә җитмәгән өчен, торги белән саттырам, йортыңны яздырам, дип, эт кадерен калдырмыйча тиргәп чыгарды, ди.

Башкалар хакында белмәде. Әнә, абзаң да кайтып килә, диде.

Габдәһ абзый ишектән керер-кермәс, Сахибны таныды, үбеп күреште, элекке иптәшләрне көндез фонарь белән эзләргә җитешәм, һичберен күрер хәл юк, ди... Сахибка текәлеп карады да:

– Авыл килешкән. Син тазаргансың, – диде.

Ләкин Габдәһ абзый үзе дә тазарган, ныкланган иде. Аның яңаклары, иң башта катнашкандагы кебек кибеп эчкә кермәгәннәр, тулып торалар, буй да турайган, куллар да калтырамыйлар, өст-башы да чибәр генә, яхшы итек, постау чалбар, ныклы пальто, башта күн фуражка.

Аш та, чәй дә хәзерләнде. Өчәүләп өстәл тирәсенә утырдылар. Сахиб авылдагы ел ярым тормышын, үрядник вакыйгасын, монда килүен, шәһәр буенда газеталар, иптәшләр эзләп тә һичнәрсә тапмавын, әле Заһидә җиңи сөйләгән нәрсәләрне башына сыйдыра алмавын тасвир итте.

Габдәһ абзый авыр сулады:

– Шулай, туган, шулай... – дип, югарыгы вакыйгаларны тагы ачырак, караңгырак картинада хикәя итеп бирде. Иң төплеләрнең берсе саналган Госманның хәзер банкада хезмәт итүен, үзен аклау өчен кайбер нәрсәләрне ачкан, дип сөйләүләрен аңлатты... Дашкин дигән бер нәрсә бар иде, ул элек тә җүнләп эшләми. Ара-тирә митингага килеп, бик кызылланып кычкырынгалый иде. Шул егет сәяси иминлек алып, институтка керү өчен чукынган, хәзер охранкага хезмәт итә, жалуния ала, имеш, диләр... Тагымы... Тагы, Фәхри кибет ачты, өч приказчик тота... Бик каты, бик кыса, дип зарланалар...

Габдрахман артист булып китте... Комедияләрдә бик яхшы уйный... Алга бара, диләр...

Сахибның башы шеште, һичнәрсә аңламас булды...

Аптырап кайтырга җыйналды:

– Алайса, кем генә калды соң инде?

Габдәһ абзый авыр җавап бирде:

– Син, мин, Әмин белән Дәмин диләр... Шуның кебек канатлары сынган Давыд бар. Ул, байлар гәзитәсендә эшләсә дә, күңеле белән безнең якта. Көн-төн сүгенә. Аяусыз эчә... Булат белән Хәбибтән хат килгәли. Озын язалар: кайгырмаңыз, бу караңгы төн мәңге булмас, диләр... Минем берничә иптәш эшчем бар. Бу хатларны бергә укып, Коръән аяте кебек саклыймыз...

Сахиб, исәнләшеп чыга башлагач, Заһидә җиңи аны туктатты:

– Кара әле, Сахиб, синең башкорт арасында Гөлбикә дигән берәр танышың бар идеме? Безгә яшь кенә, матур гына бер хатын килеп, сине әллә ничә мәртәбә сорады. Килсә, мине күрми китмәсен, минем адресым Давыдта булыр, ди... Ул үзе башкортныкы, бер исерекнең хатыны икән... Иреннән аерылгач, аны шунда, якындагы бер стансада[1] татарча театрмы, нәрсәме куйганда, тавышың яхшы дип, җырларга кушканнар... Авыл хатыны булса да, үткен нәрсә икән: шул җырлаудан исемгә чыгып, үзен шәһәргә алдырганнар... Хәзер монда театр уйный, ди... Син аны эзләп тап, исеме – Гөлбикә.

Бу хәбәр Сахибның башына сукты, ул аптырады, ләкин тышка чыгармаска тырышты:

– Ничек? Шул, теге бервакытта көй отарга барганда, матур бер төн биргән башкорт хатыны Гөлбикә шулай дөньяга чыга алырмы? Гаҗәп бу эш!!! – дип уйлады.

Давыдның адресын алды, бүген кич үк дөньяның хәлен аңлар өчен, анарга барам, диде дә рәхмәт укып чыгып китте.

Абзый да, җиңи дә: "Безне ташлама, вакыт булганда килә күр", – дип калдылар.

Сахиб туры Давыдка китте. Аның тәне арыган, башы авырып, шешеп каткан, Давыдта, бәлки, мәсьәлә ачылыр, дип уйлый иде.

## IX

Давыдны эзләргә дип номерга кереп барса, баскычтан нәкъ моның каршысына Гөлбикәнең төшеп килгәнен күреп, Сахиб шаша калды. Башта күзләренә ышанмады: "Бу нәрсә – төшме, өнме?"

Ләкин бу төш түгел иде. Аның алдында елмаеп, кулларын тартып алырга теләмичә, дөньядан бераз югалып, кайчандыр гаҗиб матур бер төн биргән Гөлбикә тора иде... Тик ул бераз үзгәргән, бераз мәдәниләшкән. Өстендә элекке башкорт җиләне урынында хәзер тәннәрен кысып, күкрәген

---

[1] *Дөресе*: станциядә.

белдереп торган чибәр генә пальто, башында кечкенә калфак, өстеннән килешле кара шәл. Йөзе, күзе иреннәре шул, тик алардан элекке, басып, каплап торган караңгы тормыш тупаслыгы алынган да күзләргә акыллы нур сирпелгән, йөз ачылган, элекке җылтыр каралыктан чыгып, сөйкемле кара туткылга әйләнгән. Иреннәр элекке кебек ахмакча яки артык изелеп көлмиләр, матур гына елмаялар. Иң гаҗәбе – куллары да байтак төзәлгән, йомшарганнар, егетнең кулы эчендә үзләреннән-үзләре бераз дулкынланып, йөрәкне уйгаталар...

Сахиб нәрсә әйтергә, нидән башларга белмәде, турыдан ук:

– Миңа тагы дөнья ачылды, иркәм, вакытың бардыр бит, әйдә миңа барыйк!! – диде.

Гөлбикә карышмады, извозчик алдылар да туры егетнең номерына килделәр.

Сахиб акчаны бик артык кысып тота торган кешеләрдән, чөнки аңа үз гомерендә, ярты кадак арыш икмәге алыр өчен, бер тиен бакыр таба алмыйча ач утырырга, билендәге каешын кибетче марҗага рәһенгә[1] салып, кәмәрсез йөрергә бик, бик күп туры килгәләде.

Ләкин бүген ул боларны онытты. Тизрәк самавыр куярга кушты, малайны шикәрле булкилар, шоколадлар, алма, виноградлар алырга йөгертте, хакына карамыйча, яхшысын сайларга кушты.

Болар һәммәсе килгәч, бүлмәне бикләде, тәрәзә пәрдәләрен төшерде, электрикны яктыртты да:

– Инде менә хәзер без икәү генә!..Теге төндәге кебек минем иптәш Вәли башкорт та, синең исерек Җомагыл да, башка кеше дә юк... Я, сөйлә, иркәм, нинди могҗизалар сине ул җәһәннәмнән коткарып, бу якты дөньяга чыгарды?

Гөлбикә бер дә ашыкмыйча, кечкенә генә бер ноктаны да калдырмыйча, тулы, бөтен күренештә сөйләп бирде.

Заһидә җиңи сөйләгәнчә, иреннән аерылуы, моның җырга осталыгын ишетеп, стансада ясалган бер кичәгә чакырулары, шунда шөһрәт алып, бунын шәһәргә барып ирешүе, аннан да җырларга алдырулары, җырдан уенга күчерүләре, хәзер инде труппага катнашуы бары да дөрест икән...

Боларны сөйләгәч, Гөлбикә йомшак, дустанә бер үпкә белән Сахибның аның хакында, исемен ачык әйтеп, бер хикәя язуы, буны иптәшләр арасында укып, театрда да укырга теләве хакында халыктан ишеткәнен сөйләде, исемне дөньяга фаш итә язгансың, дип үпкәләвен аңлатты... Егет буны авыр алмады, кулларыннан алмаш-тилмәш үпте дә:

[1] Рәһенгә – закладка.

– Җаным, иркәм, син бит ул вакытта шундый бер караңгы ерак почмакта идең ки, минем язганым ул тирәгә барып ирешүен аз гына хәтергә китерергә юл юк иде... Шулай да икърар итәм: ул эш минем тарафтан бер хата булган... – дип гафу үтенде.

Ханым:

– Хикәяң янында булса, укып чыгар идең, хикәянең исеме “Башкорт кызы Гөлбикә”, бугай, – диде.

Егет, бер минутта бөтен сумкаларын актарып, әллә кая эчкә яшерелгән хикәяне табып алды.

Озаклап, хатирәләргә китеп укып чыктылар. Гөлбикә бик яратты, егетнең күзләренә карап:

– Ул вакытта шулчаклы сөйгәнсең сөюен дә, аннан соң, әллә кемнәр белән йөреп, мине исеңнән үк чыгаргансыңдыр инде... – диде.

Гадәтендә булмаса да, Сахиб, кычкырып, чәнчелеп ант итте: “Валлаһи, шул яшькә җитеп, синнән башка һичбер хатын йөрәгемә кергәне юк... Сине гаҗәп сагына идем... Ләкин яшерми әйтәм, сине бу хәлдә күрермен, дөньяда бундый могҗиза булыр дип, аз гына да башыма китерә алмый идем...

Ничектер, үзеннән-үзе шулай чыкты, Гөлбикә егетнең куенына кереп югалды, иркәгә, сөюгә сусап кипкән иреннәре, бер-беренә юлыгып, һәр ике җан дөньяны онытты.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Иң элек Гөлбикә айныды. Аның чәчләре тузган, күлмәкләре бөтәрләнеп беткән иде, көзгегә килеп рәтләнде дә:

– Кайтырга вакыт, мине озат! – диде.

Егет бик сак, бик үтенүчән рәвештә монда кунарга гарыз итте. Ханым башта куркынды, ай, булмас, белерләр, диде. Ләкин Сахибның берничә сүзеннән соң, кинәт карарга килеп, өстендәге пальтосын, башындагы шәлен яңадан салып ташлады.

Моннан күп еллар элек әллә кайда, караңгы башкорт авылында үткәргән бәхетле төнне яңадан кайтардылар.

Бу ике төн һәр икесе өчен дә бөтен гомерләрендә бердәнбер, бөтен гомерләрендә тирән сөю хисе, иге-чиге булмаган бәхете, сәгадәте белән бөтен гомерләрендә тиңдәшсез һәм охшашсыз иде.

Кайбер җаннар сөю дәрте белән тулып яратылалар. Ләкин авыр караңгы язмыш бу дәртне, бу ялкынны каплый, йөрәктә кайнаган бу ашкынуны үзенең эзләгәненнән мәхрүм итә, гүя аны караңгы зинданда асрый. Бер вакыт килеп, бу зиндан ачылса, берничә минутка асыл чәчәк, матур кояш нурына юлыкса, алар өчен бу кавышу сәгатьләре дөньяның һәммә бәхетләреннән югары булалар, җәннәт хыялларын тәҗәссем

иттерәләр[1].

Сахиб белән Гөлбикә шундый җаннардан, аларның бу ике кичәсе дә шундый сәгатьләрдән иде.

Ханым якын арада труппа белән бундан китәчәк икән. Тагы берничә көн бергә булып, күңелдән аглап, һәр икесе бөтен дөньяда ятимлек хис итеп, Алладан тизлектә тагы кавыштыруны теләп аерылыштылар.

## X

Теге көндә Гөлбикәгә сихерләнеп, иптәшләрен оныткан җырчы Сахиб, берничә көннәр йөреп өйдә очрата алмыйча аптырап беткәннән соң, ниһаять, кичке сәгать унбердә Давыдның номеры ачык булган вакытны туры китерә алды.

Берничә кага – тавыш юк, тагы катырак суккач, кемдер иренүле, ярым ачулы аваз белән:

– Кем бар анда? Кереңез! – диде.

Ишекне ачкач, егет аптырап калды: бүлмә тәмәке төтене белән тулган, һава искиткеч авыр, тончыктыргыч, тәрәзә буендагы өстәлдә берничә аракы шешәсе, боларның кайсы буш, кайсы ярты, кайсы бер дә башланмаган, әллә ничаклы икмәк сыныклары, тоз, горчица, балык башы, ярты аршин озынлыгы колбаса, бер тәрилкә кыяр, байтак суган, тагы, белмим, ниләр гаҗиб бер тәртипсезлек белән өелгәннәр. Өстәл астында пиво бутылкалары белән тулы кәрзинкә... Бүлмәнең уртасында, зур ук икенче бер өстәл тирәсенә унлап кеше утырганнар, һәммәсенең чәчләре тузган, йөзләре эштән чыгып борчулы, үзләре һәммәсе дә авыр бер риязый[2] мәсьәлә чишеп утырган кебек артык җитди, артык тирән уйдалар... Арада берсе аягүрә баскан, кулында бер колода карта, исерегрәк тавыш белән:

– Булат, Булат... син... актык кул... сине дә утыртсам, эш пешә, – дип мыгырдый...

Сахиб күзләренә ышанмады: “Йа Ходай, бу Урманов түгелме соң?” – дип шаша калды...

Давыд шул иде. Ләкин Сахибкә ул башка – элеккенең харәбәсе кебек күренде: чәч, тузып, маңлайга төшкән, күптән тaралмый чобалып беткән, йөзе ябыгып караңгыланган, күзләрдә элекке ут, элекке гайрәт юк, чәчендә бераз чал күренә, җитмәсә, буе да бераз бөкрәйгән, яңаклары эчкә кергән, ирен, күз төпләре җыерчыкланган... Тагы ипләбрәк караса, һәммәсе диярлек танышлар булып чыкты: Госман, Тангатар, Баязид карый, Габдрахман, Гриша, Вера, Җиһангир. Тик арада Сәлимов дигән озынрак буйлы, аксыл

---

[1] *Тәҗәссем иттерәләр* – күз алдына китерәләр.
[2] *Риязый* – математик.

ябык йөзле, ачык күгелҗем күзле бер егет белән яшь сәүдәгәргә охшашлы өч адәм генә чит иде... Болар яхшы киенгәннәр, ләкин компаниядә бик үз кешесе күренәләр иде. Сахиб, аптырап, ни эшләргә белмәде, шулай да кире чыгарга көче җитмәде, әллә нинди бер ят тавыш белән: “Исәнмесез, иптәшләр...”, – диде. Болар күтәрелеп карады да:

– Нихәл, Сахиб, сине нинди җил ташлады... Хәзер сөйләшәм синең белән... Әле монда базарның бик кызган чагы... Банкыны харап итәләр, Булат, җә, күп уйлама, йөз илле сум банкы, күпмегә барасың?

Банкы бу компания өчен чыннан да зур иде. Тангатаров, Давыдка карап:

– Сез күп оттырган кеше, Булаттан башка берсенә дә бирмәңез, – диде.

Урманов йөз чытты:

– Әйдә, ала бирсеннәр, чукынсын банкысы!!

Булат та аягүрә торды. Аның кулында тугызлык, сынавынча, бу аңа бәхет китерми торган карта. Ләкин Урманов ике әйләнүдә Госманнан башка һичкемгә бирмәде, бу хәл бераз өмидне арттыра иде... Өстәлдә өелеп яткан алтын, көмеш, кәгазьләр компаниянең күзен кыздырды, берәм-берәм Булат янына килеп кушыла башладылар... Һәммәсе диярлек, кем унга, кем унбишкә барып, бөтен банкыны капладылар... Минут бик артык мөһим иде.

Һәр ике як олуг сугыш алдында торган ике дошман гаскәренең командиры кичергән бер хәлдәләр иде, Булат шаярып:

– Сине бүлдерәсем килми, күпме отступной бирәсең? – диде.

Давыд кул селекте:

– Куй юкны, алыңыз барын!

– Бир карта! Тукта, үзем алам!

Булат үзе кырык сумга, димәк актык акчасына бара иде, бераз дерелдәп карта алды да, туз икәнен күргәч, кинәт тугызлыгы астына тыкты. Банкирны ялгыштыру өчен, Госманга уйналган картадан берен ачарга кушты:

– Кызылмы, карамы?

Кара чыкты.

– Артык кирәкми, үзеңә ал! – диде.

Давыдның алдындагы карта кире ягы белән ята иде, кемдер гасабиланып: “Ачып уйна!”– диде. Анда алтылык буби икән. Буны күргәч, компаниянең өмиде артты:

– Банкирның картасы шәп түгел!

Давыд тагы бер карта алды, алтылык буби астына тыкты да, озаклап, мәшәкатьләнеп, бер читеннән генә карады.

Монда унлык пики иде. Давыдның иреннәре дерелдәде. Компания аңа карап катты, күпләрдә өмид уйганды.

– Уналты – банкир өчен бер дә, бер дә ярый торган эш түгел инде!!

Артык җитди минут килде. Һәр ике як, сулыш та алмый, әйтерсең, хәзер үлмәк-яшәмәк мәсьәләсе хәл ителә... Үлем тынлыгы, йөзләр, күзләр бер ноктага текәлеп каткан!!

– Аламы, юкмы? Алса, ни чыга?

Банкир карарга килде дә кинәт бер картаны ачып ташлады, ни күрсеннәр: бишлек!!

Компаниянең башына яшь[1] суккан кебек булды: "Гаҗәп бу эш: ике әйләнүдә тик бер мәртәбә бирде!!" – диештеләр.

– Күңелем сизгән иде, бармаска әйткән идем... фәлән-төгән, – дип сөйләнә-сөйләнә, банкыга акча түли башладылар.

Давыд ике йөз алтмыш сум акча җыеп алды. Булатов:

– Миннән сиңа кырык сум!! Бирсәм, уйнарга акча калмый, ахырдан түләрем, – диде. Давыд: "Пожалусты, пожалусты, бер сүз юк", – диде...

Уен дәвам итте, Давыд үз янәшәсендәге иптәшенә:

– Минем картага бөтен мәхәлләсенә бар! – дип, үзе аракы өстәле янына – Сахибкә килде.

Көлә төшеп: "Син эшнең бик кызу чагына килгән идең, гафу ит мине", – дип, бик кыска рәвештә хәлен сорашты.

– Син миңа кунарга кил, бу халык берәр сәгатьтән таралыр, сөйләшеп кунармыз, – диде.

Берәр рюмка эчкәч, Сахиб, аптырап, ватылып чыгып китте.

## XI

Сахиб төгәл бер сәгать йөреп килсә, монда һаман уен бара иде әле.

Эчүдән дә, уйнаудан да кызык тапмаганга, ул икегә чаклы карап утырды да, мин йоклыйм инде, дип, ширма эченә кереп ятты.

Башы талган, йөрәге суга, хыял бик артык кызу эшли иде. Башта Гөлбикә белән җенләнде. Аның белән беренче төнне үткәргән башкорт авылына, аннан шәһәргә китте. Кайдандыр Рауза килеп чыкты. Аларда булган җыелышны яңадан ясадылар, ләкин тегесе кебек чыкмады, туташ та чит карый, ир иптәшләрнең дә теле сүз тапмый иде. Кайдадыр Гәрәй Солтан күренде. Аны асарга алып баралар, дар агачына китереп муенына җеп сала башлагач, ул каядыр югалды, баштанаяк кызыл киенгән кара йөзле палач үзе аның урынына асыла, нидәндер гыр-гыр килә, күзләре коточкыч булганнар...

Юк, кайдадыр зур җыелыш икән. Качкын Хәбиб сүз башлый. Полиция тотам дигәндә, шаярмыйсыңмы, дип юк була. Давыдның җәһәннәм базына киләләр, яшерен басмаханәне тапканнар, имеш, дип, кемдер урамга йөгерә...

---

[1] Бу урында "*яшен*" дип аңларга кирәк.

Халык кача, кемдер таптала, атлы казаклар, куып-куып, камчы белән яра башлыйлар. Куркып уянып китсә, компания һаман бара иде әле. Кемнеңдер:

– Миндә унтугыз, егерме булса, ал! – дигәне өндәме, төштәме ишетелеп кала. Сахиб, әйләнеп, башын мендәр астына тыга да авыр саташулы йокы белән йоклап китә...

Иртән сәгать унда уянса, тегеннән шул ук тавыш:

– Миндә унтугыз, егерме булса, ал!

Торып чыкса, ни күзең белән карыйсың, бүлмәдә төтен болыт булып оешкан. Өстәлдәге бутылкалар ауган, суган, колбаса кабыклары подностагы суда йөзәләр. Аяк асты ватылган рюмкалар, түгелгән пиволар, тәмәке төпчекләре, икмәк сыныклары, балык башлары, кыяр кабыклары белән эштән чыгып, пычранып, адәм карый алмаслык рәвешкә кергән... Ләкин компания һаман бар... Тик Вера гына күренми... Башкалар урыннарыннан кузгала, башларын күтәреп карый алмыйлар, күзләре үлгән, куллары калтырый, йөзләре җәһәннәмнән чыккан шайтанны хәтерләтәләр...

Госман түзмәде, шиша[1] төпләрендә калган аракыны каплап эчте, көзге алдында ава-түнә чәчен иплән маташты да, булдыра алмагач, умывальникка килеп, йөзен, башын жуды... Бу, ахры, бераз айныткандыр:

– Кадалып китсен дөньясы, сәгать унбер икән... Бүген тагы соңга калдым... Хушыңыз! – дип, ашыгыч-ашыгыч чыгып китте...

Уенның мәгънәсе беткән, уйнарлык көч калмаган иде, шулай да тагы бер генә колода, тагы бер генә колода, дип тарта-тарта, сәгать икегәчә маташтылар да тарала башладылар... Үзләре хәлсезләр, гәүдәләрен тота алмыйлар, аяклары кушканны тыңламый, чалыш атлый. Көзгегә карыйлар да:

– Бит чабата төсенә кергән икән! – дип, ава-түнә китә башлыйлар.

Тангатаров, Җиһангир, Зариф Булатов, Госманнар барысы да төрле дәрәҗәдәге аттестатниклар, һәммәсе:

– Чукынсын! Бүген тагы дәрес калды, кичә ятлаган латин бүген тагы онытылып бетте, дип, әбисе-бабасы белән сүгенеп чыгып киттеләр. Алар артыннан Габдрахман, бүген тагы репетициягә кичегәм, тагы ачуланырлар, дип; ак ачык йөзле, күгелҗем күзле Сәлимов, Столыпинның декларациясен тәрҗемә итәсе бар иде, редакциядә материал, дип, җанга тиярләр, тәрҗемә кыл инде менә бу баш белән, дип; тагы шулай һәммәсе эш калудан, баш ярылудан зарланып, сүгенеп таралдылар. Давыд Урманов Коковцев[142+] белән Шингаров[143+] арасында бюджет мәсьәләсендәге талаш мөнәсәбәте белән мәкалә язарга тиешле иде. Сәлимов көлеп:

– Мәкалә язерме? Әйдә, редакциягә, – диде.

---

[1] *Дөресе*: шешә.

Давыд кул селекте:

– Бармыйм. Редактор: «Ник килми, эш калдыра, – дип бәйләнсә, – төне буена карта уйнады, эчте, килә алмый», – диярсең... Тагы кызып, материал сорый башласа, минем өчен ике җөмләлек баш мәкалә яз. Коковцев белән Шингаров дигән ике буржуа эт халык сөяге өчен талашалар, ләкин пролетариат боларны аерачак, диң! Ярыймы? Ну исән бул, мин яттым!

Иптәшләрен озатуга, ишек-тәрәзәне ачып, һаваны сафлады да, Сахибтан гафу үтенеп, кич белән кил, Баязид белән Булат миндә була, дип, чишенеп ятты!

## XII

Ложа барлыгы, алырга керәчәкләре алдан хәбәр ителгән иде. Рауза соңгы ике ел эчендә төрле дарулар, бик күп мәшәкатьләр соңында гына элекке тулылыгына, элекке байлыгына кайтара алган гүзәл чәчләрен соңгы мода буенча төзәтеп, туалетын тәмам итеп, үзенең матурлыгы өчен бөтен күңеленнән кәефләнеп, ирләрне сихерли торган бер елмаю белән зур көзге алдында актык мәртәбә әйләнгән вакытта ашыгыч звонок бирделәр...

Туташ бераз каушап калды:

– Бу кем булыр? «Ул» бит сигездә керергә тиешле иде!

Ашыгыч рәвештә көзгегә карап, прическасын яңадан бер кулы белән чак кына ипләде дә, килгән кешене көтеп, каршы алырга батырлыгы җитә алмыйча, зал уртасында туктады.

Ишектән ике ир кеше тавышы килде. Алдан камил тулып егет булып җиткән, сакал-мыегын яңа гына шомалап кырдырган, хушбуйланган, гаҗәеп килешле аля франк киенгән Заһид Акчулпанов, аның артыннан бераз зәвыксыз, ләкин бик артык кыйммәтле киенгән Йосыфҗан Кадыйр углы кызулап керде.

Рауза егетләргә сокланып карады. Акчулпановны әйтәсе дә юк, ул инде тәрбиясе белә генә түгел, тумышыннан аристократ, каны белән үк джентельмен. Син Йосыфҗанны кара! Бу да бит ир булып җитү өстенә, Төркиядән, Яурупадан йөреп кайткач, бөтенләй башка кеше булды... Үзен тота белә. Матур күзләре йөрәкне кытыклыйлар. Алсу иреннәргә, ачык күкрәккә бик артык җотылып карый каравын, ләкин бу инде ирләрнең һәммәсендә диярлек бар...

Рауза матур елмаеп, бераз каушау катыш иркәләнеп:

– Заһид, сез бит сигездә кермәкче идеңез... Икеңезнең дә күзләреңездә нидер бар, әллә берәр эш чыктымы? – дип, кунакларга утырырга гарыз итте...

Акчулпанов ике сүз белән әйтеп бирде.

Экспроприация[1] белән тотылып ябылган эшче Гәрәй Солтан эшен тикшерә торгач, үткәннәрнең эзенә төшәләр, бугай. Кулга алынып та хөкемгә чаклы чыгарылган Зариф Булатов мәсьәләсе дә бик киңәеп, моңарчы акланып бетте дип уйланган әллә ничаклы кешеләргә кагылу ихтималы бар икән... Хәзергә материал җыялар, вакытында чарасы күрелмәсә, боларның өчесенең дә “пычрануы» бик мөмкин... Бу эш бик ашыгыч булганга, операга барганчы шул турыда сөйләшеп үтәргә кирәк...

Килүләре шуның өчен икән.

Рауза эченнән үзен-үзе өзгәләрдәй булып әрнеде, ачуланды, ләкин тыштан белгертмәде, тик үзе агарынды, иреннәре дерелдәде, тешен кысып, бетмәде шул бәхетсезлекләр, дип уйлады:

– Соң ни эшләргә?

– Башка чара юк, Булат белән Давыдны күрергә кирәк... Ашыгыч килү шуның өчен... Сез бит аның белән кайчандыр бик якын дустлар идеңез!

Рауза кулларын өзгәләп, икенче якка борылды:

– Кайчандыр, кайчандыр! Аннан соң бик күп сулар акты шул инде! Ел ярым мин аны күргәнем юк... Бугаздан алгач кына ярдәм теләп бару килешми шул! Теләсәңез ни эшләңез, мин аңа бармыйм...

Йосыфҗан сүзгә катнашты, үзе бераз гына майлы күзләре белән Раузаның тулы алсу иреннәренә текәлгән иде:

– Сезнең бару кирәк түгел... Мин аны үзем чакырам... Ул бит минем мәктәп иптәшем, кайчандыр якын дуст иде, авыр вакытларында мин аларның Баязид карыйларын коткардым!

Рауза күнде. Аны тиз-тиз киендерделәр дә, капкага чыктылар. Анда яхшы чанага җигелгән ак юртак, башын салландырып, алгы аяклары белән баскан йирен казып, сабырсызланып тора иде.

Бер кулы белән туташны кочаклап, уң якка Акчулпанов утырды. Рауза сул ягындагы Йосыфҗанга: “Егылырсыз, миңарак кысылыңыз”, – диде...

Болар килеп җиткәндә, Кадыйр бай ястүгәме, башка бер йиргәме чыгып бара иде. Мәрмәр баскычлар аркылы югары катка менеп, кыйммәтле җиһазлар, зур көзгеләр, җәнүб[2] тупрагында гына җитешә торган асыл гөлләр белән тулган матур залга керүгә, үзенең авыр, салмак, һавалы йөреше белән, киенеп, ясанып, калку күкрәкләре илән бераз дулкынланган хәлдә, байның яшь бикәсе Һаҗәр килеп чыкты.

Тыштан дустанә елмаеп исәнләштеләр, якынлык сүзләре әйттеләр. Ләкин эчтән ике хатын бер-беренә беренче күрүдә дошман киселделәр... Һәр икесе бер-беренең киенүеннән, артык гүзәл тәненнән бер гаеп, бер начарлык

---

[1] *Экспроприация белән* –

[2] *Җәнүб* – көньяк.

табарга тырышты.

Акчулпанов Һаҗәрнең үзеннән-үзе дулкынланып торган тәненә, калку күкрәгенә, иштиһа[1] белән янып торган күзләренә, иреннәренә җотылып хәйран булды... Шул хатын, шул тән кайчандыр Җиһангир кочагында иде. Йа Ходай, нинди бәхет! – дип уйлады. Хыялы белән Һаҗәрне үзләренең Афина кичәләренә алып барды. Бу зәвыксыз киемнәрен бөтенләй салдырып, үз каршысына китереп ялангач бастырды да, башкалар күзеннән бераз каплау өчен, Афина кичәләрендәгечә Иске Юнан, Рума[2] гүзәлләренең хәзерге мәдәният белән тагы да гүзәлләнә төшкән костюмнарын кидереп, гаҗәеп эчемлекләр, ал-гөл чәчәкләр, һәммәсе тик җиңел ефәкләр белән генә төренгән матур ханымнар янына алып чыкты... Һаҗәр чыгу белән тегеләр югалдылар... Бу хыялый күренеш егетнең акылын алды... Күз алларын караңгылатты! Кунакларның ашыгыч бер эш белән киләчәге алдан әйтелгән иде. Утырып исәнләшү, бер-ике сүз әйтешү белән Һаҗәр уңгайсызрак рәвештә гафу үтенде дә, каядыр чакырулы идем, дип, яңадан исәнләшеп залдан чыкты...

Беренче эш Булатны яисә Урмановны чакыру иде. Башта мәшгуль, дип җөдәттеләр. Аннан соң Булатовның өйдә юклыгын хәбәр иттеләр... Урмановны сорагач, йоклый, диделәр. Акчулпанов: «Алар кичә бер тәүлек эчкәннәр, уйнаганнар, бугай. Шуннан соң тормаганнардыр», – дип, мыскыллы бер көлү белән Раузага карады... Бераздан кемдер каты шалтыратты. Телефонда Давыд иде.

Йосыфҗан көлде: «Әллә йокысы ачылган, әллә исерек – тавышы карт эт улаган кебек”...

Телефон аркылы аның вакытын гына белмәкчеләр, килә алса, хәзер ат йибәрәчәкләр...

Давыд Урманов кырт кисте:

– Юк, бара алмыйм... Эшем күп... Аннан соң нишләп мин сезгә барыйм? Безнең арада хәзер нинди сүз булырга мөмкин?..

– Рауза да бездә, ул сезнең килүеңезне бик тели, үтенә, – диде...

– Туташтан гафу үтенәм... Ләкин бара алмыйм. Әйтеңез, сезгә ни кирәк?

Йосыфҗан кунаклары белән киңәште дә кыскалык белән мәсьәләне аңлатты. Эләккән иптәшләрнең биргән, бирәчәк җавапларында хәзер иректә булган кайбер кешеләрнең дә катнашканлыклары аңлашыла, бугай... Без шул хакта сөйләшмәкче идек, – диде.

Давыд Урманов ачы кискен сүз белән җавап кайтарды:

– Качкын Хәбиб, Булат, Габдәһ абзый, Баязид, Гәрәй Солтан кебек

[1] *Иштиһа* – теләк.
[2] *Рума* – Византия (Көнчыгыш Рим империясе).

революционерлар жандармериянең тозагына эләгәчәк кешеләр түгелләр, кичәге иптәшләре, бүгенге дошманнары хакында сүз әйтеп, үзләрен пычратмаячаклар... Сезнең шкураларыңызга куркыныч юк, тыныч булыңыз... Бу хакта мине яңадан бимаза итмәңез!

Йосыфҗанга шул гына кирәк иде... Давыдның мондый каты җавабы бер яктан тынычландырса да, икенче яктан Рауза белән Акчулпановны бу бик чәнчеде, алар чыннан да хурландылар...

Чәй бик артык бай хәзерләнгән, татлыларның, конфет, шиколадларның һәр төре китерелгән булса да, Рауза тик ярты гына чынаяк эчте дә: “Мин операга бармыйм, мине өйгә озатыңыз!” – диде.

Туташны чанадан төшергәч, егетләр шәһәрнең мәшһүр миллионерларыннан мәрхүм Платоновның сөяркәсе Лизаның сараена киттеләр. Бүген анда “Афина кичәсе” булачак иде. Болар Акчулпановның мәктәп дустларыннан бер офицер аркылы тәкъдим кылынып, һәрбер шимбәдә ясала торган бу җәннәт кичәләренең даими кунакларыннан иделәр. Операга бару тик Рауза теләвенчә, аның күңеле өчен иде. Туташның кәефен кырып, операдан ваз кичтергән Урмановка эчләреннән рәхмәт укыдылар!

## XIII

Нахаллар, шкурниклар! Үзләре кичәге «гөнаһлары»ннан аклану өчен бөтен дөньяны сатарга әзер булгач та, ахрысы, башкаларны да шулай, дип уйлыйлардыр. Адәм хурлыгы бит: «Имеш, ат йибәрәчәкләр, имеш, Рауза да бик үтенә! Артыңа төшсәләр, үтенерсең! – дип сүгенеп, ачуланып, Булат номерына килеп керсә, анда Баязид карый, җырчы Сахиб, редакциядән бер иптәше, өстләрен салмыйча, әрле-бирле йөренәләр. Озынча буйлы, аксыл йөзле, ачык күгелҗем күзле Сәлимов, креслоның артына ята төшеп, бераз чәнчүле елмаю белән нидер сөйли иде...

Урманов иптәшләренең берсе белән дә исәнләшмичә: «Башның авыртуына чыдар хәл юк, эчәргә алдырмадыңызмыни? – диде дә, юклыгы мәгълүм булгач, – утырасыз шунда”, – дип, ачуланып чыга башлады. Сәлимов үзенең даими ярым мәсхәрәле елмаюы белән:

– Чәпчемә, Давыд, шаярып кына әйттек, хәзер килә... Утыр әле, бик мөһим бер нәрсә бар, сиңа да кирәкле, – дип, сүзен дәвам иттерде.

Газета идарәсенә «Тарих сезнең җеназаңызны укый» исемендә бер мәкалә килгән... Бунда, әлбәттә, бер дә гаҗәп эш юк. Мәкалә дигәнең туфан кебек агыла инде. Аларны кәрзингә ташлап кына өлгер... Ләкин бу мәкалә үзе дә яңарак фикер әйтмәкче, редактор белән булган тартыш мәкаләнең әһәмиятен тагы арттыра... Язучы хәзерге тормышны җимерелгән өмидләр, сынган канатлар, иманыннан, идеалыннан ваз кичкән мөртәтләр каберстаны

дип карый... Бик күп кешеләрне исемнәре белән атый... Мәдрәсәи исламиясе белән бөтен дөнья мөселманының бәхетенә хезмәт дәрте белән янган мәшһүр Гали мөдәррис хәзер исламнан, милләт, дин юлында хезмәттән бигрәк, күптән түгел бурычка алган ике йорты өчен банкага түләргә акча табу кайгысы белән яна... Төркиядәге зур дәрәҗәсен ташлап, «Русия мөселманнары»на хезмәт өчен кайткан атаклы фән, гыйлем дусты Кәрим Гайфи (Мы учим һәндәсә) байлык җыю, йорт салу эшендә Гали мөдәррис артыннан җитә алмаганга, ел картаясын ай картая. Үзенең рәкыйбен[1] бөтен вөҗданы белән дошман саный... Заманында бик шәпле, бик югары фикерле булган Нәҗип Кәмал, зур дәрәҗәгә менеп, бай кызы алу өчен, иптәшләренә каршы интрига кора. Мәктәпкә мөдир булыр өчен җан ата... Миллият, исламият тәрәккыйсе өчен җаным, тәнем фида булсын дип, муллалыктан хурланып, күкләргә, гарешләргә ашкынган татар шәкертләре «тормыш тәэмин» хәсрәтенә төштеләр, ришвәт биреп, тәрилкә тотып, муллалыкка урын эзләп йөриләр... Капитализмны җимереп, дөньяны җәннәткә әйләндерергә йөргән татар яшьләре идеалларыннан социализмга хезмәттән генә түгел, кешелектән, вөҗдан, әхлактан ваз кичеп, бер төрлесе диплом өчен аттестатник булып китте, бер төрлесе, кичә буржуа дип сүккән бай абзыйлар чанасына утырып, маллы кыз, яхшы урын эзли башлады, бер төрлесе үзен карта, аракы, фәхеш сазлыгына ташлады... дип тасвир итә дә: “Шулаймы, идеалдан карын көчлеме?” – дип тәмам кыла...

Баязид йөзен чытып, кашын җыерды, ни дисең, һәммәсе дөрест, ди. Башкалар дәшмәде. Сәлимов яңадан көлә төшеп, мәсьәләнең кызыгы, дөрестме, ялганмы булуда түгел, безнең редактор бу мәкаләнең «могтәбәран»га[2] кагылган йирен сызып, яшьләрне сүккән урыннарын кертмәкче була, диде.

Моңарчы бер сүз әйтмичә, өзлексез тәмәке тартып утырган Давыдны Сәлимовның соңгы җөмләсе уйгатты, гасаби кызу тавыш белән:

– Соң, сез ни эшләттеңез? Әллә шуңа риза булдыңызмы? – дип сорады.

Сәлимов:

– Юк инде, Мөхәммәдҗан абзый, үзебезгә кыйбат тора. Бөтен редакция моңа каршы төште. Икенче бер вакыт кертеп йибәрмәсен дип, мин мәкаләне кесәгә тыктым... Менә, кирәксә укы!

Давыд кул селекте, нәрсәсен укыйм, мин ул ахмактан башка да боларның барын үзем күреп йөрим...

Сахиб, мәкаләне алып, бик җентекләп укый башлады. Ул арада җиңел атлап, үз эченнән нидер җырлап, Зариф Булатов килеп керде. Йомышчы

[1] *Рәкыйбен* – көндәшен, конкурентын.
[2] *Могтәбәран* – ихтирам ителә торган кешеләр.

аракы, кыяр, колбаса, икмәк кертте.

Дәртсез, рухсыз эчә башладылар. Тик Сәлимовның күтәренке, яхшы күкрәк тавышы белән “Мәдинәкәй”не җырлавы, Сахибның аңа кушылуы гына мәҗлескә бераз җан бирә иде.

### XIV

Булатны телефонга чакырдылар. Вера икән. “Бездә күңелле компания, тик сез генә юк, бер минут кичекми, Давыд белән килеңез, җырчы Сахибны да калдырмаңыз”, – дип әйтә, ди.

Сахиб, карышып бакса да, булдыра алмады, киенделәр дә чыгып киттеләр. Сәлимов калганнарга, шаярып, команда бирде:

– Шагом, марш, Иванов ресторанына!

Берсе дә карышмады, Баязид, гәзитә сотруднигы, Сәлимов, үзләренә бер компания ясап, Ивановка юнәлделәр.

Барсалар, анда Габдрахман, Фәхри, теге карта мәҗлесләрендә булган яшь байлардан бере, шәкерттән чыгып, китап кибете ачкан, хәзер зур наширләрнең берсе булып барган Садыйков, тагы ике артист, бер шагыйрь, бер яшь мөхәррир зур өстәлне тутырып утыралар, алларында, күп гаскәр өстеннән күтәрелгән штыклар кебек, пиво шишалары тезелгән...

Боларны күрүгә, Габдрахман сикереп торды да, ачык, шат йөз, бераз ук тонып өлгергән күзләре белән көлеп, иптәшләренә каршы килде...

Тагы бер өстәл кушып, зур табын ясап, уен-көлке, шау-шу белән эчә башладылар.

Баязид сүзгә күп катнашмады, ләкин Сәлимов, үзенең акыллы күзләре белән тирә-якны тамаша итә-итә, бертуктаусыз җиңел, ләкин үткен көлкеләр чәчә иде.

Сәгать икедә бу ресторан ябылып, Васильевка барсалар, анда Булатов, Вера, Гриша, Урманов, Госман, җырчы Сахиб утыралар иде. Эчәргә беткәч, өйдәге компаниянең кызыгы калмаган булырга кирәк ки, болар монда килгәннәр... Ханымнан башкасы бары да яхшы ук кызмачалар. Булатов, Сәлимов янына килеп, һичбер сәбәпсез:

– Яратам, сине, Сәлим! – дип сөйләнә, яңагыннан үбә башлады.

Тагы бер өстәл арттырып, барлыгы бергә җыелырга теләсәләр дә, бигрәк артык китәсез, дип, Госман буңа каршы төшкәч, якын өстәлләрнең беренә утырдылар. Ләкин бу компаниянең берлегенә зарар итмәде, исергән саен бергәрәк бутала, сүзләр, стаканнар алмаша, иптәшләр бер өстәлдән икенчесенә күчәләр, чәкәшеп эчәләр дә үбешәләр, кочаклашалар... Верага барып, аның кулларын үбеп, гыйшык игълан кылалар.

Госман аек иде, бу компаниядә үзен бераз чит күрә иде. “Артык изә

башлыйлар”, – диде дә, һичкемгә сиздермәстән, акрын гына чыгып сызды. Ләкин анардан соң калганнарга да күп утырырга туры килмәде: сәгать төнге дүртне сугарга биш минут дигәндә, кулына ак салфет тоткан карт официант килеп, ресторан ябылырга вакыт җиткәнен хәбәр итте, бетереңез, диде.

Аңа, тагы ике генә пар, дип ялынсалар да, карт күнмәде, булмый, безгә шелтә тия, диде.

Теләсә кем күңеленә нәрсә килсә, шуны алдыра биргән икән, компаниянең кәефе яхшылыгын күреп, официантлар бераз артыграк та язганнардыр, ахры: түли башлагач, акча җиткерә алмый гаҗиз булдылар. Әле дә ярый Сәлимовның ниндидер тәрҗемәгә акча алган көне икән, ул:

– Кыяматтә бирерсез, иптәшләр, – дип, җитмәгәне өчен түләде.

Инде кая барырга? Кемдер: “Кая барасың, кайтабыз”, – диде. Аңа каршы Сәлимов: “Бу вакытта кайтып йоклау – мещаннар, обывательләр эше, мин “мәхәл”гә барырга тәкъдим итәм”, – диде.

Сахиб аңламады:

– Нәрсә ул “мәхәл”? – диде.

Сәлимов, көлеп, ярым җитди, ярым шаярып җавап бирде:

– Казанда – “Җиңгәчи”, Уфада – “Кәмали”, Оренбургта – “Газиз”, Әчтерханда “Гаҗби” дигән йортлар бар, анда акшарлы карт “фирештәләр” асрыйлар, фән телендә боларны “мәхәл” дип атыйлар!! Аңладыңмы?

Вера ире белән кайтып китте. Башкалар, ава-түнә чыгып, мең бәла белән ямщик табып, дүртәр-бишәр кеше төялеп, полиция ишетмәсен өчен, акрын гына җырлый-җырлый “Мәхәл”гә чаптылар.

## XV

“Мәхәл”дә хәятның бик кызу кайнаган чагы булырга тиеш ки, кызыл фонарьларга якынлашу белән, тыштан ук гармунның исерек кулда гырылдаган тавышы, салкын пиводан тамаклары карлыккан “туташлар”ның ватык граммофон кебек җан әрнеткеч бер рәвештә җырлаулары, “Дүдәк” көенә әйттерүләре ишетелә иде.

Компанияне швейцар да, зур буйлы, сабыр кузгалышлы хуҗа хатын да, битләрен, каш, иреннәрен эштән чыгарып буяган карт “фирештәләр”дә, әйдәңез, әйдәңез, дип, ачык йөз белән каршы алдылар...

Гаҗиб матур, зур кара чәчләрен иңенә салындырып, гимназисткалар формасында кыска күлмәк кигән яшь бер кыз кайдандыр килеп чыкты да, һичкемнән һичнәрсә сорамыйча, Булатовны кочаклап алды, пианинога уйнарга кушты, егетнең карышуына карамастан, зал буенча җенләнеп әйләндерә, акылыннан шашып бии башлады... Аны ташлап, Сәлимовка килде дә: “Әйдә, җырлыймыз, Гали абзый, “Ашказар”ны уйна!!” – диде.

Сахиб белән Маһи да катнашты.

Зал тынды, “Мәхәл”нең төрле бүлмәләреннән кызлар, кунаклар, тышкы киемнәргә төренеп, тыңларга чыктылар...

Иң үтереп, иң зур гыйшык белән җырлап барган йиреннән “гимназистка” кинәт тукталды да “җитте” дип кычкырды.

Компания өчен зур бер бүлмә бирделәр, күпләрнең үзләренең кызлары керде, гармунчы чакырылды... Пивоны ике егет чак ташып өлгертәләр иде.

Җыр, уен-көлке ара-тирә парлап югалулар, шау-шулар белән таң атып яктыра башлаганы сизелми дә калды...

Кунаклар эштән чыгып исергәннәр, үзләрен-үзләре белмәслек хәлгә килгәннәр иде...

Ничек, кая, кем белән туры килсә, шулай төрле бүлмәләргә таралып аудылар.

Компания таралгач, “гимназистка” Гөлнур Булатовны креслога утыртты да, үзе аның алдына менеп:

– Күптән күренмисең, үзеңне сагынып беттем, ничә бардым – номерыңда юксың... – дип, ярым үчекләү, ярым иркәләү тавышы белән аңа иркәләнә башлады. Ләкин егет изелгәннән изелә, хәлсезләнеп ава бара иде...

Болар шул хәлдә утырганда, коридорда Сахиб белән Баязид карый тавышы ишетелде. Булат иптәшләрен чакырды, киенгәннәр, кайтырга торалар, артык исерекләр, ава-түнә бүлмәгә керделәр дә акылдан язган күзләре белән теләгән йирләренә туры карый да алмыйча:

– К...айтсаң, әйдә... без... киттек... – диделәр.

Булат кузгалды. Гөлнурның: “Китмә, үпкәлим, җылыйм, яратмыйм”, – дип ялынуларына карамастан, әллә кайларга таралып беткән фуражкаларын, пальтоларын таптырды да, өч исерек кочаклашып, ава-түнә чыгып киттеләр.

Бәхеткә, ямщик бар икән. Туры Сахибның номерына кайтып, чишенми-нитми, кайсы караватка, кайсы диванга егылдылар.

## XVI

Болар уянганда, кич булып килә иде инде.

Баязид карыйның бик, бик күптәнге гадәте бар: ул авыр газаплар белән төн кичерә дә, һәммә иптәшләреннән элек торып, караватына утыра, һичкемгә мәгълүм булмаган бер көйне әллә нинди эчке әрнү белән сузып-сузып моңланырга керешә иде. Бу моң егетнең йөрәк түрендә сызланып яткан ниндидер бер ярадан, бер фаҗигадән икәнен хис иткәнгә, һичкем һичбер вакыт игътираз итми[1] иде. Баштарак качкын Хәбиб белән Сәлимов: “Сиңа ни булды, ник болай анасын югалткан бозау кебек мөңрисең”, – дип

[1] *Игътираз итми* – каршы төшми.

көләргә уйласалар да, сүзләре аз гына да әсәр итмәгәч, болар да ташлаганнар иде.

Бүген дә Сахиб белән Булат Баязидның шул авыр моңы астында уяндылар... Башта аңламадылар: болар кайда? Давыдтамы, ресторан кабинетындамы, “мәхәл”дәме, әллә башка берәр йирдәме? Бу моң кайдан килә икән?

Эшне аңлагач, Сахиб та озын бер көйне сузды, аңа, аксый-аксый булса да, Баязид белән Булат та кушылды. Бара торгач, соңгы вакытта үз араларында көн-төн көйләнә башлаган “Нигә болай?”га барып җиттеләр...

Кемдер ишек какты. Ахры, яңлыш булгандыр, ачсалар, анда бер кеше дә юк.

Авыр кузгалып тордылар, тән арыган, аяк-кул тарау, баш тубал чаклы булган. Киенеп җуынганчы, сәгатьләр үтте. Баязид карый тору белән, баш төзәтү өчен, пивога йибәргән икән, самавыр белән бергә ул да килеп җитте. Авыз тәмсез, аз гына да кабасы килми иде. Берәр яртышар чынаяк чәй эчтеләр дә яңадан пивога тотындылар. Ул әзрәк төзәткән кебек итә башлады...

Баязид үлек кебек иде. Сахиб аңа карап аптырады: ни булган бу егеткә? Килгәннән бирле аның шатланган, көлгән вакытын күргәне юк. Җүнләп сөйләшми дә. Элгәре эчкәч кәефләнә иде, хәзер ул да калмаган... Йөзе, әйтерсең, гасабилыктан көйгән, күзләре әллә нинди бер югалтунымы, мәхрүмлекнеме, эзләп тә таба алмаунымы, тирән бер әрнүне, сызлануны‌мы, белмим, ниндидер бер газапны аңлаталар... Кайбер вакыт берничә сүз белән үзен дә, бөтен дөньясын да сүгә... Телендә иң күп йөргәне: “Чәнчелсен, кадалсын, чукынып китсен!! Төкер бөтен дөньясына!! Барыбер бер нәрсә дә чыкмый!!” – дигән кебек ачы, агулы, өмидсез сүзләр иде.

– Менә, – ди, – Сахиб иптәш, безнең тормыш шул инде: жандармериянең тозакларыннан, зинданнардан бушаган вакытта бер атна, атна-ун көн бикләнеп укып ташлыйсың, имеш, аттестатка хәзерләнәсең... Кирәк булса, мин үзем ул профессорларга “аттестат зрелости” урынына “акылга зрелость” өйрәтер идем, хәзер дөнья аларныкы, әлләни эшләп булмый... Рус теленнән двойка алып, утызга җиткәч, имтиханнан куыла-куыла һаман барасың шунда... Кем белән булса да, азрак бушану өчен, бер парны, эчеп чыгарга дип, ресторанга барасың... Башкалар очрый, компания төзеп, дөньясын бер онытасың... Ул трактир ябылгач, икенче, аннан Васильевка барып, сәгать дүрткәчә “тибәсең” дә, актык акчаларыңны җыеп, булмаса, берәрсен җиде төн уртасында уятып, бурычка алып, Сәлимов әйтмешли, “мәхәл”гә китәсең... Кызыл фонарь... Акшарлы кызлар... Кәрзинкәләп ташыган пиволар, майсыз арба кебек лыгырдаган гармун,

карлыккан “фирештәләр”, шулар белән эштән чыгып, исереп, бер йиргә авасың... Иртән уянсаң, үзеңне, тирә-ягыңны, “фирештәңне” күрмәс өчен, бөтен дөньяны бирерлек буласың. Бүлмәң әллә нинди әчеле-төчеле исләр белән тулы, караватың, аяк астың адәм карагысыз шахшы. Кичә исереклек белән яныңа кереп яткан кызың үзенең карт тәне, капчык кебек салынган буш күкрәге, дөньяның һәммә буяуларын сөртенеп беткән җирәнгеч, акшарлы йөзе белән синең косасыңны китерә... Башың эштән чыгып авырый... Үзең кузгала да алмыйсың, шулай ватылгансың... Менә шунда инде адәмнең үзен-үзе үтерә торган минутлары... Бу уй миңа менә шундый чакларда һәрвакыт башыма килә...

Шул авыр газап белән дөньясына, туган көнеңә ләгънәт укып, барын каһәрләп, барына төкереп, шул җәһәннәмнән чыгасың... Ярый акчаң булса, ат яллап кайтып китәсең... Кайбер вакыт шул газаптан соң, баш төзәтергә дип, бер-икене эчәргә керәсең дә, шул “Иванов”лар, “Васильев”лар ябылгач, зур компания төзеп, тагы шул “мәхәл”гә барып төшәсең...

Сахиб үз гомерендә Булатовның болай сөйләгәнен күргәне юк иде. Ул аны үз теләге белән юл ярып бара торган каһарман дип уйлый иде... Боларны башына сыйдыра алмады... Зарифның бит, күзен җуып, чәчләрен тарап, фуражкасын, пальтосын бераз сөрткәләп кигәнен карап торды да үз йөрәгендә атна-ун көн буенча сызланып йөргән мәсьәләне ачты:

– Ә соң, революция кая, социализм кая?

Бу сүзләр Баязидның да башын күтәртте, ул бер Сахибкә, бер Булатның күн фуражкасына карады.

Булат, аз гына да уйлап тормыйча, ачык, садә җавап бирде:

– Иртәгә кояшның чыгуына ышынасызмы?

Сахиб балалар кебек: “Ышанам!” – диде. Баязид, мин ышанмыйм, дияргә уйлады, ләкин нидер буны әйтүдән тыйды!

Булат эчке җитди тавыш белән:

– Иртәгә кояш чыгуына ышансаң, революциягә дә ышан! – диде.

– Ә соң, миңа хәзер ни эшләргә?

– Шәһәр читеннән ике сумга бүлмә ал, биш сумга студент ялла да бикләнеп укырга тотын! Безнең арада хәзер сиңа файдалы эш юк. Кирәк сәгате җитү белән, без сезне барыңызны да яңадан чакырырмыз...

Булат исәнләшеп чыгып китте.

Бераздан, һава алып керим дип, Сахиб та чыкты. Баязид: “Мин бераз утырам әле”, – дип калды.

Сахиб, үзе чыгуга, бүлмәсенең эчтән бикләнгәнен ишетте.

## XVII

Ике сәгатьтән урап кайтса, бүлмә һаман бикле. Уты да яндырылмаган. Шакылдатты – җавап юк. Әллә ачкычны үзе белән алып китте микән дип, шырпы яндырып карады: юк, китмәгән, ачкыч эчтә. “Баязид, ач, ач”. – дип, бик озак шакылдатты – һаман тавыш-тын юк.

Сахиб куркып китте: бу ни хәл? Адәм бу чаклы каты йоклармы? Берәр эш булмаса ярар иде.

Номерның хуҗасын, официантны чакырды, алар ачкыч яратырга маташтылар, булдыра алмадылар.

Ахыр, остадан бикне ваттырып кереп ут яндырсалар, Баязид карыйны асылган таптылар. Бик артык салкын акыл белән эшләнгәнгә охшый: Сахибның әйберләр бәйләп килгән озын җебе түшәмдә элек лампы[1] тагар өчен куелган ыргакка бик ныклап бер башы белән беркетелгән, икенче башыннан бик уңгайлап, муенчак ясалган... Муенга салгач, басып менгән урындык аяк белән читкә тибеп йибәрелгән – шуның белән үлем килгән.

Ахры, байтактан асылынгандыр, болар кергәндә кул-аягы каткан, тәне бөтенләй суынган, йөзе каралган, күзләре әллә нинди коточыргыч бер диһшәт белән каядыр карап, ачылып туктаганнар. Авыз эштән чыгып бозылган, тел, бер чирек булыр, тышка чыгып, каралып салынып тора...

Хуҗа буны күргә куркып, харап итәсез, минем номерыма китереп, кеше үтергәнсез, башым Себергә китте, дип акырып йибәрде... Бөтен номер җыелды. Кем, кызганып: “Имансыз үтте, аз гомер өчен үзен мәңгелек җәһәннәмгә салды”, – дип шелтәли, кем, ни әйтергә белмичә, аптырап карап катты.

Полицмя килеп протокол ясаганчы, Давыд, Булат, Госман, Сәлимов килеп җиткәннәр иде инде... Йөзләре артык җитди иде. Ләкин һичберсе мәрхүм иптәшләре хакында шелтәгә охшаш бер генә дә сүз әйтмәделәр.

## XVIII

Имамнардан бере: “Шәригатемездә катле нәфес[2] хәрам, катиле нәфес[3] әл-гаязе биллә[4], мөртәттер[5]”, – дип җеназа укырга теләмәде. Буны ишеткәч, иптәшләр дини мәрасимнәрдән[6] башка күмделәр.

Кеше аз булды. Мәетне ат белән иттеләр. Якын иптәшләрдән һичбере калмый барды.

---

[1] *Дөресе*: лампа.
[2] *Катле нәфес* – үз-үзен үтерү.
[3] *Катиле нәфес* – үз-үзен үтерүче.
[4] *Әл-гаязе биллә* – Аллаһ сакласын.
[5] *Мөртәт* – диннән язган кеше.
[6] *Дини мәрасимнәрдән* – диндә рәсмиләшкән гадәтләр, йолалар.

“Ник үлгән?” дигән сүз булмады. Мәрхүмнән: “Үлүемдә һичкемне гаепләмәңез... Иптәшләр минем үлүемне аңлар, табигый табар, башкаларның ничек каравы әһәмиятсез... Анам белән сеңелләремә ишетелмәсен өчен, гәзитәгә яздыра күрмәңез, аларга, авырып үлде, дип хәбәр йибәреңез... Буны Давыд сиңа тапшырам...” – дигән бер язу калган иде. Бу булмаса да, Баязидның язмышын, рухын белгәннәргә мондый хатимә[1] табигый күренәчәк иде. Хәятында вакытында якынлыклары зур булмаса да, Сәлимов кашында бу фаҗигале үлем Баязидны бик югары мендерде.

Ахры, шул тәэсир беләндер, каберстаннан кайтышлый, һичкемне атамыйча:

– Иптәшләр, Баязидны яд итәмез[2]... Үзен аңа якын дип белүчеләр хәзер туры миңа барыңыз, – диде.

Һәммәсе дә килделәр.

Аракы күп, пилмән дә байтак хәзерләнгән иде. Ләкин һичкем аз гына да исермәде.

Давыд аз, кыска сүз белән мәрхүм Баязид карыйның бөтен гомерен сөйләп чыкты: мәгъсум бала чагында Каргалы мәдрәсәсендә намаз укымаганлык өчен, биш йөз шәкерт алдында әчелеккә яткырып сугуларын, бер марҗа белән йөри, имеш, дигән гайбәт буенча тагы да хур итүләрен, аннан китеп, акчасыз, телсез, тәҗрибәсез көенчә, Русиянең төрле караңгы почмакларында әллә ничаклы газаплы тормышларда булуын, революция якынлагач, зур өмид белән эшкә тотынуын, беркөн, яныпкөеп килеп, атасын, мөфтине, тагы кемнәрне үтерергә карар биргәнлеген сөйләвен, татар шәкертләрен террор юлында оештырырга теләү белән янганын, зинданда газаплануын, контрреволюция җиңгәч, революциянең болай изелүен башына сыйдыра алмаганлыгын, һичбер эшкә кулы бармаганлыгын, ахыр барып, киләчәк якты көннәргә иманы беткәнлеген тасвир итте...

Булат, кайта-кайта, русларда “человек-душа” дигән сүз бар, Баязид шул иде, ди...

Сәлимов, стаканын күтәреп:

– Намус белән яшәде, намус саклап үлде! Буржуалар чанасына утырмады! Баязид рухына эчәмез! – диде.

Чәкәшеп, бер тамчы калдырмыйча эчтеләр.

## XIX

Сахиб, Баязид фаҗигасеннән бераз айныгач, мәрхүмнең кара көйгән йөзе, бер чирек булып, тышка чыгып салынып торган кара теле төннәрдә күз

---

[1] *Хатимә* – эпилог.
[2] *Яд итәмез* – искә алабыз.

алдына килеп газаплавы бераз кимегәч, шәһәр читеннән тәңкә ярымга бүлмә алды, дүрт ярымга студент яллады да укырга кереште...

Бер көн аңа студенты: “Сез Булатовны беләсезме, кичә шуны урамда тотып алып киттеләр”, – диде.

Сахиб, Ходаем, тагы ниләр бар икән, дип, Булатлар торган номерга барса, жандармнар Давыд Урмановны алып төшеп киләләр. Күзләренә ышанмады, татарча: “Сез кая барасыз?” – дип дәште.

Давыд жандармнар башлыгыннан: “Миңа бер-ике сүз әйтергә мөмкинме?” – дип сорады.

– Русча булса, ярый... – диделәр.

Урманов Сахибтән шушы ике-өч көн эчендә участкага, анда булмаса, шәһәр зинданына тәмәке һәм китаплар итүен үтенде.

Егет вәгъдә бирде. Тоткын, иптәшенең йөзенә чыккан борчылуын күргәч:

– Тыныч булыңыз, курка торган нәрсә юк... Безнең язмыш шул инде... Бу – артык гади эш! – диде.

Давыдны бер тәүлек участкада тотып, аннан ары зинданга озаттылар.

Ул ялгыз иде. Камерасы Солтан Гәрәй белән бер коридорга туры килә иде.

## XX

Булатов Зариф белән Давыд Урмановның ябылуына бер атна дигәндә, Тангатаров, йомышчы малай аркылы, Кадыйр бай углы Йосыфҗаннан кечкенә бер хат алды. Кич сәгать җидедә анарда җыелыш булачак икән, шуңа чакырган, килми калмаңыз, 1) мөселман клубы ачу, 2) җәмгыяте хәйрияне аякка бастыру кебек мөһим мәсьәләләр бар, ди, вакыт сыйдырса, картлар таралгач, Госманның рефераты да була икән. Егет аптырады: барыргамы, юкмы? Анда җуан корсаклы байлар, фахиш байбәтчәләр, байлар алдында калтыранып, аларга тәрилкә тотып, Кадыйр әфәнденең сүзе хак, фәлән-төгән дип, нифак саткан[1] мәшһүр татар җәмәгать хадимнәре, татар мөхәррирләре белән ничек бер мәҗлестә утырасың?

Бәлки, бармый да калыр иде, яхшы киенеп, ал галстуклар тагып, әллә тагы, битләренә пудра сөртеп, үзенчә камил аля франк булып беткән Җиһангирның килүе Тангатаровның шөбһәләренә каршы:

– Юкка бала булма, дөнья хәзер икенче якка китте!! – дип, кискен рәвештә димләве мәсьәләне өзде.

Ул җуынды, кырынды, бераз сипкелле йөзен чак кына шомартты, яңарак алган студент форма киемнәрен какты, сөрткәләде дә икәүләп чыгып

[1] *Нифак саткан* – икейөзлеләнгән.

киттеләр.

Кадыйр байның ике катлы зур таш пулатына барып ишекне ачуга, боларны бик яхшы киенгән олугсыманланган, бик аз гына түгәрәкләнеп корсагы да үсеп килмәктә булган Фәхри:

– Рәхим итегез! Сез ник болай соңга калдыңыз!! – дип, ачык йөз белән каршы алды.

Чыннан да бераз соңгарак калганнар икән: болар кергәндә матур җәнүб гөлләре, кыйммәтле җиһазлар белән зиннәтләнгән олуг залның уртасында һәртөрле тәмле нигъмәтләр, яхшы вареньелар белән тулган зур өстәлнең тирә-ягында, шыгрым тулып, кунаклар утырган иде. Иң түрдә бер хәзрәт, аның уң ягында Гали бай, Садыйк миллионер, сул яганда сабынчы Заһид, тиречe Вәли, алардан түбәнгәрәк һәркем, хәлле хәленчә, байлыгы нисбәтендә урын алганнар.

Йосыфҗанның тәкъдиме белә Госманны рәис сайладылар. Ул яхшы тройка, кечкенә кара кәләпүш кигән иде.

Милләт, дип, төрек-татар халкы артта калган, дип, җәмгыяте хәйрияләр бу юлда беренче чара, дип, озын гына нотык сөйләде. Моңа каршы Кадыйр бай:

– Җәмәгать, сүз белән эш чыкмый: кем күпме бирә ала? Миннән – биш йөз сум! – диде.

Барлыгы ике мең ярым акча җыелды, килмәгәннәрдән җыярга дип, тиречe Вәли белән Госманны, элекке фитнә башлыгы – приказчик, хәзер яшь сәүдәгәр Фәхрине сайладылар.

Хәзрәт фатиха бирде. Мәҗлес: “Әмин, әмин”, – диде. Шуның белән могтәбәр байлар таралды, яшьләр генә калды. Бераз сөйләшкәннән соң, кирәк кешеләрнең килеп җитмәвен бәһанә[1] итеп, мәсьәләне икенче мәҗлескә кичектерделәр, Госманга клубның низамнамәсен – уставын хәзерләргә тапшырдылар.

Кеше азайгач, Йосыфҗан, хадимәне чакырып, үз бүлмәсенә чәй хәзерләргә кушты. Яшьләр шунда чыктылар.

Ике-өч сәгать буена тәмәке тартмау барын да бик газаплаган иде, Йосыфҗан бүлмәсенә керү белән, һәммәсе:

– Уф-ф... үлә яздым... тартсаң, яхшы түгел кебек тоела! – дип, папиросларга тотындылар.

Госман әллә кайчаннан ук “Милләт нигезләре” исемендә реферат укымак булып йөри иде, чәй килеп берәр чынаяк эчүгә, шуны тыңламак булдылар.

---

[1] *Бәһанә* – сылтау.

Тангатаров башта ук:

– Кичәге социалист-интернационалистның бүген милләткә чакырып язган нәрсәсен тыңлап карыйк әле: үзенең мөртәт булуын нинди суфизм белән акларга маташа икән? – дип чәнчеде. Җиһангир дәшмәде. Аның башында томан иде. Акчулпанов бик тирән уйлы, салкын канлы кеше булып:

– Тангатар, син һаман балалыктан чыга алмыйсыңмыни әле? – диде.

Госман укырга хәзерләнгәч, тирә-якка карап, Йосыфҗанга сөаль бирде:

– Рауза ник юк, әллә чакырмадыңмы?

– Чакырдым, чакырдым: анакае авырый, бик теләсәм дә бара алмыйм, гафу итеңез, – дигән...

Тангатаров көлде:

– Балга барасы бардыр, яисә аңа өйләнергә ниятләнеп йөргән фабрикант Абызовны көтәдер?!

Шул арада ак йөзле, тулы тәнле асрау килеп: “Йосыфҗан абый, анда бер кеше бар, сине сорый”, – диде.

Йосыфҗан чыгарга өлгерә алмады, үзенең зур гәүдәсе, алга таба калкып чыккан таза, киң күкрәге, ачык киң йөзе белән, ишектән үк нидер сөйләп, көлеп, егетләрнең иске танышы Нигъмәт казый килеп керде.

Буны ничә еллар күргәннәре юк иде, сикереп торып, сөйләп-көлеп, шатланышып күрештеләр...

– Нихәл? Бер дә күренмисең, кайдан җил ташлады?! – дип сораша башладылар.

Нигъмәт көттермәде, сораттырмады, соңгы еллардагы вакыйгаларын берәм-берәм сөйләп китте.

Ул имтихан тоткан да, авылына кайтып, эшкә тотынган... Мулла да, учитель дә, мөгаллим дә, кооператор да, умартачы да, сәүдәгәр дә... Кайтуына аз гына вакыт үтсә дә, “Ярдәм” җәмгыяте, “Җәмгыяте хәйрия”, “Өяз кооперациясе”, “Умартачылар җәмгыяте” ачып өлгергән. Һәммәсендә аны рәис сайлаганнар... Өязне җәдид мәктәп белән тутырган... Тиз арада бөтен губернаны кулга алып бетмәсәм дә, шуңа якынлыйм, аннан соң монда, шәһәргә күчеп, “Милләт” исемендә нәшрият һәм мәгариф җәмгыяте ачачакмын, буңа хәзердән нигезләре салына башлады инде...

Аны көчләп диярлек туктаттылар. Госман русча рефератын укыды...

Миллиятнең төп нигезләрен, милли көрәш юлларын саный, күрсәтә дә төрек-татар халкының милли бөтенлеген саклау өчен чаралар эзли, яшьләрне юк хыяллар белән баш ватмаска өнди. 5 нче елдагы[1] кызыллык модасы миллиятемез өчен зур агу, гаҗәеп тоткар булды, ди. Акчулпанов буны

[1] Биредә: 1905 ел дип аңларга кирәк.

куәтли, Нигъмәт казый Госманны кочаклап үбә, рәхмәт укый. Ислам яшьләре кызыл мода һәм тәкълид бәласе белән үз милләтләреннән ваз кичкәндә без ялгыз идек, ул вакыт “миллият”, “милләтче” дигән сүзләр бер кара йөзлек, хурлык иде. Хакыйкать өсткә чыкты: безнең кичәге дошманнарымыз, кичә мода, тәкълид афәте белән күзләре сукырайган яшьләремез бүген үз аналары кочагына яңадан кайттылар. Өмид зур, төрек-татар милләте үзенең борынгы шәүкәтен[1] кайтарачак, дип, озын, куәтле нотык сөйли...

Тангатаров, кызып, әрнеп, зәһәрләнеп бәйләнә:

– Сез кичә интернационалист идеңез, сез кичә инсаниятче идеңез... Милләтчелек – сезнең кашта халыкны алдау өчен буржуазия ялчыларының ялган пәрдәсе... Милләтчеләр – бары да корсак коллары, бары да байларның ялчылары иде... Безнең “Таң”, “Урал” гәзитәләремез Фатих Кәримиләрне, Рәшид казый, Тупчибашларны, Акчураларны[144+] сатлыклар, шарлатаннар, буржуазия ялчылары дип пычраклады, Гаспринскийны[145+], милли хис, милли бөтенлек юлы белән барган өчен, “Сез егерме биш еллык карт хулиган” дип сүктеңез!! Инде бүген шулар юлына төшәсез... Байларның садакасы, хәзрәтләрнең фатихасы белән Җәмгыяте хәйрия ачып, халык алдыйсыз! Социализм белән башлап, Җәмгыяте хәйрия белән бетү – бу бит адәм хурлыгы!!

Нәрсәгә ышанырга: сезнең эшләреңез эшче-крәстиянне социализмга чакырган вакытта ихлас идеме, әллә ул вакыт сез, монафыйклар булып, хәзер буржуазиягә хезмәт итүеңез чын күңелдәнме? Әллә сез тирә-ягына карап төсе алмашына торган хамелеоннармы яки кем күп бирсә, шуңа эшли торган сатлыклармы?

Тангатаровны һичкем якламады. Госман, Нигъмәт, Акчулпанов аңа каты бәйләнделәр, байтак эчеп тә алганнар иде, сүз артык кызды... Тангатаров, иптәшләренең тыярга тырышуына карамастан, күзләрен кан баскан хәлдә акырып, бер Акчулпанов, бер Госман өстенә килә иде.

– Җә, мөртәтләр, җә Госман, җә Акчулпан, сөйләңез!! Кайда татарларны ялкынлы нотыклары белән социализмга чакырган Госман?!

Госман бераз исерек иде. Шулай да гаҗәб ачык, садә җаваплары белән каршылый торды:

– Ул Госман кая, дисеңме?

– Шулай, дим.

– Ул үлде!!

– Аның идеаллары, аның идеаллары кая?

Госман ачы көлде, җавап бирмәде.

[1] *Шәүкәтен* – бөеклеген.

– Димәк, болар да үлделәр!

– Үлделәр, туган, үлделәр!!

– Революция дә, сыйнфый көрәш тә беттеме?

– Ул да!!!

– Хәзерге тормышның эшләүче белән эшләтүче, хезмәт белән капитал арасындагы җәберле мөнәсәбәтнең зарури нәтиҗәсе, азатлык, тигезлекнең гамәли татбигы[1] булган яңа дин – социализм да беттеме?

– Ул да бетте!

– Аларны кем алды? Алар ник бетте?

– Алар язгы таңның матур хыяллары, яшьлекнең ал чәчәкләре иде, аларны каты тормышның хыялга, өмидкә иярми торган кара көчләре алды!!

Тангатаров артык сөйләшмәде, тутырып берне эчте дә һичкем белән исәнләшмичә чыгып китте... Иптәшләре:

– Бу егет һаман шул хыялдан котыла алмаган икән әле! – дип көлеп калдылар.

## XXI

Инде ни эшләргә? Башны кая куярга?

Үз бүлмәсенә кайтып бикләнгәч, Тангатаров, мәҗнүн кеше кебек, шул сүзләрне кычкырып сөйли-сөйли, бер почмактан икенче почмакка кызу адымнар белән йөрергә тотынды.

Чыннан да мин бәламе, мин хыялыймы? Әллә алар вак җаннар, сатлыкلармы? Алар хамелеоннармы? Хакыйкать кайда?

Ай, качкын Хәбиб, Булат, Давыд Урмановларның берсе булса, мин, вакытның төн булуына карамастан, аларга барыр, уятып керер дә авыр фаҗигане сөйләп бирер идем!! Революция өчен, социализм өчен, мин бөтен нәрсәмнән ваз кичтем... Гимназиядән куылып, сасы бүлмәләрдә ач, ялангач яшәдем... Рауза һәрвакыт минем тез башым белән терсәгемнең җыртылуыннан дустанә көлә иде. Ул вакытта ташлаган гимназиянең программасын үтү өчен, хәзер күпме мәшәкать кирәк булды... Инде килсеннәр дә шуларның барын утка яксыннар, имеш: балалык, хыял!! Буңа ничек риза булырга? Ни эшләргә? Кайда яктылык? Кайда юл?

Бичара Баязид та шулай газаплангандыр, шул авыр фаҗигаләрдән чыга алмыйча, үзенә-үзе кул салгандыр!!

Тукта, Баязидның бит миндә берничә хаты бар иде. Ул вакытта аңламаган идем... Анда да шул фаҗигаләр язылган иде, бугай!!

Бичара намуслы җан нәрсә, ди, нәрсә, ди? Сүзләре берсеннән-берсе

[1] Татбигы – чагыштырып карау.

ачырак, берсеннән-берсе агулырак: “Үзең, үз бәхетең юк иде, кирәкми дә иде... Син гомум өчен яна, шул юлда эшләвең зур сәгадәт тә бирә иде... Кемдер, мин үзем өчен яшәмәдем һәм яшәмәм, дигән. Бу сүз – минем Инҗилем, Коръәнем иде... Күңел ал канатлар белән гаршеләргә[1] оча, йөрәк бөтен йир йөзен җәннәткә әйләндерү өмидләре белән ашкына иде... Нидер булды, ниндидер, каты, рәхимсез җилләр исте. Адәм ничаклы гына очынмасын, күңел никадәрле генә ашкынмасын – ул гаршеләргә менә алмый икән... Басыл, йөрәк, син туфрактан!!

Көч бетте, зиһен таралды, яшьлек үтте, диләр. Болар тагы бер хәл икән... Өмид бетте, иман бетте – менә фаҗига кайда?!

Беркемне сөймәгәч, һичбер нәрсәгә ышанмагач, дөньяда ничек яшәргә кирәк!! Карта, фәхеш, аракы – болар вакытлы оныттырырга ярыйлар, ләкин бөтенләйгә тынычландыра алмыйлар! Башта – томан, йөрәкне ачы имансызлык агуы ашый, тирә-як караңгы! Әйт, ни белән, ни өчен яшим?! Толстойдан, Ницшедан юл эзләдем. Ләкин болар да коткара алмады... Акчулпанов, мине индивидуализм коткарды, ди. Мине шуңа чакыра... Ләкин минем җанымны ул туйдыра алмый...”

Үзенең фикерләре, шөбһәләре, мәрхүм дусты Баязидның хатлары, шул фаҗигаләрдән чыга алмый үлгән кадерле иптәшемнең асылган гәүдәсе, янып каралып, тышка салынган зур теле, коточкыч күз карашы белән саташып, җенләнеп төн үткәрде дә иртән сәгать сигездә үк зинданга китте.

Табигый, аны кертмәделәр. Рөхсәт кәгазе ал, диделәр. Ашыгып, тирләп, жандармский полковникка китте. Ул кабул итмәде. Әнисеннән хәбәр бар, мин – аның кардәше, дип, һаман китмәгәч, кылычлары, шпорлары белән шалтырап, бер офицер чыкты да усал, шөбһәчел күзләре белән Тангатаровның акылдан шашкан күзләренә, студент фуражкасына карап:

– Сезгә ни кирәк? Ник әйткәнне аңламыйсыз? – диде.

Егет, янына ук килеп, офицерның күзләренә текәлде:

– Сездә кешелек юкмыни? Ник мине күрешергә кертмисез?

Офицер ачу катыш мәсхәрә белән көлде:

– Зиндан сездән башка да бик артык тулган... Кайда куярга урын тапмыймыз. Әгәр сез болай гомумның тынычлыгын бозып йөрсәңез, мин сезне айныганчы участкага озатырмын. Анда тиз тынычландырырлар!!

Студентымыз, яңадан зинданга барып, “Давыд иптәш Урмановка” озын итеп хат язып калдырды да, аптырап, башын каплаган томанны таратудан гаҗиз булып, өенә кайтып китте.

[1] *Гаршеләргә* – күкнең иң югары катлавына.

## XXII

– Баязид карый провакатор!!

– Баязид карый провакатор!!

– Баязид карый провакатор!!

Йа Ходай, бу гына җитмәгән иде!! Башкаларның йөзе, меңе берьюлы охранкага агент булган, дисәләр, бик артык исем китмәс иде!

Баязид бит, Баязид!! Юк, юк, булмас, яңлыштыр, ялган шөбһәдер, уйдырмадыр!! Әгәр чын булса? Йа Ходай, аннан соң кемгә ышанырга, кемгә кул бирергә?

Давыд, аптырап, яңадан Гәрәй Солтанга дивар аша чиертеп, үзенең шөбһәсен сөйләде. Алар бер камера аша гына иде. Ике уртада бик әмин[1] марҗа булганга, болар теләгән вакытта теләгәнчә хәбәрләшә алалар иде. Баштарак, карцерга ябам, дип, бик артык бәйләнсә дә, хәзер Габдәһ абзый ярдәме белән надзирательләрдән берсе – Крапченко яхшы ук дустланган, юк-барны күрмәскә тырыша иде.

Гәрәй Солтан тиз, кыска җавап кайтарды:

– Үз-үзеңне газаплый башларсың дип, мин сиңа ул хәбәрне әйтмәскә дә уйлаган идем, муенга Столыпин галстугы[146+] бик артык якынлагач, исән чакта әйтеп калыйм, саклануга сәбәп булыр дип, сиңа белдерә салдым.

Ике сүзгә урын юк: сатылган, акча алган, шуның икенче көнендә үзен-үзе аскан... Бу хәбәр миңа беренче кулдан мәгълүм.

Тоткын тар тимер рәшәткә тәрәзәле караңгы камерасының бер башыннан икенче башына ашыгыч газаби адымнар белән йөри башлады. Аның чәче, тузып, маңлаена төшкән, башы әйләнә, йөрәге урыныннан куба, бөтен тәне эсселе-суыклы булып калтырый иде... Алдында авыр дәһшәт белән шул бер сүз иде:

– Баязид карый провакатор! Ул сатылган да икенче көнне үзен-үзе аскан!!

Бу нәрсә? Бу фаҗигане ничек башка сыйдырырга?!

Йөри-йөри арып хәлдән тайгач, йөрәк тә акрын эшли башлады, җаны да бераз тынычланган кебек булды.

– Бичара, өмиден, иманын югалткандыр да, акылдан шашып, үзен саткандыр, намуслы җаны бу хурлыкка чыдый алмагач, үзен-үзе саткандыр!!

Тоткын бу фаҗиганең тәфсыйлен күз алдына китерергә тырышты, ләкин бонардан гаҗиз: ничек кенә тарткалашсаң да, бу кара вакыйганы Баязидка ябыштырып булмый!! Һәрбер сәяси тоткын алдына, бигрәк тә беренче элэгүдә бундый тозакны салалар, әллә нинди авыр җәзалар

---

[1] *Әмин* – биредә: ышанычлы мәгънәсендә.

булачагын хәбәр биреп, үзләренчә хакыйкатьне сөйләү революционерча хыянәт итү шарты белән мәхбүснең[1] авыр язмышын җиңеләйтергә вәгъдә кылалар.

Давыд Урманов иптәше Зариф Булатовның бу хакта үз башыннан үткән бер вакыйганы тасвирын хәтерләде.

Егетнең беренче эләгүе... Әйтерлек зур эш тә юк... Шулай булса да, элек участкада, аннан соң шәһәр зинданында ялгызын яткыралар, сорау юк, китап-кәгазь, хәбәрләшү, күрештерү юк... Өч айга якын шулай газаплаганнан соң, аны жандармский полковник чакырта. Пакь кына, чибәр генә бүлмә. Уртада яшел постаулы зур өстәл, аның бер башында ниндидер “эш” (делолар) яталар, икенче башында графина белә су, бер стакан, бакыр пепельница.

Кылычлы, мылтыклы каравыллар белән Булат барып кергәндә, бүлмәдә һичкем юк. Бераздан зур буйлы, хәрби киемле, киң ак сакаллы полковник ачык, шат йөз белән эчке яктан килеп чыга да көттергәне өчен нәзакәтле рәвештә гафу үтенә, утырырга урын күрсәтә, көмеш портсигарын чыгарып, яхшы папирос тәкъдим кыла. Соңра тоткынның өстендәге җыртык пальтога, өч айдан бирле кырылмаганлыктан, бөтен йөзен каплап килгән кара сакалына, җитеп, тузылып торган чәчләренә, формасы бозылып, читләре салынып төшкән кара эшләпәсенә текәлеп карый да бераз кызганулы дустанә тавыш белән, кардәшчә елмаеп, сүз башлый:

– Йа Ходай, – ди, – сездә адәм төсе калмаган... Рәсемеңездә сез яшь принц кебек күренәсез... Ә хәзер кем булгансыз... Ышанмасаңыз, көзгегә караңыз... Мин сезне кызганам... Үз балам, якыным кебек кызганам... Дөрестен сөйләсәңез, мин сезгә җиңеллек ясатырга бар көчем белән тырышачакмын. Юкса, сезгә бик күп нәрсәләр өяләр, юкса сезне бик авыр көннәр көтә, – ди. Аннан соң үзенең яшь чакларын. Кайчандыр Маркс белән, социализм белән янып йөргәнен әле дә Бебель[147+], Каутский[148+] кебек чит мәмләкәттәге идеалист, социалистларга тирән бер хөрмәт белән караганлыгын сөйли...

– Ләкин, – ди, – бездә нәрсә? Безнең крәстияннәр сезнең хезмәтне тәкъдир итәрлекмени? Алар бит үзләре сезне үрәдниккә тотып бирәләр!! Ә сезнең башлыкларыңыз кемнәр? Алар бит – азган-тузган жид[2] малайлары! Алар үзләре Швейцариядә рәхәтләнеп яталар, монда кайтсалар да, алтын эчендә йөзеп йөриләр. Ә сезнең кебек яшь, матур егетләрне, матур сүзләр белән алдап, ут эченә йибәрәләр... Менә без бит шуңа әрнимез... Шуларга каршы көрәшәмез... Сез яшь, истигъдадлы, тырыш күренәсез... Сезне алда

[1] *Мәхбүснең* – тоткынның.

[2] *Жид* – халык телендә еврейларны шулай атаганнар.

яхшы тормыш, бәлки, зур дәрәҗә көтә... Тугры юлга төшсәңез, үз халкыңызга әллә ничаклы хезмәт итәрсез... Мин татарларны бик яратам. Алар тыныч, тугры халык. Тик аларны агартасы бар... Үзеңезне үзеңез әрәм итмәңез. Акылга утырыңыз... Мин сездән күп нәрсә теләмим, – ди.

Хезмәте белән танылган берничә революционерның рәсемен күрсәтә. Тагы берничә сөаль бирә, җавап сорый...

Булат боларны тыңлап тора-тора да:

– Һичбер нәрсә белмим, һичберсеннән хәбәрем юк, – дип кырт кисә.

Полковник тагы сүз башлый... Тагы җәзаның каты булачагын, тоткынны кызгануын, аны коткарырга теләвен аңлата...

Мәгънә чыкмавын күргәч, Булатны яңадан зинданга озатып, ялгызын бер камерага бикләтә.

Иптәше башыннан күптән килеп кичкән бу вакыйга Давыдның күз алдыннан үтте... Ләкин жандармериянең бу тозагында Баязидны эләктерерлек бер урын тапмады. Киресенчә, ул полковникның сүзен тыңламыйча ук утырган йиреннән кинәт сикереп торырга да, гасаби ачулы тавыш белән:

– Юк, мине ул юлга тарта алмассыз!! – дияргә тиешле иде.

Адәм табигатен аңламассың, кайбер вакыт аякның яңлыш бер таеп китүе мәңгелек һәлакәт тудырырга мөмкин, күрәсең!! Кызганыч, бичара син, адәм!!

Зиндан тынды.

Надзиратель, ишектәге күзне ачып, тугыздан соң йөрергә ярамаганын беләсез бит, ятыңыз, диде.

Карышуда ни мәгънә?

Тоткын эченә салам тутырылган, каты киндер белән тышланган мендәр һәм матрасы өстенә ауган гына иде, уң як күрше камерадан Зоя акрын гына чиертте:

– Йөрәгем нидәндер, – ди, – куркына... Берәр хәл булмаса ярар иде. Бүген надзирательләр дә, ничектер, башкарак күренәләр...

– Ни булыр дисез?

– Гәрәй Солтанның хәле ничек икән? Ул үзе бик артык гади нәрсә кебек “Столыпин галстугы”, ди. Аз гына да борчылмый, пошынмый... Гаҗәп бер кеше! Сорасам, кешенең йөрәк ярасына кагылу буладыр кебек...

Зоя, сүзен бүлеп, кинәт теге якка китте. Бер биш минуттан тагы чиертә башлады:

– Миңа Гәрәй Солтан болай ди: “Дөньяның хәлен белеп булмый... Ул-бу булса, Давыд иптәш Габдәһ абзый аркылы минем Бакуда калган балаларым белән хатыныма хат йибәртсен, уңайлап аңлатсын!!”

Туташның сизгер йөрәгендә туган куркыну калын таш диварлар аша һәммә сәяси тоткыннарга таралып өлгерде, бөтен зиндан бу төнне шул эчке фаҗига белән каршы алды.

Һичкем йокламады. Нидер көтәләр, караңгы бина бу төндә ниндидер авыр бер дәһшәткә хәзерләнәдер кебек иде.

## XXIII

Зиндан тын, караңгы иде.

Төн буена йоклый алмый, нидер көтеп, хафаланып, газапланып яткан тоткыннар сәгать дүртләрдә иң түбәнге каттагы авыр тимер ишекнең бик сак кына ачылып ябылган тавышын ишеттеләр. Берничә аяк, бик артык акрын басып, тар караңгы баскычлар буенча югарыга таба менеп киләләр кебек тоелды. Мәхбүсләрдән бере, ахры, начар төш күрептер, авыр ыңгырашты, бу ни эш, дип, ачы бер кычкырды да тукталды. Зиндан тагы авыр, караңгы тынлыкка чумды.

Түбәннән килгән аяк тавышлары һаман якынлыйлар. Кемдер нәрсәдер төшерде. Икенче берәү аңар басынкы, ачулы аваз белән: “Болван, ипләп йөр!” – дигән кебек булды... Менә килеп җитәләр, менә сәяси тоткыннар коридорына керделәр...

Кемдер акрын, эчке тавыш белән: “Кайда?” – диде.

Зоя түзмәде, уяныпмы, саташыпмы сикереп торды да, атылып, ишегенә килде. Күзнең тимер капкачын тышка бәрде, ул ачылмады, надзиратель тыштан әллә нинди куркулы, каты каушаулы тавыш белән:

– Тыныч ятыңыз, юкса мин сезне богаулатырмын! – дип кычкырды.

Зиндан саташып китте. Сәяси мәхбүсләр надзирательне, аның тәһдидләрен[1] онытып шаулаша, кычкырыша, тимер ишекне ватып чыгардай булып дөбердәтә башладылар. Авыр, басынкы таш бина батып барган кораб рәвешен алды.

Ул ара да булмады, шашып, саташып барган шау-шуны, дөбердәтүләрне каты, ачы, ләкин гаҗәп ачык русча бер тавыш, әйтерсең, кисеп төшерде:

– Иптәшләр! Бәхил булыңыз!..

Кемдер каты сукты, ашыктырды, ахыргы сүзләрне әйтергә бирмәде, тик иң якын камерадагылар гына буылган, кысылгын бер аваз белән:

– Мине үтерәләр, ләкин сез безнең байракны ташламаңыз!! – дигән сүзләрне ишетә алдылар.

– Бу – Гәрәй Солтан иде.

---

[1] *Тәһдидләрен* – куркыту, янауларын.

Зиндан яшен суккан кебек катып, тынычсызланып калды. Ләкин бу бер секунд кына булды. Камералар тагы элеккедән яман авазлар, җенләнеп, шашып, ишек дөбердәтүләр белән капланды.

## XXIV

Гәрәй Солтан үзе тыныч күренә иде. Өстендә шул даими майлы тужуркасы, аягында зур итек, башында күн фуражка. Тик йөзе бераз ябыккан, иреннәре чак кына дерелдиләр, ләкин үткен кара күзләр ачу белән карыйлар иде.

Аны түбәнге катка алып төштеләр дә тәбәнәк, ярым караңгы бер залга керттеләр.

Анда байтак жандарм офицерлары, полковник, хәрби киемдә прокурор, боларның һәммәсенең алдында зур буйлы, вәхши кысык күзле, ерткыч йөзле палач тора иде. Ул баштанаяк кызыл киенгән: кызыл чалбар, кызыл тужурка, кызыл бүрек. Уң кулында нindидер җеп, сул кулында кургашын очлы каеш камчы...

Башкалар кузгалмады, ишек ачылып, ялангач кылычлы каравыл уртасында, Гәрәй Солтан килеп керүгә, палач, кинәт сикереп, аңа каршы барды, тагы артка чигеп, корбанын идән уртасында туктатты да карлыккан вәхши тавыш белән:

– Аз гына карышсаң, камчы белән ярачакмын, китер кулларыңны! – дип акырды.

Гәрәй мәсхәрәле ачу белән көлде:

– Дурак, кеше үлемгә бара, син аны камчы белән куркытмак буласың!! – дип, кечкенә тимер чылбыр белән богаулау өчен, кулларын артка каерды.

Сәяси тоткыннар арасында сигезенче камерада ялгыз утырган Тарбашев фамилияле бер мәхбүс хакында, күптән, шул палачлык хезмәте үтәмиме икән, дип шөбһәләнәләр. Кайберәүләр, тәфсыйлгә кереп, ул, мирас өчен ике сеңелесен үтерү сәбәпле, үлемгә хөкем ителсә дә, үзен коткару өчен, шул кара тәкъдиргә риза булган бер җинаятьче икән, кеше тапмагач, аны Томски зинданыннан монда күчергәннәр икән, дип сөйлиләр. Кемдер, ике ел эчендә һәммә революционерларны асып бетерә алса, аны бөтенләй азат итәчәкләр, өстәвенә, беренче “Анна”[149+] тагачаклар икән, дип көлдерә иде.

Гәрәй Солтан бу шөбһәләрнең чынлыгын үз күзе белән күрде: аның алдында шул Тарбашев иде.

Ул эченнән уйлый башлады, кайдан алып китәчәкләр: әгәр дә сәясиләр тәрәзәсе яклап алып китсәләр, ул иптәшләренә теге шөбһәләренең урынлы икәнен кычкырачак, алар, өченче катта булсалар да, бәлки, үткенрәк колаклы

берәрсе аны ишетеп калыр...

Тоткын шул уйлар эчендә торганда, палач эшне бетерде дә, кискен, җитез адым белән моның яныннан читкә таба сикереп:

– Булды! Әзерлек бетте!! – диде.

Кузгалырга әмер булды. Мәхбүсне кылычлы жандармнар озатты. Фонарьлар белән яктырта-яктырта, ниндидер тар коридорлар, бер җүеш подвал, тагы ниләр ашадыр үтеп, зинданның таш коймасы эчендә уң як почмактагы бер ташландык сарайга килеп керделәр.

Гәрәй хәтерләде: бу аның тәрәзәсеннән чак кына күренә иде. Үзенең бөек коймасы, яртылый җимерелгән түбәсе белән бу хәрабә әллә нинди бер эчпошыргыч иске караңгылыкны аңкыта иде.

Барып керсәләр, мәхбүс аптырый калды: иске таш сарай аз гына яктыртылган, аның уртасында үзенең шомлы сурәте белән, югары таба күтәрелеп, дар агачы, шуның сул ягында чалма-чапаннан бер адәм тора: күзе шашкан, ахрысы, өшидер, карасу-саргылт сакаллары дер-дер селкенәләр, ниндидер кызыл яулыкка ураган калын тышлы Коръәнен әле бер, әле икенче култыгына кыстыра.

Зинданда имам барлыгы аңа мәгълүм иде. Ләкин моңарчы, җомга укытырга киләм дигән булып, чалмасы эчендә боларга хатлар, гәзитәләр ташый торган мулла яшь кеше иде, ул, күрәсең, боның ярдәмчесе булгандыр, мондый зур эшкә имамның үзе килергә тиешле, күрәсең.

Бу фикерләр Гәрәйнең башыннан бер секунд эчендә үттеләр. Ул үзеннән-үзе:

– Хәзрәт, сез ни эшләп монда? – дигәнен сизми дә калды.

Мулла аптырады. Коръәнен тагы култыктан култыкка күчерде. Шулай да туры, ачык җавап кайтарды:

– Мин сезне тәүбә иттерергә, ахыр сулышта иман өйрәтергә килдем!!

Гәрәй йөзен чытты:

– Юкка йөрисез, сезнең алда тәүбә итәрлек гөнаһ эшләгәнем юк минем!!

Палач килеп тукталу белән, алдан әзерләп куелган урындыкка менеп, дар агачын, аның югарыгы башында җеп эләктергән йирен карады, ерткыч кебек кинәт сикереп төште дә:

– Һәммәсе әзер, – диде.

Кемдер мәхкәмәнең карарын укыды. Прокурор муллага карады. Бу, Коръәнен күтәреп, мәхбүскә килде, ләкин Гәрәй бер кулы белән хәзрәтне акрын гына читкә этәрде:

– Мәшәкатьләнмәңез!

Палач, үзенең корбанын дар агачының янына куелган урындыкка

бастырды, кемдер, моңа карый алмыйча, күзләрен каплап, читкә борылды. Мәхкүм[1] тыныч күренә, тик аның куллары белән ireннәре бераз дерелди, күзләре чак кына томаланган кебек була иде.

Алдан хәзерләнгән тегүле кәфен корбанга кидерелде. Палач, ашыгып, бераз каушап, җепне мәхкүмнең бугазына кинәт кенә салды да шул ук секундта аяк астындагы урындыкны тибеп очырды...

Ахрысы, бераз хата салынгандыр, корбан бөтен гәүдәсе белән асылынып, озын агач буенда берничә селкенде дә нindiдер ачы, авыр тавыш белән каты гырылдый башлады...

Мулла түзмәде, йөзен каплап, нидер кычкырды, мине озатыгыз, диде... Кемдер аны алып китте.

Ләкин корбан һаман да гырылдый, нindiдер авыр ыңгыраш чыгара иде... Прокурорның күз алды капланды, аяк тибеп кычкырды:

– Син бу газаптан коткарасыңмы, юкмы? Булмаса, мин шуның янына үзеңне астырам!

Палач, корбанын асылган йиреннән кочаклап, бөтен көче белән түбәнгә таба тарта башлады.

Гырылдау туктады.

Ун минуттан корбанны алдылар. Доктор, карап, эш яхшы үтәлгән тапты.

Иртәгә ташлату өчен, революционерның үлек гәүдәсен бер ящикка салдылар да ишекне бикләп таралдылар.

Таң атты. Кызарып кояш чыкты. Язның матур, аяз көннәреннән бере иде.

---

Ун-унбиш көн үткәч, Бакудагы сул рус гәзитәләреннән бере, Гәрәй Солтанны мактап, вафатнамә язды. Аның, Идел-Уралга кайтып, татар социалист гәзитәләре, оешмалары, хезмәтләре белән танышканнан соң, хәлләрен бик кызганыч табуын, шуңа ярдәм өчен экспроприациягә тотылуын, арадан берсенең, әләгеп, чәчләрен, тырнакларын суыру белән газаплаганнан соң әйтүен, башкалары котылса да, Гәрәй Солтан кулга алынуын, нәтиҗәдә, асылуын тәфсыйлле рәвештә ачып бирде.

Кырымдагы төрек-татар гәзитәсе бондан кечкенә бер хәбәр оештырды, Идел-Уралдагы татар гәзитәсе “Иштиракиюн хыялының корбаннары” дип күчереп бастылар. Бу хәбәрдә тәрҗемәи хәл юк, тик балалары, хатыны булуга карамастан, бер хыялга корбан ителүенә, татар яшьләренең иштиракь[2]

---

[1] *Мәхкүм* – хөкем ителгән кеше.
[2] *Иштиракъ* – уртак булу, катнашу; берләшү; гомумлык.

юлында көчләрен, үзләрен һәлак кылуларына тәэссеф[1] аңлатылган, яшүсмерләргә бондый юллардан саклану хакында бер үгет арттырылган иде.

Бу хәбәрне күргәч, Җиһангир, Сахиб, Тангатаров:

– Бөтен дөнья мәзлумнәренең азатлыгы юлында һәлак булган бөек корбанның кабер тупрагы суынмас борын, икенче мәртәбә палачлык итәргә тотындыңыз... Оят кирәк!!! – дип, бик ачы мәкалә язсалар да, һичкайда бастыра алмадылар.

## XXV

– Не полагается!

– Не полагается!

– Не полагается!

Менә ничә айлар инде мәхбүс Урманов шуңарга башка җүнле адәм сүзе ишеткәне юк.

Тар, озын, бөек, ярым караңгы камера. Түшәмгә якын тимер рәшәткәле кечкенә бер тәрәзәсе бар. Бу төн ягына карый, шуңа күрә бүлмәгә һичбер вакыт кояш төшми. Кайдадыр кояш бар, бугай. Тоткын кайбер чакта, караватының тимерләренә басып, шул кечкенә тәрәзәгә үреләп – кояшның йөзен күрергә тели. Ләкин бу мөмкин түгел, ишекнең кечкенә тимер күзе ачыла да аннан ниндидер тупас, калын күкрәк тавышы ишетелә:

– Не полагается!

Кайбер төннәрдә ирек искә төшә: дустларны, матур ярларны, кайнап торган хәят дулкыннарын сагынасың. Йокың оча, бер яктан икенче якка әйләнеп ята-ята газапланып, кабыргаларың авырый да ярым караңгы камераның бер башыннан икенче башына йөрергә тотынасың. Йомшак басасың, йөрегәнеңне белдермәскә тырышасың. Ләкин надзирательнең үткен колагы ишетеп өлгергән: шунда ук ишектәге тимер күзлек шалтырый, тагы шул ук тупас тавыш килә:

– Не полагается!

Кайбер вакыт эчең поша, вакытны ничек үткәрергә гаҗизсең, эшсезлектән бизәрсең, каравылның аяклары ераклашканын көтеп торасың да янәшә камерадагы тоткын белән таш диварга чиертеп сөйләшә башлыйсың. Бу сине җуата, дөньяда бөтенләй үк ялгыз түгеллекне хәтерләтә...

Ләкин бу бәхет тә озак бармый, синең сүзеңнең иң күңелле бер йирендә тагы тимер күзлек ачыла, тагы шул күкрәк авазы яңгырый:

– Не полагается!

Болар белән генә калмый, тагы бер мәртәбә күрсәм, сезне карцерга

---

[1] *Тәэссеф* – кайгырып, үкенеп, ачынып.

утырттырырмын, ди.

Утыртмагаең, кадалып кына кит, карцер дигәнең дә әлләни түгел. Бөтенләй караңгы җүеш бүлмә, урындык, караватюк, китап юк, ашарга-эчәргә каты икмәк кисәге белән коры су! Ләкин бу Давыдны куркытмый – көннәр, төннәр, атналар, айлар һаман-һаман бер төсле сузылган бу ялыктыргыч тормыштан карцерга чыгып керү, бәлки, бераз үзгәреш, бераз төрлелек бирер! Ләкин бу бичара надзиратель Крапченко һичбер вакыт андый эшкә бармаячак. Ул үзе дә яхшы кеше икән. Габдәһ абзый кайдандыр аның квартирын эзләп табып дустлашкан, шуңа күрә безгә мөмкин кадәр каты булмаска тырыша, тик үзенең өстендәге аждаһаларыннан курыкканга, шулай “не полагается!” дип, туктамый әйтеп йөрергә мәҗбүр инде!

Зиндан үзенең артык кысынкы, каты низамнары, тыныч тормышы белән тышкы дулкыннар, иге-чиге булмаган эчү, фәхеш, карталар сәбәпле, йөрәген талап, өзгәләнеп беткән Давыд өчен башта бераз вакытка ошаган[*], аңа бер хәл җыю урыны кебек булган иде. Чөнки монда сине көчләп, мәгълүм бер рамка эченә куялар: вакытында йоклыйсың, билгеле сәгатендә торасың, ашыйсың, эчәсең, ярты гына сәгатькә булса да, һавага чыгып керәсең, аннан соң укырга тотынасың!

Бераз көннәр үтеп, газаплары төзәлә, куәте ныгый төшкәч, тоткынлык үзен яңадан сиздерә, бу тар бүлмә, бу бетмәс-төкәнмәс «не полагается» туйдыра башласа да, алдында Гәрәй Солтан мәсьәләсе торуы, аның язмышының билгеле булмавы, үзе һәрвакыт “Столыпин галстугы” дип сөйләве Давыдны бик нык ишгаль итә[1], эч пошарга күп вакыт бирми, бу көннән-көн якынаеп килгән авыр күренеш башка һәммә нәрсәне – зинданын да, надзирателен дә оныттыра, көннәр-төннәр буенча бөтен уйны үзенә баглап тора иде...

Баязид асылды, Гәрәй Солтанны астылар, Гришаны сөргенгә йибәрделәр – шуның белән тоткынның алдында дөнья капланды, тормыш җәһәннәмгә әйләнде...

Беразга Зоя белән җуанган иде. Бу нечкә аңлы, нечкә җанлы туташ аз, кыска сүзләр белән, ничектер, караңгы уйларны аз гына вакытка булса да таратып йибәрә ала иде. Мең, миллион ләгънәтләр булсын ки, тоткынны бу бәхеттән дә мәхрүм иттеләр: Гәрәй Солтанның асылынуына кырык көн дигәндә, аны сөргенгә озаттылар.

Үзе кайгырмады, киресенчә, Давыдны җуатырга тырышты, ләкин хәлен яшермәде:

– 102 нче белән богаулыйлар, Акатуйга җиткерми[150+] туктатмаслар,

---

[*] *Г.Ибраһимовта:* охшаган.

[1] *Ишгаль итә* – берәр төрле эш, уй белән мәшгуль итә; биләп ала.

ахры. Лəкин бу мине куркытмый, безгə андагы зəһəр суыкта озак газапланырга тугры килмəс, минем күңелем пролетариат йөрəгенең яңадан тибə башлавын сизə, озакламас, яңадан безнең көннəр килер, – ди.

Зояны озатканнан соң, мəхбүс өчен ниндидер авыр, басынкы, томанлы көннəр башланды. Кемнедер, нəрсəнедер артык сагыну да, йөрəкне яндырып барган кайгы да, авыр уйларны югалтып йибəрəчəк шатлык та юк – шулай буш, мəгънəсез, томанлы, озын көзге төннəр!

Никтер иректəн дə хəбəр юк... Гəрəй Солтан фаҗигасе мулланың котын алган, ахры: ул да хəзер «җомга» укытырга килми. Ул, ичмаса, тышкы дөньяның хəллəрен сөйлəштерə, чалмасы эченə тыгып, хат, гəзитə китерə иде...

Иптəшлəрнең башкаларына ышаныч аз. Алардан күп нəрсə өмид итəргə урын юк.

Кая соң бу Габдəһ абзый? Габдəһ абзый!

Əллə сине дə яптылармы? Юкса, əллə син дə икенче кыйблага карап гыйбадəт кыла башладыңмы? Алай булса, эшлəр харап!! Аннан соң яңадан безнең көннəр килүеннəн өмидеңне өз дə Гəрəй Солтан артыннан кит.!!

Юк, юк, мин саташам, мин акылдан язам!!

Бөтен дөнья революциядəн ваз кичəр, ихтимал, мин үзем дə, арып, читкə ташланырмын, лəкин Габдəһ абзый белəн Заһидə җиңи өчен башка юл юк!!

Сугыш вакытында җиңелеп, бөтенлəй һəлак булган гаскəрлəрнең эченнəн берничə фидаи чыгып, зур корбаннар белəн үзлəренең байракларын сакларга тырышуларын сөйлилəр...

Габдəһ абзый белəн Заһидə җиңи дə җиңелгəн революция армиясенең байрагын саклаучылардыр!

Без җиңелдек, гаскəремез һəлак булды. Исəннəренең күбе дошман ягына чыкты – сатылды. Шул гомуми мəгълүбият[1], шул гомуми хараплык эчендə безнең байрагымыз Габдəһлəр кулында калды. Дөнья җимерелсен, реакция бөтен диһшəтлəрен юлга койсын, лəкин болар кызыл əлəмгə җинаять итмəячəклəр!!

Соң, алай булгач, ни өчен бер дə хəбəр юк!?

Давыд, шул уйлар белəн газапланып, йөрəген теткəлəп, көннəр, төннəр үткəргəндə, аңа якты дөньядан кечкенə генə бер тəрəзə ачылды: Заһидə җиңги, кызыннан яздырып, кечкенə генə хат йибəрткəн. Сүз күп түгел, мəгънəсе дөнья чаклы:

– Габдəһ абзаң каты авырып алды, инде сəламəтлəнə, тиздəн йөри

[1] *Мəгълүбият* – җиңелү.

башлар. Үзең аңла!!

Ходаем, нинди бәхет, нинди зур сәгадәт!! Дөньяда минем шундый иптәшләрем бар!! Болар булмаса, ни эшләр, ни белән иманыңны саклар идең?!

Берничә көннәр үткәч, теге шәкерт тагы “җомга” укытырга килә, аның чалмасы тагы почта хезмәтен үти башлады!!

Өмид өзәргә ярамый, революциянең угыллары бары да дошманга сатылмаганнар икән!

Менә хат! Йа Ходай, нинди озын, нинди зур хат!! Моңа бит бөтен дөньяңны бирерсең!!

Тоткын, дерелдәп, каушап, тар, ярым караңгы камерасының бер башыннан икенче башына әйләнде дә, караватына йөзтүбән капланып, хатны укырга хәзерләнде!

Чү! Тимер күзлек ачыла!

Ярый башкасы түгел, Крапченко икән:

– Минем балам, гаиләм бар, сез мине һәлак иттерәсез. Тизрәк укыгыз да, җырткалап, миңа бирегез, утка ягармын! – ди.

Ходаем, нинди яхшы кеше бу надзиратель!

Мәхбүс, яңадан капланып, мәктүбне укый башлады: “ ...Тын алырга һава калмады... Кая барсам да, кем белән сөйләшсәм дә, ябу, сөрү, асу, ату сүзләре ишетәм, төшемдә дар агачлары, кызыл киемле палачлар күреп саташам... Син мине сүккәнсең, Нәҗиб Кәмал ул дәрәҗәдә түбән төшәргә тиешле түгел иде, мин анардан күп нәрсә өмид итә идем, дип сөйләгәнсең... Чыккач күрерсең, иптәш, бөтен дөнья шуңа әйләнде...

Булдым Уфада, Оренбургта, Казанда, Әстерхан, Троицкида... Башка йирләрдә хат алам. Һәркайда бер үк хәл: ул куәтле дулкыннар көнендә халык өчен, революция өчен янып, үзен онытып хезмәт иткән, күңеле белән гарешләргә ашкынган егетләр, хадимнәр бүген һәммәсе канатлары сынган кош кебек сүлпән, хәлсез йөриләр...

Һәркайда булдым... Һәр йирдә җыладым... Ни диим? 5 нче елдан хәзергәчә үткән дәвер миңа әмәлләр каберстаны, тапталган бөек идеаллар хәрабәсе булып күренә.

Кичәге социалист бүген буржуага тәлинкә тота. Кичә милләтче булып янган зыялы – бүген корсак колы... Кичә милләт дип, хезмәт дип ялкынланып йөргән мөгаллим, бүген: “Ни эшләмәк кирәк, бала бар, хатын бар”, – дип, хәзрәт белән мәхәллә халкының җырын җырлый, җонны уңгаена сыпыра!

Иң яман фаҗигасе: йөзләренә бу ике арадагы кара аерманы сөйләсәң, аңламыйлар да, “дөньясы шул инде аның” дип кенә куялар. Үземне дә

истисна кылмыйм[1]. Мин дә төштем. Күңел сүнде, җан үлде, дәрт бетте – мин дә шул күктән егылып, канатлары сынган кошларның берсе!! Талпынырга уйлыйсың, ләкин куәт юк, бер омтыласың да кире ятасың!!

Революциянең куәтле дулкыннары вакытында халыкта рух күтәрелүе, үз мәнфәгатен ташлап, гомум юлына корбанга хәзерлек дәртләре артканын мин тарих буенча беләм... Яшь җаннарның бер дәвердә бөек әмәлләр белән янып, күкләргә ашкынуы да миңа мәгълүм. Безнең буын бу ике ашкынуга берьюлы туры килде. Бәлки, шуңа күрәдер алар артык күтәрелделәр, ләкин ул дәвер үтү белән, бик артык түбән киттеләр... Син яшьләргә Париж коммуналарын, Шлиссельбургта егерме, егерме бишәр ел буенча каты зинданнарда газап чигеп тә иманнарын югалтмаган каһарманнарны сөйләргә ярата идең... Бу араларда мин шулар хакында күп уйлыйм... Алар, чыннан да, гаҗиб даһиләр икән шул... Уналты яшьлек матур кыз чагыңда гаиләңне, зур дәрәҗәңне, миллионнарыңны ташлап, бер идеалга табын, шул вакыттан үзеңне халык хезмәтенә бир дә гомерең зинданнарда, сөрген, каторларда[2] үтсен, чәчең агарсын, җитмеш яшьлек карт бул – шуннан соң да үзеңнең иманыңны, идеалыңны сакла, шул хәлдә дә ерак Себернең каторларында: “Мин сөргендә үләрмен, бәлки, безнең балалар да һәлак булыр, ләкин болар әрәм китмәячәк, безнең чиккән газапларымыз, түккән каннарымыз дулкыны дошманның таш крепостьларын җимерәчәк, халыкны азат итәчәк!” – дигән иманыңны аз гына да какшатма, бу бит, чыннан да – зур каһарманлык!! Бундый кешеләр үзләрен ихтирам итәргә, чыннан да, хаклылар.

Ә без... без нәрсә?

Дулкын кайда кауласа, шунда бара торган кызганыч чүпләр!!

Синең алдыңда рия сатарга теләмим... Мине беләсең, тормыш сөям, аны мещаннарча аңлаудан котыла алмыйм, укытам... Мәктәпкә мөдирмен... Бай кызы димлиләр, бәлки, өйләнермен дә!!

Йөрәгем буш, үзем болардан канәгатьләнмим... Җаным әрни... Ләкин бернәрсә дә эшли алмыйм.

Мин, сугышта имгәнеп, хәле бетерелеп ташланган бер гаскәримен... Тизрәк котыл, сине күрәсем, сөйләшәсем килә...”.

Давыд хатны укып чыгуга аптырап катты. Саклыкны онытып, мәктүбне мендәр өстендә калдырды да йөри башлады. Тагы укыды:

– Ничә укысаң да, шул инде!! Кызганыч зыялының үз йөрәгенә үзе төкерүе! Ул сазга баттым дип җылый, ләкин коткарырга көче юк яки теләми. Һаман бата, баткан саен үзенә үзе төкерә!! Ә менә Габдәһләр, Гәрәй Солтаннар алай түгел инде!! Аларның иманнары иҗтимагый зәминнәре

[1] *Истисна кылмыйм* – аермыйм, искәрмә ясамыйм.
[2] *Дөресе*: каторгаларда.

белән ныгытылган һәм шуннан сугарыла!!

Мәктүбне җырткалады да: “Мә, утка як!” – дип, Крапченкога бирде. Бу, рәхмәт укып, янган мичкә ташлады.

Нәҗиб Кәмал кайчандыр якын иптәш иде. Аның матур буе, мәгънәле карашы, үзен бик яхшы тотуы, бигрәк тә мәсьәләләрне киң, тирән аңлавы Давыдка бик охшыйлар, мәдрәсә ихтиляллары[1] вакытында аның бераз читтә булуы, аннан соң да артык үз эше итеп, революция хезмәтенә кереп китә алмавы егетне бераз уйлатса да, ул һаман Нәҗибтән зур бер нәрсә өмид итә, бу куәт ятып калмас, җәмәгать хезмәтендәме, гыйлемдәме, әдәбияттамы үзен күрсәтер, бер мәйданда балкыр, дип көтә. Нәҗибнең үзенә дә боны сөйли һәм яза, эшкә димли, әллә кайдан йоккан зур тору, зур күренү, башка шундый аристократия йогынтыларыннан якларга тырыша иде...

Менә ни булып чыкты!!

Имеш, игътибары бар, байлар яхшы карый, имеш, бай кызы, яхшы тормыш, дәрәҗә!

Тагы нәрсә?

Мәхбүс: “Фу, кабахәт”, – дип төкеренде дә йөрергә тотынды.

## XXVI

Давыдка яшерен басмаханә эше, прокламацияләр язып, җилем белән бастырып тарату, җыелышларда халыкны хәзерге идарәгә каршы көрәшкә чакыру, хәзерге тормышны кораллы гыйсъян белән җимерергә тырышучы партиядә әгъза булу кебек авыр «гөнаһлар»да гаепләделәр.

Хөкемгәчә дүрт, аннан соң уналты, барлыгы ел да сигез ай утырттылар.

Башта ял итте. Баязид, Гәрәй Солтан фаҗигаләреннән соң нindидер бер томан эчендә үткәрде. Болардан бераз айныгач, башын күтәрми укырга тотынды.

Зиндан аның җанына, йөрәгенә яхшы тәэсир итте. Ялгызлык уку өчен дә, уйлар өчен дә бик артык уңгайлык бирде.

Утыз ел гомер үткән, чәчкә чал кергән, маңлайда эре-эре җыерчыклар йөри.

Шул озын гомердә ничаклы үзгәрешләр булган, ничаклы фаҗигаләр кичкән.

Зиндан, шуларны җыеп, бер тәнкыйть күзеннән үткәрү өчен, гүя бер сихерле дәресханә иде. Әйтерсең, тышкы дөньяның хикмәтләре таш стеналар аша аның бүлмәсенә үзләре агалар иде. Гүя тормышның чобалчык вакыйгалары монда бер тәртипкә тезеләләр, гүя күреп, ишетеп тә тик тышкы

[1] *Ихтиляллары* – бунтлары, чуалышлары.

кайгылары гына беленгән эшләр, зинданның калын диварлары аша үзләренең төп мәгънәләре, тирән рухлары белән керәләр иде.

Куәтле дулкын, аның соңындагы караңгы төннәр, һәлакәтләр, хыянәтләр, бары да эчке сәбәпләре, чын бәгланышлары белән ачылдылар.

Ватылып, гасабиланып, борчылып кергән зинданнан ул ачык, якты уйлар белән чыкты.

Тик аның тән сәламәтлеге беткән, каны азаеп, бераз җүтәл башланган иде.

## XXVII

Майның беренче көннәре иде.

Давыд Урманов, зинданнан чыгып, паспортларын, кәгазьләрен жандармериядән алды да элек үзе торган номерларга килде. Танышларыннан бере дә юк, аларны белмиләр дә.

Ярый, буш номерлар бар икән. Үзенең элекке бүлмәсеннән ерак түгел, номер 23 не күрсәттеләр.

Җиһаз бай түгел, матурлыгы да аз, ләкин ширмасы бар, һавасы күп, тәрәзәләре йортка карыйлар. Күп сатулашмастан, шуңа урынлашты. Паспортын шунда ук алып киттеләр.

5-10 минут үтмәде, номер хуҗасы, паспортны тотып, кире килде. Үзе бараз каушый, кыенсына:

– Сез, – ди, зинданнан чыктыңызмени, – ди. Безгә, – ди, ул-бу булмасмы икән? – ди.

Давыд башта ачуланды. Тегенең һаман борчылуын күргәч, яхшылап аңлатырга уйлады. Ләкин хуҗа һаман тора иде:

– Курыксаң, хәзер бар да бу паспортны участкага яздыр, – дигәч кенә тынычланып китте.

Пәрәмәчләп чәй эчеп беткәнче, кич була башлаган иде инде.

Туры порох заводына таба китте.

Габдәһ абзый да, Заһидә җиңги дә өйдә юклар. Тик аларның бик матур булып үсеп килгән кызлары Маһирә генә бар иде.

Туташ кунакны күрүгә, урыныннан сикереп торып каршы килде дә, ике куллап күрешеп, үзенең шатлыгын, әти-әниләренең сагынуын, һәрвакыт аны искә төшерүләрен сөйләде. Бик яшерен сер итеп, качкын Хәбиб Мансуровның мондалыгын, ул Габдәһ абзыйның якын танышларыннан бер эшчедә качыбрак яшәвен әйтте.

Тиз кайтмаячаклары мәгълүм булганга, озын гына хат язып, туташның кулына бирде дә сәламнәр, рәхмәтләр әйтеп чыгып китте.

Җырчы Сахибның авырулыгы хатлар буенча аңа билгеле иде. Күчмәгән булса, аның квартиры да юл уңгаенда бит, кереп хәлен белеп чыгарга кирәк!

Шәһәрнең чите. Тар, кечкенә, пычрак урам. Фонарьлар юк. Канау буенда дуңгызлар быркылдап ята. Егет, бата-чума барып, җимерек капкадан бер йорт эченә керсә, иске агач өйнең түбәнге катыннан нидер сөйләшеп, ике кеше чыгып килә... Ипләбрәк караса, болар студентлар булды... Кемнәр икән дип уйларга өйгерә алмады:

– Йа Ходай, кемне күрәм, кемне күрәм! Давыд! Давыд! – дип шатланып кычкырып, Җиһангир белән Тангатаров яңа зинданнан чыккан иптәшләрен үбә, кочаклый башладылар. Шатлыкларын, сагынуларын әйтеп бетерә алмыйлар, тәртипсез рәвештә әллә ничаклы сөальләр яудыралар иде.

Беренче сәламнәрдән, шатлыклардан айныгач, Давыд җырчының хәлен сорады, икесе бер авыздан:

– Начар, иптәш, бик начар. Аның көннәре санаулы, – диделәр.

Яшь студентлар бүген Зәйнәп туташка, ниндидер яшьләр кичәсенә чакырулылар иде. Урмановны күргәч, аны оныттылар, икесе ике култыгыннан алып, ватык, җимерек, караңгы баскычлардан түбән катка алып керделәр.

Ишек ачылуга борынга әчеле-төчеле бер ис бәрелде. Кечкенә лампа белән яктыртылган, ватык-сынык урындыклар белән бер өстәлдән башка җиһазы булмаган, обойлары җыртылып беткән зал ашасыннан эчке бүлмәгә үттеләр.

Анда кемнеңдер үзен-үзе тыя алмый җүтәлләгәне ишетелә иде.

Рөхсәт сорап тормадылар. Ишекне ачып, бүлмәгә керделәр.

Һава авыр, җүеш, әллә нинди дару исләре белән тулы. Моның да обойлары җыртык, урындыклары артсыз, өстәле үзеннән-үзе аварга тора. Сул яктан бер кушетка куелган. Анда япма, одеял-фәлән юк. Тик, керләнеп, төсе танылмас дәрәҗәгә килгән бер кечкенә мендәр бар...

Артык җүтәл белән Сахиб боларның керүен сизмәде, ахры: кушеткасы янындагы тимер ләгәнгә бөгелгән, бер кулы белән кушетка читенә таянган, икенчесе белән күкрәген кыскан. Шул хәлендә, эченең әллә кай йирләрен өзеп, һаман җөткерә иде.

Боларны күрүгә атылып кочакларга уйласа да, җүтәл тагы хәлен бетереп, күкрәген буды. Давыд авыру иптәшенең башыннан, биленнән тотты. Су китереп чайкаттылар, Сахиб тынычланды. Кочаклап күреште дә урынына утырды.

Давыдның йөрәге чымырдап китте. Авыруның чыннан да актык көннәре икән: йөзендә кан, тереклек әсәре калмаган, тик, тимгел-тимгел булып, кайбер вакыт кан таплары күренә дә тагы үлем аклыгы каплый, яңак

җотылып, кибеп эчкә кергән. Күзләр, әйтерсең, теге дөньядан карыйлар, аларда һичбер тереклек әсәре юк. Куллары, ничектер, озынаеп, ябыгып киткәннәр. Бармаклар бишесе биш якка аерылып катканнар... Тавышы хәлсез... Ләкин үзенең зиһене, сүзе гаҗәп ачык иде.

Башкалар аягүрә торды, Давыд ватылырга торган урындыкны сак кына ипләп утырды.

– Ну, нихәл, иптәш?

Авыру иреннәрен ачып көләргә итте, ләкин бу ниндидер бер бит җыерылуы булып чыкты:

– Менә күрәсең хәлне! Килүеңә рәхмәт, сине бик сагынган идем. Күрми үләм, күрәсең, дип курка идем...

Давыд җуатырга тырышты:

– Ник алай дисең? Өмид өзәргә ярамый... Хәзер май айлары... Сине тиздән авылга кымызга озатырмыз... Теләсәң, минем белән барырсың!..

Сахиб хәлсез, үлек күзләре белән тутырып карап, Давыдның кулын кысты:

– Яхшы сүзеңә рәхмәт... Ләкин мин төзәлүдән үттем инде.

Бераз көлә төшеп, тагы арттырды:

Мин китаплардан укып, адәмнең үпкәсез яшәмәвен беләм...

Бераз җүтәлләп, кул селекте:

– Их... шул укулар, шул китаплар!! Алар үзләре минем ике үпкәмне ашап бетерделәр?!

Авыруның йөзенә тимгел-тимгел кызыллыклар чыкты. Күзләренә бераз җан әсәре керде.

– Дөньяда мин күргәнне яхшы кешенең эте дә күрмәсен... Яратылыштан бик артык нык булганмын, күрәсең, әле дә күп яшәдем инде... Бу ачлыкка, бу мохтаҗлыкка, минем урында башка берәү булса, әллә кайчан кабердә булыр иде инде, – дип башлап, гүя үзалдына сөйләнгән кеше кебек, авыр, бәхетсез язмышын тасвир итеп китте.

Балачакта ата-ана иркәсен белмәгән. Ятим, ярлы сабыйлык. Җиде яшендә чакта әбисе, мәрхүмә, җитәкләп илтә дә авыл читендәге "мәптек"кә кертеп йибәрә. Анда ачлык, әлиф йат (ят), тузан, камчы. Унөч яшьтә чүпрәк букчага язма "Шәрхе Габдулла"ны салып, яңгырлы көздә шәһәр мәдрәсәсенә китә. Мондагы ачлык, түбәнлек... Гаед, хәтем[1], җеназа садакалары өчен күргән хурлыклар! Җәй көне фабрикта, салда, белмәм, тагы кайда эшлә... Кыш тагы бер иске казаки белән дерелдәп, 5-6 чакрымдагы зияратка егерме тиен садака өчен йөгер! Аннан соң яңа мәдрәсә... Андагы ачлык...

[1] *Хәтем* – Коръәнне укып чыгу.

Тырышлык... Лəкин йөрəк тынмый, имеш, русча кирəк, учительлек, институт, университет! Укыйм, диң, тəңкə ярымлык бүлмə, дүрт ярымлык студент, атнага ике-өч мəртəбə биш тиенлек силəнке (?), өстəвенə, көн-төн укы... Укырга акча тап: табагын өч тəңкəгə тəрҗемə кыл, юлын ярты тиеннəн гəзитəгə язып маташ! Аны да редактор үзенең кəефле чагына туры килсə генə баса. Булмаса, актык дəреслегеңне, билеңдəге кəмəреңне рəһенгə салып, кибетче марҗадан бер кадаклап бурычка икмəк телəн!!

– Шуларны уйласам, əле дə озак яшəвемə аптырыйм... Бу авыр гомердə бер генə, тик бер генə яктылык булды. Ул да – Гөлбикə... Үлəм, язмыш шулдыр, лəкин, иптəшлəр, аңа минем актык сəламемне, сагынуымны, күрергə телəвемне аңа əйтерсез...

Тыштан кемдер керде. Ахры, юлны белмидер, Сахиб кайда тора дип, бик артык сынык русча белəн сорады. “Биредə”, – дип əйтергə өлгерə алмадылар, бүлмə ишеге ачылды, аннан аягына читек-кəвеш, өстенə иске җөббə, башына тирəн бүрек кигəн бер мулла килеп керде. Кунакның йөрүе ашыгыч, күзлəре уйнап тора иде.

Һəммə иптəшлəргə берəм-берəм күз ташлады да:

– Берегез дə танымыйсыз, ахры. Мин – сезнең мəдрəсəи исламиядəге иптəшеңез Сəйфуллин буламын, – дип күрешə башлады.

Чыннан аптырап калдылар. Ничаклы үзгəреш!

Теге вакыт Сəйфуллинның җитү чəче шомалап таралган, өстендə ярым русча кием, аякларында итек була, басканда, кузгалганда бер нəрсəне җимерергə бара, сөйлəгəндə авызыннан ут чəчрəтə, йөзе үткен, күз карашы кискен иде. Болар өстенə шəкерт ихтилялында Җиһангирдан кала беренче башлык, җитмəсə, социалист та иде! Ə хəзер нəрсə? Читек, җөббə, чəч-мыек кырулы, сакал җитү! Йөздə, күздə элекке ялкынның əсəре дə юк! Шул аз арада бу чаклы үзгəреш!

Боның килүенə башка һəркемнəн бигрəк авыру шатланды. Алар якташ, мəдрəсəдə казандаш[1], соңыннан якын дустлар иде.

Сəйфуллин бүреген, җөббəсен ташлады да, Сахибның янына ук килеп, хəлен сорашырга тотынды.

Авыру кыска бетерде:

– Мин чахотка. Тиздəн үлəм! Син менə үзеңне сөйлə: безнең шəкерт каһарманы Арыслан Сəйфуллин ни эшлəп бу чаклы үзгəргəн? Син бит муллалыкка каршы, мөгаллимлектə туктамаска, югары китəргə хыяллана идең?

---

[1] *Казандаш* – бер казаннан (савыттан) ашап яшəгəн кешелəр.

## XXVIII

Сәйфуллин:

– Бик күптән тартканым юк. Җаным көйде. Урамда тартсаң, мулла кешегә килешми. Авылда да газапланып бетәм! – дип, авыруга һава бозмас өчен, залга чыгып тәмәке тартты да яңадан кереп сөйли башлады:

– Ничек, төшкәнеңне, – ди, – үзең сизми дә каласың икән ул... Безнең кебек русча укырга, имеш, учитель булырга. Аннан соң институт, аттестат, университет белән хыялланасың... Акча юк... Ач торасың... Актык нәрсәңне сатып бетерәсең, бурычка бер эт тә бирми... Тукта, дисең, болай торып булмас, бер йиргә мөгаллим булырга кирәк, дисең... Көненә өч-дүрт сәгать укытырмын, калган вакытымда, студент яллап, үзем хәзерләнермен, дисең. Имеш, берьюлы ике көймәнең койрыгын тотасың.

Мөгаллим булу фикере вакытлы бер эш уларак шулай туа... Әлбәттә, шәһәрдә кирәк... Ләкин ул табылмый... Шулай да карарың үзгәрми. Ачсың, интеккәнсең, ярый, дисең, бер кышта авылда булса да зыян юк, үзем хәзерләнермен, анда тормыш арзан. Алдагы кышка укырлык акча арттырырмын, дип җуанып барасың бер авылга... Халык караңгы. Мулла беренче сүздә үк: “Халыкның җаенарак карыйк, юкса сүз үткәреп булмый, бик өрекмәсеннәр”, – ди. Эчеңнән сүгенә-сүгенә чәчеңне кырдырасың, кәләпүш киясең... Билеңдәге каешыңны кәрзинкәңнең төбенә үк яшерәсең... Биш вакытка даим була алмасаң да, җомгадан калмыйсың.

Син көненә өч-дүрт сәгать уйлагансың, ә анда рәхим ит, сигездән дә ким эш булмый... Ничек тә күтәрергә мәҗбүрсең. Ташлап китәр идең, бер тиен акчаң юк, барыбер шундый бер урынга барырга туры киләчәк...

Түзәсең. Мужик малае белән каның бозыла... Инде яз... Имтихан... Тизрәк качасың... Карасаң, кесәңдә башы-аягы йөз сумлап акча! Бу бит җәй үткәрергә дә җитми. Үзең арып, хәлдән тайгансың...

Өст-баш ясыйсың, берәр тибәсең, карасаң, кесә тагы саега... Авылга кайтып егыласың... Ярты-йорты белгән телең белән русчаданмы, гарәпчә, төрекчәдәнме берәр китап тәрҗемә кылып маташасың... Шигырьләр тезәсең, берәр хикәя дә әвәләп аласың... Бер дә гаҗәп шәп чыгалар!

Менә сиңа юл: акча да, шөһрәт тә икесе бергә килә!

Җәйге матур көннәрдә хыялланасың: Казанга барачаксың да боларны сатачаксың. Шул акча белән укырга тотынасың... Шул арада тагы берәр тәрҗемә өлгертергә була... Шундый хыяллар белән Казанга актык тиеннәреңне тотып киләсең... Әнә нинди һәйбәт китап магазиннары, әнә нинди яхшы бай иаширләр!

Каушап, өмет катнаш курку белән нашир әфәндене күреп, әсәреңне

бирәсең... Ул илтифатсыз[1], бераз караңгы йөз белән алып кала да бер атнадан килерсез, ди. Йа Ходай, ник бик озак, аңарча мин нәрсә ашармын, дип уйлыйсың. Хыял белән аптыраш бергә кайный. Күпме гонорар бирер икән? Ул акчаны бик кадерләп тотарга кирәк булыр.

Атна үтә. Өмет белән ут эчендә көтепханәгә барасың! Әйтерсең тәнеңә эссе су койдылар: нашир әфәнденең укырга вакыты булмаган, бик ашыкса, кире алып китсен, дигән.

Тагы атна-ун көн наширнең канторын таптап, ансыз да тузып килгән штиблет табаннарыңны әллә ничаклы шомартканнан соң, мә сиңа, рәхим ит:

– Әсәреңезне зарарсыз таптык... Ләкин алган нәрсәмез бик күп булганга, сезнекен баса алмыйбыз, – ди.

Үзе сиңа күтәрелеп карамый да. Әгәр ачулы вакыты булса: “Яратмадык, алмыймыз”, – дип үк сала. Фу, нәүмизсезләр[2], ничек мөмкин шундый әсәрне яратмаска!

Янып, тирләп, сукранып, икенче наширгә бирәсең. Анда да шул ук хәл...

Ә син, шуңа ышанып, бурычка баткансың!

Ни чара? Тагы мөгаллимлеккә урын эзли башлыйсың! Шәһәрдәге мәктәпләр тулы – тагы караңгы авылга!

Ләкин һаман бирешергә теләмисең. Бу ел кыш әрәм булды, алдагысына җәйдән үк яхшы йир табарым, дисең.

Һәм табасың. Ләкин ни файда?! Айга утыз сум. Катор хезмәте. Акчаң ашарга җитми. Җәй башы, җүтәлләп, авылга китәсең. Ярый әле дә атаң бар. Хәлдән тайганда, аңа кайтып, аңа баш куясың...

Еллар үтә... Яшең утызга якынлый... Маңлаеңда җыерчыклар...

Рухыңның төбендә бу бетмәс-төгәнмәс өстерәлүдән арыганлык сизә башлыйсың... Ялгызлыктан да туйган кебек тоеласың... Яңа бер хис даими бер оя, тугры бер юлдаш кирәксенү сизелә...

Менә матур бер кыз да бар. Яңа фикерле, әдәбият сөючән. Атасы күрмәгәндә качмый да. Бераз укытсаң, һичшиксез мөгаллимә булачак!

Өйләнәсең, бер башың ике була. Ул ара өченчесе дә килеп чыга.

Хатының, бала-чагаң белән авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә өстерәлеп йөрү бер дә килешми инде, ул ояла. Бабалар:

– Яхшы урын бар, кияү ник мулла булмый икән? Гомер буена чегән кебек йөрмәс бит, – диләр икән.

Башка ни чара?!

Әллә кайчан шүрлеккә ташланып, тузанланып беткән “Мөхтәсәр әл-

---

[1] *Илтифатсыз*– әһәмият бирмичә.
[2] *Нәүмизсезләр* – өметсезләр.

викайә” белән “Фәраиз әс-сиражийә”не[151+] яңадан тартып чыгарып, бер мәртәбә күз йөртәсең дә, мөфти хәзрәтләренә барып, имтихан кылынасың.

Атаң белән бабаң ул арада сиңа тозакны, богауны әзерләп куйган – урын табып, ришвәтләр бирә-бирә, тамга җыйган була...

Менә шулай акрынлап янасың...

Моны үзең сизмисең... Тик менә хәзерге кебек иске хәлләрне искә төшергәндә генә аңлыйсың... Ләкин аңлаудан ни файда?! Тик йөрәкне әрнетә генә!

Сәйфулллинның сөйләве кызыклы булса да, авыру тыңлый-тыңлый арыды... Иптәшенең сүзе бетүгә керле мендәрен ипләбрәк салды да, тәрәзәгә күзләрен терәп, гүя үзалдына сөйләнә башлады:

– Их иптәш, синеке тагы бер хәл, менә минеке авыр... Мин үткәннән зарланам... Ләкин мөмкин булса, аңардан мең мәртәбә авырлык белән булса да яшәргә риза булыр идем... Тик гомер генә булсын иде...

Бераз җүтәлләде дә тагы дәвам итте:

– Менә хәзер май ае... Җәй килә... Бәхетле җаннар яшел урманнарга чыгар, көмеш елгалар күрер, чәчәкнең хуш исләрен иснәр, сандугачның моңын тыңлар... Ләкин мин булмамын... Уф... Их, белсәңез үләсе килмәве!

Җүтәл тагы буды. Давыд урыныннан торып, баштан биленнән тотты, авыру тынычлангач, авыз чайкарга су бирделәр.

Сәйфуллин Сахибта кунарга булды:

– Мин, ди, сине бу көеңдә калдыра алмыйм. Аз гына хәл җыйгач та авылга китәрбез... Бездә кымыз эчәрсең, тазарырсың.

Башкалар исәнлек теләп, яңадан керергә вәгъдә итеп чыгарга булдылар.

Авыру гүя, актык күрүен сизенгән кебек, иптәшләренә хәлсез күзләрен тутырып, озак-озак карады, кулларын каты кысты.

– Үлсәм, бәхил булыңыз. Гөлбикәгә сүзләремне ишеттерeңез, – диде.

## XXIX

Кайчандыр каһарман Сәйфуллинның үз хакындагы тасвиры, бигрәк тә авыру иптәше Сахибның хәле Давыдны караңгы уйларга алып киттеләр.

Кая карама – анда үлем, һәлакәт, төшкенлек!

Акрын, салмак адымнар белән шул хафалар астында номерына кайтып җиткәч шикләнеп китте: “Бу ни хәл? Аның бүлмәсендә ут. Әллә зинданнан чыгып җитмәс борын, жандармерия тагы тентүгә килеп өлгергәнме юкса?!” Ишек эчтән бикле, акрын гына шакылдатты.

– Кем бар?

– Мин Давыд, ачыңыз!

Керсә аптырый калды. Киткәндә ачкычын швейцарда калдырган иде. Габдәһ абзыйдан ишетеп белгәннәр дә зинданнан кайткан иптәшләрен күрергә килгәннәр икән. Мәҗлес яхшы ук кызган. Зур өстәлдә берничә аракы, пиво бутылкалары, суган, кыяр, икмәк, селедка, казылык, кечкенә генә бер дуңгыз боты, сүнгән самавыр, берничә стакан.

Сәлимов, урындыкның аркасына терәлә төшеп утырган хәлендә, ачык, якты күгелҗем күзләре белән елмаеп:

– Күрдеңме, Давыд, без сине ничек каршы аламыз! – диде.

Шат, хозур йөз белән, дустанә сүзләр белән күрештеләр. Өстен салып, беренче исәнләшү сүзләре үтүгә, Давыд качкын Хәбибкә карап:

– Мин сине күрүгә бик артык шатмын... Ләкин бондый халыкның кайнап торган бер йирендә, шау-шулы зур компаниядә утыруны синең конспирациян[1] ничек сыйдыра?! Бераз сак булырга кирәк иде... Тагы эләктерсәләр, сине богаулап крепостькә атачаклар...

Хәбиб сызгырып, кул селекте:

– Богауларын үз муеннарына кисеннәр, мин тере көенчә аларга эләкмәскә ант эчтем... Чукынып үлсәләр дә тота алмыйлар. Яңадан безнең көннәр килгәч, мин качып йөриячәкмен! Юкка кайгырма, әйдә, эчәргә утыр!

Давыд һаман туктамады:

– Син мәңге шул тискәре бер адәмсең инде... Мин һаман да сиңа сак булырга киңәш итәм...

Качкын иптәшчә көлде:

– Киңәшеңне кесәңә тык та, әйдә, эчәргә утыр!

Тагы ишек кактылар, үзләренең студент формалары белән ялтырап, Җиһангир, Тангатаров, югары рәсем мәктәпләре киемендә тагы бер яшүсмер матур егет килеп керде.

Студентлар туры аракыга җотылды. Художник егет Давыдның кулларын йибәрмичә, нурлы күзләре белән елмаеп:

– Давыд абый, сез әллә мине танымыйсыз да инде... Мин – Камил Ходаяров, – диде.

Кайчандыр Кадыйр бай углы Йосыфҗаннан акча алып бирүен, шуның аркасында аякка басып китүен, хәзер рәсем мәктәбендә укуын сөйләде. Кат-кат рәхмәт укыды

Мәҗлестәгеләрнең күбе аңа таныш иде. Һәммәсе белән нәзакәтле рәвештә күреште дә рәсми шинелен, фуражкасын салып, көзгедә чәчен төзәткәннән соң, иптәшләренә килеп утырды.

Давыд зинданны, Гәрәй Солтанны сөйләде, Баязидка тукталды, иң

---

[1] *Русчадан:*

ахыргы мәсьәлә итеп, җырчы Сахибның авыр хәлен хәбәр итте. Аны байтагы белә иде. Хәбиб[1] җүнле егет иде, әрәм, бик әрәм. Безнең бер кеше югала, диде...

Күп эчтеләр. Аракы, пиво килеп торды...

Гадәт буенча, бара торгач, бердәнбер сөйләүче качкын Хәбиб булып калды. Җиһангир аны бу кайтуында беренче күрә иде. Эчке бер дәрт, тирән ихтирам белән тыңлап, йөзеннән күзләрен алмады.

Качкын байтак үзгәргән. Чәчендә берничә бөртек чал да күренә. Тик торган вакытында карасаң, йөзендә, күзләрендә, бөтен торышында бераз арыганлык, талганлык төсе бар кебек сизелә... Ләкин кызып, ачуланып сөйли башладымы – тагы элекке тимер табигатьле Хәбиб килеп чыга: тавышы каты, сүзләре ачы, кискен карашы үткен, усал... Бөтен торышы менә хәзер һөҗүм итә дә җимереп ташлый кебек күренәләр. Маңлаенда, күз төбендә берничә җыерчык арткан...

Кемдер: "Аракы бетте, алдырамызмы?", – диде.

Җиһангир якасын чиште дә өстәл сукты:

– Алдырамыз, Давыд белән Хәбибне күрү шатлыгыннан үзем алдырам... Мин бүген кырык сумга бер тәрҗемәне саттым... Шуңа күрә, вечердагы матурларны ташлап, сезгә килдек!!

Сәлимов җырларга тотынды, аңа Камил кушылды, Тангатаров, ай ул да булса, дип, Сахибнең тавышын, моңын сөйләргә кереште. Ул исереп өлгергән иде, стаканын күтәрде дә: "Давыд белән Хәбиб өчен эчтек, инде Сахиб өчен дә эчик, ул мондый вакытта гади кеше булса да, җырлый башласа, аның йөзенә әллә нинди бер мәгънә чыга, ул бөтенләй бөекләнә иде", – дип сөйләнергә кереште.

Чәкәшеп эчтеләр. Давыд, күптән эчмәгәнгә, егып ташламасын дип, саграк булды. Камил Ходаяров бөтенләй эчми, эчә дә алмый иде.

Күңеленнән бу кадәрле яхшы иптәшләренең бондый ямьсез рәвештә эчеп, юк-барны сөйләп утыруына аптырый иде. Ләкин гаепләргә, шелтәләргә үе бармый, боны ниндидер бер аңлашылмау кебек карый иде...

Сәгать ун тулып үтүгә:

– Иртән сигездә торып, дәрескә барасы бар, мин кайтам, – дип, иптәшләреннән гафу үтенде дә исәнләшеп киенә башлады. Давыд, тутырып, берне эчте дә: "Мин бик аз гына һава алып керәм, таралмаңыз!" – дип, Камил белән чыгып китте.

---

[1] Бу урында *Сахиб* дип аңларга кирәк.

### XXX

Ахры, эчми эчкәнгәдер, Давыдның аяклары тыңламый, теле бераз көрмәкләнә башлады. Камил аның култыгыннан алды. Яхшы һавадан файдалану өчен урамга тулган халыкны җырып, Камил фатирына таба киттеләр.

Давыд яшь егеткә юл күрсәтергә теләпме яки күңелендәге шөбһәләргә җавап бирепме, сөйләнергә тотынды:

– Туган, – ди, – без җиңелдек... Безнең саф сирәгәйде... Баязидны, Гәрәйне астылар... Булат салкын Себердә. Синең, ди, җаның ак, пакь, йөрәгең изге уйлар белән тулы... Мәдәни көчең булачак... Син, ди, укы, тырыш, мондый мәҗлесләрдә сиңа мәгънә юк... Безнең буын, ди, хыял белән гарешкә очты... Йир йөзен җәннәткә әйләндерергә теләде... Ләкин, ди, адәм йир маддәсенннән яратылган... Ул күккә тиз менә алмый... Ул акрын кузгала... Яшьләр дә менә алмады... Аларның канатлары сынды... Әнә алар хәзер йөрәктәге актык чаткыларын аракы белән сүндерәләр. Бер төрлесе, иманын, байрагын сатып, дошман сафына чыкты... Син, ди, яңа яшь буын кешесе, укуыңны, эшеңне бел...

Шулай сөйләнә баргач, Камилнең квартирына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Егет стипендия ала, өстәвенә сигезәр сумлык ике сабагы да бара, үзе дә пөхтәлекне бик сөя икән. Бүлмәсе курчак кебек җыештырылган: һәммә нәрсә урынында, карават гаҗиб пакь, ак. Өстәле яхшы тышлы китаплар, альбомнар, матур кара савытлар белән, диварлары иске Юнан рәсемнәре белән тулы... Язу өстәлендә сөекле бер кыз елмаеп тора. Давыд моны күргәч, үз эченнән, беренче мәхәббәттер, дип уйлады.

Килеп керүгә, теге яктан хадимә чыгып: “Чәй кертимме, Камил Вилданович?” – дип сорады.

Ике стакан чәй, яхшы сохари керттеләр...

Урмановның Камилдә тапканы, бер яктан, музыкага осталык булса, икенчедән, аның гомерендә җүнләп сурәтле китап күрмәгәне хәлдә, дәфтәрләрне, парта эчләрен төрле рәсемнәр белән тутырып бетерүе. Шуңа мәхәббәте һәм истигдады иде. Караңгы татар тормышында боларның югалу ихтималын күз алдына китергәнгә, ул Йосыфҗаннан ярдәм иттергән иде.

Егет, бераз тартынып, бераз каушап, ни әйтә, яратамы, юкмы, дигән бер хәлдә, үзенең әле бөтенләй эшләрнеп бетмәгән тәҗрибәләрен күрсәтте.

Беренче рәсем – “Сөю”. Айлы кичә. Дөнья тирән бер тынлыкта. Төн гаҗиб аяз, якты. Шулвакыт диңгез эченнән ярга кимә килеп туктый. Кемдер дачаның ачык тәрәзәсеннән рояльдә уйнап йибәрә. Егет “аһ” ди дә янындагы матур туташның күкрәгенә каплана...

“Актык өмид” дигән икенче бер рәсемдә Сөембикәне аңлатырга

тырыша. Төн караңгы, диңгез куркыныч дулкынлана. Кимә батып бара.Аның үз эчендә сугыш-талаш: берсе – бер якка, икенчесе икенче якка тарта. Арада һәлакәттән коткару өмиде белән янган кайгылы йөзле бер ханым бар, ул ниндидер бер нур белән тирә-якны яктыртырга тырыша – әнә шунда барыйк, шунда дип, юл күрсәтә. Ләкин тыңламыйлар, кимә бата, ханым, аһ беттек, дип егыла...

Бу – Сөембикә икән...

Давыд: "Яхшы, яхшы, сездә өмид зур, эшләңез", – дип чыга башлады... Камил, киенеп, аны озатырга китте.

Юлда аз сөйләштеләр.

Давыд уйланып барды. Ул, гүя дөньядан чыккан иде. Ике рәсем аның күз алдында иде...

Техникасы үскән... Төзәлгән... Ләкин яңлыш юлга кермиме икән?.. Тагы шунысы гаҗәп, безнең буынны газаплаган фикерләр, фаҗигалар боның иҗадатында[1] аз гына да эз калдырмаган... Хәер, Камил ул вакыт бөтенләй бала иде шул... Болар китаптан, күчергечләрдән йоккан нәрсә генә булмаса ярар иде... Күрәсең, татарга иртәдер, күрәсең, әле рәсем иҗадаты канат җәерлек, аны үз рухында сугарып чыгарырлык зәмин[2] бездә юктыр әле...

Камил, исәнләшеп, рәхмәтләр укып, иртәгә озатырга киләчәген әйтеп, номер капкасы төбендә күрешеп, кире китте...

Давыд бүлмәсенә керде...

Ни күрсен, аракылар да, кешеләр дә арткан. Бу Габдрахман, күрәсең, исереп үк килгәндер, ширма эчендә умывальник алдына башы белән яткан да, бармагын бугазына тыгып, косарга маташа... Гәүдәсен тота алмый, әле бер якка, әле икенче якка барып сугыла, үзе нидер сөйләнә:

– Давыд... Давыд... Мин шатлыктан... Син чыккан шатлыктан... эчтем... Килсәм, монда... синдә тагы эчерделәр... ачуланма, үзем... үзем җуармын... – ди.

Өстәл тирәсендә исә кызу талаш бара... Ахрысы, Качкын кемне булса да сүккәндер, Тангатаров, яман исереп, өстәл суга да, йөреп, ава-түнә сөйләнә:

– Синең, – ди, – Хәбиб, сүзең дөрест... Валлаһи, дөрест... Хәзер мин... мин нинди социалист?! Мә, минем... битемә, күземә төкер... Мин кем?.. Мин арзанлы кабакта эчәм, имеш, мин демократ... мин... мин, исереп, частька кергәч... анда ... хулиганнар белән... караклар белән кочаклашып... җылыйм... имеш, мин аларны кызганам... имеш, мин социалист!!. Юк, бер мин түгел, бары да шулай... шулай... Валлаһи шулай... Ә "тегеләр", Госманнар, кая

[1] *Иҗадатында* – иҗатында.
[2] *Зәмин* – нигез, җирлек.

китте... Алар сатылды... Алар, имеш, остепенеться итте... Ә мин әйтәм... бу кешеләр... Без аларга караганда... без әүлия... Без алдашмыймыз... Мин аларның... битләренә төкерәм...

Җиһангир кайдандыр карта тапкан... Үзе исерек... Яхшылык белән тыңламагач, Тангатаровның якасыннан алды да: “Туктыйсыңмы, юкмы? Булмаса, мин сине, бәйләп, караватка салам...” – ди.

Тангатаров баягы сүзләрен онытты, яңа күргән кеше кебек, Җиһангирның ике кулбашына ябышты да:

– Синме – туган, син – Җиһангир дустыммы?.. Яратам үзеңне, син – честная душа...– дип үбә, кочаклый, кысып буа башлады...

Җиһангир аны бер якка этәрде:

– Ярый, бар, үзең эч... Без карта уйныймыз... Әйдә, кемнәр 21 гә катнаша?

Картага кушылучы аз булды... Урманов эчәргә тотынды. Сәлимов “Мәдинәкәй”не суздя, Җиһангир, картасын онытып, эчке бер дәрт белән очынып, очынып җырлый башлады. Давыд нык исерде, инде урынында утырмый, ава-түнә йөри. Изүе чишелгән, билендәге каешы салынып тора, чәче тузылган... начар тавыш белән кушылып, көйне, моңны боза...

Шулвакыт сак кына ишек кагалар... Сәлимов русча: “Кереңез”, – ди. Тагы кагалар. Сәлимов ачулы, бераз сүгенүле тавыш белән:

– Кереңез, диләр бит сезгә! – дип кычкыра...

Ишек ачыла. Урта буйлы, ярым европача, ярым татарча киенгән, кечкенә калфак өстеннән кара шәл ябынган, йөзе куе пәрдә белән капланган бер яшь ханым килеп керә.

Сәлимов, бер дә аптырамыйча:

– Сезгә кем кирәк? Сез яңлыш кергәндерсез бире, – ди.

Ханым сак, эчке тавыш белән:

– Миңа Давыд әфәнде Урманов кирәк иде, – ди.

Давыд кинәт уянган кебек була. Үзе дә сизмәстән, чишелгән изүен каплый, чәчен, кәмәрен төзәтә дә, сикереп торып, ишеккә бара, сүзсез-нисез ханымны биленнән алып, тышка чыгара.

Нәфисә, аз гына да тартынмыйча, егетнең биленнән ала, егет кочаклап үбә, бер секундта бөтенләй айнып җитә:

– Бүлмә начар, иптәшләр исерек, сезне кертергә кыенсынам, күңелеңез кайтыр, – ди.

Ханым шелтә белән җавап бирә:

– Ул нинди яңа сүз тагы? Син булган йир, теләсә нинди булса да, миңа җәннәт... Синең иптәшләрең, теләсә кем булсалар да, миңа фирештәләр, әүлияләр... Әйдә, керик, – ди.

Урманов аптырап кала: бу – кем? Шул юаш, йомшак, оялчан Нәфисәгә мондый куәт кайдан килгән?

Керәләр. Давыд таныштыра. Хәбиб Мансуров та айный. Үзен бераз төзәтә дә гаҗәеп бер дикъкать, җитдият белән сүзгә катнаша...

Мәҗлеснең яме китә. Башлап, Сәлимов кузгала. Ул ашыкмый, нитми, берне эчә, яхшылап закуска каба да янындагы иптәшләренә:

– Монда сантиментализм[1] башлана, бугай, әйдәгез, Ивановка, – ди.

Алар китә башлау белән, ширма эченнән Габдрахман, нидер мыгырданып, ава-түнә килеп чыга да Нәфисәне күрү белән агарынып ката, шул ук секундта:

– Җаным, Нәфисәм, мине гафу ит, мин кадереңне белмәдем, – дип, ханымның аягына егыла. Нәфисә, урыныннан торып, Хәбибнең артына таба йөгерә. Һәммәсе өчен дә бик артык күңелсез бу хәлдән Җиһангир коткара. Ул кулындагы карталарын атып бәрә дә:

– Башта адәмнең эт кадерен китәреп газаплагансың да, инде гафу үтенәсең... Әйдә, исерек башланма, тор, киен, – дип тарткаларга тотына.

Аның мөгамәләсе бик артык каты булганга, Урманов түзми, Җиһангирны читкә этәреп, исерекне торгыза, башын җуа да ипләп киендерә. Габдрахман карышмый, ни кушсалар, шуны эшли, тик берөзлексез:

– Бетте, бетте, сүзем юк... Гафу итегез... – дип мыгырдана.

Җитәкләп алып чыгып китәләр.

Алардан соң биш-ун минут калып, Нәфисә камил тынычланган, Качкын да киенә башлый. Үзендә бик артык сирәк очрый торган нәзакәт белән, дустанә елмаю белән исәнләшә:

– Сезне күрүгә бик шатмын... Бөтен үткәннәрем күз алдыма килде... Иртәгә Давыдны озатырга килә торгансыздыр, яңадан сезне бер күрергә өмид итәм, – ди.

Нәфисә, Хәбибнең кулларын йибәрмичә, сөйкемле күзләре белән текәлә:

– Сез картайгансыз... Тану да кыен... Сезнең арага килеп керүем белән үземне бәхетле саныйм...

Мансуров тәмәке төтене белән тулган бүлмәгә, идәндә тузылып яткан папирос төпчекләренә, өстәлдәге аракыга, кечкенә дуңгыз ботына, ватылган стаканга күрсәтә дә:

– Белмим, Нәфисә ханым, белмим, сез безне бондый хәлдә күрергә уйламагансыздыр да, теләмәгәнсездер дә...

Нәфисә, үпкәләп, шелтәләп кырт кисә:

---

[1] *Дөресе*: сентиментализм.

– Ай, юкны сөйләмәңез!.. Сез булгач, миңа алар күренми... Бая Давыдка да әйттем, сез булган йир миңа җәннәт, һәммә иптәшләреңез фирештәләр, әүлияләр, дип...

Хәбиб:

– Исән булыңыз, сез гаҗәп, гаҗәп үзгәргәнсез... – дип, ханымның нечкә, йомшак кулларын яңадан кысты да чыгып китте.

## XXXI

Ул китүгә, Нәфисә бүлмәнең хуҗасы роленә керә. Ишекне, форточканы ача. Өстәлне җыештыра. Коридордан щетка табып, бүлмәне себереп чыгара. Давыдны үбеп, шаяртып, умывальник янына китерә дә башын салкын су белән җуа, үзе һаман, сиңа хәл керер, тизрәк айнырсың, дип, көлә-көлә иркәли.

Аннан соң, одеял, мендәр, япмаларны кагып, караватны тәртипкә кертә дә комодтан нидер эзләнергә тотына, анда һәммәсе кара керләр. Егеткә килеп, тагы үбә, иркәли дә, без бит дустлар, миңа ачуланма, синең бер дә ак бельяң[1] юкмыни, ди.

Бәхеткә каршы, бүген зинданнан кайтышлый алынып та, вакыт булмаганнан киелми торган бер пар яңа белья бар икән. Шуларны егетнең кулына бирә дә, тагы иркәләп, ачуланма, дип, ширма эченә кертеп йибәрә.

Давыд яшь бала кебек һәммә сүзне тыңлый.

Ничаклы актарынса да, одеколон табылмады, ахрысы, бөтенләй юктыр. Һава сафланып җитә, ишекне, форточканы яба, ридикюленнән үзенең хушбуен алып, су белән сыеклый да бөрки. Бүлмә тәмле ис белән тула.

Давыд, Нәфисәнең эшен бетергәнен күрә дә, акрын гына биленнән алып, итәгенә утырта.

Хатын егетнең йөрәгенә керердәй сыенып, иркәләнеп сүз башлый:

– Беләсеңме, Давыд, бүген мин синдә калам... Бу минем күптәнге өмидем иде...

Шуннан үзенең Габдрахманнан өч ел элек аерылуын, энҗеләрен, кыйммәтле зиннәтләрен сатып укырга тотынуын, ничек имтихан тотуын, учительница чагында ниләр булуын акрын, йомшак, зарлы тавыш белән сөйләп китә...

Каядыр ашкыну, ниләрдер өмид итү, Давыдны яңадан күрү әмәле белән яшәү... Кайбер егетләр белән ашкынгаласа да, болар һәммәсе тиз килеп кичкән дулкыннар гына булу... Бөтен сүзләренең рухы менә шул иде.

Нәфисә иртәнге чәйне эчкәч кенә китте. “Озатырга киләм, Габдрахман

[1] *Русчадан*: бельё.

булса, ничек тә аны кире йибәрә күр", – ди.

## XXXII

Ике ат, яхшы тарантас белән Бәдри учитель килгән. Давыдның авылга китәчәген белгәч бәйләнә калды:

– Мин хәзер Кама Тамагына якын бер авылдамын, – ди, – йорт-йирем, бакчаларым яхшы... Миндә берничә көн кунак булырсың, аннан соң пароходка үзем илтеп куярмын, – ди.

Ник бармаска? Һава яхшы, юл уңгай, өстәвенә, анда ничаклы халык күрәсең...

Бәдри иртә үк китәргә димләсә дә, Давыд, өлгерә алмыйм, Габдәһ абзыйларны да күрмәгән, кичкә каршы гына чыгармыз, дигәч, моңа да риза булды. "Алайса, син эшләреңне бетер, мин сәгать алтыда килермен", – дип китте.

Төне буенча диярлек Нәфисә белән сөйләшеп чыгылганга, Давыдның йокысы туймаган, кунак ханымны чәйләп озаткач, ишеген бикләп йокларга ятмакчы булып кына тора иде, "Вином мы родились, вином мы умрем" дип көйләп, Сәлимов килеп керде:

– Баш та бик авырта, сине дә озатасым бар, мин бүген редакциягә бармадым... Редактор сүгенсә сүгенер инде, чукынып китсен, кая, малайны чакыртып, берне алдырыйк әле... – ди.

Тиз арада аракы, кыяр, бераз икмәк килде. Бераздан:

– Ну, егетләр, бармы рәтегез, – дип, Качкын Хәбиб килеп керде.

Яңадан самавыр алдырдылар. Сүз кызмады, Мансуров ара-тирә төрле кешеләрне бер-ике ачы сүз белән чәнчеп ташлый.

Сәлимов, креслога аркасы белән ята төшеп утырган хәлдә, акрын гына эчә, үзенең эчке күкрәк тавышы белән бер русча, бер татарча акрын гына көйли иде.

Бераздан гаеплерәк йөз, авыру баш белән Габдрахман килде.

– Кичә, – ди, – артыграк булган, бугай... Чит кешеләр алдында күңелсез күренеш ясап ташлаганмын шикелле... – ди. Гафу үтенгән сыманрак сөйләнә.

Урманов кул селекте:

– Ташла, юк сүзне, нинди артыграк та, нинди күңелсез күренеш, әйдә, эч!!

Артист рәтеннән берничә рюмка салып эчә, суган белән икмәк каба да:

– Һич китмәс идем, сезнең белән җаным хәл җыя... Шул репетиция бар, каһәр төшкере, – дип, бер яктан сүгенә, икенче яктан Давыдка хәерле юл, сәламәтлек теләп чыгып китә.

Калганнар көндезге ашны ашап бетүгә, сәгать өчләр булды. Кем редакциясеннән, кем земстводан, кем мәктәбеннән, университеттан эш бетереп, Давыдны озатырга берәм-берәм башкалар да килә башлады... Аракы, икмәк, казылык, кыяр, суган, селедка артты.

Мәҗлес кызып кына барганда, култыклашып, ике “туташ” килеп керде. Берсе теге “мәхәл”дәге “гимназистка” Гөлнур, икенчесе аның дусты икән...

Җиһангир бераз кыенсынды, эченнән: “Бусы артыграк инде, кеше кайнап тора, туташлар, ханымнар килеп керүе мөмкин”, – дип уйлады. Сәлимов, Тангатаров, Давыд кунакларны ачык йөз белән каршы алдылар, чишенергә, эчәргә димли башладылар. Гөлнур: “Рәхәт, соң, валлаһи, сезнең тормышлар...” – дип көлеп, матур тавышы белән җырлап исәнләште дә, Тангатаровның итәгенә утырып, үзенең сагынганын, күптән күренмәүләрен, бу компаниядән башка дөньяда кызык тапмавын сөйләргә тотынды.

– Мин, – ди, – Булат кайткан, имеш, дип килгән идем... Булат дигәнем, Давыд булып чыкты... Ул кайчан кайтыр икән? – ди. Аның адресын сорый. Сагынып үләм инде, хат язар идем, ди. Дусты ашыктыра башлады. Гөлнур тагы берне салып эчте дә, Булатның адресын алып, көлешеп, җырлап чыгып киттеләр.

## XXXIII

Алар артынннна ишек ябып өлгерә алмадылар, җылап кызарып беткән Заһидә җиңи килеп керде. Давыд каршы барып күреште. “Ни булды, ни булды, иплэп сөйләңез”, – дип, креслога утыртты. Хатын, искерә төшкән бишмәтен, кызыл-көрән шәлен бер якка ташлады да, тагы җылап, күз яшен сөртә-сөртә сөйләргә керешге:

– Ходаем, бер бәхеткә каршы, – ди, – мең кайгы килә... Давыд котылды, үзара тагы элекке кебек җыелып яшәрмез дип шатланырга өлгерә алмадык, инде, инде тагы күз яше, тагы кайгы...

Егетләр эчүдән тукталдылар, Хәбиб белән Давыд җиңгинең алдына килеп: “Ни булды, ни булды, Габдәһ абзый, Маһирә туташ исәннәрдер бит, иплэп сөйләңез”, – дип җуата башладылар.

Җиңги күз яшенә капланды:

– Габдулла абзаңыз да, Маһирә дә исән, Сахиб бичара вафат! – диде дә тагы үкереп җылады. Иптәшләр аптырап калдылар, алар моны көтә иде, кызганыштылар, Җиһангир белән Тангатаров мәрхүмнең квартирына барырга киенделәр.

Су эчкәч, җиңги азрак тынычланды, шәл почмагы белән күзләрен каплап, фаҗигане тасвир итте.

– Бүген, – ди, – әллә нинди яман төшләр белән куркып уяндым... Сине дә чакырмакчы идем... Сөтләп, йомыркалап, тәмле генә итеп коймаклар, вак күмәчләр пешердем дә, бар, дим, кызым Маһирә, Сахиб абыеңа илтеп кайт, бичара, дим, ялгыз ачлы-туклы авырып ята, үзеңә, дим савап булыр, абыең, рәхмәт әйтер, дим. Кызым тиз генә киенде дә олы тәрилкә тутырып алып китте... Шуннан ике чынаяк чәй эчәрлек тә вакыт үтмәгәндер, кызым акырып җылап, йөгереп кайтты... Ни булды, кем тиде, дим... Иплэп сүзен дә әйтә алмый... “Барыңыз, бар, Сахиб абый үлә, теленнән калган”, – ди. Өстемезгә ни туры килде шуны киендек тә, картым белән икәүләп чаптык. Аягымыз йиргә тими, әйтерсең, Ходай безгә канат бирде, шулчаклы очабыз... Хәлемез бетеп, ахылдап барып керсәк, ни күзең белән күрәсең, бичараны, идәнгә пальто җәеп, кыйблага каршы сузып салганнар... Әйтерсең, яңа гына йокыга киткән яшь бала – шулай тыныч кына, матур гына булып ята... Йөзендә, күзендә нур уйнап тора... Мин моны күрүгә түзмәдем, өстәлгә капланып җылый башладым. Картым, мәрхүмнең кул-аягын ипләде дә катып калды...

– Бигрәк кызгандым инде бичараны... Үз баламнан болайрак күрә идем... Атна саен диярлек безгә килә иде, ишектән керә-керүгә үк: “Нихәл, җиңгәкәем, исәнмесез... Кәефләр матурмы?” – дип өзелеп тора торган иде... Атна кич җитте исә, тәрәзәгә утырып, аны көтә иде, килү белән тамагын туйдыра идек, үзе белдермәсә дә, бичараның ачлыктан йөрәге өзелеп беткән иде... Безнең белән сөйләшкәч, кызым Маһирә аңа үз абзасы кебек иркәләнеп, Сахиб абый, мин теге сез өйрәткән матур көйне әзрәк боза башладым, бугай, җырлыйк әле, ди торган иде. Икәүләп моңланырга тотыналар иде. Ходаем, шул ике бала моңланганда, барлык хәсрәтләрем тарала иде...

Изге җаннар бу дөньяда күп тормый дигәннәр, үлде шул инде, үлде... Ичмаса, бичаракайның актык сулышлары вакытында була алмадым... Баязид кая? Булат, Гәрәй Солтан кая? Инде Сахиб та юк... Ходаем, бу нинди эш!!

Заһидә җиңи, туктап, бишмәтен каптырды, кызыл шәлен, чәчләрен төзәтте дә:

– Ходаем, онытып киткәнмен, абзаңыз анда көтә... Ул мин баруга килеп җитәр, сиңа көтәргә кушты, – дип чыга башлады.

Мәрхүмнең тупрагына актык сәламне бирер өчен, иптәшләр һәммәсе киенеп, Заһидә җиңи белән бергә юнәлделәр.

### XXXIV

Алар яңадан кайтканда, сәгать алты булып килә иде инде.

Мәҗлес авыр барды, җүнләп эчмәделәр. Эчсәләр дә исерә алмадылар. Сәлимов кайта-кайта:

Намуслы җан иде, иң авыр вакытта таянырга мөмкин иде, – дип сөйләде.

Җиһангир аның иптәшлеген, авыр язмышын тасвир итте. Гөлбикәгә хат язарга, актык сүзләрен ирештеререгә тиешле, диде.

Качкын Хәбиб:

– Ул иске тормыш җәһәннәменең төбеннән күтәрелде, бөтен дөнья хыянәт итсә дә, Сахиб безнең кеше иде, башкача уйлауны аның башы кабул итми иде... Әрәм, әрәм, – диде.

Кайгыдан үлеп, Нәфисә килеп керде. Иптәшләр, гүя юк иде. Сахибның матур, авыр моңы хакында:

– Ишетсәм, дөньядан югала идем, кайгылы күңел иде, мәрхүмкәең, – дип, берничә сүз әйтте дә, гафу үтенеп, ширма эченә керде, Урмановның мендәренә капланып җылый башлады.

Ләкин озак калмады: “Береңез мине һавага алып чыгыңыз, әле”, – дип үтенде.

Давыдның җыенасы, Габдәһ абзыйны көтәсе, иптәшләре белән сөйләшәсе бар. Нәфисә аңа:

– Син чыкма, эшләреңне бетер... Без Җиһангир белән йөреп килик, – диде.

Җиһангир, сикереп торып, студент фуражкасын, сары төймәле пальтосын киде дә ханымны култыклап чыгып китте.

Адәм кайбер вакыт аракыны, ат су эчкән кебек эчә, ләкин һаман исерми. Бүген шундый хәл булды. Башта тамакларыннан үтмәсә дә, сөйли торгач, стаканнарын аудара башладылар .Мәҗлес шулай авыр гына барган вакытта, керле алҗапкычлы малай кереп:

– Давыд абзый, сине бер хатын чакыра, – диде.

– Кем ул тагы? Ник үзе керми?

– Кем икәнен белмим. Атлары белән урамда тора. Мөмкин булса, бер-ике минутка гына чыксын иде, – ди...

Давыд билендәге каешын ипләде, чәчен бик аз гына төзәтте дә: «Кем булыр? Үткән гөнаһларның берәрсеме әллә?” – дип, сукрана-сукрана чыгып китте.

Ләкин озак тормады. Биш минут үтүгә, кызарып, сүгенеп, яңадан килеп керде...

– Хатыннарны, – ди, – җылан дип әйтәләр... Бу гына аз. Алар гади җылан гына түгел. Алар үз теләкләренә ирешү өчен, агуларын яшереп, фирештә сыйфатына керә, шулай итеп, сине астыртын чага торган җыланнар... Имеш, ул онытмаган, имеш, кулыннан килгәнчә, ярдәмләшергә тели...

Бу сүзләрдән бер мәгънә дә аңламаган Сәлимов белән Хәбиб көлә башладылар:

– Әллә сине чынлап та җылан чактымы? Ник ул чаклы сүгенәсең?

Давыд тагы кызды:

– Чагарга дип килгән... Җылан кабыгын салып, фирештә төсенә кергән, агуларын яшергән... Тик Давыдның үткен күзләре генә ул тышкы кабыкны үтә күрделәр...

Сәлимов тагы бәйләнде:

– Сөйләсәң, рәтләп сөйлә... Кем килгән, ни булды?

Давыд бер рюмка салып эчте, ачуыннан чәчәде, умывальникка барып төкеренде, сөртенде дә, гасаби адымнар белән йөреп, ачулы, сүгенүле тавыш белән дәвам итте:

– Борынгы Юнан шагыйрьләреннән Һизиядның "Пандора" дигән легендасы[152+] хәтерегездәдер... Аллалар атасы "Зевс"[+153] адәмнәргә ачулана да үч алырга чара эзли башлый. Дөньяның бөтен матурлыкларын, нәфислекләрен җыйнап, гаҗәеп гүзәл хатын халик кыла[1]. Йөрәген, миен мәкер белән, рия[2] белән, яшерен оятсызлыклар белән тутыра... Соңра йир йөзенә йибәрә... Һәм теләгенә ирешә: аңарчы тыныч рәхәт яшәгән адәмнәрнең тормышы җәһәннәмгә әйләнә...

Вакытында мин буңа шагыйрьнең кызыклы хыялы, дип кенә карый идем... Ул кызыклы гына түгел, гаҗәеп тирән мәгънәле дә икән.

Чыксам, күземә ышанмадым, баскан йирләрендә чыдаша алмый торган шәп пар кара ат. Баштанаяк зәңгәр постау киенгән, башына канатлар куйган калын кучер... Кыйммәтле дышло[3]. Шуңа аркасын терәп, әллә нинди графинялар кебек киенеп, ясанып, яшь гүзәл ханым утырган... Кем дисез?

Теге вакытларда: "Мин ул хәяттан мәңгегә киттем. Кайту булмаячак. Мин – революционер", – дип янып, эшче-крәстиян белән язмыш, имеш, берләштергән Рауза!

Хәбиб тә, Сәлимов та мәсьәләгә чыннан әһәмият бирделәр. Күзләрен зур итеп, дәвамын сорадылар:

– Шуннан, шуннан...

– Шуннан соң ни булсын? Күрүгә аптырап калдым, сөйләшми кереп китү балалык булачак... Мине сез чакырдыңызмы? Ни йомыш? – дидем... Күрешмәскә теләсәм дә, ул урыныннан кузгалып, матур елмаеп, кулын сузгач, килештермәдем. Русча сүз башлады:

– Сез сүксәңез дә, мин иске дустларны оныта алмыйм... Сезнең, – ди, –

---

[1] *Халик кыла* – барлыкка китерә.
[2] *Рия* – икейөзлелек.
[3] *Дышло* – бер тәртәле арба.

зинданнан чыгуыңызга бик шатмын, – ди.

– Рәхмәт, – дидем.

Туташның яңакларында ут уйный... Күзләре шундый иркәләп елмаялар, иреннәрендә шундый матур мәгънәләр ки, бу гаҗәеп үткен гүзәллектән минем күз алларым караңгылана язды... Күзләремә җотылды. Кулымны катырак кысып елмайды да:

– Мине тәбрик итеңез, мин кияүгә чыктым... Беләсездер фабрикант Абизовны, ди...

– Хәерле булсын, бәхетле тормыш телим, йомышыңыз нәрсә, – дим.

Туташ кинәт суынды. Елмаюларын басты. Күзендәге нурларын яшерде, бөтенләй кайгылы төс алды, әйтерсең, матур якты нурлы күкне кара болыт каплады... Тавышы да гүя, йөрәктәге авыр хәсрәттән килә иде:

– Мин, – ди, – яңа гына җырчы Сахибның вафатын ишеттем... Бик кайгылы хәбәр, бик авыр югалту... Иптәшләрнең кайгысына камил кушылам, үкенеч ки, мин хәзер йөрәгемә якын иптәшләрнең язмышларында катнаша да алмыйм, – ди.

Ләкин болыт тиз таралды. Кояш ачылды, Күк йөзе тагы якты нур белән тулды... Туташ калку күкрәге белән дышло читенә таянды да, елмаеп:

– Сез, – ди, – ахры, зинданда бик ватылгансыздыр, бөтенләй элекке Давыд түгелсез... Авылга китәчәгеңезне ишеттем. Анда тазарырсыз, – ди.

Ни әйтәсең? Ләкин ул миңа сөйләргә дә урын калдырмый, үзенең гаҗәеп дустанә карашы, сихерле елмаюы белән кулымны яңадан ала да мине тозакның үзәгенә бастырмак була:

– Мин, – ди, – хәзер сезнең кебек хезмәт итә алмыйм... Инде дөнья кешесе булам, сезнеңчә мещанлык сазына батам. Ләкин, – ди, – күңелем моның белән тынычланмый. Кулдан килгәнчә ярдәмләшергә телим... – дип, кәгазь акчалар белән тулы бер пакет тәкъдим итә...

– Моны, – ди, – үз танышларымнан яшерен рәвештә җыйнадым... Сахибнең күмүенә тотарга булыр. Булат, Гриша, тагы кайбер иптәшләр сөргендә бик мохтаҗлык күрәләр, дип ишеттем, рәхим итеп, буны шул тиешле урыннарга тотсаңыз, бик рәхмәт укыр идем. Мине бәхетле ясар идеңез, – ди...

Мин кырт кистем:

– Сахибнең күмүен иптәшләр тәэмин итте. Алар чит кешедән акча алырга хурланачаклар... Зариф Булатовның хәле дә зыянсыз, Нина көн-төн эшли, яхшы акча таба, тапканының яртысын Булатка йибәрә тора... Сез ул садакаңызны җәмгыяте хәйриягә яисә приютка йибәртеңез! Хушыңыз... – дидем дә борылып кереп киттем...

Баштан бирле хикәяне бик кызыкланып, ахыры ни булыр, дип торган

иптәшләр, Урмановның сүзе бетүгә, балалар кебек кәефләнделәр. Качкын Хәбиб, урыныннан торып, кызып, сүгенә башлады:

– Яраган, бик яраган... Акчулпаны, Раузасы, Госманы, Йосыфҗаны, шулар шикелле кичә революция дип йөреп тә, контрреволюция сафына, имеш, милләтчелеккә чыккан ул сәяси фахишәләргә башкача мөгамәлә булырга мөмкин түгел... Ләкин ничек аңларга? Ул ник тагы безгә килеп ялагайлана? Моның сәбәбе нәрсә?

Давыд мәсьәләнең төбен ачты:

– Сиңа, – ди, сөйләдем, бугай... Ул мөртәтләр үзләренең үткән «гөнаһлар»ының ачылуыннан куркалар... Безнең арада тентүләр, сөрүләр, асулар, сораулар булган саен, алар үзләренең исемнәре килеп чыкмаудан әмин түгелләр... Моннан ике еллар элек, мине бу хакта, өчәүләшеп, Йосыфҗан өенә кунакка чакырдылар... Ул вакыт мин: «Курыкмаңыз, сезнең шкураларыңыз әмин...” – дип, сүзне кистем, бармадым... Тагы шундый берәр нәрсә чыккандыр... Аннан да бигрәк бу матур җылан ул вакытта бик артык хурланган булырга тиешле... Имеш, ул чакыра, килмиләр, шундый каты җавап бирәләр... Ике ел буена шул ачуны саклагандыр, хәзер инде безне йомшарганнар, җиңелгәннәрдер, дип уйлап, шул элекке үчне алырга килгән... Имеш, ярдәм, имеш, Сахибне күмәргә, Булатка йибәрергә... Әгәр дә алган булсам, ул үз эченнән бәйрәм итәчәк, теге вакыт тапталган горуры яңадан торгызылган булачак... Аннан соң ул шундый типларның берсе ки, уңны да, сулны да үзенең сихерле елмаюына кол итәргә – бөтен дөньяны үзенә табындырырга тели...

Сәлимов ачы ямьсез сүзләрдә фабрикант Абизовны кырык биш яшьлек карт фахиш, дип тәүсыйф кыла[1] башлады:

– Давыд, мин, ди, кияүгә чыктым, тәбрик ит, дигәч, Абизовның әле күптән түгел йөз мең биреп котылган элекке сөяркә марҗасыннан балалары барлыгын, алар: «Әни, әни», – дип, Рауза муенына асылачакларын беләсезме, дип сорарга иде, ди. Давыд кул селекте, чукынсын ла, кырык биш булмагае, йөз дә биш булсын, баласы, миңа дисә, ун булсын, безгә әһәмият анда түгел. Ул бит җылан, фирештәләнеп, үлгән, сөрелгән революционерлар бәһанасы[2] белән бездән издеваться итәргә килгән... Рауза: “Мин яшәргә телим, тормыш телим”, – ди икән. Шуның белән бөтен нәрсә ачыла.

Кемдер ишек какты да җавап көтмичә үк ачты.

[1] *Тәүсыйф кыла* – сыйфатлый.
[2] *Бәһанасы* – сылтавы, ялган сәбәбе.

## XXXV

Габдәһ абзый, Заһидә җиңи, Нәфисә, Тангатаров, Җиһангир, тагы берничә иптәшләр, арып, кайгы белән капланып килеп керделәр.

Габдәһ абзый Давыд белән исәнләште, хәле беткән кеше кебек креслога чумды:

– Җиңгәң әйтмешли, бер шатлыкка мең кайгы, ди, син чыктың, Сахибне күмәбез... Ходай миңа шундый авыр газап йибәрде: кадерле иптәшләрне зинданга, сөргенгә озатам, үз кулым белән кабергә төшерәм, палач кулыннан үткәннәрнең гәүдәләрен эзләп саташам... Миңа тагы бер хәл, мин удар булган саен, тешемне кысам, озакламас, яңадан безнең көннәр килә әле, дип, ачу белән ныграк эшкә тотынам... Менә җиңәңез белән Маһирәгә бик авыр... Алар Сахибкә үз туганнарыннан артык багланганнар иде. Һични белән җуатыр хәл юк...

Заһидә җиңи тагы мәрхүмне мактап, үз баламнан якынрак иде, җиңгәкәем, дип, үлеп торадыр иде, дип җылый башлады.

Җанымны җуаттылар. Кемдер Габдәһ абзыйга: «Кабарга да яхшы, берәр ни эчеңез», – диде. Ул йөз чытып, кул селкеде:

– Юк, мин ул нәрсә белән күптән үк булашмыйм, – диде. Җиңи, шатланып, рәхәтләнеп, иренә карады. Ходаем, ди, беткән, кешелеге калмаган иде бит... Аны менә шул иптәшләр коткарды, ди. Давыд юл аягы, дип, көлә-көлә самавыр, бик күп чынаяклар, әллә ничаклы пәрәмәчләр алдырды.

Күңелләр бераз күтәрелде. Тик Нәфисә белән Заһидә җиңги генә элеккечә боек утыралар иде...

Хәбиб элек сул булып йөреп тә, хәзер буржуазиягә сатылган мөртәтләрне сүгәргә тотынды.

Кемдер Госманның земствода яхшы урын алуын, байлар белән камил килешүен, тиздән җәмгыяте хәйриягә рәис булачагын, бай кызы алырга план коруын, иң кимендә ике катлы таш йортың, үзеңнең парларың, кучер, кареталарың булмагач, тормышмыни ул, дип каравын сөйләде...

Давыд:

– Шәп эш! Шәп эш! Социализм белән башла да, җәмгыяте хәйриягә барып тукта! Бу – чыннан да, шәп эш! – диде.

Икешәрне эчкәч, Габдәһ абзый белән Заһидә җиңи, рәхмәт укып, урыннарыннан тордылар да:

– Син киткәнче тагы килермез, – дип чыга башладылар.

Нәфисә дә кузгалды, утырырга димләсәләр дә:

– Хушыңыз, башым авырта, – дип, җиңгиләргә кушылды.

Давыд башына кепка, өстенә җәйге пальто салды да: «Мин хәзер кайтам, Бәдри килсә, көтсен”, – дип, Нәфисәне озата чыкты.

Габдәһ абзыйлар 5-10 адым алга китү белән, ханым:

– Сахиб үлде, син китәсең, болар мине үтерә бит, башымны кая куйыйм, Илаһым, дип, дустының күкрәгенә капланды.

Ләкин үзләренең коридорда булуы, кеше күрү ихтималы аны тиз айнытты. Давыд, Нәфисәнең биленнән алып, иркәләргә, җуатырга тотынды.

Озак бармадылар. Урамда туры килгән беренче ямщикны чакырып, ханым үзе генә китәчәк булды.

– Хәлем бетә, башым әйләнә, мин кайтыйм, онытма, хат яз, озын яз, – диде дә, сикереп, коляскага менде.

Давыд яңадан кайтканда, Бәдри килгән, үзе эчә, үзе тизрәк, дип ашыктыра иде.

Габдәһ абзыйны көтеп, тагы акрын гына эчә башладылар.

Хәбиб сүзне Давыдка тартты: "Китүеңне аңламыйм, тизрәк килсәң ярый, юкса эш туктала", – диде.

Урманов бераз уйлангач җавап бирде:

– Син аңларга тиешлесең! Мин яңадан тереләм, ләкин халык эченә кайтып, аның чишмәсеннән куәт алырга телим...

Хәбибнең күзләрендә ниндидер бер сөаль, бер яңа фикер ялтырады, иптәшенә текәлеп карады:

– Син ни сөйлисең? Ниужәли синдә дә шул бөтен яшьләрне харап иткән шөбһә булып үтте?

Давыд яшермәде:

– Булганда да нинди шөбһәләр булды?! Минем газапларым, күрәсең, вакытсыз чәчләремне агартты... Миндә бервакыт революциягә, социализмга гына түгел, кешелеккә иман бетте... Яхшылык белән явызлык бергә буталды... Йөрәгемдәге Җәбраил каядыр богауланып, анда Иблис хаким булды... Иҗтимагый юллар белән дөньяның рәткә керүеннән өмид өзгәч, мин Толстойга капландым... Аның "Үзеңне төзәт, бөтен дөньяң төзәлә!" дигән нигезләре өстендә иман ясарга теләдем... Булмады, канәгатьләндермәде, Ницшегә сугылдым... Бервакыт аның "Заратусра"ларын[154+] бөти итеп йөреттем...

Ләкин бары да тиз үтте... Актык тәҗрибә зинданда булды һәм шунда мин яңардым... Башкалар катнашмады, Хәбиб үзалдында яңа, бөтенләй яңа бер мәсьәлә ачылган кеше кебек, акрын җитди тавыш белән иптәшенең сүзен бүлде:

– Син гаҗәп, гаҗәп яшерен кеше икәнсең! Хәер, мин соңгы вакытларда сине күп күрмәдем дә бит! Сәбәбең, үзең әйтмешли, халык чишмәсеннән куәт эчү, йөрәгеңә революция көчләрен җоту булса, аның өчен ник авылга барырга? – дип, тәрәзәдән күренеп торган зур завод морҗасына ишарә

кылды:

– Ул сиңа куәт бирә алмыймы?

– Шөбһәсез, бирә. Ләкин икенче сәбәпләре дә бар. Әни белән сеңелем бик үпкәләп чакыралар, безне бөтенләй оныттың, диләр.

Тән сәламәтлеге дә начар... Ул яктан да ныгаясы бар...

Һичкем һичбер сүз әйтмәде, качкын Хәбиб берне эчте дә, урыныннан торып:

– Ярый, ярый, бар, көч ал, ләкин тиз кил... Җиңелгән гаскәрнең хәле башта гына харап икән... Эшчеләр хәзер яңадан уйлана, уяна башладылар... – диде дә, үзенең хыялларын, планнарын тасвир итәргә тотынды. Болар берсеннән-берсе авыррак, ләкин авыр булган саен, Качкын Хәбибнең ялкынын арттыралар, канын кыздыралар, күзләреннән ут чәчәләр иде...

Усал, курыкмас егетләрдән кечкенә фиркалар ясарга... корал алырга... почта, банка ясарга... яшерен басмаханә куеп, идән астыннан газета чыгарырга, әдәбият таратырга... Көчне арттыргач, Уралга барып, шахталарны кузгатырга... гыйсъян[1] чыгартырга... кан дәрьялары эчендә йөзеп, реакциянең өзелгән башлары өстеннән таптап, революциягә барырга...

Шуларны гаҗәеп җанлы күренешләрдә тасвир итте, иптәшләрен кыздырды да, ахырдан:

– Их, минем Баку шахталарында кайнап чыккан Гәрәй Солтаным исән булса... Без күрсәтер идек аның белән...

Ләкин өмид өзмим, Габдәһ абзый аркылы мин материалның бик яңасына барып каптым... – диде...

Үзенең һәркөн дәвам иткән түгәрәкләрен, кечек организациясен, боларның зурая баруын сөйләде.

Бәдри тагын ашыктырырга тотынды.

Әнә Габдәһ абзый да килде.

Исәнлеккә, яңадан күрешүгә дип, берәрне, икешәрне эчтеләр дә Давыдның әйберләрен күтәреп чыга башладылар.

Качкын Хәбиб, Габдәһ абзый әйтүе буенча, саклык йөзеннән, иптәшләре белән чыкмаска булды:

– Хәерле юл, тиз кайт. Хәбәрләшү Заһидә җиңи аркылы! – диде дә, күрешеп, номерның ашханәсе үтәли йөри торган ишегенә таба китте.

Атлар әллә кайчаннан бирле көтә иде. Ак җон эшләпә, оек, чабата кигән кучер:

– Абзыйлар, ай-һай озак булдыңыз... Малкайларым яңадан ачыктылар... Кояш та батып бара! – дип шелтәләп, нәрсәләрне урынлаштырырга тотынды.

---

[1] *Гыйсъян* – баш күтәрү, бунт.

Юлчылар, урыннарын иплəп, тарантаска утыргач, Габдəһ абзый иң кирəкле бернəрсəне хəтерлəгəн кеше кебек, яңадан йөгереп килде:

– Тукта əле, Давыд, тукта, – ди,– кайгыдан зиһенем таралып беткəн... Иң кирəкле эшне оныткамын, мин бүген генə Булаттан хат алдым...

Боны ишеткəч, Урманов урыныннан ук кузгалды, артык дикъкать белəн эшче иптəшенең күзлəренə текəлде:

– Нəрсə яза, нəрсə яза? Бик хафаланмыймы?

Габдəһ абзыйның йөзенə шатлык чыкты. Күзлəре эчке бəхет белəн нурланды:

– Кызым Маһирə, – ди, – кат-кат укыды... бик шатландык... Барыңызга да сəлам əйтə. Хəлем яхшы, – ди. – Безне җуата. Кайгырмаңыз, бу караңгы төн мəңге булмас, – ди.

Давыд, бөтен гəүдəсе белəн сузылып, Габдəһ абзыйның иреннəреннəн үпте:

– Шулай, Габдəһ абзый, шулай, безнең көннəр озакламый яңадан килер... Кайгырма, бу караңгы төн мəңге булмас!! Маһирə туташка, Заһидə җиңигə сəлам сөйлə, рəхмəт əйт!!

Атлар кузгалды.

Почмактан Нəфисə килеп чыкты. Ул, ахрысы, өенə кайтмый, кире бонда борылгандыр.

Давыд Урманов, кепкасын күтəреп, баш иде. Ханым сөеп елмайды, кечкенə ак зонтигын селкə-селкə карап калды.

---

(Беренче дəвер трилогиядəн беренче бүлем шуның белəн тəмам).

1914–1920, Кавказ-Казан.

# ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

[1+] *... казачий шәкерте...* – татар казачий катламы турында сүз бара. Татар казачийлары беренче тапкыр XVII гасырда Оренбург якларында барлыкка киләләр, Урал һәм Уралдан ары төбәкләргә дә таралалар. Типтәр-башкорт гаскәрләреннән аермалы буларак, бүгенге көндә дә аерым милли-иҗтимагый төркемне хасил итәләр. Ислам динен тоталар.

[2+] *“Исляхате мәдарис” исеме белән бер җәмгыять* – Татар җәдитчелек хәрәкәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән, мәдрәсәләрне милли нигездә үзгәртеп кору юнәлешендә эш алып барган җәмгыять. 1905 елдан татарлар яшәгән һәр төбәктә диярлек оешып, уку-укыту реформаларын әзерләгән, татарда мәгариф эшен европача үзгәртеп корган, дини белем системасыннан дөньяви белемнәрне аерып, һәр ике өлкәдә дә заман таләпләренә җавап бирерлек шәкертләр әзерләүне оештыруны максат иткән һәм үз җаваплылыгына алган иҗтимагый оешма. Казанда, Уфада, Оренбургта һәм башка зур шәһәрләрдә андый оешмалар берничә булган, төрле исемнәр белән йөртелгән. Монда сүз Ф.Әмирхан җитәкләгән «Әл-Ислах» комитеты хакында бара.

[3+] *...прокламация тарату, кызыл фикердә булу белән гаепләделәр* – Революцион хәрәкәтләрдә катнашуда гаепләү хакында сүз бара. «Кызыл фикер» дип, революция юлы белән патша властен һәм буржуаз-феодаль сыйныфны юк итү идеясен алга сөрә торган фикерләр атала. Революцион хәрәкәттә катнашучыларны патша Россиясендә ирекләреннән мәхрүм иткәннәр һәм сөргеннәргә сөргәннәр.

[4+] *Мәшрутияте гавамиячеләр* – Россия хөкүмәте Дәүләт Думасындагы Конституцион-демократик партия хакында сүз бара. Аларга «Мөселман иттифакы» партиясе кушыла.

[5+] *“Мәкамәте Хәрири”нең баш каһарманына охшатып...* – гарәп язучысы Мөхәммәт ибне әл-Касыйм әл-Хәрининең (1054–1122) мәкам жанрында иҗат ителгән әсәрләренең төп әдәби герое Әбу-Зәйд әс-Сәрүҗи хакында сүз бара. Ул хәйләкәр, һәртөрле авыр хәлдән җиңел чыга алучы, бәлаләрдән җиңел котылучы зирәк шәхес, шул ук вакытта рухани итеп тә сурәтләнә. Хәрири шушы әсәрләре аша дан казана. Бу мәкамнәр озак еллар буена әдәби осталык өлгеләре санала. Хәрири бай сәүдәгәр һәм җирбиләүченең улы була. Яхшы белем ала. Бик яшьли әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Бер шигырь җыентыгы һәм рисаләләре мәгълүм.

[6+] *Яманташ буендагы крәстияннәр...* – Яманташ – хәзерге Башкортстанның көньягында Мәгаш елгасына коючы инешнең исеме. Мәгаш

үзе Сакмарга, Сакмар исә Җаекка коя. Сүз бу җирләрдә игенчелек белән шөгыльләнүче халыкның башкүтәрүе хакында бара.

[7+] *“Кызыл флаг”, “Крестьяннарга ни кирәк?”, “Эшчеләр авазы”, “Дума ни бирер?”,* – революцион-демократик эчтәлектәге мәкалә исемнәре.

[8+] *“Безнең юл”* – 1917 елның октябреннән 1918 елның гыйнварынача Уфада чыккан большевистик юнәлештәге газета. Ул – “Ирек”, “Авыл халкы” һәм “Солдат теләге” исемнәре астында чыгып килгән газеталарның берләшүеннән туган басма. Мөхәррире Г.Ибраһимов була. Барлыгы 36 саны дөнья күрә.

[9+] *Колядагы* – Коля. Бу образның прототибы – 1905-1907 елларда революция хәрәкәтендә актив катнашкан, Уфада сугышчан дружиналар оештырган Николай Кадомцев.

[10+] *...кантон заманасыннан калган* – 1798-1865 елларда башкортлар, типтәрләр, мишәрләр, калмыклар, Оренбург һәм Урал казачийлары яшәгән төбәкләрдә урнаштырылган хәрби идарә формасы. Ул төрле башкүтәрүләрне басып тоту, Азияне яулап алу сәясәтен алып бару өчен оештырылган булган.

[11+] *“Вестник” газетасын* – Дөресе: «Правительственный вестник», Санкт-Петербургта 1869 елдан алып 1918 елның февраленә кадәр чыгарыла. Матбугат эшләре буенча төп идарәнең басма органы. Вакытлы хөкүмәт чорында анда «Серле документлар» рубрикасы ачыла.

[12+] *...партиянең иң сул канатында торуы* – һәртөрле партиядә дә “револоюция юлы белән генә илдә иҗтимагый гаделсезлекне юк итәргә мөмкин” дип инанган төркем.

[13+] *“Ислахе мәдарис”нең сигезенче номеры* – 1908 елда Казанда Ф.Әмирхан тарафыннан оештырылган демократик яшьләр газетасы. Халыкка аң-белем тарату, агарту юлы белән гадел җәмгыять төзү идеясенә хезмәт иткән.

[14+] *Маркснең “Капитал”ы* – Карл Генрих Маркс (1818-1883), немец фәлсәфәчесе, социолог, икътисадчы, язучы, шагыйрь, сәяси журналист, җәмәгать эшлеклесе. 1848 елда Ф.Энгельс (1820-1895) белән берлектә «Коммунистлар партиясе манифесты»н яза. 1867 елда «Капитал. Сәяси экономикага тәнкыйть» классик фәнни хезмәтенең беренче томын бастырып чыгара. Материалистик диалектика, Гегель фәлсәфәсен, мәдәният тарихын материалистик аңлату, фәнни социализм, сыйнфый көрәш, өстәмә табыш алу теориясен тудырган акыл иясе санала. Аның өйрәтмәләре нигезендә «марксизм» барлыкка килгән.

[15+] *“Фидаиләр” исеме белән бер партия* – 1905–1907 еллардагы революция вакытында кайбер мәдрәсәләрдә шәкертләр тарафыннан оештырылган, эсерлар партиясе тәэсирендә булган вак буржуаз оешма.

[16+] *Кавказларның “дифагый”ләре* – монда сүз азәрбәйҗаннарның либералистлары хакында бара.

[17+] *...Мариинскаяның гимназисткалары* – 1917 елга кадәрге Россиядә җидееллык кызлар урта белем мәктәпләрендә укучылар. Бу мәктәпләр император Александр II ның (1818–1881) хатыны патшабикә Мария Александровна (1824-1880) тарафыннан ачылганга күрә, «мариинская» дип аталып йөртелгәннәр.

[18+] *Фарансуз революциясе* – Бөек Француз революциясе. Ул 1789 елның 14 июлендә Бастилияне алу белән башланып, 1799 елның 9 ноябрендә тәмамлана. Аның нәтиҗәсендә Франциядә алдынгы демократик җәмгыять барлыкка килә.

[19+] *Кавказда әрмәннәр белән татарларның бер-берләрен кырулары* – Сүз 1905–1906 елларда әрмәннәр һәм азәрбайҗаннар (ул чорда азәрбайҗаннарны татарлар дип йөрткәннәр) арасындагы канлы бәрелешләр турында бара. Аеруча каты көрәш Бакуда һәм Нахичеваньда була. Нәтиҗәдә, йөзләгән азәрбайҗан һәм әрмән авыллары юкка чыга, меңләгән кешеләр һәлак була.

[20+] *“Иттифак әл-мөслимин” әһеленә* – 1905 елда татар милли буржуазиясе тарафыннан оештырылган, 1918 елга кадәр яшәп килгән, милли мохтарият – республикалар төзү өчен көрәшкән партия әгъзалары хакында сүз бара. Бу партия Россия конституцион-демократик партиясенә теләктәшлек күрсәтә, Думага сайлауларда бердәм платформада бара.

[21+] *Ротшильдләр* – XVIII ахырыннан бирле Европаның данлыклы банкирлары нәселе. Алар иҗтимагый-сәяси эшләрдә шактый актив һәм алдынгы карашлы булганнар. 1826 елдан Австриянең императоры аларга барон титулы биргән. 1848 елгы инкыйлабта артык зыян күрмиләр. Европада тимер юллар челтәре һәм икътисад үсешендә зур роль уйныйлар.

[22+] *Ясакка актык атымны саттырдылар* – Россиядә дәүләт казнасына түләнелүче салымнар «ясак» дип аталып йөртелгән, биредә шул салымны түләү өчен соңгы атын сатарга мәҗбүр ителү хакында сүз бара.

[23+] *Душамны саттым* – имана җирен сатуы хакында сүз бара. Инкыйлабка кадәр җир гаиләдәге “душа”лар – җан башы саны буенча бүленеп бирелгән. Исәпкә ир-атлар гына алынган. Монда русча аталышы кулланылган.

[24+] *Талчокчы татарлар* – вак-төяк, иске-москы әйберләрне сатучылар хакында сүз бара.

[25+] *“Тау башы” ягындагы башкортларга кантон булып яшәгән* – Меңле өязе башкортлары хакында сүз бара.

*Кантон* – XVIII–XIX йөзләрдә Башкортстандагы административ-

территориаль берәмлек. Әлеге территориягә идарәче итеп билгеләнгән җитәкче дә шул ук исем белән аталып йөртелгән.

[26+] *Язма "Шәрхе мөлля" белән "Шәрхе викайә"* – кадим мәдрәсәдә укытылган дәреслекләр. "Шәрхе мулла" (тулы исеме – "Кәфийә шәрхи Фәваид Дийагыйә) – гарәп грамматикасы дәреслеге. Ул ибн әл-Хаҗибәнең XVIII гасырда иҗат ителгән "Кәфийә" исемле хезмәтенә шәрехләр буларак языла. Халык телендә "Шәрхе Мулла" дип аталган бу дәреслек татарлар арасында бик киң таралган була.

"Шәрхе викайә" – фикх (ислам хокукы) дәреслеге. Авторы – Гобәйдулла бин Мәсгут Садрашшәрига әс-сәни. Китапның нәкъ менә әлеге варианты татарлар арасында шулай ук киң таралыш алган.

[27+] *Мәкәрҗә* – Түбән Новгородта урнашкан ярминкәнең татардагы аталышы. Иң элек ул Болгар шәһәрендә булып, аннан Казанга күчерлә. 1552 елда, руслар Казанны алгач, бу ярминкә Түбән Новгородта, Макарий монастыре янында уздырыла башлый. Шул исемгә бәйле рәвештә, татарлар аны «Мәкәрҗә» дип атыйлар. Анда Европа илләреннән, Кытай, Иран, Россиянең төрле шәһәрләреннән күпләп сәүдәгәрләр килә. Аеруча татарлар ярминкәгә яратып йөри. Ярминкә Ука елгасының Иделгә койган урынында 8 гектар җирне биләве, кунакханәләре, театрлары (1830 елдан) белән дан тота. XIX гасырның соңгы чирегендә монда татар театры да беренче спектакльләрен куя.

[28+] *Оренбург Каргалысының биш йөз шәкертле кадим бер мәдрәсәсендә* – Оренбург губернасының Каргалы авылында (Сәгыйть бистәсендә) XVIII гасырның урталарында ачылып, Октябрь революциясенә кадәр яшәп килгән кадим мәдрәсәләрнең берсе. Биредә беренче номерлы мәчет каршындагы мәдрәсә турында сүз бара. Ул татар суфичылык үзәкләреннән берсе булган. XIX гасыр ахырында Каргалы мәдрәсәләренең кайберләрендә дөньяви фәннәр кертелсә дә, күбесендә искечә укыту кала. Бу мәдрәсәләр 1919-1920 елларда ябыла.

[+29] *Авызына Хозер галәйһиссәләм төкергән* – бу урында "укымышлы, белемле" мәгънәсендә. Хидер (яисә Хозер) галәйһиссәлам – пәйгамбәр. Ул Әбел-хәят чишмәсенән су ("тереклек суы") эчә һәм җир йөзендә ахырзамангача калдырыла. Япан-кырларда адашкан кешеләргә юл күрсәтә. Ак сакаллы бабай рәвешендә күренә. Ак күгәрчен булып оча. Ильяс пәйгамбәр белән икесе бергә йөриләр. Үзара бер-берсенә охшашлар.

[30+] *Синдә хәзрәти Давыд тавышы бар* – Давыд пәйгамбәр матур тавышы белән аерылып торган, шигырьләр язган. Алар «Зәбур» (псалмалар, дини гимнар) тупланмасын тәшкил итәләр.

[31+] *"Мәраҗәл бәхрайни йәлтәкыян, фәбиәййи галәйи Раббикумә*

*тукәззибән...”* – “Әр-рахмән” сүрәсенең 19 һәм 21 аятьләре. Мәгънәсе: “Ул ике диңгезне янәшә ага торган итте. Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялганга чыгармакчы буласыз?”

32+ *Япон сугышы* – 1904 елның 27 гыйнварында (9 февралендә) башланып, 1905 елның 23 августына (5 сентябренә) кадәр дәвам иткән Маньчжурия һәм Корея җирләре өчен барган Рус-япон сугышы. Россия бу сугышка 1860 еллардан бирле әзерләнә, әмма рус гаскәрләренең һәм флотының җиңелүе, Сахалин утравының көньягын Японияге бирү, Портсмут солыхы төзү белән тәмамлана. Россиядә инкыйлаби вазгыять барлыкка килә.

33+ *Ул арада Русия диңгезендә куәтле дулкын күтәрелә... Шул дулкын эчендә татар көймәсе дә кузгала, җанлана башлый...* – Рус-япон сугышы нәтиҗәсендә, 1905 елның көзендә илдә башланып киткән революцион күтәрелешләр хакында сүз бара. Анда татар халкы бердәм милләт буларак катнаша, Россиядәге башка төрки халыкларны да үзенә ияртә, азәрбайҗан милли революцион көчләре барлыкка килә.

34+ *Шансоньеткалар* – кабареда биюче «очсызлы» җырчы кызлар күздә тотыла, биредә мыскыллау сүзе буларак кулланылган.

35+ *Писарев, Чернышевский, иң гаҗәбе – монда Герцен да бар* – рус публицистлары, тәнкыйтьчеләр, революцион-демократлар Герцен А.И. (1812-1870), Чернышевский Н.Г. (1828-1889), Писарев Д.И. (1840-1868) хезмәтләре турында сүз бара.

36+ *Писаревнең “Реалистлар” дигәнен укый башладым* – рус әдәби тәнкыйтьчесе Д.И.Писаревның 1964 елда язган, практикларны реалистлар буларак аңлаткан, И.С.Тургеневның (1818-1883) 1861 елда язылган «Отцы и дети» романына бәйле күләмле хезмәте хакында сүз бара. Анда автор иҗтимагый, сәяси, икътисади тормыш материалын әдәби аң күзлегеннән чыгып бәяли һәм фикерләмәләрендә ачык фәлсәфи-демократик, фәлсәфи-революцион идеяләр уздыра.

37+ *Маркс* – 14 нче искәрмәне карагыз.

38+ *Хәзрәти Мәрьям рәсемнәре* – Мәрьям ана (Дева Мария) сурәтләре төшерелгән иконалар хакында сүз бара.

39+ *Бакунинның хәяты, тәгълиматы* – Михаил Александрович Бакунин (1814-1876) рус акыл иясе һәм революционеры, анархизм идеологы, халыкчы һәм панславизм вәкиле. Тверь өлкәсе Прямухино имениесендә олы алпавыт гаиләсендә туа. Әнисе – Варвара Александровна, декабрист Муравьевларның туганы була. Петербург артиллерия училищесында укый, әмма, җитәкчегә тупас мөнсәбәте өчен, укудан чыгарыла. Хәрби хезмәткә алына. 1835 елда, бер елдан соң, отставкага чыга һәм Мәскәүдә яши башлый. Үзен фәнгә багышларга ниятли, Станкевич түгәрәгенә йөреп, герман фәлсәфәсен

өйрәнүгә керешә. Рус алдынгы карашлы иҗат яшьләре белән аралаша. 1839 елда аны А.И.Герцен (1812-1870), Н.П.Огорев (1813-1877) белән таныштыралар. 1840 елда чит илгә китә һәм революцион мәкаләләр яза башлый, революционерлар белән тыгыз элемтәгә керә. Аңа 1844 елдан Россиягә кайту тыела. 1848 елда Париж халык башкүтәрүендә актив катнаша. 1849 елда Дрезден башкүтәрүендә җитәкчеләрнең берсе була. 1851 елда Австрия хөкүмәте аны Россиягә бирә. Бакунинны Петропавел, аннары Шлиссельбург кирмәннәренә ябып тоталар. Монда Николай Беренчегә «Тәүбә»сен яза, анда үзенең революцион карашларын бәян итә. 1857 елда Себергә сөрелә. 1861 елда Япония һәм Америка аша Европага кача, Герцен янына килә, «Колокол» журналы наширләреннән берсе була. Англиядә славяннарга мөрәҗәгатьләрен яза. 1862 елда «Халык Эше. Романов, Пугачев яки Пестель?» хезмәтен яза. 1862-1863 елларда Польша башкүтәрүләрендә катнаша. Аннан Италиягә китә. 1864 елда Лондода Беренче Интернационал оеша, 1868 елда Бакунин аңа керергә уйлый, әмма сәяси карашлары туры килмәү сәбәпле кире кагыла. Цюрихта «Народное Дело» журналын чыгаруны оештыруда катнаша. 1869 елда рус теленә «Коммунистлар партиясе манифесты»н тәрҗемә итә. Һәртөрле башкүтәрүләрне оештыруларда актив катнашып, 1879 елда Швейцариянең Берне шәһәренә килә һәм кара эшчеләр больницасында авырып ята һәм шунда вафат була. Фәлсәфи карашларында ул һәртөрле идарәне, сыйнфый карашларны, өстенлекләрне инкарь итә, кеше шәхесенең иреген өстен куя. 1874 елда ул «Дәүләт һәм анархия» хезмәтен бастыра. Анда хөкүмәт һәм социаль-революцион агымнар арасында гына үзара көрәш баруын ачыклап яза, алманнарны дәүләтчелек үсешенә хезмәт итүче халык буларак атый, славяннар һәм роман халыклары шуның өчен алар белән көрәшергә тиеш дип белдерә. Аның социализм теориясе үзәкләштерелгән дәүләт системасыннан баш тартуга, табигый кануннар нигезендә яшәүче община-мәхәлләләр белән тормыш итүне мактаудан гыйбарәт. Мондагы яшәешне ул коммунистик принципка корырга кирәклекне яза. Мондый иҗтимагый тормыш моделе «анархо-коллективчылык» дип атала. Җитештерү көчләре аларда уртак булырга тиеш, белем алу – бушка. Әмма пролетариат диктатурасын ул кире кага һәм аны авторитарлыкка кире кайту дип атый. Бу аның марксизмга тәнкыйть өлеше булып тора.

[40+] *Мещаннар* – поляк теленнән кергән сүз, «шәһәр кешесе» дигән мәгънәгә ия. 1917 елга кадәр Россиядә шәһәрнең түбән катлам вәкилләрен рәсми рәвештә «мещаннар» дип атап йөрткәннәр. Аларның җәмгыятьләр төзергә хаклары булган, аерым шәһәргә бәйле паспортлар алганнар. Мещаннарга үз мәхкәмәләре, җан башыннан салым түләү системасы

оештырылган. 1866 елда бу салым түләүдән азат ителгәннәр. Мещаннарга тән җәзасы бирү тыелган. Хәрби хезмәттән кайткан крестьяннар һәм дәүләт крестьяннары мещанлыкка чыга алган. 1863 елдан сәүдәгәрләрнең өченче гильдиясе бетерелгән һәм алар да «мещаннар» дип аталып йөртелә башлаган.

[41+] *Кәтер кләймәсе суга* – каторжан, XVI гасырда хөкүмәт даирәләренә хуш килмәгән кешеләрне Россиядә үз җирләреннән сөрү тәртибе кертелә, XVII йөздән башлап, Себергә сөрү башлана, 1648 елдан хөкем тәртибенә керә. Сөргенгә сөрелүчеләр мәҗбүри эшкә яисә крестьян эшенә билгеләнә, аерым очракларда ябылып тотыла. Дәүләт файдасына сөргендә хезмәт иттерү 1691 елдан кертелә. Авыр хезмәтләргә аларны тарту башлана. 1845 елдан үлем җәзасы каторга хезмәтенә алыштырыла. XIX гасыр ахырыннан каторжаннар тимер юл төзүгә, хәтта Сахалин утравына кадәр озатылалар. Анда юл төзү белән беррәттән, базларда руда чыгару эшенә дә хөкем ителәләр. Бу урында “кәтер кләймәсе суга” гыйбарәсе шәкертләрнең авыр тормышын күрсәтүдән киная буларак кулланылган.

[42+] *“Шәрхе мәвакыйф”лар алдыра. “Мәүләви хөсни”ләр китертә... “Сөлләм казый” белән “Шәмсия Габделхәким”нәрен моталәгә кыйлып чыга* – кадим мәдрәсәләрдәге дәреслек китаплары.

[43+] *Иң сул якта…* – Сәясәттә суллар дип күп тармаклы – социаль-демократларны, реформизмны, радикаль үзгәрешләрне яклаучы идеологияне атыйлар. Гомумән алганда суллар барлык кешеләр өчен дә, этник, милли һ.б. якларына карамастан, тигез хокуклар һәм шартлар булдыруны яклыйлар.

[44+] *Истанбулда Габделхәмиднең истибдады астында тәрбияләнеп кайткан* – Габделхәмид II (1842–1918), 1876–1909 елларда Төркия солтаны. Залимлыгы, һәртөрле яңалыкларга, үзгәрешләргә каршы, реакцион фикерле булуы белән танылa. 1878 елда Төркиянең Дәүләт Мәҗлесен (парламентын) тарата. Конституцияне юкка чыгара, илдә деспотизм урнаштыра.

[45+] *“Без”, “Яшен”, “Чүкеч”, “Сөңге”* – мәдрәсә шәкертләре тарафыннан чыгарылган дип фаразланган хыялый бесмалар.

[46+] *“Химая комитеты”* – «Җәмгыяте-хәйрия», үзара ярдәмләшү җәмгыяте. 1917 елга кадәр татарларда алга киткән иҗтимагый оешмаларның берсе. Алар китапханәләр ачканнар, мохтаҗларга ярдәм иткәннәр.

[47+] *Караңгы сартлар* – XV-XIX гасырларда Урта Азия халыкларын, милләтенә карамыйча, шул исем белән атаганнар. 1917 елдан соң казахлар һәм кыргызлар үзбәкләрне һәм кыр таҗикларын «сарт» дип йөрткәннәр. Аларның диндар булуларына бәйле «караңгы сартлар» дип яза автор.

[48+] *Эссе Дагстан чүлләрендә вәхши кара нугайлар* – Хәзерге Дагстан республубкасының Нугай районында яшәүче нугайлар хакында сүз бара. Төньяктан Калмык республикасы, көнбатыштан Ставрополь крае, көньяктан

Чечня җирләре белән чикләнә. Үзәге – Терекле-Мәктәп авылы. 1966 елга кадәр ул Каранугай районы исемен йөрткән. Автор тарафыннан «вәхши» аталуларының сәбәбе күчмә тормыш белән яшәүләренә бәйле.

[49+] *Кайдандыр беренче сада, икенче почмактан икенче сада тавышлары ишетелде* – “Беренче сада” – мәдрәсә реформасын таләп иткән шәкертләр тарафыннан чыгарылган җыр; шәкертләр «Марсельеза»сы. Беренче тапкыр Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә җилем басмада яшерен рәвештә чыккан «Әльислах» газетасында басыла, шуннан Россиядәге барлык татар мәдрәсәләренә тарала. 1907 елда ул Оренбургта «Шәкерт садалары» исемле китапта басыла. Ләкин Оренбург жандармериясе бу китапны басылу белән үк җыеп ала, хәтта Казанга җибәрелгән өлешен дә юлда конфискацияли. «Беренче сада» һәм «Икенче сада» полиция тарафыннан тыелган җырлар исемлегенә кертелсә дә, шәкертләр арасында кульязма хәлендә йөри.

[50+] *Поляк маршы көенә ... “Чыгабыз”ны җырлап күтәреп йибәрде* – Хәзерге Польша гимны. Ул элек «Добровский мазуркасы», «Добровский маршы» исемнәре белән дә йөртелгән. 1797 елда Юзев Выбицкий (1747-1822) тарафыннан язылган санала. Беренче исеме – «Италиядә поляк легионнары җыры», Польшаны азат итү теләге белән янган кешеләр аны революцион маршка әверелдерәләр. Ул 1848 елда Прага, Париж, Вена, Берлин кебек шәһәрләрдә революционерлар тарафыннан җырлана башлый. «Добровский маршы» мотивына словаклар, болгарлар, украиннар, руслар һәм татарлар үз җырларын тудыралар. Аларның эчтәлеге дә, күпмедер дәрәҗәдә, бер үк төрле була. Профессиональ җырчы Камил Мотыйгый (1883-1941) да әлеге җырны үз репертуарына ала.

[51+] *Карагруһлар* – Патша Россиясендә: монархистлар. Үтә реакционерлар төркеме. «Черносотенцы» дигән рус сүзеннән тәрҗемә. Алар үзләрен «чын руслар», «чын патриотлар» дип атаганнар, рустан гайре һәр милләтне басып тотуны, санга алмауны, юк итүне яклаганнар. Биредә реакцион карашлы, яңа фикерләргә каршы булган шәкертләргә карата әйтелгән.

[+52] *“Мулла Җәлал”*, *“Хикмәт әл-гайн”* – иске мәдрәсәләрдә дәрес дәрес китабы булып йөргәннәр.

*“Хикмәт әл-гайн”* – “Белем чишмәсе хикмәте”. Авторы: Нәҗметдин Гали бине Гомәр әл-Казвини әл-Кятиби (1276 елда үлгән). Шул ук авторның “Рисаләтүл гайни фи гыйлмил мантыйк” (“Мантыйк белеме чыганаклары”) исемле китабына өстәмә булып тора. Метафизика, физика турында трактат. Бу өстәмә бик популяр булган һәм аны бик күп шәрехләр язылган.

[53+] *Духовный собрание* – мөфтият, Россиядә мөфти тарафыннан идарә

ителүче рәсми мөселман оешмасы, 1789 елның 22 сентябрендә императрица Екатериана Икенче (1729-1796) указы нигезендә Уфада ачыла. Ул вакытта Уфа шәһәре Оренбург губернасына кергәнлектән, «Оренбург мөселман диния нәзарәте» исемен йөртә.

[54+] *Әхмәд Мидхәт* (1844-1913) – төрек язучысы, мәгърифәтче, журналист, тәрҗемәче, төрек әдәбиятында кыска хикәягә һәм романга нигез салучы. Тәнзимат дәверенең бөек әдипләреннән берсе санала. Аның чорында сәясәтче Әхмәт Мидхәт-паша Дунай провинциясендә губернатор була. Язучы Әхмәт Мидхәт анда газетада мөхәррир булып эшли, "Әхмәт Мидхәт-әфәнде" буларак яза. 1878 елдан «Тәрҗемани-хакыйкать» газетасында хезмәттәшлек итә. Романнар, хикәяләр, пьесалар һәм шулай ук тарих, дин, фәлсәфә, география мәсьәләләренә багышланган китаплар авторы. Татарлар арасында әсәрләре дан казана, гарәп хәрефле китапларын әле хәзер дә очратырга була. Карашларына бәйле Әхмәт Мидхәт, Тәнзимат дәвере әдипләре белән чагыштырганда, консервативлыгын да күрсәткән язучы буларак бәяләнә.

[55+] *...диңгез артыннан истибдад төяп кайткан "иштә" һәм "шәйдер әфәндем" иде* – бу урында: Төркиядә белем алып кайтып, монда да шул гадәтләр нигезендә эш алып баручы, сөйләгәндә еш кына төрек сүзләрен кушып сөйләүче персонаж Кәрим Гайфине сыйфатлый.

[56+] *Шәкертләрнең "Дуэль" исемле журналында* – "Дуэль" исемендә 1900 елда Санкт-Петербургта рәсемле көлке журналы чыга башлаган. Биредә шәкертләрнең бу журнал белән танышлыгы һәм үзләренең дә шул исемдә кульязма сатирик журнал чыгарулары ихтималына ишарә. Хыялвый басма.

[57+] *Тәрҗемәсе:* «Сез, җәнабе гали, монда кайтып, зур хата эшләгәнсез! Монда сезнең кебек деспотизм әһеленә җирлек юктыр. Сез, әфәнде хәзрәтләре, бөек Госманлы мәмләкәтенә барып, анда солтан Габделхәмид канаты астында үзегезнең камил белемле шәкертләрегез белән мөкатдәс деспотизмыгыз тәхетендә тыныч кына тәрбия эшләре алып барыгыз. Әфәндем, ихтирамымны кабул итүегезне үтенеп...»

[+58] *"Кызыл байрак" исемендә сул журнал* – хыялый басма. Чынлап та соңрак М. Вахитов тарафыннан оештырылган, Казан мөселман социалистик комитетының, аннары Үзәк мөселман социалистик комитетының 1917 елның 15 июненнән 1918 елның 10 маена кадәр Казанда, 26 июненә кадәр берничә саны Мәскәүдә бастырылган, М. Вахитов (1885-1918), Г. Нугайбәк (1881-1943) һәм Б. Мансуров (1889-1942) мөхәррирлегендә нәшер ителгән татар газетасы чыгуы билгеле.

[59+] "*Марсельеза"* – французларның революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. Текстын һәм музыкасын француз шагыйре һәм композиторы Руже де Лиль (1760–1836) язган. 1840 елгы вакыйгалардан соң, бөтен Европа

буйлап инкыйлаб дулкыны таралгач, ул бөтендөнья революционелары җырына әверелә. Россиядә, беркадәр үзгәртелеп, XIX гасырның 80-90 нчы елларында тарала башлый. "Марсельеза"ны татарчага 1906 елда С.Рәмиев тәрҗемә итә.

[60+] *Галиәсгар Камал* – Галиәскар Галиәкбәр улы Камалетдинов (1879-1933) татар класссик драматургы, татар совет язучысы, җәмәгать эшлеклесе. 1923 елда аңа «Хезмәт батыры» шәрәфле исеме бирелә, ТАССРның халык драматургы санала.

[61+] *"Шәрхе Габдулла"* – "Әл-Мугыйзза" исемле гарәп сарыфына (морфологиясенә) фарсы телендә шәрех (аңлатмалар) биргән грамматика дәреслеге. Идел буе җирлегенә аны Урта Азиядә укыган татар шәкертләре алып кайткан. Казанда күп мәртәбә басылган һәм кадим мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган китап.

[62+] *"Сөлләм"* – кадим мәдрәсәләрдә укытылган мантыйк дәреслеге. Тулы исеме – "Сөлләм әл-голум" ("Белемнәр баскычы"). Бу хезмәт төньяк-көнбатыш Һиндстанда, Урта Азиядә, шулай ук Идел буенда бик киң таралган булган. Авторы – Мәхбүлла бин Габдел-шәкүр әл-Бохари.

Мәгълүм ки, кадим мәдрәсәләрдә шәкертләрнең төрле баскычта белем алуы укый торган китап исеме белән бәйле була. Шуңа текстта "Сөлләм"гәчә дип бирелгән, ягъни бу дәреслеккә керешкәнчегә, "яңа баскычка күчкәнгә кадәр" мәгънәсендә.

[63+] *"Шантан кошы"* – сәхнәдә әдәпсез биюләр күрсәтелә торган төнге кафе-кафешантаннарга йөри торган кешеләргә карата әйтелә.

[64+] *Рәшид казыйның «Миръат»ларын* – Габдрәшид Гомәр улы Ибраһимов (1857–1944), җәдидче. Россия мөселманнарын азат итү көрәше байрагын күтәрә. Иҗтимагый һәм сәяси тәнкыйть китаплары яза. 1900–1903 һәм 1907–1909 елларда Петербургта журнал тибында "Миръат" ("Көзге") исемле китап-брошюдралар бастыра (16-сы – Петербургта, 6 сы – Казанда).

[65+] *Бубыйның "Хакыйкать"ләрен* – Габдулла Бубый (1871-1922) – дин галиме, педагог, дин гыйлеме буенча хезмәтләр авторы, "Иж-Бубый" мәдрәсәсенең җитәкчесе. Бу урында аның 1904-1906 елларда Казанда басылган «Хакыйкать, яхуд тугрылык» исемле җиде кисәктән гыйбарәт хезмәте күздә тотыла. Алга таба 8 нче кисәге басылгач, аңа арест салына. Автор 1910 елга кадәр аның 20 кисәген тәмамлый. Галимнең бу хезмәте татар һәм башка мөселман халыкларының артталыгы сәбәпләрен тикшерүгә һәм өйрәнүгә багышланган. Г. Бубый алга таба үсешне ислам динен төрле хаталардан азат итүдә, салафи нигезләргә кайтаруда күрә. 1911 елның 30 гыйнварында кулга алына. 1912 елның 28 маенда «Хакыйкать»нең 8-9 кисәкләре өчен, хөкүмәткә каршы эшчәнлек буларак бәяләнеп, Сарапул

мәхкәмәсе тарафыннан 6 айга төрмәгә ябылуга хөкем ителә.

66+ *Риза казыйның "Асар"ы* – татар язучысы, мәгърифәтче, галим, дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин (1859-1936) тарафыннан язылган энциклопедик характердагы «Асар» хезмәте күздә тотыла. 1900-1908 елларда аның 15 кисәктән гыйбарәт беренче ике томы басылып чыга. Калган 3-4 томнары кулъязма хәлендә саклаңган. Аның бу әсәре хәзерге татар язуына күчерелеп 2006–2009 елларда "Рузият" нәшрияте тарафыннан татар һәм рус телләрендә ике том итеп нәшер ителә.

67+ *Күлтәсинең «Һәйят җәдидә»ләрен* – Шәмсетдин Күлтәси (1856-1930) – күренекле татар галиме, мәгърифәтче, дин әһеле, фәлсәфәче. Җәдитчелек хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе. Биредә Күлтәсинең "Мофассал һәйяте җәдидә" – дөньяның яратылышы, материя, физика, химия кебек фәннәр, гомумән, Җир һәм галәм белән бәйле хезмәте турында сүз бара.

68+ *"Әбугалисина" хикәясендәге Хәлвәфрүш вакыйгасы* – татар галиме һәм язучысы Каюм Насыйриның (1825–1902), шәрык халык романы «Әбугалисина кыйссалары»н кыскартып һәм әдәби эшкәртеп язган «Әбугалисина» әсәренең геройларыннан берсе Мисыр егете Хәлвәфрүшнең (татлы ризыклар сатучы) патша кызына өйләнүе маҗалары хакында сүз бара.

69+ *"Гакаид"тән "Хөдүсе галәм" дәресе* – Ислам дине кануннары, исламның терәкләре турындагы гарәбчә дәреслек. Авторы – Нәҗметдин Нәсафи (1068–1142). Анда дөнья һәм галәмнәр Аллаһы Тәгаләнең «күн-фәйәкүн», ягъни «"бул" дисә була» әмере белән юктан бар кылынуы хакында да төшендерелә.

70+ *"Казый Мөбарәк"* – XVIII йөз ахыры-XIX йөз башлары Кавказ азатлык хәрәкәтендә мөридләр арасында дан торткан, кумыклар тарафыннан нәкышбәндиягә бәйле язылган мәдрәсә китапларыннан берсе. Казанда еш басылган. Авторы – Газый Мөхәммәт, кумык имамы Газый-Мөхәммәт бине Мөхәммәт бине Исмәгыйль әл-Гыймрави ад-Дагыстаный (1795-1832). Руслар тарафыннан Гыймра авылын алганда шәһит китә. Аның кул астында данлыклы Шамил (1797-1871) азатлык көрәшчесе булып җитлегә.

71+ *Фатих Кәрими* – татар язучысы, мәгърифәтче, журналист, җәмәгать эшлеклесе Фатих Гыйльман улы Кәрими (1870-1937), Самара губернасы, Бөгелмә өязе, Миннебай авылында туа. Чистайда «Камалия мәдрәсәсе»н, аннан Истанбул университетын тәмамлый. Ялтага килә һәм 1896-1898 елларда Дерекөй авылында укыта. 1899 елда, Рәмиевләр чакыруы буенча, Европага сәяхәткә китә, «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабын яза. Оренбургка күченә, 1902 елдан «Кәримов, Хөсәенов һәм компаньеннары» типографиясен җитәкли. 1906-1917 елларда «Вакыт» газетасының баш мөхәррире була. 1924

елга кадәр укытучылык вазифасын башкара. 1925 елда Мәскәүгә чакырыла һәм университетка төрек теле укытучысы итеп билгеләнә. Йөздән артык фәнни, әдәби, педагогик хезмәтләр яза.

72+ *Достоевскийның* – бөек рус язучысы Федор Михайлович Достоевский (1821-1881). Россиядә революцион-демократик рухның үсешендә аның әдәби әсәрләре, фәлсәфи-публицистик язмалары зур роль уйнаган.

73+ Кешеләргә үзләре күтәрә алмаслык авырлыкны йөкләмәүче (бирмәүче) Аллаһыга, шулай ук үзенең гадәте, шәригатькә мөнәсәбәте белән һәр акыллы кешене гаҗәпләндерүче Мөхәммәт (с.г.в) мактаулар соңында. Дөреслектә, калеб – үзенә буйсындыручы һәм карар чыгаручы хөкемдардыр. Башка әгъзалар аңа хезмәт итә. Әгәр син моны кабул итсәң, без әйтербез...

74+ *Касыйм Әмин бәк хәзрәтләре үзенең "Тәхрир әл-миръат" нам әсәр галиясендә* – К,асыйм Әмин бәк хәзрәтләре үзенең «Көзге яктысы» исемле бөек әсәрендә... Касыйм Әмин (1865-1908) – юрист, фәлсәфәче, иҗтимагый-сәяси эшлекле, Мисыр милли хәрәкәтен һәм Каһирә университетын оештыручылардан берсе, гарәп язучысы һәм мөселман хатыннары азатлыгы көрәшчесе. Көрди. Әтисе – госманлы губернаторы, әнисе – Каһирә аксөяге. К.Әмин әсәрләре татарлар арасында популяр булган. Аның мөселманнар тормышын мөмкин кадәр европалаштыруга омтылышы җәдитчеләр тарафыннан хуплап кабул ителгән. Ул Коръәнне яхшы белүе, фикерләрен аятьләргә таянып белдерүе һәм раславы белән көчле. «Тәхрир әл-миръат» әсәре Казанда татарчага тәрҗемәдә басылган.

75+ *Төрек фәйләсуфы Әхмәд Мидхәт әфәнде хәзрәтләре үзенең "Чуҗык", "Ана" һәм "Пәдәр улмак сәнгате" исемнәрендәге нәзыйрсез әсәрләрендә* – монда күренекле төрек язучысы Әхмәт Мидхәтнең дини һәм тәрбияви-педагогик темаларга язылган "Бала", "Ана", "Ата булу сәнгате" хезмәтләре телгә алына. Тулырак 54 нче аңлатманы карагыз.

76+ *Беренче милли шагыйрь мәшһүремез Мәҗит әфәнде Гафури хәзрәтләренең "Себер тимер юлы"атлы шигыре* – шагыйрь Габделмәҗит Нургани улы Гафуров (1880-1934). 1898-1904 елларда Троицкида «Рәсүлия» мәдрәсәсендә Зәйнулла ишанда (1833-1917) белем ала. 1904 елда Оренбургта «Себер тимер юлы, яки әхвале милләт»« поэмасы басыла. Шагыйрьнең бу әсәре фән-техник казанышларга шигъри дан булып яңгырый һәм алдынгы карашлы татар укучысы тарафыннан зурлап кабул ителә. Тәнкыйтьтә алдынгы әдәби фикер үрнәге буларак бәяләнеп йөртелә. Шул ук елда (1904) М.Гафури Казанга килә һәм «Мөхәммәдия»мәдрәсәсендә укый башлый. 1906 елда исә Уфага китә һәм 1908 елга кадәр «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. 1917 елда «Кызыл байрак» шигырен яза. Революцияне кабул итә, халык

тормышына бәйле күпсанлы әсәрләре бар. 1923 елда аңа «Башкортстанның халык шагыйре» исеме бирелә. 1934 елда вафат була.

[77+] *Гоҗ бин Ганк әкиятләре белән тулган Рабгузый тарихлары* – 1310 елда Насретдин бине Борһанетдин Рабгузыйның Алтын Урдада язылган «Кыйссасел-әнбия» (“Пәйгамбәрләр тарихы”) әсәре күздә тотыла.

*Гуҗ бине Ганк* – дөнья беткән вакытта чыгып җир өстендәге бөтен нәрсәне ашап бетерә торган мифик зат. Күп ашаучы кешегә дә Гуҗ булдымы әллә диләр.

[78+] *“Таһир-Зөһрә”, “Бүз егет” кебек нәрсәләрне* – Әхмәт Уразаев-Кормаши (1855-1883) тарафыннан язылган романтик сюжетлы, көйле «Кыйссаи Бүз егет» (Казан, 1874) һәм «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (Казан, 1876) дастаннары күздә тотыла. Бу ике китап күп тапкырлар басыла, татар халкы арасында киң таралыш ала.

[79+] *“Икъраэ” кәлимәи таитәседер* – Коръәндә “Галәк” сүрәсенең беренче аяте. “Икъраэ бисми раббикәл-ләзин халәк” (“Сине барлыкка китергән Раббының исеменә укы”).

[80+] “Зүмәрә” сүрәсе, 9 аятьтән. *Тәрҗемәсе*: “Белгән белән белмәгән тиң булырлармы?”

[81+] *Мәэмун, Һарун Рәшид заманнарын* – Габбасилар династиясеннән булган Һарун Рәшид (763-809), аның улы Мәэмун (786-833) хәлифләр хакимлеге чоры турында сүз бара (8-9 гасырлар).

[82+] *Әндәлес мәдәнияте* – Андалусия – VIII-XV гасырларда Испаниядәге мөселман дәүләте. 711-1492 елларда Пиреней ярымутравы, төньяк өлешеннән кала, “Әл-әндәлүс” дип йөртелгән (латин телендәге Вандалития аталышыннан Андалусиягә әверелгән). Биредә яшәүче халык (христианнар, яһүдиләр һ.б.) үз теләге белән ислам динен кабул итә. Аларда, һәртөрле ирекләр булу сәбәпле, мәдәният искиткеч югары үсеш ала. Андалусиянең данын күтәргән мәдәният гарәп-испан цивилизациясенең бер өлеше буларак формалаша. Халкы бөтендөнья ислам казанышлары, шул исәптән Әбугалисина, Әл-Фараби, Әл-Бируни хезмәтләре белән таныш була. Мәдәниятнең тиз арада үсешенә җирле халыкның бер-берсенә карата хөрмәте, теләктәшлеге көчле йогынты ясый.

[83+] *“Әл-Хәмра”, “Әл-Бәйда” сарайлары...* – Испаниядәге мөселман дәүләт архитектура истәлекләре.

*әл-Хәмра* – (Кызыл замок), борынгы мөселман ядкәре Кордовадагы боронгы мәчет-сарай. Әндәлестәге мөселман дәүләтендә Насридилар династиясе идарә иткән чорда (1230–1492) төзелгән гаҗәиб мәһабәт бина. Башта мәчет буларак төзелсә дә аннары гаҗәиб зур сарай буларак формалаша. Гарәп теленнән “Дар әл-әмра” (“Хуҗа йорты”) дигәнне аңлата.

Гранада шәһәренең көнчыгыш өлешендә калкулыкта урнашкан бу бина хәзерге вакытта архитектура – парк ансамблен тәшкил итә. Ул электән үк шәһәрдән автоном рәвештә яшәгән. Анда идарә бинасы, мәктәпләр, һөнәрчеләр мастерскойлары һ.б. урнашкан була. Шул вакытта ук аны “Җәннәт бакчасы” дип атап йөрткәннәр. Мавритан архитектурасы стилендә төзелгән бу биналарны исә, Әндәлестән гарәпләр киткәч, испанлылар чиркәүләр һәм соборлар итеп үзгәрткәннәр. Мавритан архитектурасының гүзәл истәлеге саналган мәһабәт әл-Хәмра мәчете бүген дә Испаниянең мөһим тарихи ядкәре санала.

*әл-Байда* – (Ак замок), Испаниядәге ислам дәүләтеннән сакланып калган архитектура истәлеге – VIII гасырда төзелгән бу гаҗәеп зур һәм матур бина – мәчет-сарай. Башта ул 784–786 елларда Әндәлеснең беренче хөкемдары Габдер-рәхман ибн әл-Хәка тарафыннан мәчет буларак төзелә. Аннары ул мәһабәт сарай рәвешен ала. Шунда ук крепость-ныгытма да төзелә.

Гомумән, Әндәлестә дәүләт торткан чорда гарәпләр Кордовада 1000 нән артык мәчет, 60000 гә якын мәһабәт сарайлар төзиләр.

[84+] *Һинднең мәшһүр галимнәреннән Мәүланә Габделхәйне* – татарлар арасында аеруча мәшһүр булган «Дәкаикуль-әхбар» (Казан, 1901) (“Тәфсиле хәбәрләр”) китабы авторы күздә тотыла булса кирәк.

[85+] *“Бәни әсфәр” дигән кавем* – “Бәни әсфәр” “сары кавем” дигәнне аңлата. Элек гарәпләр Рум (Византия) халкын шулай атаган. Дини мифологиядә ахырзаман алдыннан дөньяны басып алачак кавем, сары раса дип тә атыйлар

[86+] *...“ливауль-хәмде”не күтәрәчәк* – “ливауль-хәмд” – дини риваятьләр буенча, мәхшәр мәйданында Мөхәммәт (с.г.с.) күтәрәчәк байрак, шуның астына Адәмнән (г.с.) алып, барча пәйгамбәрләр җыелачак.

[87+] *Дәҗҗал, Мәһди, Гайсә* – Дини өйрәтмәләр буенча, ахырзаманның олы галәмәтләре.

*Дәҗҗал* –халыкларны аздыручы бозыклык иясе, бик көчле сихергә ия булып, күп халыкны фетнәгә дучар итәчәк зат.

*Мәһди* – кыямәт алдыннан динне торгызучы, кяферләргә каршы изге сугышны җитәкләүче Мөхәммәт (с.г.с.) нәселеннән булган зат.

*Гайсә* – кыямәт алдыннан дөньяга икенче тапкыр киләчәк пәйгамбәр. Дәҗҗалны үтереп, җир йөзендә гаделлек урнаштырачак.

[88+] *Яәҗүҗ-мәәҗүҗләр* – ахырзаман галәмәтләреннән булган ике кавем. Кыямәт алдыннан дөнья буйлап таралып, бозыклык кылучылар. Аллаһы Тәгалә аларга “ән-Нәгыф” дигән зәхмәт җибәреп һәлак итәчәк.

[89+] *“Даббәтул-әрдз” чыгып, бер кулында Сөләйман йөзеге, икенчесендә*

*Муса таягы булдыгы хәлдә* – “Даббәтүл-әрдз” – ахырзаманның олы галәмәтләреннән булган җирдән чыгачак бер хайван. Аллаһы Тәгаләнең хикмәте белән ул кешеләрнең мөэмин яки кяфер икәнлекләрен белдерер. Үзендә булган Сөләйман йөзеге (Сөйләйман пәйгамбәрнең җеннәрне буйсындыруда кулланган йөзеге) белән ул кяферләргә мөһер салып, йөзләрен кара итәр. Муса таягы (Муса пәйгамбәрнең могҗизалар күрсәтү коралы булган таягы) белән мөэминнәргә кагылгач, йөзләре нурланыр.

[90+] *Мөнкир-Нәкир* – җирләгәннән соң мәеттән сорау алырга килә торган ике фәрештә.

[91+] *Әфгани, Габдеһ, Тәнтави, Фәрид Вәҗди…* – дини темаларга язган, төрле чорларда яшәгән Ислам галимнәре һәм әдипләре.

*Әфгани* – Мөхәммәт ибне Сәфдар (1839-1897), Җәмалетдин Әфгани буларак билгеле. Мөселман реформаторы, идеологы. Кабул һәм Һиндстанда белем ала, аннары әфган әмирләрендә хезмәттә тора. 1869 елда Әфганстаннан китә. 1871 елда Каһирәгә килә. Деспотизмга каршы мәкаләләр яза, демократияне яклый. Бер ара Европада яши. Аннары Иракта, Россиядә була. Ислам динен ул Көнбатышка каршы көрәш коралы итү ягында тора, аны социализм һәм милләтчелек белән бәйли, йолалардан бигрәк, иманны өстен куя. Шушы карашлары аркасында 1870 елда Төркиядән куыла. Әмма 1879 елда кире кайта һәм кулга алына. Төркиядә вафат була. 1944 елда аның җеназасы Кабулга күчерелә. Җәмалетдин Әфгани Көнчыгыш мөселман дәүләтләрендә һәм Россия империясенең мөселман халыклары арасында милли-азатлык хәрәкәте барлыкка килү һәм үсешендә сизелерлек эз калдыра.

*Габдеһ* – Мөхәммәт Габдеһ (1849–1905), Мисырда мөселман яңарышының күренекле галиме, нашир, сәет Җамалетдин Әфганинең шәкерте һәм көрәштәше. Хәзерге заман Коръән тәфсиренең күренекле төзүчеләреннән берсе. Шәригатькә реформа ясауга зур тырышлык куя. 1899-1905 елларда, ягъни вафатына кадәр, Мисырның баш мөфтие була.

*Тәнтави* – Мисыр һәм Россия филологы, гарәп теле һәм әдәбияты белгече шәех Мөхәммәт Гайяд Тәнтави (1810-1861), Мисырның Тәнта шәһәреннән. 1823 елда Каһирәдә «Әл-Әзһар»да укый башлый. Соңыннан үзе дә монда укыта. Шул ук вакытта инглиз мәктәбендә дәресләр бирә, француз телен өйрәнә. Аңардан Европаның танылган күп кенә галимнәре белем ала. Рәсми чакыру белән 1840 елда Петербургка килә, рус телен үзләштерә, университетта эстраординар профессор дәрәҗәсенә ирешеп, 1846 елдан гарәп теле кафедрасына мөдир була. 1855 елдан ул – ординар профессор. 1861 елда вафат. Санкт-Петербургта Татар зиратына җирләнә. 35 исемдәге фәнни хезмәте мәгълүм.

*Фәрид Вәҗди* – Мөхәммәт Фәрит Вәжди-әфәнде әл-Мысри, дини-

фәлсәфи хезмәтләр, тел гыйлеменә бәйле китаплар язган XIX йөз–XX гасыр башы галиме, язучы. Танзимат дәвере вәкиле.

92+ *Әхмәд Мидхәт* – 54 нче искәрмәне карагыз.

93+ *Бруно, Галилео, Ньютон, Коперник кебекләрнең исемен, мәшһүр инквизиция җәмгыятьләрен* – Рим католик чиркәвенең дини тәгълиматларга каршы фикер әйткән кешеләрне һәм галимнәрне эзләү, табу, җавапка тарту белән шөгыльләнгән оешмаларның уртак аталышы «инквизиция» булган. *Бруно* – Джонардо Бруно (1548-1600) итальян монах-доменикан, фәлсәфәче, шагыйрь. Яңарыш дәверенең (XVI-XVII гасырлар) бөек шәхесе. Ул дини-христиан күзаллауларны тәнкыйть итә. 1576 елдан Европа илләре буйлап сәяхәт итә. 1592 елда инквизиция хөкеменә тартыла. Җиде елга зинданга ябыла, аннары утта яндырыла. Аның төп фәлсәфәсе – галәмнең чиксезлеге һәм дөньяларның күплеген раслау. Ул моның шулай булуын галәмдә һәм дөньяларда Ходайның булуы белән аңлата.

*Галилео* – Галилео Галилей (1564-1642), итальян физигы, механик, астроном, философ, математик. Галәмне тикшергәндә беренче булып телескоп файдалана. Эксперименталь физиканы тудыра. Галәмнең гелиоцентрик системада булуын раслаучы фәнни карашлар яклы. Дини карашлар белән каршылыкка килүче галим.

*Ньютон* – Исаак Ньютон (1643-1727), инглиз физигы, механик, математик, астроном, классик физиканы барлыкка китерүчеләрнең берсе. «Натураль философиянең математик башлангычлары» хезмәтендә (1687) җирнең тарту көчен, механиканың төп өч законын ача, дифференциаль һәм интеграль исәпләүләр уздыра, нур чагылышы теориясен, физик оптика һәм физика, математиканың башка кануннарын аңлата.

*Коперник* – Николай Коперник (1473-1543), поляк галиме, астроном, математик, механик, икътисадчы, Яңарыш дәвере католик дин эшлеклесе, беренче фәнни революцияне башлап җибәрүче. Яңа астрономия теорияләре тудыра. Китаплар төзеп, аларны дуслары арасында тарата. 58 яшендә астрономия белән шөгыльләнүеннән читләшеп, табибчылык белән мавыга. Коперникның төп хезмәте «Күк йөзе сфераларының йөреше» (1543) дип атала. Биредә ул дөньялыкның гелиоцентрик моделен күрсәтә һәм планеталарның Кояш тирәли әйләнүләрен математик исәпләүләр нигезендә дәлилләп бирә. Аның бу хезмәте фәндә революция ясый.

94+ *Сакытдин исеме илә мәшһүр булган берәвенең* – Казан шагыйре һәм дин эшлеклесе, суфи Мөхәммәт-Садыйк Иманколый (1870-1932) хакында сүз бара.

95+ *...шул бөек мәдәниятнең якты йолдызы булган ибне Рөшд* – Әбү Вәлид Мөхәммәд ибне Әхмәд ибне Рөшд (1126-1198), Әндәлүсиянең бөек

философы, географ, физик, математик, астроном, психолог, сәясәтче, аверроизмга нигез салучы. Испаниянең Кордова шәһәрендә туа. Шәрыкта Аристотель тарафдарларының күренекле вәкиле. Татар фәлсәфәсендә һәм дин гыйлемендә XX йөз башына кадәр ибн Рөшднең фәлсәфи тәгълиматы киң таралган була.

[96+] *Ибне Сина, Фараби, Ягъкуб Кинди, Рази* – Аристотель тәгълиматына нигезләнгән IX-XII йөзләрдәге урта гасыр мөселман фәлсәфи юнәлешенең төп вәкилләре.

*Ибне Сина* – Әбү Гали Хөсәен ибне Габдуллаһ ибне Сина (980-1037), Урта Азиянең бөек энциклопедист галиме. Көнчыгышның, гомумән, ислам дөньясының мәшһүр философы, табиб. Бөтен дөньяда шөһрәт казанган хезмәтләре фәннең төрле өлкәсенә карый: фәлсәфә һәм математика, асторония һәм физика, химия һәм биология, медицина һәм фармакология, филология һәм лингвистика. Шулай ук ул музыкант һәм шагыйрь дә була.

*Фараби* – Әбү Насыр Мөхәммәд ибне Тархан Узлаг әл-Фараби әт-Төрки (якынча 870-950), мәшһүр философ, энциклопедист галим. Аның хезмәтләре ибне Сина, ибне Рөшд кебек күренекле галимнәргә, шулай ук урта гасыр Көнбатыш Европа фәлсәфәсе һәм фәненә йогынты ясый.

*Ягъкуб Кинди* – Әбү Йосыф Ягъкуб ибне Исхак әл-Кинди (якынча 801-873), гарәп философы, математик, астроном. Метафизика, математика, этика, астрономия, медицина, метеорология, музыкадан күпсанлы трактатлар авторы. Ислам дөньясында беренчеләрдән булып, Аристотель хезмәтләренә мөрәҗәгать итә.

*Рази* – Әбу Бәкер Мөхәммәд ибне Зәкәрия әр-Рази (якынча 865-925), фарсы энциклопедист галиме, табиб, алхимик, философ. Аның күп кенә хезмәтләре латин теленә тәрҗемә ителеп, Көнбатыш Европа табиблары һәм алхимиклары арасында дан казана, хөрмәтләнә.

[97+] *Юнан мәдәниятенең алтын дәверендә* – безнең эрага кадәр V-VI гасырларга туры килә. Грек мәдәнияте хакында сүз бара.

[98+] *Багдад* – Габбасилар хәлифәлегенең башкаласы, 762 елда хәлифә Әбу Җәгъфар әл-Мансур тарафыннан нигезләнә, IX-X гасырларда дөньядагы иң зур мәдәни һәм икътисадый үзәкләрнең берсе булып тора. Хәзерге вакытта Гыйрак дәүләтенең башкаласы.

[99+] *Граната* – Гранада, Пиреней ярымутравының көньягындагы тарихи өлкә, Гранада әмирлеге (1228-1492) – Көнбатыш Европадагы соңгы мөселман дәүләте.

[100+] *Кортүбә* – Кордова – Испаниядәге шәһәр, 929-1031 елларда Өмәвиләр хәлифәлегенең башкаласы. 1236 елда христианнар тарафыннан яулап алынганчы, дөньядагы иң зур мәдәни һәм икътисадый үзәкләрнең

берсе була.

[101+] *...миңа "мөселманнар" йиренә "татарлар", Багдад, Кортүбә, Граната, Әндәлес, Һарун әр-Рәшид урынына Алтай, Алтын Урда һәм Чыңгызлар күренә башлады* – сүз миллиләшү хакында бара, мөселман дөньясы өчен изге тарихларны, шәхесләрне, урыннарны белгән кешенең үз милли тарихы, шәхесләре белән кызыксына башлавы турында сүз бара.

[102+] *"Тәрҗеман" бабага...* – Бакчасарай шәһәрендә "Тәрҗеман" исемле газета чыгаручы Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914) турында сүз бара.

[103+] *...яңа рәвиз, иске рәвиз...* – "яңа ревизия", "иске ревизия". Ревизия – XVIII-XIX гасырларда Россиядә җан башыннан налог түләргә һәм рекрут хезмәтен үтәргә тиешле кешеләрне ачыклар өчен халык санын исәпкә алу. 1881, 1887 елларда – җир-суга, ә 1893 елдан башлап чәчү җирләренә ревизия ясала, ягъни аларның күләме исәпкә алына. Бу очракта әдип шуларны күз алдында тота.

[104+] *"Налей, товарищ!"* – Бөек Октябрь түнтәрелешенә чаклы яшьләр арасында киң таралган табын җырының беренче сүзләре.

[105+] *Бәйруттагы "Америка көллиясе"* – XX йөз башында татарларның Франция, Швейцария, Германия, Америка, Япония, Төркия, Мисыр илләрендә урнашкан урта һәм югары уку йортларында укулары шактый киң таралган күренеш була. Шулар арасында Ливанның Бейрут шәһәрендәге "Америка көллияте" дә бар.

[106+] *Ротшильдлар* – 30 нчы искәрмәне карагыз.

[107+] *"Әлебби"* – "Әлеппи", "Әлифба иман шартлары белән" дигән дәреслекнең халык телендәге кыскача исеме. Ул татарларда, озак еллар кулъязма килеш таралып, мәктәп-мәдрәсәләрдә башлангыч уку әсбабы булып йөргән. Беренче мәртәбә 1802 елда Казанда 11 мең нөсхә белән чыга.

[108+] *"Иман шарты"* – ("Шариат әл-иман") – мәдрәсәләрдә укырга, язарга өйрәнә башлаган балаларга бирелә торган беренче дәреслек – китап. Аның эчтәлеге моннан гыйбарәт: башта гарәп әлифбасы бирелә, аннары хәрефләрнең исемнәре, иҗекләрне уку күнегүләре, саннарны белдерү өчен кулланыла торган хәрефләр, гарәп телендә Аллага ышануны белдерә торган догалар китерелә. Казанда 1874 елдан басыла башлый.

[109+] *Мәптектә ятып укучы* – мәчет каршындагы кечкенә мәктәптә даими торып укучы шәкертләр.

[110+] *"Гакаид"кә төшкәннән бирле* – "Гакаид" дәресен укый башлагач. "Гакаид" – ислам дине кануннары, исламның терәкләре турындагы гарәпчә дәреслек. Авторы – Нәҗметдин Нәсәфи (1068 – 1142).

[111+] *Эшлиссабор крепостендә* – Шлиссельбург крепосте, хәзерге Ленинград өлкәсенә керә торган Шлиссельбург шәһәренә каршы Балтыйк

диңгезенә урнашкан Орехов утравындагы борынгы рус ныгытмасы. Аңа 1323 елда Александр Невскийның оныгы князь Юрий Данилович тарафыннан нигез салына. Ул Орехов крепосте дип атала. XVIII йөз башында Орехов ныгытмасы Шлиссельбург (ачкыч-шәһәр) крепосте дип үзгәртелә һәм сәяси тоткыннарны яба торган каты режимлы төрмә буларак хезмәт итә башлый. Анда күпсанлы танылган шәхесләр сәяси тоткынлыкта була. 1949 елдан соң Шлиссельбург крепосте архитектура һәйкәле буларак игълан ителә. 1985 елдан инде хәрабә хәленә җиткән бу крепость мемориаль музей статусын ала.

[112+] *Некрасовның "Несжатая полоса"сы* – күренекле рус шагыйре һәм язучысы Н.А Некрасовның (1821-1877) 1854 елда язылган шигыре.

[113+] *Брюсовның "Ташчы"сы* – танылган рус шагыйре һәм язучысы, тәрҗемәче, әдәбятчы, тәнкыйтьче В.Я.Брюсовның (1873-1924) 1901 елда язылган шигыре. Ул җәмгыятьтә хөкем сөргән тигезсезлек, гади халыкның чарасызлыгы турында.

[114+] *Мөхәммәд галәйһиссәламгә килмеш Җәбраил фәрештә* – Аллаһка иң якын торган дүрт фәрештәнең берсе. Аңа Аллаһтан пәйгамбәрләргә вәхи (хәбәр) китерү йөкләнгән. Аллаһы Тәгалә кушуы буенча Җәбраил Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.с) изге Коръән аятьләрен җиткерү өчен күктән иңә. Коръән сүрәләрен өлешләп-өлешләп пәйгамбәрнең күңеленә сеңдерә. Мөхәммәд (с.г.с.) соңыннан аны үзенең өммәтенә җиткерә.

[115+] *"Нише" фәлсәфәсе* – Фридрих Ницше (1844-1900) күренекле немец философы. Үзенең фәлсәфи тәгълиматында әхлакый, дини, мәдәни, иҗтимагый-сәяси нигезләрне шик астына куя. Шуңа күрә әсәрләре берьяклы гына каралмый, күп бәхәс тудыра.

[116+] *Эздиклар* (эсдек, социал-демократлар партиясе) – Россия империясендә 1898 елда барлыкка килгән, Маркс тәгълиматына ияргән беренче социалистик партия.

[117+] *Эсерлар* (социал-революционерлар партиясе) – Россиядә народниклар төркемнәре һәм түгәрәкләре бергә оешудан туган (1902) сәяси партия. Алар капиталистларның хосусый милкенә кагылмыйча, җирне крестьяннарга бүлеп бирүне тәкъдим итә. Г.Ибраһимов, хаклы рәвештә, аны элекке народникларның яңа формациясе, ягъни буржуазиянең сул фракциясе дип атый.

[118+] *Николай истибдадының ... дошманы* – Романов Николай Александрович (1868 – 1918), 1894–1917 елларда Россия дәүләте императоры (Николай II). Биредә сүз аның идарәсенә, монархиягә каршылык турында бара.

[119+] *Софья Перовская* – Софья Львовна Перовская (1853-1881), "Народная воля" оешмасы җитәкчеләренең берсе, патша Александр II

үтерүдә турыдан-туры катнаша.

120+ *Меньшевиклар* – РСДРПның 2 нче съездында азчылыкны тәшкил иткән сәяси фракция тарафдарлары. Сайлап куелган үзәк җитәкчелегенә берсүзсез буйсыну тәртибенә (централизмга) каршы торучылар. 1917 елдан мөстәкыйль партия. 1923 елда меньшивиклар партиясе эшчәнлеге тыела.

121+ *Максималист* – 1904 елда эсерлар партиясе эчендә барлыкка килгән вак буржуаз группа члены.

122+ *Проданистлар* – прудонистлар, Француз сәясәтчесе, публицист Пьер Жозеф Прудон (1809–1865) җитәкчелегендә прудонизм дип аталган I Интернационалдагы француз секциясе әгъзалары. Прудозизм – буржуаз социализмның бер төре (юнәлеше). Бу тәкълимат җәмгыятьтә һәркем хосусый милек иясе һәм җитештерүче дә булырга тиеш дип өйрәтә. Прудон П.Ж. – вак буржуаз утопист, анархист хәрәкәтенә нигез салучы.

123+ *Беренче интернационал* – пролетариатның беренче халыкара революцион оешмасы. Аны 1864 елда Лондонда К.Маркс оештыра һәм аңа җитәкчелек итә.

124+ *Париж коммунасы* – Франциядә булып үткән беренче пролетар революция һәм эшчеләр сыйныфының беренче хөкүмәте Бу хакимият Парижда 72 көн генә яши (1871 елның 18 мартыннан 23 маена кадәр).

125+ *Казанның да "Учительский школасы"* – Казан татар Укытучылар мәктәбе 1876 елда татар уку йортлары өчен укытучылар хәзерләү максатыннан ачыла. Ул татарлар өчен рус телендә белем бирүче беренче дөньяви уку йортларыннан санала. Укытучылар арасында В.Радлов ( 1876-1884 елларда мәктәп җитәкчесе), телче В.Богородицкий, татар мәгърифәтчеләре К.Насыйри һәм И.Терегулов кебек үз чорының алдынгы карашлы, танылган галимнәре була. 1905-1907 елларда бу мәктәптә дә демократик рух хөкем сөрә. Аны тәмамлаган укытучыларның күбесе патша хакимияте өчен сәяси яктан ышанычсыз дип табыла. Казан татар Укытучылар мәктәбе татар һәм башкорт халкының демократик яшьләре сафына күренекле шәхесләрне бирде. Алар арасында М.Солтангалиев, Г.Исхакый, С.Максуди, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов, М.Корбангалиев һ.б. бар.

Казан татар Укытучылар мәктәбе 1917 елның 1 июленә кадәр эшләп, аннан совет урта мәктәбенә әверелә.

126+ *Герцен, Чернышевский, Михайловскийлар* – Россиядә 1860-1910 еллардагы народниклык революцион хәрәкәтен нигезләүчеләр.

*Герцен А.И.* (1812-1870), рус язучысы, публицист, философ, XIX гасырда Россия империясе идеологиясен һәм сәясәтен кискен тәнкыйтьләүче, революцион буржуаз-демократик үзгәрешләр тарафдары. 1857 елда Лондонда Н.П.Огарев белән берлектә "Колокол" дигән беренче рус

революцион газетасын оештыра. Газетаның нашире дә, төп язучысы да Герцен була. “Колокол” бөтен Европада һәм легаль булмаган юллар белән Россиядә дә тарала.

Герцен – Гегель, Белинский карашларын яклаучы революцион-демократ.

*Чернышевский Г.Н.* (1828-1889), философ, энциклопедист, әдәби тәнкыйтьче, публицист һәм язучы, XIX йөзнең 60-70 елларында Россиядәге революцион-демократик хәрәкәтнең җитәкчесе. Әдәби, тәнкыйди эшчәнлегеннән тыш, сәясәт, икътисад өлкәсенә караган хезмәтләр дә яза.

*Михайловский Н.К.* (1842-1904), социолог, публицист, әдәбият белгече, либераль народниклар идеологы. 1879 елда “Халык азатлыгы” оешмасы белән элемтәдә тора.

[127+] *Революция тарихында мәңгелек урын алган мәшһүр “Халык азатлыгы” партияләре* – русча “Народная воля” дип йөртелгән 1879 елда барлыкка килгән революцион халыкчылык оешмасы. Төп максаты - хакимиятне демократик реформалар ясауга мәҗбүр итү. Әлеге сәяси көрәштә, террор алымын кулланып, император Александр II юк итәргә уйлаганнар.

[128+] *Перовская* – 122 нче искрмәне карагыз.

[129+] *Желябовлар* – Андрей Иванович Желябов (1851-1881), революционер-народник, “Халык азатлыгы” партиясенең башкарма комитеты әгъзасы, шулай ук патша Александр II үтерүдә турыдан-туры катнаша. “Желябовлар” дигәндә автор әлеге оешма вәкилләрен күздә тота. Алар арасында С. . Перовская, В. Н.Фигнер, Н. А. Морозов, Л.А. Тихомиров, С.Н. Халтурин, Н.С. Тютчев, Н.В. Клеточников, Я.Л. Юделевский һ.б. бар.

[130+] *Романовлар* – 1613 елдан башлап хакимлек иткәнрус патшалары династиясе. Беренөе патша – Михаил Федорович (1596–1645), соңгысы – Николай II (1868–1918)

[131+] *Мәкәрҗәдә булган съездларында* – “Иттифак әл-Мөслимин” оешмасының Мәкәрҗәдә 1905, 1906 елларда үткәрелгән беренче һәм өченче корылтайлары турында сүз бара. Анда прорамма эшләү өчен төп нигезләр билгеләнә, комиссияләр булдырыла. Өченчесендә исә “Иттифак”ның Үзәк идарәсе сайлана.

[132+] *“Таң”* – әсәрдә искә алынган “Таң” исемле матбугат органы юк. 1906 елда Г.Исхакый мөхәррирлегендә нәшер ителгән, социал-революционерлар карашын чагылдырган “Таң йолдызы” газетасы булуы мөмкин.

[133+] *“Урал”* – татар телендә чыккан беренче большевистик газета. Беренче саны 1907 елның 4 гыйнварында басыла. Барлыгы 31 сан чыккач,

1907 елның 27 апрелендә патша хөкүмәте тарафыннан туктатыла. Редакторы – Хөсәен Ямашев.

[134+] *Церетели* – И.Г. Церетели (1881-1959), Россия һәм Грузиянең сәяси эшлеклесе. 1907 елда II Думага әгъза итеп сайлана. Думаның социал-демократик бүлеге рәисе һәм аграр комиссия әгъзасы була.

[135+] *Дума куылган, Думадагы социал-демократия фракциясенең илле әгъзасы кулга алынган* – сул партияләр вәкилләре белән Столыпин җитәкләгән хөкүмәт арасында килешмәүчәнлек мөнәсәбәтләре аркасында патша Николай II Икенче Дәүләт Думасын тарата һәм андагы социал-демократлар фракциясен – барлыгы 50 (1934 елгы варинта – 65?) кешене кулга алып судка бирә, Себергә сөрә.

[136+] *Столыпин* – П.А. Столыпин (1862-1911), патша Россиясендә дәүләт эшлеклесе, 1906-1911 елларда Эчке эшләр министры һәм шул ук вакытта Министрлар советы рәисе. XX гасыр башында Россия тарихында, беренче чиратта, реформатор буларак танылa. Илнең икътисадын күтәрү юлында әһәмиятле реформалар үткәрә. Авылда аграр реформа булдырып, кулак хуҗалыкларын ныгытучы, шул ук вакытта революция хәрәкәтен кан эчендә бастыручы да ул. Тарихта диктаторлыгы, кансызлыгы, эшчеләр сыйныфына, ярлы һәм урта хәлле крестьяннарга каршы алып барган терроры, репрессияләре белән мәгълүм.

[137+] *Государственный переворот ясалды!* – 1917 елның июнендә император Николай II Икенче Дәүләт думасын вакытыннан алда тарата. Бу вакыйга дәүләтнең төп законының 87 матдәсен сайлау законын бозуга китерә. Чөнки сайлай законын Дәүләт думасы һәм Дәүләт советы килешүе белән генә үзгәртергә мөмкин. Икенче төрле бу вакыйганы 3 июнь перевороты дип тә йөртәләр.

[138+] *Анда: “Кулым куйдым, тамгам салдым”, – дип, йөзләрчә кешенең исеме язылган, чүкеч, урак, дага, ыргак сурәтләре төшерелгән иде...* – биредә документларга имза урынына нәсел тамгасы кую турында сүз бара.

[139+] *“Бәянел-хак”* – 1906-1914 елларда Казанда татар телендә чыккан, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Динне һәм милләтчеләрне яклый. Эчтәлегендә халыкның мәдәни тормышы, милли традицияләре, театр, музыка һәм әдәбият яңалыклары, сәүдә игъланнары яктыртыла. Барлыгы 1307 дөнья күрә.

[140+] *“Йолдыз”*– иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Баш мөхәррире – Һади Максуди, сәркатибе Галиәсгар Камал була. Газетада Россия һәм мөселман илләре турында фәнни-популяр мәкаләләр, иҗтимагый-сәяси тормышны яктырткан аналитик язмалар басыла. Мәгариф,

укыту, тәрбия мәсьәләләре дә шактый яктыртыла. Газетада даими рәвештә Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмдиев мәкаләләре басыла.

"Йолдыз" революциягә кадәрге татар басмалары арасында иң абруйлы, тотрыклы газеталарның берсе итеп санала. Россиянең татарлар яшәгән күп төбәкләрендә тарала.

[141+] *"Вакыт"* – 1906-1918 елларда Оренбургта татар телендә чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Баш мөхәррире – Фатих Кәрими, наширләре – Шакир һәм Закир Рәмиевләр. Биредә Россия һәм чит ил хәбәрләре, дини һәм милли мәсьәләләр яктыртыла. "Вакыт" битләрендә әдәбият, тел, музыка, театр, мәгариф, мөселман хатын-кызларының гаиләдәге роле һ.б. багышланган мәкаләләргә урын бирелә. Үз заманында барлык татар матбугатына үрнәк булып тора. "Вакыт" Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә тарала.

[142+] *Коковцев* – В.Н. Коковцев (1858-1926), патша хөкүмәтенең күренекле чиновнигы, 1906-1914 елларда финанс министры; 1911-1914 елларда Министрлар советы рәисе дә; хөкүмәтнең финанс һәм бюджет мәсьәләләрен тикшергәндә Дәүләт думасының хокукларын чикләү өчен көрәш алып барган кеше. «Доходлы урын чиновнигы Коковцев Думада, барыннан да бигрәк, доходсыз урын чиновникларыннан Шингарев һәм Аджемов белән бәхәсләште»[*]. Романда сүз шушы бәхәс турында бара.

[143+] *Шингаров* – А.И. Шингарев (1869 – 1918), II, III һәм IV Дәүләт Думасы депутаты; кадетлар фракциясе җитәкчесе. Думадагы бюджет һәм азык-төлек комиссияләренең члены.

[144+] *Фатих Кәримиләрне, Рәшид казый, Тупчибашларны, Акчураларны...* – XX гасыр башы татар милли хәрәкәте җитәкчеләре, мәгърифәтчеләр, җәмәгать эшлеклеләре.

*Фатих Кәрими* – 71 искәрмәне карагыз.

*Рәшид казый* – Рәшит Ибраһимов, 64 искәрмәне карагыз.

*Тупчибашларны* – Галимәрдән Галиәкбәр улы Тупчибашев (1862–1934) азәрбәйҗан җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, юрист, журналист, I Дәүләт Думасы депутаты. "Иттифак әл-мөслимин" партиясен оештыруылардан, аның Үзәк Комитеты әгъзасы.

*Акчураларны* – Йосыф Хәсән улы Акчурин (1876–1935), җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, язучы, журналист. «Иттифак әл-Мөслимин« партиясе җитәкчеләреннән берсе.

[145+] *Гаспринскийны* – Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), фикер иясе, педагог, журналист. "Тәрҗемен" газетасының нашире, оештыручысы һәм

---

[*] Ленин В. И. Әсәрләр / рус телендә, 4 нче басма. – Т. XIII. – Б. 400.

мөхәррире. Җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. “Мөселман иттифакы” партиясе җитәкчеләренең берсе буларак, И.Гаспринский “Тәрҗеман” газетасы аша эшчеләрне сыйнфый көрәштән читләшергә, мөселманнарга сәясәттә кайсы юлны тотарга, кайсы телдә сөйләшергә кирәклеген пропагандалый. Г.Ибраһимов биредә шушы якка да ишарәле кебек.

[146+] *Столыпин галстугы* – бу сүз белән дар агачын атап йөрткәннәр.

[147+] *Бебель – Аугуст Бебель* (1840 – 1913) – Германия социал-демократлар партиясен һәм II Интернационалны оештыручыларның берсе. Аугуст Бебельнең бөтендөнья эшчеләр хәрәкәте чорындагы, бигрәк тә К.Маркс һәм Ф.Энгельс тәгълиматлары тәэсирендә эшләгән чактагы зур хезмәтләре билгеле.

[148+] *Каутский* – Карл Каутский (1854-1938), Германия социал-демократлар партиясе һәм II Интернационал җитәкчеләреннән берсе, марксизмга хыянәт иткән кеше, уң социалистларның идея остазы һәм аңа юл башлап җибәрүче.

[149+] *Беренче “Анна” тагачаклар* – император Павел I тарафыннан 1797 елда кертелгән 1 (иң югары дәрәҗәдәге) изге Анна ордены.

[150+] *Акатуйга җиткерми...* – Акатуй – Себердәге Акатуй авылы. 1832-1917 елларда биредә каторга төрмәсе урнашкан була.

[151+] *“Мохтәсар әл-викайә” белән “Фәраиз әл-Сиражҗийә”не* – мәдрәсә дәреслекләре.

*“Мохтәсар әл-викайә”* – фикх дәреслеге. Авторы – Борһанетдин Мәхмүд бин Садрашшәрига. Бу хезмәт Али Әбу Бәкер әл-Мәргинанинең хокук турындагы “Башлап өйрәнүчеләрнең беренче нигезләре” исемле киң таралган кулланмасына шәрехләү булып тора.

*“Фәраизу әл-Сиражҗийә”* – ислам хокукы өлкәсендә милек бүлешү турындагы хезмәт. Ул Көнчыгышта да, Казанда да киң таралаган була. Авторы – Сираҗетдин Әбу Таһир Мөхәммәд бин Мөхәммәд Габдеррәшит әс-Сәҗәвәнди.

[152+] *Һизиядның “Пандора” дигән легендасы* – Гесиод легендасы буенча, Пандора – борынгы грек мифологиясендә, Зевс кушуы буенча, кешеләргә, ут урлаган өчен, җәза буларак җибәрелгән хатын-кыз.

[153+] *Аллалар атасы “Зевс”* – борынгы грек мифологиясендә күк алласы.

[154+] *“Заратустра”* – немец философы Фридрих Ницшеның (117 нче искәрмәне кара) «Заратустра шулай әйтте» исемле китабы. Бу әсәрендә ул «башкалардан югары булган» кеше образын дөньяда булмаганча идеаллаштырып, һәр яктан камил, батыр, кыю итеп тасвирлый. Аның уенча, шундый кешеләр капитализмны һәлакәттән коткарып калырга тиешләр. «Башкалардан югары булган» бу кешенең чын йөзе философның икенче

әсәрләрендә тагын да ачыла төшә. Ул анда кыргый, явыз инстинктлар белән сугарылган, шуңа җаны-тәне белән бирелгән яңа варварга әверелә.